Таһир Кәрим

# ҖИДЕ БАБАҢНЫ БЕЛ, КАТАЙЛЫМ

*Башкортстанның Бакалы районы Катай авылы нәселләре тарихы*



ТАҺИР КӘРИМ

# ҖИДЕ БАБАҢНЫ БЕЛ, КАТАЙЛЫМ

Башкортстанның Бакалы районы
Катай авылы нәселләре тарихы

Казан
«Яз» нәшрияты
2020

ББК 63.3
К95

**Кәримов Т.Т.**

**К95** Җиде бабаңны бел, катайлым: Башкортстанның Бакалы районы Катай авылы нәселләре тарихы. – Казан: Яз, 2020. – 384 б., төс. рәс. белән

978-5-6044519-3-9

Тарихчы-галим һәм язучы бу хезмәтен туган авылы Катай нәселләренә багышлап, «Үткәннәрен бел Катайның» (Казан, 2018) китабының дәвамы буларак нәшер итә. Бер өлеше 1999 елда язылган, соңгы елларда шактый тулыландырылган бу китап белән автор нәсел тарихларына игътибарны арттыра, татар генеалогиясен фәнни күзәтүләр һәм яңа фикерләр белән баета. Туган авылының үткәне, нәселләре һәм кешеләре темасын алга таба дәвам итеп, автор киләчәктә «Үткәннәргә карап уйланам» исемле өченче китабын бастырырга ниятли.

Белешмәләр өчен: tkarimov@bk.ru

ISBN 978-5-6044519-3-9

© Кәримов Т.Т., 2020
© «Яз» нәшрияты, 2020

# Сүз башы

Элек-электән мөселман кешесе үзенең җиде бабасын белүне фарыз санаган. Нәсел агачы (шәҗәрә) төзеп, аны ядкарь итеп саклау, киләчәк буыннарга калдыру изге гамәлләрнең берсе буларак кабул ителгән. Бүгенге көндә дә шәҗәрәләргә зур игътибар бирелә, мәктәпләрдә төрле чаралар, республика күләмендә конкурслар оештырыла.

Үз нәселеңнең тарихын өйрәнү — туган төбәгеңнең үткән чорларын белү кебек үк әһәмиятле. «Үткәннәрен бел Катайның» китабын язганда, нәселләр тарихына аерым бүлек багышлаган идем. Ул — китабымның иң зур бүлеге булды, шуңа да карамастан, аны тагын да тулыландыру мөмкинчелеге бар иде. Уйлап-уйлап карадым да, ә ник аны нәселләр тарихыннан гына торган аерым китап итмәскә дигән фикергә килдем. Менә шулай авылыма багышланган тагын бер китап чыгару нияте туды.

«Үткәннәрен бел Катайның» китабын типографиягә тапшыру белән җиң сызганып эшкә тотындым, җентекләп өйрәнү өчен архивтан метрикә кенәгәләренең үземдә булмаган күчермәләрен сорап алдым, үз нәселләре турында мәгълүмат, истәлекле фоторәсемнәр сорап авылдашларыма мөрәҗәгать иттем. 2018–2020 елларда бик күп өстәмәләр керттем, китапның күләмен шактыйга арттырдым.

Китабымның күләме никадәр зур булуга карамастан, барлык нәселләр тарихы бертигез дәрәҗәдә тулы ачылды дип әйтергә батырчылык итмәс идем. Ни өчен дигәндә, авылыбыз шулкадәр зур ки, аның Иске һәм Яңа Катай яклары һәрберсе аерым китапка лаек. Кул астында булган чыганакларны өйрәнү генә дә бик күп вакыт таләп итте, шуңа да карамастан, аларның мөмкинчелеге тулысынча эшкә җигелде дип әйтә алмыйм. Нәселләр тарихы — киң колачлы тема, аны бер китап рамкасында гына тулы ачып бетереп тә булмый.

Башка авылларның үз нәселләре тарихына багышланган аерым фәннипопуляр китабы бармы, тәгаен әйтә алмыйм, ишеткәнем булмады. Фәкать үземнең беренче тәҗрибәм «Ата-бабалар иле Камышлы» (2002 ел) дип аталган, районыбызның Камышлы авылы тарихына бәйле рәвештә чыккан китабымда чагылыш тапты. Ул авылның нәселләре тарихына зур игътибар биреп, «Нәсел-нәсәбең кайдан?» бүлеген шуңа багышладым, башка китаплар язганда да бу тема һәрвакыт күз уңында булды.

Катай 1917 елга чаклы — биш мәчете, биш йөздән артык хуҗалыгы булган зур авыл. Шул мәчетләрнең метрикәләрен өйрәнү генә түгел, авылда кемнәр

яшәгән яисә яши, кем кайсы нәселгә карый — барысын да белү мөһим. Катай тарихын язарга керешкәндә миңа зур бәхет тәтеде: туксанынчы елларда авылның үткәнен, нәселләрен белгән ак сакаллы авылдашларым белән аралаштым, алардан сораштырып күп мәгълүмат язып алдым. Соңгы елларда да халыктан истәлекләр җыюны дәвам иттем, авылдашларым белән аралашып-хәбәрләшеп яшәдем. Хәтер сандыгыннан чыгарылган гаять әһәмиятле мәгълүмат бер читтә калса, китабым күп нәрсә югалткан булыр иде.

Нәселләр тарихын өйрәнү фәнни телдә генеалогия дип атала. Бу китап — фәнни югарылыкта башкарылган генеалогик эзләнүләр нәтиҗәсе. Иске һәм Яңа Катайдагы төп нәселләрне ачыклар өчен автор нәсел тамгаларын өйрәнде, архив мәгълүматын киң кулланып, аксакалларыбыз сөйләгәннәрне тулыландырды, дәлилли төште.

Китап авылдашларымның һәм милләттәшләремнең үз нәселен белү, өйрәнү теләген уятса яисә арттырса, аларны яңа мәгълүмат белән кызыксындырса, автор үзенең максаты үтәлде дип саный ала. Бабаларыбыз белән рухи якынлыкны тоеп, алар турында истәлекләрне кадерләп сакласак, киләчәк буыннарга язып яисә әйтеп калдырсак, алар рухына багышлап дога кылсак, шуннан да зуррак изге эш булмас, шәт.

Киң колачлы фәнни-иҗади эзләнүләр алып барганда, авторның аерым нәселләргә багышлап китаплар да язганы булды. Бу китаптагы мәгълүматка таянып, теләге һәм мөмкинчелеге булган һәркем үз нәселе тарихын китап итеп яза яисә яздыра ала. Болай иткәндә нәсел тарихы беркайчан да югалмаячак, киләчәк буыннарга рухи мирас булып калачак.

Катай нәселләренә багышланган бу китабымның әһәмияте авылыбыз белән генә чикләнмәс, монда китерелгән фактлар, кызыклы күзәтүләр татар тарихын өйрәнүче галимнәребез игътибарын да җәлеп итәр дип уйлыйм. Мондый китаплар күбрәк булсын, тарихыбыз тагын да баесын, тулылана төшсен иде. Шундый тарихлар күп булганда милләтебез өчен горурлык тагын да артачак, татарның дөнья-ил тарихында роле калку күренәчәк.

# I бүлек.
# Җиде бабам эзеннән

Мөселман кешесе элек-электән үзенең җиде бабасын белүне фарыз санаган, дип әйткән идек. Кызганыч, Катай буенча үткән гасырлардан бернинди дә язма истәлек калмаган. Картлар сөйләве буенча, ерак бабаларыбыз күрсәтелгән шәҗәрәләребез булган, тик «искелек» калдыгы дип олау-олау китапларны яндыру заманнарында алары да юкка чыккан. Шулай да берничә кешедә узган гасырның туксанынчы елларында төзелгән шәҗәрәләрне күрдем, әмма ишетеп-сорашып белгән дүрт-биш буыннан артмаганлыктан, аларның гыйльми әһәмияте чамалы иде.

«Үткәннәрен бел Катайның» китабында авылыбызның борынгы чорда Кыргыз олысына керүе хакында әйтеп үткән идек. Шул олыска кергән Иске Күктау авылының шәҗәрәсе сакланган икән. Бу хакта шул авыл кешесе Фидан Мәрваровның «Шәҗәрәңне беләсеңме?» исемле язмасы сөйли. Автор болай дип яза: «Шәҗәрә уртасында зур түгәрәктә безнең ерак буын бабаларыбызның исемнәре язылган. Әвәл Җана-би, Кушук-би, Аккуш-би, Бутамыш-би. Зур түгәрәк янындагы кече түгәрәкләрдә биш исем язылган: Тәнеч, Тутай, Кулчан, Байсар, Бурый. Болары Күккүз-би малайлары булырга тиеш. Ә Күккүз-би үзе Кушук-бинең улы булган [...]. Шәҗәрәгә Байсар һәм Кулчан нәселләренең 9–10 буыннан соңгылары язылмаган. Димәк, аларның соңгы буыннарын язу XIX гасыр башларында тукталган. «Байсар морза килде, нәселе аураткан» – дигән язу бар. Бу нәселләрнең икенче җирләргә күчеп киткән булулары мөмкин»[1].

1996 елда автор бу хакта үзе белгәндерме-юкмы, әмма аның язмасындагы исемнәр (Күккүз, Тәнеч, Байсар һ.б.) күп кенә архив документлары белән раслана. Тәнеч архив чыганакларында Тенәч дип күрсәтелә. Кулчан белән Тенәч Күккүзовлар шул ук Кыргыз олысының Иске Кыргыз авылында (хәзерге Илеш районына керә) яшәгәннәр, мондагы биләмәләренә хокукларын раслап Алексей Михайлович исемле патшадан 1632 елда грамота алганнар. Аларның җирләре искиткеч зур була, чикләре Агыйдел, Дала Зәе, Актаныш, Ютазы, Димескәй, Үзән елгаларына чаклы җиткән, биләмәләрендә Сөн һәм Ык елгалары аккан[2].

Бер нәсел кешеләренең әллә күпме авылларга, еракларга таралып урнашуы тарихтан мәгълүм. Шул ук Кулчан белән Тенәч Күккүзовның нәселе Иске

[1] «Маяк», Азнакай район газетасы, 1996 ел, 20 февраль.

[2] БҮДТА, ф. И-2, 1 тасв., 3090 сакл. бер., б.341–343.

Күктау һәм Иске Кыргыз авыллары белән генә түгел, Катай белән дә бәйле икән. Кулчанның оныгы Бикмөхәммәт кардәшләре белән Катай авылына килеп утырган. Бикмөхәммәтнең Хөсәен исемле бер улы булып, ул 1700 елда кардәшләре белән бөтенләйгә Ташлы авылына күченгән. Бу авыл бүгенге Татарстан республикасының Баулы районына карый[1].

Кыргыз олысында яшәгән ерак бабаларыбызның нәсел тарихы Казан ханлыгына, аннан да тирәнгәрәк чорларга барып тоташа. Ф. Мәрваров язмасында Байсар юкка гына морза дип әйтелмәгән. Казан ханлыгын урыслар басып алганчы, татар дәүләтендә дворян дәрәҗәсенә тиң титул саналган ул. Кыргыз олысы старостасы Байсар морза Тенәчовның (ул Тенәч Күккүзовның улы) исеме тагын Катай һәм Күктау авыллары белән бәйле 1727—1750 елгы документларда да телгә алынуын әйтеп үтәргә кирәк. Бу вакытта олыс старшинасы Күктау кешесе Атнагол Сөлеков була. Ике авыл — Катай белән Күктау — шулкадәр бер-берсе белән бәйле була ки, Атнагол Сөлеков (кайбер очракта исеме Атнагол Сөләев дип хаталы языла) еш кына Катай кешесе дип тә күрсәтелә. Менә кайсы чорларга, шул чор шәхесләренә барып тоташа икән безнең бабаларыбызның нәсел тарихы!



**«Казанской дороги Киргиской волости деревни Катаевы» дигән юллардан соң, астарак «старосты Баисары Тенишева» дип язылган. БҮДТА, И-2 фонд, 1 тасв., 3866 сакл. бер.**

«История башкирских родов. Кыргыз» китабында[2] Иске Кыргыз авылы тарихы бирелә, әмма анда Ф. Мәрваровның морзалык турындагы сүзләрен тапмыйбыз. Чөнки морзалык башкорт, кыргыз кебек күчмә халыкларга ят нәрсә, үз дәүләте белән яшәгән татарга гына хас. Шул китап авторларының берсенә әйләнгән Ф. Мәрваров «Иске Күктау авылы тарихы»нда «Кыргыз авылы барлыкка килү — ыру халкының күчмә тормыштан туктап, ярым күчмә яшәү рәвешенә күчә башлау чорына туры килә», дип яза[3]. Монысы ин-

[1] М. Әхмәтҗанов. Татар шәҗәрәләре.— Казан, 1995, б. 48.

[2] История башкирских родов. Кыргыз. Уфа, 2015.

[3] История башкирских родов. Кыргыз, б. 85

де – тарихны бозу, китап төзүчеләргә бу юллар бик хуш килгән, анда урын тапкан. Бабаларыбыз гел утрак тормыш белән яшәгәнен, башкорт һәм башка дала халыклары (кыргыз, казах һәм башкалар) кебек тирмә корып җәйләүдән җәйләүгә күчеп йөрмәгәнен башкача ничек аңлатасың? Әнә шундый буш сүзләр белән: кайчандыр алар да күчеп йөргән, имеш. Тик бу турыда борынгы чорга караган архив документларында бер сүз дә әйтелми, чыганаклар бары тик этник (милли) башкортның һәм башка дала халыкларының гына күчмә тормышта яшәвен күрсәтә.

Шул ук китапта берничә юлда Катай тарихы турында мәгълүмат бирелә. Ул мәгълүматта иң әһәмиятлесе – башкорт белән типтәрне сословие дип бирү («сословные группы» дип язалар). Аларны сословие дип язарга ерак бабаларымның җир мәсьәләсе аркасында өстенлекле башкорт сословиесенә күчәргә омтылышы турында сөйләүче документ саклану мәҗбүр иткән, күрәсең, башка авыллар буенча бер дә сословие дип язмыйлар. Ул документка гадел һәм тәфсилле аңлатма бирәсе урынга, китап авторлары бөтен Катай халкы этник башкортлар, шуңа типтәрләрнең дә башкорт булып язылачы килгән дигән шаккатырлык нәтиҗә ясап куялар.

Ә инде кыргыз Исәнгилде Мингалиев һәм төрек Акмирза Даутовның ничек Катай «башкорт»ы булып китүен алар бөтенләй белми яисә күрмәмешкә салыша. Ревизия документларында «башкорт» дип язылган кыргызлар еш очрый, китапның бу бүлегендә махсус тукталып тормыйм, җай чыккан саен бу хакта гел әйтәм.

«Башкорт» булып язылырга типтәр сословиесендәге 83 кеше омтылган, 58 кеше (бу китаптагы Табыш һәм Гобәй нәселләре) «башкорт»лыкка бөтенләй дәгъва кылмаган. Ник бу хакта әйтмиләр? 1762 елгы мәгълүмат китерелгән әдәбиятта һәм архив документларында шул ук типтәрләр ясаклы татар дип языла бит, бу хакта да әйтергә кирәк иде. Ә инде 1917 елга чаклы «башкорт» дип теркәлгән Күчемовларның ерак бабасының туганы архив документында татар дип язылуын алар бөтенләй белми яисә белмәмешкә салыша, ә менә Фнүн Күчемованың кызы Фәгыйләдән туган оныгы Нурия авызыннан без башкортлар дип әйттерә. Китапның төп максаты – башкортлаштыру сәясәтен аклау, тарихны шул сәясәткә яраклаштырып аңлату, интерпретация бирү. Төбәк татарлары үзләренең бабалары «башкорт» булуы турында белмиләр икән, китапның төп авторы-идеологы С. Хәмидуллин кереш сүздә аларны нәселен белмәгән Иван («Иванами, не помнящими родства», диелә китапның 7 нче битендә) булмаска чакыра. Аларның китабын укып, татарлыгыңнан ваз кичсәң, мескен Иван булмыйсың, күрәсең. Җиде буын бабаңны белү-белмәү турында сүз бармый монда, аларга синең башкорт булуың кирәк икән. Китап тарихны бозып, Бакалы, Илеш, Шаран һәм башка район татарларына әби-бабайларының «башкорт» икәнлеген сеңдереп, тагын бер халык санын алу вакытында «башкорт» дип язылырга өнди кебек. Язылырга теләмәсәләр, шул китапка таянып, «баш-

корт» дип язып куюлары да ихтимал. Һәр халык санын алу саен Башкортстанда яшәүче татарлар кими, башкортлар гел артып бара түгелме?

«История башкирских родов. Кыргыз» китабы фәнниме-юкмы икәнлеге түбәндәге юлларда чагыла: «III ревизия населения (1762 г.) учла тогда 44 ревизские души тептярей (башкиры до 1795 г. переписями населения не учитывались). V ревизия (1795 г.) зафиксировала в Катаево 141 башкира». 141 башкорт дигәннәрен «типтәр» дип укыгыз, чөнки алар 1762 елда типтәр дип күрсәтелгәннәр, шуңа 1795 елда да типтәр булып калалар, ә башкортлар исәбен исә VI ревизия (1811 ел) дә генә ала башлыйлар. Авторлар бу безнең хата түгел, «Бакалинская земля: история и люди» китабыныкы дип әйтергә мөмкин[1]. Фәннилек нинди әдәбиятны-чыганакны кулланасың, мәгълүмат төгәлме-юкмы икәнлеген белеп, тикшереп кулланудан, төгәл булмаса, тәнкыйть итүдән гыйбарәт. «Бакалинская земля: история и люди» китабын алсак, андагы мәгълүматлар фәнни түгел, мәктәп укытучыларын әвеш-тәвеш китереп тарих язарга мәҗбүр иттеләр ул чакта, андагы һәр бит-юл саен диярлек хаталар «История башкирских родов. Кыргыз» китабына да күчкәннәр (башка хаталарга махсус тукталып тормыйм). Бу юллар авторын Бакалыга махсус чакырсалар да, ул «Бакалинская земля: история и люди» китабын язуда катнашмады, чөнки район хакимияте башлыгы урынбасары башкортлыкны алга сөрә, халыкны башкорт дип язылырга төп өндәүче-мәҗбүр итүче иде. Шул китапка җавап, туып-үскән районына бүләк итеп, автор 1995 елда язылган «Очерки по истории Бакалинского района» кульязма китабына әйләнеп кайтырга, аны тулыландырып чыгарырга ниятли.

Катай авылының кайчан нигезләнүе турында үз фикеремне 2018 елда чыккан китабымда әйткән идем, тик ул вакытта тагын бер китап чыгару ниятем булганлыктан, шәҗәрәләргә тукталып тормадым. Ф. Мәрваров язмасындагы шәҗәрә мәгълүматына, архив һәм башка чыганакларга таянып дәлилле әйтәбез: Катай һәм районыбызның башка татар авыллары нигезләнү өчен шартлар 1632 елдан соң гына туа. Ә инде авылымны нигезләүчеләрнең шул елда патша хөкүмәтеннән җиргә хокук (грамота) алучыларның кемнәредер (оныклары, кан-кардәшләре, танышлары һәм башкалар) дип фараз кылсак, Катай шул йөзьеллыкның соңгы чирегендә барлыкка килә дип әйтәбез. Алдарак телгә алып үткән чыганакта бер катайлының 1700 елда башка авылга күчеп утыруы бу фикерне дәлилли төшә.

Бу бүлек башында шәҗәрәләребез булган, әмма юкка чыккан дип әйттек. Документларга һәм хәтер янчыкларына таянып, авылыбыздагы зур һәм киң тармакланган нәселләрнең шәҗәрәләрен үзем төзеп карарга булдым. Төп максат итеп бабаларыбызны җиденче яисә аннан да тирәнрәк буынга чаклы ачыклауны куйдым.

Мавыктыргыч та, шул ук вакытта искиткеч җаваплы вә четерекле дә булып чыкты бу эш! Кайбер мәгълүматны бөртекләп диярлек, өйдән-өйгә йөреп,

---

[1] Бакалинская земля: история и люди. Уфа, 2010.

кешеләрдән сораштыра-сораштыра җыярга туры килде. Әмма, бер башлагач, кая инде ярты юлда туктап каласың! Авылыбыз шактый зур, шунлыктан төп игътибарны үткән гасырлардан ук яшәп килүче нәселләргә юнәлтергә туры килде. Инде кем дә булса үзенең бабаларын китапта тапмаган икән, кулына каләм алып, бу һәм 2018 елда чыккан китап кушымтасында бирелгән исемлекләр буенча йөртеп чыксын иде. Үз нәселе турында тулырак белергә теләүчеләргә дә бу исемлекләр шактый кызыклы мәгълүмат бирер.

Китабымның алдагы бүлекләре белән танышканда кызыксынучан зирәк укучы гыйбрәтле күзәтүләр, нәтиҗәләр ясар, әмма бер нәрсә хакында әйтеп китми мөмкин түгелдер. Ул да булса, берничә нәселнең ничек тармакланып, гасырлар буена авылның зураюына китерүе. Уйлап карасаң, Катай авылының зур авыл булып китүе дә җиде-сигез нәселгә бәйле. Җиде дип шуңа әйтәм, берсе (Бишенде) Катайга унтугызынчы гасырда гына килеп утырган. Әлеге нәселләрнең башы кайбер очракта XVII гасырга ук барып тоташа. Иске Катайда болар биш нәсел (Юлдаш, Моталлап, Табыш, Гобәй, Бишенде нәселләре) булса, Яңа Катайда өч нәсел (Арсланбәк, Азамат, Күчем) тәшкил итә.

«Үткәннәрен бел Катайның» китабын язганда нәселләр күбрәк тоелган иде, метрикәләрне тулырак өйрәнгәч һәм нәсел тамгаларын анализлагач, Катайда сигез нәсел барлыгы ачыкланды, элек аерым нәсел саналганнар ерак нәселдәш булып чыкты. Өстәвенә, ерак нәселдәшләр Катайда гына түгел, башка авылларда да булуын раслаучы фактлар калкып чыкты.

Нәселләр тарихын Башкортстан Үзәк дәүләт тарих архивында (алга таба БҮДТА дип языла) саклапучы Катай авылы метрикәләреннән һәм халык санын алу документларыннан башка эзлекле һәм дәлилле ачыклап та булмас иде. Шуңа күрә китабымның алдагы бүлеген бу гаять әһәмиятле чыганакларны тасвирлауга багышладым.

## II бүлек.
## Метрикәләр һәм халык санын алу документлары – төп чыганак

Нәсел тарихын ачыклаганда иң беренче чиратта метрикә язуларын тирән өйрәнү мәслихәт. Гарәп хәрефләре белән язылганлыктан, күнекмәсе булмаган кешегә аларны уку чиктән тыш авыр, тиешле әзерлеге булмаганнарга, бәлки, мөмкин дә түгелдер. Гарәп имлясын гына өйрәнү җитми, татар исемнәренең дөрес язылышын-әйтелешен белү дә кирәктер.

Исемнәр дигәннән, алар татарда бик күп, ерак бабаларыбыздан калган төрки-татар исемнәре дә, дин белән кергән гарәп һәм фарсы алынмалары да. Катай авылы мисалында Азамат, Акмирза, Арслан, Кылычарслан (Кылчан), Миңлебай, Яугилде, Юлдаш, Йортбагыш, Йөзәй кебек XIX гасырга чаклы кулланылган борынгы төрки-татар исемнәрен, ә аннан соң дин йогынтысы көчәю аркасында гарәп һәм фарсыдан кергәннәрен күрәбез.

Метрикәләрдә хәзерге халыкка таныш булмаган, ят тоелган төрки-татар исемнәре шулкадәр күп очрый ки, аларның барысын туплап, аерым бер китап чыгарып булыр иде. Ни өчен дигәндә, «Татар исемнәре» кебек китапларда аларның шактыен тапмыйсың. Димәк, бу китаплар татарның рухи байлыгын тулы чагылдырмый, аларның авторлары метрикәләрне бөтенләй диярлек ачып карамаган булып чыга.

Исемнәр – татарның рухи байлыгы, аның аркылы без күпмедер дәрәҗәдә халкыбызның эчке дөньясын, зәвыгын, фикер тирәнлеген тоя алабыз. Хәзерге кебек исемнәрнең матур яңгырашын түгел, мәгънәсен алгы планга куйган бабаларыбыз. Исемнәр аркылы аларның уй-фикерләре, теләкләре чагылышын табабыз. Моны югарыда санап үткән төрки-татар исемнәре мисалында күрергә була. Кылычарслан (Кылчан) дип исем кушкан икән, димәк, гаилә башлыгы нәсел дәвамчысының кылыч кебек үткен, арсландай көчле булуын теләгән.

Һәр исем менә шулай мәгънәле, фәһемле, үтемле яңгырый. Кыз бала туса, аның матур, зифа, гөл кебек күркәм сыйфатлары булуын теләп кушылган исемнәрне күрәбез. Бу очракта исемнәр хатын-кызларның тормышыбыз бизәге, җылысы, учагы булуын чагылдыра кебек. Нәсел тарихларын яктыртканда кайбер исемнәрнең мәгънәсенә аерым игътибар биреп үтәрбез, бу җәһәттән Гомәр Саттаровның «Татар исемнәре сүзлеге»[1] китабын куллануымны әйтеп үтәм.

---

[1] Г. Саттаров. Татар исемнәре сүзлеге. Казан, 1981.

Метрикәләрдә яңа туган бала атасының сословиесе дә языла. Мәсәлән, Иске һәм Яңа Катайның 1893 елгы метрикәләрендә сословиеләре «башкорт» дип кенә бирелә[1]. Иске Катайның 1899 елгы метрикәсендә бала аталары беренче мәхәлләдә «башкорт», икенче мәхәлләдә «яңа башкорт», Яңа Катайның 1898 елгы метрикәсендә беренче мәхәлләдә «башкорт», икенче мәхәлләдә «иске башкорт» дип күрсәтелә[2].

Сословиеләр турында «Үткәннәрен бел Катайның» китабында тулы һәм дәлилле әйткән идем, тагын искә төшереп үтү урынсыз булмас. «Типтәр»ләр 1855 елдан башлап башкорт-мишәр гаскәрләре командованиесе карамагына күчкәч «яңа башкорт» («башкорт») булып китәләр һәм метрикәләрдә дә шулай язылалар. Ерак бабаларыбыз үз сословиесен күрсәтеп рәсми документларда «типтәрдән башкорт» («башкиры из тептяр») дип тә яза торган булганнар, шундый бер документның күчермәсен «Үткәннәрен бел Катайның» китабының 6 нчы битендә бирдек, бу китапта исә «типтәр»ләрнең 1855 елдан «башкорт» булып китүләрен раслаучы икенче документ фрагментын күрәсез.

Игътибар итсәгез, китапларымда «башкорт» белән «типтәр»не гел сословие дип әйтәм, чөнки 1917 елга чаклы архив документларында шулай языла. Кемнәр бу документларны күрмәмешкә салышып киресен – икесен дә милләт дип – язса, алар тарихка хыянәт итә, ялган юлга баса, ялган тарих яза.



**«…в прошлом 1855 году, все тептяри поступили в башкирское сословие» дип язылган Катайга кагылышлы документта. БҮДТА, И-2 ф., 1 тасв., 3866 сакл. бер.**

Кем 1926 елга чаклы типтәр һәм башкорт дип язылган, әмма гел татарча сөйләшсә-яшәсә, болар – татар. Архив документлары да аларның милләтен татар дип күрсәтә. «Үткәннәрен бел Катайның» китабының 7 нче битендә шундый бер документны бирдем, бу китапта тагын ике документ фрагментын күрәсез. Документтагы Урсай – безнең ерак бабаларыбыз кыз биргән-алган авылларның берсе, хәзерге вакытта Азнакай районына керә. Патша хөкүмәтенә халыкның милләте түгел, сословиесе әһәмиятле булган, шуңа күрә милләт турында сөйләүче чыганаклар аз. Шуны һәм тарихны белмәүчеләрне яисә бозучыларны истә тотып, китап саен мондый документларның күчермәләрен биреп үтәбез.

---

[1] БҮДТА, И-295 ф., 9 тасв., 779 сакл. бер., № 336 (Иске Катай).

[2] БҮДТА, И-295 ф., 9 тасв., 71 сакл. бер. (1899 ел) һәм башкалар.



Особое совѣщаніе для обсужденія и объединенія мѣропріятій по продовольственному дѣлу.

ВСЕРОССІЙСКАЯ СЕЛЬСКОХОЗЯЙСТВЕННАЯ ПЕРЕПИСЬ 1916 ГОДА.

Губернія (область) Самарская. Уѣздъ (округъ) Бугульминскій.
Волость (станица и пр.) Тумутукская. Общество (сельское, поселковое, аульное и пр.) Башкир.
Селеніе (выселокъ, аулъ, улусъ, имѣніе и проч.)
Фамилія, имя и отчество домохозяина
Сословіе или разрядъ крестьянъ Башкиръ (вотчинникъ). Національность татаринъ
Приписной, посторонній, бѣженецъ. (Подчеркнуть).
№ по списку домохозяевъ

Имѣется въ пользо...
Единицъ (душъ и т. п.) надѣла 2
ПАШНИ: Десятинъ
Своей надѣльн.
Своей купчей.
Арендованной.

**«Сословіе или разряд крестьян – башкиръ (вотчинникъ), національность – татаринъ»**

1899 елда Иске Катайның беренче мәхәлләсендә 385 ир-ат һәм 316 хатын-кыз, 16 никах теркәлгән, 11 ир бала һәм 11кыз бала туган, 7 ир бала һәм 24 хатын-кыз мәрхүм булган. Икенче мәхәлләдә 222 ир-ат һәм 225 хатын-кыз, 6 никах теркәлгән, 8 ир бала һәм 4 кыз туган, 4 ир-ат һәм 4 хатын-кыз мәрхүм. Ике мәхәлләдә дә аерылышу очрагы булмаган.



Особое совѣщаніе для обсужденія и объединенія мѣропріятій по продовольственному дѣлу.

ВСЕРОССІЙСКАЯ СЕЛЬСКОХОЗЯЙСТВЕННАЯ ПЕРЕПИСЬ 1916 ГОД

Губернія (область) Самарская. Уѣздъ (округъ) Бугульминскій.
Волость (станица и пр.) Тумутукская. Общество (сельское, поселковое, аульное и пр.) тептярское
Селеніе (выселокъ, аулъ, улусъ, имѣніе и проч.)
Фамилія, имя и отчество домохозяина Шакуръ
Сословіе или разрядъ крестьянъ тептяръ. Національность татаринъ
Приписной, посторонній, бѣженецъ. (Подчеркнуть).
№ по списку домохозяевъ 20

Имѣется въ
Единицъ (душъ и т. п.) надѣла
ПАШНИ:
Своей надѣльн.
Своей купчей.
Арендованной.

**«Сословіе или разрядъ крестьян – тептяръ, національность – татаринъ»**

1899 елда Яңа Катайның беренче мәхәлләсендә 440 ир-ат һәм 427 хатын-кыз, 14 никах, 8 аерылышу теркәлгән, 21 ир бала һәм 14 кыз туган, 19 ир-ат һәм 25 хатын-кыз дөнья куйган. Икенче мәхәлләдә 345 ир-ат һәм 338 хатын-кыз, 18 никах, 2 аерылышу теркәлгән, 16 ир бала һәм 17 кыз туган, 7 ир һәм 7 хатын-кыз мәрхүм.

Катай җиренә кемнәр генә аяк басмаган, бәхет эзләп килеп сыенмаган, гаилә корып яшәп китмәгән! Түбәндә алты елга караган мәгълүматка тукталып үтәм.

1890 елның 30 ноябрендә Самара губернасы Бөгелмә өязе Мактама авылының Хөснулла Габдулла улының кызы Бибигайшә (35 яшь; өченче никах) шул

ук өязнең Габдрахман авылының Сәмәрхан Шәмсетдин улы (38 яшь; өченче никах) белән Яңа Катай мәчетендә никахлаша. Ирнең ризалык шаһитлары булып авылдашлары Юныс Йосыф улы белән Даут Ярмөхәммәт улы күрсәтелә, алар метрикәгә нәсел тамгаларын салганнар.

1897 елның 3 октябрендә Минзәлә өязе Карамалы олысы Ташлыяр авылының Мөхәммәтшакир Мөхәммәтгали улы Мәһдиев кызы Сәхипкамал (18 яшь) шул ук өязнең Нөркәй олысы Азалак авылының Корбангали Җәләлетдин улы (24 яшь) белән никахлаша. Ризалык шаһитлары булып Байсар олысы Аккүз авылыннан Гыйльметдин Сәйфетдин улы белән Ирәкте олысы Вәрәш авылыннан Мөхәммәтвәли Габделкадыйр улы теркәлгәннәр һәм нәсел тамгаларын салганнар. Әлеге никах Яңа Катайның беренче мәхәлләсендә теркәлгән.

1898 елның 6 апрелендә Минзәлә өязе Пучы олысы Усы авылының Габделгани Габдемөэмин улының кызы Кәрамниса (18 яшь) шул ук өязнең Әмәкәй олысы Елан авылының Могыйнетдин Гыймадетдин улы (25 яшь) белән кавыша. 1898 елда тагын Яңа Катайның икенче мәхәлләсендә Тәйсуган белән Әмәкәй, Габдрахман белән Нәдер, Сеңрән белән Габдрахман авылларында туып-үскән кешеләр никахлары теркәлә.

1899 елның 7 ноябрендә беренче мәхәлләдә Килкабызның Гайникамал Шәймәрдан кызы (33 яшь) Минзәлә өязе Ахун авылының Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсабир улы (35 яшь) белән никахка керә.

1899 елның 25 апрелендә икенче мәхәлләдә Самара губернасы Бөгелмә өязе Нәдер авылы ясаклы татары Әхмәтша Дәүләтша улының кызы (21 яшь; икенче никахы) Минзәлә өязе Кәшер олысы Ләшәү авылы ясаклы татары Шиһабетдин Баһаутдин улы Фәйрушов (26 яшь; беренче никахы) белән кавыша.

1899 елның 8 декабрендә икенче мәхәлләдә Килкабызның Мөхәммәтҗан Риян улының кызы Шәмсебану (27 яшь; икенче никах) Казан губернасы Мамадыш өязе Сатыш авылы ясаклы татары Хуҗаҗан Мөхәммәтрәхим улы Колмәтов (35 яшь; икенче никах) белән никахлаша.

Егерменче гасырга күчкәч тә, читтән килеп никахка керүчеләр күп була, аларның саны йөзгә җыеладыр, мөгаен. 1901 елның 1 февралендә Яңа Катайның икенче мәхәлләсендә Самара губернасы Бөгелмә өязе Габдрахман авылының Мифтахетдин Миңлебай улының кызы Фәрхеруй (18 яшь) Тәйсуганның Сәлимгәрәй Габделсаттар улы (23 яшь) белән кавыша. Аларның ризалык шаһитлары булып Карабашның Баһаутдин Низаметдин улы белән Әхмәтсафа Мостафа улы тамгаларын салалар. Шул ук елның 4 ноябрендә Калмашбашның Фәхербанат Габделгалләм кызы (45 яшь; өченче никах) Корычның Әхмәтгали Әхмәтвәли улы (40 яшь; икенче никах) белән никахлаша.

1905 елда Яңа Катайның беренче мәхәлләсендә Әмәкәйнең Нурмөхәммәт Габделхаликъ улының кызы Гайникамал (17 яшь) Байсарның Мөхәммәтшәех Мөхәммәтнәби улы (23 яшь; атасы Мөхәммәтнәби Габделнасыйр улы) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Сеңрәннең Шәрәфетдин Ибраш улы (тамгасы Яңа Катайның Арсланбәк нәселенеке) һәм Еланның Гайнан

Габделгалим улы (тамгасы Иске Катайның Юлдаш нәселенеке белән тәңгәл килә) була. Кияүнең ризалык шаһитлары булып Байсарның Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтҗан улы белән Тимерша Дәүләтша улы теркәлә.

Читтәге милләттәшләребез өчен Катай никахлашу гына түгел, төпләнеп яшәү урыны да булган. Яңа Катайга XIX гасыр ахырында – XX гасыр башларында күчеп килгән нәселләр шулкадәр күп була ки, метрикә кенәгәләре мәгълүматына таянып, аларның яңа туган балаларын кушымтада аерым таблицада күрсәтергә булдым. Ул таблица тулы түгел, аны башка еллар мәгълүматы белән тулыландырсаң, күзәтүләрне аерым тупласаң, китапның яңа бүлеген язарга булыр иде.

Метрикә язмаларын гаҗәпләнеп укый-укый, китапның әһәмияте Катай белән генә чикләнми кебек, дигән нәтиҗәгә килдем. Китапның кушымтасындагы географик атамаларга (топонимнарга) күз салсак, анда Катайдан йөзләрчә чакрым ераклыкта яткан авылларны күрәбез. Авылым үзе кебек башка татар авыллары белән тыгыз элемтәдә булган, милләттәшләренә килен итеп гүзәл кызларын биргән, кода-кодагыйлык мөнәсәбәтләре урнаштырып, тагын да якыная төшкән. Башкорт милләтчеләре Катайны һәм төбәк авылларын башкорт авыллары исемлегенә кертүгә җавап итеп әйтәм: авылларыбыз беркайчан да этник башкортлар белән элемтәгә кермәгән, аларга кызларын да бирмәгән, шуңа этник башкорт яшәгән авылларны бу китаптагы топонимнар исемлегеннән тапмассыз.

Метрикәләрдәге никах язулары – авылларыбызның һәрдаим татарлыгы турында сөйләүче, моны дәлилләүче гадел чыганак. Бу чыганакны өйрәнеп йөзләрчә фәнни хезмәтләр, диплом эшләре, диссертацияләр язарга, татар авылларының татарлыгын шик астына куючыларны фаш итәргә була.

Миңа Бәләбәй, Бөре, Стәрлетамак, Минзәлә, Бөгелмә өязләре метрикәләрен өйрәнергә туры килде, барлык чыганаклар да татар телендә, барысында да татарларның этник башкортлар, ягъни башкорт телендә сөйләшүче авыллар белән элемтәсе күзәтелми. Бу – аларны ят итүдән түгел, алар белән тыгыз рухи-милли бәйләнешләр, тирән якынлык булмаганнан, моңа ихтыяҗ да булмаудан, дип уйларга кирәк. Андый ихтыяҗ булса, башкортларның аз-маз тел үзенчәлекләре, безнең халыкка ят тоелган берничә (мәсәлән, башкортча «өйрәк», татарча «үрдәк» кебек) сүзләре генә кодалашырга тоткарлык ясый алмас иде.

Никах язуларындагы нәсел тамгалары кемнең кайсы нәселгә караганын ачып сала. Бер шәҗәрә эчендә күрсәтелгән кешеләрне нәселдәш дип, шундый ук тамгалы икенче шәҗәрә кешеләрен ерак нәселдәш дип әйтү урынлы булыр. Кайсыдыр бик тирәнгә киткән буында андыйларның уртак бабасы булган, тик чыганаклар җитмәү аркасында кем икәнен белә алмыйбыз, шуңа ерак нәселдәш дип күрсәттек. Үзәге (туры линиясе) ир-ат буыннардан торган, нәсел тамгалары уртак булган шәҗәрәләрне күз алдында тотып, ерак кардәш дип түгел, ерак нәселдәш дип язу фәннирәк һәм төгәлрәк булыр кебек.

Милләтебезнең нәсел тамгалары күбрәк өйрәнүне сорый. Бу китап кысаларында кемнең кайсы нәселгә караганын ачыклау мөһим иде. Катайлыларныкына охшаш, тәңгәл килгән нәсел тамгаларының башка авылларда да булуына игътибар иттек, димәк, бер нәсел кешеләре шулай таралып урнашканнар. Аерым игътибар биреп, махсус өйрәнсәң, бик кызыклы фәнни күзәтүләр ясарга булыр иде.

Тамга традициясе рун язулары чорыннан ук килә, кайбер тамгаларны рун алфавиты хәрефләрен хәтерләтә дип язалар, бу тема яхшы таныш булса да, фәнни мәгълүматка тукталып тормыйбыз. Ерак бабаларыбыз руннан гарәп алфавитына күчкәч тә, нәсел тамгалары сакланган, рәсми язуларда һәм метрикәләрдә чагылыш тапкан. Бабаларыбыз укый-яза белсәләр дә, имза урынына нәсел тамгасын салуны мәгъкуль күргәннәр. Имза кую очраклары бик сирәк, нәсел тамгасы урынына «имзам куйдым» дип гадәттә муллалар һәм мәдрәсә тәмамлаучылар яза торган булган. Никах язуларында һәр вәли вәкил һәм ризалык шаһиты имза куя башласа, ул язмаларның күләме дә артыр иде. Ә тамга исә күп урынны алмый, практик яктан отышлырак һәм аңлаешлырак. Мәктәп-мәдрәсәдән соң бөтенләй диярлек каләм тотмаган, булган күнекмәсен дә онытып барган кешегә тамга салудан да ансатрагы булмаган, әлбәттә. Шулай итеп, инкыйлабка чаклы тамга актуаль булып кала, бернинди кимчелек саналмый, бары тик совет хакимияте урнашкач кына, искелек калдыгы дип кулланудан чыга башлый, ә аннары онытылып, метрикә язуларында гына тарихи ядкарь буларак саклана.

Метрикәләрдән тамгаларны өйрәнгәндә тагын бер нәрсәгә игътибар итәргә кирәк. Теге яисә бу нәселнең тамгасын дөрес ачыклар һәм нәтиҗә ясар өчен мөмкин кадәр күп чыганакка таяну яхшырак булыр. Чөнки бер нәсел вәкиле тамгасы башка нәселдәшләренекеннән тулысынча аерылган очраклар бар. Мәсәлән, 1913 елның 24 гыйнварындагы никах язуында Бәдретдин Яхшыгол улы исеменнән соң бөтенләй башка нәсел тамгасын күрәбез. Мондый очракларны аерым терки-саный башласаң, күпкә җыела, ахыр чиктә, тамга дөрес булмаганга кем гаепле дигән сорау туа. Метрикәләрне дин әһеле алып барган, димәк, андагы хаталар, төгәлсезлекләр өчен ул – җаваплы. Бәдретдин Яхшыгол улы мисалына кайтсак, тамганы ул үзе салмаган, мулла аңа мөрәҗәгать итмичә, аннан сорамыйча үз белдеге белән ничек кирәк, шулай салган булып чыга түгелме?

Катай тамгаларының төгәллеген ачыклаганда рәсми чыганакларга таяндык. Хакимият исеменә җир һәм башка мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать язуында, җир сату яисә аны кулланышка (арендага) бирү, мәчет салу һәм дин әһелләрен сайлау документларында һәр нәсел вәкиле имза урынына тамга сала торган булган. Бу рәсми документлардагы тамгалар бернинди шик уятмый. Ике төрле чыганактагы тамгаларны чагыштырып карау кайбер кызыклы күзәтүләргә китерде. Мәсәлән, рәсми чыганакта бер тамганың төп өлеше (элементы) өчпочмак булса, метрикәдә аны иреклерәк, түгәрәккә охшаган фор-


Канцелярiи Генералъ-Губернатора. ~~482~~ 482

ДѢЛО

По просьбѣ повѣреннаго отъ жителей деревень Катаевой и Курановой Тептяря Абдулвахитова, о прiостановленiи совершенiя въ Оренбургской гражданской палатѣ купчей крѣпости на проданныя Тептярями дер. Токбердиной Титулярному Совѣтнику Ситешникову земли, и проч.

Начато 17 Iюля 1838 года.
Кончено 17 ... 186..

На 318 листахъ

**Катай тарихы буенча гаять әһәмиятле фактлар тупланган «эш»нең (делоның) эчке тышлыгы**

мада күрдек. Рәсми документ булмыйча, метрикә белән генә эш итәргә туры килсә, тамгаларның кайсы дөресрәк, бер нәселнекеме-юкмы дип озак баш ватарга туры килер иде.

Иске Катай тамгалары бер очракта нәселдәшем Габделкаһир Габделвахитов Катай һәм Куян халкы исеменнән җир мәсьәләсе буенча йөргәндә төзелгән бер документта бирелә. Бу мәсьәләне карау озакка сузылып, барлык документлар 1838–1863 елларда Ырынбур генерал-губернаторы канцеляриясендә аерым «эш» (дело) итеп туплана[1]. Мондагы гаять әһәмиятле фактларны «Үткәннәрен бел Катайның» китабын язганда кулланган идем, шуңа нәсел тамгаларына гына тукталып узам.

Әлеге документтагы тамгалар Иске Катайда кайсы нәсел өстенлек иткәнлеген ачык күрсәтә. 1856 елның 26 июнендә тамгаларның яртысын диярлек (14) бер нәсел кешеләре салган, тагын берсе (Габделкаһир Габделвахитов) тамга урынына кул куйган, болар барысы китабымда Юлдаш нәселе дип аталды. Тамгалар саны буенча икенче урында Моталлап нәселе (11 тамга, тагын берсе кул куйган), өченче урында Та-



**Иске Катай нәселләре тамгалары. 1856 ел, 26 июнь**

[1] БҮДТА, И-2 ф., 1 тасв., 4185 сакл. бер.

быш нәселе (4), дүртенче урында Гобәй нәселе (2) тора. Билгеле, мондый нәтиҗәгә килгәнче, без тамга салган 31 кеше тарихын башка документлар буенча өйрәндек, тамгалар үзенчәлеген ачыкладык. Документта Бишенде нәселенең генә тамгасы юк, чөнки алар бу вакытта Иске Катайның рәсми исемлегендә тормаганнар.



**Минзәлә өязе Аеш авылы кешеләре тамгалары. Болар арасында Катайга хас тамгалар да бар. 1856 ел**

Яңа Катай тамгаларына 1753 елгы документта игътибар иттек. Бу документ буенча Арсланбәк, Азамат нәселләре, аларның ерак нәселдәшләре өстенлек иткәнен күрәбез. Күчем нәселеннән Даут Сөләйманов телгә алынса да, башкалар тамга салганда читтә калган. Йөзәй Менәй улы белән Тойгын Касыйм улы тамгалары бары тик бу документта гына бирелә, Катай метрикәләрендә кабатланмый, димәк, бу ике нәсел Катайдан күчеп киткән.

Катайдан «башкорт» Тимергали Габделкәримов 1811–1816 еллар арасында Минзәлә өязе Аеш авылына күчеп утыра. Гаиләсе белән 1834 елда да Катай исемлегендә теркәлүе белән килешмичә, Аеш исемлегенә күчерүне сорап хакимияткә мөрәҗәгать итә. Катай белән Аеш тыгыз элемтәдә була, Тимергали белән бәйле 1856 елгы документта Аеш кешеләренең Катайның Азамат һәм Арсланбәк нәселләренә хас тамга салулары шуны күрсәтә[1].

Метрикәләр буенча сүзебезне тәмамлаганчы әйтик, Бәләбәй өязе буенча беренче метрикә кенәгәсе 1836 елга карый, 1837–1844 елларныкы сакланмаган, 1845 тән 1917 елга чаклы күпчелеге сакланган. Китапта аларның 1870 һәм аннан соңгы елларныкын кулландык, чөнки икенче зур чыганак – халык санын алу документлары – җәлеп ителгәнлектән, барлык сакланган метрикәләрне өйрәнү ихтыяҗы зур түгел иде. Нәсел тарихын язганда 1762, 1795, 1811, 1816, 1832, 1859 елгы халык санын алу (ревизия) һәм 1917 елгы хуҗалыклар санын алу документларын киң кулландык. Халык санын алу документлары китабым-

[1] БҮДТА, И-172 ф., 1 тасв., 22 сакл. бер.


Земскiй Судъ проситъ Коммисiю доставить свѣдѣнiе
были ли представлены оному Начальникомъ 9го Кан
тона Киргизы: Ялбитъ Хамитовъ, Кабатъ Бикку-
ловъ и Абдрияхитъ Дюшевъ, пожелавшiе причи-
слиться въ башкирское сословiе и даномъ на тотъ
рапортъ предписанiе отъ Коммисiи о томъ: когда
и куда эти Киргизы причислены, или отобраны
отъ нихъ Коммисiей показанiя, если все это было
сдѣлано; то прислать копiи. На что Коммисiя
отъ 21 Августа 1835 года за № 2682, препровождая

**Башкорт сословиесендә торучы кыргызлар Катайда гына түгел, башка авылларда да була. «Пожелавшие причислиться въ башкирское сословiе» дип язылган бу документның 4–5 нче юлында**

ның кушымтасында бирелә, ә 1917 елгы хуҗалыклар санын алу документлары «Үткәннәрен бел Катайның» китабы кушымтасында урын алган иде.

Ревизия документлары Иске Катай буенча югарыда санап үтелгән еллар буенча тулысынча булса, Яңа Катайның мондый документлары 1816, 1832 һәм 1859 елларга гына карый. Чөнки башкорт сословиесенә кергәннәрне хөкүмәт бары 1811 елдан гына терки башлый, тик ул елга караганы сакланмаган.

«Үткәннәрен бел Катайның» китабында башкортларның 1917 елга чаклы сословие дип аталуы, ул сословиедә татарлардан башка, кыргызлар да торуы хакында әйткән идем. Кыргызларга бәйле 19 нчы гасыр уртасы документы фрагментын бу китапта бастырам. Аннан күренгәнчә, кыргызлар үзләре теләп башкорт сословиесенә кергәннәр (документта «пожелавшие причислиться в башкирское сословие» дип язылa)[1]. Ни өчен икәнлеге әйтелмәсә дә, аңлашыла: күп җир алыр өчен.

Ревизия документлары метрикә мәгълүматын тулыландырып кына калмый, шәҗәрә буыннарын ишәйтергә, борынгырак буыннарның гомер иткән елларын ачыкларга мөмкинчелек бирә, нәсел тарихын яңа исемнәр һәм кызыклы күзәтүләр белән баета.

Ике чыганак – метрикә белән халык санын алу документлары – мәгълүматын чагыштырып карау соңгысында булган кайбер хаталарны төзәтергә

[1] БҮДТА, И-2 ф., 1 тасв., 1954 сакл. бер., 28 б.

мөмкинчелек бирде. Чөнки халык санын алучылар татар исемнәрен язганда аратирә хата җибәргәли торган булганнәр. Мондый төгәлсезлекләрне Катай авылы исемлекләрендә шактый таптык һәм китап кушымтасында исемнәрнең дөрес вариантын җәя эчендә күрсәтеп үттек.

Метрикәләрдә дә хаталар күп булу күзгә ташлана. Төгәлсезлекләр халык санын алучыларның үз вазифаларын никадәр җаваплы үтәүләренә бәйле булган кебек, монда да дин әһелләренә бәйләп карау кирәктер. Хаталар яңа туган балаларның аналары исемнәрен язганда аеруча күп күзәтелә, алдагы бүлекләрдә моңа игътибар биреп үттек. Әмма күпме булуына карамастан, болар гына бу чыганакның әһәмиятен киметә алмый, әлбәттә.


УТВЕРЖДАЮ
(наименование должности руководителя организации-сдатчика)
Подпись Расшифровка подписи
Дата Печать

УТВЕРЖДАЮ
Директор ГКУ Национальный архив Республики Башкортостан
Подпись Расшифровка подписи
06.04.2017г.
Дата

АКТ
(дата) №
приема-передачи документов на хранение

(основание передачи)
(название передающего фонда)
Новокатаевский с/совет Бакалинского района БАССР сдал.
(название организации-сдатчика)
ГКУ Национальный архив Республики Башкортостан принял документы названного фонда и научно-справочный к ним:

| № п/п | Название, номер описи | Количество экземпляров описи | Количество ед.хр. | Примечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Опись 1 дел постоянного хранения |  | 6 | 34-39 |

**Катай авыл советы кенәгәләрен автор ышанычлы урынга — архивка тапшырды (шуны раслаучы акт)**

Метрикәләрдән тыш, нәселләрне бүгенге көнгә чаклы күзаллау өчен тагын бер әһәмиятле чыганак — сугыш алды еллары һәм сугышның беренче елларындагы Катай хуҗалыклары (гаилә әгъзалары белән) теркәлгән авыл советы кенәгәләре (барысы 6 данә) — ярдәм итте. Бу кенәгәләр тулы сакланмаган, сакланган өлешен, автор фотога төшереп алып калып, юкка чыкмасын дип Башкортстан Үзәк дәүләт архивына илтеп тапшырды. «Үткәннәрен бел Катайның» китабын бастырырга әзерләгәндә, автор архивка мөрәҗәгать итте һәм тапшырганлыкны раслап бирәр документ җибәрүләрен сорады. Архивтан алган документтан күргәнебезчә, әлеге кенәгәләр Яңа Катай авыл советы фондында 34—39 берәмлекләр («дело») буларак саклана. Күпчелек авылларның, тиешле шартлар һәм игътибар булмаганлыктан, мондый кенәгәләре юкка чыккан, ә безнең авылыбызныкы киләчәк буыннарга ядкарь булып мәңге сакланачак, иншалла. Кемнең ул кенәгәләрне кулына алып карыйсы, заман сулышын тоясы, үзен кызыксындырган мәгълүмат эзлисе килә икән, архивка кереп китабымның бу битен күрсәтсен.

Ул кенәгәдәге мәгълүматны бу китап кушымтасында бирергә ниятләсәм дә, ул уйдан кире кайттым. Кенәгәне тутырган авыл советы хезмәткәре исемнәрдә күп кенә хаталар җибәргән, кешеләрнең туган елларын күпчелек очракта документларга нигезләнмичә, чамалап кына язган. Төгәлсезлекләр күп булган мәгълүматны нәкъ кенәгәдәгечә китапта бастырсам, кемнәрдер авторны гаепләр, оятка калдырыр кебек тоелды. Мөмкин кадәр хаталардан арындырып, ул мәгълүматны бу китапта кулландым. Шулай да 1917 елдан соңгы чорга караган исемнәрдә һәм туган елларда хаталар табыла калса, авторның бу чыганакны куллануын истә тотсын иде. Китапта метрикәгә таянып һәр баланың туган елын, көнен һәм аен күрсәтеп бардык, мондый мәгълүмат бернинди шиксез кабул ителә. Авыл советы кенәгәләрен кулланганда, андагы мәгълүматны төгәлсезлекләрдән бөтенләй арындыру мөмкин түгел иде.

# *Иске Катай нәселләре*

Бел син ерак бабайларның
ничек итеп көн иткәнен,
ни иккәнен, ни чиккәнен,
нинди уйлар, нинди моңнар
безгә калдырып киткәнен.

*Р. Фәйзуллин*

## III бүлек.
## Юлдаш нәселе

Иске Катайдагы бик күп кешеләрнең нәсел башы булган Юлдаш карт күптән онытылган, шуңа да карамастан, нәселне аның исеме белән атау дөрес булыр. «Безне электән үк Хәким нәселе дип йөртәләр иде. Хәким картның елкылары күп булган, менә моннан, Мокатдәсләр тыкрыгыннан күпергә чаклы җирләр аныкы булган», дип сөйләгән иде бер чак Хәмит Габдерәхим улы Маликов. Тик менә Хәким картның өченче буын бабасы Юлдаш булганлыгын гына туксанга җитеп килүче аксакалыбыз һич кенә дә искә төшерә алмады.

Нәселдәшем Хәмит абыйның хуҗалыгы ерак бабаларыбызның төп нигезендә урнашкан. Монда беренче килеп утыручылар булганга, алар Маты елгасы буендагы урынны сайлап алганнар. Суның бәрәңге бакчасы итәгендә генә булуы, сөйләп тә торасы юк, уңайлы, өстәвенә җире дә уңдырышлы булган. Бакча артында гына елкылар өчен абзарлар, каравылчы йорты урнашкан. Аларны төзегәндә шул заманда ук кирпеч кулланганнар, күрәсең, әле дә бакча казыганда килеп чыккалый, дип әйткән иде Хәмит абый.

Хәмит Маликовларның күршеләре Габдуллиннар, Әхмәтовлар, берничә йорт аша урнашкан Марат Кәримовлар да, урамның аларга каршы ягындагы кайбер хуҗалыклар да нәселебезгә карый, димәк, алар да төп нигездә яши яисә яшәде. Юлдаш нәселеннән тармакланган башка кан-кардәшләр генә бераз арырак китеп урнашкан, чөнки нәсел нык ишәйгән, бер урамга сыймый башлаган.

Алдарак нәсел башы булып Юлдаш тора дип әйткән идек. Аның уллары Арслан (1706–1787), Сәлим (1710) һәм Сөяргол (1721–1812) булган. Арсланның улы Кылчан 1743–1820 елларда яшәгән.

Монда бер мөһим искәрмә ясап үтик. Югарыда күрсәтелгән затларның туган елларын 1762 елгы документ буенча исәпләп чыгардык. Башка доку-

ментларга таянганда, туган еллары бераз аерылырга мөмкин, чөнки елның төрле айларында төзелгән документлар бары ничә яшьтә икәнлеген күрсәтәләр яисә берникадәр хаталы (мәсәлән, Арсланга 1762 елда 56, 1781 елда 70 яшь дип күрсәтелгән. Димәк, аңа 1781 елда 75 яшь булырга тиеш). Бу искәрмә башка шәҗәрәләргә дә карый, китапны игътибарлы укыган укучы автордан гаеп эзләмәс, дип уйлыйбыз.

Юлдаш, Арслан, Сөяргол, Кылчан – безнең өчен гадәти булмаган, өлешчә кулланыштан чыккан, онытылган борынгы төрки-татар исемнәр. Моның сәбәбе шунда, унсигезенче гасыр урталарында татар дөньясында дин йогынтысы көчәйгәч, төрки-татар исемнәр урынына башлыча гарәп-фарсы алынмаларын куллана башлыйлар.

Юлдаш, Арслан, Сөяргол (Сөяркол; Сөекле кол (иптәш, юлдаш)) исемнәренең мәгънәсе болай да аңлашыла, ә менә Кылчан исеменә аерым тукталып үтү кирәктер. Бу борынгы төрки-татар исеменең тулы варианты – Кылыч Арслан, аны халык кыскартып Кылчан дип әйтә торган булган. Арслан үзенең улына бу исемне кылыч кебек үткен, Арслан кебек кыю, батыр булсын дигән теләктән чыгып кушкан. Кылчанга якын Кылчын дигән борынгы төрки-татар исем дә бар, анысы изге дигән мәгънәне аңлата. Яңа Катайда һәм Иске Дөмәйдә Кылчынның Кылчым варианты кулланыла, шуңа күрә Күчем нәселе турындагы бүлекне укыганда, бу искәрмә игътибар үзәгендә калсын иде.

Кылчан Урсайның (хәзерге вакытта Азнакай районына керә) «башкорт» Салиха Габдулла кызына өйләнә. Аның бердәнбер улы Габделлатыйф (1772–1812) та шул яктагы Митрәйнең «башкорт» Мәхүбә Әмир кызын алып кайта. Кылчанның бер кызы (Насиха) 1790 елда Сеңрән «башкорт»ына, икенчесе (Бәдиһә) 1792 елда Корыч авылы «башкорт»ына кияүгә чыга.

Башкорт дигәч тә, Урсай белән Митрәйдә дә, Сенрән белән Корычта да чын, милли башкортлар беркайчан да булмаган (милли башкортлар белән безнең халык бөтенләй аралашмаган), ә бары тик «башкорт» дип аталучы привилегияле (җирләре ике-өч тапкыр күбрәк) сословиегә кергән татарлар гына яшәгәннәр (1916 елгы хуҗалыклар санын алу вакытында Урсай һәм Митрәй авыллары халкы үзләренең сословиеләрен башкорт, милләтләрен татар дип яздыра; бу документлар Татарстан милли архивында, 478 нче фондта саклана). Күбрәк җир бүлүләрен өмет итеп, Юлдаш картның оныклары да «башкорт» исемен алмакчы булып хакимияткә мөрәҗәгать итеп карыйлар, ниятләре генә барып чыкмый (бу хакта «Үткәннәрен бел Катайның» китабында махсус әйтеп үттек).

Шулай итеп, Кылчан да, аның улы Арслан да хатыннарын еракта алып кайтканнар, кызларын да еракка биргәннәр. Бу – татар авылларының берберсе белән даими элемтәдә, тыгыз аралашып яшәвен чагылдыра. Шундый ук мисаллар һәр нәсел буенча күзәтелә, шуңа күрә башка очракларда моңа махсус басым ясап тормыйбыз.


Особое совѣщаніе для обсужденія и объединенія мѣропріятій по продовольственному дѣлу.
ВСЕРОССІЙСКАЯ СЕЛЬСКОХОЗЯЙСТВЕННАЯ ПЕРЕПИСЬ 1916 ГОДА.
Губернія, область: Самарская
Уѣздъ, округъ: Бугульминскій
Волость, станица и пр.: Бавлинская
Общество (сельское, поселковое, аульное и пр.): Бавлинское
Селеніе, выселокъ, аулъ, улусъ, имѣніе и пр.: дер. Бавлы
Фамилія, имя и отчество домохозяина
Сословіе или разрядъ крестьянъ: башкир
Національность: татар

**Сословіе или разрядъ крестьян башкир, національность татар, дип язылган 1916 елгы документта**

Нәсел таза булсын, бер үк нәсел кешеләренең үзара никахлашуын булдырмас өчен дә шулай эшләнгән дип уйларга кирәк. Чөнки бер үк нәсел кешеләренең үзара никахлашуы кайбер очракларда яңа туган балаларның сәламәт, чыдам иммунитетлы булмавына китерергә мөмкин.

Алдарак әйтеп үтелгән Габделлатыйф – Юлдаштан соң дүртенче буын. Аның бердәнбер улы Габделхәким (1802 елда туган) нәселнең тагын да тармакланып китүенә сәбәпче була. Биш ир бала – Габделгалим (1825), Габделгаллән (1829), Габделшәфикъ (1831), Габделкәрим (1838–04.08.1907), Габделмалик (1841–14.07.1909) – һәм дүрт кыз бала (Җиһанбану (1822), Фәхрибану (1826), Камәрбану (1935), Гыйлембану (1844)) тәрбияләп үстерә ул. Беренче хатыны Фәхриҗамал Мөхәммәтрәхим кызы (1804) була. Габделхәким кызы Камәрбану (18 яшь) 1854 елның 11 гыйнварында Мостафа авылы ясаклы татары Мөхәммәткол Рәхимкол улы (19 яшь; атасы Рәхимкол Габделмәҗит улы) белән кавыша. Ир балаларның барысы да нәсел калдыра, һәрберсе Хәким нәселеннән дип зурлап аталуга сәбәпче була.

Габделгалим Габделхәким улы балалары: Габделхәбир (1851), Латыйфабану (1858), Мөхәммәтсолтан (кайбер метрикә язуларында Солтангәрәй; 1859–21.01.1912), Гаделбану (1867), Батыргәрәй (1880–08.03.1881) һәм Батыргали (16.12.1881–1883). Габделгалим кызы Латыйфабану (18 яшь) 1877 елның 20 гыйнва-



**1854 елгы никах язуында сул якта аста Габделхәким Габделлатыйф улы, уртада уллары Габделгалим белән Габделгаллән тамгалары**

рында Мостафаның Закирҗан Мөхәммәтҗан улы (22 яшь; атасы Мөхәммәтҗан Габдулла улы) белән кавыша. Ни сәбәпледер, бу никах уңышлы булмый, 1880 елда язмышын Кадернең Мөхәммәтвәли Мөхәммәдьяр улы (60 яшь) белән бәйли. Төпчек кызы Гаделбану (18 яшь) 1885 елда Сеңрәннең Шәрәфетдин Габделгалләм улы (21 яшь; атасы Габделгалләм Габделкаһир улы) белән гаилә кора.

Габделхәбир Габделгалим улы балалары: Әхмәтгали (17.02.1876; анасы Гайникамал), Габделгали (1881–12.08.1916, чахоткадан вафат), Исламгали (04.04.1882–02.10.1897, агач басып), Мәгъдәнбану (05.03.1885–1890), Шәехгали (17.09.1889), Шагали (06.01.1893; анасы Гайникамал Хисаметдин кызы). Габделхәбир кызы Хоррәмбану (18 яшь) 1902 елның 7 ноябрендә Иштирәкнең Шаһиҗан Хәбибулла улы (25 яшь; атасы Хәбибулла Нәдергол улы) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Гыймадетдин Гыйлаҗетдин улы белән Әхмәтгали Габделхәбир улы була.

Әхмәтгали Габделхәбир улы балалары: Бибиҗиһан (03.07.1902; анасы Бибисара Исламгали кызы), Әхмәтһади (30.10.1904–1905, кызамыктан вафат), Миңлезәкия (02.06.1906; анасы Бибисара Шәйхелислам кызы), Гайшә (06.06.1908–1909, чәчәк зәхмәтеннән), Тимергали (23.07.1911; анасы Бибисара Шәйхелислам кызы), Бибимәрьям (03.06.1914), Тимершәех (28.10.1916). Тимергали Галиев Ватан сугышына киткәндә йортында хатыны Хәтирә (1910), кызы Фәнә (1938), улы Риф (1941) кала. Сугыштан кайткач, Тимергали Яңа Катайның Шәехимам Вәлиев кызы Дөһедия белән гаилә кора, балалары Рәздания (10.07.1950), Риф (07.03.1953), Миңлеира (09.09.1955) туа. Дөһедия сугыш чорында атлар карый.



**Тимергали белән Дөһедия Галиевләр**

Габделгали Габделхәбир улы балалары: Мөхәммәтхәнәфи (15.12.1907; анасы Бибиәсма Габделфәттах кызы), Бибисаҗидә (10.10.1911; анасы Бибиәсма Фәттахетдин кызы). Бибисаҗидәнең 1969 елның маенда Бакалы загсыннан фамилиясен Галиева дип күрсәтеп, туу турында белешмә алуын 1911 елгы метрикә битенә язганнар.

Габделгалимнең икенче улы Мөхәммәтсолтан (кайбер метрикә язуларында Солтангәрәй; 1859–21.01.1912) иде. Мөхәммәтсолтан Габделгалим улы балалары: Әхмәтгәрәй (25.12.1887; анасы Факия), Мөхәммәтгәрәй (10.05.1890–1914), Бибихәкимә (05.01.1893), Бибиәсма (30.11.1895; анасы Факия – Минзәлә өязе Әгъбәс авылының Биктаһир кызы), Батыргәрәй (03.08.1899), Сабирҗан (03.02.1903; Ватан сугышы ветераны), Бибисаимә (03.04.1906–1995). Мөхәммәтсолтан кызы Бибисаимә авылдашы Шәйшәриф Харисовка кияүгә чыга.

Мөхәммәтсолтанның 18 яшьлек улы Батыргәрәй 1917 елда Габделгалимов фамилиясе белән теркәлгән, абыйсын (25 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алганнар, энесе Сабирҗан һәм өч кыз туганы белән яши, 5,26 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры, бозавы, 3 сарыгы була. Сабирҗан Солтанов (1903) ерак нәселдәше Мөхәммәтислам Мөхәммәтсафа улының кызы Нәгыймә (19.10.1906–09.01.2005) белән никахлаша, балалары Гашия (1929–2016), Дәнә (1937–2003), Миңлерәдиф (1941; сугыш елларында яшьли мәрхүм) туа. Сабирҗан кызы Гашия 1950 елда Яңа Катайның Ватан сугышы ветераны Гыйльфан Афзал улы Фәрвазовка кияүгә чыга. Икенче кызы Дәнә Яңа Катайның Әгъләметдин Саяпов белән гаилә кора.



**Саимә Мөхәммәтсолтан кызы (сулда) белән Сабирҗан Солтанов хатыны Нәгыймә**

Габделхәкимнең беренче улы Габделгалим тармагын карауны тәмамлап, аның икенче улы Габделгалләмгә күчәбез. Габделгалләм Габделхәким улы балалары: Габдерәшит (1851–07.05.1883), Габделлатыйф (метрикәдә Мөхәммәтлатыйф дип тә языла; 1854), Габделбаян (1857), Сәрбиҗиһан (1863), Гайса (1865), Габделҗәлил (1868) һәм Габдулла (1868). Габделгалләм кызы Сәрбиҗиһан 1883 елның 10 апрелендә Минзәлә өязе Бүләк авылының Мифтахетдин Мөхтәсип улы (35 яшь) белән кавыша.

Габдерәшит Габделгалләм улы балалары: Мәрзия, Һидая (19.11.1878, анасы Майсорур), Бибисәвия (29.04.1880), Рәуфә (19.06.1883). Габдерәшит кызы Мәрзия Габделлатыйф Габделнасыйр улы Күчемов белән кавыша. Икенче кызы Бибисәвия 1897 елның 14 августында Яңа Катайның Әһлиулла Гыйззәтулла улы (30 яшь; икенче никах) белән никахлаша.

Мөхәммәтлатыйф Габделгалләм улы балалары Габдерәшит (15.11.1885–1889; атасы Габделлатыйф дип язылган) һәм Шәмсеҗиһан (16.08.1888; анасы Мәгъшуҗиһан) була.

Габделбаян Габделгалләм улы балалары: Хәмидә (18.12.1884), Габделханнан (09.09.1887; анасы Хафизә), Габделмәннан (04.06.1890), Габделвәли (24.09.1892–1892), Габделзаһир (16.10.1893; анасы Хафизә Балыклының Ибнмәхиян кызы), Бибигазизә (23.03.1897; анасы Хафизә). Габделбаян кызы Бибихәмдия (18 яшь) 1907 елның ноябрендә Яңа Катайның Исламгали Гомәр улы (26 яшь; атасы Гомәр Миңлегол улы) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Габделгали Габделхәбир улы белән Габдулла Габделгалләм улы була. Габделбаян Галләмовның кече улын (23 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (61), олы улы (30) һәм кызы белән яши, 4,32 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була.

Гайса Габделгалләм улы 1888 елның 14 октябрендә ерак нәселдәше Мөхәммәтшәфикъ Мөхәммәтҗан улының кызы Бибимәрхәбә (18 яшь) белән никахлаша. Гайса балалары: Әхмәтзакир (1889), Зиннәтулла (29.06.1891–1892), Муса (07.05.1893; анасы Мәрхәбә Мөхәммәтшәфикъ кызы), Зөбәрҗәтелҗинан (1897), Мөҗәһит (16.09.1898; анасы Зәйнәп Яңа Катайның Шәнгәрәй кызы), Сабирҗан (29.08.1901), Нурзидә (15.07.1903), Зиннәтулла (22.10.1906), Өммелҗинан (08.04.1910), Фатыйма (21.03.1914; анасы Зәйнәп), Мотыйгулла (13.07.1917). Гайса кызы Зөбәрҗәтелҗинан (18 яшь) 1916 елның 25 февралендә Туктаголның Мөхәммәтсадыйк Габделсалих улы (25 яшь; атасы Габделсалих Габделлатыйф улы) белән никахлаша. Мотыйгулла Гайсин сугышта һәлак була, анасы Зәйнәп (1869) 1943 елда әле исән була. Метрикәгә Өммелҗинанның 1965 елның 27 июлендә Гайсина фамилиясендә туу турында белешмә алуын язып куйганнар.

Өстәп әйтик, Гайса Габделгалләм улы Хәкимов (30 яшь; икенче никах) 1895 елның 1 гыйнварында Яңа Катайның Шәнгәрәй Булат улы Габидуллин кызы Зәйнәп (17 яшь; Арсланбәк нәселеннән) белән никахлаша. Кияүнең вәкиле – Габделбаян Габделгалләм улы, ризалык шаһитлары Габделҗәлил белән Габдулла Габделгалләм уллары була. Гайса Галләмовның (54 яшь) олы улын (24) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда ул хатыны (40), ике улы һәм өч кызы белән гомер итә, 11,78 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була. Зур хуҗалыкта кайбер эшләрне башкару өчен хезмәтче яллаган.

Муса Гайса улы (23 яшь) 1916 елның 18 мартында нәселдәше Нургали Габделнәфикъ улының кызы Бибигалимә (18 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Габделҗәлил Габделгалләм улы белән Мөхәммәтнәгыйм Заһидулла улы була. Муса балалары: Миңлехәнифә (03.06.1916; анасы Галимә Нургали кызы), Әзһәрия (25.11.1925; анасы Шәрифә Шәйхулла кызы). Муса Гайсин сугышта һәлак була, сугышка киткәндә гаиләсендә хатыны Шәрифә (1900), кызлары Җәүһәрия (1923), Әзһәрия (1925), Мәккия (1931), уллары Тимер (1928), Зәки (1932), Флүн (1935) кала. Нәселдәшем Зәки Гайсин үз куллары белән ясаган зур биек шкаф, Катайда мин туып-үскән төп йортта әлегәчә саклана, шактый тузса да, ямь өстәп, тарихи төс биреп тора.

Габделҗәлил Габделгалләм улы (22 яшь) 1890 елның 10 ноябрендә Яңа Катайның Габделмәннаф Габдрахман улының кызы Миңлеҗиһан (20 яшь) белән никахлаша, балалары Габдерәхим (19.10.1892), Хәбибрахман (22.12.1894), Гайнелҗинан (03.09.1897), Шәмсеҗиһан (03.06.1900), Фәхерҗиһан (04.08.1903), Шәмсебәдәр (07.12.1907–1916, чәчәк авыруыннан вафат) туа. Габдерәхимнән Наҗия (15.08.1925; анасы Шәмсеҗиһан Исмәгыйль кызы) туган, Иске Катай метрикәсенең 1925 елгы битендә, 1978 елда аңа туу турында справка җибәрелде, дип язып куйганнар. Габделҗәлил беренче китапта Габделҗәмил дип хаталы язылган, моны төзәтәбез. Габделҗәлил Галләмовның кече улын (22 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда ул хатыны (50 яшь), олы улы

(25 яшь) һәм кызы белән яши, 6,99 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була. Кайбер хәлле нәселдәшләре кебек, ул да хезмәтче тота.

Габдулла Габделгалләм улы (25 яшь) 1893 елның 14 октябрендә Яңа Катайның Әхмәтша Габделлатыйф улы Азаматов кызы Фәрхебану (18 яшь) белән гаилә кора, балалары Хөснулла (13.10.1894), Мотыйгулла (29.01.1897), Бибисара (19.07.1899–1902), Мәгъдәнбану (08.11.1901), Габделкотдус (28.03.1904), Тимергали (02.09.1906), Миңлебану (27.02.1909), Гыйльмиҗиһан (06.03.1911), Гөлчирә (метрикәдә Гөлчәһрә; 27.08.1913; атасы Габдулла Галләметдин улы, анасы Фәрхебану Әхмәтша кызы дип язылган) туа. Күргәнебезчә, соңгы баланың бабасы 1913 елгы метрикәдә ялгыш Галләметдин дип язылган, мондый очраклар бер генә түгел. Мәгъдәнбану (1901) авылдашы Мөхәммәтхафиз Фәррахов белән гаилә кора, балалары Нәкыя, Мөхәммәткамал, Хәтирә туа.

Габдулла Галләмов (50 яшь) 1917 елда хатыны (48), ике улы һәм өч кызы белән яши, 16,85 дисәтинә җире, 4 аты, 4 сыеры һәм башка маллары була, лавкасында сәүдә итә. Аның нәселен дәвам итүче Габделкотдус Габдуллин 1942 елның 22 мартында сугышта һәлак була, хатыны Сәхипбану (1907), уллары Мокатдәс (1931), Фәнис (1939), кызлары Әнисә (1933), Әрҗүдә (1936), Фәнүзә (03.02.1942) кала. Әнисә Яңа Катайның Мәдих Әгъләметдин улы Хафизов белән гаилә кора. Әрҗүдә Яңа Катайның Камил Кашапов белән никахлаша. Фәнүзә Яңа Катайның Халәф Газетдинов белән кавыша. Бу мәгълүматны Әнисә кызы Фәнзәлия Хәбибуллина (Хафизова) әйтте.

Игътибар иткәнсездерме, Габделҗәлил белән Габдулла Галләмовларга 1917 елда 50 яшь дип язылган. Алар игезәкләрме дигән сорау туа, максат куеп өстәмә чыганак өйрәнсәң, моны ачыклап буладыр, мөгаен.

Габделхәкимнең өченче улы Габделшәфикъ (1831) та нәсел калдыра. Габделшәфикъ Габделхәким улы балалары: Габделгазиз (1857), Бибинәфисә (1866), Габделгалләм (25.06.1875–1875), Мәгърифә (19.06.1886; анасы Җиһанбану). Габделшәфикъ кызы Бибинәфисә 1884 елда Наратлының Кашшафетдин Әхмәди улына кияүгә чыга. Икенче кызы Мәгърифә (18 яшь) 1903 елның 26 сентябрендә авылдашы Мифтахетдин Җәләлетдин улы (26 яшь) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле – бертуган агасы Габделгазиз, егетнеке дә агасы Фәхретдин Җәләлетдин улы була.

Габделгазиз Габделшәфикъ улы балалары: Габделихсан (22.07.1885), Шәмсеҗиһан (12.07.1888; анасы Якутелҗинан), Габделфаяз (08.01.1892), Мәдхиҗиһан (09.09.1895–1899, шеш рәнҗүеннән; анасы Якутелҗинан Камышлының Мөхәммәтрәхим кызы), Нурислам (13.07.1899), Мөхәммәткәшиф (24.09.1903). Габделгазиз кызы Шәмсеҗиһан (18 яшь) 1905 елның 13 октябрендә авылдашы Мөхәммәтшәех Дәүләтбай улы (27 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары итеп Габделихсан Габделгазиз улы белән Габделбаян Габделгалләм улы күрсәтелә. Егетнең вәли вәкиле – агасы Дәүләтгир Дәүләтбай улы, ризалык шаһитлары Гайса белән Габделҗәлил Габделгалләм уллары була. Газиз Шәфиковның (60 яшь) олы улын (26) Беренче бөтендөнья сугышына алалар,

1917 елда хатыны (55), ике улы һәм килене белән яши, 4,93 дисәтинә җире, 4 аты һәм 7 кәҗәсе була. Якутелҗинанның исемен кыскартып Якут дип кенә әйткәннәр, моны Хәмит абыйдан белдем.

Габделихсан Габделгазиз улы Хәтирә Нурәхмәт кызы (1895) белән гаилә кора, балалары Миңлефатыйма (1914–1916, чәчәктән вафат), Шәрифҗан (халык телендә Шәрип; 19.07.1917), Гыйлем (1920), Мөслимә (1926) һәм Зөләйха (1932) була. Шәрип белән Гыйлем Газизовлар – Ватан сугышы ветераннары. Кәшиф (халык телендә Кәшип) Газизов 1943 елда сугышта хәбәрсез югала, хатыны Мәрфуга (1907), балалары Хәбип (1930), Мәрьям (1933) һәм Җәмигънур (1938) кала. Мәрфуга әбине без бала чакта «Кәшип корткасы» дип әйтәләр, берүзе урманга дару үләннәре җыярга йөри торган иде, янып үлмәсә, йөзгә чаклы яшәр иде кебек. Катайның мемориаль стеласына Кәшиф белән Шәрип Газизовларны өстәп язарга кирәк, Гыйлем абыйны язганда боларны онытканнар, күрәсең.

Габделфаяз Габделгазиз улы 1915 елның 25 июлендә авылдашы Шәмсекамал Сафиулла кызы (18 яшь; атасы Сафиулла Нигъмәтулла улы) белән никахлаша. Габделфаяз балалары: Әгъләм (1918), Мөхәммәткамал (29.07.1925; анасы Газимә Фәхрелислам кызы). Әгъләм Фаяз улы Газизов – Ватан сугышы ветераны, «Ватан сугышы» ордены (2 нче дәрәҗә) (06.04.1985) белән бүләкләнгән (аның да исеме Катайның мемориаль стеласына язылмаган).



**Бабам Габделкәрим үз кулы белән салган тамга. 1897 ел**

Габделхәкимнең дүртенче улы Габделкәримнән (1838–04.08.1907) нәсел бу юллар авторына килеп тоташа. Габделкәрим Габделхәким улының ике хатыннан (беренче хатыны Гыйльмениса) балалары: Рузәтелкамал (1863), Гайникамал (1866), Габделмәҗит (28.05.1877), Шәймөхәммәт (16.11.1885), Мәрфуга (15.04.1891; анасы Мәфтуха Шәяхмәт кызы). Габделкәрим кызы Рузәтелкамал (20 яшь) 1883 елның 14 ноябрендә авылдашы Фәррахетдин Шәйхетдинов (23 яшь; Табыш нәселеннән) белән гаилә кора. Икенче кызы Гайникамал (17 яшь) 1890 елның 19 октябрендә Камышлының Корбангали Тимергали улы (25 яшь) белән кавыша. Төпчек кызы Мәрфуга 1908 елның 3 гыйнварында Килкабызның Мөхәммәтшакир Хисаметдин улы (35 яшь) белән никахлаша, кызның ризалык шаһитларыннан берсе авылдашы Мөхәммәтнәби Габделханнан улы була. Мәрфуга кияүдән кайтып, 1909 елның мартында Минзәлә өязе Бүләк авылының Фәррахетдин Габделлатыйф улы белән гаилә кора. Кызның ризалык шаһитлары Габдулла белән Габделбаян Габделгаллләм уллары була.

Габделмәҗит Габделкәрим улы балалары: Фәүзия (03.11.1911; анасы Бибикамилә Муллаәхмәт кызы, 1883 елда туган), Нәҗип (1922), Мәҗүрия (1930). Болар сугыш алды еллары исемлегендә Кәримов фамилиясе белән теркәлгәннәр. Нәҗип абый бабам Шәймөхәммәт янында тимерчелек эшенә өйрәнеп, Сакатта тимерче булып эшләде, гомер итте. 90 нчы елларда Катай тарихын яз-

ганда аны күрәсе килеп (әнием аны искә алып сөйли иде), беренче һәм соңгы тапкыр очрашып-күрешеп кайттым.



**Әтием Тимергазим Кәримов армиядә чакта. 1953 ел**

Шәймөхәммәт Габделкәрим улы белән Бибизәкия (1890–27.11.1953; Корычныкы) балалары: Ярмөхәммәт (09.08.1912–08.10.1942; анасы Бибизәкия Гайникамал кызы), Миңлефакия (1915–1916, чәчәк авыруыннан вафат), Миңлемәҗит (23.12.1916), Миңлегали (19.08.1924; анасы Зәкия Габдерәхим кызы), Тимергазим (23.12.1929–01.11.1980), Мәккия (1935).

Уфа архивында Шәймөхәммәт Кәримов турында беренче тапкыр мәгълүмат эзләгәндә, кирәкле документны тапкан кебек булган идем, әмма шик калган иде (еллар туры килеп бетми). Тагын эзли торгач икенче Шәймөхәммәт Кәримовка тап булдым, монысы минем бабам булып чыкты. Икесе дә бер чорда яшәгәннәр, замандашлар, хәтта нәселдәшләр. Аерма шунда, минем бабамның атасы Габделкәрим, аның нәселдәшенеке – Мөхәммәткәрим, әмма ике Шәймөхәммәтнең дә аталары исеменнән алган фамилияләрен кыскартып Кәримов дип язганнар. Дистәләрчә еллар Иске Катайда мөәзин вазифасын башкарган нәселдәшем Шәймөхәммәт Мөхәммәткәримов турында алга таба тулырак әйтеп үтәрбез.

Шәймөхәммәтнең олы улы өлкән сержант, взвод командиры Ярмөхәммәт Кәримов 1942 елның 8 октябрендә Ватан сугышында һәлак була, хатыны Нәкыя, кызы Халә (1939) кызы кала. Халә апа озак вакытлар Үзбәкстанда гомер итте, хәзерге вакытта тормыш иптәше белән Катайда яши.

Шәймөхәммәтнең икенче улы Тимергазим Кәримов – минем әтием – гомере буе урман хуҗалыгында эшләде, урманчы, берара урман техникы вазифасын башкарды. Әнием Рәкыйга (28.02.1931–2002; Тыпыйныкы) исә безне, биш баланы (Әлфия, Зөлфия, Таһир, Зөлфирә, Дамир), тәрбияләү белән мәшгуль булды, һәрберебезнең үз гаиләсе, үз шөгыле бар.



**Әти-әнием һәм нәселдәшем Шәрип абый Газизов (уңда)**

Үткәннәргә карап уйланасың да, шундый нәтиҗәгә киләсең: һәркайсыбыз бу тормышта үз мәсләген тапкан икән, монда әти-әни тәрбиясе, фатихасы искиткеч зур. Алар алдында без – мәңге бурычлы.

Югарыдагы юллар үткән гасырда язылды. Әнием дә, сеңлем Зөлфирә дә безнең арабыздан киттеләр. Әни-

емнән Катай авылы тарихын язганда күп нәрсәләр сораштыра идем, ул кемнең кем белән туган икәнен белә, ялгышмыйча исемнәрен, чамалап булса да туган елларын әйтә торган иде. 1999 елда авыл тарихы турындагы зур хезмәт куйган китабымны чыгарырга беркем дә ярдәм итмәгәч, үз акчама бастырмакчы идем, әнием хупламады. Алдагысын белеп булмый, буш кул калырга ярамый дигәч, бу уемнан кире кайттым. Аның сүзен тыңладым, үкенерлек түгел: китапларым күпкә соңрак, әмма зур эчтәлекле һәм яхшы сыйфатлы чыга. Чыгымнар бик күп булса да, зур, вакыт-вакыт колач җитмәстәй тоелган ниятемне тормышка ашырганга, авылымны бер генә түгел, хәтта ике китаплы иткәнгә сөенәм, көч-кодрәт, дәрман, илһам һәм акчасын биргәнгә Ходайга рәхмәт әйтәм.

Габделхәкимгә кайтыйк. Аның бишенче (төпчек) улы Габделмалик иде. Габделмалик Габделхәким улы балалары: Габделмөэмин (1867), Габдерәхим (05.11.1874; анасы Гайшә), Фәрхебану (1875), Габделгалләм (20.08.1877), Һидаябану (15.02.1880), Шәһәрбану (1889). Габделмалик кызы Фәрхебану (18 яшь) 1894 елның 17 гыйнварында авылдашы Мөхәммәтхарис Мөхәммәдиша улы (25 яшь; Табыш нәселеннән) белән никахлаша. Никах язуында кызның атасы Габделмалик Габделхәким улы, нәселдәше Габдулла Габделгалләм һәм туганы Габделмөэмин Габделмалик улы, кияүнең вәкиле Мөхәммәтхафиз Мөхәммәдиша улы нәсел тамгасын салганнар. Габделмаликның икенче кызы Шәһәрбану (18 яшь) 1908 елның 15 февралендә Туктаголның солдат Гыйлемхан Әхмәтҗан улы (26 яшь; атасы Әхмәтҗан Рамазанов) белән кавыша. Габделмаликның хатыны Мөхәммәтзариф белән бертуган, дип әйткән иде Хәмит абый.



**Фәрхибану никахы теркәлгән метрикә язуы. Өстә Габделмалик Габделхәким улы тамга салган. 1894 ел**

Габделмөэмин Габделмалик улы (25 яшь) 1893 елның 10 гыйнварында Яңа Катайның Габделгалләм Габделбәшир улының кызы Бибихәлимә (17 яшь) белән гаилә кора, балалары Габделкаһир (29.11.1893–1894, эч авыруыннан вафат), Мөхәммәтсалих (1896), Нурлыгаян (10.07.1900), Галимә (06.03.1904), Габделфаяз (13.02.1907), Бибимөгаллимә (03.05.1910), Бибимәдинә (16.05.1917) туа. Мөэмин Маликовның (50 яшь) олы улын (21) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (50 яшь), кече улы һәм ике кызы белән яши, 2,67 дисәтинә җире, 2 аты, 2 колыны, 8 сарыгы була.

Мөхәммәтсалих Габделмөэмин улы балалары: Фәхрелгаян (1921), Гөлҗиһан (05.04.1924; анасы Гөлбану Әхмәтгәрәй кызы), Миңленәҗибә (23.06.1925; анасы Фатыйма Шәймәрдан кызы, 1912 елгы), Нурлыгаян (1928), Вәзих (1936), Вәзиф (1943). Фәхрелгаян Салихов (1921–1942) Ватан сугышында хәбәрсез

югала, ә аның атасы Мөхәммәтсалих Мөкминов (1896) исән кайта (беренчесенең исемен Катайның мемориаль стеласына язганнар, икенчесенекен – юк).

Габдерәхим Габделмалик улы балалары: Һәдиябану (28.02.1904), Сәгыйдәбану (29.10.1906), Миңлефакия (22.02.1909), Габделхәмит (03.03.1912; анасы Мәрзия Яхъя кызы), Габделфаяз (18.11.1914; анасы Нәсимә Яхъя кызы), Әлтаф (29.06.1917–18.07.1943). Габдерәхим Маликов 1917 елда хатыны (40 яшь), өч улы һәм өч кызы белән яши, 4,16 дисәтинә җире, 3 аты, сыеры, бозавы була. Әлтаф сугыш чорына караган документларда ялгыш 1919 елда туган дип күрсәтелә. Миңлефакия авылдашы Салих Шәрифуллинга кияүгә чыга, балалары Мәүсусә (1931; авыл советы кенәгәсендә язылган), Хәбип (1940), Риф (1949), Роза (1953) туа. Фаяз Маликов (1914) – Ватан сугышы ветераны, сугышка киткәнче тракторда эшли, хатыны Мөсәвәрә (1920), анасы Мәрзия (1879) белән яши.



**Хәмит Габдерәхим улы Маликов**

Хәмит абый Маликов сугыш авырлыкларын үз җилкәсендә татыган, Нурҗиян апа белән биш бала (Рәшит, Фәрит, Тәнзилә, Фәнзилә, Равил) тәрбияләп үстергән. Туксанга җитеп килгәндә дә хәтере искиткеч әйбәт иде. Үзебезнең нәсел турында шактый мәгълүмат язып алдым аннан, шулар һәм архив чыганаклары шәҗәрәбезне төзергә ярдәм итте.

Габделгалләм Габделмалик улы балалары: Сәхапбанур (29.03.1907; анасы Мәүхүбә Мөхәммәтшәриф кызы), Сөнәгать (1910; исеме метрикәдә теркәлмәгән), Миңлефаяз (12.02.1912–1912; анасы Мәүхүбә Шәрифулла кызы), Миңлебану (23.07.1913; атасы ялгыш Галләметдин дип язылган), Мәгъсүмә (11.11.1917), Гөлбану (1922–1924), Сания (21.08.1925). 1917 елгы исемлектә Габделгаллəм Маликовның хатыны (35 яшь), ике кызы һәм анасы (70) күрсәтелгән, ә улы төшеп калган, документтагы бу хатаны төзәтәбез. Бу вакытта Габделгалләмнең 10,28 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була. Ватан сугышы алдыннан Галләм Маликов гаиләсендә хатыны Мәүхүбә (1879), улы Сөнәгать (1910), кызы Әлфинә (1942) була. Иске Катай метрикәсенең 1913 елгы битендә Миңлебануның 1968 елның җәендә загстан туу турында белешмә алуы язылган. Сөнәгать Галләм улы Маликов (1910) – сугыш корбаны (исеме Катайның мемориаль стеласына язылмаган).

Шулай итеп, нәселебезнең Хәким карт тармагын бүгенге көндә Кәримовлар, Маликовлар, Мөэминовлар, Газизовлар, Галиевләр, Габдуллиннар, Солтановлар дәвам итә. Аларның барысы да, без Хәким карт оныклары, дип горурлык белән әйтә ала. Кайчандыр хәкимнекеләр ике дистәләп ихата булып яшәгәннәр, хәзерге вакытта, билгеле, азрак. Юлдаш картның калган ике улы Сәлим белән Сөярголдан да нәсел дәвам итә, алга таба сүз шулар турыда барачак.

Юлдаш картның Сәлим исемле икенче улыннан киткән тармак бүгенге көндә башлыча Сираев, Шәмсетдинов, Кәримов фамилияләре белән билгеле.

Сәлимнән нәселне Баязит (1749–1820), Баязиттан Монасыйп (1769–1811) дәвам итә. Монасыйп Баязит улы балалары: Хисаметдин (1800), Фәхретдин (1803–15.04.1878), Сәйфетдин (1806) һәм Мөхәммәтрәхим (1808–1813). Хисаметдин Монасыйп улы балалары: Гыйлаҗетдин (1830–03.12.1886), Шәрәфетдин (1839).

Гыйлаҗетдин Хисаметдин улы балалары: Сираҗетдин (1855), Фәттахетдин, Гыймадетдин (1865), Раҗетдин (17.09.1881–1882), Фәрхениса (17.08.1883), Хәйретдин (06.04.1884).

Сираҗетдин Гыйлаҗетдин улы балалары: Шәйәгъзам (13.06.1886–1886), Бибихәдичә (1887), Миңлехәтимә (09.02.1888; анасы Сәрвиҗиһан), Сәлахетдин (1891–1965), Кәшфелмәган (1897–1900). Сираҗетдин кызы Бибихәдичә (18 яшь) 1907 елның февралендә Корычның Габделгали Шәймәрдән улы (26 яшь; атасы Шәймәрдан Биктимер улы) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Гыймадетдин Гыйлаҗетдин улы белән Ибраһим Миңлегали улы була. Сираҗетдиннең икенче кызы Миңлехәтимә (18 яшь) 1907 елның 20 сентябрендә ерак нәселдәше Мөхәммәтшакир Мөхәммәтшәфикъ улы (25 яшь) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары – Сәйфулла Җомагол улы белән Исмәгыйль Миңлегали улы, егетнеке Гайфетдин Шәмсетдин улы белән Фәттахетдин Гыйлаҗетдин улы була.

Сәлахетдин Сираҗетдин улы авылдашы Җәләлетдин Гаязетдин улының кызы Саимә белән никахлаша, балалары Мәгъфурҗан (1920–17.04.1924), Әмир (1924), Һади (1925), Хыялетдин (1930–1966), Флүн (1940) дөньяга килә. Сержант Әмир Сәлах улы Сираев сугышта һәлак була, «Дан» (III дәрәҗә) ордены (03.03.1944) белән бүләкләнә. Һади Сәлах улы Сираевның 1943 елның 10 декабрендә Украинаның Рудни авылы янындагы сугышта гомере киселә. Сугыш корбаннары Әмир һәм Һади Сираевлар исемнәре Катайның мемориаль стеласына язылмаган. Хыялетдин Сираев Яңа Катайның Җәүһәрия Әмирхан кызы Тәминдарова белән гаилә кора, балалары Фаил (01.10.1955), Шамил (16.09.1957–17.02.2017), Зилара (30.03.1960) туа.

Фәттахетдин Гыйлаҗетдин улы балалары: Әһлетдин (11.07.1894–1894; анасы Шәмсенур Яңа Катайның Габделмансур кызы), Нуретдин (12.08.1895), Гыйльметдин (01.07.1898), Хәйдәретдин (21.12.1900), Бибисорур (08.08.1902), Фәрхисорур (23.03.1905), Әгъләметдин (13.09.1907–1910; анасы Шәмсенур Мансур кызы), Акмалетдин (03.04.1910), Миңлеәгъләметдин (12.03.1912).

Гыймадетдин Гыйлаҗетдин улы балалары: Җәмгыйтдин (11.04.1894–1906; анасы Миңлесафа Балыклының Гайфулла кызы), Гыйльмисафа (1898). Гыймадетдин кызы Гыйльмисафа (18 яшь) 1916 елның 23 маенда Яңа Катайның Сабирҗан мулла Ахунҗан улы Күчемов (23 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары – Мөхәммәтсолтан Мөхәммәтгәрәй улы белән Мөхәммәтшакир Могтәметдин улы, егетнеке Сәлимгәрәй Шәйгәрәй улы белән Мөхәммәтсадыйк Сафиулла улы була. Гыймадетдин Гыйлаҗетдинов

(52 яшь) 1917 елда хатыны (52) белән яши, 4,32 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм 3 сарыгы була.

Хисаметдин Монасыйп улы нәселен Шәрәфетдин дә дәвам итә. Шәрәфетдин Хисаметдин улы балалары: Бибифакия, Низаметдин (1876), Шәйсолтан (1878), Мөхәммәдиша (Мөхәммәтша; 1881), Галләметдин (17.12.1884). Шәрәфетдин кызы Бибифакия 1889 елда авылдашы Габделихсан Сәхипбаян улы белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары булып Сираҗетдин белән Гыймадетдин Гыйлаҗетдин уллары нәсел тамгасын салалар. Шәрәфетдин Хисаметдиновның бер улын (41 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда килене (42) белән яши, 5,96 дисәтинә җире, аты, сыеры, 2 сарыгы һәм 2 кәҗәсе була.



**Сираҗетдин белән Гыймадетдин Гыйлаҗетдин уллары нәсел тамгасын салганнар. 1889 ел**

Низаметдин Шәрәфетдин улының Факия Садыйк кызы белән никахыннан улы Шәйхенур (21.04.1905) туа. Шәйхенур Низаметдин улы Шәрәфетдинов Ватан сугышында һәлак була (исеме Катайның мемориаль стеласына язылмаган).

Шәйсолтан Шәрәфетдин улы балалары: Галимәрдан (18.03.1915; анасы Мәгъсүмә Җәләлетдин кызы), Шаһимәрдан (09.12.1917; анасы Мәүсуфа Габдулла кызы). Шәйсолтан Шәрәфетдинов (39 яшь) 1917 елда хатыны (35 яшь), ике улы һәм кызы белән яши, балта остасы, 0,72 дисәтинә җире, 2 сарыгы һәм кәҗәсе була.

Мөхәммәдиша Шәрәфетдин улы 1907 елның 25 октябрендә Яңа Катайның Миңлегәрәй Мөхәммәтша улының кызы Шәмсенур (17 яшь) белән никахлаша. Мөхәммәдишаның башка никахтан балалары: Әмирҗан (19.06.1911; анасы Бибишәмсия Габделхаликъ кызы), Миңлефакия (24.03.1914–1914, кызамыктан вафат), Миңлегалимәбану (19.05.1916), Миңлегайсә (08.05.1925; анасы Мөнәздә Гайнелихсан кызы). Мөхәммәдишаның икенче хатыны (Бибишәмсия) Корычтан була, 1916 елның 25 июлендә «араларында өлфәт вә мәхәббәт» юклыктан аерылышалар. 1917 елда Мөхәммәдиша Шәрәфетдинов (чыганакта Мөхәммәтша; 38 яшь), хатыны (18) белән яши, 0,55 дисәтинә җире һәм аты, сарыгы була, утын кисеп, такта ярып йөри.

Галләметдин Шәрәфетдин улының кызы Мәһдиҗиһан (21.07.1914; анасы Бибиҗиһан Хөснетдин кызы) билгеле. Шәрәфетдиннең уллары Мөхәммәдиша белән Әхмәдишаның нәселләре калмады, дип әйткән иде Хәмит абый. Шәрәфетдин нигезе Хәмидулла Гомәров йорты урынында була.

Югарыда Монасыйп Баязитовның өлкән улы Хисаметдиннән киткән тармак каралды. Монасыйпның икенче улы Фәхретдиннән нәселне Шәмсетдин (1821–11.10.1892), Фәрхетдин (1832), Шәйхетдин (1847) дәвам итә.

Шәмсетдин Фәхретдин улы балалары: Хөснетдин (1852; анасы Хәдичә Габделвәли кызы), Гайфулла, Сәйфетдин (1869–1941), Гайфетдин (23.10.1876; анасы Хәдичә).

Гайфулла Шәмсетдин улыннан Мөхәммәди билгеле. Мөхәммәди Гайфулла улы балалары: Фәзилә (23.11.1900; анасы Миңлебану Иске Катайның Габделбасыйр кызы), Габделкотдус (15.09.1903), Фәгыйлә (14.10.1906), Рәхимә (1907–1909, шеш зәхмәтеннән вафат), Бибимәрзия (02.09.1908), игезәкләр Сафуан белән Насиха (17.06.1910).

Сәйфетдин Шәмсетдин улы нәселдәше Арслангали Мөхәммәтгали улының кызы Сәгыйдә белән никахлаша, балалары Әмирҗан (06.07.1900–1902), Сабирҗан (25.08.1903), Бибигазизә (27.01.1906–1909, кызамыктан вафат), Әмирҗан (22.01.1909–1910), Миңлерәхимә (17.02.1911–1914, кызамыктан), Рәхимә (08.06.1916), Галимҗан (15.06.1924) дөньяга килә. Сабирҗан Сәйфетдинов (1903) 1941 елның 17 декабрендә Ватан сугышына китә, язмышы билгесез, хатыны Хафизә (1908), балалары Әфудә (1928), Хаҗгали (1939), Әгъзам (1941) була. Хафизә җилбәзәк хатын була, балаларын балалар йортына (детдомга) тапшыра. Шуңа карамастан, балалары игелекле була, үз тормышлары белән яшәгәндә, аналарына гел күчтәнәчләр-бүләкләр алып кайткалап торганнар.

Ватан сугышы ветераны Галимҗан Сәйфетдин улы Шәмсетдинов Фәния Салих кызы (01.07.1930) белән гаилә кора, балалары Сәлимә (01.03. 1955), Зәлифә (05.06.1956), Әлмира (27.06.1961), Илшат (01.10.1964) туа.

Гайфетдин Шәмсетдин улы балалары: Фәхретдин (22.02.1902; анасы Шәмсеруй Дәүләтша кызы), Гыйльмиҗамал (09.11.1904; анасы Миңлеҗамал Сәлимгәрәй кызы), Сәрвиҗамал (29.06.1907), Гыйльмиҗиһан (18.03.1909), Могтәметдин (02.01.1911; анасы Миңлеҗамал Сәлимгәрәй улы), Сәрвиҗамал (27.09.1913), Миңлехәнифә (09.01.1916–1916, чәчәктән вафат), Хисаметдин (10.12.1917). Гайфетдин Шәмсетдинов (42 яшь) 1917 елда хатыны (35) һәм ике кызы белән яши, итекләр тегә, 4,58 дисәтинә җире, аты һәм 3 кәҗәсе була. Гыйльмиҗамал Гайфетдинова һәм аның энесе Хисай (Хисаметдин) Ватан сугышы алды еллары документында теркәлгән, беренчесенең туган елы ялгыш 1903 дип язылган.

Фәхретдин Монасыйповның икенче улы Фәрхетдин иде. Фәрхетдин Фәхретдин улы балалары: Габдулла (1856; анасы Бибигазимә), Сәйфулла, Насыйбулла, Насифулла, Сәхипкамал (01.10.1874; анасы Газимә), Фәтхетдин (1897–1903). Фәрхетдин кызы Сәхипкамал (18 яшь; вәли вәкиле – Шәмсетдин Фәхретдин улы) 1892 елның 24 июнендә авылдашы Фәррахетдин Гыймадетдин улы (25 яшь; атасы Гыймадетдин Фәрхетдин улы) белән никахлаша.

Габдулла Фәрхетдин улы (27 яшь) 1882 елның 2 ноябрендә Базы Куянның Шәрифҗамал Хәйрулла кызы (20 яшь; икенче никах) белән гаилә кора.

Габдулла балалары: Шәмсекамал (1883), Сәмигулла (23.02.1886), Шәрифулла (23.12.1888–1889), Гыйндулла (08.05.1890–1893), Шәрифулла (26.04.1893), Хәйрикамал (15.08.1895–1899, ютәл авыруыннан вафат; анасы Шәрифҗамал), Бибикамал (09.04.1898–1900), Шәйәгъзам (04.07.1903–1905, кызамыктан), Миңлеразия (20.01.1906; анасы Әбәдия Риян кызы), Мәрзия (1906–1910), Миңлефазилә (12.06.1908–1909, кызамыктан), Шаһинур (26.05.1910), Миңлеәгъзам (08.03.1913), Миргабитҗан (25.06.1915–1916; анасы Шәриҗамал Габдулла кызы), Галимҗан (09.12.1917; анасы Әбәдия Риян кызы). Габдулла кызы Шәмсекамал (18 яшь) 1902 елның 29 февралендә авылдашы Мөхәммәтхарис Ибнехаҗип улы (27 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Насифулла Фәрхетдин улы белән Сәмигулла Габдулла улы була.

Фәхретдин Монасыйповның өченче улы Шәйхетдин дә нәсел калдыра. Шәйхетдин Фәхретдин улы балалары: Маһиҗамал (1876), Гөлҗиһан (1879), Фәрхиҗиһан (05.10.1880), Кашшафетдин (15.03.1884), Шиһабетдин (18.03.1887), Фәхерҗиһан (09.10.1890; анасы Сәхипҗамал), Мәдхиҗиһан (14.11.1893). Шәйхетдин кызы Маһиҗамал (18 яшь) 1895 елның 27 гыйнварында Корычның Фәррахетдин Гайнетдин улы (28 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Икенче кызы Гөлҗиһан (18 яшь) 1897 елның 22 ноябрендә нәселдәше Ахунҗан мөәзин Шәймөхәммәт улына (25 яшь; икенче никах) кияүгә чыга. Кызның ризалык шаһитлары нәселдәшләре Габдулла Фәхретдин улы белән Гыймадетдин Гыйлаҗетдин улы була. Өченче кызы Фәрхиҗиһан (18 яшь) 1900 елның 25 ноябрендә Баекның Габделгани Мөхәммәтвәли улы (35 яшь) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары нәселдәшләре Сәйфулла белән Габдулла Фәрхетдин уллары була. Дүртенче кызы Фәхерҗиһан (18 яшь) 1910 елның декабрендә Баекның Хаҗиәхмәт Нуриәхмәт улы (35 яшь, икенче никах; атасы Нуриәхмәт Шәяхмәт улы) белән гаилә кора.

Кашшафетдин Ватан сугышы алды еллары кенәгәсендә «Кәшби Шәйхетдинов» дип теркәлгән, хатыны Кәшифә (1892), уллары Шәрифулла (1926), Сибагатулла (1938) була. Алар шул чорда ук авылдан чыгып китәләр, шуңа язмышларын берничек тә ачыклап булмый.

Алга таба сүз Сәлимнең кече улы Ильястан (1765–1806) киткән тармак турында. Ильясның өлкән улы Мөхәммәткәрим (1801) була. Мөхәммәткәрим Ильяс улы балалары: Мөхәммәдьяр (1827–03.09.1899; ютәл авыруыннан вафат), Мөхәммәтгәрәй (1833–02.10.1892, холера зәхмәтеннән), Мөхәммәтшәриф (1834–04.09.1881), Шаһимөхәммәт (Шәймөхәммәт; 1844), Шаһиәхмәт (Шәяхмәт, 1853–03.05.1914), Миңлеҗамал (1858), Хупҗамал (1859), Шәмсеҗамал (1864–1889). Мөхәммәткәрим кызы Миңлеҗамал (18 яшь; вәли вәкиле – абыйсы Шәймөхәммәт) 1877 елның 20 гыйнварында Балыклының Арслан Мортаза улы (20 яшь; атасы Мортаза Әсәдулла улы) белән кавыша. Икенче кызы Хупҗамал (22 яшь) 1881 елда Яңа Катайның Муллаян Үмербай улы (25 яшь) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле – абыйсы Шәяхмәт Мөхәммәткәрим улы, егетнеке агасы Мөхәммәтҗан Үмербай улы була. Кыз ягыннан ризалык

шаһитлары булып Мөхәммәдьяр белән Шәймөхәммәт Мөхәмматкәрим уллары теркәлгән.

Мөхәммәдьяр Мөхәмматкәрим улы балалары: Әүдияр (1855–24.11.1893, ютәл зәхмәтеннән), Шәмсенур (1871), Фатыйма (1874). Мөхәммәдьяр кызы Шәмсенур (18 яшь) 1889 елның 6 февралендә Минзәлә өязе Елан авылының Габделхәлим Габделгани улы (32 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Икенче кызы Фатыйма (18 яшь) 1892 елның 19 октябрендә нәселдәше Кашшафетдин Шәйхетдин улы (35 яшь; икенче никах) белән гаилә кора.

Әүдияр Мөхәммәдьяр улы балалары: Рамазан (20.09.1882), Мөхәмматвәли (17.10.1884), Әхмәтвәли (09.07.1887–1890), Әхмәтгәрәй (12.11.1890; анасы Гыйззениса Мөхәмматҗан кызы), Галимәрдан (06.03.1894–1894; анасы Гөлҗиһан Мөхәмматвәли кызы).

Мөхәмматкәрим Ильясовның икенче улы Мөхәмматгәрәй иде. Мөхәмматгәрәй Мөхәмматкәрим улы балалары: Гыйльмикамал (1866), Солтангәрәй (метрикәдә Мөхәмматсолтан дип язылa; 1867), Гайникамал (1871), Бибикамал (10.10.1878; анасы Гайниҗамал), Сәлимгәрәй (1879–20.09.1908), Әхмәтгәрәй (13.12.1883), Шәмсеҗиһан (16.10.1888; анасы Гайниҗамал), Шәмсеҗиһан (1891). Мөхәмматгәрәй кызы Гайникамал (18 яшь) 1889 елның 11 сентябрендә ерак нәселдәше Исрафил Ризван улы (30 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Икенче кызы Гыйльмикамал (25 яшь; икенче никах) 1892 елның 8 мартында Куянның Батырша Әделгәрәй улы (24 яшь; атасы Әделгәрәй Миңлегәрәй улы) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Солтангәрәй белән Сәлимгәрәй Мөхәмматгәрәй уллары була. Төпчек кызы Шәмсеҗиһан (17 яшь) 1908 елның 29 апрелендә Балыклы мишәре Миңлегәрәй Мортаза улы белән гаилә кора. Кызның вәли вәкиле – агасы Әхмәтгәрәй Мөхәмматгәрәй улы, ризалык шаһитлары Шәвәли Габдерәфикъ улы белән Солтангәрәй Әхмәтгәрәй улы була.

Мөхәмматсолтан Мөхәмматгәрәй улы балалары: Дәүләтгәрәй (03.08.1900; анасы Гыйззениса Корычның Нурәхмәт кызы), Кифая (03.09.1903), Гөлҗиһан (11.12.1907), Дәүләтгәрәй (16.09.1909–1912; анасы Гыйльмиҗиһан Мөхәмматшакир кызы), Бибиҗиһан (19.08.1911), Муллагали (14.02.1917; анасы Гыйльмиҗиһан Мөхәмматшакир кызы). Солтангәрәй Мөхәмматгәрәев (50 яшь) 1917 елда хатыны (35 яшь), яңа туган улы һәм өч кызы белән яши, 5,25 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була.

Әхмәтгәрәй Мөхәмматгәрәй улы (23 яшь) 1905 елның 3 декабрендә нәселдәше Әхмәтгали Габдерәфикъ улының кызы Шәмсеҗиһан (18 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары – Шәвәли Габдерәфикъ улы белән Әхмәтнәби Әхмәтгали улы, егетнеке Шәйхетдин Фәхретдин улы белән Солтангәрәй Мөхәмматгәрәй улы була. Әхмәтгәрәй балалары: Сәрмәдия (12.06.1906), Мирзаәхмәт (08.11.1908–1916; анасы Шәмсеҗиһан Әхмәтгали кызы), Бәһия (08.04.1911), Зөләйха (10.04.1917). Әхмәтгәрәй Мөхәмматгәрәев 1917 елда ике кызы һәм хатыны (30 яшь) белән яши, 5,41 дисәтинә җире, 2

аты, сыеры һәм башка маллары була. Игенчелектән тыш, итекләр тегү белән шөгыльләнә.

Мөхәммәткәрим Ильясовның өченче улы Мөхәммәтшәриф иде. Мөхәммәтшәриф Мөхәммәткәрим улы балалары: Хәмдениса (22.12.1881), Әбүталип (02.09.1876–09.02.1912). Әбүталип Мөхәммәтшәриф улы балалары: Бибимәликә (19.03.1901), Сәфәргали (03.05.1904), Бибимәдинә (28.09.1906; анасы Шәмсекамәр Габделкадыйр кызы), Бибисара (1909–1914, кызамыктан вафат), Миңлесабира (03.04.1910).

Мөхәммәткәрим Ильясовның дүртенче улы Шәймөхәммәт Мөхәммәткәримов өч дистә ел (1873–1904 елларда) Иске Катай мәчетендә мөәзин булып хезмәт итә. Нәселдәшем Лилия Садыйкова мәгълүматы буенча, хатыны Кәрамниса белән балаларга дин сабаклары да бирә. Шәймөхәммәт Минзәлә өязенең Әмәкәй авылында (хәзерге вакытта Мөслим районына керә) Габдулла хәзрәттә укыган, 1873 елның 8 мартында мөәзинлеккә указ алган. 1917 елда әле ул исән, аңа 75 яшь була, өч улы һәм ике кызы белән яши.

Шәймөхәммәт Мөхәммәткәримов балалары: Ахунҗан (1872), Шәрәфниса (09.04.1875; анасы Кәрамниса), Суфиҗан (Суфиян; 02.06.1878), Мирзаҗан (Мирзаян; 15.11.1880), Шәйхерам (03.03.1883), Кафия (09.06.1886–1886), Шакирҗан (22.09.1888; анасы Кәрамниса), Шәкүрҗан (1890; яшен суга).

Шәймөхәммәтнең олы улы Ахунҗан 1895 елның 10 ноябрендә Яңа Катайның Шәйхетдин Мөхәммәткәрим улы Галиев кызы Мәһдивафа (18 яшь) белән никахлаша. Кияүнең ризалык шаһитлары Мөхәммәдьяр белән Шәяхмәт Мөхәммәткәрим уллары була. Ахунҗанның (25 яшь) икенче никахы 1897 елның 22 ноябрендә нәселдәше Шәйхетдин Фәхретдин улының кызы Гөлҗиһан (18 яшь) белән була. Кызның ризалык шаһитлары нәселдәшләре Габдулла Фәхретдин улы белән Гыймадетдин Гыйлаҗетдин улы була. Бу никахтан Ахунҗан Шәймөхәммәт улы балалары: Дөррия (25.10.1898), Суфиәхмәт (25.05.1901), Һидая (07.10.1903), Гатия (22.05.1906–1909, кызамыктан вафат), Суфиәхмәт (14.01.1909–1909, кызамыктан), Гатиятулла (16.10.1910–1911). Һидаяның Корычта яшәүче ике кызы бар, дип хәбәр итте Л. Садыйкова.

Шәймөхәммәтнең икенче улы Сафиян (Суфиҗан) Шәймөхәммәт улы (25 яшь) 1904 елның 3 гыйнварында авылдашы Мөхәммәтсадыйк Сафиулла улының кызы Бибизәйнәп (20 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтнасыйп улы белән абыйсы Мөхәммәтхәниф була. Әлеге никахтан Гафурҗан (14.10.1906–04.10.1908), Шәехбостам (15.02.1909), Гафурҗан (11.11.1911–1912) туа. Сафиянны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (30 яшь), улы һәм кызы кала. Бастан Сафиянов 1941 елның 16 декабренда Ватан сугышына китә, 28 нче кавалерия дивизиясенең 132 нче полкында хезмәт итә, 1942 елның 8 мартында Украинаның Харьков өлкәсе Лиговка авылы янындагы сугышта һәлак була (исеме Катайның мемориаль стеласына язылмаган), хатыны Гөлбостан (1912) кала.

Мирзаян Шәймөхәммәт улының Фәрхенур Габдулла кызы белән никахыннан Миркасыйм (10.1.1908), Кифая (09.09.1912), Нажия (1914) туа. Миркасыйм Мирзаян улы Кәримов (10.10.1908–1989) – Ватан сугышы ветераны. Миркасыймнан нәселне Миргазыян дәвам итә. Нәселдәшем Лилия Садыйкова әбисе Нажия Мирзаян кызы Кәримованың портретын ясатканын шатланып хәбәр итте.

Шәймөхәммәт Мөхәмммәткәримовның дүртенче улы Шәйхерам иде. Шәйхерам Шәймөхәммәт улы (27 яшь) 1911 елның гыйнварында Яңа Катайның Габделвахит Габделҗаббар улы Габделгаффаров кызы Мәмдуха (17 яшь) белән никахлаша, балалары Шәехзадә (02.01.1912–1912), Сафия (1913–1916, чәчәктән вафат), Шәехзадә (12.01.1916, чәчәктән) туа. Шәйхерам Шәймөхәммәтовны (35 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (24) кала, 1917 елда 0,55 дисәтинә җире, сыеры, 2 сарыгы һәм кәҗәсе була. Бу сугыштан Шәйхерам исән кайта, совет чорында балалары Тайбә (12.06.1925), Рәйсә (1927), Риза (1937) дөньяга килә. Улы Риза тугач Шәйхерам Кәримов күп тормый, мәрхүм була, сугыш чорында бөтен авырлык Мәмдуха җилкәсенә төшә. Сүз уңаеннан әйтик, Мәмдуханың энесе Гапсаттардан Закуан Вахитов (1920–1980) дөньяга килгән. Ул сугышта кече сержант, разведчик була, «Кызыл Йолдыз» ордены (10.11.1944), «Батырлык өчен» (26.08.1944), «Ленинград оборонасы өчен» (12.1942) медальләре белән бүләкләнә.

Мөхәмммәткәрим Ильясовның төпчек улы Шәяхмәттән дә нәсел дәвам итә. Шәяхмәт Мөхәмммәткәрим улы балалары: Шәехзаман (1878), Хәмдесафа (19.12.1881), Шәехәхмәт (02.10.1884), Миңлевәдига (11.10.1887; анасы Сәрвиҗиһан), Миңлехәмдесафа (06.04.1890), Хаҗиәхмәт (05.10.1892–1893), Вәдига (26.12.1895; анасы Сәрвисафа Баек авылының Галиулла кызы), Бибимәрьям (03.07.1900).

Шәехзаман Шәяхмәт улы хәлле (13,12 дисәтинә җире) була, Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, исән кайта, ә менә аның уллары Хәерзаман (03.01.1912; анасы Мәрзия Мөхәмммәтгәрәй кызы) һәм Кәнзелмәган (1915) Кәримовлар Бөек Ватан сугышында һәлак булалар. Ватан сугышы алдыннан Шәехзаман Кәримов исән булмый, документта хатыны Мәрзия Кәримова (1885 елда туган), аның балалары Миңленәҗибә (19.03.1925), Әкрәм (1927) һәм Әгъләм (1933) теркәлә. Боларның хуҗалыгы Хәйдәр Әхмәтов өе урынында була. Миңленәҗибә авылдашы Акмалетдин Сайрановка кияүгә чыга. Әкрәм белән Әгъләм читкә чыгып китәләр, «Арланнефть»тә нефтьче булып эшлиләр.

Юлдаш нәселе кешеләре, башка нәселләр кебек, бер-берсенең килеп чыгышын, тамырларын яхшы белгәннәр, үзара аралашып-хәбәрләшеп яшәгәннәр. Моның шулай булуы метрикә кенәгәләрендә аеруча чагыла. Менә бер факт. 1883 елның 14 ноябрендә икенче буын бабам Габделкәримнең кызы Рузәтелкамал (20 яшь) авылдашы Фәррахетдин Шәйхетдин улы (23 яшь) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле дип мөәзин Шәймөхәммәт Мөхәмммәткәрим улы, аннан соң гына атасының исеме (Габделкәрим Габделхәким улы) язылa.

Кызның ризалык шаһитлары Җиһанша Габделлатыйф улы (Азамат нәселе) белән нәселдәше Габделбаян Габделгалләм улы була.

Мөәзин Шәймөхәммәт Мөхәммәткәрим улы белән икенче буын бабам Габделкәрим Габделхәким улының 17 гасырда дөньяга килгән уртак бабасы – Юлдаш. Юлдаштан соң ике гасыр чамасы вакыт үтүгә карамастан, аның нәселен дәвам итүчеләр кайбер йолаларны бергә үтәп, бер-берсенең шатлыгын уртаклашып яшәгәннәр.

Бабаларыбыздан безнең буын өчен нинди гүзәл үрнәк! Бабаларыбыз рухын шатландырып, без дә бер-беребезнең нәселдәшлегебезне белеп-аңлап, алар кебек йолаларны бергә үти алмасак та, аралашып-хәбәрләшеп яшәсәк иде.

Юлдаш бабабызның төпчек улы Сөяргол (1721–1812) иде. 1795 елгы документ мәгълүматына караганда, аның беренче хатыны Йөзек (1731–1791) – Стәрлетамак (Бөгелмә округы), икенчесе Котлыбикә (1755) Әгер (Бөгелмә округы) авылыннан була. Бу авыллар хәзерге вакытта Азнакай районына керә.

Сөярголның нәселен уллары Габделвахит (1770–1856) белән Габделвәли (1793) дәвам итә. Сөяргол кызлары: Хәбибә (1789 елда Бәләбәй округы Кәкребаш авылы «башкорт»ына кияүгә чыга), Гаширә (1791 елда шул ук округның Үрмәт авылы «типтәр»енә кияүгә чыга), Мәүлетбикә (1790).

Габделвахитның хатыны Сәхипҗамал Яркәй кызы (1775) – Минзәлә округы Әмәкәй авылы «башкорт»ы кызы, аларның уллары Габделтаһир (1790) Габделкаһир (1797), Габделханнан (1801), Габделмәннан (1810), Шәйхетдин (1714), Могтәметдин (1827–30.11.1877) була.

Габделтаһир Габделвахитовның беренче хатыныннан уллары: Габделхаликъ (1822–21.10.1892; ютәл зәхмәтеннән вафат), Габдерәфикъ (1824–02.02.1902), Габделзаһир (1842–15.04.1877). 1859 елда хатыны Шәрифә Баязит кызы (1802) була. Габделтаһирның бу өч улыннан нәсел шактый тармаклана, Иске Катайда дистәдән артык гаилә барлыкка килә.

Габделхаликъ Габделтаһир улы балалары: Гыйльмениса (1845; беренче хатыныннан), Габделкадыйр (1851), Габделбасыйр (1853), Мөхәммәтвәли (метрикәдә Әхмәтвәли, 1856; барысы да икенче хатыны Шәмсеҗиһан Ибнехаҗип кызыннан туганнар), Әхмәтгәрәй (1868–1893), Гыйльмиҗиһан (1869), Фәхерҗиһан. Габделхаликъ кызы Гыйльмиҗиһан 1887 елда Әмәкәйнең Юныс Ильяс улы (22 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Фәхерҗиһан Яңа Катайның Муллаян Дәүләтгир улы Азаматов белән кавыша.

Габделкадыйр Габделхаликъ улы балалары: Сәлимгәрәй (10.09.1874; анасы Мәмдуха), Хәйдәргали (15.12.1883), Мөхәммәтхәләф (1884–1909), Миргали (07.01.1887), Миңлешакирҗан (15.06.1889), Мөкәррәмә (25.10.1892–1897; анасы Мәмдуха мулла Габделгани кызы), Сәетгали (23.12.1906; анасы Маһиҗиһан Йосыф кызы), Миңлемәргубә (14.04.1910). Хатыны вафат булгач, Габделкадыйр Габделхаликъ улы 1905 елның 21 декабрендә Яңа Катайның Йосыф Фәйзулла улының ирдән аерылган кызы Нурҗиһан (1870) белән гаилә кора. Габделкадыйр Габделхаликовның (67 яшь) улын (28) Беренче бөтендөнья су-

гышына алалар, 1917 елда ул хатыны (50) һәм өч улы белән яши, 7,06 дисәтинә җире, аты, 3 сыеры, 8 сарыгы була. Ике улы белән такта яруны кәсеп иткән.

Сәлимгәрәй Габделкадыйр улы балалары: Насыйха (13.01.1907), Гыйльмебануа (13.04.1910–1911), Миңлемөкәррәмә (29.06.1912), Сәетгәрәй (28.02.1916; анасы Шәмсебануа Фәттахетдин кызы). Сәлимгәрәй Кадыйровны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (40 яшь), өч улы һәм ике кызы кала, 1917 елда 2,12 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм 2 сарыгы була.

Хәйдәргали Габделкадыйр улы 1912 елның 11 октябрендә Яңа Катайның Хәсбиетдин Хөснетдин улының кызы Хәмдиҗиһан (17 яшь; Азамат нәселеннән) белән никахлаша, кызлары Мөнәвәрә (22.10.1914) туа. Хәйдәргалинең беренче хатыны Камышлының Миңлесафа Низаметдин кызы була, 1911 елның 23 ноябрендә «араларында өлфәт вә мәхәббәт» булмаганлыктан аерылышалар. Хәйдәр Кадыйровны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (25 яшь) кала, аты була.

Миргали Кадыйров Ватан сугышы алдыннан хатыны Галия Габделхаликъ кызы (1892), балалары Миңлесания (27.08.1924), Мәрьям (1928), Рамазан (1941) белән яши. Аның энесе Шакирҗан Кадыйров Ватан сугышында һәлак була, балалары Миңлезакирә (19.02.1925), Закирҗан (1927), Фәния (1935) кала.

Габделбасыйр Габделхаликъ улы балалары: Габделмалик (01.08.1884), Мөхәммәтсабир (24.12.1888–1889), Сабит (16.07.1890–20.04.1915), Мөхәммәтсалих (22.07.1893; анасы Гөләндәм Камайның Галиәкбәр кызы), Габделгали (16.08.1897), Фаизә (25.12.1902; Корычның Даут исемле кеше белән никахлаша, Бурят-Монголиягә чыгып китәләр), Фатыйма (23.03.1906, анасы Шәмсеҗамал Шәммәт кызы; Куянның Әхмәтхан Әхмәтҗановка кияүгә чыга, ире Иркут өлкәсеннән сугышка китеп, хәбәрсез югала), Хаҗиәхмәт (23.05.1909), Муллаәхмәт (18.06.1912; анасы Шәмсеҗамал), Галиәхмәт (1916). Габделбасыйр кызы Вәсфиҗамал (25 яшь; икенче никах) 1900 елның 20 ноябрендә Сеңрәннең Шәехмөхәммәт Габделлатыйф улы (30 яшь; икенче никах) белән кавыша. Кызның вәли вәкиле – агасы Габделлатыйф Габделвафи улы, ризалык шаһитлары Габделмәҗит белән Габделвахит Габделвафи уллары була. Габделбасыйр Габделхаликовның (64 яшь) олы улын (24) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (40), дүрт улы һәм ике кызы белән яши, 6,98 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры, 2 сарыгы була.

Габделмалик Габделбасыйр улы 1911 елның гыйнварында нәселдәше Гыйрфан Ризван улының кызы Гайнелхәят (18 яшь) белән никахлаша. Беренче бөтендөнья сугышында 316 нчы Хвалын пехота полкында хезмәт итә, һәлак була.

Хаҗиәхмәт Халиковны (1909–29.12.1991) 1942 елның 19 гыйнварында хәрби хезмәткә чакыралар, ике авылдашы (берсе Хәйдәретдин Нургалиев) белән Чиләбе трактор заводында танклар җитештерәләр, авылга 1949 елда гына кайта. Хатыны Корычның Вәҗиха Хәбир кызы Хәкимова (07.11.1917–1972), балалары Вәсилә (1939–2020), Рифкать (1941), Вәзирә (1950) була. Бу һәм кайбер башка мәгълүматны 7 апрельдә Вәсилә Хаҗиәхмәт кызы әйтте.


Разит һәм Рина Басыйровлар

Галиәхмәт Басыйров (1915–1950) – Ватан сугышы ветераны, Иске Катайның Нажия Әхмәтхан кызы (1918–1953) белән гаилә кора, балалары Рәсимә (1940), Разит (09.08.1946; хатыны Рина) дөньяга килә.

Әхмәтвәли Габделхаликъ улы балалары: Миңлекәримә (15.10.1887–1888; анасы Бибиҗамал), Солтангали (15.01.1890), Солтангәрәй (12.03.1892), Муллагали (15.10.1894–1903; анасы Бибифатыйма Корычның Сәхаутдин кызы), Батыргәрәй (28.06.1897–1902), Дәүләтгәрәй (13.03.1900–1903), Рәкыя (03.11.1905), Әхмәтгәрәй (26.10.1907; анасы Гөлчирә Заһидулла кызы), Миңлеһидая (09.04.1910–1910), Хаҗгали (04.10.1911–1912), Миңлеһәдия (09.09.1913), Миңлекифая (10.02.1916). Әхмәтвәли (30 яшь; өченче никах) авылдашы Заһидулла Шәрифулла улының кызы Гөлчирә (18 яшь) белән 1903 елның 5 мартында никахлаша. Әхмәтвәли Халиковның улын (24 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (35 яшь) һәм өч кызы белән яши, 4,26 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм кәҗәсе була. Ватан сугышы башланганда Гөлчирә Халикова (1888) кызы Фәйрүзә (1922; тракторда эшли) белән яши.

Югарыда без нәселне Габделхаликъ яклап карадык. Габделтаһирның икенче улы Габдерәфикътан да нәсел шактый тармаклана.

Габдерәфикъ Габделтаһир улы балалары: Әхмәтгали (1854; анасы Шәһәрбану Төхфәтулла кызы), Мөхәммәтгалим (1858), Шәвәли (1862), Фәрвизә (1869). Габдерәфикъ кызы Фәрвизә (18 яшь) 1887 елның 23 феврalendә авылдашы Әхмәтлатыйф мулла Мөхәммәтнәби улы (24 яшь; Табыш нәселе) белән кавыша.

Әхмәтгали Габдерәфикъ улы балалары: Мөхәммәтгали (16.08.1877–1888), Бибисания (1880), Әхмәтнәби (20.04.1882), Бибишәмсия (25.08.1884–1888), Шәмсеҗиһан (05.05.1887), Исламгали (30.07.1889), Миңлеҗиһан (13.02.1894–1916; анасы Кафия). Әхмәтгали кызы Бибисания 1898 елның октябрендә Корычның Мөхәммәтхәсән Мостафа улы (25 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Шәмсеҗиһан 1905 елның 3 декабрендә нәселдәше Әхмәтгәрәй Мөхәммәтгәрәй улы (23 яшь) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары нәселдәше Шәвәли Габдерәфикъ улы белән абыйсы Әхмәтнәби Әхмәтгали улы, егетнең вәли вәкиле – Шәймөхәммәт Мөхәммәткәрим улы, ризалык шаһитлары Шәйхетдин Фәхретдин улы белән Солтангәрәй Мөхәммәтгәрәй улы була. Метрикәдә ике якның да нәсел тамгалары тәңгәл килә, бер нәсел кешеләре булуын күрсәтә. Әхмәтгали Габдерәфиковның бер улын (25 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (69), олы улы (29), кызы һәм килене белән яши, 12,09 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була.

Әхмәтнәби Әхмәтгали улы балалары: Тәзкирә (16.09.1914), Миңлежиһан (28.05.1917; анасы Миңлеҗамал Шәрәфетдин кызы), Мөсәвәрә (27.08.1925; анасы Мөнәвәрә Мөхәммәтзакир кызы). Миңлежиһан 1969 елның 26 июнендә загстан туу турында белешмә ала. Шушы Әхмәтнәбинең улы Мөхәррәм (1923) булса кирәк, 1942 елның 15 октябрендә сугышка китә.



**Сугыш ветераны Кәшбелгаян Исламгали улы Әхмәтов**

Исламгали Әхмәтгали улы (26 яшь; атасы Әхмәтгали Габдерәфикъ улы) 1916 елның 30 ноябрендә авылдашы Мөхәммәтсадыйк Сафиулла улының кызы Бибирәшидә (19 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтнасыйп улы белән Әхмәтзариф Фазлыәхмәт улы була. Исламгали балалары: Мәрьям (1921), Кәшбелгаян (1923), Мөхәммәтгали (21.11.1925), Муллагаян һәм Хәйдәр (1928). Мәрьям Яңа Катайның Рухылбаян Дәүләтовка кияүгә чыга. Кәшбелгаян Исламгали улы Әхмәтов сугышта сержант була, «Дан» ордены (2 нче дәрәҗә) (01.03.1945) һәм «Батырлык өчен» медале (27.09.1944) белән бүләкләнә, сугыш инвалиды. Кәшбелгаян белән Әрҗүдә Баязит кызы балалары: Рузалин (1951), Айрат (1952), Зәлифә (1955), Фәридә (1957), Зилина (1962).

Шәвәли Габдерәфикъ улының Бибифатыйма Әбүбәкер кызы (Яңа Катайдан) белән никахыннан Шәехгали (22.01.1893–1895), Хәкимә (08.09.1895), Шагали (08.03.1897), Хуҗагали (16.08.1901; атасының исеме ялгыш Шагали Габдерәфикъ улы дип күрсәтелгән), Хаҗгали (03.09.1906) туа. Шәвәли Габдерәфиков (55 яшь) 1917 елда хатыны (45 яшь) һәм өч улы белән яши, 8,35 дисәтинә җире, 2 аты, 3 сыеры, 7 сарыгы була. Шагали Шәвәлиевнең гомере Ватан сугышында 1943 елның 28 августында өзелә, нәселен уллары Мөхлис (1927) белән Ясир (1929–2001), Нәкыя дәвам итә. Ясир Шагали улы Шәвәлиев Яңа Катайның Әбүнәгыйм Яруллин кызы Маһизүрә белән гаилә кора, балалары Диләвир (1956–20.05.2019), Сөгъдә (1957), Мөсәвир (1959), Клара (1966), Радик (1971) туа. Хаҗгали Шәвәлиев 1941 елның 14 июлендә Ватан сугышына китә һәм 1943 елның 13 ноябрендә һәлак була, хатыны Галимә (1915), балалары Рәйханә (1937), Фәгыйль (1938), Мөгаллимә (1940) кала. Хаҗгали Шәвәлиев Катайның мемориаль стеласына язылган, аның абыйсы Шагали һәм Шагалинең улы кече сержант Мөхлис Шәвәлиевләр – юк.

Габделтаһир Габделвахитовның төпчек улы Габделзаһир (1842) иде. Габделзаһир Габделтаһир улы балалары: Мәгъфүрә (1862), Габделҗәлил (1873). Габделзаһир кызы Мәгъфүрә (18 яшь) 1881 елның 7 декабрендә Камышлытамакның Нәҗметдин Шәрәфетдин улы (23 яшь; атасы Шәрәфетдин Мифтахетдин улы) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары нәселдәшләре Габделкадыйр Габделхаликъ улы белән Әхмәтгали Габдерәфикъ улы була.

Габделҗәлил Габделзаһир улы балалары: Шәмсениса (16.09.1897), Сәвия (13.07.1900; анасы Шәмсевафа Иске Катайның Габделгалләм кызы), Гыйльмениса (13.08.1902; анасы Шәмсевафа Галләметдин кызы), Сәвия (1906), Миңлефәүзия (29.03.1909), Корбангали (23.11.1911–1914, кызамыктан вафат), Мөхәммәткамал (25.08.1915). Габделҗәлил Габделзаһиров 1917 елда хатыны (43 яшь), улы һәм өч кызы белән яши, 8,33 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була.

Югарыда Габделвахит Сөярголовның өлкән улы Габделтаһирдан киткән буыннар күрсәтелгән иде. Габделвахитның икенче улы Габделкаһир (1797 елда туган) – Катай «типтәр»ләре арасында зур хөрмәт казанган кешеләрнең берсе. Марилар белән җир мәсьәләсе буенча бәхәс чыккач, катайлылар иң зиһенле вә гыйлемле Габделкаһир Габделвахитовны үз араларыннан сайлап, югары инстанцияләрдә үз хокукларын яклауны йөклиләр1.

Габделкаһир Габделвахит улы балалары: Габделнасыйр (1827–24.03.1889), Гарифулла (1837), Хәбибулла (1844–21.12.1907).

Габделнасыйр Габделкаһир улы балалары: Хәмидулла (1855–27.08.1909), Галиулла (1858), Гыйльмебану (1872), Гаделбану (20.06.1876; анасы Шәһәрбану), Габделхәбир, Габдулла (16.06.1883), Сәйфулла (09.08.1887–1892). Габделнасыйр кызы Гыйльмебану (18 яшь) 1890 елның 12 гыйнварында Яңа Катайның Арслангали Мөхәммәтшәриф улы (25 яшь; атасы Мөхәммәтшәриф Мөхәммәтвәли улы) белән никахлаша. Кыз тарафыннан вәли вәкил – Габдерәфикъ Габделтаһир улы, ризалык шаһитлары Кашшафетдин Шәйхетдин улы белән Мөхәммәтшакир Могтәметдин улы була.

Хәмидулла Габделнасыйр улыннан бары Галимҗан (03.11.1897–1898; эч авыруыннан; анасы Сәрвиҗиһан Корычның Мөхәммәтәмин кызы) билгеле.

Габделхәбир Габделнасыйр улы балалары: Габделгани (08.08.1908; анасы Фәхрелбанат Габделкаюм кызы), Бибигарифә (20.08.1912; анасы Шәрифә Мофаздал кызы). Хәбир Насыйров читкә чыгып китә, 1917 елда авылда хуҗалыгы булмый.

Габдулла Габделнасыйр улы (26 яшь) 1909 елның 19 ноябрендә Бөгелмә өязе Тәйсуган авылының Фәрхиҗиһан Габделсаттар кызы (17 яшь; атасы Габделсаттар Ярмөхәммәт улы) белән никахлаша. Кыз тарафыннан вәли вәкил – бертуган агасы Сәлимгәрәй Габделсаттар улы, кияүнең дә вәкиле бертуган агасы Габделхәбир Габделнасыйр улы була. Кызның ризалык шаһитлары – Нуретдин Шәрәфетдин улы (Азамат нәселеннән) белән бертуган энесе Мөхәммәтгәрәй Габделсаттар улы, кияүнеке нәселдәшләре Һидиятулла Хәбибулла улы белән Шәехзаман Шәяхмәт улы була. Әлеге никах Яңа Катайның икенче мәхәлләсендә теркәлә. Габдулла Габделнасыйр улының бу никахтан балалары: Латыйфулла (28.08.1910–1910), Шәрхемулла (09.10.1911), Нигъмәтулла (19.02.1914–1916). Габдулла Насыйров (35 яшь) 1917 елда хатыны (24) һәм ике улы белән яши, 3,80 дисәтинә җире, аты һәм 2 сыеры була.

---

[1] БҮДТА, И-2 ф., 1 тасв., 4185 сакл. бер.

Хәбибулла Габделкаһир улы балалары: Кәлимулла (13.05.1917 елда мәрхүм), Хөрмәтулла (1868–21.10.1913), Зиннәтулла (28.04.1880), Һидиятулла (24.02.1883), Хәбибрахман, Гыйниятулла (03.05.1897), Насыйбулла (08.06.1899), Хикмәтулла (1901–16.07.1908; анасы Хәерниса Килкабызның Заһидулла кызы), Шәмсениса (07.05.1903), Гыйльмениса (1906–1909, кызамыктан). Хәбибулла кызы Фәрхиҗиһан (18 яшь) 1895 елның 13 ноябрендә Килкабызның Гобәйдулла Заһидулла улы (22 яшь) белән никахлаша. Шул ук Фәрхиҗиһан (22 яшь; икенче никах) 1898 елның 3 мартында Бала Куян авылы кешесенә кияүгә чыга. Кызның бер ризалык шаһиты Мирказыйгаяз Күчемов була. Гыйниятулла Хәбибуллинны Ватан сугышына алалар, хатыны Гафифә (1896), балалары Газим (1926), Сәүдә (1928) һәм Хәүлә (1931) кала.

Кәлимулла Хәбибулла улы балалары: Бибихәтимә (1889 елда мәрхүм), Гарифулла (16.03.1876–1903; анасы Латыйфа). Кәлимулла Хәбибулла улы (икенче никах) 1903 елда Кадернең Шәмсезиядә Гыйльван Гыйльман улының кызы (30 яшь; өченче никах) белән никахлаша. Гарифулла Кәлимулла улы балалары: Хәкимә (03.05.1897–1912), Шәфигулла (15.06.1900; анасы Хәсәнҗиһан Иске Катайның Миңлегали кызы). Шәфигулла Гарифуллинның хатыны Талига (1912), улы Малик (1936) була, хуҗалыгы Ватан сугышы алдыннан бетә.

Хөрмәтулла Хәбибулла улы (26 яшь) 1900 елның 16 февралендә авылдашы Җәләлетдин Гыймадетдин улының кызы Мәүсуфа (18 яшь) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле – Кәлимулла Хәбибулла улы, кияүнеке Хәбибулла Габделкаһир улы була. Кызның ризалык шаһитлары Нәбиулла Кәлимулла улы белән Шәйхулла Рәхмәтулла улы була. Хөрмәтулла балалары: Шәрхемулла (23.09.1905–1909, кызамыктан вафат; анасы Мәүсуфа Җәләлетдин кызы), Хамматулла (07.09.1909), Кәлимулла (19.06.1913; анасы Таифә Шәрәфетдин кызы).

Габделвахит Сөярголовның өченче улы Габделханнан иде. Габделханнанның уллары Габделнасыйх (1827) белән Йосыфтан (1838) бер бала да теркәлмәгән. Габделвахит Сөярголовның дүртенче улы Габделмәннанның да нәселен дәвам иткән ир балалары юк.

Габделвахит Сөярголовның бишенче улы Шәйхетдингә (1818–16.04.1886) тукталып үтик. Шәйхетдин Габделвахит улы балалары: Камалетдин (1846–22.09.1892; ютәл зәхмәтеннән вафат), Кашшафетдин (1859; анасы Фәрхиҗамал Гайсар кызы), Бибитаифә (1852), Бибифатиха (1855), Бәдриҗамал, Бибихәнифә (1869). Шәйхетдин кызы Бәдриҗамал (18 яшь) Иштирәкнең Борһанетдин Шәмсетдин улы (25 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Бибихәнифә (18 яшь) 1887 елның 4 октябрендә Яңа Катайның Шәйсолтан Ильяс улы (22 яшь) белән кавыша.

Камалетдин Шәйхетдин улы балалары: Шәрәфетдин (1867), Мифтахетдин (01.06.1875), Бибигатифә (1876), Бибигазизә (03.04.1877), Кашшафетдин (26.06.1878), Бибигазизә (1879–1893), Хәйретдин (29.06.1881), Шәрифҗамал (1882–1897), Сәгыйдетдин (16.12.1883), игезәкләр Миңесорур (29.06.1887–1888) белән Миңлесафа (29.06.1887–1888; аналары Маһикамал). Камалетдин кызы

Бибигатифә (18 яшь) 1895 елның 1 гыйнварында Иштирәкнең Шәрифулла Сафиулла улы (22 яшь; атасы Сафиулла Габдулла улы) белән кавыша. Кызның вәли вәкиле – нәселдәше Кашшафетдин Шәйхетдин улы, ризалык шаһитлары Мөхәммәтшакир Могтәметдин улы белән Шәрәфетдин Камалетдин улы була.

Шәрәфетдин Камалетдин улы балалары: Шәйсолтан (29.12.1878; анасы Фәриха), Мәдхия (29.12.1897–1899; анасы Мәлиха Корычның Муллаян кызы). Шәрәфетдин Камалетдин улы (35 яшь; дүртенче никах) 1901 елның 10 сентябрендә Яңа Катайның Гарифулла Фәйзулла улының төпчек кызы Мәрфуга (17 яшь) белән кавыша. 1917 елгы исемлектә Шәрәфетдин Камалетдинов (50 яшь) читкә чыгып киткән дип күрсәтелә.

Мифтахетдин Камалетдин улы 1904 елның сентябрендә Яңа Катайның Гайса Шәяхмәт улының кызы Бибизакирә белән никахлаша, балалары Мөхәммәткәшиф (03.07.1906), Мөхәммәтнасыйх (22.03.1908), Мөхәммәтвазыйх (05.08.1910–1912) дөньяга килә. Мифтахетдин 43 яшьтә 1915 елның 3 ноябрендә Яңа Катайның Бибифатиха Хөснетдин кызы (30 яшь; өченче никах) белән никахлаша, 1916 елның 12 апрелендә «мәхәббәтләре юклыктан» аерылышалар. Шул ук Мифтахетдин 1916 елның 10 маенда үзе кебек күп никахлы авылдашы Миңлекамал Нәдергол кызы белән кавыша.

Кашшафетдин Камалетдин улыннан Әгъләметдин (03.10.1908–1909, кызамыктан) билгеле. Хәйретдин Камалетдин улы балалары: Әгъләметдин (10.07.1910), Бибисания (10.04.1925; анасы Саимә Әхияретдин кызы). Хәйретдин Камалетдинов 1941 елда мәрхүм була, бу вакытта хатыны Саимә, балалары Минаҗетдин (1920), Сания (1925), Әкрәм (1928) була.

Кашшафетдин Шәйхетдин улы (35 яшь; икенче никах) 1892 елның 19 октябрендә нәселдәше Фатыйма Мөхәммәдьяр кызы (18 яшь; атасы Мөхәммәдьяр Мөхәммәткәрим улы) белән никахлаша. Аның бу һәм башка хатыннарыннан балалары: Хәсәнҗиһан (29.10.1884–1888), Гыйззетдин (1886–1888), Әһлетдин (22.07.1889–1892; анасы Фәрхиҗиһан), Фәтхетдин (1891–1892), Хәтирә (07.12.1895), Кәраметдин (23.12.1897; анасы Фатыйма Мөхәммәдьяр кызы), Бибиталига (05.07.1900), Фазлытдин (04.06.1902–1905), Миңлеһәдия (1905–1904, кызамыктан вафат), Миңлезакирә (06.07.1908–1909, кызамыктан), Әнвәретдин (27.04.1911; анасы Фатыйма Мөхәммәдьяр кызы), Шәрхемулла (29.11.1914; анасы Кәшифә Раян кызы), Шәрифулла (15.07.1925).

Әнвәр Шәйхетдинов (1911) Ватан сугышы алдыннан хатыны Рәшидә (1915), балалары Әхияр (1938), Гөлчирә (1940), анасы Фатыйма (1868) белән яши.

Габделвахит Сөярголовның төпчек улы Могтәметдин (1827–30.11.1877) иде. Могтәметдин Габделвахит улы балалары: Мөхәммәтхафиз (1854), Мөхәммәтзакир (1859–09.12.1914, ютәл авыруыннан), Мөхәммәтгариф (1862–23.02.1907), Мөхәммәтсабир, Мөхәммәтшакир, Фәррахетдин, Афзалетдин (10.08.1874; анасы Хәерниса), Бибигайшә (1876). Могтәметдин кызы Бибигайшә 1894 елның 9 декабрендә авылдашы Нурислам Габделихсан улы белән никахлаша.

Мөхәммәтхафиз Могтәметдин улы балалары: Бибизәйнәп (1868), Мөхәммәтдин (05.10.1883–1888), Бибизәкия (20.09.1885–1887), Бибифатыйма (28.12.1887), Мөхәммәтдин (27.01.1889–1879; Ватан сугышы ветераны), Мөхәммәтсалих (20.03.1891–1892), Бибикәшифә (23.11.1892), Габделбасыйр (08.11.1894; анасы Насиха Байбулат авылының Габделкаһир кызы), Габделзаһир (23.06.1898). Мөхәммәтхафиз кызы Бибизәйнәп (18 яшь) 1886 елның 25 февралендә нәселдәше Әхмәтхан Мөхәммәтҗан улы (26 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Бибикәшифә (20 яшь) 1914 елның 15 гыйнварында Корычның Газизҗан Шәйхулла улы (23 яшь; атасы Шәйхулла Гарифулла улы) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтсабир белән Мөхәммәтшакир Могтәметдин уллары була. Мөхәммәтхафизның ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда ул хатыны белән генә яши, 7,63 дисәтинә җире, 2 аты, 3 сыеры һәм башка маллары була.


**Мөхәммәтдин Хафизов**

Мөхәммәтдин Мөхәммәтхафиз улы Җәмилә Насыйбулла (1897) кызы белән гаилә кора, балалары Тәкмилә (1924), Тәрҗимә (24.10.1925), Акмал (1928), Хәния (1930), Зәмзәмия (1934), Гафия (1939), Миңнефлүзә (1943) дөньяга килә. Кызларның барысы диярлек үз ярын Катайда таба: Тәкмилә – Закир Фәрраховка, Тәрҗимә – Әүхади Дәүләтовка, Хәния – Әгъләә Вәлиевкә, Гафия – Фәнил Галиуллинга, Миңлефлүзә – Фәһим Вәлиәхмәтовка кияүгә чыга, бер Зәмзәмия генә Куян авылы кешесе белән гаилә кора. Мөхәммәтдиннең төпчек кызы Миңлефлүзә (1943) атасының сугыш елларында Чиләбедә хезмәт армиясендә булуын әйтте.

Габделбасыйр Мөхәммәтхафиз улы гаиләсендә Габделзаһир (23.10.1925; анасы Шәрифә Шәрифулла кызы) һәм Мансур туа. Габделзаһир Яңа Катайның Нурлыгаян Дәүләтов кызы Фәния (1932) белән гаилә кора. Мөхәммәтсабирның улы Хәниф була.

Хәмит абый Маликовтан Мөхәммәтхафизның уллары кемнәр дип сорагач, Мөхәммәтдин, Габделбасыйр һәм Мөхәммәтсабирны әйткән иде. Һәрберсе турында җентекләп сорарга вакыт аз булгандыр, күрәсең, шулай да Сабирны «яраплан Сабир» дип әйткәннәрен язып куйганмын. Ни өчен дигәч, алдакчы булганга, диде. Сабир яшәгән заманда аэропланнар яңа гына оча башлаган, моның да очып карыйсы килгән, очкан да, имеш. Сабир белән Таҗинең (шул Сабирның ерак нәселдәше) ничек очканнары турында «Үткәннәрен бел Катайның» китабының 101 нче битендә әйтелә.

Мөхәммәтзакир Могтәметдин улы балалары: Миңлемөхәммәт (26.12.1888; анасы Фәхрибанат), Миңлеәхмәт (1890–1893, ютәл зәхмәтеннән), Мәрьям (21.07.1894), Мөхәммәтгали (26.04.1897), Шәмсемөхәммәт (08.02.1900; анасы Фәхрибанат Тыпыйның Хисаметдин кызы), Кифая (04.02.1903), Мөхәммәтхә-

ниф (12.10.1906), Газизҗан (27.12.1909). Мөхәммәтзакир кызы Бибимәрьям 1917 елның 30 маенда Дияш олысы Яңа Әҗми авылының Габделлатыйф Габдерәхим улы (26 яшь; атасы Габдерәхим Габделгалим улы) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле – энесе Мөхәммәтгали Мөхәммәтзакир улы, ризалык шаһитлары Мөхәммәтшакир белән Фәррахетдин Могтәметдин уллары була. Газизҗан Закиров «Байкал» колхозы рәисе була, 1941 елның 14 июлендә сугышка китә. Фронтка озатканда хатыны Әдия (1916), уллары Фарис (1939), Роберт (1941), кызлары Фәвәзимә (1935), Ягъдә (1938) кала. Газизҗан 1966 елгы документта Могтаев фамилиясендә теркәлгән. Роберт Газизҗан улы Закиров совхозда трактор бригадасында эшли, 1969 елның көзендә совхоздан китә.

Мөхәммәтгариф Могтәметдин улы Габделвахитов балалары: Мөхәммәтрәуф (10.02.1885–1886), Бибинәфисә (15.08.1888), Саҗидә (22.11.1890), Әхмәтнәгыйм (20.07.1893; анасы Гөлфәрзанә Камай авылының Галиулла кызы), Габдерәуф (28.09.1899), Госаметдин (07.07.1902). Мөхәммәтгариф кызы Саҗидә (18 яшь) 1909 елның 6 ноябрендә Камайның Шәмсетдин Шәйхетдин улы (25 яшь; атасы Шәйхетдин Исхак улы) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Афзалетдин Могтәметдин улы белән Әхмәтнәгыйм Мөхәммәтгариф улы була. Әхмәтнәгыйм Мөхәммәтгариф улыннан Миңлемәгъсүмә (17.06.1925; анасы Фәрхәнә Заһидулла кызы) билгеле.

Мөхәммәтшакир Могтәметдин улы Габделвахитов балалары: Бибигарифә (1893–1911), Миңлегалимә (11.04.1894; анасы Гайшә), Мөхәммәтгалим, Миңлеәһлия (18.01.1899–1900, кызамыктан), игезәкләр Хәсән белән Хөсәен (08.12.1900–1901; анасы Гайшә Корычның Сәхаутдин кызы), Миргалим (04.01.1902), Фатыйма (20.09.1904), Миңлеәхмәт (03.08.1906; анасы Бибигайшә Сәхаутдин кызы), Миңлегарифулла (26.02.1909), Мөхәммәтнәби (29.08.1911). Мөхәммәтгалим Мөхәммәтшакир улыннан Мөхәммәткамил (29.08.1925; анасы Мәгъфүрә Габделхаликъ кызы) туган. Камил Галим улы Шакиров (1925) – Ватан сугышы ветераны.

Афзалетдин Могтәметдин улы балалары: Бибисара (29.05.1903; анасы Һәдия Мөхәммәтлатыйф кызы), Әхкәметдин (02.08.1907–1909, чәчәк зәхмәтеннән вафат; анасы Миңлегалия Габделлатыйф кызы), Әнвәретдин (22.06.1910; анасы Миңлегалимә Мөхәммәтлатыйф кызы), Кәраметдин (29.08.1913–1914, кызамыктан), Әгъләм (1920). Афзалетдин Могтәметдинов 1917 елда хатыны (40 яшь), улы һәм кызы белән яши, 3,78 дисәтинә җире, 3 аты, сыеры һәм кәҗәсе була. Әнвәретдин Афзалов (1910) 1941 елның 14 июлендә китеп, 1944 елның ноябрендә сугышта һәлак була, хатыны Дөһөдия (1916), кызы Асия (1939), анасы Әдия кала. Әгъләм Афзалов 1942 елда сугышта хәбәрсез югала.

Монда бер искәрмә ясап үтик. Афзалетдиннең бер генә хатыны (метрикәдә – Һәдия, халык телендә Әдия) була, әмма Иске Катайның беренче мәхәллә имамы Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтнәби улы кулы белән язылган метрикәдә шул хатын төрлечә күрсәтелә, кемдер моңа карап әллә берничә хатын белән яшәгәнме дип уйларга мөмкин. Ярый, өстәмә чыганак – сугыш

алды исемлеге һәм «Халык хәтере» сайты мәгълүматы — бар, шуңа карап дөрес исемен белдек. Мондыйрак хаталар башка муллаларда да күзәтелә, андый очракларга урыны-урыны белән тукталып үтәрбез.

Югарыда Сөяргол Юлдашевның улы Габделвахиттан (1770—1856) киткән тармакларны карадык. Сөярголның икенче улы Габделвәлидән (1793) дә нәсел дәвам итә. Габделвәли Сөяргол улы балалары: Габделвафи (1822—15.09.1892), Габделнәфикъ (1829—26.11.1904), Мөхәммәтвәли (1836).

Габделвафи Габделвәли улының 1859 елда хатыннары Хәлимә Хәйбулла кызы (1824) белән Сафия Сәйфулла кызы (1827) була. Габделвафи балалары: Габделлатыйф (1851), Шәмсениса (1855), Габделвахит (1869), Миңлеәминә (1877), Мөхәммәтнәҗип, Габделмәҗит (10.10.1885), Габделмалик (27.02.1889; анасы Бибиҗәмилә), Хөббениса (1864—1884). Габделвафи кызы Шәмсениса (20 яшь) 1876 елның 1 мартында Сакатның Нәбиулла Сәйфулла улы (22 яшь) белән кавыша. Икенче кызы Миңлеәминә (18 яшь) 1895 елның 27 гыйнварында Яңа Катайның Төхфәтулла Гайнулла улы (50 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле — агасы Габделлатыйф Габделвафи улы, ризалык шаһитлары Мөхәммәтзариф Габделнәфикъ улы белән Габделвахит Габделвафи улы була. Әлеге никах шул ук елның 21 сентябрендә «араларында мәхәббәт вә өлфәт булмаган сәбәпле» таркала.

Габделлатыйф Габделвафи улы балалары: Габдерәкыйп (14.03.1877; анасы Газизә), Һәдия (10.11.1882), Миңлегалия (29.12.1885), Миргабитҗан (15.11.1888), Гыйлемҗан (1890). Габделлатыйф кызы Һәдия алдарак сүз барган нәселдәше Афзалетдин Могтәметдин улы белән гаилә кора (фараз кылып әйтәм). Икенче кызы Миңлегалия (18 яшь) 1907 елның 8 ноябрендә авылдашы Әхмәтшәех Әхмәдиша улы (26 яшь; атасы Әхмәдиша Мөхәммәдиша улы) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары — Габдерәкыйп Габделлатыйф улы белән Габделвахит Габделвафи улы, егетнеке Шәвәли Габдерәфикъ улы белән Нурлыгаян Габделнәфикъ улы була. Латыйф Вафиевнең (66 яшь) ике улын — Гыйлемҗан белән Миргабитҗанны — Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда 6,83 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры, 5 сарыгы була.

Габдерәкыйп Габделлатыйф улы 1904 елның мартында авылдашы Мөхәммәтзариф Вәлимөхәммәт улының кече кызы Бибигалимә (18 яшь) белән никахлаша, балалары Шәрифҗан (06.11.1905; анасы Бибигалимә Мөхәммәтзариф кызы), Әмирҗан (26.02.1911) дөньяга килә.

Гыйлемҗан Габделлатыйф улы балалары: Зәкиҗан (10.05.1924—12.08.2000), Мәгъфурҗан (1928), Әшрәфҗан (1930—1980) һәм Әмирҗан (1934) Латыйповлар. Зәкиҗан белән Мәгъсүмә Солтангәрәй кызы (01.07.1926—11.09.2001) балалары: Мөдәмир (02.09.1948), Гөлсинә (07.11.1952), Мәвазиф (18.03.1955), Рәзиф (19.05.1958). Әшрәфҗан балалары: Мирзаһит (1955), Гөлчирә (1956), Сәгит (1958), Әлфидә (1960), Фәнил (1964—2007). Рәзиф Зәкиҗан улы Латыйпов дин һәм әхлак турында кайгыртып, Иске Катай күрке булган «Әниләр» мәчетен төзетте, бу изге гамәле белән туган авылы тарихына керде, башкаларга үрнәк күрсәтте.

Габделвафиның башка улларыннан да нәсел дәвам итә. Габделвахит Габделвафи улы (25 яшь) 1894 елның 10 декабрендә Яңа Катайның Гарифулла Гафиятулла улы Мортазин кызы Сәгыйдәбану (17 яшь) белән никахлаша, балалары Камилә (02.05.1897), Бибикамал (1896–1899; эч рәнҗүеннән), Габделкаһир (04.07.1900–1902), Мәликә (29.03.1903), Габделхәбир (13.05.1905), Сәфәргали (29.03.1907–1909, чәчәк зәхмәтеннән вафат), Габдулла (29.10.1909–1916), Миңлебану (23.07.1914) туа. Вахит Вафиев (50 яшь) 1917 елда хатыны (50) һәм кызы (10) белән яши, 1,75 дисәтинә җире була. Ярлы яшәгәнлектән, көтүче булып ялланган. Мөхәммәтнәҗип Габделвафи улыннан бары Миңлеәһәдия (8.01.1914) билгеле.

Габделмәҗит Габделвафи улы балалары: Габделфаяз (03.11.1916; анасы Сәхипкамал Гыйсмәтулла кызы), Мөдәррис (24.03.1924; анасы Сәхипкамал Сәхипгәрәй кызы), Вәҗиһа (1930; Баекта кияүдә), Рәзифә (1934). Мәҗит Вафиев (35 яшь) 1917 елда хатыны (25 яшь) һәм улы (1) белән яши, 3,17 дисәтинә җире, 2 аты, 3 сарыгы һәм кәҗәсе була. Аның улы Мөдәррис Вафиев 1944 елда Ватан сугышында хәбәрсез югала (исеме Катайның мемориаль стеласына язылмаган).

Югарыда нәселне Габделвафи Габделвәли улы яклап карадык. Габделвафиның энесе Габделнәфикъка күчик.

Габделнәфикъ Габделвәли улы балалары: Мөхәммәтзариф (1854–1912), Бибифатыйма (1868), Нургали (1869), Маһисорур (1870–1884), Нурлыгаян (29.07.1877; анасы Маһинур), Шәмсеҗамал (1881), Габдерәкыйп, Хәбибҗамал (08.08.1898–1899, эч авыруыннан; анасы Әсхәбҗамал Аблайның Шәнгәрәй кызы). Габделнәфикъ кызы Бибифатыйма (18 яшь) 1887 елның гыйнварында Яңа Катайның Мөхәммәтдин Габделлатыйф улы (25 яшь; атасы Габделлатыйф Габделсаттар улы) белән кавыша. Икенче кызы Шәмсеҗамал (18 яшь) 1899 елда Дөмәй авылы кешесе белән никахлаша.

Мөхәммәтзариф Габделнәфикъ улы 1876 елның 25 декабрендә авылдашы Шәмсекамал Мөхәммәдиша кызы (18 яшь; Табыш нәселеннән) белән гаилә кора, балалары Шәмсеҗамал (23.03.1880), Шәмсеҗиһан (1882), Өммегөлсем (16.02.1883), Хәмидә (1885), Бибивәдига (11.02.1895) туа. Мөхәммәтзариф кызы Өммегөлсем (18 яшь) 1900 елның 29 ноябрендә авылдашы Бикмөхәммәт Әюп улы (23 яшь; атасы Әюп Габделгали улы) белән кавыша. Икенче кызы Шәмсеҗиһан (20 яшь; икенче никах) 1902 елның 3 июлендә Куянның Муллагали Гыйрфан улы (35 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Төпчек кызы Бибивәзига (18 яшь) 1913 елның 13 февралендә Яңа Катайның Исламгали Әхтәмгали улы (25 яшь) белән гаилә кора. Кызның ризалык шаһитлары – Әхмәтгали белән Мөхәммәтхарис Мөхәммәдиша уллары, егетнеке Әхмәтвәли Габделмәннаф улы һәм Мөхетдин Габделлатыйф улы була.

Нургали Габделнәфикъ улы (25 яшь) 1894 елның 9 декабрендә Яңа Катайның Корбангали Әхмәт улының кызы Фәрхизиядә (18 яшь) белән никахлаша. Егетнең вәли вәкиле – атасы Габделнәфикъ Габделвәли улы, ризалык шаһитлары Әхмәтвәли Җәләлетдин улы белән Мөхәммәтвәли Габделвәли улы була.

Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтшәриф белән Мөхәммәтситдыйкъ Корбангали уллары була. Нургалине мулла ялгыш Нурлыгаян дип язган, бу хатаны төзәттек. Нургалинең бу никахтан балалары: Хәйдәретдин (1896), Миңлегалимә (06.02.1897), Саимә (1898–1899), Бәһия (23.01.1900), Миңлефәүзә (10.02.1902), Миңлерәхимә (03.07.1906), Миркасыйм (22.12.1907), Миңлерауза (13.10.1909), Миңлерәҗәп (13.07.1911–1914, кызамыктан вафат). Нургали кызы Бибигалимә (18 яшь) 1916 елның 18 мартында нәселдәше Муса Гайса улы (23 яшь) белән никахлаша. Нургали Нәфиковның (49 яшь) улын (Хәйдәретдинне) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда ул хатыны (52) һәм биш кызы белән яши, 8,80 дисәтинә җире, 2 аты, 3 сыеры һәм башка маллары, җилгәргече була.

Хәйдәретдин Нургали улы балалары: Асия (1923–1924), Мәккия (20.07.1925; анасы Талига Ярулла кызы), Рәүдә (1931), Мөнзия (1936), Гамил (1939–1977). Гамил Хәйдәр улы Нургалиев – гомеренең соңгы чорында Яңа Маты совхозының Катай бүлекчәсендә ферма мөдире булып эшләде, авыл советы депутаты булды, балалары: Дамир, Румия, Рәфил.

Нурлыгаян Габделнәфикъ улы балалары: Мөҗәһидә (24.09.1905; анасы Бәдерҗиһан Габделханнан кызы), Сәрвәрия (23.08.1907; анасы Мәдхиҗиһан), Миңлеразия (08.10.1909; анасы Мәдхиҗиһан Габделханнан кызы), Оркыя (12.02.1911), Хәмзә (29.08.1913–1916; анасы Миңлеҗиһан Сәүбән кызы), Рәйфә (08.04.1916; анасы Миңлеҗиһан Габделханнан кызы), Гыйльмелгаян (01.09.1925; анасы Миңлеҗиһан Габделихсан кызы), Әмирҗан (1928–1981), Мәрьям (1933). Нурлыгаянның хатыны исемен беренче мәхәллә мулласы (Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтнәби улы) төгәл белмичә-сорашмыйча, үз белдеге белән әнә шулай төрлечә язган, димәк, вазифасын җаваплы башкармаган. 1917 елда Нурлыгаян Нәфиковның 4,63 дисәтинә җире, аты һәм 5 сарыгы була. Гыйльмелгаян Нәфиков сугышта һәлак була (исеме Катайның мемориаль стеласына язылмаган). Әмирҗан Нәфиков озак еллар Катай авыл советы секретаре (берара шунда рәис) булып эшләде, аның Гөлсем Назиф кызы (1930–2015; Чакмагыш районының Бүләк авылында туып-үскән) белән никахыннан балалары Рәзилә (1955), Венера (1957), Лүзия (1961), Илдар (1965) туа.



**Нәселдәшләр Ясир Шәвәлиев (сулда) белән Әмирҗан Нәфиков**

Габдерәкыйп Габделнәфикъ улыннан кызы Бибисара (13.06.1901; анасы Халидә Тыпыйның Фәрхетдин кызы) билгеле.

Габделвәли Сөярголовның төпчек улы Мөхәммәтвәли (1836) иде. Мөхәммәтвә-

ли Габделвәли улы балалары: Мөхәммәтнәби (1867), Гыйльмиҗиһан (1868), Миргали, Госмангали (18.06.1874; анасы Бибисафа), Исламгали (22.10.1876), Шәмсеҗиһан (25.01.1880). Мөхәммәтвәли кызы Гыйльмиҗиһан (19 яшь) 1887 елның 25 сентябрендә Минзәлә өязе Исәнсеф авылының Мөхәммәтхарис Мөхәммәтлатыйф улы (25 яшь; атасы Мөхәммәтлатыйф Зөбәер улы) белән никахлаша.

Мөхәммәтнәби Мөхәммәтвәли (Габделвәли дип тә күрсәтелә) улы балалары: Фәрхениса (04.07.1902; анасы Хәсбиниса), Мөхәммәтҗан (14.08.1908–1910; анасы Хәсбиниса Мостафа кызы), Рамазан (14.09.1911), Хәерзаман (21.01.1915). Мөхәммәтнәби Вәлиев (52 яшь) 1917 елда хатыны (30) һәм өч улы белән яши. Такта яру белән кәсеп иткән.

Миргали Мөхәммәтвәли улы балалары: Бибикамилә (20.11.1894; анасы Мәликә Габделвәли кызы), Шәмсеҗиһан (21.01.1898; анасы Мәликә Корычның Габделвәли кызы).

Госмангали Мөхәммәтвәли улы балалары: Мөхәммәтгали (11.11.1900; анасы Бәдрисафа Мөхәммәтгали кызы), Шәмсениса (18.02.1903), Габделгали (15.07.1905; анасы Гыйzzелбанат Габделкаюм кызы), Миңлениса (1908–1909, чәчәк зәхмәтеннән вафат), Шәехгали (07.12.1909), Миңлесәетгали (16.01.1913; бабасы Габделвәли дип язылган), Габделгани. Госмангали Габделвәлиев (фамилиясе шулай язылган; 44 яшь) 1917 елда хатыны (40), ике улы һәм дүрт кызы белән яши, 3,06 дисәтинә җире һәм аты була. Ватан сугышы алды еллары исемлегендә Госмангалинең туган елы 1873 нче ел дип күрсәтелгән, гаиләсендә хатыны һәм өч улы күрсәтелә. Мөхәммәтгали (1900), Шәехгали (1909) белән Сәет (1913; фамилиясе Вәлиев) Бөек Ватан сугышына китәләр, беренчесе 1942 елда хәбәрсез югала, соңгысы исән кайта. Мөхәммәтгали Госмановның хатыны Мәргубә (1903), уллары Фазыйл (1930), Әбелгасыйм (1932), Кәнәфи (1940), кызы Флүрә (1935) була (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән). Шәехгали Госманов сугышка 1941 елның 14 июлендә китә, хатыны Тәгъзимә (1909) кала. Сугыш чорында «Валеев Шайхалей Усманович» дип теркәлгән, хәрби әзерлек үткәч, 1943 елның 18 ноябрендә фронтка китә (язмышы билгесез).

Исламгали Мөхәммәтвәли улы балалары: Гайнелхәят (05.11.1904), Нурхәят (25.01.1907), Бибимәрьям (01.01.1910; анасы Шәмсехәят Шәмсетдин кызы), Мөхәммәтхәнәфи (1913–1914, кызамыктан). Исламгали Габделвәлиевне (40 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (30) һәм ике кызы кала, 1917 елда 0,30 дисәтинә җире, 4 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була.

Шулай итеп, Сөяргол тармагыннан киткән нәселдәшләрем бүгенге көндә Әхмәтов, Басыйров, Вафиев, Вәлиев, Госманов, Кадыйров, Латыйпов, Нәфиков, Нургалиев, Шакиров, Шәвәлиев фамилияләре белән билгеле.

**Юлдашның ерак нәселдәше – Мостафа Аетов** (1753–1820). Мостафа уллары: Мөхәммәтгали (1803), Мөхәммәтша (1815–1818), Корбангали (1821–1855). Мөхәммәтгали уллары: Мөхәммәди (1841), Арслангали (1853).

Мөхәммәди Мөхәммәтгали улы балалары: Бибикамилә (1869), Кашшафетдин (Кәшфетдин; 01.09.1876; анасы Вәдига), Имаметдин (1879–1914), Хәйретдин (16.10.1882). Мөхәммәди кызы Бибикамилә (18 яшь) 1887 елның 10 ноябрендә Камайның Мөхәммәтсаяф Мөхәммәтзариф улы (22 яшь; атасы Мөхәммәтзариф Мөхәммәткәрим улы) белән никахлаша. Мөхәммәди Мөхәммәтгалинның улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда аның 1,76 дисәтинә җире, аты һәм 4 кәҗәсе була.

Кәшфетдин Мөхәммәди улы балалары (беренче мәхәллә): Җәмгыйтдин (18.06.1906–1912; анасы Мәгърифә Шаһидулла кызы), Гыйлемҗан (19.12.1914), Әгъләметдин (3.08.1916; анасы Мөнәзә Мәгъдәннур кызы). Кәшфетдин 1910 елда хатыны Мәгърифә вафат булгач, Мөнәзә белән гаилә кора. Кәшфетдин Мөхәммәдиев 1917 елда хатыны (30 яшь) һәм улы (2) белән яши, 1,05 дисәтинә җире һәм 2 кәҗәсе була.

Имаметдин Мөхәммәди улы балалары: Мөсәвәрә (13.12.1910; анасы Шәмсенур Мөхәммәтсалих кызы), Имамгыйззәли (18.04.1913). 35 яшьлек Имаметдин 1914 елда ютәл зәхмәтеннән мәрхүм була.

Хәйретдин Мөхәммәди улы (25 яшь, икенче никах; атасы Мөхәммәди Мөхәммәтгали улы) 1912 елның 19 октябрендә ерак нәселдәше Исмәгыйль Миңлегали улының өченче кызы Фәрхисорур (18 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары – Кәнзелголум Сәйфулла улы белән Нургали Миңлегали улы, кияүнеке Нурлыгаян Габделнәфикъ улы белән Габделгалләм Габделмалик улы була. Хәйретдин балалары: Фәрхинур (12.07.1914; анасы Фәрхисорур), Миңлемөсәвәрә (12.12.1925; анасы Мөнәвәрә Мөхәммәтислам кызы).

Арслангали Мөхәммәтгали улы балалары: Бибисабира (15.12.1878; анасы Фәрвизә), Бибикафия (1879), Миңлесабира (1879–10.12.1881), Сәгыйдә (28.12.1880), Исламгали (20.02.1884–1884), Казыйхан (14.07.1888), Мирзахан (11.11.1890–1894), Нурдидә (14.10.1893; анасы Фәрвизә Гыймадетдин кызы). 1897 елның 25 мартында Арслангали (өченче никах) Яңа Катайның Гафиятулла Хәсән улы Мортазин кызы Җиһанбану (35 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Арслангали кызы Бибикафия (18 яшь) 1897 елның 25 октябрендә Яңа Катайның Галәветдин Хөснетдин улы (25 яшь; атасы Хөснетдин Хөсәен улы) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәди Мөхәммәтгали улы белән Гайса Габделгалләм улы була. Арслангали белән Мөхәммәди Мөхәммәтгали улларының тамгалары Юлдаш нәселенеке белән тәңгәл килә. Шул ук Бибикафия (25 яшь; икенче никах) 1904 елның гыйнварында Яңа Катайның Габделхаликъ Йөзәй улы (30 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары ерак нәселдәшләре Габделҗәлил Габделгалләм улы белән Сәйфетдин Шәмсетдин улы була. Арслангалинең икенче кызы Сәгыйдә ерак нәселдәше Сәйфетдин Шәмсетдин улы белән кавыша.

Югарыда китерелгән никах язуларына игътибар итсәк, Мостафа Аетовтан киткән тармак белән Юлдаштан киткән тармак вәкилләренең тыгыз элемтәдә булуын күрәбез. Без бер нәсел кешеләре дип, аралашып яшәгән алар.

**Юлдашның ерак нәселдәше – Йортбагыш.**

Нәселнең бу тармагы Йортбагыштан башлана. Юлдаш белән Йортбагыш – бер нәселдән, аларның варислары күп гасырлар буена бер үк нәсел тамгаларын кулланып килгәннәр. Ревизия исемлекләрендә дә алар гел янәшә баралар, башта – Юлдаш, аннары Йортбагыш варислары теркәлә.

Моны архив документлары буенча ныклап ачыклаганчыга кадәр үк, кайбер нәселләр турында мәгълүматлы Рим Гыйлембаян улы Нәбиев бервакыт күршесе Әхмәтнәгыйм Зарипов ягына ишарәләп, «алар да сезнең нәсел», дип әйткән иде. Ул чагында аның бу сүзләрен шактый гаҗәпләнеп, ышанмыйчарак кабул иткән идем.

Йортбагышның Зыят (1710 елда туган) һәм Тимер (1721) исемле уллары була. Зыяттан Гомәр (1742–1805) белән Гайсар (1749) туган, икесеннән дә нәсел дәвам итә. Гомәрнең уллары Таҗетдин (1777), Габделдаян (1794–16.11.1877), Раян (1799) була.

Гомәрнең беренче улы Таҗетдиннән (1778–1830) Гайнан (1804–1823), Гыймадетдин (1814–1827) һәм Сиражетдин (1823–1852) дөньяга килә. Сиражетдиннан нәселне Баһаутдин (1838–19.02.1883) дәвам итә. Баһаутдинның хатыны Нурҗиһан Тимергали кызы (1839), балалары Фәттахетдин (1870), Рабига (16.06.1874), Мифтахетдин (17.03.1877) була. Баһаутдин кызы Рабига (18 яшь) 1894 елның 10 декабрендә нәселдәше Мөхәммәтислам Мөхәммәтсафа улы (23 яшь) никахлаша. Никах язуында кызның бертуган агасы Фәттахетдин Баһаутдин улы, кияү ягыннан вәкил бертуган агасы Мөхәммәтсолтан Мөхәммәтсафа улы, кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтзариф Мөхәммәтҗан улы белән Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтсафа улы, егетнең ризалык шаһиты Мөхәммәтзариф Габделнәфикъ улы нәсел тамгасын күрәбез. Бу тамгалар Юлдаш белән Йортбагыш тармакларының нәселдәш булуын раслый.



**Нәселнең Юлдаш һәм Йортбагыш тармаклары вәкилләре салган тамгалар. 1894 ел**

Фәттахетдин Баһаутдин улы (25 яшь) 1895 елның 20 гыйнварында авылдашы Габделҗәмил Шаһингәрәй улының кызы Бибигайшәгә (18 яшь) өйләнә. Егетнең вәли вәкиле – Әһлиулла Шәяхмәт улы, ризалык шаһитлары Җомагол Рамазан улы белән Солтангәрәй Мөхәммәтгәрәй улы була. Бу никахтан Галимә (1896), Афзалетдин (18.03.1899, икенче мәхәллә), Маһикамал (1902–24.06.1903) туа. Фәттахетдиннең башка балалары: Мөхәммәтдин (16.12.1904; анасы Сәрвисафа Мөхәммәтзариф кызы), Таҗетдин (20.04.1906; анасы Сәрвисафа Гарифулла кызы), Җәмгыйтдин (20.11.1909–1910), Бибигамилә (01.10.1915; ана-

сы Шәмсенур Габдулла кызы). 1903 елның 20 апрелендә хатыны Бибигайшә мәрхүм булгач, Фәттахетдин Баһаутдин улы (35 яшь; икенче никах) шул елның маенда Яңа Катайның Мөхәммәтзариф Галикәй улының кызы Сәрвисафа (30 яшь; бишенче никах) белән никахлаша. Шул ук Фәттахетдин «мәхәббәтләре юклык өчен» 1911 елның 6 апрелендә Иске Катайның икенче мәхәллә мәчетендә Сәрвисафа Мөхәммәтзариф кызы белән аерылыша. Фәттахетдин кызы Галимә (18 яшь; икенче мәхәллә) 1914 елның 20 мартында Яңа Катайның Габидулла Гарифулла улы (22 яшь; атасы Гарифулла Фәйзулла улы) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтсафа улы белән Әхмәтгәрәй Мөхәммәтгәрәй улы була.

Таҗетдин Фәттахов Яңа Көчнең Мосаллия Шәмсемөхәммәт кызы (1911) белән никахлаша, балалары Мөдәррис (1935) белән Мосаллия (1938) туа. 1942 елда хәрби хезмәткә чакырыла, тылда хезмәт итә. Хатыны вафат булгач, балалары Бурят-Монголиядә балалар йортында тәрбияләнә. Сугыштан соң Фәйрүзә Сафиулла кызы Сафина (1917; Теләче районы Максабаш авылыннан) белән гаилә кора, балалары Илдус (13.11.1950), Рөстәм (1954), Мулланур (1957) туа. Азат Мулланур улы Таҗиев – үз нәселе тарихы белән ныклап кызыксынучыларның берсе, Казанда яши.


**Таҗетдин Фәттахов хәрби киемдә**

Гомәр картның уртанчы улы Габделдаяннан нәселне Мөхәммәтҗан (1815–15.03.1875) белән Мөхәммәтлатыйф (1835) дәвам итә.

Мөхәммәтҗан Габделдаян улыннан нәсел тагын да ишәя төшә. 1859 елгы документта аның гаиләсендә хатыны Шәмсевафа Бәхтияр кызы (1818), уллары Мөхәммәтшәфикъ (1839), Мөхәммәтситдыйкъ (1859 елда Мөхәммәтсадыйк дип хаталы язылган; 1844), Муллаян (1849–08.09.1903), Мөхәммәтзариф (1851–19.09.1917), кызы Бибигайшә (1842) теркәлгән. Мөхәммәтҗанның төпчек улы Әхмәтхан (1856–03.09.1916), ни сәбәпледер, 1859 елгы исемлеккә керми калган. Мөхәммәтҗанның бер кызы (Шәмсебану) Яңа Катайның Дәүләтгир Габделфәез улы Азаматов белән кавыша.

Мөхәммәтшәфикъ Мөхәммәтҗан улы балалары: Мөхәммәтназиф (1862), Мөхәммәтнасыйп (1868), Бибимәрхәбә (1870–1894), Әхмәтзә-

ки (1870), Мөхәммәтбәдигъ (25.10.1874, анасы Хөббениса), Мөшәррәфә (19.08.1877), Мөхәммәтшакир (04.03.1881), Әхмәтлатыйф (26.09.1886). Бибимәрхәбә 1888 елның 14 октябрендә ерак нәселдәше Гайса Габделгалләм улы (23 яшь) белән никахлаша. Мөхәммәтшәфикъ Мөхәммәтҗанов 1917 елда төпчек улы (25 яшь) белән генә яши, 7,27 дисәтинә җире, 3 аты, сыеры, 3 сарыгы була.

Мөхәммәтшәфикъ кызы Мөшәррәфә – Салихҗан Сарьяновның анасы. Салихҗан – сугышка чаклы «Яңа Тормыш» колхозы рәисе, 1942 елның 5 февралендә сугышка китә, һәлак була, хатыны Майҗамал (1907), балалары Рифкать (1934), Өнсия (1936), Сырдәрия (1939), Амудәрия (1942) кала. Өнсия – авылдашы Рәиф Афзаловка, Сырдәрия – авылдашы Хатмулла Хафизовка, Амудәрия Яңа Катайның Шамил Дәүләтовка киүягә чыга.

Мөхәммәтназиф Мөхәммәтшәфикъ улы балалары: Мөхәммәтхәтим (17.09.1892–1893), Әһлия (04.03.1901; анасы Мәгъфүрә Килкабыз авылының Габделнасыйр кызы), Бибибәһия (16.06.1908), Миңлезөһрә (28.03.1911–1911), Мөхәммәтхәтим (22.03.1913). Мөхәммәтназиф Шәфиков (55 яшь) 1917 елда хатыны (45 яшь), улы һәм ике кызы белән яши, аты була, утын кисеп, такта ярып йөри.

Мөхәммәтнасыйп Мөхәммәтшәфикъ улы балалары: Мөкәррәмә (16.08.1897; анасы Шәмсенур Хөснетдин кызы), Мөхәммәтхәниф (14.05.1901–1905), Бибисара (29.09.1903), Бибимосаллия (21.03.1908), Бибимөкәррәмә (23.03.1910), Мөхәммәтфатих (18.02.1912). Насыйп Шәфиков (49 яшь) 1917 елда хатыны (47), ике улы һәм өч кызы белән яши, 3,32 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм 2 сарыгы була.

Әхмәтзәки Мөхәммәтшәфикъ улы балалары: Мөнәвәрә (18.09.1900; анасы Гыйззениса Үрмәтнең Әхтәмҗан кызы), Рәхимә (17.11.1903), Әхмәтзакир (27.01.1906–1914, ютәлдән вафат; анасы Суфия Газетдин кызы), Әхмәдетдин (28.09.1911), Миңлесабира (03.03.1909; атасы Мөхәммәтзәки дип күрсәтелгән), Миңлесаимә (24.09.1914–1916, кызамыктан), Тимергази (12.09.1917). Әхмәтзәки кызы Миңлесабира авылдашы Мирзаәхмәт Нәбиевкә кияүгә чыга.

Мөхәммәтбәдигъ Мөхәммәтшәфикъ улы балалары: Хөснебану (29.10.1907), Мөхәммәтхәниф (07.08.1910–1912; анасы Мәдхиҗамал Шаһингәрәй кызы), Миңлекамал (17.02.1914–1914, кызамыктан). Мөхәммәтбәдигъ 1921 елгы ачлыктан дөнья куя (1917 елгы исемлектән күренгәнчә, ул ярлы яшәгән).

Мөхәммәтшакир Мөхәммәтшәфикъ улы (25 яшь) 1907 елның 20 сентябрендә ерак нәселдәше Сиражетдин Гыйлажетдин улының кызы Миңлехәтимә (18 яшь) белән никахлаша, балалары Бибизәйтүнә (25.05.1910), Миңлемәдәния (03.03.1914), Мөхәммәткамал (15.01.1917), Гарәби (1920), Мөнәвәрә (1921–1924) туа. Мөхәммәтшакир Шәфиков (37 яшь) 1917 елда хатыны (35), улы һәм ике кызы белән яши, 3,30 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм сарыгы була. Сугыш алдыннан Шакир Шәфиков гаиләсендә тагын Зәйтүнәнең кызы Вәсилә (1935) теркәлгән. Ватан сугышы ветераны Гарәби Шәфиков Яңа Катайның Тәкмилә

Шәйхулла кызы белән гаилә кора, балалары Канәфи (1949), Айрат (1951), Ягъфәр (1954), Венер (1957) һәм Лира (1962) дөньяга килә.

Мөхәммәтшәфикънең алтынчы улы Әхмәтлатыйф Корычның Хәлфия Гыйльван кызы белән гаилә кора, балалары Әхмәтзариф (15.01.1914–1914, кызамыктан вафат) белән Мөхәммәткамал (10.07.1915) дөньяга килә. 1916 елның 20 июлендә «араларында өлфәт вә мәхәббәт» булмаганлыктан, Хәлфия белән Әхмәтлатыйф аерылышалар (шаһитлар – Мөхәммәтшәфикъ Мөхәммәтҗан улы белән Әхмәтзәки Мөхәммәтшәфикъ улы). Шул елның 24 октябрендә Әхмәтлатыйф (30 яшь, икенче никах) авылдашы Мөхәммәтхафиз Мөхәммәдиша улының кызы Кәшифә (19 яшь) белән никахлаша, балалары туа. Әхмәтлатыйф Шәфиковны (30 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алганнар, 1917 елда йортында хатыны (25 яшь), яңа туган улы һәм кызы (ул балалар беренче хатыныннан, дип уйларга кирәк) булган, дип әйтелә бер документта. Ватан сугышы башланганда Латыйп Шәфиков колхозда завхоз булып эшли, хатыны Кәшифә (1886), уллары Камал (1915), Әмир (1924–1944), Рәмдрәк (1932–1986) белән яши. Камал белән Әмир Латыйповлар – Ватан сугышы корбаннары (Камалның исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән). Әхмәтлатыйфның төпчек улы Рәмдрәк Латыйпов Фәнә Шәрифҗан кызы белән гаилә кора, балалары Урал (1951), Рудамир (1954), Нурия (Әлфия; 1958) һәм Лилия (1961) туа. Рәмдрәк абый белән Фәнә апа Катай урта мәктәбендә укыттылар.

Мөхәммәтҗанның икенче улы Мөхәммәтситдыйкъ иде. Мөхәммәтситдыйкъ Мөхәммәтҗан улы балалары: Мөхәммәтсафа (04.03.1874; анасы Гыйльмениса), Хәмдениса (17.12.1876), Мөхәммәтхарис (19.11.1878), Хәмдесафа (1879), Мөхәммәтзакир (25.12.1881–1894). Мөхәммәтситдыйкъ кызы Хәмдесафаны (19 яшь) 1898 елның 5 ноябрендә Әмәкәйнең Мөхәммәди Әхмәтҗан улына (40 яшь; дүртенче никах) кияүгә бирә. Кызның вәли вәкиле – бертуган агасы Мөхәммәтсафа Мөхәммәтсадыйк улы, ризалык шаһитлары Муллаян Мөхәммәтҗан улы белән Әхмәтгали Мөхәммәдиша улы була.

Мөхәммәтсафа Мөхәммәтситдыйкъ улы балалары: Шәехмансур (22.01.1902; анасы Шәмсеруй Габделхәбир кызы), Тәгъзимә (17.07.1904), Миңлесәгыйдә (09.05.1925; анасы Фатыйма Габдерәшит кызы).

Мөхәммәтҗанның өченче улы Муллаяннан да нәсел дәвам итә. Муллаян Мөхәммәтҗан улы балалары: Раян (1872), Ахунҗан (15.02.1878–09.04.1924), Фәрхиниса (1879), Фәрхинур (13.03.1881), Гыйльмебану (12.11.1884), Миңлебану (27.07.1889–1890), Миңлеҗиһан (1893–1900), Мәрхәбә (1894), Минһаҗетдин (15.01.1895–1895; анасы Мәхүпҗамал Камышлының Фәхрислам кызы), Әхмәтҗан (13.07.1900; анасы Хупҗамал Камышлының Фәхрислам кызы). Муллаян кызы Фәрхиниса (18 яшь) 1897 елның 4 декабрендә Корычның Таҗетдин Фәтхетдин улы (30 яшь, икенче никах; атасы Фәтхетдин Хәбибулла улы) белән кавыша. Икенче кызы Мәрхәбә (18 яшь) 1913 елның 13 декабрендә Корычның Нигъмәтулла Гарифулла улы (25 яшь) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле – агасы Раян Муллаян улы, егетнеке Әхмәдулла Гарифулла улы,

кызның ризалык шаһитлары – Ахунҗан Муллаян улы белән Мөхәммәтзәки Мөхәммәтшәфикъ улы, егетнеке Таҗетдин белән Сираҗетдин Фәтхетдин уллары була.

Раян Муллаян улы балалары: Кәримә (01.06.1904; анасы Фәрхениса Габделбаян кызы), Бибигалимә (12.01.1907–1909, кызамыктан), Рәхимә (19.09.1909), Сабирҗан (16.03.1912; анасы Фәхернисa Габделбаян кызы), Газизҗан (29.08.1917). Раян Муллаянов (45 яшь) 1917 елда хатыны (32), ике улы (берсен асрамага алган) һәм ике кызы белән яши, 3,12 дисәтинә җире, аты һәм 2 кәҗәсе була.

Ахунҗан Муллаян улы (26 яшь) 1906 елның 10 ноябрендә авылдашы Габделбаян Сәхипбаян улының кызы Хәмдениса (18 яшь) белән никахлаша, балалары Бибитәгъзимә (25.06.1908), Гыйлемгир (13.09.1912) туа. Ахунҗан Муллаяновны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (31 яшь) һәм кызы кала, 1917 елда 0,25 дисәтинә иманасын арендага биргәннәр, аты була.

Мөхәммәтҗанның дүртенче улы Мөхәммәтзарифка тукталыйк. Мөхәммәтзариф Мөхәммәтҗан улы балалары: Мөхәммәтхан (1880–1887), Миңлешәргыя (21.07.1888–1892; анасы Мәрфуга), Гөлчирә (29.01.1894–1897; анасы Мәрфуга), Зөлкагдә (22.03.1897), Казыйхан (10.07.1882–02.05.1912), Мирсәгыйть (21.04.1885) һәм Мөхәммәтхан (23.05.1900; анасы Мәрфуга Камышлының Әшрәфетдин кызы). Мөхәммәтзариф Мөхәммәтҗанов 1917 елда хатыны (65 яшь), улы (17) һәм 2 кызы белән яши, 9,66 дисәтинә җире, 3 аты, 3 сыеры һәм башка маллары була.

Казыйхан Мөхәммәтзариф улы балалары: Гыйлемхан (04.06.1906; анасы Миңлехәят Миңлебай кызы), Миңлехәнәфия (21.11.1907), Хәниф (27.06.1910). Гыйлемхан Зарипов – Ватан сугышы ветераны, балалары: Фәнәһия (1946), Галихан (1950–11.04.2003), Фәрәзинә (1953), Зәлирә (1957), Зилия (1959).

Хәниф Зарипов (1910–1994) – Ватан сугышы ветераны, сугыш алды елларында нәселдәше Сабир Хафизов кызы Бибиәфудә (1915–1997) белән никахлаша, атасы Мирсәгыйть (1880), анасы Хәят (1879), энесе Гарифҗан (1924) белән яши. Әйтергә кирәк, Мөхәммәтхәниф метрикәдә Мөхәммәтхәнәфи (27.06.1910; анасы Миңлехәят Миңлебай улы) дип язылган, атасының исеме Казыйхан урынына ялгыш Мирказый дип күрсәтелгән. Ире мәрхүм булгач, Хәнифнең анасы Хәят Мирсәгыйть (Казыйханның энесе) белән никахлаша. Хәниф Зарипов балалары: Фәрис (1941), Фәрит (1944), Фәнәс (1947), Әлфинә (1950), Гөлзирә (1955), Рәвис (1958).

Мирсәгыйть Мөхәммәтзариф улы балалары: Бибисорур (21.06.1910; анасы Шәмсесорур Фәрхетдин кызы), Рәзифә (1913–1916, чәчәк авыруыннан вафат), Мирзасалих (16.07.1916), Миңлегарифҗан (20.10.1924; анасы Миңлехәят Миңлебай кызы). Мирсәгыйть Зарипов 1917 елда хатыны (35 яшь), өч улы һәм кызы белән яши, 7, 04 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һәм сарыклары була.

Мөхәммәтзариф улы Мөхәммәтхан хатыны Мәэлүфә (халык телендә – Мәклүфә; 1900) белән өч ир (Мөхәммәтнәгыйм, Әхмәтнәгыйм, Әбүнәгыйм

Зариповлар) һәм бер кыз (Дәнә) бала тәрбияләп үстерә. Мөхәммәтхан Ватан сугышында һәлак була. Мөхәммәтнәгыймнең – Наил, Вәкил, Вәзир, Лира, Әхмәтнәгыймнең – Фәгыйль һәм Илмир, Дәнәнең – Шәрифҗан, Алия һәм Гөлчирә исемле уллары һәм кызлары дөньяга килә.

Югарыда Ватан сугышында һәлак булган (Мөхәммәтхан) һәм исән кайткан (Гыйлемхан, Хәниф) Зариповлар турында әйттек, аларның исемнәрен Катайның мемориаль стеласына өстәп язарга кирәк.

Әхмәтхан Мөхәммәтҗан улы (26 яшь; вәли вәкиле – Мөхәммәтзариф Мөхәммәтҗан улы) 1886 елның 25 февралендә нәселдәше Бибизәйнәп Могтәметдин кызы (18 яшь) белән никахлаша, балалары Кашшафетдин (Кәшфетдин; 14.12.1887), Бибизәкия (16.02.1890), Әхмәтнәгыйм (Мөхәммәтнәгыйм; 10.08.1892), Кафия (25.12.1894), Мөхәммәткәшиф (14.11.1897), Бибихәнифә (16.04.1902), Мөхәммәтхәниф (09.11.1905) туа. Әхмәтхан кызы Бибизәкия (18 яшь) 1909 елның гыйнварында Минзәлә өязе Әгъбәс авылының Мирсалих Мөхәммәтгариф улы (23 яшь; атасы Мөхәммәтгариф Фәтхулла улы) белән никахлаша. Кызның ризалык вәкилләре Кәшфетдин Әхмәтхан улы белән Мөхәммәтзакир Могтәметдин улы була. Әхмәтхан Мөхәммәтҗановның өч улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (57 яшь), кызы һәм килене белән яши, 12,87 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче яллый.



**Әхмәтхан никахы теркәлгән метрикә фрагменты. 1886 ел**

Әхмәтханның өч улы да герман сугышыннан исән кайта, берсе аннары Ватан сугышында да катнаша. Кәшфетдин Әхмәтхан улыннан – Әхкәметдин (1922–1924), Мөхәммәтнәгыймнән Җәннәт билгеле, башка балаларын ачыклап тормадык.

Мөхәммәткәшиф Әхмәтхан улы балалары: Мөхәммәтрәиф (24.10.1924; анасы Бибизакирә Мөхәммәтсафа кызы), Вәзиф (1931), Рафаэль, Фәния (1936). Кәшиф Әхмәтханов, аның улы Рәиф – сугыш ветераннары һәм инвалидлары. Рәиф абый сугышта сержант, миномет расчеты командиры була, «Дан орде-

ны» (3 нче дәрәҗә) (01.02.1945), «Батырлык өчен» медале (28.09.1943) белән бүләкләнә. Рәиф белән Нәкыя Хафиз кызы балалары: Зөбәер (1952), Рудамир (1958), Алфира (1960).

Мөхәммәтлатыйф Габделдаян улы балалары: Мәүсуфә (1868–1888), Бәдриниса (1881–1888), Әхмәтлатыйф (15.02.1883–1883), Миңлебибисара (06.09.1884–1887), Кифая (26.03.1887–1888; анасы Хәйриниса), Хафизетдин, Гыйльмивафа (27.03.1891; атасы Габделлатыйф дип язылган; анасы Гарифә Галиулла кызы). Габдерәкыйп Мөхәммәтлатыйф улыннан Әшрәфҗан (21.06.1908; анасы Бибигалия Мөхәммәтзариф кызы) билгеле. Хафизетдин Мөхәммәтлатыйф улының баласы Гыйрфанетдин (1892–22.06.1907) була.

Алдарак әйткәнчә, Гомәр картның төпчек улы Раян (1799) иде. 1834 елгы документта аның уллары Мөхәммәтсафа (1825) белән Мөхәммәтсадыйк (1833) күрсәтелә.

Мөхәммәтсафа Раян улы балалары: Мөхәммәтбәдигъ (1848), Мөхәммәтсадыйк (1851), Мөхәммәтхафиз (1853–18.10.1915), Әхмәтвәли (1858), Мөхәммәтсолтан (Солтангәрәй; 1863), Мөхәммәделислам (1868) туган. Мөхәммәтсафа кызы Бибифатыйма (18 яшь) 1885 елның 24 гыйнварында Бөре өязе Карабаш авылының Ахун Мөхәммәтҗан улы (22 яшь) белән гаилә кора.

Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтсафа улы балалары: Мөхәммәтшәех (17.02.1878; анасы Бибигазизә), Бибисания (04.04.1880), Габделдаян (25.12.1883), Факия (1885–1911), Әхмәтнәгыйм (17.12.1886–1888; анасы Газизбануа). Мөхәммәтсадыйк кызы Факия (25 яшь; икенче никах) 1910 елның 24 апрелендә Иштирәкнең Сәлимгәрәй Корбангали улы (26 яшь) белән никахлаша.

Мөхәммәтшәех Мөхәммәтсадыйк улы 1907 елның ноябрендә авылдашы Мөхәммәтхафиз Вәлимөхәммәт улының кызы Бибикәшифә (18 яшь) белән никахлаша. Егетнең ризалык шаһитлары Габделхәбир Габделнасыйр улы белән Нурлыгаян Габделнәфикъ улы була. Әлеге никахтан Бибизәкия (04.07.1909) дөньяга килә.

Габделдаян Мөхәммәтсадыйк улыннан Хәзинә (03.10.1911; анасы Бибиҗиһан Хөрмәтулла кызы) билгеле.

Мөхәммәтсафаның өченче улы Мөхәммәтхафиздан (1857) да нәсел дәвам итә. Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтсафа улы балалары: Мөхәммәтсабир (1878), Рамазан (03.06.1887–1888), Мөнәвәрә (09.11.1894; анасы Миңлевафа Мусакай кызы). Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтсафин 1917 елда улы (25 яшь) белән яши, 3,87 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һәм 6 сарыгы була.

Мөхәммәтсабир Мөхәммәтхафиз улы балалары: Мөхәммәтфатих (07.02.1905; анасы Шәмсия Фәтхелислам кызы), Миңлесәвия (23.08.1907), Мөхәммәтшәех (07.06.1910; анасы Шәмсеҗиһан Фәтхелислам кызы), Мөнирә (04.09.1912), Бибиәфудә (15.09.1915). Сабир Хафизовны (39 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (35 яшь), улы һәм өч кызы кала, 1917 елда 2,12 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры, 2 бозавы һәм сарыгы була. Сабир

улы Фатих читкә чыгып китте, дип әйтте Хәмит абый. Сабир кызы Бибиәфудә (1915–1997) нәселдәше Хәниф Зарипов (1910–1994) белән никахлаша.

Мөхәммәтсафаның бишенче улы Мөхәммәтсолтанга тукталыйк. Мөхәммәтсолтан Мөхәммәтсафа улы балалары: Мөхәммәтҗан (06.09.1895; анасы Миңлеҗамал Килкабызның Әхмәтша кызы), Мөбәрәкҗан (14.11.1897), Бибинур (23.01.1901), Мөхәммәтнәгыйм (14.09.1903), Хәсәнҗан (18.12.1905; анасы Миңлеҗамал Әхмәтша кызы), Бибибәһия (13.07.1908), Нигъмәтҗан (05.12.1910–1911; анасы Миңлеҗамал Әхмәтша кызы), Рәйфә (16.10.1914; анасы Әбәдия Ибраһим кызы), Гарифҗан (22.03.1917; анасы Мөнәзә Ибраһим кызы). Мөхәммәтсолтан Сафинның олы улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (35 яшь), өч улы һәм ике кызы белән яши, 7,62 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була, сәүдә итә. Мөбәрәкҗаннан Миргазиян (20.08.1925; анасы Бибиҗиһан Хөрмәтулла кызы) туган.

Хәсәнҗан Солтанов – Ватан сугышы ветераны, сугыш алдыннан гаиләсендә хатыны Камилә (1906), уллары Фәһим (1936), Миңлемөстәкыйм (01.03.1942) теркәлгән. Мөстәкыймнән нәселне Радик белән Рәмис Солтановлар дәвам итә.

Мөхәммәтислам Мөхәммәтсафа улы (23 яшь) 1894 елның 10 декабрендә нәселдәше Рабига Баһаутдин кызы (18 яшь; атасы Баһаутдин Сираҗетдин улы) белән никахлаша, балалары Кәримә (14.11.1897; Читада яшәгән), Мөхәммәтситдыйкъ (02.07.1903), Нәгыймә (19.10.1906–2005), Хәзинә (05.01.1910–1911), Мөхәммәтҗан (08.10.1912) туа. Ислам Мөхәммәтсафин (49 яшь) 1917 елда хатыны (45 яшь), ике улы һәм ике кызы белән яши, 4,34 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры, бозавы, 6 сарыгы һәм 3 кәҗәсе була. Мөхәммәтислам 1925 елның 25 декабрендә Яңа Катайның Бибиҗиһан Минһаҗетдин кызы (40 яшь) белән никахлаша. Нәгыймә ерак нәселдәше Сабирҗан Солтанов белән гаилә кора.

Мөхәммәтситдыйкъ Исламов (1903–1978) – Ватан сугышы ветераны, авылдашы Гайникамал Мөхәммәтнәби кызы (1910) белән никахыннан балалары Хавис (20.04.1932–13.02.2012), Мохәттәрә (1935), Мисбах (1939), Бәшир (1944–1981), Хәзинә (07.01.1952; Сибайда яши), Вәзимә (1956) туа. Хавистән нәселне Лилия (26.09.1959), Фиркать (31.01.1962), Юлия (21.11.1966), Нурзилә (21.07.1973) Исламовлар дәвам итә. Мәгълүматның бер өлешен Фиркать Исламов хәбәр итте.

Йортбагыш нәселе турында мәгълүмат тулы булсын өчен, аның Гайсар исемле оныгыннан (ул алдарак сүз барган Гомәрнең энесе) киткән тармакка тукталыйк. Гайсардан (1749) Рамазан (1786–1830), аннан Миңлегали (1820–16.08.1887) туган.

Миңлегали Рамазан улы балалары: Ибраһим (1856–26.02.1916), Исмәгыйль (1859), Нургали, Әхмәтзәки (15.11.1875–1883; анасы Нурҗиһан), Бибимәфтуха (15.09.1881), Фәрхенур (05.01.1884–1899), Гыйззенур (21.04.1887). Миңлегалинең олы кызы Шәмсенур (19 яшь) 1883 елда Килкабызның Гарифулла Гайнулла улы (2 яшь) белән гаилә кора. Икенче кызы Шәмсекамәр (20 яшь;

икенче никах) 1897 елның 30 декабрендә Каръяуды олысы Байки авылының Низаметдин Сәйфетдин улы (25 яшь, икенче никах; вәли вәкиле – Яңа Катай мөәзине Мөхәммәтзариф Мөхәммәтҗан улы) белән никахлаша. Өченче кызы Миңлебану (18 яшь) 1889 елның 20 мартында Сәкәшнең Хәмидулла Гыйсмәтулла улы (30 яшь; икенче никах) белән кавыша. Төпчек кызы Мәфтуха (18 яшь) 1902 елның 11 октябрендә шул ук Каръяуды олысы Каран авылының Таҗетдин Шәрәфетдин улына (25 яшь) кияүгә чыга.

Ибраһим Миңлегали улы балалары: Исхак (20.07.1876; анасы Хәбибҗамал), Сәрвиҗиһан (1879–1897), Ильяс (24.12.1881), Исламгали (03.09.1884–1888), Муллагали (16.09.1887), Маһикамал (1891–1892), Фәрхиҗамал (23.11.1894–1895; анасы Хәбибҗамал Гыймадетдин кызы), Әхмәтгали (21.03.1897–1907).

Исхак Ибраһим улы балалары: Гыйльмебану (03.08.1906; анасы Миңлебану Габделкадыйр кызы), Миңлекәшифә (18.07.1917; анасы Миңлебану Габделгалләм кызы). Исхак Ибраһимов 1917 елда хатыны (35 яшь), улы һәм яңа туган кызы белән яши, 1,55 дисәтинә җире, аты һәм 2 кәҗәсе була. Утын кисәргә, такта ярырга ялланып өстәмә акча эшли.

Ильяс Ибраһим улы балалары: Гыйкрәмә (03.11.1908; анасы Мәдинә Хәмидулла кызы), Габбас (19.06.1911–1912), Әнвәретдин (29.10.1913), Миңлемөкәррәмә (12.09.1917). Ильяс Ибраһимов 1917 елда хатыны (30 яшь), улы һәм ике кызы белән яши, 4,37 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры була.

Муллагали Ибраһим улы балалары (беренче мәхәллә): Фәрхебҗамал (1915–1916, чәчәк авыруыннан), Фәрхебҗамал (1923–1924), Тимергали (10.11.1924; анасы Сәхипҗамал Әхмәтҗан кызы).

Исмәгыйль Миңлегали улы балалары: Фәрхинур (1883–1883), Маһинур (18.08.1884), Габделхәким (02.05.1888), Исламгали (21.02.1892; анасы Фәрхиҗиһан), Фәрхисорур (20.03.1894; анасы Фәрхиҗиһан Яңа Катайның Сәлимгәрәй кызы), Фәрхебану (27.04.1897), Җиһанбану (02.09.1900; анасы Хәсәнҗиһан Яңа Катайның Сәлимгәрәй кызы), Шәехгали (16.10.1903; анасы Фәхерҗиһан Сәлимгәрәй кызы), Шәехзаман (26.01.1907; анасы Фәрхиҗиһан), Гыйльмиҗиһан (04.01.1910), Хәерзаман (03.05.1914–1916; анасы Фәрхинур Сәлимгәрәй кызы). Исмәгыйль кызы Маһинур (18 яшь) 1907 елның февралендә Яңа Катайның Нурәхмәт Бәхетгәрәй улы (25 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары – Ибраһим Миңлегали улы белән Нургали Миңлегали улы, егетнеке Шәйгәрәй Тимербулат улы белән Сәлимгәрәй Шәйгәрәй улы була. Бу никах озакка бармый, шул елның сентябрендә Маһинур Корычның Габдерәхим Габделвахит улы (35 яшь; дүртенче никах) белән кавыша. Исмәгыйльнең икенче кызы Фәрхебану (18 яшь) 1917 елның 26 июнендә авылдашы Суфиәхмәт Габделханнан улы (26 яшь) белән гаилә кора. Кызның ризалык шаһитлары – Ильяс Ибраһим улы белән Нургали Миңлегали улы, кияүнең вәли вәкиле атасы Габделханнан Габдулла улы була. Исмәгыйльнең өченче кызы Фәрхисорур (18 яшь) 1912 елның 19 октябрендә авылдашы Хәйретдин Мөхәммәди улы (25 яшь, икенче никах; атасы Мөхәммәди Мөхәммәтгали

улы) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары – Кәнзелголум Сәйфулла улы белән Нургали Миңлегали улы, кияүнеке Нурлыгаян Габделнәфикъ улы белән Габделгалләм Габделмалик улы була. Исмәгыйль Миңлегалиевнең ике олы улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (55 яшь), ике кече улы һәм ике кызы белән яши, 4,23 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры һәм башка маллары була.

Югарыда нәселне Рамазанның беренче улы Миңлегали яклап карадык.



**Документның Йомагол Рамазанов тамга салган фрагменты. 1860 ел**

Рамазанның икенче улы Җомагол (1828–03.05.1915) була. Җомагол Рамазан улы балалары: Габдулла (1854), Сәйфулла (1856–03.02.1912), Нигъмәтулла (1859), Гарифулла (15.01.1878–1886). Җомагол кызы Бибисара (18 яшь) 1880 елның 25 гыйнварында язмышын Рәҗәпнең Миңлегол Якуп улы (23 яшь; атасы Якуп Мөхәммәдьяр улы) белән бәйли.

Габдулла Җомагол улы балалары: Хөрмәтулла (01.08.1875; анасы Хөббениса), Гыйндулла (12.11.1877), Нигъмәтулла (28.05.1882), Хәмидулла (20.12.1884–1888), Миңлемөхәммәт (13.07.1887), Әхмәдулла (22.02.1890), Миңлемөхәммәт (1891), Рәхмәтулла (22.08.1892; анасы Хөббениса Корычның Мөхәммәтгали кызы), Галия (28.02.1895), Төхфәтулла (25.02.1897).

Хөрмәтулла Габдулла улы балалары: Миңлегарифа (23.04.1903; анасы Таифә), Зиннәтулла (16.04.1905), Бибирәхимә (21.08.1907), Җәүһәрия (1911–1915, чәчәктән). Хөрмәтулла Габдуллинны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (35 яшь) һәм ике кызы кала, 1917 елда җире һәм мал-туары булмый.

Гыйндулла Габдулла улы балалары: Кифая (02.04.1903; анасы Фәхерниса Мөхәммәтлатыйф кызы), Шәрхемулла (27.06.1906; анасы Хәерниса Мөхәммәтлатыйф кызы), Гарифулла (02.02.1909; анасы Хәерниса), Миңлефатыйма (14.10.1911). Гыйндулла Габдуллин ике иманасын арендага биреп, авылдан чыгып китә.

Нигъмәтулла Габдулла улы балалары: Миңлезәкия (03.08.1910; анасы Миңлемәфтуха Гайса кызы), Зиннәтулла (1913–1914, кызамыктан), Сәрмәдия (17.11.1914).

Әхмәдулла Габдулла улының беренче баласы Җәннәтеләсма (15.10.1917; анасы Хөсния Гайса кызы) була. Әхмәдулла Габдуллин (28 яшь) 1917 елда хатыны (19), энесе (25 яшь) һәм анасы (70) белән яши, 3,79 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм 3 сарыгы була. Әхмәдулла староста, аннары авыл советы рәисе була, дип сөйләгән иде Хәмит абый. Ул хәзерге укытучы Габдуллиннар өе урынында яшәгән, каршыдагы күршесе Габделихсан Газизов була. 1921 елда Габделихсан хатыны Хәтирә (Гыйлем Газизовның анасы) өенә ут төрткәч, озак тормый, 1922 елда читкә чыгып китә (Хәмит абый Маликов мәгълүматы).

Миңлемөхәммәт Габдулла улы 1917 елның 15 октябрендә авылдашы Тәгъзимә Гатиятулла кызы (26 яшь; атасы Гатиятулла Шәрәфулла улы) белән никахлаша.

Рәхмәтулла Габдулла улы балалары: Гәүһәрия (28.04.1911; анасы Таифә Шәрәфетдин кызы), Гыйльмулла (1921), Мәгъсүмә (1924), Миңлемәгъдәния (07.09.1925; анасы Шәмсенур Гайсә кызы), Мулланур (1929), Әсхәдулла (1931), Мәвәзинә (1933), Сәнирә (1936, яшьли вафат), Рәзимә (1939), Фәрит (1942). Гыйльмулла Габдуллин Ватан сугышына китә, 1943 елның апрелендә һәлак була (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән). Әсхәдулла Габдуллинның беренче никахыннан классташым Мәүлисә (1960) туган.

Җомагол Рамазановның икенче улы Сәйфулла иде. Сәйфулла Җомагол улы балалары: Мәйсара (17.12.1880), Баязит (23.12.1883–1888), Сәмигулла (07.07.1886), Миңлехәзинә (28.10.1888; анасы Маһисорур), Бибинәгыймә (07.12.1890), Кәнзелголум (04.11.1895; анасы Маһисорур Базы Куянның мулла Габдерәкыйп кызы), Кәнзелмәган (10.04.1898), Зөләйхәбикә (1899), Кәшфелмәган (19.10.1901), Кәнзелмәган (1904). Сәйфулла кызы Миңлехәзинә (18 яшь) 1907 елның 10 декабрендә Баекның Сәхипгәрәй Әбүмәхиян улы (26 яшь) белән кавыша. Егет тарафыннан вәли вәкил – туганы Батыргали Әбүмәхиян улы, кызның ризалык шаһитлары – Сәмигулла Сәйфулла улы белән Гыйндулла Габдулла улы, егетнеке Мөхәммәтсабир Солтангәрәй улы белән Мөхәммәтзакир Мөхәммәтша улы була. Икенче кызы Зөләйхәбикә (18 яшь) 1917 елның 6 апрелендә Иштирәкнең Габдрахман Мөхәммәди улы (35 яшь) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле – агасы Сәмигулла Сәйфулла улы, ризалык шаһитлары Кәнзелмәган Сәйфулла улы белән Нургали Миңлегали улы була.

Сәмигулла Сәйфулла улы балалары (беренче мәхәллә): Фәрхисрур (16.08.1906; анасы Шәмсинур Арслангали кызы), Зөфәр (29.06.1912; анасы Хөршидҗиһан Баһаутдин кызы), Хаммадулла (26.09.1914), Миңлеәсма (06.06.1917). Сәмигулла Сәйфуллинны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (28 яшь), улы (3), кызы (яңа туган) һәм анасы (70) кала, 1917 елда хуҗалыгында аты, 2 сыеры, 4 сарыгы, 4,80 дисәтинә җире була. Сәмигулланың улы Хаммадулла (Хаммат Сәйфуллин; 1914) Ватан сугышының беренче көнендә һәлак була (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Кәнзелголум Сәйфулла улы балалары: Әсма (1918), Миңлеасия (22.10.1924; анасы Хөршидә Баһаутдин кызы). Кәнзел Сәйфуллин колхозда балта остасы була, Ватан сугышына китә (исеме «Халык хәтере» сайтында теркәлгән, язмышы билгесез). Кәнзелмәган Сәйфулла улыннан Мөдәррис (21.10.1925; анасы Фәрхиҗиһан Габделихсан кызы) туган.

Югарыда Зыятның беренче улы Гомәрдән киткән тармаклар каралды. Зыятның икенче улы Гайсардан нәселне Гыйльман (1776) белән Рамазан (1786) дәвам итә. Гыйльманның уллары Ризван (1803) һәм Вилдан (1822–29.09.1884) була. Ризван Гыйльман улы балалары: Исрафил (1852) белән Гыйрфанетдин (1859–19.01.1910).

Исрафил Ризван улы балалары: Габдерәхим (21.12.1875), Миңлеҗиһан (25.09.1878–1890; анасы Шәмсеҗамал), Габдрахман (25.06.1881), Миңлезадә (15.08.1884–1888), Миңлекамал (27.01.1889–1889), Хәбибрахман (16.06.1890; анасы Гайникамал Мөхәммәтгәрәй кызы). Исрафил Ризван улы (30 яшь; икенче никах) 1889 елның 11 сентябрендә нәселдәше Мөхәммәтгәрәй Мөхәммәткәрим улының кызы Гайникамал (18 яшь) белән никахлаша. Исрафил белән Гайникамал шул ук 1890 елның 17 ноябрендә аерылышалар, шаһитлар Габделҗәмил Шаһингәрәй улы белән Мөхәммәтгәрәй Мөхәммәткәрим улы була. Исрафил Ризванов 1917 елда хатыны (60 яшь), улы (36), килене (25 яшь) һәм өч оныгы белән яши, 7,96 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була.

Габдерәхим Исрафил улы балалары: Мөхәммәтрәхим (25.09.1903), Мөнирә (1905–1909, кызамыктан вафат), Мөхәммәткәрим (25.08.1908; анасы Мөгаллимә Хәйрулла кызы), Мөхәммәтрәхим (1914–1924). Мөхәммәтрәхим Габдерәхимов (1903) читкә чыгып китә, шунда аны сугышка алалар, гаиләсе 1942 елның 20 октябрендә Катайга кайта. Бу вакытта хатыны Майбану (1905), балалары Касыйм (1934) белән Нәсимә (1937) була.

Габдрахман Исрафил улы балалары: Дөркамал (09.07.1910), Фәйзрахман (15.02.1913; анасы Фәрхениса Кәлимулла кызы), Миңлефәргыя (04.09.1914; анасы Мөгаллимә Хәйрулла кызы), Миңлемөнирә (06.02.1917). Дөркамал 1964 елның 19 июнендә Октябрьский шәһәре ЗАГСына мөрәҗәгать итеп, туу турында белешмә ала, фамилиясен әтисе исеменнән Габдрахманова дип язалар.

Гыйрфанетдин Ризван улы балалары: Габделихсан (25.02.1883–1888), Мәгъшукҗиһан (29.08.1885), Фәхрелислам (04.11.1888; анасы Хөсниҗиһан), Гайнелҗинан (19.07.1892), Нурислам (20.01.1895–1905; анасы Хәсбиҗамал Ибнҗәмил кызы, Баек авылыннан), Гайнелхәят (18.07.1898), Сәвия (21.11.1901; анасы Хәсбиҗамал Габделҗәмил кызы). Гыйрфанетдин кызы Мәгъшукҗиһан (18 яшь) 1904 елның гыйнварында Яңа Катайның Гыймадетдин Гаязетдин улы (25 яшь) белән кавыша. Егетнең вәли вәкиле – бертуган энесе Заһретдин Гаязетдин улы, ризалык шаһитлары Җиһангир Габделгани улы белән Галләметдин Сәйфетдин улы була. Икенче кызы Гайнелхәят (18 яшь) 1911 елның гыйнварында нәселдәше Габделмалик Габделбасыйр улы белән никахлаша.

Фәхрелислам Гыйрфанетдин улы 1913 елның 6 гыйнварында Яңа Катайның Сәригаскәр Миңлехан улының кызы Фәхерҗиһан (17 яшь) белән никахлаша, балалары Хаҗимәсгут (03.02.1914), Сания (26.08.1924), Бәһия (20.11.1925) туа. Фәхрелислам (1888) Ватан сугышы алдыннан хатыны Зәйнәп (1900), уллары Хәтим (1927), Галислам (1935) һәм ике кызы (берсе Суфия (1928) белән яши, фамилиясе, ни сәбәпледер, Гыйльфанов язылган.

Ризваннан башка, Гыйльман Гайсар улының нәселен тагын Вилдан дәвам итә. Вилдан Гыйльман улы балалары: Хасбиран (1851–29.12.1880), Гыйльфан (1855–1878), Шәмсеруй (1868), Шәмсенәһар (1870). Вилдан кызы Шәмсеруй (18 яшь) 1886 елда Корычның Җәгъфәрсадыйк Габделханнан улы (22 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Шәмсенәһар (18 яшь) 1888 елның декабрендә

Яңа Катайның Кашшафетдин Саяфетдин улы (22 яшь) белән кавыша. Шул ук Шәмсенәһар күпмедер вакыт үткәч, Яңа Катайның Шәрәфетдин Саяфетдин улы Фазлуллин хатыны дип күрсәтелә, балалары туа (Кәраметдин (халык телендә исеме Кәрам, 26.07.1894), Сәрвиҗиһан (21.02.1897) һәм башкалар).

Хасбиран Вилдан улы балалары: Гыйльметдин (15.06.1876; анасы Хәсбиҗамал), Гыйльмиҗамал (01.03.1878), Хупҗамал (01.09.1880). Хасбиран кызы Гыйльмиҗамал (18 яшь) 1894 елның 8 декабрендә Яңа Катайның Галләметдин Саяфетдин улы (22 яшь; атасы Саяфетдин Фазлулла улы) белән никахлаша. Егетнең ризалык шаһитлары Шәрәфетдин белән Фәттахетдин Саяфетдин уллары була.

Гыйльметдин Хасбиран улы балалары: Гыйкрәмә (16.09.1904), Рәхимә (05.08.1907–1911), Мөхәммәтнаҗәр (21.03.1911–1911), Рәйфә (15.08.1912; анасы Хөсниҗиһан Миңлегали кызы), Тимергази (23.09.1916). Гыйльметдин Хасбирановны (42 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (40), улы һәм кызы кала.

Шулай итеп, бер нәсел кешеләре – Юлдаш белән Йортбагыштан киткән буыннар – бүгенге көндә Иске Катайдагы бик күп кешеләргә барып тоташа, иң зур нәсел дип әйтергә нигез бирә. Катайның үткәнен һәм бүгенгесен нәселдәшләремнән башка күз алдына китерү мөмкин дә түгелдер. Аерым-аерым тукталып үтәрлек шәхесләр күп булуы да күзгә ташлана, алар хакында тәфсилләп сөйли башласаң, үзенә бер китап язу кирәктер. Илледән артык нәселдәшем ил бәйсезлеге өчен Ватан сугышында көрәшкән, хәрби бурычын үтәгән, шуларның яртысы диярлек Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән. Авыл хакимияте стелага «Беркем дә онытылмаган, бернәрсә дә онытылмаган» дип язса да, күп нәрсә онытылган шул, димәк, ул стеланы алып, онытылганнарны өстәп, өр-яңадан язарга һәм элеп куярга кирәк.



**Нәселдәшләр Дәүәти яланында: Азат Таҗиев (сулда), Дамир Кәримов, Фиркать Исламов**

# IV бүлек.
# Моталлап нәселе

Бу бүлектә каралачак нәсел 1795–1859 елгы халык санын алу документларында бер урында теркәлгән. 1811 елгы исемлектә Галибәк Зыямбәтов, Атнагол Монаитмасов, Рәмәй Сәетов, Морадым Ибраев дүрт хуҗалык булып бер-бер артлы бирелә. Кайсыдыр гасырда боларның уртак бабасы булган, бер нәселгә караганлыкларын үзләренә генә хас нәсел тамгасы раслый.

Нәсел тамгасына берничә урында алдарак тукталып үтәрбез, ә хәзер сүз нәселне ничек атау турында барачак. Уртак бабаларын берничек тә белү мөмкин булмаганлыктан, бары тик шартлы рәвештә Моталлап нәселе дип атадык, ә Атнагол, Рәмәй һәм Морадым тармакларын Моталлапның ерак нәселдәшләре дип күрсәттек. Ни өчен Моталлап нәселе дип атауның сәбәбе: Галибәкнең улы Габделмоталлаптан киткән тармаклар нәсел эчендә аеруча күп була, туксанынчы елларда да өлкән буын хәтерендә Моталлап нәселе дип әйтү сакланган иде.

Әнә шул Габделмоталлапның бабасы Җанибәк Йувашкин (русча документта «Ювашкин») 1762 елгы документта теркәлгән, якынча 1687 елда туган. Җанибәктән нәселне уллары Галибәк (1726–1809) белән Гыйбадулла (1758) дәвам итә. Икесенең дә ир балалары була, әмма бүгенге көндә Галибәктән киткән тармак вәкилләре күбрәк билгеле. Галибәк 1811 елда Зыямбәтов фамилиясе белән теркәлгән, 1795 елда хатыны Тыпый мишәре Алтынбикә Хансөяр кызы, уллары Зәйсан (1755–1804), Габделгаффар (1771–1800), Габделмоталлап (1780) һәм өч кызы була. Габделмоталлапның ир балалары: Габделгали (1805), Габделгалләм (1807), Шәмбаз (ревизия документында Шәммас, метрикәдә Шәммаз дип тә языла; 1820–08.02.1898) һәм Баһаутдин (1822).

Боларның тамгаларының төп өлешен (нигезен) очы өскә карап торган өчпочмак тәшкил итә. Нәсел вәкилләре шул өчпочмакның уртасына яисә астына аска таба сызык сызып тамгаларын салалар. Текстта Габделмоталлап Галибәков тамга салган 1811 елгы ревизия документы фрагментын күрәсез («К сей скаске деревни Катаевой ис тептерей выборной и скаскоподатель Габдулмуталлап Алибяковъ тамгу свою приложил [...] такову). Әлеге сүзләрдән аңлашылганча, катайлылар Габделмоталлапны ревизия (авылда яшәүчеләр) исемлеген хакимияткә тапшырырга һәм документның дөреслеген раслап тамга салырга үз араларыннан вәкил итеп сайлаганнар.

Габделмоталлапның өлкән улы Габделгали дүрт ир бала тәрбияли: Габделихсан (1823–11.10.1874), Габделисхак (1825), Әюп (1839–20.02.1915), Ибраһим (1842).



**Габделмоталлап Галибәков тамга салган документ. 1811 ел**

Габделихсан урядник булып хезмәт итә, аның Шәйхеразый (1849), Шәйхелислам (1851–17.12.1915), Фәхрислам (1863–16.08.1924), Нурислам (1869) исемле уллары була. Габделихсан кызы Миңлесафа (18 яшь) 1878 елның 15 июнендә Куянның Әхмәди Габделмалик улы (19 яшь; атасы Габделмалик Габделсаттар улы) белән гаилә кора.

Сүз уңаеннан әйтим, Габделмалик Габделсаттар улы – Бакалы район хакимиятенең элеккеге башлыгы, Куян авылында туып-үскән Рәмис Маһиян улы Дәүләтовның икенче буын бабасы. Аның нәсел чылбыры болай: Килмәт (Килмөхәммәт) – Йосыф (1711 елда туган) – Исламгол (1752) – Габделсаттар (1793) – Габделмалик (1816) – Дәүләтбай (1878) – Маһиян (1905) – Рәмис (1948), аның балалары һәм оныклары. Бу шәҗәрәне узган гасырда язган Куян авылы тарихына керткән идем, ул кульязма китапта Катайга бәйле кызыклы мәгълүмат та бирелә, китап кайчан да булса дөнья күрер дип өметләнәм.

Шәйхеразый Габделихсан улы балалары: Нургали (15.02.1874; анасы Шәмсеҗамал), Миңлегайшә (15.01.1877), Миңлехәтирә (16.10.1878), игезәкләр Габдрахман белән Габдулла (25.02.1881), Хәбибрахман (09.05.1884), Мәдинә (16.09.1887). Шәйхеразый кызы Бибихәтирә (18 яшь) 1900 елның 3 мартында Яңа Катайның Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтзариф улы (23 яшь; атасы Мөхәммәтзариф Габделлатыйф улы) белән никахлаша, ризалык шаһитлары Исхак Исмәгыйль улы белән Исмәгыйль Ибраһим улы була.

Нургали Шәйхеразый улы Бибимәрьям Габделкаһир кызы белән гаилә кора, балалары Бибимәрдия (25.03.1903), Шәйхенур (халык телендә Шәйнур; 19.02.1907), Бибигайшә (07.06.1910), Габдулла (06.03.1917) туа. Җәмигънур Шәйнур улы Нургалиев (1936) Яңа Катайның Мәгъзүрә Фәттахова белән гаилә кора, балалары Галинур (1960), Марсель, Физәлия дөньяга килә. Галинур – классташым, бу китапны нәшриятка әзерләгәндә хәл-әхвәл белешеп Ульян өлкәсенең Дмитровград шәһәреннән шылтыратты, әти-әнисе һәм туганнары турында мәгълүмат әйтте, бабасы Шәйнурның Ватан сугышында хәбәрсез югалуын искә алды (сугыш корбаны Шәйнур Нургалиев Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Габдрахман Шәйхеразый улы (25 яшь) 1908 елның октябрендә авылдашынәселдәше Бибикифая Габделихсан кызы (18 яшь) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле – атасы Габделихсан Сәхипбаян улы, егетнеке Шәйхеразый Габ-

делихсан улы була. Кызның ризалык шаһитлары булып Габделҗәлил белән Исхак Сәхипбаян уллары нәсел тамгасы салалар. Габдрахман балалары: Хәбибрахман (10.03.1911), Лотфрахман (16.09.1913; анасы Кифая Габделихсан кызы), Шәехгали (Шәйхали; 23.06.1916), Сабирҗан (11.07.1921–25.02.1999) һәм Нигъмәтҗан (21.12.1925) Шәйхеразыевлар. Шәйхали Габдрахман улы Шәйхеразыев Ватан сугышында һәлак була, энеләре Сабирҗан белән Нигъмәтҗан – Ватан сугышы ветераннары (Катайның мемориаль стеласына бер Сабирҗан гына теркәлгән).

Шәйхелислам Габделихсан улы балалары: Шәйхенур (23.02.1876; анасы Бибимөшәррәфә), Миңлешәйхәйдәр (29.05.1878–1884), Бибимөнәвәрә (05.03.1881), Һидая (03.08.1884), Бибимөкәррәмә (07.09.1888), Шаһинур (1891–1893, эч авыруыннан вафат), Мөхәммәтхәбип (29.11.1894; анасы Мөшәррәфә Корычның Мөхәммәтәмин улының кызы), Мотаһирә (15.07.1897). Шәйхелислам кызы Мөкәррәмә (24 яшь; икенче никах) 1914 елның 3 июнендә Сеңрәннең Нурлыгаян Гыйзаметдин улы (37 яшь; өченче никах) белән кавыша.

Шәйхенур Шәйхелислам улы (27 яшь; икенче никах) 1902 елның 2 мартында Килкабызның Гөлҗиһан Габделмәннан кызы (21 яшь, икенче никах; атасы Габделмәннан Мөхәммәтгали улы) белән никахлаша. Шәйхенур балалары: Бибисаҗидә (27.12.1900–1904; анасы Гөлҗиһан Габделмәннаф кызы), Габделзаһит (22.09.1905; анасы Гөлҗиһан), Җәүһәрия (22.01.1907; анасы Сәвия Гыйльман кызы), Зәкәрия (17.01.1909), Нәҗип (13.03.1917), Вәсилә (1927).

Фәхрислам Габделихсан улы балалары: Нәгыймә (21.12.1884), Гыйльмиҗиһан (03.12.1886), Һидая (29.03.1894; анасы Нәгыймә), Бибимөгаллимә (18.03.1897), Бибигалия (01.04.1901), Бибигазимә (08.09.1903; анасы Бибинәгыймә Габделхәким кызы). Фәхрислам кызы Һидая (19 яшь) 1914 елның 7 февралендә Куянның Галиулла Шаһидулла улына (25 яшь; вәли вәкиле – Фәхрулла Габидулла улы) тормышка чыга.

Нурислам Габделихсан улы (25 яшь) 1894 елның 9 декабрендә авылдашы Бибигайшә Могтәметдин кызы (18 яшь; атасы Могтәметдин Габделвахит улы Юлдаш нәселеннән) белән никахлаша, балалары Камилә (22.10.1895), Бибикәримә (21.11.1897–1912), Миңлесәвия (02.09.1900), Нурлыгаян (1902), Нуретдин (21.04.1905; Ватан сугышында һәлак була), Фәхрелгаян (25.06.1907), Муллагаян (25.07.1909), Хәтимә (05.08.1912–1916, кызамыктан вафат) дөньяга килә. Нурислам кызы Камилә (20 яшь) 1917 елның 13 июлендә авылдашы Хәбибрахман Хәбибулла улы (25 яшь) белән никахлаша. Нуретдин Габделихсан улы (19 яшь) 1925 елның 10 мартында Хөснеруй (18) белән гаилә кора. Кызның вәли вәкиле – Мөхәммәтсафа Әхмәтситдыйкъ улы, ризалык шаһитлары Мөхәммәтфатих Мөхәммәтсадыйк улы белән Миргабитҗан Әхмәтов була.

Нурлыгаян Ихсанов Ватан сугышына 1941 елның 22 сентябрендә китә, 1943 елның апрелендә хәбәрсез югала, хатыны Шәмсениса (1905), балалары Мәзхат (1928), Фәнүзә (1930), Ягъдә (1933), Фәһим (1936), Лена (1941; Октябрьскийда



**Сулдан уңга: Аймара, Лиза, Клара, Фәнә, Халә анасы Сәкинә, атасы Муллагаян белән**

яши) кала. Сугыш корбаннары Ихсановлар Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән.

Муллагаян Ихсанов Яңа Катайның Нурлыгаян Дәүләтов кызы Сәкинә (1912) белән гаилә кора, балалары Халә (1932), Фәнә (1935), Клара (1937), Лиза (1939), Аймара (1941), Разит (1947), Зәлифә (1951), Нәуфилә (1953) туа. Муллагаян Нурислам улы Ихсанов – Ватан сугышы ветераны, 1940 елның 13 августыннан 1941 елның 22 сентябренә чаклы Катай авыл советы рәисе, сугыштан соң 1946 елның кышына чаклы диярлек «Байкал» колхозы рәисе була.

Габделгалинең икенче улы Габделисхакны 1846 елда солдат хезмәтенә алалар, шул китүдән аннан хәбәр булмый.

Әюп Габделгали улы балалары: Миңлебану (1866), Әлмөхәммәт (1868), Шәмсебану (1872), Бикмөхәммәт (15.07.1875; анасы Нәфисә). Әюп кызы Миңлебану (18 яшь) 1884 елның 16 февралендә Камышлының Габдерәфикъ Габделнәфикъ улы (20 яшь; атасы Габделнәфикъ Габделвәли улы) белән никахлаша. Икенче кызы Шәмсебану (18 яшь) 1890 елның 24 декабрендә Камышлының Фәррахетдин Сираҗетдин улы (25 яшь; атасы Сираҗетдин Габит улы) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Шәйхелислам Габделихсан улы белән Әлмөхәммәт Әюп улы була, соңгысының тамгасы «А» хәрефенә охшаган.

Әлмөхәммәт Әюп улы балалары: Нурмөхәммәт (26.08.1898; анасы Миңлеҗамал Сәхаутдин кызы), Шәмсебану (20.09.1900), Фәрхебану (04.05.1903), Шәмсемөхәммәт (20.08.1907), Гыйлембану (1908–1912), Хаҗимөхәммәт (22.10.1910), Шәймөхәммәт (02.03.1914; анасы Миңлеҗамал Сәхаутдин кызы), Вәлимөхәммәт (18.07.1916). Әлмөхәммәт Әюпов (49 яшь) 1917 елда хатыны

(40), ике улы һәм ике кызы белән яши, 12,49 дисәтинә җире, 3 аты, сыеры һәм башка маллары була.

Әлмөхәммәтнең беренче улы Нурмөхәммәт тууын язганда икенче мәхәллә мулласы зур хата җибәрә: атасын Бикмөхәммәт Әюп улы дип яза. Әлмөхәммәтнең хатыны гел Миңлеҗамал Сәхабетдин кызы була, Нурмөхәммәтнең дә анасы шул теркәлгән. Анасы турындагы мәгълүматка таянып хатаны төзәттек, Нурмөхәммәтне Бикмөхәммәттән Әлмөхәммәт балалары исемлегенә күчереп куйдык.

Бикмөхәммәт Әюп улы (23 яшь) 1900 елның 29 ноябрендә авылдашы Мөхәммәтзариф Габделнәфикъ улының кызы Өммегөлсем (18 яшь; Юлдаш нәселеннән) белән кавыша. Бикмөхәммәт балалары: Динмөхәммәт (12.03.1903), Гыйльмиҗиһан (халык телендә Гыйльмизиян; 10.12.1906), Суфиәхмәт (05.08.1910; анасы Өммегөлсем Мөхәммәтзариф кызы), Шәяхмәт (05.09.1913; анасы Өммегөлсем Мөхәммәтзариф кызы), Әбелкәрам (08.08.1915) һәм Мулламөхәммәт (1919–1977). Бикмөхәммәт Әюпов 1917 елда хатыны (42 яшь), өч улы һәм кызы белән яши, 10,54 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була. Өммегөлсем «кендек әби» иде, дип искә алды бер авылдашым. Динмөхәммәт белән Суфиәхмәт Ватан сугышында хәбәрсез югалалар. Динмөхәммәтнең – хатыны Галия (1906), балалары Тәлгать (1933), Рәкия (1936), Рәйханә (1939), Суфиәхмәтнең хатыны Мәрдия (1918), кызы Разия (1939), анасы Өммегөлсем (1870) кала. Мулламөхәммәт Бикмөхәммәт улы Әюпов – Ватан сугышы ветераны, өлкән сержант.

Габделмоталлапның икенче улы Габделгалләмнән нәселне Йосыф (1835–29.01.1893) дәвам итә. Аннан нәсел шулкадәр ишәеп китә, хәтта «Йосыф нәселе» дип тә йөртелә башлый. Йосыфның алты улыннан – Әбүбәкер (1865–1939), Габделгали (1869), Гомәр (1874), Габдрахман (15.03.1877; анасы Бибилатыйфа), Госман (1879), Габделхәбирдән (15.05.1880) – һәрберсеннән нәсел тармаклanып, бүгенге көндә дә дәвам итә. Йосыф кызлары: Мәүлиха (1863), Бибигалимә (1869), Мәдхиҗиһан (28.12.1878). Йосыфның бер кызы Бибигалимә (18 яшь) 1887 елның 3 сентябрендә Сеңрәннең Госаметдин Габделгалләм улы (25 яшь) белән никахлаша, икенчесе Мәүлиха 1888 елның гыйнварында 25 яшьтә әбсе (сукыр эчәге) зәхмәтеннән вафат була.

Әбүбәкер Йосыф улы балалары: Бибимәүлиха (04.11.1890), Бибинәгыймә (22.08.1893; анасы Хәкимә Куянның Хәлим кызы), Баязит (1896–1976; Ватан сугышы ветераны), Хәсәнгата (17.04.1898–1900), Хөрмәтулла (05.05.1901), Миңлемәдинә (07.06.1904), Нигъмәтулла (14.06.1907; анасы Бибихәкимә Миңлехәлим кызы), Сибагатулла (12.10.1909).

Баязит Әбүбәкер улы (30 яшь; икенче никах) 1924 елның февралендә авылдашы Гафиятулла Хәйрулла улының кызы Сәрвәрия (27 яшь; өченче никах) белән никахлаша. Бу никахтан беренче бала булып Илһамия (21.10.1924) туа. Баязит Бакиров 1942 елның 29 мартында Ватан сугышына китә, бу вакытта гаиләсендә хатыны Закирә (1900), уллары Әбүзәр (1929), Әнвәр (1933), Рәсим

(1941; Донбасста шахтада эшли), кызлары Илһамия (1924), Әрҗүдә (1927), Мөзәкирә (1935), Зәкия (1937) була. Хатыны Сәрвәрия вафат булгач, Баязит Закирә белән гаилә корган, соңгы ике кызы шул хатыныннан туган. Илһамия – авылдашы Миргазиян Шагалиевкә, Әрҗүдә авылдашы Кәшбелгаян Әхмәтовка кияүгә чыга. Берникадәр мәгълүматны Әрҗүдәнең кызы Зәлифә Сабирова (Әхмәтова) язып җибәрде.

Сугыш ветераны Сибагатулла Бакиров белән Зифа (1918) балалары: Нигъмәтулла (1937), Тәзкирә (1939), Рәфкать (09.01.1942), Рәзиф (1945), Мәвазиф.

Габделгали Йосыф улы балалары: Габдулла (11.09.1897; анасы Бибикамилә Фәхретдин кызы), Бәһия (23.06.1900), Солтангали (15.09.1904; Ватан сугышында һәлак була), Исламгали (15.11.1906–1969; Ватан сугышы ветераны), Бибизакирә (15.08.1909; анасы Мәдхиҗиһан Мөхәммәтгәрәй кызы), Хаҗгали (15.11.1911), Дөррия (17.03.1917; анасы Мәдхиҗиһан Әхмәтгәрәй кызы). Дөррия Габделгали кызының уллары: Әхтәм (1947), Хөсәен (1954).

Габдулла Габделгали улының Фатыйма Шәрәфетдин кызы белән никахыннан Нәкыя (05.09.1925) туа. Габдулла Галиев 1942 елның 19 гыйнварында сугышка китә, хатыны Фатыйма (1891), балалары Нәкыя (1925), Зиннәтулла (1929), Әбелгавис (1934) кала. Нәкыя Ватан сугышы ветераны Закуан Вахитов белән гаилә кора. Әбелгавис балалары: Зимфира (1957), Альбира (1959), Зилия (1961), Гүзәлия (1963), Рәмзия (1966). Габдулла Галиев, алдарак телгә алган Баязит һәм Хөрмәтулла Бакировлар (Йосыповлар) Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән.

Сугыш корбаны Солтангали Галиев балалары: Хаҗиәкрәм (1930), Хәләф (1934), Миргасим (1936), Фәүзия (1939).

Исламгали Галиев нәселдәше Гыйльмизиян Бикмөхәммәт кызы (1906–17.08.2000) белән гаилә кора, балалары Хаҗгали (1930), Фәһимә (1936; Килкабызда яши), Фәнәвия (1939–05.03.2011) дөньяга килә. Исламгали 1941 елның 12 сентябрендә сугышка китә, сугыштан соң Өлфәт (09.03.1949–12.07.2015) туа. Фәнәвия (беренче китапта исеме ялгыш Фәнәхия дип язылган) Яңа Катайның Мәсгут Харисовка кияүгә чыга.

Хаҗгалинең балалары турында тулырак мәгълүмат сорап, Зәлифә Хаҗгали кызына яздым, ул түбәндәгеләрне хәбәр итте. «Минем әткәй Хаҗгали Исламгали улы Галиев (1930–17.04.2011), «Үткәннәрен бел Катайның» китабында ул бар. Карт әти – Исламгали Габделгали улы Йосыпов (1906–1969), әнкәй – Рәзинә Галикәрам кызы Гаязова (15.11.1934–06.03.1973). Галикәрам Гаязов кулак хуҗалык саналган (сезнең китаптагы исемлектә алар бар). Колхозлар оеша башлагач Галикәрам гаиләсе белән Хабаровский ягына чыгып китәләр, колхозга керәселәре килми (алар кулаклар булган бит). Әнкәй авыр чирдән вафат булды, алты баласы калды, иң зурысы – мин (1953 елгы), 3 курста укый идем. Энем Рәфәт (1956) Уфада милициядә эшләде. Сеңлем Нәүфилә (1959) Салават Госмановта тормышта, хәзер Катайда яшилар. Икенче сеңлем

Зөлфирә (1960) – Урсайда, энем Рафис (1963) – Уфада, Наил (1963) Нижневартовскийда яши. Әткәйнең икенче хатыннан кызлары, сеңелләрем Гөлзирә (23.07.1974) – Уфада, Гөлназ Тюменьдә яши».

Гомәр Йосыф улы (21 яшь) 1893 елның 13 гыйнварында Яңа Катайның Гыймадетдин Фазлулла улы Солтанбәков кызы Бибисорур (19 яшь) белән никахлаша, балалары Хәмзә (01.01.1893), Хәмидулла (25.09.1895), Бибибания (26.06.1900), Бибисания (05.01.1903), Гыйндулла (1905–1906), Сәвия (02.02.1908), Мосаллия (08.08.1910–1912), Габбәс (15.07.1913), Мәрьям (15.02.1916) туа. Метрикәнең Мәрьям исеме астына, 1957 елда загстан туу турында белешмә алуын язып куйганнар.

Хәмзә Гомәров Ватан сугышы алдыннан хатыны Һаҗәр (1897), уллары Хәмидулла (1923), Фәвәрис (1932), Зөфәр (1935), кызлары Мөназзәха (1921), Мөкәррәмә (1926), Мөхәссәнә (1928) белән яши. Мөнәззәха Тымытыкның Галим Хафизовка кияүгә чыга, кызы Зоя (1939) туа.

Габбәс Гомәров гаиләсендә Ватан сугышы алдыннан анасы Бибисорур (1862), хатыны Камилә (1916), улы Фәнис (1940) була. Хәмзә, Габбәс, Хәмидулла Гомәровлар – Ватан сугышы ветераннары.

Габдрахман Йосыф улы балалары: Якутелҗинан (08.12.1901–1904; анасы Гайниҗамал Гарифулла кызы), Гайнелҗиһан (метрикәдә Гайнелҗинан, 26.10.1904–1973; анасы Гайниҗамал Гарифулла кызы), Әлмәгый (09.09.1906–1936), Гайнелхәят (10.11.1908), Хыялый (29.03.1910–1910), Лотфрахман (15.05.1911), Габделхәй (03.07.1914–1980; анасы Гайниҗамал Гарифулла кызы), Мәгънәви (1923–06.03.1944; Ватан сугышында һәлак була), Зөбәйдә (01.09.1925; анасы Гакифә). Габдрахманның ике хатыны була, 1904 елның 30 гыйнварында Корыч олысы Камышлытамак авылыннан алган хатыны Гафия (атасы Әхмәтгали Мөхәммәтгали улы) белән аерылыша («араларында өлфәт вә мәхәббәт юк сәбәпле», дип әйтелә). Ватан сугышы алдыннан Габдрахман Йосыпов (1876) хатыны Гакифәдән (1879) туган балалары Мәгънәви (1923) һәм Зөбәйдә (1925) белән яши. Әлмәгый балалары: Фәния (1932) һәм Өлфәт (1934). Әлмәгыйның кызы Фәния авылдашы Фәтхелбәян Галиев белән гаилә кора. Габделхәй белән Бәһия (1912–1994) Йосыповлар балалары: Рим (1946), Рәшидә (1950), Хәбип (1954).



**Гөлнәзирә Кадыйрова, Рәшидә Галиева, Сажидә Сәлманова**

Хәбип Габделхәй улы Йосыпов пенсиягә чыгар алдыннан Бакалы район казначействодсы җитәкчесе булып эшләде, бу юллар авторына мөрәҗәгать итеп, туксанынчы елларда беренчеләрдән булып шәҗәрәсен төзеттерде, аннары очрашкан саен, иң зур байлыгым шул дия торган иде. Нәселеңнең тарихын белеп, ата-бабаларыңны искә алып яшәү, алар рухына багышлап дога уку яисә укыттыру — болар барысы кешене рухи яктан баета, күңел бөтенлеге тудыра, фани дөнья — бер мизгел, рухи байлык зуррак булуын искәртә.

Госман Йосыф улы балалары: Фәрхебҗамал (22.12.1893; анасы Фәрхиҗамал Тыпыйның Мөхәммәткәрим кызы), Хөснулла (1896), Гыйндулла (05.09.1899–1900). Госман кызы Фәрхебҗамал (17 яшь) 1911 елның гыйнварында Яңа Катайның Габдулла Мөхәммәди улы (24 яшь; вәкиле — агасы Мөхәммәтзариф Мөхәммәди улы) белән никахлаша. Ни сәбәпледер, Госман һәм аның туганы Габделхәбир никах язуында үз нәсел тамгаларын түгел, Арсланбәк нәселенекен («Н» хәрефен хәтерләтә) салганнар (бәлки, алар түгел, мулла үз кулы, билгеге белән шулай салгандыр). Хөснулладан Лотфулла (1919–1924), Тәрҗимә (1923–1924; анасы Кәримә Габдулла кызы), Габделәхәт (22.03.1925–1976; Ватан сугышы ветераны), Нәҗибә (1930), Фоат (1933), Фәрит (1940), Мөдәмил (1943) Госмановларны күрәбез. Нәҗибә — дустым Роберт Акмал улы Фәхретдиновның анасы, Роберт та, Хәбип Йосыпов кебек, автордан шәҗәрәсен төзеттерде, нәсел тарихын белүенә шатлануын әйткән иде.

Габделхәбир Йосыф улы (23 яшь) 1903 елның 10 декабрендә Яңа Катайның Фәрхинур Габделнасыйр Мөхәммәтгалим улының кызы (17 яшь) белән никахлаша. Кияүнең вәкиле — бертуган агасы Госман Йосыф улы, ризалык вәкилләре Габделгали белән Габдрахман Йосыф уллары була. Бу никахтан Габделхәбир балалары: Гөлҗиһан (16.11.1904), Габделкәбир (10.02.1906), Гәүһәрҗинан (02.06.1908), Габделфаяз (10.05.1910), Асия (18.10.1916), Өммеҗиһан (1921–1924), Габделгали (1922–1924), Габделәгълә (08.05.1925; анасы Бибифәрхинур Габделнасыйр кызы). Габделкәбир балалары: Флүн (1931), Гавис (1935), Наилә (1936), Лена (1939). Габделкәбир Хәбиров «Байкал» колхозында бригадир булып эшли, 1942 елның 12 сентябрендә Ватан сугышына китә, 1944 елның 30 сентябрендә һәлак була. Габделхәбир кызы Гәүһәрҗинан авылдашы Мөхәммәтхәтим Мөхәммәтхарис улы Харисов белән никахлаша. Фаяз Хәбир улы Йосыпов (1910–1995) — сугыш инвалиды (1 группа). Әгълә Хәбир улы Йосыпов (1925–1965) Ватан сугышына 1943 елның 1 февралендә китә, кече сержант була, «Батырлык өчен» медале (16.06.1945) белән бүләкләнә.

Габделгали Әюп улы Бибикамилә Фәхретдин кызы белән никахта була, 1903 елның 13 мартында Нигъмәтулла исемле улы туа.

Габделмоталлапның өченче улы Шәмбаз иде. Шәмбаз балалары: Шәмсемөхәммәтгали (1855), Шәймөхәммәт (1859), Миңлешагали (1860), Бибимәрфуга, Бибимәймүнә һәм Миңлебану. Шәймөхәммәт Шәмбаз (Мөхәммәтшәммаз) улы балалары: Өммегөлсем (1873–1883), Мәүлиха (1874–1887), Мөхәммәтхәлим (1880), Мөхәммәтсабир (06.03.1881–25.09.1925), Миргалим

(16.04.1884–1886), Өммегөлсем (15.09.1886–1887), Бибимәүлия (06.08.1888; анасы Бибизәйнәп), Рәхимә (29.03.1894; анасы Зәйнәп Габделбасыйр кызы), Галимөхәммәт (28.06.1898; анасы Бибихәлимә Хөснетдин кызы), Бибикәримә (05.07.1900), Мөхәммәтгали (14.05.1903), Бибиталига (15.01.1904–1904; анасы Маһруй Әхмәтша кызы), Маһирә (10.07.1907), Исламгали (05.06.1909; анасы Хәлимә Хөснетдин кызы), Мәйшәрифә (22.10.1910; анасы Маһруй Әхмәтша кызы), Бибинәгыймә (18.06.1912; анасы Бибихәлимә Хөснетдин кызы). Шәймөхәммәтнең кызы Рәхимә (18 яшь) Мамадыш өязе Сатыш авылының Дәүләтбай Шәрәфетдин улы (36 яшь; икенче никах) белән кавыша. Шәймөхәммәт (35 яшь) 1894 елның 10 маенда Үрмәтнең Хөснибану Шәймәрдан кызы (30 яшь) белән никахлаша. Һәр икесенең икенче никахы дип язылган бу документта егетнең ризалык шаһитлары булып Миңлешагали Шәммаз улы һәм Шәммаз Габделмоталлап улы нәсел тамгасын салганнар. Шул ук Шәймөхәммәт (38 яшь; өченче никах) 1897 елның 20 августында Яңа Катайның Хөснетдин мулла Әүдияр улы Азаматовның кызы Бибихәлимә (18 яшь) белән никахлаша.



**Миңлешагали Шәммаз улы һәм Шәммаз Габделмоталлап улы нәсел тамгасын салганнар. 1894 ел**

Мөхәммәтсабир Шәймөхәммәт улының Факия Җәләлетдин кызы белән никахыннан Әбелкасыйм (20.03.1916) туа. Ватан сугышы алдыннан Факия Шәмбазова (Сабирова; 1889) балалары Фатыйма (1915), Әбелкасыйм (1916), Хәтим (1923), Хаммат (1925), Кифая (1928), Рима (1939) белән яши. Әбелкасыйм (Касыйм), Хәтим һәм Хаммат Ватан сугышында һәлак була (Катайның мемориаль стеласында өч туганның берсе (Касыйм Сабир улы Шәмбазов) генә теркәлгән).

Мөхәммәтхәлим Шәймөхәммәт улы (27 яшь) 1905 елның 21 декабрендә нәселдәше Бибимәдинә Шәйхеразый кызы (19 яшь; атасы Шәйхеразый Габделихсан улы) белән никахлаша. Мөхәммәтхәлим балалары: Вәҗиһа (22.01.1907), Ибраһим (06.01.1909; анасы Бибимәдинә Шәйхеразый кызы), игезәкләр Фатыйма белән Хөсәен (15.06.1912–1912), Габделәгъләә (20.11.1924; анасы Таифә Әхмәтша кызы) һәм Ибраһим (1928) була. Ибраһимнан нәселне Ислам Шәмбазов дәвам итте.

Миңлешагали Шәммаз улы балалары: Миргали (икенче чыганакта Миргалим; 06.01.1890; анасы Гөлбикә), Рәхилә (10.02.1895; анасы Мәликә Кенәз авылының Фәхретдин кызы), Тәрҗимә (22.11.1897), Мирсалих, Әмирсәгыйть (16.04.1912–1912), Мирзаһит (03.06.1913; анасы Мәрзия Әхмәтхан кызы), Мөҗәһит (07.04.1917). Шагали Шәммазовның (57 яшь) ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (30), ике улы һәм кызы белән

яши, 5,75 дисәтинә җире, аты һәм кәҗәсе була. Миргалим Шагалиев (1890) Ватан сугышы алдыннан хатыны Кәшифә (1903), балалары Миргазиян (1923; сугышка 1942 елның 6 мартында китә), Әхмәтнәгыйм (1927), Зәйтүнә (1930), Маһизүрә (1936), Мәккия (1939) белән яши. Миргазиян Миргалим улы Шагалиев (1923) – Ватан сугышы ветераны.

Габделмоталлапның дүртенче улы Баһаутдин да нәсел калдыра, 1859 елда аның Миңлегәрәй (1841) һәм Баһманша (1843–15.05.1917) исемле уллары була.

Миңлегәрәй Баһаутдин улы балалары: Шәрифҗамал (1876), Саимә (1877–1890), Тәгъзимә (19.08.1880), Бибисания (02.09.1884). Миңлегәрәй кызы Шәрифҗамал (22 яшь) 1898 елның 1 мартында нәселдәше Ибнҗәмил Шаһингәрәй улы (55 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле Баһманша Баһаутдин улы була. Миңлегәрәйнең икенче кызы Шәрифҗамал (30 яшь; өченче никах) 1904 елның 25 февралендә Яңа Катайның Мөхәммәтгалим Бәдретдин улы (35 яшь; икенче никах) белән кавыша. Ир тарафыннан ризалык шаһиты – Кашшафетдин Бәдретдин улы (Күчем нәселе тамгасын салган), хатынныкы Госман белән Гомәр Йосыф уллары була.

Баһманша Баһаутдин улы балалары: Мәгъдәнҗиһан (1872), Мөхәммәтшәех (20.11.1875; яшьли вафат), Шәйгардан (1877; анасы Маһинур), Шәйсолтан (10.08.1880), Мөхәммәтназиф (20.08.1883), Мөхәммәтфазыйл (21.02.1886), Хөснижиһан (1888–1889), Кифая (25.05.1889; анасы Маһинур Габделханнан кызы). Баһманша кызы Мәгъдәнҗиһанны (18 яшь) 1890 елның 16 июнендә Корычның Газетдин Сәхаутдин улына (25 яшь; атасы Сәхаутдин Мөхәммәтгали улы) кияүгә бирә. Икенче кызы Кифая (19 яшь) 1909 елның 13 декабрендә Яңа Катайның Вәлиәхмәт Мөхәммәтситдыйкъ улы Күчемов (22 яшь) белән никахлаша.

Шәйгардан Баһманша улы белән Зәкия балалары: Бибиситдыйка (02.11.1908; анасы Бибизәкия Шәйхулла кызы), Миңлезакирә (25.07.1911; анасы Зәкия Шәрәфетдин кызы), Әнвәр (1914). Әнвәр Гарданов – Ватан сугышы корбаны (1941 елда хәбәрсез югалган). Шәйсолтан Баһманша балалары: Сәгадәтбану (07.12.1909), Шәйәкрәм (14.05.1911–1911), Бибизәйтүнә (23.07.1912), Әхмәтсолтан (13.07.1915; анасы Зәкия Әбүнәгыйм кызы), Мөдирә (02.06.1924).

Шәйсолтан Баһманшин (37 яшь) 1917 елда хатыны (30), улы (3) белән яши, 4,56 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була. Шәйсолтан сугыш алды елларында хатыны Зәкия (1885), балалары Солтан (1920), Мәүзидә (1925), Мәккия (1928) белән яши. Солтан Шәйсолтан улы Баһманшин (1920–24.02.1944) Ватан сугышында һәлак була.

Катайның мемориаль стеласында Солтанның фамилиясен русча «Бахманшин» дип язасы урынга, «Бахаманшин» диелгән. Авыл хакимияте, ни сәбәпледер, барлык исемнәрне русча язган, саф татар авылы өчен бу башка сыймаслык хәл. Беләсегез килсә, «Бахаманшин»нан өстәрәк өч «Батретдинов» дигән фамилия дә бар әле. «Бәдретдинов» дип үзебезнең телдә, күңелгә якын итеп язуга ни җитә!




**«Никто не забыт ничто не забыто» дип укыгыз. Фамилияләрне генә түгел, монысын да хаталы язганнар!**

Нәсел турында сүз башлаганда, Җанибәкнең төпчек улы Гыйбадулла, дип әйткән идек. Аның нәселен Ибнехаҗип (1804–08.03.1883) белән Шәнгәрәй (1811) дәвам итә. Ибнехаҗип Гыйбадулла улы ир балалары: Сәхипбаян (1832–20.05.1904; эч авыртуыннан вафат), Сәхратулла (1837–02.12.1904), Равил (1841–17.03.1903), Әбүталип (1864–07.07.1910), Мөхәммәтхарис (1875).

Сәхипбаян Ибнехаҗип улы балалары: Габделбаян (1854), Риян (1869–10.06.1904; эч авыруыннан вафат), Габделихсан, Габделҗәлил (1869–10.05.1914), Исхак (1872), Батыргәрәй (05.08.1878; анасы Фәрхиҗамал).

Габделбаян Сәхипбаян улы балалары: Нурлыгаян (1886; анасы Бәдерниса), Хәмдениса (01.12.1888), Нурислам (24.06.1891–1894, кызамыктан), Нурәхмәт (29.03.1894; анасы Бәдерниса Әбүбәкер кызы), Гөлзифа (15.04.1897). Габделбаян кызы Хәмдениса (18 яшь) 1906 елның 10 ноябрендә авылдашы Ахунҗан Муллаян улы (26 яшь) белән никахлаша. Габделбаян Сәхиповның ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (64 яшь), килене (28) һәм оныгы (3) белән яши, 4,30 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры һәм башка маллары була. Нурлыгаян Габделбаян улы балалары: Фәхрелгаян (20.04.1914), Рәхилә (1923–1924; анасы Гайниҗамал Әбүнәгыйм кызы).

Риян Сәхипбаян улы балалары: Бибикәшифә (20.03.1894; анасы Бибиһәдия Галиулла кызы, Баек авылыннан), Бибихәкимә (27.10.1898), Бибирәйфә (18.03.1901), Сабирҗан (25.07.1903). Риян кызы Кәшифә (17 яшь) 1910 елның 24 ноябрендә Сеңрәннең Муллаәхмәт Дәүләтгәрәй улы (28 яшь) белән никахлаша.

Габделихсан Сәхипбаян улы балалары: Габделгалим (03.07.1894; анасы Факия Шәрәфетдин кызы), Миңлехәкимә (15.09.1897–1898). Габделихсан «мәхәббәтләре юк өчен» 1912 елның 24 гыйнварында Килкабызның Гафиятулла Хәбибулла улының кызы Фәрхенисаны аерып җибәрә. Шул ук Габделих-

сан 1915 елның 9 гыйнварында хатыны Шәмсевафа Низаметдин кызы белән аерылыша («араларында өлфәт вә мәхәббәт юклык сәбәпле»).

Габделҗәлил Сәхипбаян улы балалары: Нургазизҗан (01.05.1897–1899; яман шештән вафат), Габделгазиз (12.05.1900–1905; анасы Сәгыйдә Шәйхулла кызы), Габделгазиз (20.12.1908–1909, эч авыруыннан; анасы Гайнелхәят Сафиулла кызы), Газизҗан (14.07.1910).

Исхак Сәхипбаян улы (25 яшь) 1897 елның 30 декабрендә авылдашы Мөхәммәтхафиз Вәлимөхәммәт улының кызы Маһикамал (18 яшь) белән никахлаша, кызлары Бибикамал (15.04.1900) туа. Исхак (30 яшь) 1905 елның апрелендә Минзәлә өязе Әмәкәй олысы Баек авылының Бибиһәдия Галиулла кызына (32 яшь; икенче никах) өйләнә. Шул ук Исхак (32 яшь; дүртенче никах) 1906 елның 10 июлендә авылдашы Гаязетдин Фәхретдин улының кызы Мөнирә (25 яшь) белән никахлаша, балалары Мөнәвәрә (30.02.1908), Бибимөкәррәмә (27.07.1911–1912) һәм Мөхәммәтхәниф (05.09.1915) дөньяга килә. Исхак Сәхипов (47 яшь) 1917 елда хатыны (48), улы, ике кызы һәм абыйсы (50) белән яши, 4,00 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм 2 кәҗәсе була.

Югарыда Ибнехаҗипның Сәхипбаяннан киткән тармагын карадык. Сәхратулла Ибнехаҗип улы балалары: Шәрифулла (1865), Гыйззәтулла, Һидиятулла (1875), Өммегөлсем (16.02.1880), Шәйәгъзам (10.10.1883), Габидулла. Сәхратулла кызы Өммегөлсем (19 яшь) 1899 елның 1 февралендә Корычның Габделсалих Габделлатыйф улы (23 яшь) белән кавыша. Шул ук Өммегөлсем (22 яшь; икенче никах) 1903 елның 25 гыйнварында Сеңрәннең Хәмидулла Мөхәммәткәрим улы (49 яшь; дүртенче никах) белән никахлаша. Кыз тарафыннан ризалык шаһитлары Шәрифулла белән Габидулла Сәхрәтулла уллары була.

Гыйззәтулла Сәхратулла улы балалары: Бибисорура (15.06.1903), Мәгъмүрә (08.03.1910; анасы Мәхмүдә Әхмәтша кызы), Сөнагатулла (17.03.1917; анасы Мәхмүдә Галләметдин кызы).

Шәрифулла Сәхратулла улы балалары: Сәрвиҗиһан (10.12.1890–1893; анасы Гыйльмиҗиһан), Галия (09.12.1895; анасы Фатыйма Корычның Габдулла кызы), Кафия (10.06.1898), Бибигафия (18.03.1901), Гыйндулла (17.12.1907; анасы Фатыйма Габдулла кызы), Бибифәтхия (22.12.1910), Гыйлемҗан (23.02.1915), Нәһая (02.11.1917). Шәрифулла кызы Бибигалия (22 яшь) 1917 елның 7 декабрендә Корычның Сәлахетдин Шәрәфетдин улы (25 яшь; атасы Шәрәфетдин Җамалетдин улы) белән кавыша. Шәрифулла Сәхратуллин (52 яшь) 1917 елда хатыны (40), улы һәм ике кызы белән яши, 0,56 дисәтинә җире һәм 2 кәҗәсе була. Аның энесе Һидиятулла Сәхратуллинны (42 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (40), ике улы һәм 3 кызы кала, 1917 елда 1,31 дисәтинә җире, сыеры һәм кәҗәсе була.

Шәйәгъзам Сәхратулла улы (22 яшь) 1906 елның 6 гыйнварында Яңа Катайның Шәйхетдин Шиһабетдин улының кызы Майкамал (18 яшь) белән кавыша. Шәйәгъзам балалары: Шәйхелзаман (01.10.1906), Фәхрелгаян (11.01.1909–22.12.1943), Бибигайшә (20.07.1911; анасы Майкамал Шәйхетдин

кызы), Муллагаян (27.04.1914; анасы Гайниҗамал Әбүнәгыйм кызы), Мөкәррәмә (07.08.1917; анасы Майкамал Шәйхетдин кызы), Мөнәвәрә (1921), Зәйтүнә (1923–1924; анасы Майкамал Шәйхетдин кызы), Рухылбаян (09.05.1925). Шәйәгъзам Сәхратуллин (32 яшь) 1917 елда өч улы һәм хатыны (30) белән яши, 4,29 дисәтинә җире, аты, 3 сыеры, кәҗәсе була. Фәхрелгаян Сәхратуллин Ватан сугышында һәлак була, фронтка киткәндә авылда хатыны Мөзәкинә (1914), балалары Мөнәярә (1937), Әлфинә (1939) һәм Разит (1942) кала.

Шәйхелзаман Сәхратуллин (1906–1952) – сугыш ветераны, яшь чагында НКВД да офицер булып хезмәт итә. 1944 елда яраланып кайткач, аны Әхмәргә колхоз рәисе итеп җибәрәләр. Анда 1950 елга чаклы эшли, аннары Катайга кайта, авыл советы рәисе вазифасын башкара. Шәйхелзаман Камышлының Хаҗиәхмәт Шәрифуллин кызы Тәгъзимә белән гаилә кора, балалары Риф (1933), Ирек (1935), Рәүф (1938), Рим (1942), Роза (1945), Рина (1950; нәселдәшем Разит Басыйровка кияүгә чыга) туа. Хаҗиәхмәт Шәрифуллин турында «Ата-бабалар иле Камышлы» китабында мәгълүмат биреп үткән идем (китапның 180 нче битендә), оныгы Рина апа Басыйрова тагын өстәп, аның хәлле яшәвен, авылдашлары аңа рәхмәтле, бердәм булып, кулаклыкта гаепләнүдән алып калуларын әйтте. Дистәләрчә еллар авылыбыз медпунктында шәфкать туташы булып эшләгән Рина апаны, аның хезмәттәшләре Мөзәккия Госманова, Җәүһәрия Харисова, Зоя Арсланова, Фәһимә Габдуллина апаларны бу юллар авторы һәм авылдашларым рәхмәт хисләре белән искә ала.

Шәйхелзаманның сугышта алган бүләкләре дә булган, тик алар юкка чыкканнар. Аның энесе «Батырлык өчен» медале (04.02.1945) белән бүләкләнгән сугыш ветераны Муллагаян Сәхратуллиннан (1914–1997) да нәсел дәвам итә.

Равил Ибнехаҗип улы балалары: Бибимәәлүфә (1869), игезәкләр Таифә белән Габделмансур (02.02.1877; аналары Фәхербанат), Шәмсехәят (10.06.1880–1887), Сәмигулла (15.02.1884). Равил кызы Бибимәәлүфә (18 яшь) 1888 елның 25 гыйнварында Балыклының Габдрахман Әбүбәкер улы (22 яшь) белән никахлаша. Сәмигулла Равил улының кызы Асия (13.06.1925–1925; анасы Мөнирә Гаязетдин кызы) билгеле.

Әбүталип Ибнехаҗип улы балалары: Әбүнәгыйм (17.09.1901), Әбелкәрам (16.04.1905; анасы Фатыйма Хәмидулла кызы), Бибихәкимә (1907–1912).

Мөхәммәтхарис Ибнехаҗип улы балалары (икенче мәхәллә): Мөхәммәтхәниф (15.10.1897–1898, чәчәк рәнҗүеннән вафат; анасы Гыйззебану Габделнасыйр кызы), Бибихәтимә (10.06.1904; анасы Шәмсекамал Габдулла кызы), Шәйшәриф (07.06.1907–1969; Ватан сугыш ветераны), Кәнзелголум (19.02.1910), Мөхәммәтвазыйх (30.01.1916; анасы Шәмсекамал Габдулла кызы). Мөхәммәтхарис Ибнехаҗип улы (27 яшь; икенче никах) 1902 елның 29 февралендә авылдашы Габдулла Фәрхетдин улының кызы Шәмсекамал (18 яшь; Юлдаш нәселеннән) белән никахлаша. Мөхәммәтхарис Хаҗипов (46 яшь) 1917 елда хатыны (35 яшь), өч улы һәм ике кызы белән яши, 2,80 дисәтинә

җире, аты, кәҗәсе була. Шәмсекамалны «кендек әби» дип әйткәннәр (Сайка апа мәгълүматы).

Шәйшәриф Харисов авылдашы Мөхәммәтсолтан Габделгалим улының кызы Бибисаимә (1906–1995; Юлдаш нәселеннән) белән гаилә кора, балалары Мөдәриф (1935–24.03.1994), Руфәт (документында – Рәфәт; 1938–2015), Флүрә (1941), Әрҗүдә (1947) дөньяга килә. Боларны ачыклаганда кайбер мәгълүматны Алфира Руфәт кызы Габдулгалиева (Харисова) язып җибәрде, бабасы Харисны аклар атып үтергәнен өстәп әйтте.

Гыйбадулланың икенче улы Шаһингәрәй иде. Шаһингәрәй (Шәнгәрәй) Гыйбадулла улы балалары: Ибнҗәмил (Ибнеәмин дип тә языла; 1841) һәм Габделҗәмил (1844–23.03.1915, чахоткадан вафат).

Ибнҗәмил Шаһингәрәй улы балалары: Габделгалим, Бибигазизә (1869), Фатыйма (1870), Габделгалим (1871), Габдрахман (21.07.1875; анасы Гафифә), Хәбибрахман. Ибнҗәмил кызы Бибигазизә 1888 елның 11 гыйнварында Камайның Хәмидулла Галиәкбәр улы (22 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Фатыйма 1889 елның 29 ноябрендә Сеңрәннең Әхмәтшакир Габделхаликъ улы (22 яшь) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Габделҗәмил Шаһингәрәй улы белән Габделгалим Ибнҗәмил улы була. Ибнҗәмил Шаһингәрәй улы (55 яшь, икенче никах) 1898 елның 1 мартында нәселдәше Миңлегәрәй Баһаутдин улының кызы Шәрифҗамал (22 яшь) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле – Баһманша Баһаутдин улы, ризалык шаһитлары Габделгали белән Гомәр Йосыф уллары була. Җәмил Шәнгәрәев 1917 елда хатыны (74 яшь) белән генә яши, 4,30 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры, 6 сарыгы була.

Габделгалим Ибнҗәмилов (Ибнеәминов) 1910 елдан Яңа Катайның өченче мәхәлләсендә имам вазифасын башкара. Имам Габделгалим Ибнҗәмил улы балалары: Бибифәрвизә (08.07.1893; анасы Камилә Корычның Мөхәммәтзариф кызы), Сабира (26.03.1895; анасы Мәликә Корычның Мөхәммәтзариф кызы), Бибигөлҗиһан (15.05.1900), Габделгазиз (14.01.1905; анасы Бибикамилә Мөхәммәтзариф кызы), Габделхәбир (1906–1909, эч авыруыннан вафат), Бибисәгыйдә (16.04.1908; анасы Бибикамилә), Мәликә (28.04.1908–1910; анасы Гайникамал), Гайниҗиһан (08.09.1909–1912; анасы Камилә Гарифулла кызы), Мәликә (17.01.1910; анасы Гайникамал Әхмәтша кызы), Мәрьям (12.04.1911–1912; анасы Камилә Мөхәммәтзариф кызы), Габделмәҗит (11.10.1911; анасы Гайникамал Әхмәтша кызы), Һәдия (10.01.1913; анасы Камилә), Габдерәкыйп (15.03.1914; анасы Гайникамал), Рабига (1916–1917), Әмирҗан (01.04.1925; анасы Сания Габделзаһир кызы), Талига (25.06.1925; анасы Гайникамал Әхмәтша кызы). Габделгалим кызы Фәрвизә (18 яшь) 1910 елда Бөре өязе Байкибаш олысы Руш Битулы авылының Солтангали Әхмәтгали улы (35 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Сабира 1915 елда Корычның Мирзасалих Хаҗгали улы (25 яшь) белән кавыша.

Имам Габделгалим Ибнҗәмил улы 1903 елның 30 октябрендә икенче хатын итеп Яңа Катайның Әхмәтша Тимергали улы Габидуллов кызы Гайникамалны (17 яшь) ала. 1916 елның 25 августында ул (45 яшь) өченче тапкыр өйләнә, бу юлы аның хатыны авылдашы Мөхәммәтзаһир Мөхәммәтшакир улының кызы Бибисания (21 яшь) була.

Габдрахман Ибнҗәмил улы балалары: Мәдхиҗиһан (03.06.1903), Газизҗан (29.09.1904–1905), Сабирҗан (18.05.1912; анасы Шәмсеҗиһан Әхмәтша кызы), Камил (1923). Камил Габдрахман улы Җәмилов – Ватан сугышы корбаны (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Хәбибрахман Ибнҗәмил улы балалары: Сабирҗан (15.05.1904; анасы Шәрифҗамал Тәхаутдин кызы), Бибимәрдия (16.08.1906), Разыя (18.05.1912), Тимерхан (02.01.1916; анасы Шәрәфҗамал Тәхаутдин кызы), Хафизә (1922–1924; анасы Шәмсеҗамал Габдулла кызы).

Габделҗәмил Шаһингәрәй улы балалары: Миңлегалим, Габдерәшит (15.01.1876–25.05.1924), игезәкләр Хәсән белән Хөсәен (02.04.1878; аналары Миңлесафа), Бибисабира (10.09.1881), Бибихәтирә (04.09.1884), Хәнифә (21.09.1889), Габдерәфикъ (03.08.1893; анасы Миңлесафа). Габделҗәмил кызы Бибихәнифә (18 яшь) 1905 елның 20 октябрендә Яңа Катайның Фәрхетдин Камалетдин улы (56 яшь; өченче никах) белән никахлаша. Бу никах кыска гомерле була, Габделҗәмил кызы Бибихәнифәне (18 яшь; икенче никах) 1907 елның 27 октябрендә авылдашы Мөхәммәтгәрәй Гайнанша улына (26 яшь) кияүгә бирә. Кызның ризалык шаһитлары булып туганнары Миңлегалим белән Габдерәшит Габделҗәмил уллары теркәлә. Җәмил Шәнгәрәев (77 яшь), хатыны (74) белән генә яши, 4,30 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры, 6 сарыгы була.

Миңлегалим Габделҗәмил улы балалары: Бибисафа (07.12.1897; анасы Бибикамилә Габдулла кызы, бабасы Ибнҗәмил дип язылган), Мирсалих (10.09.1907; анасы Хупҗамал Гыйрфан кызы), Әмиргалим (13.02.1911). Миңлегалим Җәмилев (44 яшь) 1917 елда хатыны (35) һәм ике улы белән яши, 2,06 дисәтинә җире, аты, кәҗәсе була. Игенчелектән тыш, чабата үрү белән шөгыльләнә.

Урман очын тулысынча диярлек Моталлапныкылардан гына тора дип әйтәләр иде, хак икән...

**Моталлапның нәселдәше – Монаитмас** (ул – Моталлапның бабасы Җанибәк белән бертуган). Нәселнең бу тармагы шәҗәрәсе Атнагол Монаитмасовтан (1754–1818) башлана. Аның уллары Чурагол (1787), Мөхәммәтхәнәфи (Хәнәфи; 1801), Үтәгол (1802–1858), Вәлиша (1804–22.10.1878) була.

Чурагол Атнагол улы балалары: Гаделша (1810–02.12.1881), Корбангали (1814–23.04.1887), Мөхәммәди (1844).

Гаделша Чураголов балалары: Дәүләтша (1835), Фәйруша (Фәйрузша; 1842–10.07.1904), Гайнанша (1849–02.08.1905), Гарифә (1856), Мөгълифә (1865). Гаделшаның олы кызы Гарифә (22 яшь) 1878 елның 29 декабрендә авылдашы Мөхәммәтзаһир Мөхәммәтшакир улы (21 яшь) белән никахлаша. Кече кызы

Мөгълифә (18 яшь) 1883 елның 18 ноябрендә шулай ук авылдашы Фәхрислам Габделихсан улы (22 яшь) белән кавыша.

Дәүләтша Гаделша улы балалары: Мөхәммәтша (1858), Мәрданша (1869–1897), Шәмсеруй (1872). Дәүләтша кызы 1890 елның ноябрендә Килкабыз кешесенә кияүгә чыга. Шәмсеруйның (32 яшь) икенче никахы 1901 елда Гайфетдин Шәмсетдин улы (22 яшь) белән була. Кыз тарафыннан ризалык шаһитлары – Фәйруша белән Гайнанша Гаделша уллары, егетнеке мөәзин Шәймөхәммәт Мөхәммәткәрим улы була.

Фәйруша Гаделша улы балалары: Бибигафия (1871), Әхмәтша, Мәхмүдә (07.01.1875; анасы Гайникамал), Хәсәнша (02.10.1878), Фәйрухша (12.03.1881), Хәсәнша (1882), Бибихәкимә (04.07.1884), Бибихәтирә (14.07.1887; анасы Шәмсекамал). Фәйруша кызы Бибигафия (18 яшь) 1889 елның 19 февралендә Байбулатның Мөхәммәтгали Галиулла улы (35 яшь; икенче никах) белән кавыша. Икенче кызы Бибихәтирә (20 яшь) 1910 елның февралендә Корычның Нуретдин Әбүнәгыйм улы (26 яшь; атасы Әбүнәгыйм Әсәдулла улы) белән никахлаша.

Әхмәтша Фәйруша улы балалары: Дәүләтша (20.05.1901; анасы Шәмсеҗамал Габдулла кызы), Миңлеҗамал (20.01.1906), Гайниҗамал (10.12.1903; анасы Шәмсеҗамал Габделгалим кызы), Фәрухша (07.03.1910). Аның туганы Хәсәнша Фәйруша улы (25 яшь) 1907 елның 7 гыйнварында Яңа Катайның Әхтәмгали Габделмәннаф улы Габдрахманов кызы Сафура (17 яшь) белән никахлаша.

Гайнанша Гаделша улы балалары: Мөхәммәтгәрәй (25.12.1878; анасы Миңлеҗамал), Мөхәммәтсадыйк (15.02.1881), Әхмәтгәрәй (30.07.1884), Әхмәдиша (28.09.1887; анасы Сәхипҗамал), Маһикамал (15.03.1890), Мөхәммәтхарис (20.07.1893; анасы Сәхипҗамал Балыклының Мортаза кызы).

Мөхәммәтгәрәй Гайнанша улы (26 яшь) 1907 елның 27 октябрендә авылдашы Габделҗәмил Шаһингәрәй улының кызы Бибихәнифә (18 яшь; икенче никах) белән никахлаша, балалары Дәүләтгәрәй (17.03.1910), Сәетгәрәй (21.12.1911) туа. Мөхәммәтгәрәй Гайнаншинны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (35 яшь) һәм ике улы кала, иманасын арендага биргәннәр.

Мөхәммәтсадыйк Гайнанша улы (26 яшь) 1910 елның 12 гыйнварында авылдашы Әхтәмҗан Мөхәммәтҗан улының кызы Бибифакия (19 яшь) белән никахлаша, балалары Мәдинә (02.04.1924) туа. Аның туганы Әхмәтгәрәй Гайнанша улының да баласы Солтангәрәй (20.01.1914, анасы Хәнифә Габделҗәмил кызы) дөньяга килә. Сугыш алдыннан Садыйк Гайнаншин хатыны Фәхерзиян (1902), улы Тимерьян (1928), кызлары Сурия (1930), Фәүзелзинан (1935) белән яши.

Чураголның икенче улы Корбангали яклап та нәсел дәвам итә. Корбангали Чурагол улы балалары: Тимергали (1845–12.06.1890), Муллагали (1848–1851), Бибиҗамал (1868). Корбангали кызы Бибиҗамал (18 яшь) 1886 елда Яңа Катайның Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтҗан улы (40 яшь; икенче никах) белән

кавыша, әмма кияүдә озак тормый. Шул ук Бибиҗамал (24 яшь) 1888 елның 7 апрелендә Яңа Катайның Җәләлетдин Мөхәммәтсәлим улы (27 яшь) белән никахлаша.

Тимергали нәселен улы Муллагали һәм кызы Бибигайшә дәвам итә. Бибигайшә (19 яшь) 1900 елның 12 февралендә Яңа Катайның Габдерәшит Габдерәкыйп улы (25 яшь; Күчем нәселеннән) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары – Миңлемөхәммәт Якуп улы белән Миңлеәхмәт Хаҗиәхмәт улы, егетнеке Җәләлетдин Мөхәммәтсәлим улы белән Мөхәммәтвәли Мөхәммәтшәфикъ улы була.

Муллагали Тимергали улы балалары: Фәрхисорур (22.06.1898), Бибисәрвәрә (20.01.1901; анасы Шәмсезиядә Мөхәммәтвәли кызы), Шәмсенур (08.08.1903), Гыйззенур (23.11.1905), Бибифәрвизә (08.09.1908), Биктимер (21.11.1909), Мөнәвәрә (1922–1924), Миңлезадә (16.06.1925; анасы Мәсрүрә Габдулла кызы). Муллакай Тимергалиевнең (1863) соңгы хатыны Мәсрүрәдән (1890) тагын Мөнәвәрә (1929) туган.

Чураголның төпчек улы Мөхәммәди иде. Мөхәммәди Чурагол улы балалары: Бибимәмдуха (1872), Нургали (30.08.1874; анасы Зөләйха), Мөхәммәтгали (10.01.1877–1883; анасы Зөләйха), Исламгали (17.12.1881–1882), Миңлемәрфуга (17.02.1883), Нурислам (25.02.1885), Миргали (19.04.1888; анасы Зөләйха), Фатыйма (12.01.1909; анасы Миңлесылу Сәлимгәрәй кызы), Мөхәммәтдин (01.11.1911), Әхмәди (20.02.1915; анасы Миңлесылу Габдулла кызы). Мөхәммәди кызы Бибимәмдуха (18 яшь) 1890 елның 30 ноябрендә Тыпыйның Миңлегали Габделмәннан улы (25 яшь) белән никахлаша. Шул ук Бибимәмдуха кияүдән кайтып, 1892 елның 6 мартында авылдашы Сираҗетдин Камалетдин улы (23 яшь) белән кавыша.

Нургали Мөхәммәди улы балалары (икенче мәхәллә): Миргали (05.12.1901; анасы Миңлевафа Фәррахетдин кызы), Бибихәмдия (08.06.1904; анасы Бибихәмидә Шәймәрдан кызы), Бибихафизә (14.08.1907). Нургали Мөхәммәдиев 1917 елда хатыны (40 яшь), ике улы һәм өч кызы белән яши, 2,50 дисәтинә җире, аты, сыеры була. Нургалинең төпчек кызы (Рәкига; 1916) метрикәдә теркәлмәгән.

Югарыда нәселне Атнаголның беренче улы Чурагол яклап карадык. Атнаголның икенче улы Мөхәммәтхәнәфидән нәселне Хаҗиәхмәт (1840–06.08.1877) дәвам итә. Хаҗиәхмәт Мөхәммәтхәнәфи улы балалары: Миңлеәхмәт (1863–30.07.1915, атасы Хаҗиәхмәт Үтәгол улы дип язылган), Нурмөхәммәт (1870), Бибикамилә (1876), Мөхәммәтсадыйк (16.02.1878). Хаҗиәхмәт кызы Бибикамилә 1894 елның 29 ноябрендә Яңа Катайның Габделхаликъ Йөзәй улы белән никахлаша.

Миңлеәхмәт Хаҗиәхмәт улы балалары: Хөршидҗиһан (17.11.1895; анасы Сәхипкамал Яңа Катайның Шәймәрдан кызы), Казыймөхәммәт (01.12.1899), Бибишәфига (26.07.1909).

Нурмөхәммәт Хаҗиәхмәт улы (45 яшь) 1915 елның 10 декабрендә Яңа Катайның Габделгазим Габделихсан улының кызы Хәмидә (20 яшь) белән никахлаша, аларның баласы Мулламөхәммәт (07.11.1916) туа.

Мөхәммәтсадыйк Хаҗиәхмәт улы (26 яшь; вәли вәкиле – Миңлеәхмәт Хаҗиәхмәт улы) 1911 елның гыйнварында авылдашы Нәдергол Шәмгун улының кызы Миңлекамал (18 яшь) белән никахлаша. Бергә тормышлары барып чыкмый, «өлфәт вә мәхәббәт юк өчен» шул елның 18 мартында аерылышалар. Өч ел хатынсыз яшәгәч, Мөхәммәтсадыйк 1914 елның 7 мартында Яңа Катайның Фазлытдин Хөснетдин улының кызы Саимә (18 яшь) белән гаилә кора.

Атнаголның төпчек улы Вәлиша иде. Вәлиша Атнагол улы балалары: Әхмәтша (1827; 1853 елдан рекрут), Мөхәммәтша (1835–15.07.1894), Мөхәммәтҗан (1838), Гайса (1842–05.03.1899).

Мөхәммәтша Вәлиша улы балалары: Миңлебану (1867), Әлмөхәммәт (15.02.1874; анасы Сәхибә), Кадермөхәммәт (15.08.1877), Миңлехан (15.06.1880), Бибимәликә (22.08.1883), Әмирхан (15.12.1886), Сәгыйдә (1890). Мөхәммәтша кызы Миңлебану (18 яшь) 1885 елның 29 ноябрендә Балыклының Нургали Хәбибулла улы (22 яшь; атасы Хәбибулла Акбулат мулла улы) белән кавыша. Икенче кызы Сәгыйдә (18 яшь) 1909 елның 23 февралендә Тыпыйның ясаклы татары Мөхәммәтгариф Шәймөхәммәт улы (26 яшь) белән гаилә кора. Кызның ризалык шаһитлары туганнары Әлмөхәммәт белән Миңлехан Мөхәммәтша уллары була.

Әлмөхәммәт Мөхәммәтша улы 1901 елның 4 февралендә Яңа Катайның Сәлахетдин Шәйхетдин улының кызы Фәрхиҗамал (18 яшь) белән никахлаша. Әлмөхәммәт балалары: Миңлемөхәммәт (24.11.1903), Миңлеҗамал (12.01.1907; анасы Фәрхиҗамал Сәлахетдин кызы), Казыймөхәммәт (24.06.1910; анасы Фәрхисорурә Исламетдин кызы), Шәймөхәммәт (20.10.1913). Әлмөхәммәт Мөхәммәтшин 1917 елда хатыны (40 яшь), ике улы һәм кызы белән яши, 4,27 дисәтинә җир эшкәртә, 2 эш аты, сыер һәм бозау асрый.

Кадермөхәммәт Мөхәммәтша улы балалары: Мулламөхәммәт (26.10.1904), Бибигалимә (02.12.1905–14.03.2003), Миңлесәмига (30.03.1908), Хаҗимөхәммәт (30.05.1909–1917), Сәфәргали (23.01.1912; анасы Камилә Шәрәфетдин кызы), Муллаәхмәт (11.01.1914). Кадермөхәммәт Мөхәммәтшин 1917 елда хатыны (38 яшь), ике улы, кызы һәм анасы (75) белән яши, 7,61 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм 2 сарыгы була. Кадермөхәммәт кызы Бибигалимә Яңа Катайның Әбүнәгыйм Гайсин (1904) белән гаилә кора, балалары туа.

Гайса Вәлиша улы балалары: Хөсәен (03.11.1874–1883; анасы Бибисорур), Фәрхенур (10.07.1880), Фәрхисорур (1882), Солтангәрәй (20.01.1885–1887). Гайса кызы Фәрхисорур (18 яшь) 1900 елның ноябрендә авылдашы Мөхәммәтнур Кадергол улы (28) белән никахлаша. Кыз тарафыннан ризалык шаһитлары Миңлехан Мөхәммәтша улы белән Миңлеәхмәт Хаҗиәхмәт улы була.

Атнаголның өченче улы Үтәголдан да нәсел дәвам итә, ир балалары Якуп (1836) белән Идрис (1846–22.02.1914) була.

Якуп Үтәгол улы балалары: Миңлемөхәммәт (1868), Фәхерҗиһан (1873), Миңлеәхмәт (1874), Шәмсеҗиһан (1875). Якуп кызы Фәхерҗиһан (18 яшь) 1892 елның 17 гыйнварында Мостафа авылы ясаклы татары Хәбибрахман Габдерәхим улы (22 яшь; атасы Габдерәхим Гайнулла улы) белән кавыша. Икенче кызы Шәмсеҗиһан (23 яшь) 1898 елның 9 декабрендә Иске Куянның Әхмәтлатыйф Габделхәлим улы (26 яшь; агасы Мөхәммәтшакир Габделхәлим улы никахта вәкил була) белән никахлаша. Шул ук Шәмсеҗиһан 1907 елның 5 декабрендә Яңа Катайның Батыргәрәй Арслангәрәй улы (49 яшь; өченче никах) белән гаилә кора. Хатынның ризалык шаһитлары Миңлеәхмәт Хаҗиәхмәт улы белән Муллагали Тимергали улы була.

Миңлемөхәммәт Якуп улы (27 яшь) 1895 елның 23 ноябрендә ерак нәселдәше Шәйхеразый Габделихсан улының кызы Миңлегайшә (18 яшь) белән никахлаша. Миңлемөхәммәт балалары: Сәрвиҗиһан (02.06.1903–1904; анасы Мәрхәбә Фәрхетдин кызы), Ярмөхәммәт (26.01.1907; анасы Миңлекамал Сәфәргали кызы), Фәрхизиядә (16.01.1910; анасы Миңлекамал Сәфәргали кызы), Шәехгали (04.04.1913), Талбетдин (10.11.1916).

Миңлеәхмәт Якуп улы (25 яшь) 1899 елның 2 декабрендә Яңа Катайның Шәймәрдан Тимербулат улының кызы Бәдримөнирә (17 яшь) белән никахлаша. Кияүнең вәли вәкиле – кардәше Миңлеәхмәт Хаҗиәхмәт улы, ризалык (вәкиллек) шаһитлары Шәйхулла белән Әһлиулла Шаһиәхмәт уллары була.

Идрис Үтәгол улы балалары: Сәетвәли, Бикмөхәммәт (1873), Мәдхиҗиһан (21.02.1876), Талбетдин (25.02.1877–1878), Бибифатыйма (21.08.1883–03.08.1910), Исламгали (01.08.1886–1887), Солтангали (06.03.1889; анасы Бибилатыйфа Галиулла кызы), Шәехгали (04.01.1893–1894). Идрис кызы Фатыйма (18 яшь) 1900 елның 3 гыйнварында Мамадыш өязе Сатыш авылы ясаклы татары Дәүләтбай Шәрәфетдин улы (26 яшь) белән никахлаша. Сәетвәли улы Мирзаҗан 1892 елда мәрхүм була. Бикмөхәммәт Идрис улы Яңа Катайның Төхфәтулла Габидулла улының кызы Миңлеҗиһан белән никахлаша, 1915 елның 9 гыйнварында «араларында мәхәббәт юклык сәбәпле» аерылышалар.

Солтангали Идрис улы (26 яшь) 1915 елның 10 декабрендә авылдашы Миңлеһидая Шәйхулла кызы (18 яшь; атасы Шәйхулла Шәрәфулла улы) белән никахлаша, балалары Имамгыйзали (22.11.1916) туа.

Миңлехан Мөхәммәтша улы балалары: Казыйхан (23.01.1909; анасы Таифә Әхмәтша кызы), Саимә (25.06.1911), Мосаллия (1914–1916; кызамыктан вафат), Сания (1920–1924). Казыйхан Миңлеханов Ватан сугышында һәлак була.

Нәселнең Монаитмас тармагы турында сүзебезне тәмамлар алдыннан текстта Гаделша Чурагол улы, Фәйруша белән Гайнанша Гаделша уллары тамгасы салынган 1878 ел документы фрагментын китерәбез. Документта сүз Гаделшаның олы кызы Гарифәнең (22 яшь) авылдашы Мөхәммәтзаһир Мөхәммәтшакир улы (21 яшь) белән никахлашуы турында бара. Гаделша һәм

аның уллары салган тамганың төп элементын (нигезен) очы өскә карап торган өчпочмак тәшкил итә, димәк, ул бу бүлектә сүз барган Моталлап тамгасыннан аерылмый, шуңа аның нәселдәше санала.



**Уң якта аста Гаделша Чурагол улы, уртада аның улы Гайнанша тамга салган. 1878 ел**

**Моталлапның ерак нәселдәше – Рәмәй.** Нәселнең бу тармагына караган кешеләр бүгенге көндә башлыча Бәдретдинов, Дәүләтов һәм Сираев фамилияләре белән билгеле, кемнеңдер хәтта Рәмәй нәселе дип әйткәнен ишеттем. Рәмәйдән нәсел тармагы ишәя, исеме узган гасыр ахырында да хәтер сандыгында саклануын шуның белән аңлатырга кирәктер.

Рәмәй Сәетов 1764 елда теркәлгән, бу вакытта ул туганы Исламай Сәетов белән нәселдәше Ает Биккенин гаиләсендә яши. Рәмәйнең (1754–1827) уллары Миңлегол (метрикәдә исеме Миңлекол; 1779–1855), Вәлиша (1780–1830), Миңлебай (1791), Ямангол (1794–1858), Йөзекәй (1801) һәм Йөзәйдән (1805–20.10.1875) нәсел ишәеп китә.

Миңлеголның уллары Шәмгун (Шәмигол һәм Шәмгол дип тә языла; 1805), Сәеткол (1815–15.11.1881), Яхшыгол (1818–14.04.1886), Муллагол (1826) һәм ике кызы була.



**Шәмгун Миңлеголов һәм аның нәселдәше тамгасы. 1860 ел**

Шәмгун Миңлегол улы балалары: Кадергол (1837–12.06.1889; беренче хатынынннан улы), Нәдергол (1848; икенче хатынынннан улы), Фатиха (1868). Шәмгун кызы Фатиха (18 яшь) 1886 елның 26 февралендә Кандраның Шәрифулла Вәлиша улы (22 яшь) белән никахлаша.

Мөхәммәтнур Кадергол улы (28 яшь) 1900 елның ноябрендә нәселдәше Гайса Вәлиша улының кызы Фәрхисорур (18 яшь) белән никахлаша, балалары Мөхәммәтгәрәй (03.03.1902), Шәйхенур (17.06.1906), Шаһинур (13.02.1910) дөньяга килә.

Нәдергол Шәмгун улы балалары: Миңлеҗамал, Миңлеәхмәт (1878–09.03.1881), Вәлиәхмәт (28.06.1881), Галиәхмәт (1884), Шәехгали (25.01.1885–1889), Сәетгали (18.04.1888–1889; анасы Бәдриҗамал), Миңлекамал (20.01.1894; анасы Гайниҗамал), Шәмсекамал (1899–1900, эч рәнҗүдән вафат), Хаҗиәхмәт (08.02.1902–1905, кызамык), Хаҗгали (17.12.1905; анасы Гайниҗамал Солтангәрәй кызы), Исламгали (25.12.1908; анасы Гайниҗамал Солтангәрәй кызы). Нәдергол кызы Миңлекамал (18 яшь) 1911 елның 10 гыйнварында авылдашы Мөхәммәтсадыйк Хаҗиәхмәт улы (26 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары – Сираҗетдин Яхшыгол улы белән Мөхәммәтнур Кадергол улы, егетнеке Мөхәммәтсадыйк Сафиулла улы белән Мөхәммәтгариф Мөхәммәтсадыйк улы була. Миңлекамал кияүдә озак тормый, 1912 елның 3 гыйнварында Яңа Катайның Габдрахман Хөснулла улы (25 яшь; атасы Хөснулла Гыйсмәтулла улы) белән гаилә кора. Нәдергол кызы Миңлекамал (25 яшь; икенче никах) 1914 елның 21 июнендә Иске Катайның Ширияздан Кашшафетдин улы (икенче никах) белән никахлаша. Шул ук Миңлекамал (25 яшь; исеме Бибикамал шулай язылган) белән Ширияздан Кашшафетдин улы 1915 елның 1 сентябрендә аерылышалар да («араларында мәхәббәтләре киткәнлектән»), ике көннән (3 сентябрьдә) яңадан никах кылып кушылалар. Миңлекамалга бер никахта да озак торырга язмаган күрәсең, 1916 елның 10 маенда үзе кебек күп никахта булган авылдашы Мифтахетдин Камалетдин улына (40 яшь) кияүгә чыга. «Чиләгенә күрә капкачы» дигән халык әйтеме нәкъ бу яңа барлыкка килгән парга туры килә кебек.

Галиәхмәт Нәдергол улы (25 яшь) 1910 елның 3 июнендә авылдашы Фәрхетдин Фәхретдин улының кызы Сәхипкамал (21 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Бу никахтан Миңлетаҗетдин (18.04.1911) дөньяга килә.

Сәеткол Миңлегол улы балалары: Сәйфелмөлек (1850–1890; ютәл зәхмәтеннән вафат), Миңлеягъфәр (Миңлегаффар, 1855–05.04.1912), Миңлеҗиһан (1864), Җиһанбану (1868–1893). Сәеткол кызы Миңлеҗиһан 1886 елда Яңа Катайның Юныс Сәфәргали улы белән никахлаша.

Миңлегаффар Сәеткол улы (икенче никах) 1890 елның 6 ноябрендә Яңа Катайның Мөхәммәтгәрәй Мөхәммәтвәли улының кызы Бибишәмсия (27 яшь; дүртенче никах) белән никахлаша. Миңлегаффар кызы Фәрхиҗиһан (18 яшь) 1882 елның 29 октябрендә Яңа Катайның Мөхәммәтшәфикъ Габделнәфикъ улы (30 яшь; икенче никахы) белән кавыша.

Миңлегол улы Яхшыголдан (1818) нәсел дәвамчылары булып Рахманкол (1841–02.03.1915), Бәдретдин (1857–18.04.1916) һәм Сираҗетдиннар (1859) тора. Яхшыгол кызы Бибикамилә (20 яшь) 1883 елның 2 мартында Килкабызның Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтшәриф улы (25 яшь) белән никахлаша.

Рахманкол Яхшыгол улы балалары: Шәйхелислам (25.08.1874; анасы Кинҗәбикә), Сәфирә (1875–1894), Шәмсеҗиһан (16.03.1895; анасы Якутелҗинан Баһаутдин кызы). Рахманкол кызы Бибикафия (18 яшь) 1890 елның 18 октябрендә авылдашы Садрелшәрига Ибраһим улы (25 яшь) белән кавыша.

Шәйхелислам Рахманкол улы балалары: Мәргубә (12.04.1901; анасы Мәрзия Яңа Катайның Әхмәтгәрәй кызы), Хоббәтелислам (12.10.1903), Гыймаделислам (27.08.1905), Фәхрелислам (04.10.1908; анасы Бибикәшифә Низаметдин кызы), Миңлегафифә (16.04.1910), Миңлесалиха (23.11.1916). Шәйхелислам кызы Мәргубә (18 яшь) 1917 елның 23 декабрендә Кадернең Мөхәммәтназиф Мөхәммәтнәби улына (26 яшь; атасы Мөхәммәтнәби Габделвәли улы) кияүгә чыга.

Бәдретдин Яхшыгол улы балалары: Фәттахетдин (1878), Шәмсемаһия (20.09.1881), Саяфетдин (07.11.1884), Бибизәкия (1885), Бибигарифә (27.11.1886), Бибигазизә (26.12.1888), игезәкләр Газетдин (13.12.1890) белән Зыятдин (13.12.1890–1893; анасы Шәмсеталига), Бибивәдига (08.10.1892–1893), Нуретдин (20.07.1894–1895), Мөнәвәрә (05.12.1895), Җәмгыйтдин (26.12.1897). Бәдретдин кызы Бибизәкия (18 яшь) 1902 елның 29 декабрендә Яңа Катайның Афзалетдин Бәдретдин улы (25 яшь; атасы Бәдретдин Габделфәез улы) белән никахлаша. Уртанчы кызы Бибигарифә (18 яшь) 1909 елның 2 февралендә Иштирәкнең Гыйрфанетдин Җамалетдин улы (23 яшь) белән кавыша. Әлеге Гыйрфанетдин Катайда яши, улы Шәрхемулла (13.10.1910) туа. Бәдретдиннең кече кызы Бибигазизә (18 яшь) 1913 елның 24 гыйнварында Туктаголның мөәзин Минһаҗетдин Баһаутдиновның улы Лотфулла (24 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары – Саяфетдин белән Фәттахетдин Бәдретдин уллары, егетнеке Габдулла Баһаутдин улы белән Кәшфелголүм Минһаҗетдин улы була.

Фәттахетдин Бәдретдин улы балалары: Әминә (17.12.1905), Габделхәй (03.10.1907; анасы Зәкия Шәйхулла кызы), Габделәгълә (23.11.1909–1910; анасы Шәмсебәдәр Шәйхулла улы), Оркыя (15.09.1911; анасы Зәкия Шәйхулла кызы), Сәхия (13.06.1914). Фәттахетдин Бәдретдиновны (39 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (36), улы (10) һәм өч кызы кала, 1917 елда 2,18 дисәтинә җире, аты һәм 3 сарыгы була.

Саяфетдин Бәдретдин улы балалары: Акмалетдин (20.04.1909), Шәмсемаһия (14.12.1910), Әмирһади (07.07.1916; анасы Шәмсениса Габделнәфикъ кызы). Саяфетдин Бәдретдинов 1917 елда хатыны (30 яшь), ике улы, ике кызы, энесе (20), сеңлесе һәм анасы (62) белән яши, 15,93 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче яллый.

Җәмгыйтдин Бәдретдин улы белән Газимә Малик кызы (1905; Кандалакбашныкы) балалары (1925 елгы метрикә һәм авыл советы кенәгәсе мәгълүматы буенча): Җәмигънур (1924), Кыяметдин (20.12.1925; анасы Газимә), Мәвәзинә (1928), Флүн (1936) һәм Гавис (1941). Җәмгыйтдин 1944 елның 25 июнендә сугышта һәлак була, рәсми документларда, ни сәбәпледер, 1896 елда туган дип

күрсәтелә. Мәвәзинә улы Ринат Нәбиев 2017 елда үз оныкларын алып бабасы җирләнгән урынны таба. Җәмигънур Җәмгыйтдин улы Бәдретдинов (1924–1997) сугышта кече лейтенант була, «Кызыл Йолдыз» ордены (14.04.1944) белән бүләкләнә. Кыяметдин хезмәт армиясендә була, Кемеровода шахтада эшли. Мәвәзинә апа сугыш вакытында колхозда эшли, тыл хезмәткәре буларак, сугыш ветеранына тиңләнә.

Сираҗетдин Яхшыгол улы балалары: Бибигыйзҗиһан (25.01.1888), Нуретдин (14.06.1889; анасы Фәхерҗиһан Баһаутдин кызы), Газетдин (13.12.1893; анасы Зөһрә Яңа Катайның Мөхәммәтвәли кызы), Шәмсетдин (28.11.1895), Гыйлаҗетдин (15.02.1898), Шәмсеҗиһан (10.09.1900), Әхмәтхәнәфи (02.12.1905), Әхмәтгариф (04.02.1911; анасы Зөһрә Гаязетдин кызы).

Газетдин Сираҗетдин улы балалары: Миңлемөхәсин (19.11.1925; анасы Сәкинә Шәйхелислам кызы), Фәһим (1928), Нәҗибә (1932; аның кызы Рәзилә, 1956) һәм Вәрисә (1937). Газетдин халык телендә Гастыйм дип аталганлыктан, аның авылдагы кызын Гастыйм Нәҗибәсе дип әйтәләр иде. Вәрисә авылдашы Яхъя Хәбибуллинның улы Флүн белән кавыша, ике кызы туа.

Гыйлаҗетдин Сираҗетдин улы балалары: Миңлегадәвия (24.10.1924; анасы Мәликә Мөхәммәтзакир кызы), Фнүнә (1928), Ганифә (1931), Хәләфетдин (28.12.1934–16.03.2020). Гыйлаҗетдин Сираев 1942 елның 19 гыйнварында Ватан сугышына китә, шул ук елда һәлак була (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Югарыда без нәселнең Миңлегол Рәмкол улыннан киткән тармагын карадык. Рәмколның икенче улы Вәлиша иде. Вәлишадан нәселне уллары Дәүләтша (1820–01.08.1884) белән Мөхәммәтҗан (1827) дәвам итә. Дәүләтшаның улы Әхмәтша (1857) була.

Мөхәммәтҗан Вәлиша улы балалары: Әхмәтҗан (метрикәдә Әхтәмҗан; 1850), Бибифатыйма (1865). Мөхәммәтҗан кызы Бибифатыйма (23 яшь) 1888 елның 24 июнендә Минзәлә өязе Бәкәбез авылының Дәүләтша Фәрухша улы (23 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Сәхипбаян Ибнехаҗип улы белән Мөхәммәди Чурагол улы була, тамгалары тәңгәл килә.

Әхтәмҗан Мөхәммәтҗан улы балалары: Муллаян (10.05.1877; анасы Мәхүпҗамал), Хупҗамал (1882–1887), Әхтәмгали (10.11.1884), Миңлехәтимә (22.07.1888), Бибифакия (1891), Гыйлемҗан (1900–1901), Фәүзия (10.06.1911; анасы Сөгъдә Шәрәфетдин кызы), Тимерҗан (21.01.1914). Әхтәмҗан кызы Хәтимә (18 яшь) 1907 елның 18 мартында Килкабызның Габдулла Габидулла улы (25 яшь) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Муллагали Тимергали улы белән Госман Йосыф улы була. Шул ук Бибихәтимә 1908 елда Камайның Мофаздал Габделваһап улы (45 яшь) белән никахлаша (икесенең дә өченче никахлары). Кызның ризалык шаһитлары Габделгали Йосыф улы белән Гыйззәтулла Сәхратулла улы була. Хәтимәнең дүртенче никахы 1911 елның маенда Әмәкәйнең Габделлатыйф Мөхәммәтислам улы (24 яшь; өченче никах) белән була. Әхтәмҗанның икенче кызы Бибифакия (19 яшь) 1910 елда

авылдашы Мөхәммәтсадыйк Гайнанша улы (26 яшь) белән кавыша. Әхтәмҗан Мөхәммәтҗанов 1917 елда ике оныгы һәм кызы белән яши, 0,62 дисәтинә җире, аты, 2 кәҗәсе була. Муллаян Әхтәмҗан улының балалары Нурлыгаян (28.11.1914; анасы Мәмдуха Гарәфулла кызы) белән Әбелгаян (04.02.1917) була.

Нәселнең Миңлебай Рәмкол улы тармагында Гомәрбай (1815) белән Конгырбайны (1818–08.03.1889) һәм тагын өч кыз баланы күрәбез. Конгырбай уллары: Дәүләтбай (1841) һәм Дәүләтгәрәй (1844).

Дәүләтбай Конгырбай улы балалары: Дәүләтгир (1863), Әсхәбетдин (1872–1887), Мөхәммәтдин (1873), Имаметдин (16.06.1876–1876; анасы Фәррахҗамал), Мөхәммәтхан (12.11.1877), Мөхәммәтшәех (16.05.1880), Әхмәтхан (06.10.1884), Мөхәммәтхан (07.03.1889–1889), Маһисафа (16.04.1890; анасы Фәрхиҗамал). Бер кызы 1899 елда Үрмәт авылы кешесенә кияүгә чыга.

Дәүләтгир Дәүләтбай улы балалары: Бибишәрига (27.04.1892), Рәйфә (15.11.1894; анасы Шәмсениса Габдерәкыйп кызы), Әбүбәкер (1897–1903), Гакифә (12.10.1899; анасы Шәмсениса Тыпыйның Габдрахман кызы), Рәйфә (10.03.1904; атасы – Дәүләтгәрәй, анасы Бибикафия дип язылган), Миңлерәхимә (1906–1909, кызамыктан), Латыйфа (08.04.1909–1909, эч авыруыннан; анасы Кафия Нигъмәтулла кызы), Галимгир (08.11.1911–1912; анасы Шәмсениса Галиулла кызы). Дәүләтгир кызы Бибишәрифә (18 яшь) 1909 елның 19 декабрендә авылдашы Мөхәммәтгали Мөхәммәтхафиз улы (22 яшь; атасы Мөхәммәтхафиз Вәлимөхәммәт улы) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары – Солтангәрәй Дәүләтгәрәй улы белән Мөхәммәтдин Дәүләтбай улы, егетнеке Мөхәммәтнәби Мөхәммәтхафиз улы белән Бәдретдин Камалетдин улы була. Әлеге Яңа Катай кияве Мөхәммәтгали Мөхәммәтхафиз улының балалары Иске Катай метрикәсендә теркәлгән, шуларның берсе Мөхәммәтгазый (29.09.1911) була.

Мөхәммәтдин Дәүләтбай улы Конгырбаев (22 яшь) 1895 елның 20 гыйнварында Яңа Катайның Гарифулла Фәйзулла улы Корбангалиев кызы Бибимәфтуха (17 яшь) белән кавыша. Кияүнең вәли вәкиле – бертуган агасы Дәүләтгир Дәүләтбай улы, ризалык шаһиты Сәмигулла Сәйфулла улы була. Бу никахтан Мәргубә (16.07.1898), Мөгаллимә (03.04.1901), Әхмәдетдин (30.10.1903–1910), Мәхдүмә (29.03.1906), Бибимәрьям (20.11.1908), Бибизәйнәп (18.10.1911) туа.

Мөхәммәтшәех Дәүләтбай улы 1905 елның 13 октябрендә авылдашы Габделгазиз Габделшәфикъ улының кызы Шәмсеҗиһан (Юлдаш нәселеннән) белән никахлаша. Әлеге никахта Мөхәммәтшәехнең вәли вәкиле булып агасы Дәүләтгир Дәүләтбай улы теркәлә. Мөхәммәтшәех балалары: Мөхәммәтхан (18.09.1906; анасы Шәмсеҗиһан Габделгазиз кызы), Мәдхиҗиһан (1908–1909, кызамыктан вафат), Мөхәммәтхәниф (02.03.1913), Мөбәрәкҗан (16.08.1914–1914, чәчәк зәхмәтеннән; анасы – Шәмсеҗиһан, атасы Шәехгали Дәүләтбай улы дип язылган), Әмирҗан (25.01.1917; анасы Шәмсеҗиһан), Камил (1922). Шәех Дәүләтовның икенче никахы Кәримә Шакир кызы (1894; Килкабызныкы) белән була, аннан Рәис (14.11.1935), кызлары Тәскирә (30.10.1938), Рамима


**Рәис һәм Мөзәянә Дәүләтовлар**

(01.11.1941), Рәйханә (06.05.1944) туа. Болар турында кайбер мәгълүматны Дамира Рәис кызы Күчемова (Дәүләтова) язып җибәрде.

Мөхәммәтхан Мөхәммәтшәех улы Дәүләтов авылдашы Кифая Мөхәммәтхарис кызы (Табыш нәселеннән) белән гаилә кора, кызлары Фәния (1928) белән Әнисә (1934; Шаран районында яши) туа. Сугыш алдыннан Мөхәммәтхан Үзбәкстанда юкка чыга.

Әмир Дәүләтов – Ватан сугышы ветераны (өлкән сержант, командир), «Ватан сугышы» (II дәрәҗә; 31.01.1945) ордены белән бүләкләнгән, аның энесе Камил шул сугышта хәбәрсез югала.

Рәис Дәүләтов Яңа Катайның Исмәгыйль Ибраһимов кызы Мөзәянә (18.10.1935) белән гаилә кора, балалары Фәвәзил (08.02.1958), Дамира (14.01.1960), Фәвил (29.01.1964), Фәнзил (06.02.1968), Ильмира (12.12.1972) туа.

Әхмәтхан Дәүләтбай улы балалары: Нажия (1918), Тимерхан (16.08.1925; анасы Мөгълифә Газетдин кызы) һәм Ясави (1931). Алар барысы Дәүләтов фамилиясе белән билгеле. Әхмәтхан кызы Нажия авылдашы Галиәхмәт Басыйровка кияүгә чыга, балалары туа.

Дәүләтгәрәй Конгырбай улы балалары: Миңлезиядә (10.02.1877; анасы Шәргыя), Солтангәрәй, Факия (23.12.1881), Бибифатыйма (12.07.1884), Шәехгали (11.09.1886), Хәтирә (26.1888–1893), Бибизәкия (1892–1893), Хәтирә (17.02.1894), Хәкимә (08.08.1898–1898, эч авыруыннан; анасы Шәргыя Яңа Катайның Нигъмәтулла кызы). Дәүләтгәрәй кызы Фатыйма (18 яшь) 1902 елның 27 декабрендә Камышлытамакның Габделкаһир Бикташир улы (22 яшь; атасы Биктаһир Бикморза улы, ризалык шаһитлары – Биктимер белән Динмөхәммәт Биктаһир уллары) белән никахлаша. Дәүләтгәрәйнең кече кызы Бибихәдичә (18 яшь) 1917 елның 13 октябрендә авылдашы Мөхәммәтхәтим Мөхәммәтхарис улы (26 яшь; атасы Мөхәммәтхарис Нурмөхәммәт улы) белән гаилә кора. Кызның ризалык шаһитлары Муллаян Нигъмәтулла улы белән Дәүләтгир Дәүләтбай улы була. Дәүләтгәрәй Коңгырбаевның улын (35 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (65), килене (30) һәм кызы белән яши, 9,14 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры, 8 сарыгы һәм кәҗәсе була.

Солтангәрәй Дәүләтгәрәй улы балалары: Миңлесәетгәрәй (13.01.1907; анасы Миңлеҗиһан Мөхәммәтгәрәй кызы), Сәхипгәрәй (03.03.1909), Шәйхелимам (04.10.1911–1912), Сәетгали (16.04.1913). Сәхипгәрәй Гәрәев Ватан сугышына китә, хатыны Саҗидә (1910), балалары Рәфкать (1939) һәм Халидә кала.

Шәехгали (Шәйхелгали) Дәүләтгәрәй улы 1911 елның октябрендә авылдашы Галиулла Шәрифулла улының кызы Гыйльмениса (19 яшь; икенче никах) белән кавыша, балалары Зәкия (05.05.1914) туа. Башка никахтан Шәехгали кызы Миңлерәйсә (30.08.1924; анасы Нурдидә Хәйдәретдин кызы) билгеле.

Югарыда Рәмколның икенче улы Миңлебайдан киткән тармакны карадык. Рәмколның өченче улы Яманголның балалары булмый, дүртенче улы Йөзекәйгә күчәбез. Йөзекәй Рәмкол улы балалары: Шәмсетдин (1836), Хисаметдин, Миңлегали (1841–19.03.1908; өчесе дә беренче хатыннан). Йөзекәй кызы Майкамәр (18 яшь) 1877 елның 26 сентябрендә Камайның Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәт улы (35 яшь) белән никахлаша. Шәмсетдиннең улы Саяфетдин (1859) билгеле.

Миңлегали Йөзекәй улы балалары: Әхмәтгали (1863–15.10.1916), Хәсәнҗиһан (16.03.1877; анасы Хәсәнҗамал), Шәехгали (11.08.1880–1883), Шәмсесорур (06.07.1884–1886). Миңлегали кызы Хәсәнҗиһан (25 яшь; икенче никах) 1904 елның 25 февралендә Гыйльметдин Хасбиран улы (26 яшь) белән никахлаша.

Әхмәтгали Миңлегали улы балалары: Әхмәтзакир (23.04.1898; анасы Бибимәрзия Камайның Габделнәфикъ кызы), Миңлесания (14.07.1903), Миңлесаимә (29.08.1906), Мөхәммәтмәкки (03.11.1909), Миңленәфисә (15.11.1913; 1968 елда загстан туу турында белешмә ала). Мәкки Галиев (1909) 1941 елның 14 июлендә Ватан сугышына китә, 1942 елның 20 гыйнварында һәлак була (Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән), хатыны Мәгъмүрә (1910), уллары Гарәби (1936), Мөдәррис (1939) кала. Мәккинең кыз туганнары Саимә (1906) белән Нәфисә (1913) гаилә кормыйча бер йортта яшәделәр.

Рәмколның төпчек улы Йөзәйдән нәселне Тәхаутдин (1827), Сәхаутдин (Сәхабетдин; 1843–26.05.1882), Гыйззәтулла (1850) дәвам итә. Аларның һәрберсенә аерым тукталып үтәбез.



**Йөзәй Рәмколов тамга салган документ фрагменты**

Тәхаутдин Йөзәй улы балалары: Гыйльметдин (1855–21.11.1895), Бибигарифә (1859), Миңлехан (1860). Тәхаутдин кызы Бибигарифә 1878 елның 15 февралендә Балыклының Шәрәфетдин Габдулла улы (23 яшь) белән кавыша.

Гыйльметдин Тәхаутдин улы балалары: Галимҗан (10.01.1883–1883), Миңлехәкимә (28.06.1884), Минлегарифә (02.08.1887), Әсхәбетдин (15.01.1890; анасы Хәлимә мишәр Гыйсмәтулла кызы).

Миңлехан Тәхаутдин улы балалары: Миңлебибимаһирә (29.05.1891; анасы Маһруй), Бибимөнәвәрә (26.06.1893), Галимҗан (25.08.1895–1905, кызамыктан вафат), Мөнирә (04.01.1900; анасы Маһруй Корычның Габделгазиз кызы), Габитҗан (02.02.1905). Миңлехан кызы Маһирә (18 яшь) 1917 елның

20 декабрендә Яңа Катайның Миңлеражетдин Сиражетдин улына (26 яшь) кияүгә чыга. Кызның ризалык шаһитлары – Саяфетдин Бәдретдин улы белән Галәветдин Нәдергол улы, егетнеке Әһлетдин белән Гыйльметдин Сәйфетдин уллары була. Миңлеханның соңгы никахы Мәмдуха Гарифулла кызы (Яңа Катай) белән була, 1913 елның 15 маенда «араларында өлфәт вә мәхәббәт юк сәбәпле» аерып җибәрә. Миңлехан Тәхаутдинов (57 яшь) 1917 елда ике улы һәм кызы белән яши, 3,19 дисәтинә җире, аты була.

Сәхаутдин Йөзәй улы балалары: Садретдин (1863), Насретдин (1868–25.12.1895), Шәмсенур (1869), Миңлеәхмәт (01.11.1875; анасы Шәмсесорур), Миңлешәмсезиядә (05.04.1880–1883). Сәхаутдин кызы Шәмсенур (18 яшь) 1887 елның гыйнварында Камайның Фәррахетдин Мөхәммәтшәриф улы (23 яшь) белән гаилә кора.

Садретдин Сәхаутдин улы балалары: Зәйнегабид (06.12.1899; анасы Миңлесафа Камайның Кәлимулла кызы), Әгъләметдин (29.10.1909; анасы Саяда Әсәдулла кызы). Садретдин Сәхәбетдиновның (54 яшь) олы улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (45 яшь), кече улы һәм кызы белән яши, 0,05 дисәтинә җире, 3 кәҗәсе була.

Гыйззәтулла Йөзәй улы балалары: Маһикамал (1876), Зиннәтулла (12.11.1877), Сәйфулла (10.12.1881–1882), Гыйсмәтулла (15.08.1883). Гыйззәтулла кызы Маһикамал (18 яшь) 1894 елның 11 декабрендә авылдашы Вәлиулла Сәйфулла улына (25 яшь) кияүгә чыга. Кызның ризалык шаһитлары нәселдәшләре Дәүләтгәрәй Конгырбай улы белән Гыйльметдин Тәхаутдин улы була.

**Моталлапның ерак нәселдәше – Госман** (Сайран). Нәселнең бу тармагы Госманнан башлана. Аның оныклары күп булып, Сайран исемлесеннән Сайранов фамилиясе барлыкка килә һәм өстенлек итә. Шуңа күрә Госман белән җәя эчендә оныгы Сайранны күрсәттек. Бу тармак вәкиле Таҗетдин Сайранов салган тамганың төп элементы шулай ук өчпочмактан тора. Шулай итеп, китабымның бу бүлегендә сүз барган кешеләрнең барысы да бер нәсел кешеләре икәнлеген документлардагы тамгалар раслый, бернинди шиккә урын калдырмый. Бик борынгы документлар сакланган булса, бу нәсел кешеләренең уртак бабасын да күрсәткән булыр идек. Кызганыч, архивларның мөмкинчелекләре чикле, шуңа күрә уртак бабай кем булган, кайсы чорда яшәгән кебек сорауларга берничек тә җавап таба алмыйбыз.

Госманның Ибраһим (Ибрай; 1724) исемле улы булып, аннан Морат (1744), Морадым (1760) һәм Мәхмүт (1762) дөньяга килә. Китап кушымтасында бирелгән 1795 һәм 1811 елгы чыганакларда боларның балалары кайсына караганы кайбер очракларда төгәл күрсәтелми, шуңа күрә хаталанмас өчен 1816 елгы һәм аннан соңгы документларга таянырга кирәк.

Нәсел ишәюдә Мораттан киткән тармак өстенлек итә. Шәҗәрә схемасы болай: Госман–Ибраһим (1724) – Морат (1744) – Монасыйп (1769–1850) – Төхфәтулла (1801–1830) – Шәрифулла (Шәрәфулла дип тә языла; 1827).

Шәрифулла Төхфәтулла улы балалары: Гатиятулла (1850–07.04.1914), Заһидулла (1853), Галиулла, Хәбибулла (1867), Шәйхулла (1868), Хәмидулла (1873–1897; ютәл рәнҗүеннән вафат), Гарифулла (15.02.1875), Фәхерҗиһан (1879), Хәйрулла (29.08.1880–1884), Хөснулла (15.07.1884–1886). Шәрифулла кызы Фәхерҗиһан (18 яшь) 1897 елның 30 декабрендә Яңа Катайның Сәлимгәрәй Шәнгәрәй улы (25 яшь; атасы Шәнгәрәй Тимербулат улы) белән никахлаша.

Гатиятулла Шәрифулла улы балалары: Әбелфатих (1879), Исламгали (04.02.1885), Солтангали (18.04.1887–1890), Факия (09.10.1888), Сөнәгатулла (26.01.1891; анасы Хәкимә Кәлимулла кызы), Хөрмәтулла (16.03.1897; анасы Мәликә Рәҗәп авылының Корбангали кызы), Тәгъзимә (08.04.1899), Лотфулла (05.01.1902), Әмирҗан (13.08.1904–1916), Нурзидә (08.04.1907), Имамгазый (29.11.1910), Галимҗан (03.04.1913; анасы Мәликә Корбангали кызы). Гатиятулла кызы Тәгъзимә 1917 елның 15 октябрендә авылдашы Миңлемөхәммәт Габдулла улы (26 яшь; атасы Габдулла Җомагол улы) белән никахлаша. Икенче кызы Нурзидә 1925 елда Чүмәлә Катайның Мөхәммәтназиф Габделлатыйф улы белән гаилә кора.

Әбелфатих Гатиятулла улы (26 яшь) 1905 елның 17 ноябрендә авылдашы Сиражетдин Яхшыгол улының кызы Гыйззеҗиһанга (18 яшь) өйләнә. Әбелфатихның вәли вәкиле – атасы Гатиятулла Шәрәфулла улы, ризалык шаһитлары Заһидулла Шәрифулла улы белән Исламгали Гатиятулла улы була. Әбелфатих белән Гыйззеҗиһан балалары: Фәрвизә (12.03.1909–1910), Кыйбан (18.06.1911), Габделәхәт (08.07.1914), Габделгали (29.08.1917). Әбелфатих Гафиятуллин 1917 елда хатыны (28 яшь) һәм ике улы белән яши, 2,80 дисәтинә җире, 2 аты һәм 2 кәҗәсе була.

«Үткәннәрен бел Катайның» китабында Әбелфатих турында мондый мәгълүмат биргән идек: «Иске Катайдан Әбелфатих Гатиятуллин слесарь, тимерче буларак билгеле, аның Маты буенда алачыгы булган. Үзе кебекләрдән зур осталыгы белән аерылып торган, ат кадагына чаклы ясаган, заказга да эшләгән. Әсләм абый Күчемов сөйләве буенча, Әбелфатихның алты улы (Фоат, Мигъзәм, Локман, Гыйльван, Кыйбан, Габделәхәт) була. Ул гаиләсе белән Чүмәлә Катайга күчә. Бертуганы Шәрифулла исемле, аның уллары Салих һәм Даһид була». Метрикәләрне җентекләп өйрәнә торгач, Әсләм абый мәгълүматында төгәлсезлекләр ачыкланды, Әбелфатихның олы уллары Кыйбан белән Габделәхәт булуын, бертуганы Шәрифулла түгел, Исламгали булын күрдек. Читкә чыгып киткән кешеләрнең нәсел-нәсәбен кайдан белеп бетерәсең?

Исламгали Гатиятулла улы (22 яшь) 1909 елның гыйнварында Яңа Катайның Мөхәммәдиша Фәрукша улының кызы Галимә (18 яшь) белән никахлаша, беренче мәхәлләдә балалары Хаҗгали (19.04.1911; атасы Мөхәммәтислам дип язылган), Хуҗагали (03.06.1914), Миңлекәшифә (04.11.1916) туа. Ислам Гатиятуллин (32 яшь) 1917 елда хатыны (30), улы һәм кызы белән яши, 0,62 дисәтинә җире һәм 4 кәҗәсе була.

Шәрифулланың икенче улы Заһидулла (халык телендә Зәйдулла) иде. Ул 25 яшьтә 1880 елның 10 февралендә Иштирәкнең Галия Низаметдин кызы (18 яшь) белән никахлаша, балалары Мөхәммәтфатих (03.02.1882–1908), Гөлчирә (29.06.1884), Миңлемөнәвәрә (06.11.1886), Мөхәммәтнәгыйм (16.11.1887), Бибимәсрүрә, Мөхәммәткәбир (07.03.1894), Миңлемәрхәбә (21.04.1897), Фәрханә (28.09.1901) туа. Зәйдулла кызы Бибимәсрүрә 1909 елның 2 февралендә Дөмәйнең Госман Сәлимгәрәй улы белән никахлаша. Мөхәммәтнәгыйм Зәйдулла улы 1916 елда авылдашының никахында кыз ягыннан ризалык шаһиты буларак телгә алына. Мөхәммәтнәгыймне Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда Зәйдулла хатыны һәм кызы (16 яшь) белән яши, 4,28 дисәтинә җире, аты, 4 кәҗәсе була.

Шәрифулланың өченче улы Галиуллага күчик. Галиулла Шәрифулла (Шәрәфулла) улы балалары: Шәмсениса (16.11.1888–1894; анасы Гыйззениса), Гыйльмениса (08.08.1892), Шәмсеҗиһан (26.12.1895; анасы Гыйззениса Яңа Катайның Сәйфетдин кызы), Гыйльмиҗиһан (1896–1900), Бәдерниса (25.05.1899), Фәрхениса (05.08.1902; анасы Гыйззениса Сәйфетдин кызы), Сәвия (03.12.1906). Галиулла кызы Гыйльмениса (18 яшь) 1910 елның ноябрендә авылдашы Сәлимгәрәй Миңлехәлим улы (25 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Афзалетдин Гыймадетдин улы белән Шәрифулла Хәбибулла улы була. Шул ук Гыйльмениса кияүдән кайтып, 1911 елның 4 октябрендә авылдашы солдат Шәехгали Дәүләтгәрәй улы (26 яшь) белән никахлаша.

Нәселне Шәрифулланың дүртенче улы Хәбибулла яклап карыйк. Хәбибулла Шәрифулла (Шәрәфулла) улы балалары: Миңлехәбибрахман (03.03.1891; анасы Шәфига), Габдрахман (15.03.1894), Миңлеталига (1896–1899; эч авыруыннан вафат), Ибраһим (21.07.1899; анасы Шәфига Камай авылының Габделхаликъ кызы), Яхъя (06.05.1902; анасы Шәфига Габделхаликъ кызы), Зәкәрия (07.01.1905; анасы Шәфига Габделхаликъ кызы), Миңлефакия (09.05.1908–1909, кызамыктан), Миңлегалим (16.06.1910–1914, кызамыктан). Хәбибрахман Хәбибулла улы (25 яшь) 1917 елның 13 июлендә авылдашы Нурислам Габделихсан улының кызы Камилә (20 яшь) белән никахлаша.

Габдрахман Хәбибулла улы балалары: Лотфрахман (1919), Әрҗүдә (1923–1924), Мөхәммәткамал (13.06.1925; анасы Мөнәвәрә Мөхәммәтхафиз кызы), Әхәт (1932). Лотфрахман Хәбибуллин (1919–1979) – Бөек Ватан сугышы ветераны. Лотфрахман кызы Гамбәрия Хәбибуллина (1940) алдынгы савучы була, «Хезмәт Кызыл байрагы» орденнары (1971, 1976), «Хезмәт батырлыгы» медале, «ВДНХ»ның көмеш һәм алтын медальләре белән бүләкләнә. Хәбибуллиннарның тырыш һәм эшчән гаиләсе турында авылдашыбыз Әлфия апа Хәйдәрова «Коммунизм байрагы» гәзитендә 1977 елның 24 маенда бер язма бастырган иде. Түбәндә аны тулы килеш бирүне кирәк дип таптык.

«Катай авылы кешеләре Лотфрахман Габдрахманович Хәбибуллин яки аның тормыш юлдашы Дөррия Габделгалиевна белән очрашканда, ихтирам һәм хөрмәт йөзеннән беренче булып исәнлек биреп үтәләр. Аларны хезмәт

ветераннары һәм өлкән яшьтә булганнары өчен генә түгел, бәлки Яңа Маты совхозының Катай бүлекчәсендәге барлык эшчәннәр дә горурланырлык алты бала тәрбияләп үстергән өчен дә ихтирам итәләр.

Ата-аналар үз балаларына һәрчак хезмәткә мәхәббәт, намуслы караш үрнәкләре күрсәттеләр. Лотфрахман Габдрахманович сугышка кадәр атлар караучы булып эшли, ә сугышның беренче көннәреннән үк Совет Армиясе сафына чакырыла. Дүрт ел буена кулына корал тотып Бөек Ватан сугышы фронтларында сугыша. Бөек Җиңүдән соң туган авылына кайтып, кабат үзенең элекке эшенә керешә. Ул хәзер дә дуңгыз асрау фермасында атлар карый, производство алдынгысы булып тора.

Лотфрахман Габрахманович кулына корал тотып Туган илебезне саклаганда Дөррия Габделгалиевна ире урынында атлар карый, үзенә йөкләтелгән вазифаны намус белән үти. Хәзер ул законлы ялда инде. Бу гаиләдә туыпүскән балалар ата-аналары үрнәгенә иярделәр. Кызлары Гамбәрия берничә еллар инде савучы булып эшли, күп сөт өчен ферма савучылары арасындагы социалистик ярышның алгы сафында бара. Бөтенсоюз социалистик ярышында ирешкән уңышлары, планнарны һәм социалистик йөкләмәләрне үтәүдә күрсәткән хезмәт батырлыгы өчен Гамбәрия Хәбибуллина ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, «Батыр хезмәт өчен. В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу хөрмәтенә» медале, «Социалистик ярышта җиңүче», «Тугызынчы бишьеллык ударнигы» билгеләре, Почет грамоталары белән бүләкләнде. Ферма коллективында ул коммунист, терлекчелек остасы булды, зур гына җәмәгать эше алып бара – агитатор булып эшли, коллективтагы яшь работникларның киңәшче-тәрбиячесе.

Катай урта мәктәбен тәмамлаганнан соң бертуган комсомолецлар Акмал, Хөсәен, Вәзилә һәм Әхкәм дуңгыз асрау комплексы коллективына кушылды, Акмал котельныйда кочегар булып эшли, намус белән эшләгәне өчен совхоз дирекциясе тарафыннан берничә тапкырлар дәртләндерелде, Почет грамоталары белән бүләкләнде, үзешчән сәнгатьтә актив катнаша.

Хөсәен шофер булып эшли, әзерләнелгән азыкларны ул махсус машинада корпусларга илтә, «Комсомол прожекторы» редакторы да.

Вәзилә – дуңгыз асрау комплексының азык цехы эшчесе, союзның эчке эшендә актив катнаша.

Алар икесе дә производство алдынгылары, Бөек Октябрьны лаеклы каршылау хөрмәтенә кабул иткән социалистик йөкләмәләрен уңышлы үтиләр. Әхкәм, комплекста эшләү белән бер үк вакытта, урман хуҗалыгы техникумын тәмамлап, хәзер белгечлеге буенча эшли.

Гаиләдәге иң кече бала – Рәмил музыка училищесында укый.

Үз балалары өчен ата-аналарның күңеле шатлык һәм горурлык белән тулы. Якты киләчәгебез – коммунизмны яшь төзүчеләр дөрес юлдан атлыйлар. Бу киң һәм якты юлны Бөек Октябрь социалистик революциясе ачты».

Менә нинди күңелле, оптимист рухта язылган язма. Әйе, дөрес юлдан барабыз дип уйлый, зур хыяллар белән яши идек, чит илләр йогынтысы, шуларга сатылган, үз мәнфәгатьләрен өстен куйган адәмнәр илне таркатты да, ярымкыргый капитал шартларына куйды, хәзер үткәннәрне сагынырга гына кала.

Хәбибулланың башка улларына күчик. Ибраһим Хәбибулла улы балалары: Миргазиян (25.04.1924), Фәүкыя (04.11.1925; анасы Хәтимә Габделкаһир кызы). Ибраһим Хәбибуллин (1899) Ватан сугышында һәлак була, хатыны Хәтимә (1903), балалары Фәһимә (1930), Фәнүдә (1939), Тимергазиян (1941) кала.

Яхъя Хәбибуллин (1902–1962) – Ватан сугышы ветераны, старшина була, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә. 1945–1949 елларда авыл советы башкарма комитеты рәисе, 1950 елда Яңа Катайда «Яңа тормыш» колхозы рәисе булып эшли. Яхъя белән Тутыя балалары: Нәкыя (1928), Сәхия, Суфия, Флүн, Флүр, Флүрә.

Яхъя кызы Нәкыя Кәшбел Фазлыев белән гаилә кора, балалары Рәмзә, Зөһрә, Зәйлә, Алфира, Венера, Илшат туа. Кәшбел (27.06.1919 елда Мәсгүт (хәзерге Мөслим районы) авылында туган) хәрби хезмәткә 1939 елда чакырыла, японнар белән сугышта катнашканда старшина була, «Сугышчан хезмәтләре өчен» (14.09.1945) һәм «Японияне җиңгән өчен» (30.09.1945) медальләре белән бүләкләнә. Кәшбел абыйның анасы – Зөләйха Мортазина (1890), туганнары Мөдәррис (1922), Рәйфә (1923; Октябрьскийда яшәгән), Хәмит (1927; Уфада фәнни хезмәткәр булып эшләгән), Мирзаһит (1930; хәрби кеше була). Зөләйханың ире мулла була, «12 яшьтә кияүгә бирделәр», дип әйтә торган булган Сайка апага.

Яхъяның икенче кызы Суфия Яңа Катайның Мөҗәһит Әбүнәгыйм улы Яруллинга кияүгә чыга, балалары Зилә, Зира, Илдар дөньяга килә. Флүн авылдашы Вәрисә Газетдин кызы белән гаилә кора, фаҗигагә тарый, ике кызы (Илсөяр, Илүсә) кала. Яхъяның башка балалары читкә чыгып китә.

Зәкәрия Хәбибулла улыннан Нурзөмәрә (13.10.1924; анасы Саҗидә Нургали кызы) дөньяга килә. Зәкәрия Хәбибуллин – Ватан сугышы ветераны, сугышка киткәндә гаиләсендә хатыны Бану (1910), кызлары Наилә (1929), Заһирә (1932), Фәрәһия (1936), Әлфия (1939) була.

Шәрифулланың бишенче улы Шәйхулла иде. Шәйхулла Шәрифулла улы балалары: Миңлеһидая (04.01.1897), Нигъмәтулла (03.01.1901; анасы Әбәдия Тыпыйның Сираҗетдин кызы), Миңлекафия (28.02.1904–1909), Хөрмәтулла (03.01.1907–1909, кызамыктан вафат), Миңлегазимә (21.05.1910), Миңлегыйззәтулла (21.07.1911). Шәйхулла хатыны Әбәдиянең (30 яшь; атасы Сираҗетдин Габдулла улы) гомере 1914 елда тамак (ютәл) авыруыннан киселә. Шәйхулла кызы Миңлеһидая (18 яшь) 1915 елның 10 декабрендә авылдашы Солтангали Идрис улы (26 яшь) белән никахлаша. Шәйхулла Шәрифуллин 1917 елда хатыны (40 яшь), улы һәм кызы белән яши, 2,08 дисәтинә җире, 2 сарыгы һәм 3 кәҗәсе була, кара эшче булып яллана.

*«Үткәннәрен бел Катайның» китабын тәкъдир итү. 2018 ел, 3 май*







ТЕАТР
ФГОС


ФГОС
ВЫПУСКНИКУ ШКОЛЫ
СЫҒАРЫЛЫШ УҠЫУСЫҺЫНА
ЕГЭ
2018






Катайымды



*Катай һәм Бакалы Сабантуйларында. 2018 елның июне*










D*ISCard
ANOTther
DESsign



*Сыйныфташлар очрашуы. 2018 ел, 23 июнь*





Шәрифулланың җиденче улы Гарифулла да нәсел калдыра. Гарифулла Шәрифулла улы (25 яшь) 1900 елның ноябрендә авылдашы Бибихәдичә Шәрәфетдин кызы (19 яшь; атасы Шәрәфетдин Шатбәһар улы) белән никахлаша, беренче мәхәлләдә балалары Миңлекәшифә (13.05.1903), Мөхәммәтсалих (03.03.1906), Мирсәгыйть (13.07.1909–1912), Мөхәммәтзаһит (02.02.1912), Мөхәммәтфазыйл (22.01.1915–1916), Мөхәммәтнасыйх (10.09.1924) туа. Салих Шәрифуллин (1906–1995) белән Заһит Шәрифуллин (1912–1997) – Ватан сугышы инвалидлары. Насыйх Шәрифуллин (Гарифуллин) сугышка чаклы Иске Корычта сигезенче классны тәмамлый, сугышта пулемет взводы командиры (лейтенант) була, ике орден белән бүләкләнә, исән-имин кайта.

Ибраһимның Морат тармагын карауны төгәлләп, Морадымга күчәбез. Аның аеруча зур нәсел калдырган улы Сайранга чаклы шәҗәрә схемасы болай: Госман–Ибраһим (1724) – Морадым (1760) – Сайран (1785).

Игътибар итсәгез, шәҗәрә схемасындагы исемнәр барысы да гарәптән алынган. Морадым – теләгәнем булды дигән мәгънәне аңлата, аның нигезен гарәпнең морат (теләк, максат, теләгән әйбер) сүзе тәшкил итә. Сайран – табигать кочагында ял итеп, күңел ачып йөрү дигән мәгънәне аңлата, гарәпнең сайр (ял итү, күңел ачу) сүзеннән алынган. Шәҗәрә башында торучы Госманның без белмәгән ата-анасы унҗиденче гасырда яшәгәнен искә алсак, шул чорда ук дин йогынтысы аркасында гарәп-фарсы исемнәре безнең милли төрки-татар исемнәргә көндәш була, ә унсигезенче гасырда аларны кысрыклый башлаган дип әйтә алабыз. Безнең кебек милли төрки-татар исемнәребезне сагыныпмы, Сайран беренче улына Таймас дип исем куша; гомер юлыннан таймас, үлмәс (бала), ата-ана сүзеннән тайпылмас бала, дигән күңелгә якын ике тирән мәгънә хас бу исемгә. Әмма калган улларына исемнәрне муллалар тәкъдиме беләнме әллә үзе сайлапмы, гарәптән кергәнен кушкан. Сайран гаилә корган унтугызынчы гасыр башында төрки-татар исемнәрен белгәннәр, ә без үзебез аларны никадәр дәрәҗәдә беләбез, балага исем сайлаганда ник өстенлек бирмибез? Үз асылыбызга кайтыйк дисәк, дин дә булсын, милли төрки-татар исемнәребез дә өстенлекле булсын. Нәкъ Төркиядә яшәүче диндәш кавемнәрнеке кебек.

Сайран Морадым улы балалары: Таймас (1814), Таҗетдин (1818–06.05.1883), Фәхретдин (1821), Сиражетдин (1827), Шәрәфетдин (1829–25.01.1906), Җамалетдин (1833), Камалетдин (1843). 1859 елгы документта Таҗетдин, Шәрәфетдин, Камалетдиннәр Сайранов фамилиясе белән теркәлгән, Сайранның башка уллары (Фәхретдин белән Сиражетдин) бу вакытта исән булмый.

Таймас Сайранов яклап нәселне Нәҗметдин (1846–26.05.1895) дәвам итә. Нәҗметдин Таймас улы балалары: Фәтхетдин (29.06.1878), Фәрважетдин (16.07.1884–1889), Миңлехәйдәретдин (10.10.1888–1889), Сәрвәретдин (27.06.1894; анасы Җиһанбану Тимергази кызы). Нәҗметдин кызы Бибисара (18 яшь) 1897 елның 4 декабрендә авылдашы Мөхәммәтназиф Мөхәммәтшә-

фикъ улы (30 яшь, икенче никах; атасы Мөхәммәтшәфикъ Мөхәммәтҗан улы) белән гаилә кора. Икенче кызы Бибисара (20 яшь; икенче никах) 1898 елның 18 декабрендә Корычның Садретдин Фәхретдин улы (25 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Шәрәфетдин Сайран улы белән Кашшафетдин Шәрәфетдин улы була.

Сайранның икенче улы Таҗетдинга күчәбез. Таҗетдин Сайранов уллары: Җәләлетдин (1838–06.11.1880), Мөхәммәтдин (1843), Гыймадетдин (1845–25.02.1881), Гыйлаҗетдин (1847), Минһаҗетдин (1861–23.04.1913). Җәләлетдин Таҗетдин улыннан Гыйлаҗетдин (01.07.1881–1882) билгеле.



**Таҗетдин Сайранов нәсел тамгасын салган документ фрагменты. 1860 ел**

Гыймадетдин Таҗетдин улы нәселен Сираҗетдин (1872) белән Афзалетдин (1873) дәвам итә, бер кызы (Миңлехәтирә, 15.01.1880) була.

Сираҗетдин Гыймадетдин улы балалары: Фәсхетдин (18.05.1899; анасы Миңлекамал Тыпыйның Гайфулла кызы), Җәмгыйтдин (03.08.1902), Әгъләметдин (19.01.1906), Хәйдәретдин (29.10.1908; анасы Миңлекамал Гайфулла кызы), Галләметдин (23.11.1911), Миңлехәтимә (05.07.1914–1916), Фәхеркамал (16.01.1917). Фәсхетдин (рәсми чыганакларда 1898 елда туган дип күрсәтелә) сугышка киткәндә хатыны Тәзкирә (1903), кызы Сираҗия (1931), уллары Мәрхәм (1934) белән Рим (1940) кала. Җәмгыйтдин 1940 елның 16 апрелендә метрикә таныклыгы ала, башка мәгълүмат юк. Әгъләметдин Сираҗетдин улы Сайрановның (1906; хатыны Рабига, 1907) сугыш алдыннан балалары Мәгъдәнетдин (1931), Рәис (1933), Хавия (1937), Әнис (1940) була. Хәйдәретдин сугышка киткәндә өендә хатыны Хәнифә Әхмәтхан кызы (1912), улы Кави (1931), кызлары Гәдәбия (1934), Фәнәдия (1937), Саяда (1940) кала. Сугыштан соң туган балалары: Рәвис (1949), Фәнәвис (1952), Фирдәвис (1954), Фәйрүзә (1957), Фәнис (1960).

Афзалетдин Гыймадетдин улы Сайранов (22 яшь) 1895 елның 23 ноябрендә Яңа Катайның Дәүләтгәрәй Миңлегәрәй улының кызы Бибиҗамал (19 яшь) белән никахлаша. Кияүнең вәкиле – агасы Минһаҗетдин Таҗетдин улы, ризалык шаһитлары Камалетдин Сайран улы белән Гатиятулла Шәрәфулла улы була. Афзалетдин балалары (беренче мәхәлләдә): Сәгъдетдин (Сәгадетдин, 21.01.1897; анасы Бибиҗамал Яңа Катайның Дәүләтгәрәй кызы), Бибихәкимә (16.07.1899; аның кызы Әнүзә, 1932), Сәлахетдин (03.12.1901), Бибизакирә (27.01.1906), Миңлесәрмәдия (29.07.1908), Бибисәфирә (07.08.1909), Сабира (15.02.1912), Миңлесабирҗан (09.02.1915–1916, чәчәк авыруыннан), Фәрвизә

(28.02.1917; анасы Бибикамал Дәүләтгәрәй кызы), Хәтимә (12.08.1925; анасы Камилә).

Сираҗетдин белән Афзалетдин хуҗалыклары 1917 елда Иске Катайда иң хәллеләр исәбенә керә. Беренчесе – 16,25, икенчесе 18,01 дисәтинә җир эшкәртә. Икесенең дә җилгәргече була, 2–3 ат тоталар, хезмәтче яллыйлар.



**Сәгадетдин белән Зөләйха (фотомонтаж)**

Сәгадетдин Афзалетдин улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, аннан кайткач өйләнә, тимерче булып эшли. Сәгадетдин балалары: Имаметдин (1923–27.04.1924; анасы Зөләйха Габдерәкыйп кызы), Әхкәметдин (02.04.1924–30.04.1924; анасы Зөләйха Габдерәшит кызы), Әхкәм (19.07.1927–27.06.2000), Акмалетдин (1929–18.02.1967), Мөзәянә. Имаметдин белән Әхкәметдиннең гомерләре чәчәк дип аталган йогышлы авырудан бер-бер артлы өзелә, аналары Зөләйханың атасын мулла шулай ике төрле хаталы язган, кайсы дөрестер, белмибез. Сәгадетдин Афзалетдинов 1944 елның язында Ватан сугышында һәлак була.



**Бертуган Әхкәм белән Акмалетдин Сайрановлар**

Әхкәм Сәгадетдин улы Сайранов белән Гөлрух Шаһимәрдан кызы (19.11.1929–10.09.2009) балалары: Зинира (29.07.1952), Альберт (19.03.1955), Рафит (19.08.1957), Рәзиф (02.01.1961), Рәшит (02.06.1967). Әхкәм абый да, атасы кебек, тимерче булып эшләде.

Акмалетдин Сәгадетдин улы Сайранов авылдашы Шәехзаман Кәримов кызы Нәҗибә (1925–07.02.2007) белән гаилә кора, балалары Рәмил (1953–07.04.2017), Фәнирә (17.06.1956), Рәсим (10.09.1962–03.01.2018) туа. Нәҗибәләр шул урамда икәү булганлыктан, монысын Төмән Нәҗибәсе дип әйтәләр иде.

Сәлахетдин Афзалетдин улы 1942 елда сугышта хәбәрсез югала, хатыны Хәмдия (1905), балалары Хәләфетдин (1928), Мәвазиф (1931), Рәиф (1934), Фәнүзә (1936), Насих (1939) Афзаловлар кала. Хәмдия Иске Балыклыдан (халык телендә – «Төмән Балыклысы»)

булганлыктан, аның Катайда яшәүче улын «Түмән Мәвазиф» дип әйтәләр иде (Иске Катайда тагын бер Мәвазиф (1932; атасы Суфиәхмәт Нәбиев) булгангадыр инде).

Таҗетдин Сайрановның төпчек улы Минһаҗетдин да гаилә кора. Минһаҗетдин Таҗетдин улы (22 яшь) 1881 елның 10 июлендә Камышлының Миңлебану Фәхретдин улының кызы (30 яшь; икенче никах) белән никахлаша, балалары Хәйдәретдин (15.10.1882), Хәйдәргали (05.11.1884), игезәкләр Миңлелатыйфа (29.09.1887–28.11.1912) белән Миңлехәтимә (29.09.1887), Хаҗгали (25.11.1890), Миңлегали (04.01.1893–1893) туа. Минһаҗетдин кызы Хәтимә (18 яшь) 1906 елның декабрендә Корычның Муса Габдерәфикъ улы (26 яшь) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Хәйдәргали Минһаҗетдин улы белән Сираҗетдин Гыймадетдин улы була. Икенче кызы Миңлелатыйфа 1908 елның 21 ноябрендә Яңа Катайның Дәүләтбай Дәүләтгәрәй улына (26 яшь) кияүгә чыга. Кызның ризалык шаһитлары – Сираҗетдин белән Афзалетдин Гыймадетдин уллары, егетнеке Бәхетгәрәй Миңлегәрәй улы белән Сәлимгәрәй Шаһингәрәй улы була.

Хәйдәргали Сайрановны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында анасы һәм хезмәтчесе кала. Хәйдәргалинең 1917 елда 17,10 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була, алга таба язмышы билгесез.

Сайранның өченче улы Фәхретдин (1821) иде. Фәхретдиннән Гаязетдин (метрикәләрдә Гаязетдин дип язылa; 1847–05.07.1910, икенче мәхәллә) һәм Мифтахетдин (1849) туган.

Гаязетдин Фәхретдин улы балалары: Гыйкрәмә (21.03.1875–27.08.1925; анасы Бибитаҗия), Бибимөнирә (1883), Бибизәкия (1884), Хаҗигали (09.11.1885), Кафия (28.07.1889; анасы Таҗия), Бибикәшифә (05.04.1893; анасы Таҗия), Кәшфия (1895). Гаязетдин кызы Бибимөнирә (20 яшь) 1903 елның 10 декабрендә Иске Балыклы ясаклы татары Мөхәммәтзариф Мөхәммәтвәли улы (23 яшь; атасы Мөхәммәтвәли Габдерәхим улы) белән кавыша. Кыз тарафыннан вәли вәкил – атасы Гаязетдин Фәхретдин улы, ризалык шаһитлары Камалетдин Сайран улы белән Гыйкрәмә Гаязетдин улы була. Балыклыдан кайтып, Бибимөнирә 1906 елда авылдашы Исхак Сәхипбаян улы белән гаилә кора, балалар таба. Гаязетдиннең икенче кызы Бибизәкия 1905 елда авылдашы Нуретдин Борһанетдин улы белән кавыша. Өченче кызы Бибикафия 1910 елда авылдашы Мөхәммәтсабир Мөхәммәтнасыйп улы белән никахлаша, кызның абыйсы Гыйкрәмә Гаязетдин улы ризалык шаһиты була. Төпчек кызы Кәшфия (18 яшь; вәли вәкиле – абыйсы Гыйкрәмә Гаязетдин улы) 1913 елның 8 мартында Каранның Әхмәтзәки Сәйфелмөлек улы (24 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Хәерзаман Вәлиәхмәт улы белән Әхмәтзариф Фазлыйәхмәт улы була.

Гыйкрәмә Гаязетдин улы балалары (икенче мәхәллә): Кәнзелголум (20.11.1904; анасы Галимә Ахунҗан кызы), Бибисәвия (18.10.1906–1974), Галикәрам (20.10.1909; анасы Галимә), Шәйхерам (12.08.1912, анасы Галимә),

Бәһия (1915–1916, кызамыктан вафат), Бәһия (1918–25.05.1985), Дөһәдия (1921–23.03.2006),Бибикәшифә (14.06.1925–1925; анасы Галимә). Гыйкрәмә Гаязетдинов 1917 елда хатыны (38 яшь), ике улы, кызы һәм анасы (65) белән яши, 18,34 дисәтинә җире, 3 аты, 3 сыеры һәм башка маллары була. Галикәрам Гаязов авылдашы Хәмдия Муллагали кызы (1910) белән гаилә кора, балалары Рәзинә (15.11.1934–06.03.1973), Рәмзия (13.07.1938–23.09.2018), Миңлефәнил (1941; яшьли мәрхүм) туа. Галикәрам кызы Рәзинә авылдашы-ерак нәселдәше Хаҗгали Исламгали улы Галиев (1930) белән никахлаша. Шәйхерам Гаязов (Гыйкрәмов) Ватан сугышына киткәндә гаиләсендә хатыны Гайнелҗиһан (1910), улы Вәис (1939), кызы Вәсилә (1941), туганы Сәвия (1906) кала. Бертуган Галикәрам белән Шәйхерам Гаязовлар – Ватан сугышы корбаннары (исемнәре Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Сайранның дүртенче улы Сиражетдин (1827) бары 1834 елгы документта гына телгә алына, димәк, нәселнең бу тармагын дәвам итүчеләр юк. Сайранның бишенче улы Шәрәфетдингә күчик. Шәрәфетдин балалары: Шәмсенур (1870), Кашшафетдин (1879), Солтангали (1888). Шәрәфетдин кызы Шәмсенур (18 яшь) 1888 елның 31 октябрендә Яңа Катайның Мөхәммәдиша Фәрухша улы (22 яшь) белән никахлаша.

Кашшафетдин Шәрәфетдин улы (25 яшь; икенче никах) 1904 елның 28 октябрендә Яңа Катайның Насретдин Күчемов кызы Бибифатыйма (икенче никах) белән кавыша, балалары Кәшфеләсрар (26.06.1907), Кәнзеләсрар (27.04.1911), Миңлекамил (28.02.1914), Мөхәммәтшамил (27.05.1917) туа. Аның энесе Солтангали Шәрәфетдин улы (26 яшь) 1914 елның 29 гыйнварында авылдашы Җәләлетдин Гыймадетдин улының кызы Мәүсуфа (25 яшь; икенче никах) белән никахлаша.

Сайранның алтынчы улы Җамалетдиннән (1833) нәселне Гыймадетдин (1874) дәвам итә. Гыймадетдин Җамалетдин улы балалары (икенче мәхәллә): Рузәтелҗинан (27.11.1908), Саяфетдин (10.08.1912; анасы Шәмсеҗиһан Гыйззәтулла кызы). Гыймадетдин Җамалетдинов 1917 елда хатыны (33 яшь), ике улы һәм кызы белән яши, 4,25 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм кәҗәсе була.

Сайранның җиденче улы Камалетдиннән дә (1843) нәсел дәвам итә. Камалетдин Сайран улы балалары (беренче мәхәллә): Мөхәммәтдин (1869), Нәҗметдин (14.05.1901; анасы Маһинур Иштирәкнең Ибраһим кызы), Фәтхетдин (23.02.1905), игезәкләр Һидиятулла (09.07.1908) белән Зиннәтулла (09.07.1908–1909; кызамыктан вафат). 1909 елның 29 маенда Камалетдин (67 яшь) өченче тапкыр өйләнә, хатын булып Камайның Фәрхебану Хәнәфи кызы (63 яшь; өченче никах) килә. 1911 елның 21 октябрендә «араларында өлфәт вә мәхәббәт булмау» сәбәпле әлеге никах таркала, калган гомерен хатынсыз яши. Камалетдин Сайрановның олы улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда ул ике улы белән яши, 4,16 дисәтинә җире була. Нәҗметдин Камалетдинов (1901) 1944 елның 15 гыйнварында Калинин өлкәсенең Слободка авылы янында һәлак була. Фәтхетдин Камалетдинов Ватан сугышына китә, хатыны

Рәйфә (1904), балалары Нәзифә (1928), Нәйрә (1930), Люция (1941) кала (1942 елда читкә чыгып китәләр).

Мөхәммәтдин Камалетдин улы Сайранов (25 яшь) 1894 елның 30 ноябрендә Яңа Катайның Мөхәммәтсадыйк Габделшәфикъ (Мөхәммәтшәфикъ) улы Күчемов кызы Фәхерниса (17 яшь) белән кавыша, балалары Гыйлаҗетдин (10.01.1897–19.02.1910), Гыймадетдин (07.07.1900), Җамалетдин (02.08.1905), Әгъзаметдин (13.09.1908–1909, кызамыктан вафат), Гыйлаҗетдин (23.03.1911–1914, кызамыктан) дөньяга килә.

Гыймадетдин Мөхәммәтдинов (1900) хәрби хезмәткә чакырылганда гаиләсендә хатыны Хөсниҗамал (1895), кызлары Миңленаҗия (04.05.1925), Сәхия (1929), Рәшидә (1931), Фәния (1934) була. Җамалетдин Мөхәммәтдинов 1942 елда сугышта хәбәрсез югала, хатыны Гайникамал (1908), кызлары Тәрҗимә (1931), Вәзимә (1935), Вәсимә (1939) кала.

Бу китапны язганда, авылдашларымнан үз нәселләре турында язып җибәрүне сораган идем. Рәмзилә Госманова (Афзалова) түбәндәгеләрне хәбәр итте: «Сәлахнең олы улы Хәләфетдин Үзбәкстанның Алмалык шәһәрендә гомер итә, нәселен уллары Хәниф белән Рәмил дәвам итә. Икенче бала булып Мәвазиф туа, ул Рауза Нургалиева белән гаилә кора, дүрт балалары туа. Кызлары Рәмзилә (1959) мәктәпне тәмамлагач, Уфада китапханәче һөнәренә укып, мәктәптә китапханә мөдире булып эшли, хәзерге көндә лаеклы ялда, балалары Лилия белән Юлия. Мәвазифнең уллары Раил (1961) белән Фәндил (1963) гаилә корып, ерак Себер якларында яшиләр. Раил лаеклы ялда булса да, бүгенге көндә эшләп йөри, балалары Артем, Рина, Равил. Фәндилнең балалары: Регина белән Альбина. Кече улы Азат (1972) әти-әни нигезен саклап, төп йортта гаиләсе белән яши, балалары Айгөл, Алмаз, Алсу. Бүгенге көндә безнең әнкәебез исән-сау. Аңа 89 яшь, олы яшьтә булуына карамастан, кече оныгын карап, ярдәм итеп яши.

Картый белән картәтинең өченче балалары Рәиф Корыч авылында яши. Алар Сайранова Инсия белән тормыш корып, биш бала үстерәләр. Кызлары Фәнүзәнең өч улы туа: Айрат, Илдар, Зирәк. Кече уллары Насих бүгенге көндә Катайда гаиләсе белән яши, балалары Ирек белән Илүсә».

Менә шундый кечкенә бер хикәя нәселнең бер тармагын бүгенге көн белән ялгап бирә. Нәселнең Госман (Сайран) тармагына караган шундый хикәяләрне бергә җыйнасаң, үзе бер китап булыр иде түгелме?

Ибраһимның төпчек улы Мәхмүт Ибраевның ир балалары: Гайнулла (1793), Миңлекәй (1800), Нигъмәтулла (1804), Һибәтулла (1807).

Миңлекәй Мәхмүт улы ир балалары: Әбүбәкер (1826–29.11.1874), Зәйнулла (1830), Сәйфулла (1833). Әбүбәкер балалары: Хәмидулла (1854), Төхфәтулла (1863–1890), Миңлебану (1870–1874). Зәйнулла кызы Фәрхебану Иске Катайның Нургали Мөхәммәтсафа улы белән никахлаша.

Сәйфулла Миңлекәй улы балалары: Шәмсенәһар (1860), Сәмигулла, Вәлиулла (1869). Сәйфулла кызы Шәмсенәһар (18 яшь) 1878 елның 25 июнендә


5.06.2018 ел АВЫЛ ТАҢНАРЫ № 45 (10558) 3

Үз якташларыңны бел!

## Язучы Таһир Кәримов туган авылы Катай турында китап бастырды

**Уку елы ахырында Катай укучылары һәм педагоглары өчен чираттагы истәлекле вакыйгада - Таһир Тимергазим улы Кәримовның туган авылы Катайның барлыкка килү һәм үсеш тарихы турында китабын тәкъдир итүдә (презентацияләүдә) катнаштылар.**

Т.Т.Кәримов — язучы-тарихчы, тарих фәннәре кандидаты, татар нәселләре һәм авыллары тарихы буенча белгеч. 1990нчы елларда вакытлы матбугатта һәм журналларда ул "17нче - 19нчы гасыр башында Кама аръягы авыллары (барлыкка килү һәм үсеш тарихы)" исемле докторлык диссертациясе темасы буенча зур тикшеренү эше кысаларында Кама аръягы авыллары тарихы турында фәнни-популяр мәкаләләрнең тулы бер сериясен (100гә якын) бастырды. Автор "Татар энциклопедиясе"н төзүдә катнашты, "Татарстан" һәм "Аргамак" журналларында Татарстан авыллары тарихы буенча рубрика алып барды. Соңгы елларда төбәкләр һәм нәселләр тарихы (генеалогия) буенча китаплар язу һәм бастыру белән актив шөгыльләнә. Ул 15тән артык китап авторы, алар арасында күптән түгел нәшер ителгән "Үткәннәрен бел Катайның" китабы да бар.

Шуны билгеләргә кирәк, дөнья күргә китап озак, төгәлрәк әйтсәк, 20 елга якын әзерләнгән. Авыл тарихы буенча беренче фәнни-популяр мәкаләсен автор районның "Авыл таңнары" газетасында 1993 елда бастырды, ике елдан соң "Бакалы районы тарихы буенча очерклар" язды һәм 1999 елда авыл тарихы буенча зур хезмәтен төгәлләде. Бу хезмәтләре басылмый кала (финанс авырлыклары килеп чыга), әмма автор алар өстендә эшләвен дәвам итә һәм шактый гына тулыландыра, авылның тарихы буенча бәяләп бетергесез мәгълүмат җыя, Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа һәм Ырынбур архивларында саклан-ган төрле документларны анализлый.

Таһир Кәримов белән истәлеккә фото.

Китапны язганда ул шулай ук авыл аксакаллары истәлекләрен кулланә, аларны ул чирек гасыр элек туплый башлый һәм әле дә булса дәвам итә. Язучы аларга бик сакчыл карый, чөнки аерым кешеләрнең истәлекләре китапка үзенчәлекле төс өсти. Исемнәре телгә алынган, истәлекләре кулланылган аксакалларның бу китапның чыгуын күрә алмыйча дөнья куюына автор бик көрсенә. Ата-бабалар турында хәтергә хөрмәт йөзеннән ул, авылның барлык төп нәселләре тарихын баян итеп, башка китап язган, аны бастыруны киләсе елга планлаштыра. Ул "Җиде бабаңны бел, катайлым" исемендә чыгачак.

Апрель ахырында дөнья күргән "Үткәннәрен бел Катайның" китабын тәкъдир итүне Таһир Тимергазим улы үзенең туган мәктәбендә үткәрде. Очрашуга мәктәп укучылары һәм коллективы, авторның беренче укытучысы Р.Г.Хәсәнова, педагогик хезмәт ветераннары Р.Ф.Шәйдуллина, Н.А.Ситдыйкова, язучының бертуган энесе Д.Т.Кәримов һәм башкалар килгән иде. Авылдашлары алдында чыгыш ясап, ул китап өстендә ничек эшләве турында җентекләп сөйләде, эчтәлеге белән таныштырды, аны язуда актив катнашкан кешеләрнең исемнәрен атады. Автор бу китапның күмәк хезмәт икәнлеген, аны төзүдә ярдәмләшкән барлык якташларына рәхмәтле булуын билгеләп үтте. Ул китапның, барыннан да элек, яшь буын өчен файдалы булачагын ассызыклады. Аның буенча туган авыл тарихын өйрәнерләр, горурланырлар һәм тарихыбызны лаеклы дәвам итәрләр дип ышаныч белдерде.

Китапны тәкъдир итү кызыклы үтте. Җанлы сөйләшү барышында автор укучыларның һәм укытучыларның сорауларына җавап бирде, чакырылучы кунакларга, мәктәпкә, китапханәгә яңа китабын бүләк итте.

Чара ахырында мәктәп директоры В.Г.Нурисламов Таһир Тимергазим улына очрашу, бүләк иткән китаплары өчен рәхмәт әйтте, авторга иҗади уңышлар һәм яңа китаплар теләде.

Район газетә корреспонденты һәм авылдашлары белән әңгәмә вакытында язучы бу китабында төп игътибарны авыл тарихының аз билгеле булган чорларына юнәлтүен ассызыклады. Шуңа күрә китапта анда үзенең яки ата-бабасының исемен күрергә теләгәннәрне канәгатьләндермәскә дә мөмкин. "Җиде бабаңны бел, катайлым" китабын бастыруга әзерләгәндә барлык тәкъдимнәрне мөмкин кадәр искә алачагына ышандырды.

Автор авылдашларына якын елларда үзенең өченче хезмәтен дә бастырып чыгарырга нияте барын белдерде һәм аларны иҗатта актив катнашырга, истәлекләре, иске фоторәсемнәре булса китапка тәкъдим итәргә чакырды. Һәм авылдашларына үзләренең искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен язма рәвештә ярдәмчесе Әлфия Зиннуровага тапшыруларын үтенде.

Авыллар тарихы буенча китаплардан тыш язучының "Бакалы районы тарихы буенча очерклар"ны бастыруны да планлаштыруын исәпкә алсак, данлы төбәгебез тарихында "ак таплар" тагын да азаюына ышанабыз. Авторга иҗади уңышлар һәм ниятләренең тормышка ашуын телибез!

Эльвира ШӘЙХРАЗИЕВА.

Яңа Катайның Мәрданша Мөхәммәтша улы (30 яшь) белән гаилә кора. Шул ук Шәмсенәһар (икенче никах) 1898 елның 29 июлендә Минзәлә өязе Чат авылының Мөхәммәтшәриф Мөхәммәдьяр улы (40 яшь; икенче никах) белән кавыша.

Вәлиулла Сәйфулла улы (25 яшь) 1894 елның 11 декабрендә авылдашы Гыйззәтулла Йөзәй улының кызы Маһикамал (18 яшь) белән кавыша. Кияүнең ризалык шаһитлары Шәрәфетдин Хәйрулла улы белән Камалетдин Сайран улы була. Вәлиулла белән Маһикамал балалары (беренче мәхәллә): Мөсәвәрә (06.09.1898–1899; эч рәнҗүеннән вафат), Миңлемөнирә (28.06.1900), Мөкәррәмә (29.10.1904), Сәрмәдия (20.10.1909–1914, кызамыктан). Вәлиулланың беренче никахы Фәрхиҗамал Әһәдулла кызы белән була, «араларында өлфәт вә мәхәббәт булмау сәбәпле» 1894 елның 11 сентябрендә аерылышалар.

Сәмигулла Сәйфулла улы балалары (беренче мәхәллә): Бибинур (09.03.1888; анасы Шәмсенур), Бибимаһинур (20.12.1892), Маһисорур (11.07.1900; анасы Шәмсенур Катайның Арслангали кызы), Гыйниятулла (03.11.1904).

Шулай итеп, нәселнең бу тармагы башлыча Ибраһимның ике улыннан (Морат белән Морадым) ишәя. Гасырдан гасырга нәсел зурайган, Иске Катайда дистәләрчә хуҗалык булып урнашкан. Моталлапның ерак нәселдәшләре Килкабызда да яши, 320 нче биттәге фоторәсемдә шул авылның ике тамгасы моны фәнни нигездә раслый.

# V бүлек.
# Табыш нәселе

Иске Катайда шактый киң таралган, зурлыгы буенча өченче урында торган нәселләрнең берсе. Нәсел башы булып Габдулла (Абдулла) карт тора. Ул унҗиденче гасырның икенче яртысында дөньяга килгән, аның Табыш исемле улыннан нәсел ишәйгәнгә, Табыш нәселе дигәннәр.

Нәселнең шулай аталуын Рим Гыйлембаян улы Нәбиевтән ишеттем. Катайга Табыш карт нигез салган, дип сөйли торган булган аның бабалары. Табыш – Катай картның табып алган улы, шуңа күрә исемен дә «Табыш» дип кушканнар, имеш. Табыш исеме архив документы белән расланса да, аның фамилиясе генә икенче төрле, бер дә Катаев түгел. Димәк, бу риваять архив чыганаклары белән дәлилләнми, бары чынбарлыктан ерак хикәя (әкият) кебек кенә кабул ителә.

Исемнең мәгънәсен дә гади табып алу белән бәйләү дөрес түгел, борынгы төрки-татар исемнәрнең берсе ул. Бу исем башка авылларда да очрый, мәсәлән, Бәләбәй өязе Ишмәт авылында 1791–1853 елларда Табыш Йөзекәев яшәгән, ул Бакалыда туып-үскән эшкуар Флюр Фәнәви улы Галләмовның атасы яклап ерак бабасы. Аның шәҗәрә схемасы болай: Солтангол–Йөзекәй (1763) – Табыш (1791–1853) – Габделлатыйф (1827) – Галләметдин (1868) – Ибраһим (1958) – Фәнәви (1934) – Флюр (1968) һәм туганнары.

Безнең фикеребезчә, исемен Табыш (русча «прибыль») дип кушып, ата-ана бала нәселгә мал-мөлкәт (байлык), муллык китерсен-тапсын дигән теләк теләгән. Мәгънәви яктан ул Байдәүләт кебек борынгы төрки-татар исемнәргә якын тора.

Табыш – берничек тә Катайга нигез салучыларның беренчесе була алмый, чөнки нәсел Иске Катайның икенче мәхәллә өлешендә үскән-тармакланган. Иң беренче күчеп килүчеләр Иске Катайның беренче мәхәллә территориясенә килеп утырганнар, китап та шул мәхәлләнең иң зур нәселеннән башлана.

Табыш Абдуллинның (1709–1790) нәселен аның күпсанлы уллары – Мөэмин (1740), Ягъфәр (1743–1814), Баязит (1749–1830), Фәйзулла (1750), Габдрахман (1771), Габбәс (1775–1801), Габдерәфикъ (1777–1820; 1798 елда казак хезмәтенә алалар), Габделмәҗит (1781–1786), Габделлатыйф (1783–1851) һәм Габделгаффар (1789) – дәвам итә.

Мөэмин Табышевның бер генә улы (Фәйзулла, 1770–1791) булып, ул да яшьли дөнья куйгач, бу яклап нәсел чылбыры өзелә. Сүз уңаеннан әйтик, Табыш

картның Габдрахман (уллары Галиәкбәр һәм Габделвәли яшьли вафат була) белән Габдерәфикъ (ир баласы булмый) исемле улларыннан да варислар калмый. Шуңа күрә китапның бу бүлегендә Табышның дүрт улыннан (Ягъфәр, Баязит, Фәйзулла һәм Габделлатыйф) киткән тармаклар карала.

Ягъфәр Табышев уллары: Габделгазиз (1790), Габделҗаббар (1799–1820), Габделсаттар (1800–1830), Габделкадыйр (1803–1833). Габделгазиз уллары: Сәхәбетдин (1813) белән Низаметдин (1822–26.12.1898).

Низаметдин Габделгазиз улы балалары: Фазлытдин (1864–1892), Фәрхиҗамал (1867), Гыйльметдин (1870), Хәтирә (1874), Хәкимә (01.07.1876; анасы Маһиҗамал), Кашшафетдин, Гыймадетдин, Гыйззетдин. Низаметдин кызы Фәрхиҗамал (18 яшь) 1886 елның 29 февралендә Чуракайның Сибгатулла Габдулла улы (22 яшь, икенче никах; атасы Габдулла Габделлатыйф улы) белән никахлаша. Икенче кызы Хәтирә (18 яшь) 1893 елның 7 гыйнварында Яңа Катайның Гыйльметдин Сәйфетдин улы (25 яшь; атасы Сәйфетдин Шиһабетдин улы) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары туганнары Гыймадетдин белән Кашшафетдин Низаметдин уллары була. Низаметдин 1894 елның 14 июлендә Карабашның Бибифаизә Шәмсетдин кызы (30 яшь; бишенче никах) белән кавыша, бу аның дүртенче (соңгы) никахы була. Әлеге никах, ни сәбәпледер, Яңа Катай мәчетендә теркәлә, ризалык шаһитлары да Күчем нәселе кешеләре.

Гыйльметдин Низаметдин улы балалары: Мөхәммәтдин (02.12.1899), Имаметдин (09.06.1904–1904), Җәмгыйтдин (20.04.1905; анасы Бибимөбәрәкә Дәүләтгәрәй кызы), Әхләметдин (18.02.1908), Акмалетдин (30.10.1910), Фазлытдин (10.08.1915). Гыйльметдин Низаметдинов (47 яшь) 1917 елда хатыны (37), биш улы һәм кызы белән яши, 2,81 дисәтинә җире була. Фазлытдин (Фазлый) Гыйльметдинов Ватан сугышына китә, язмышы билгесез. Сугыш алды еллары исемлегендә аның хатыны Зәйнәп (1919), кызы Флүзә (1939) теркәлгән. Гыйльметдиннең олы улы «сукыр Хәмәй», тагын берсе Акмал, болар урман очында яшәделәр, дип әйткән иде Хәмит абый Маликов. Гыйльметдин улларының берәрсе булса да Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән, язмышларын да тәфсилләп сорамаганмын.

Кашшафетдин Низаметдин улы балалары: Габделмәннаф (06.05.1899–1900; анасы Шәрифә Хөрмәтулла кызы), Рабига (02.06.1903), Бибисәфирә (24.03.1906), Миңлеразия (28.07.1909). Гыйззетдин Низаметдин улыннан бары Бибишәмсия (13.08.1899; анасы Зарифә Шәймөхәммәт кызы) билгеле.

Шулай итеп, Ягъфәр Табышевтан нәсел бүгенге көнгә чаклы бара. Әмма нәсел ишәюгә зур өлешне Баязит Табышев уллары Нигъмәтулла (1783) белән Төхфәтулла (1793) кертә.

Нигъмәтулла Баязит улы мулла вазифасын башкара, аның ир балалары Мохтарулла (1815), Шәйхулла (1817; 1835 елдан рекрутта, шуннан кайтмый), Сафиулла (1818), Галиулла (1820), Мөхәммәтнәби (1822–13.04.1886; мулла) була.

Мохтарулла Нигъмәтулла улы ир балалары: Фазлыәхмәт (1840–25.09.1909), Вәлиәхмәт (1849–15.07.1916), Фәйзрахман (1854), Хәлилрахман (1856–01.04.1883).

Фазлыәхмәт Мохтарулла улы балалары: Хәбибрахман (1870–1884), Габдрахман (1873), Әхмәткәрам (03.11.1875–1875; анасы Бибикамилә), Хөҗҗикәрам (17.03.1977), Фәрхизиядә (25.03.1878), Габдулла (26.06.1881), Әхмәтзариф (10.08.1884), Хәбибрахман (1886–1889), Нурзидә (14.06.1888–1890), Шәймөхәммәт. Фазлыәхмәт кызы Фәрхизиядә (чыганакта Зиядә; 21 яшь) 1900 елның гыйнварында Килкабызның Габдрахман Шәрәфетдин улы (25 яшь) белән никахлаша. Фазлыәхмәт уллары оста итекчеләр, заказга эшләүчеләр була.

Габдрахман Фазлыәхмәт улы 1897 елның 10 декабрендә Яңа Катайның Хөснетдин Мөхәммәткәрим улының кызы Гайнелҗиһан (19 яшь) белән кавыша, балалары Газизҗан (03.02.1901; анасы Гайнелҗиһан Хөснетдин кызы), Хәсәнҗиһан (1903–1912, кызамыктан вафат), Сәрвиҗиһан (25.09.1906), Гыйззеҗиһан (13.07.1909–1912, кызамыктан) туа. Габдрахман Фазлыәхмәтов 1917 елда хатыны (43 яшь), улы һәм ике кызы белән яши, 5,34 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була. Габдрахман Фазлыев гаиләсендә Ватан сугышы алдыннан хатыны Гайнелҗиһан (1870), килене (?) Хупҗамал (1912), оныклары (?) Әмирҗан (1932), Рауза (1934), Хәдичә (1937), Рәхимҗан (1940) була.

Габдулла Фазлыәхмәт улы балалары: Сөләйман (05.10.1909; анасы Саимә Мөхәммәтхарис кызы), Габделфаяз (01.01.1912; анасы Саимә Әхмәтхарис кызы), Габделәхәт (20.05.1914–1924), Тәрҗимә (1916), Хәмит (1919; 1940 елда армиягә китә). Габдулла Фазлыәхмәтовны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (30 яшь), ике улы һәм анасы (70) кала, 1917 елда 4,67 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры, 3 сарыгы була. Фаяз Габдуллин белән Хәмит Фазлыев сугышта һәлак булалар, Сөләйман Габдуллин исән-имин кайта (боларның берсе дә Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Габдулла гыйлемлелеге белән аерылып торган, сөйләгәнне язып барган, Урыс Абдулласы дигән кушаматы булган, дип әйткән иде Хәмит абый. Аның тормышын якыннан күреп үскән Сайка апа түбәндәгеләрне сөйләде. «Хуҗалыгы нык, өе иркен, алты почмаклы иде. Сайра апа белән башкаларда булмаган кавын, карбыз, кыяр, суган кебек яшелчәләр үстерә, ак мунчасы, эте бар иде. Кибет алдына җыелган халыкка үзе белгән-ишеткән ил яңалыкларын сөйли, тәртипле кеше иде. Без балалар аны «бал абзый» дип әйтә идек, юмарт булып, ипигә бал ягып ашата иде безне. Ипине дә башкалар кебек арыш оныннан һәм коры камырдан түгел, үзенә бодай оныннан аерым күкәй-май салып пешерттерә, үзен карата иде. Алтмышынчы елларга кергәч, урман кискәндә башына агач төшеп, мәрхүм булды».

Әхмәтзариф Фазлыәхмәт улының кызы Шәмсеҗиһан (19.07.1916; анасы Миңлеҗиһан Муллагали кызы) билгеле. Әхмәтзариф Фазлыәхмәтов 1917 елда хатыны (25 яшь) һәм кызы белән яши, 6,10 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була, итекләр тегә.

Шәймөхәммәт Фазлыәхмәт улы 1924 елның 5 февралендә Мәсрүрә мулла Галимулла кызы белән никахлаша. Егетнең вәли вәкиле – Габидулла Суфиәхмәт улы, кызныкы мулла Галимулла мулла Галиулла улы була. Әлеге никахтан Сәгадәтханым (17.11.1924) туа.

Мохтарулла Нигъмәтулла улы нәселен тагын Вәлиәхмәт дәвам итә. Вәлиәхмәт Мохтарулла улы балалары: Шәехзаман (Шәйхизаман; 28.08.1874; анасы Закирә), Хәерзаман (04.05.1877–03.07.1924), игезәкләр Миргалим (30.06.1886–1886) белән Мирсәлим (30.06.1886), Бибизифа (03.05.1889), Нурзидә (17.02.1892), Таһирә (13.05.1895; анасы Закирә Корычның Мозаффар кызы). Вәлиәхмәт кызы Бибизифа 1908 елның 5 ноябрендә Килкабызның Мөхәммәтсабит Кашшафетдин улы (24 яшь) белән кавыша. Икенче кызы Нурзидә (20 яшь) 1913 елның 14 гыйнварында Токтагулның Бикмөхәммәт Садрелислам улы (25 яшь; атасы Садрелислам Шәяхмәт улы) белән никахлаша. Кыз ягыннан ризалык шаһитлары абыйлары Шәехзаман белән Хәерзаман Вәлиәхмәт уллары була, түбәндә алар хакында әйтеп үтәбез.

Шәехзаман Вәлиәхмәт улы балалары: Саимә (1902), Әлтаф (22.09.1905), Әхнәф (25.01.1908), Сәкинә (10.03.1912), Әнвәр (06.09.1915; анасы Һидая Мөхәммәткәрим кызы), Тәзкирә (1918), Рәздәнә (25.07.1924). Шәехзаман Вәлиәхмәтовның 1917 елда 14,41 дисәтинә җире, 4 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була. Итекләр тегә, хезмәтче яллый. Шәехзаман сугыш алды еллары исемлегендә Заман Вәлиев дип теркәлгән, хатыны Идая (1879), кызлары Саимә (1902), Сәкинә (1912), Ризәнә (1926), оныгы Сәлимә (1942) була. Тәзкирә Яңа Катайның Әхмәтшәриф Күчемовка кияүгә чыга. Шәехзаманның улы Әхнәф Заманов сугышка чаклы колхозда хисапчы булып эшләгән, авыл советы кенәгәсендә хатыны Фатыйма (1918), кызы Финә (1936), улы Рәфкат (1939) теркәлгән. Сугыштан исән-имин кайта. Әлтаф Заманов читкә чыгып китә (Катайның мемориаль стеласында Заманов фамилияле кешеләр теркәлмәгән).

Хәерзаман Вәлиәхмәт улы балалары: Садрелимам (20.02.1907; анасы Мөкәррәмә Шәяхмәт кызы), Бибифәүзия (14.09.1909), Саҗидә (09.05.1912), Фәхрелимам (15.03.1914), Имамразый (20.02.1916).

Фәйзрахман (Фазлырахман дип тә язылa) Мохтарулла улы балалары: Бибимәрфуга (18.09.1878; анасы Маһибәдар), Бибимәсрүрә (01.10.1881–1888), Әхмәткәрам, Хәбибрахман (18.08.1885), Бибимөсәвәрә (29.01.1889), Миңлемөхәррәм (17.03.1891–1892, кызамыктан вафат), Мәргубә (08.05.1894–1894), Әхиярetдин (06.05.1895; анасы Гаделбану Камышлының Габделмән кызы), Әгъләметдин (20.01.1897–1900), Бибимөкәррәмә (15.05.1900–1904), Бибимөнәвәрә (13.07.1903), Бибисәвия (15.01.1908), Әүхади (05.09.1911). Фазлырахман Мохтаруллин (64 яшь) 1917 елда хатыны (45 яшь), улы (6) һәм ике кызы белән яши, 7,78 дисәтинә җире, аты, сыеры, бозавы, 3 сарыгы була. Әхмәткәрам Бибикәримә Сәхаутдин кызы белән никахлаша, кызы Бибихәкимә (20.09.1907) туа.

Нигъмәтулла Баязитовның өченче улы Сафиулла иде. Нигъмәтулла Сафиулла улы балалары: Мөхәммәтнасыйп (1852–10.10.1916), Мөхәммәтсадыйк (1854), Шәмсекамал (1896). Сафиулла кызы Шәмсекамал (18 яшь) 1915 елның 25 июлендә авылдашы Габделфаяз Габделгазиз улы (Юлдаш нәселеннән) белән никахлаша.

Мөхәммәтнасыйп Сафиулла улы балалары: Мөхәммәтхафиз (Әхмәтхафиз), Мөхәммәтсабир (1879), Бибимәрьям (1884), Мәрзия (26.02.1885), Мәрзия (1888), Гафифә (16.10.1889–1892; анасы Миңлевафа), Гөлчирә (07.05.1893–1894). Мөхәммәтнасыйп кызы Бибимәрьям (19 яшь) 1903 елның 15 гыйнварында Минзәлә өязе Әмәкәй олысы Чуракай авылы мулласы Ибраһим Шәйхәйдәр улы (22 яшь; атасы Шәйхәйдәр Хәбибулла улы) белән никахлаша. Икенче кызы Мәрзия (19 яшь) 1908 елда Корычның Муллагали Мөхәммәтзакир улына (25 яшь) кияүгә чыга. Никахның соңгысында кызның ризалык шаһитлары Әхмәтхафиз Мөхәммәтнасыйп улы белән Мөхәммәтсадыйк Сафиулла улы була.

Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтнасыйп улы балалары: Әгъләметдин (18.07.1901–1903; анасы Бибиһаҗәр мулла Гыйрфан кызы), Мостафа (16.03.1904), Сабирҗан (03.03.1910), Миңлесабит (15.07.1913), Закирҗан (1921). Тракторчы Сабит Насыйпов белән аның энесе Закирҗан сугышта һәлак булалар (исемнәре Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Мөхәммәтсабир Мөхәммәтнасыйп улы (30 яшь) 1910 елның 2 февралендә авылдашы Гаязетдин Фәхретдин улының кызы Бибикафия (19 яшь) белән никахлаша. Бу никахтан балалар булмый, Ватан сугышы алдыннан Сабир Насыйпов хатыны Нурдида (1900), улы Мөзәмил (1928), кызы Шәүганә (1930) белән яши.

Мөхәммәтсадыйк Сафиулла улы балалары: Бибизәйнәп (25.09.1883), Мөхәммәтхәниф (20.07.1884), Мөхәммәтгариф (29.09.1887), Габдерәкыйп (23.02.1890–1978; анасы Сара Гыйлаҗетдин кызы), Бибирәхимә (02.06.1892), Ибнфатих (21.02.1894; анасы Бибисара мулла Гыйлаҗетдин кызы), Бибирәшидә (1897), Бибисәхия (17.06.1899). Мәхәммәтсадыйк кызы Бибизәйнәп (20 яшь) 1904 елның 3 гыйнварында авылдашы Сафиян Шәймөхәммәт улына (25 яшь) кияүгә чыга, балалары була. Икенче кызы Бибирәшидә (19 яшь) 1916 елның 30 ноябрендә шулай ук авылдашы Исламгали Әхмәтгали улы (26 яшь; атасы Әхмәтгали Габдерәфикъ улы) белән никахлаша, аның да балалары туа.

Мөхәммәтхәниф Мөхәммәтсадыйк улы балалары: Хәбип (1922; Ватан сугышында хәбәрсез югала), Тәрҗимә (1924–1925), Ләбип (1931), Зәйтүнә (1932), Зөлфәт (1939) һәм башкалар. Болар – Садыйков фамилиясендә.

Габдерәкыйп Мөхәммәтсадыйк улы балалары: Лотфрахман (23.06.1917), Габидин (1919), Тәкмилә (1926–1986), Әминә (1928), Хәйбрахман (1926), Тәрҗимә (1933), Фанис (1940), Зинфира (01.01.1951). Болар да Садыйков фамилиясендә теркәлгәннәр. Габдерәкыйпнең туганы Мөхәммәтфатих Мөхәммәтсадыйк улыннан Оркыя (25.02.1925) дөньяга килә. Габидин Габдерәкыйп улы

Садыйков 1942 елда Ватан сугышында хәбәрсез югала (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Нигъмәтулла Баязитовның төпчек улы Мөхәммәтнәбидән нәселне Мөхәммәтгариф (1852), Мөхәммәтлатыйф (1854; имам), Әхмәтлатыйф (1863; мөәзин) һәм Мәүләви (1869–05.02.1915) дәвам итә. Мөхәммәтнәби кызы Бибимөкәррәмә (19 яшь) 1885 елның 29 мартында Балыклының Баһаутдин Мәүләветдин улы (20 яшь; атасы Мәүләветдин Сабит улы) белән никахлаша.

Мөхәммәтгариф Мөхәммәтнәби улы балалары: Оркыя (21.06.1889), Зәкия (26.07.1895; анасы Бибирәйфә Идрис кызы), Кафия (01.12.1897), Бибисалиха (20.09.1905). Мөхәммәтгариф кызы Оркыя (19 яшь) 1907 елның 5 декабрендә Корычның Әхмәтлатыйф Мөхәммәтлатыйф улы (22 яшь) белән кавыша.

Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтнәби улы балалары: Гыйлемхан (26.04.1882), Мәхәсим (13.12.1908; анасы Галимә), Мөгаллимә (03.12.1910; анасы Галимә Гайфулла кызы). Мәхәсим Нәбиев сугышта старшина, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә, инвалид булып кайта, бу чорда хатыны Хөснизиядә (1912), уллары Әгълә (1937), Габделәхәт (1941), анасы Галимә (1883) була. Беренче китапта мәрхүм булган елы ялгыш күрсәтелгән (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Әхмәтлатыйф Мөхәммәтнәби улы (24 яшь; вәли вәкиле – җизнәсе Мортаза Мөхетдин улы) 1887 елның 23 февралендә авылдашы Габдерәфикъ Габделтаһир улының кызы Фәрвизә (18 яшь; Юлдаш нәселеннән) белән никахлаша, балалары Бибихәтимә (22.09.1888–1904), Гыйлемхан (19.08.1890), Әкълимә (23.04.1893), Кәшфелмәган (16.01.1895–1895), Гыйлембаян (1896), Миргабитҗан (18.05.1899–12.06.1944), Сабирҗан (20.10.1901), Мирмөҗәһидан (08.06.1905–1912), Кифая (15.03.1908), Идая (1909) дөньяга килә. Әхмәтлатыйфның ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда 7,62 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һәм башка маллары, 2 баш умартасы була.

Гыйлемхан Әхмәтлатыйф улы балалары: Миргазиян (1921), Әбүзәр (21.05.1924–1925; анасы Кифая Сәмигулла кызы), Зөфәр (1926), Халидә (1929), Рәиф (1935), Әсхәт (1937). Миргазиян Нәбиев сугышта һәлак була, энесе Зөфәр исән-имин кайта. Гыйлемхан кызы Халидә Яңа Катайның Гыйльман Госманов белән кавыша.

Гыйлембаян Әхмәтлатыйф улы белән Гания Шәмсемөхәммәт кызы (Камайныкы) балалары: Рәзинә (1922–1924), Саяда (01.07.1925), Рим (1928), Фәйка (1931), Рәгънә (1934), Динәрә (1937). Гыйлембаян Нәбиев – сугыш корбаны, «Батырлык өчен» медале (15.05.1945) белән бүләкләнә. Рим һәм Мәвәзинә Нәбиевләр балалары: Ринат (1952), Риф (1953), Равилә (1956), Равил (1958), Ралина (1964). Ринат Нәбиев бабасы Гыйлембаян Көнчыгыш Германиядә (Беренче бөтендөнья сугышында әсирлектә (пләндә) булган урында) 1945 елның 25 апрелендә хәбәрсез югала дип хәбәр итте. Шуңа өстәп, 2019 елда оныклары белән бабасы дошман белән сугышкан, Беренче бөтендөнья сугышында тоткынлыкта яткан урыннарны күреп кайтуын әйтте.

Гыйлембаян Нәбиев – Беренче бөтендөнья сугышында катнашып, исән кайткан күпсанлы авылдашларыбызның берсе. Аның оныгы Ринат Нәбиев бабасының германда әсирлек тормышын тасвирлап Бакалы район гәзитендә «Якташларыбыз Беренче бөтендөнья сугышында» исемле зур күләмле язма бастырды. Ни сәбәпледер, автор Катай кешеләре турындагы мәгълүмат Таһир Кәримнең «Үткәннәрен бел Катайның» китабыннан алынганын әйтми, бу җитди җитешсезлек Ринат Нәбиевнең кайбер башка язмаларына да кагыла. Автор Беренче бөтендөнья сугышы дип язса да, шул мәкаләдә аерым (бишенче) абзац итеп «Бу сугышны «Бөек сугыш», «Икенче Ватан сугышы» дип атыйлар. Ә мин картәниемнең аны «герман сугышы» дип йөртүен яхшы хәтерлим», дип язуы сәер. Төрле фикерләргә карамастан, бу сугыш берничек тә «Бөек» яисә «Икенче Ватан сугышы» була алмый, дәреслекләрдә болай языла: Ватан сугышларының беренчесе – Наполеонга каршы 1812 елгы, икенчесе – совет халкының немец-фашист илбасарларына каршы 1941–1945 елгы сугышы. 1941–1945 елгы Ватан сугышының ил һәм дөнья тарихында гаять зур әһәмиятен билгеләп, Бөек Ватан сугышы дип тә әйтәбез һәм язабыз, бу сугышта кан койган, михнәт кичергән бабаларыбызны, тыл хезмәткәрләрен искә алып, һәр ел Җиңү бәйрәмен зурлап уздырабыз. Дошман бәреп кереп, илнең яшәешенә зур куркыныч туганда гына халыкны берләштергән Ватан сугышы башлана, ә 1914 елда патша Россиясе башка шартларда сугышка керде һәм зур һәлакәткә дучар булды. 1917 елгы инкыйлаб (революция), ачлык-ялангачлык, террор – шул сугыш нәтиҗәсе булды. Бу китабымда 1914–1917 елларда авылдашларымның Беренче бөтендөнья сугышында катнашу фактларын махсус билгеләп үттем, интернеттан шул сугышта катнашучылар сайтын (исемлеген) табып, яңа мәгълүмат өстәдем. Кулланыгыз мин бөртекләп диярлек, күпме вакыт сарыф итеп, зур түземлек һәм көч куеп җыйган мәгълүматны, тик авылдашым, язучы һәм галим Таһир Кәрим китабыннан алдым дип әйтергә онытмагыз! Үзегез һәм башкалар алдында һәрчак намуслы булыгыз, вөҗдан кушканча яшәгез, башкаларны да шатландырып иҗат итегез!

Югарыда әйтеп үткән ике сугыш каһарманы Гыйлембаянның энесе Миргабитҗан була. Авыл советы кенәгәсендә Миргабитҗан Нәбиев (1899) сугышка 1942 елның 17 маенда киткән, хатыны Нажия (1902; Сеңрәннеке), балалары Зөбәрҗәт (1927), Әфудә (1930), Фәнүзә (1933), Сабирҗан (1939), Фәһимә (1942) дип язылган. «Халык хәтере» сайтында Миргабитҗан Латыйповның 1944 елның 12 июнендә Эстония территориясендә барган сугышларда һәлак булуы турында әйтелә (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Мәүләви Мөхәммәтнәби улы балалары: Шәрифҗан (03.09.1888–25.04.1924; анасы Гыйльмиҗиһан), Галимҗан (25.03.1895; анасы Гыйльмениса Мостафаның Мөхәммәтгали кызы), Бибинәгыймә (01.03.1898), Шакирҗан (25.05.1901–1904), Бибиһаҗрә (20.09.1904), Бибисаимә (08.05.1908). Мәүләви Мөхәммәтнәбиевнең ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда ике кызы белән яши, 12,80 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була. Га-

лимҗан Мәүләвиев 1942 елда сугышка китә, гаиләсендә хатыны Кафия (1894), балалары Әнисә (1928), Җәвирә (1930), Тимерҗан (1940) кала. Аның язмышын ачыклап, исемен Катайның мемориаль стеласына өстәп язарга кирәк.

Югарыда без нәселне Нигъмәтулла Баязитов яклап карадык. Баязитның икенче улы Төхфәтулла да биш ул үстерә: Фәтхулла (1814), Хәйрулла (1820–05.06.1893), Мөхәммәтшакир (1829), Мөхәммәдиша (1831), Әхмәдиша (1833).

Фәтхулла Төхфәтулла улы балалары: Әхмәтсадыйк (1845–1850), Гыйззәтулла (1849). Гыйззәтулла Фәтхулла улы балалары: Фәхерҗиһан (25.02.1880), Корбангали (15.10.1884), Шәмсеҗиһан (25.03.1887; анасы Фәхерхәят). Шәмсеҗиһан (18 яшь) 1905 елның 30 ноябрендә Минзәлә өязе Әмәкәй олысы Бүләк авылының Гыймадетдин Җамалетдин улына (28 яшь) кияүгә чыга. Никахта кызның вәли вәкиле Гафиятулла Хәйрулла улы була.

Хәйрулла Төхфәтулла улы балалары: Гатиятулла (1848), Мифтахулла (1853), Гафиятулла (1855), Вәлиулла (1859), Бибикафия (1866), Сабира (1872). Хәйрулла кызы Бибикафия 1888 елның декабрендә Яңа Катайның Габделҗәмил Габделгани улы (22 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Сабира (18 яшь) 1890 елның 5 октябрендә Куянның Габделхак Габделгазиз улы (25 яшь; икенче никах) белән кавыша.



**1860 елгы документ фрагментында Хәйрулла Төхфәтуллин тамгасы**

1860 елгы Иске Катай авылы кешеләре тамгалары салынган документта Хәйрулла Төхфәтуллин да бирелә. Аның тамгасының төп элементы ике таяктан тора. Шул документтагы нәселдәшләре Шатбәһар Габделлатыйфов белән Мөхәммәтшакир Төхфәтуллин тамгасында шул ике таякның өстендә («П» хәрефе кебек) яисә астында сызык күрәбез.

Алга таба Табыш нәселе тамгасына махсус туктап тормасын өчен, шул документта бөтенләй аерылып торган Галиулла Нигъмәтуллин тамгасы турында да әйтеп үтик. Андый тамга башкача бер җирдә дә кабатланмый, шуңа бу нәселгә хас тамга түгел, дигән нәтиҗә ясадык. Катай авылы тамгаларын җентекләп өйрәнгән галим буларак әйтәм: ят (очраклы) тамгалар башка нәселләрдә дә очраштыргалый, шуңа күрә ниндидер зур мәгънә эзләп, аларны аерым игътибарга алырга кирәкми. Ят тамга еш кабатланса, бер нәсел кешесе икенче тамгага күчкәнме әллә, дип уйлар идек тә, әмма Катай һәм мин өйрәнгән башка авыллар мисалында мондый нәрсә күзәтелми кебек.

Гафиятулла Хәйрулла улы балалары: Әсәдулла (03.12.1882–1892, холера зәхмәтеннән вафат), Төхфәтулла (04.10.1885–1886), Бибизәкия (25.01.1888–1892; анасы Бибиданә), Хөрмәтулла (14.04.1894; анасы Сафура Корычның Гыймадетдин кызы), Сәрвәрия (20.02.1898), Мотыйгулла (15.01.1901; анасы Сафу-




**Сул якта (аста) Әхмәтгали Мөхәммәдиша улы, уңда Гафиятулла Хәйрулла улы тамгасы**

ра Гыймадетдин кызы), Мөҗәһит (23.12.1903–1906; анасы Сафура Фәрхетдин кызы), Сәмигулла (10.04.1913; анасы Хәйрелниса Габделгани кызы). Гафиятулла үзенең Корычтан алып кайткан хатынын 1913 елның 4 апрелендә «араларында мәхәббәт вә өлфәт юк сәбәпле» аерып җибәрә («беренче талаклары»), бу хакта Яңа Катайның өченче мәхәллә метрикәсендә әйтелә. Гафиятулла кызы Сәрвәрия (27 яшь; өченче никах) 1924 елның февралендә авылдашы Баязит Әбүбәкер улы (30 яшь; икенче никах) белән никахлаша.

Хөрмәтулла Гафиятулла улы балалары: Нигъмәтулла (20.04.1924–1924; анасы Сания Гомәр кызы), Мөҗәһит (09.05.1925). Авыл советы кенәгәсендә 1925 елдан соң туган балалары Мосаллия, Галимулла (1930), Рәйханә (1932), Нәгыймә (1939) теркәлгән. Мөҗәһит Гафиятуллин – сугыш ветераны, «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале (25.08.1945) белән бүләкләнгән (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән). Мотыйгулла Гафиятулла улы (икенче никах) 1924 елның 7 маенда Мәрхәбә Габдерәфикъ кызы (35 яшь; өченче никах) белән никахлаша, кызлары Әбәдия (23.05.1925) туа.



**1860 елгы документ фрагментында Мөхәммәтшакир Төхфәтуллин тамгасы**

Төхфәтулла Баязитовның өченче улы Мөхәммәтшакир да нәсел ишәюгә шактый өлеш кертә. Мөхәммәтшакир Төхфәтулла улы балалары: Мөхәммәтзакир (1853), Мөхәммәтзаһир (1856–01.09.1925; фамилиясе Табышров дип язылган), Мөхәммәтхафиз (1957), Бибигалимә (1868), Мөхәммәтхәйдәр (1869), Бибигалия (1870). Мөхәммәтшакир кызы Бибигалимә (18 яшь) 1881 елның гыйнварында Корычның Сәетгали Мөхәммәтша улы (28 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Бибигалия (18 яшь) 1888 елның декабрендә Туктаголның

Габделсалих Габделлатыйф улы (25 яшь) белән гаилә кора. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтзакир белән Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтшакир уллары була. Мөхәммәтзакир тамгасы алдарак телгә алынган Хәйрулла Төхфәтуллинныкы белән тәңгәл килә.

Мөхәммәтзакир Мөхәммәтшакир улы балалары: Мөхәммәткасыйм (1874), Бибизәйнәп (29.09.1878; анасы Хәтирә), Бибигайшә (05.11.1880), Мөхәммәтнәгыйм (15.01.1882–1886), Шәмсеруր (15.05.1885), Гыйззенур (07.03.1889), Фәрхинур (1891), Мирзаһит (16.07.1895–1899; анасы Хәтирә Чуракайның Хәбибулла кызы). Мөхәммәтзакир кызы Шәмсеруր (18 яшь) 1903 елның 11 декабрендә Минзәлә өязе Әмәкәй олысы Баек авылының Шәрәфетдин Җамалетдин улы (23 яшь) белән никахлаша. Кыз тарафыннан ризалык шаһитлары булып нәселдәшләре Мөхәммәткасыйм Мөхәммәтшакир улы белән Мөхәммәтхарис Мөхәммәдиша улы теркәлә. Мөхәммәтзакир икенче кызы Гыйззенурны 1907 елның 2 гыйнварында кардәше Миңлегәрәй Мифтахетдин улына (65 яшь) икенче хатынлыкка бирә. Кыз тарафыннан ризалык шаһитлары Әхмәтгали Мөхәммәдиша улы белән Мөхәммәткасыйм Мөхәммәтзакир улы була. Төпчек кызы Фәрхинур (19 яшь) 1910 елның 23 гыйнварында Тыпыйның Шәмсетдин Фәрхетдин улына (23 яшь; атасы Фәрхетдин Таҗетдин улы) кияүгә чыга. Мөхәммәтзакир Шакировның улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда ул хатыны (55 яшь), килене (35) һәм оныгы (15) белән яши, 14,62 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче яллый.

Мөхәммәткасыйм Мөхәммәтзакир улы балалары (икенче мәхәллә): Бибиәминә (25.10.1907), Миргазетдин (20.01.1911–1911), Бибигазизә (1916–1916, чәчәктән), Тимерхан (27.12.1917; анасы Фәтхия Гафиятулла кызы), Әмиркасыйм (1921–1924; анасы Сәрвәрия Гафиятула кызы).

Мөхәммәтзаһир Мөхәммәтшакир улы (21 яшь) 1878 елның 29 декабрендә авылдашы Гаделша Чурагол улының кызы Гарифә (22 яшь) белән никахлаша. Мөхәммәтзаһир балалары: Мөхәммәтшәкүр (1879), Мөхәммәтхәлим (15.11.1881–06.07.1898, яшен афәтеннән вафат), Бибисайра (1882), Бибисәрия (01.07.1884), Мөхәммәтнәгыйм (24.09.1888), Мөхәммәтгалим (29.08.1890), Мирсалих (03.01.1893), Сания (23.12.1894; анасы Гарифә Гаделша кызы), Бибисаимә (05.02.1897–1898, кызамык). Мөхәммәтзаһир кызы Бибисайраны (25 яшь; икенче никах) 1907 елның 20 ноябрендә Бакалы олысы Балыклы авылы ясаклы татары Сәйфулла Гайфулла улына (45 яшь) икенче хатынлыкка бирә. Икенче кызы Бибисания (21 яшь) 1916 елның 25 августында авылдашы имам Габделҗәмил Ибнҗәмил улына (45 яшь; өченче никах) икенче хатын булып бара.

Мөхәммәтшәкүр Мөхәммәтзаһир улы (23 яшь) 1905 елның 10 гыйнварында Яңа Катайның Фәттахетдин Саяфетдин улының кызы Маһикамәр (Майкамәр; 17 яшь) белән никахлаша, балалары Бибисаимә (13.08.1906), Шәйхенур (12.04.1909), Мәгъдәннур (21.12.1911), Шәехмәрдан (31.01.1915) туа. Ватан сугышы алды елларында Шәкүр Заһиров анасы Фәрвизә (1866), хатыны Һидая (1899), балалары Җәмигънур (26.06.1924; анасы Һидая Фәхрислам кы-



**1907 елгы никах язуында Мөхәммәтзаһир (өстә) һәм Мөхәммәтхәйдәр (аста) Мөхәммәтшакир уллары өч таяктан торган тамга салган**



**Венер Шәкүров (сулда) белән Фәвәрис Гаязов армиядән кайткач**

зы), Мөхәммәтхәбип (06.09.1925–1967), Мәвәзинә (1927), Мөслимә (1929), Фәридә (1931) белән яши. Җәмигънур белән Хәбип Шәкүровлар – Ватан сугышы ветераннары (фамилияләре Катайның мемориаль стеласында Шакиров дип язылган). Хәбип Шәкүров совхозда агроном, аннары зоотехник (1967 елның 20 апреленнән) булып эшли. Сугышта сержант, отделение командиры була, «Дан» ордены (3 нче дәрәҗә) (25.10.1944), «Бөек Ватан сугышы» ордены (2 нче дәрәҗә), ике «Батырлык өчен» (берсе 18.10.1944 елда бирелә), «Сугышчан хезмәтләре өчен», «Кенигсбергны алган өчен» медальләре белән бүләкләнә. Хәбип сугыштан кайткач авылдашы Ләйлә Фәтхелгаян кызы (1926) белән гаилә кора, балалары Венер (1948), Зоя (1951), Рифкать (1953), Рудамир (1955), Ришат (1957) туа (бүгенге көндә болардан бер Зоя гына исән). Рудамир Хәбип улы Шәкүров берара (1987 елның 26 июненнән) Катай авыл советы башкарма комитеты рәисе булып алды.

Мөхәммәтнәгыйм Мөхәммәтзаһир улы Яңа Катайның Әхтәмгали Габделмәннаф улының кызы Сәтига белән никахлаша, балалары Шәйхеләнаф (1924–1990), Хәйреләнам (1927), Дөһедия (1929-2018) туа. Мөхәммәтнәгыйм сугыш вакытында Чиләбедә эшли, шуннан кайтырга чыккан җиреннән юкка чыга. Шәйхеләнаф – Ватан сугышы ветераны, сержант, миномет командиры була, яралана. Сугыштан кайткач Куянның Гыйззәтулла Фәйзуллин кызы Мәшүдә (1928–2014) белән гаилә кора, балалары Зәнәһия (1949), Насиха (1951), Рәзилә

(1953), Гөлнәзирә (1956), Замир (1958), Рәфинә (1961) дөньяга килә. Мөхәммәтнәгыйм кызы Дөһөдия Кандалакбашның Гаян Мәрданов белән никахлаша. Хәйреләнам авылдашы Минзиян Кадермөхәммәт кызы белән гаилә кора, уллары Зинир туа. Аның белән аерылышкач, Хәйреләнам икенче хатыны белән Октябрьскийда яшәгән, ул мәрхүм булгач Кандалакбашка кайткан.

Мөхәммәтгалим Мөхәммәтзаһир улы 1916 елда Яңа Катайның Бибибәһия Мифтахетдин Гыйлаҗетдин улы Күчемов кызы (18 яшь) белән никахлаша. Аларның сугышка чаклы туган балалары: Мөхәммәтхәлим (1919–1926), Әзһәрия (20.10.1924; анасы Бәһия Мифтахетдин кызы), Җәүһәрия (1934), Тимерҗан (1934), Халисә (1939).

Монда бер искәрмә ясап үтик. 1925 елның дөньяга килүчеләр исемлегендә Хәйреләнам Мөхәммәтнәгыйм улы белән Әзһәрия Мөхәммәтгалим кызы бербер артлы бирелгәннәр, тик икесенең дә атасы Мөхәммәтнәгыйм күрсәтелгән, ә аналарының исемнәре аерыла. Аналарына карап мулланың хатасын төзәттек, компьютердан текст буенча эзләттергәч, Әзһәриянең Мөхәммәтгалим кызы булуын ачыкладык. Ата исемен язганда мулла ялгышкан мондый очраклар аз, ә менә ана исемнәрендә төгәлсезлекләр еш очрый.

Мирсалих Мөхәммәтзаһир улы авылдашы Фәхрислам Габделихсан улының кызы Галия (1901) белән никахлаша, балалары Гания (1921), Сайра (1923), Гөләндәм (1926), Тавис (1928), Әхмәтзәки (1930), Мәүва (1935), Тутыя (1940; Яңа Катайның Фатихҗан Гәрәев кияүгә чыга) дөньяга килә. Мирсалих Заһиров – Беренче бөтендөнья һәм Ватан сугышы ветераны, сугышларның беренчесендә Германиядә әсирлектә була. Тавис Иске Корычның Габделдаян Габдерәкыйповның кызы Фәйрүзә (1928-2012) белән гаилә кора, балалары Мәүлизә (1956), Рәвис (15.01.1959; хатыны Рита Вагыйз кызы, уллары Марат белән Артур), Дәния (1962) туа.

Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтшакир улы балалары: Сәмигулла (15.08.1894; анасы Мәхмүдә Корычның Арслангали кызы), Мәмдуха (30.01.1897–1899), Мөхәммәтвафа (04.07.1900), Бибифатиха (15.11.1904), Хәмидулла (27.12.1907), Мөхәммәтгата (13.04.1909).

Сәмигулла Хафизов балалары: Хәтмулла (02.09.1925), Хәдичә (1928; авылда яши), Гайшә (1930). Сәмигулла Хафизов 1942 елның 23 декабреннән 1943


**Орден-медальле сержант Мөхәммәтгата Хафизов (сул якта)**

елның октябренә кадәр «Байкал» колхозы рәисе була, аның шул чордагы ачы язмышы хакында «Үткәннәрен бел Катайның» китабында Әлфия апа Хәйдәрова истәлекләренә таянып сөйләгән идек.

Мөхәммәтвафа Хафизов балалары (11 баладан исән-имин үскәннәре): Нәсимә (1934), Рәис (1938), Мөдәррис (1946), Вәсимә (1949), Мөҗәһидә (1953), Мөҗәһит (1956). Мөхәммәтгата Хафизов балалары: Хәтмулла (1934), Фән (1938), Фәнирә (1939) һәм Рузалин. Вафа һәм Гата Хафизовлар – Ватан сугышы ветераннары. Гата абый сугышта кече сержант, артиллерист (наводчик) була, «Кызыл Йолдыз» ордены (21.07.1945), «Батырлык өчен», «Ленинград оборонасы өчен» медальләре белән бүләкләнә. Авылдашлары арасында агач эше остасы буларак аерылып торды.

Мөхәммәтхәйдәр Мөхәммәтшакир улы балалары: Суфиәхмәт (17.03.1899; анасы Газизә Шәяхмәт кызы), Нурдидә (29.06.1900; анасы Бибигазизә Шәймөхәммәт кызы), Хаҗиәкрәм (25.10.1904), Мирзаәхмәт (23.02.1907; анасы Бибигалимә Шәяхмәт кызы), Әмиргали (10.09.1910; анасы Галимә Шәяхмәт кызы), Зәйтүнә (1913–1916, чәчәктән вафат). Мөхәммәтхәйдәр Шакиров Ватан сугышы алды елларында хатыны Галимә (1882), балалары Мәдинә (1918), Нәҗип (1921), Сәүдә (1928), оныгы Әкрәметдин (1940; Мәдинәнең улы) белән яши. «Беренче хатыны мәрхүм булгач, Мөхәммәтхәйдәр Чуракайдан Галимәне алып кайта. Әмиргали Хәйдәров Ватан сугышында һәлак була, туганы Нәҗип исән-имин кайта», дип язып җибәрде Альбина Сәмигуллина (Ашурова). «Халык хәтере» сайтында Нәҗип Хәйдәров сугышта хәбәрсез югалган дип әйтелә (Әмиргали белән Нәҗип Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Мирзаәхмәт Хәйдәр улы Шакиров (Хәйдәров) – Ватан сугышы ветераны, «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале (15.11.1944) белән бүләкләнгән. Сугыш алдыннан гаиләсендә хатыны Җәннәт (1910), кызы Әлфия (12.04.1936) теркәлә.

Әлфия Мирзаәхмәт кызы Хәйдәрова аерым игътибарга лаек. Ул үзенең хезмәт биографиясен китапханәче булып башлый, 1973–1978 елларда авыл советы рәисе вазифасын башкарды. Кабат китапханәче эшенә кайтып, 1998 елда лаеклы ялга киткәнче, үз һөнәренә тугрылыклы калды. Менә дигән алмаш әзерләде – кызы Альбинаны үз һөнәренең нечкәлекләренә өйрәтте, китапханәчеләр хәзерләүче техникумда укытты. Озак еллар китапханәче булып эшләү дәверендә, ул Катайның үткән чорын яктырткан шактый кызыклы мәгълүмат туплаган, истәлекле фоторәсемнәр җыйган, аларны пөхтә итеп альбомга теркәп куйган. Аның «Катай авылы тарихы» дип аталган хезмәтендәге кайбер мәгълүматны «Үткәннәрен бел Катайның» китабын язганда файдаландым. Ул китапханәче булып эшләгән чорда, Катай авылы хуҗалыклары турында 1917 елгы архив мәгълүматын язып алып һәм китап итеп төпләп, китапханәгә тапшырган идем, авылдашларым аны кызыксынып һәм шатланып укыдылар, китабыңны укыдык дип, үземне дә сөендергәннәр иде.

Төхфәтулла Баязитовның дүртенче улы Мөхәммәдишадан да нәсел ишәя. Мөхәммәдиша Төхфәтулла улы балалары: Әхмәдиша (1853 елда туган), Шәмсе-

камал (1858), Мөхәммәтфатих, Мөхәммәтхафиз (1860), Әхмәтгали (1862–1940) һәм Мөхәммәтхарис (1868). Мөхәммәдиша кызы Шәмсекамал (18 яшь) 1876 елның 25 декабрендә авылдашы Мөхәммәтзариф Габделнәфикъ улы (Юлдаш нәселеннән) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле – нәселдәше Мөхәммәтшакир Төхфәтулла улы, ризалык шаһитлары Мөхәммәтзакир Мөхәммәтшакир улы белән Әхмәдиша Мөхәммәдиша улы була. Беренче китабымдагы 1917 ел исемлегендә Мөхәммәдиша уллары аталарының исеме белән Мөхәммәдишин (яисә Мөхәмәтшин) дип күрсәтелгәннәр.

Әхмәдиша Мөхәммәдиша улы балалары: Әхмәтзәки (15.04.1877–16.10.1916; анасы Хәлимә), Әхмәтшәех (16.01.1882), Бибимәликә (25.03.1885), Бибифатыйма (16.07.1890; анасы Хәкимә Әхмәдиша кызы), Мәдхирәфия (1892). Әхмәдиша кызы Бибимәликә (20 яшь) 1906 елның 12 гыйнварында Тыпыйның Хәсән Миңлегали улы (36 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Икенче кызы Мәдхирәфия (19 яшь) 1911 елның 13 октябрендә Бөре өязе Яңа Күктау авылының Әһлетдин Фәррахетдин улы (24 яшь; атасы Фәррахетдин мулла Хәйретдин улы) белән кавыша. Әхмәдиша Мөхәммәдишин 1917 елда хатыны (65 яшь), улы һәм кызы белән яши, 5,81 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры һәм сарыгы була.

Әхмәтзәки Әхмәдиша улы балалары: Кәнзелголум (16.02.1904; анасы Бибигатифа Мослахетдин кызы), Мөбәрәкҗан (19.01.1907; анасы Гатифә Мослахетдин кызы), Әмирҗан (26.03.1910).

Әхмәтшәех Әхмәдиша улы (26 яшь) 1907 елның 8 ноябрендә авылдашы Габделлатыйф Габделвафи улының кызы Миңлегалия (18 яшь) белән никахлаша. Кыз тарафыннан ризалык шаһитлары – Габдерәкыйп Габделлатыйф улы, Габделвахит Габделвафи улы, егетнеке Шәвәли Габдерәфикъ улы белән Нурлыгаян Габделнәфикъ улы була. Әхмәтшәех балалары: Бибивәҗһия (16.10.1911; анасы Галия Әхмәтлатыйф кызы), Мөҗәһит (03.06.1913; анасы Галия Мөхәммәтлатыйф кызы). Шәех Әхмәдишинны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (25 яшь) кала, 1917 елда 3,75 дисәтинә җире, сарыгы һәм 2 кәҗәсе була. Бик таза кеше иде, дип искә алды аны Хәмит абый.

Югарыда Мөхәммәдишаның Әхмәдиша исемле улыннан киткән тармак каралды. Мөхәммәтфатих Мөхәммәдиша улы балалары: Маһирә (13.01.1899; анасы Шәмсекамал Исмәгыйль кызы), Мөхәммәтнасыйх (19.10.1900; анасы Шәмсекамал Исмәгыйль кызы), Мирзаһит (08.05.1903), Мирсәгыйть (15.04.1908; анасы Гайникамал Исмәгыйль кызы), Рәхилә (07.10.1911; анасы Шәмсекамал Исмәгыйль кызы).

Мөхәммәтхафиз Мөхәммәдиша улы балалары: Әхмәтлатыйф (12.02.1894; анасы Бибигайшә Галиулла кызы), Кәшифә (03.01.1897), Мөхәммәтлатыйф (07.06.1900), Әхмәтназиф (01.01.1904–1904), Бибизәкия (10.07.1908), Бибихәтимә (26.11.1910; анасы Бибигашия Хәлилулла кызы), Мөхәммәтвагыйз (03.11.1913; анасы Бибигашия Хәлилулла кызы). Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтшин (57 яшь) 1917 елда хатыны (40), өч улы һәм кызы белән яши, 4,40 дисәтинә җире, аты була. Мөхәммәтхафиз кызы Кәшифә (19 яшь) 1916 елның 24 октяб-

рендә авылдашы Әхмәтлатыйф Мөхәммәтшәфикъ улы (30 яшь, икенче никах; атасы Мөхәммәтшәфикъ Мөхәммәтҗан улы) белән никахлаша, балалары (берсе Рәмдрәк Латыйпов) була. Кызның ризалык шаһитлары Әхмәтгали белән Әхмәтхарис Мөхәммәдиша уллары була.

Ватан сугышы алдыннан Латыйп Хафизов (1894; хәрби хезмәткә 16 декабрьдә чакырыла) хатыны, уллары Әхнәф (1924), Канәфи (1926), Ягъфәр (1930) теркәлә. Әхнәф Әхмәтлатыйф улы Хафизов (1924) сугыштан өлкән сержант, инвалид (2 группа) булып кайта, «Батырлык өчен» (26.09.1943), «Сугышчан хезмәтләре өчен» медальләре белән бүләкләнә.

Әхмәтгали Мөхәммәдиша улы (25 яшь) 1889 елның 30 ноябрендә авылдашы Мөхәммәтситдыйкъ Мөхәммәтҗан улының кызы Хәмдениса (18 яшь) белән никахлаша. Әхмәтгали балалары: Бибиәсма (26.01.1891–1898; бугаз рәнҗүеннән вафат), Дөрреләсма (10.07.1894; анасы Хәмдениса Мөхәммәтситдыйкъ кызы), Кәшфелмәган (12.08.1897), Кәшфелгаян (07.08.1903–1904), Кәшфелгаян (18.03.1907), Әсма (17.06.1910), Мәүҗүдә (1922–1924; анасы Хөснибану), Фәтхелбәян (халыкта телендә Фаткылбаян, Фаткыл; 1927). Әхмәтгали белән Хөснибану Мөхәммәтшиннар 1933 елда репрессияләнә. Әхмәтгалинең кече улы Фәтхелбәян Галиев – Ватан сугышы ветераны, «Японияне җиңгән өчен» медале белән бүләкләнгән, балалары: Тимерҗан (1956), Галимҗан (1958), Вәзилә (1960), Хәмитҗан (1962), Фатихҗан.

Мөхәммәтхарис Мөхәммәдиша улы (25 яшь) 1894 елның 17 гыйнварында авылдашы Габделмалик Габделхәким улының кызы Фәрхебану (18 яшь; Юлдаш нәселеннән) белән никахлаша, балалары Кафия (21.12.1894), Мөхәммәткәшиф (12.06.1897), Бибифәүзия (08.01.1901), Мөхәммәтхәтим (25.08.1903–30.07.1986), Кифая (07.12.1905), Мөхәммәтхәлим (26.07.1908–1912) дөньяга килә. Мөхәммәтхарис кызы Кафия (19 яшь) 1914 елның 6 февралендә Тыпыйның Хаҗиәхмәт Әхмәтҗан улы (23 яшь) белән кавыша. Кафия ире мәрхүм булгач, өч баласы белән Березники шәһәренә чыгып китә (Ханә Хәтим кызы мәгълүматы). Мөхәммәтхариснең икенче кызы Кифая авылдашы Мөхәммәтхан Мөхәммәтшәех улы Дәүләтовка кияүгә чыга.

Мөхәммәтхарис Фәрхебану белән никахлашкан дип әйттек. Фәрхебану – «кыз шатлыгы» дигән мәгънәне аңлаткан, киң таралган, бу китапта 37 тапкыр телгә алынган исем. Аның оныгы Ханә апа (1939 елгы) белән сөйләшкәндә, язмышы белән кызыксындым. Фәрхебануның ире Мөхәммәтхарис сугышка чаклы дөнья куя, ә Фәрхебану сугыштан соң да исән, берүзе җиләк-җимеш җыярга йөри торган була. Балалары моңа каршы булган, шулай бер көнне аларга әйтми-нитми Маты әрәмәсенә карлыган җыярга чыгып киткән бу. Шул китүдән Фәрхебану юкка чыккан, бөтен авыл белән күпме эзләп тә таба алмаганнар. Сугыштан соң шикле әдәмнәр булып, шулар кулына эләгеп харап булмады микән, дип юраган хафага төшкән халык.

Мөхәммәткәшиф Мөхәммәтхарис улы балалары: Шаһиян (1923), Гамилә (1926; Яңа Корычта яши), Асия (1929; яшен суга), Мәвәзинә (1932; Сакат-

ның Ямигнур исемле кешесенә кияүгә чыга), Фәһим (1934), Фәнис (1937), Әлфия (1940). Мөхәммәткәшиф – Ватан сугышы ветераны. Ефрейтор, пулеметчы, ВКП(б)га кандидат Шаһиян Харисов Көнчыгыш Пруссиядә барган сугышларда 1945 елның 11 гыйнварында һәлак була.



Хәтим белән Гәүһәрия Харисовлар

Мөхәммәтхәтим Мөхәммәтхарис улы Харисов авылдашы Хәбир Йосыпов кызы Гәүһәрия (метрикәдә – Гәүһәрҗинан; 1908) белән никахлаша, балалары Ханә (1939), Фәнил (1943), Фән (1946–1968), Фәһим (1949) һәм Фәнә (08.07.1953) туа. Хәтим абый – Ватан сугышы ветераны.

Шулай итеп, югарыда нәселне Табыш Абдуллинның өченче улы Баязит яклап карадык. Табышның дүртенче улы Фәйзуллага күчәбез. Фәйзулла уллары: Сираҗетдин (1795), Хисаметдин (1796–1852), Гыймадетдин (1802). Сираҗетдин уллары: Гыйлаҗетдин (1825), Минһаҗетдин (1827). Хисаметдин уллары: Шәйхетдин (1828–25.08.1881), Шәрәфетдин (1832).

Шәйхетдин Хисаметдин улы балалары: Фәррахетдин (1858), Шәһәрзадә (1877). Шәйхетдин кызы Шәһәрзадә (18 яшь) 1895 елның 26 гыйнварында Корычның Әхмәтгәрәй Шәйхелислам улы (25 яшь, икенче никах; атасы Шәйхелислам Сәйфулла улы) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле бертуган агасы Фәррахетдин Шәйхетдин улы була.

Фәррахетдин Шәйхетдин улы балалары: Бибиһаҗәр (21.09.1884), Бибикамилә (22.03.1889), Гайникамал (16.02.1892–1894), Гайникамал (23.10.1894; анасы Сөббехҗамал Галләметдин кызы), Хөсниҗамал (1896–1904), Кәраметдин (12.03.1897–1897), Хөсбиҗамал (07.04.1898), Оркыя (25.09.1900), Миңлезәкия (26.10.1903), Әһлетдин (1904–1911), Оркыя (1905), Гыйлаҗетдин (20.04.1908), Сәлахетдин (09.08.1910), Әгълә (1925). Фәррахетдин кызы Бибиһаҗәрне (20 яшь; икенче никах) 1905 елның 2 гыйнварында Бөгелмә өязе Чәкән олысы Бәйрәкә авылының Гобәйдулла Суфиәхмәт улына (21 яшь) кияүгә бирә. Кызның ризалык шаһитлары – Мөхәммәтзаһир Мөхәммәтшакир улы белән Әлмөхәммәт Мөхәммәтша улы, егетнең вәли вәкиле җизнәсе Галимулла мулла Галиулла улы була. Шул ук елның 17 ноябрендә Фәррахетдин тагын бер кызын кияүгә бирә – Бибикамилә (17 яшь) Яңа Катайның Әхмәтша Тимергали улы (47 яшь; өченче никах) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары нәселдәшләре Мөхәммәтзакир белән Мөхәммәтзаһир Мөхәммәтшакир уллары була. Фәррахетдиннең 1917

елда 12,75 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була, айгыр печүче булып танылган.

Сәлахетдин Фәррахов 1942 елның июнь-сентябрь айларында «Байкал» колхозы рәисе, аңа чаклы бригадир була. Ул Яңа Катайның Мөхәммәтхәтим Күчемов кызы Тәрҗимә (1915) белән гаилә кора, балалары Рәзинә, Зилә, Вәсилә, Вәсимә (Свердловскийда яшиләр), Рәфбәрия (Урманайда яши).

Шәрәфетдин Хисаметдин улы нәселен Фәтхетдин (1869) дәвам итә. Фәтхетдин Шәрәфетдин улыннан Газизәбану (20.07.1908), Фәтхелгаян (03.09.1911; анасы Фәтхиябану Миңлегәрәй кызы) туа. Фәтхетдин Шәрәфетдинов 1917 елда хатыны (48 яшь), улы һәм ике кызы белән яши, 0,06 дисәтинә бәрәңге бакчасы, 3 сарыгы һәм кәҗәсе була.

Фәйзулланың төпчек улы Гыймадетдин (1802–1855) иде. Гыймадетдиннең беренче хатынынннан уллары: Камалетдин (1827), Баһаутдин (1831–15.02.1880).

Камалетдин Гыймадетдин улы балалары: Җәләлетдин (1857), Фәттахетдин (1862), Хөснибануа (08.11.1885), Хөрмәтулла (25.12.1888; анасы Фәрхебану), Хәсәнҗиһан (03.02.1893–1893; анасы Фәрхебану), Хәсәнҗамал (04.04.1902; анасы Фәрхиҗамал Мөхәммәделислам кызы). Камалетдин кызы Хәсәнҗамал (18 яшь) 1885 елның 25 октябрендә Корычның Габделбаян Габделихсан улы (22 яшь; атасы Габделихсан Тимергали улы) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Фәттахетдин Камалетдин улы белән Фәррахетдин Шәйхетдин улы була.

Фәттахетдин Камалетдин улы балалары: Гайнисафа (1886–1898), Әхсәнетдин (01.09.1900), Әхләметдин (12.08.1903). Фәттахетдин кызы Бибимәдхияне (19 яшь) 1915 елның 15 ноябрендә Тыпыйның Сәйфетдин Таҗетдин улына (24 яшь; атасы Таҗетдин Галләметдин улы) кияүгә бирә. Кызның ризалык шаһитлары Әхмәтзәки Әхмәдиша улы белән Әхмәтзариф Фазлыәхмәт улы була. 1917 елда Фәттахетдин Камалетдинов (55 яшь) хатыны (49), ике улы һәм кызы белән яши, 2,79 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры, сарыгы һәм кәҗәсе була.

Баһаутдин Гыймадетдин улыннан нәселне Гарифулла (1863) дәвам итә. Гарифулла Баһаутдин улы (30 яшь; икенче никах) 1893 елның 15 гыйнварында Кадернең Габделкадыйр Габделбәшир улының кызы Мәугизә (25 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Кияүнең вәли вәкиле Мөхәммәтшакир Төхфәтулла улы була. Гарифулла балалары: Миңлехәкимә (13.11.1893), Фәрвизә (30.06.1897).

Нигъмәтулла Баязитовның дүртенче улы Галиулла иде. Галиулла балалары: Нуриәхмәт (Нурәхмәт; 1844), Бибитаифә (1857), Галиәхмәт (1858). Галиулла кызы Бибитаифә 1878 елның 20 гыйнварында Корычның Мөхәммәтсафа Садретдин улы (22 яшь) белән кавыша.

Нуриәхмәт Галиулла улыннан Нурлыгаян (1870–18.07.1914), Муллаәхмәт (30.04.1880), Шәехәхмәт (26.06.1883–1887), Шәйхәйдәр (25.07.1886–1887), Шәехәхмәт (29.01.1889; анасы Лотфыйҗиһан Сираҗетдин улы) дөньяга килә.

Муллаәхмәт Нуриәхмәт (Нурәхмәт) балалары: Сабиткәрам (15.10.1909; анасы Миңлеҗиһан Яңа Кенәзнең Гарифулла кызы), Сәрвиҗиһан (1915–1916, кызамыктан).

Галиәхмәт Галиулла улы балалары: Мөхәммәтнәби (13.06.1886), Әхмәтнәби (29.07.1889), Бибитаифә (17.03.1892), Батырша (16.04.1894; анасы Бибикамал Куянның Нигъмәтулла кызы), Исламгали (1897–1911), Бибифатыйма (13.05.1899), Шәехгали (03.08.1905), Хуҗагали (03.03.1908; анасы Бибикамал), Миңлекамал (07.05.1911). Галиәхмәт кызы Бибитаифә (19 яшь) 1910 елда Иске Куянның Мөхәммәтзакир Муллагали улы (25 яшь) белән никахлаша.

Табыш картның кече улларыннан берсе Габделлатыйф иде. Габделлатыйф уллары: Шатбәһар (1814–16.12.1881), Шәяхмәт (1820). Шатбәһар уллары: Шәрәфетдин (1845), Галләметдин (1860), Хәсән (1864–02.01.1892), Бәдретдин (1867), Имаметдин (10.02.1880–1887).



**1860 елгы документ фрагментында Шатбәһар Габделлатыйпов тамгасы**

Шатбәһар – сирәк кулланылучы исем, күпме авыл-нәсел тарихларын өйрәнеп, бер дә очраганы юк иде, хәтта шундый вариантта «Татар исемнәре» кебек китапларда да теркәлмәгән. Исемнең «шат» дигән өлеше болай да аңлашыла, ә менә «бәһар» фарсы сүзе буларак, «яз, яз көне» дигән мәгънәне аңлата икән. Шатбәһар ата-анасын шатландырып дөньяга яз көне килгән, дип әйтә кебек бу исем.

Шәрәфетдин Шатбәһар улы балалары: Бибихәдичә (22.11.1881), Миңлебибиәсма (05.12.1884), Миңлеәкрәм (02.09.1888; анасы Фәриха), Шакирҗан (16.04.1894; анасы Фәриха Катайның Гарифулла кызы), Бибиразыя (01.05.1897), Бибисәрия (09.01.1901; анасы Кәримә Гарифулла кызы). Шәрәфетдин кызы Бибихәдичә (19 яшь) 1900 елның ноябрендә авылдашы Гарифулла Шәрәфулла улы (25 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Галләметдин Шатбәһар улы белән Фәтхелислам Шәрәфетдин улы була. Шәрәфетдиннең икенче кызы Сәрия (16 яшь) 1917 елның 11 гыйнварында Яңа Корычның Шәйхулла Хөснулла улы (28 яшь, икенче никах; атасы Хөснулла Мохтарулла улы) белән кавыша. Шул ук кызы (икенче никах) 1917 елның 8 июнендә шул авылның Гыйлаҗетдин Тәхаутдин улы (26 яшь; атасы Тәхаутдин Җамалетдин улы) белән никахлаша. Шәрәфетдин Шатбәһаров (77 яшь) 1917 елда хатыны (56) белән генә яши, 1,39 дисәтинә җире, 3 сарыгы була, чабата үрү белән кәсеп итә. Шакирҗан Шәрәфетдин улы Нәгыймә Әбүбәкер кызы белән никахлаша, уллары Әмирҗан (21.12.1925) туа.

Шатбәһарның икенче улы Галләметдиннән дә нәсел дәвам итә. Солдат Галләметдин Шатбәһар улы (26 яшь) 1886 елның 16 октябрендә авылдашы Мәрхәбә Ибраһим кызы (18 яшь; вәкиле Садрелшәрига Ибраһим улы) белән никахлаша. Галләметдин балалары: Гыймадетдин (07.08.1887; анасы Мәрхәбә), Миңлегабделхәким (03.06.1890), Мәрзия (23.10.1893; анасы Мәргубә Корыч-

ның Фәхретдин кызы), Габделгалим (14.03.1897), Бибигайшә (28.10.1904), Мәдинә (20.02.1908). Галләметдин кызы Мәрзия 1911 елның 4 июнендә Килкабызның Мөхәммәтхарис Мөхәммәтзариф улы (25 яшь) белән никахлаша. Галләметдиннең ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, берсе һәлак була.

Шатбәһарнең өченче улы Хәсән (1864—02.01.1892; ютәл зәхмәтеннән вафат) иде. Хәсән Шатбәһар улы балалары: Җәмгыйтдин (23.09.1883), Бибифакия (01.09.1886), Бибиһидая (19.09.1889; анасы Миңлебануа Галиулла кызы), Галиулла. Хәсән кызы Факия (18 яшь) 1905 елның 22 декабрендә Корычның Мөхәммәтгариф Мөхәммәтзариф улы (21 яшь) белән никахлаша. Кыз тарафыннан ризалык шаһитлары — Галләметдин Шатбәһар улы белән Фәтхетдин Шәрәфетдин улы, егетнең вәли вәкиле — карт әткәсе Мөхәммәтсадыйк Таҗетдин улы, ризалык шаһитлары Ярулла Мөхәммәтсадыйк улы белән Нурлыгаян Әхмәтҗан улы була. Хәсәннең икенче кызы Һидая (19 яшь) 1909 елның 13 мартында Туктаголның Миңлеәхмәт Габделгалләм улы (25 яшь; атасы Габделгалләм Габделбасыйр улы) белән кавыша.

Җәмгыйтдин Хәсән улы балалары: Җәмигъянур (04.12.1909; анасы Хәсбиҗамал Әхмәтҗан кызы), Казхинур (1913—1996), Шәйхенур (18.07.1915; анасы Хәсбиниса Әхмәтҗан кызы), Мөсәвәрә (1923), Әминә (1930) һәм Шәйхимам (Шайман; 1932). Китабымда кайбер катайлыларның метрикәдә теркәлмәүләре турында әйткәлим, шундыйларның берсе — Казхинур. Казхинур кызы Рәзинә әйтүенчә, әтисе 1913 елда туган, әбиләрен Хөббениса дип әйткәннәр (димәк, мулла Җәмгыйтдиннең хатыны исемен дә дөрес язмаган). Хөббениса Яңа Корычта туып үскән. Казхинур белән Мәрзия Әкрәметдин кызы (Ямадыбаш авылыннан) балалары: Мәгъзинур (1940—2007), Хаҗинур (1953—2013), Рабига (1947), Рәмзия (1950), Рәзинә (1957). Казхинур — Ватан сугышы ветераны, «Японияне җиңгән өчен» медале белән бүләкләнгән. Шәйхенур Хәсәнов — Ватан сугышы ветераны (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән), сугыштан контузия белән кайткан, Волгоград өлкәсенең Сарай поселогында гомер иткән. Мөсәвәрә Октябрьскийда яшәгән, балалары Тимерҗан (1955), Фәнис (1958). Әминә Яңа Катайның Мөтәвәкил Кашаповка кияүгә чыга. Шайман Яңа Катайның Әхмәтнәгыйм Яруллин кызы Сәгадәт белән гаилә кора, балалары Галия (1957), Салават (1959), Галимә (1961), Ришат (1967), Ринат (1973) туа.

Җәмигъянур Яңа Катайның Габдрахман Габдерәхимов кызы Рәйфә (1912) белән никахлаша, балалары Фәнил (1937) белән Рәмил (1939; хатыны Ралия Гафият кызы) Хәсәновлар туа. Җәмигъянур Хәсәнов тракторда эшли, 27 августта сугышка китә, 1943 елда һәлак була (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Рәмил Хәсәнов — Катай мәктәбе һәм авылы тарихында якты эз калдырган шәхесләрнең берсе. Аның турында педагогик хезмәт ветераны Айрат Әхмәтов



**Рәмил Хәсәнов пионерларга яңа җыр өйрәтә**

район гәзитендә «Укучылар хәтерендә» (2010 ел, 14 октябрь) язмасын бастырды, түбәндә аны бераз кыскартып бирәбез.

«Катай урта мәктәбе тынлы оркестрының элекке җитәкчесе Рәмил Җәмигъянурович Хәсәновка октябрь башында 71 яшь тулган булыр иде. Яхшы күңелле, үз һөнәренә чиксез бирелгән музыка укытучысының бу тормыштан китүенә ышанасы да килми.

Районда беренче тынлы оркестр мәктәбен ул оештырды. Безнең, 5–7 сыйныф укучыларының, түгәрәккә беренче башлап йөрүчеләрнең 1966 елда кечкенә кысан бүлмәдә моңарчы безгә таныш булмаган бакыр һәм көмеш торбаларның яңгыравыклы тавышларын ишетүебезне бик яхшы хәтерлим. Тынлы оркестрлар курсларын яңа тәмамлап кайткан Рәмил абый аларның тавышларын сынап карый.

Яңа уку елы башлану белән безнең балалар кулында да тынлы оркестр уен кораллары җанлана башлады. Кыска гына вакыт эчендә остазыбыз җитәкчелегендә без оркестрның көчле уйнавына, төрле уен коралларының гармонияле яңгыравына ирешә алдык.

Тынлы оркестр музыкасына балаларны өйрәтүгә 30 елга якын гомерен багышлап, ярты ел эчендә аның катлаулы оркестр әсәрләрен башкарырга өйрәтә алуына әле булса гаҗәпләнәм. Чайковскийның «Кечкенә аккошлар биюе», Шәриповның «Башкорт маршы», Агапкинның «Славянканың хушлашуы»

һәм мәктәп оркестры башкарган башка әсәрләрне авыл халкы хәйран калып тыңлый иде.

Шушы коллективтан күп кенә үзешчән һәм һөнәри музыкантлар чыктылар. [...] Мәктәпне тәмамлаучыларның күбесе хәрби оркестрларда музыкантлар булып хезмәт иттеләр [...].

Түгәрәккә йөрүчеләр Башкортстан районнары буйлап йөрделәр, Урал артына да бардылар. Үзешчән сәнгать смотрларында, күпсанлы конкурсларда катнаштылар, призлы урыннар алдылар. Аларның һәммәсе хөрмәтле остазыбызның армас-талмас хезмәт нәтиҗәсе булды.

Рәмил абый йомшак күңелле һәм бер үк вакытта таләпчән булды, ул балаларны яратты, ә без аны сайлаган һөнәренә тугрылыгы өчен яраттык һәм хөрмәт иттек.

Тормыш иптәше Ралия Гафиятовна белән бәхетле гаилә тормышы кичерделәр, бик яхшы ике ул үстерделәр, аларга югары белем бирделәр. Рәмил абыйның әнисе Рәйфә апа да хәстәрлекле улы һәм килене канаты астында 35 ел яшәде.

Бүгенге мәктәп укучыларына тормыш юлларында олы йөрәкле, талантлы кешеләр очрасын иде, дип телисе килә. Укытучы Р. Җ. Хәсәновның образы укучыларының рәхмәтле күңелендә сакланачак».

Нәселдәшем Айрат Әхмәтов язмасын хуплап, аңа кушылып әйтәсе килә: Катай мәктәбе Рәмил Хәсәнов кебек үз тормышын мәктәбенә һәм авылына багышлаган шәхесләрне искә алып, төрле чаралар уздырсын иде. Музеебыз булса, шунда уздырырга булыр иде. Заманында биш мәчете, хәзер исә ике мәчете һәм китабы булган Катайда күп экспонатлар тупланган, үткән тормышны яктырткан, шәхесләребез турында истәлекләр, фоторәсемнәр тупланган музей юк. Болар – совет чорыннан ук Катай мәктәбе директорларының, авыл хакимиятенең бу мәсьәләгә битарафлыгыннан, киләчәкне уйламыйча, бүгенге көн белән генә яшәвеннән килә. Музей мәсьәләсендә кайбер авыллардан үрнәк алырга кирәк, Мостафада аның өчен аерым бина бирелгән, бөтен шартлар тудырылган. Катайның андый мөмкинчелекләре юк дип әйтеп булмый, бөтенесе җитәкчеләргә бәйле, туган авылын яратып, аның үткәнен музейда чагылдыру-яктырту турында уйлап, бүгенгесен генә түгел, киләчәген дә кайгыртып яшәсеннәр иде.

Рәмил Хәсәнов кебек зур шәхесне биргән Шатбәһар улы Хәсән турында сүзебезне дәвам итәбез. Хәсәннең төпчек улы Галиулла булып, аның Зәкия Фәррахетдин кызы белән никахыннан Әһлетдин (26.04.1924) туа.

Шатбәһарның дүртенче улы Бәдретдиннән дә нәсел дәвам итә. Бәдретдин Шатбәһар улы (25 яшь; икенче никах) 1892 елның 11 маенда Корычның Миңлебану (25 яшь, икенче никах; атасы Галиулла Габдулла улы) белән гаилә кора, балалары Талбетдин (08.11.1892–1893), Әхияретдин (27.12.1893), Мөхәммәтдин (1896–1897), Гыйниятулла (20.07.1898) дөньяга килә. Гыйниятулладан нәселне Ватан сугышы ветераннары Тәкыйулла (1923–1999) һәм Зәкиулла (12.12.1925;

анасы Сәрия Габделвахит кызы) Бәдретдиновлар, аларның балалары һәм оныклары дәвам итә.

Югарыда Габделлатыйф Табыш улының беренче варисы Шатбәһардан киткән тармаклар каралды. Габделлатыйфның икенче улы Шәяхмәт (1820–12.10.1874) иде. Шәяхмәт балалары: Әһлиулла (1849), Шәйхулла (1854–19.07.1905), Әһәдулла, Фазлыәхмәт, Фәрхиҗиһан (1863), Фәхерҗиһан (1868–1890). Шәяхмәт кызы Фәрхиҗиһан (18 яшь) 1881 елның 7 декабрендә Корычның Таҗетдин Җамалетдин улы (25 яшь) белән никахлаша.



**Ватан сугышы ветераннары Зәкиулла Бәдретдинов (сулда) белән почтальон Әслахетдин Шәрәфетдинов**

Әһлиулла Шәяхмәт улы балалары: Габидулла (20.01.1876; анасы Гыйльмисафа), Хәмидулла (08.08.1887–1892), Миңлеҗиһан (23.12.1894; анасы Гыйльмисафа Вәлиша кызы).

Шәйхулла Шәяхмәт улы балалары: Таифә (1882–1899, ютәл авыруыннан), Хөсниҗиһан (28.03.1895–1899, чәчәктән; анасы Хөсниҗамал), Миңлехәмидулла (1896–1898; эч авыруыннан вафат), Гарифулла (22.08.1897–1898, чәчәктән; анасы Миңлеҗамал Талбетдин кызы), Миңлехәмидулла (12.10.1897; анасы Гыйльмиҗиһан Мөхәммәтҗан кызы).

Әһәдулла Шәяхмәт улы балалары: Вәлиулла (02.11.1883), Бибифакия (29.07.1911; анасы Мәрзия Таҗетдин кызы). Аның туганы Фазлыәхмәт Шәяхмәт улыннан Шәмсекамал (26.04.1889; анасы Маһикамал Һидиятулла кызы) билгеле.

**Табышның ерак нәселдәше – Бикташ**. Нәселнең бу тармагы башында Хөсәен Айтуков тора. Аңа 1762 елда 67 яшь, 18 яшьлек улы Бикбулат (күпчелек чыганакларда исеме Байбулат) була.

Шул ук 1762 елгы документта 35 яшьлек Акбай Янбулатов та теркәлгән. 1811 елгы чыганакта фамилиясе Байбулатов, 1809 елда мәрхүм дип күрсәтелә.

Шул соңгы чыганакта Акбай, ни сәбәпледер, Хөсәен Айтуков нәселен дәвам иткән Бикташ Байбулатовның абыйсы дип бирелә. Ул аның абыйсы була алмый, ә менә нәселдәше булуы ихтимал.

Хөсәен Айтуковның оныгы Бикташ Байбулатовтан нәсел үрчи, тармаклана, Иске Катайда дистәгә якын хуҗалыклар белән бәйле. Шуңа нәселнең Бикташ тармагы дип билгеләп үтәбез.

Бикташ – борынгы төрки-татар, ир бала таш шикелле нык булсын, дигән теләктән чыгып кушылган исем. Исеме җисеменә туры килә: Бикташ Байбулатов нык булып, исән-сау үсеп, нәселне дәвам итәрлек варис калдыра.

Бикташ турында беренче мәгълүмат 1795 елгы документта бирелә. Аңа бу вакытта 25 яшь, хатыны Әмәкәйнең Бәдигылҗамал Арслан кызы, улы Шәмсетдин (3 яшь) була.

Шәмсетдин яшьли вафат була, 1811 елда Бикташ гаиләсендә ир балалардан Шәйхетдин (1800; беренче хатыннан), Ризван (1802), Мөхетдин (1810–11.07.1875; икенче хатыннан) күрсәтелә. Бикташның икенче улы Ризван да кыска гомерле (1820 елда 17 яшьтә вафат) була, 1834 елда нәселне Шәйхетдин белән Мөхетдиннән башка, кече улы Мөхәммәтгалим (2 яшь; башка чыганакта исеме Мөхәммәтгатаулла) һәм оныгы Мөхәммәтлатыйф (1 яшь; Шәйхетдиннең улы) дәвам итә. Бикташ гаиләсендә иң соңгы ир бала булып Мөхәммәтшәйхулла дөньяга килә, әмма 1851 елда 16 яшь көе бакыйлыкка күчә.

Ничә ир баладан бары Мөхетдин озын гомерле булып, нәселне ишәйтә. Мөхетдин Бикташев балалары (беренче хатыннан): Ибраһим (1835–02.08.1886), Бикмөхәммәт (1843–1852), Әдһәм (1845–16.12.1915), Бибисара (1853), Мөхәммәди (1855), Мортаза (1859). Мөхетдин кызы Бибисара (22 яшь; икенче никах) 1875 елның 15 февралендә Минзәлә өязе Мәсгут авылының Мөхәммәтшәриф Мәсгут улы (35 яшь; икенче никах) белән гаилә кора.

Мөхетдин Бикташев «Үткәннәрен бел Катайның» китабында телгә алынды, аның 1842 елда авылдашы-ерак нәселдәше Мохтарулла Нигъмәтуллин белән бергә Казыяр елгасында тегермән төзүе хакында әйткән идек. Бу хакта сөйләүче документта Казыяр «Кызылъяр» дип язылган. Шуннан чыгып, атама барлыкка килү кайчандыр мул сулы елганың кызыл ярлары белән бәйле дип фараз кыла алабыз. Бу юлларны язганда кошлар тишкәләп бетергән, оя ясаган биек кызыл яр буе астында балачакта кармак тотып балык тотканнар искә төшә.

Мөхетдиннең балаларына күчкәнче, аның энесе Мөхәммәтгатаулла Бикташев турында әйтеп үтик. Ул указлы мулла була, 1881 елның 25 ноябрендә кызы Закирәне (20 яшь) Корыч авылының Минһаҗетдин Әсәдулла мулла улына (25 яшь; Әсәдулла Габдулла улы) кияүгә бирә. Корычның шул ук нәселендә тагын бер кызы бәхетен таба – Шәфига (20 яшь) 1884 елның 28 гыйнварында Зыятдин Әсәдулла улы (25 яшь; атасы Әсәдулла Габдулла улы) белән никахлаша. Уртанчы кызы Бибихәнифә (18 яшь) 1885 елның 11 октябрендә Килкабыз-


подали въ деревнѣ Мастюсевой Мензелин-
скаго уѣзда на татарскомъ діалектѣ
Вашему Превосходительству прошеніе
о дозволеніи ихъ однодеревенцу Мухет-
дину Бикташеву возобновленія мельни-
цы на рѣчкѣ Кызыль-яръ прежде
содержимой – по имѣемой, будто бы, ни-
нуждѣ въ размолѣ хлѣба. Мельни-
ца эта въ дѣйствіи остановлена
рѣшеніемъ Белебеевскаго Уѣзднаго Суда
состоявшимся 9го Ноября 1854 года и

**Казыяр «Кызылъяр» дип язылган документ фрагменты**

ның Сираҗетдин Раҗетдин улы (22 яшь) белән кавыша. Кече кызы Гакифә (18 яшь) 1895 елның 26 гыйнварында Килкабызның Мөхәммәтсадыйк Госман улы (25 яшь; атасы Госман Гаделша улы) белән никахлаша. Мөхәммәтгатаулла 1912 елның 25 апрелендә вафат була, нәселен улы Мөхәммәтхафиз (1867) дәвам итә. Мөхәммәтхафиз Гатаулла улы балалары: Гыймаделислам (12.05.1900–1900), Гәүһәрҗинан (15.07.1901; анасы Фәрвизә Хаҗиәхмәт кызы), Бибиәминә (25.01.1904–1912), Гәүһәрҗинан (29.01.1907), Тәлхия (12.03.1910–1912), Миңлегали (1923–1924; анасы Хәмидә).

Алдарак Мөхетдин гаиләсендә ир балалардан беренчесе итеп Ибраһимны күрсәттек. Ибраһим Мөхетдин улы балалары: Исмәгыйль (1863), Бибимәрхәбә (1864–1889), Садрелшәрига (1865), Шәмсеҗиһан (1869), Зиннур (1878), Имаметдин, Мөнәвәрә (1881). Ибраһим кызы Шәмсеҗиһан (18 яшь) 1888 елның 11 гыйнварында Куянның Сәүбән Габделсаттар улы (25 яшь; икенче никах) белән кавыша. Икенче кызы Мөнәвәрә (20 яшь) 1901 елда Яңа Катай кешесе Шәйсолтан Дәүләтгәрәй улы (24 яшь) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле – бертуган агасы Садрелшәрига Ибраһим улы, ризалык шаһитлары нәселдәшләре Мортаза Мөхетдин улы белән Зиннур Ибраһим улы була.



**Зиннур Ибраһим улы нәсел тамгасы «Ш» хәрефенә охшатып салган. 1901 ел**

Икенче мәхәлләдә Исмәгыйль Ибраһим улы белән Бибифаизә Әхмәтша кызы (Корыч авылыннан) гаиләсендә Исламгали (13.10.1893–1894), Миңлеәгъләм (20.09.1898), Әнгаметдин (1899; метрикәдә юк), Миңлемәвәзинә (18.09.1904), Хәтмулла (18.11.1907), Бибисаҗидә (26.11.1910), Рәхмәтулла (06.02.1914) дөньяга килә. Исмәгыйль Ибраһимовның бер улын (18 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (45 яшь), калган дүрт улы һәм өч кызы белән яши, 4,25 дисәтинә җире, аты, сыеры, бозавы һәм 2 сарыгы була.

Икенче мәхәлләдә Әгъләм Исмәгыйль улы белән Сания Хәйрелзаман кызы гаиләсендә Камил (02.09.1924; анасы Сания Хәерзаман кызы) туа, аларның башка балалары да була.

Әнгаметдин Исмәгыйль улы (26 яшь) 1925 елның 12 февралендә Яңа Катайның икенче мәхәлләсендә Йөзлебикә Имаметдин кызы Азаматова (20 яшь) белән никахлаша. Кияүнең вәкиле агасы Әгъләметдин Исмәгыйль улы була. Әнгаметдин Исмәгыйлев – сугыш ветераны, сугышка киткәндә гаиләсендә хатыны Йөзлебикә (1903), уллары Зифир (1928), Фән (1934), кызы Әнисә (1937)

була. Сугыш чорына караган документларда 1901 елда туган дип әйтелә, әмма ул 1899 елда дөньяга килгән.

Хәтмулла Ибраһимов 1941 елда сугышка китә, шул ук елда хәбәрсез югала (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән). Сугыш алдыннан Хәтмулла белән Мөнирә гаиләсендә кызлары Гөлсайра (1938) белән Фаягөл (1941), анасы Фаизә була.

Ибраһимның икенче улы Садрелшәригага күчәбез. Садрелшәрига Ибраһим улы (25 яшь) 1890 елның 18 октябрендә авылдашы Бибикафия (18 яшь; атасы Рахманкол Яхшыгол улы) белән никахлаша, балалары Бибикәшифә (10.02.1893–1893), Шәрифулла (12.08.1894–1940), Шәрхемулла (15.01.1899–1900), Гарифулла (01.12.1901), Шәрхемулла (22.07.1904–1904), Гыйниятулла (16.11.1905), Кифая (27.01.1908), Нигъмәтулла (02.10.1911) дөньяга килә. Шәрига Ибраһимовның олы улын (22 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (45 яшь), кече улы (12) һәм кызы белән яши, 9,63 дисәтинә җире, 2 аты, 4 сыеры һәм башка маллары була.

Шәрифулла Садрелшәрига улы Үрмәтнең Җәннәтеләсма Сәетгәрәй кызы (1903) белән гаилә кора, балалары Гыйльмулла (25.11.1924; яшьли мәрхүм), Сания (09.01.1930–2008), Әүхәт (1933–1985) һәм Әсхәт (1935–2006; Нефтекамскийда яшәгән) Шаригиннар туа. Сугыш алдыннан ире Шәрифулла мәрхүм булгач, Җәннәтеләсма үзбәк Каләмдәр Сәпәевне (1905) йортка кертә (Кәнзел Күчемов димләп), кызлары Сайка (01.06.1943) туа. 1943 елның 18 мартына караган хәрби документта Каләмдәр ВКП(б)га кандидат, Төрекмәнстанның Ташауз шәһәрендә туып үскән, һөнәре «путевой обходчик» дип язылган, ул шул елның язында сугышка киткән һәм 1944 елның көзендә хәбәрсез югалган. Бу мәгълүматның бер өлешен авыл советы кенәгәсеннән алган идем, Эльмира Әлфәт кызы Йосыпова (Әнвәретдин Саяповның оныгы) Сайка Каләмдәр кызы Исмәгыйлеваның телефон номерын биреп, аның белән сөйләшкәч тулыландырдым.


**Җәннәтеләсма кызы Сайка белән**

Шәрифулла кызы Сания Яңа Катайның Әнвәретдин Саяпов белән никахлаша. Әүхәт белән Дәнә (Куянныкы) балалары: Ринат (1960), Зилара (1962), Радик (1965). Сайка апа Борайның Сәгыйтҗан Ахунҗан улы Исмәгыйлев белән гаилә кора, балалары Гүзәл (17.12.1968), Ирек (17.08.1971) туа. 1974–1980 елларда читтән торып Казан ветеринария институтын тәмамлый. Туган авылын, авылдашларын сагынып яши.

Шәрифулланың энесе Гыйниятулла Шаригин – сугышка Үзбәкстанның Хорезм өлкәсеннән 1942 елның сентябрендә китә, «Сугышчан хезмәтләре



**Сулдан уңга: Лиза, Сайка, Клара апалар**

өчен» (15.06.1944) медале белән бүләкләнә, 1944 елның 18 июлендә һәлак була (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән), хатыны Саимә (1905), балалары Рәис (1931; Приютовода яшәгән), Фәнә (1936; Наманганда яшәп, Кумертауда төпләнәләр) һәм Фәридә (1940) кала.

Ибраһимның өченче улы Зиннурдан да нәсел дәвам итә. Беренче хатыны Зәйнәп Ибраһим кызы була, аннан Нуретдин (05.01.1897–1897, эч авыруыннан вафат), Бибикамал (25.07.1898), Шәмсеҗамал (08.07.1901–1909, эч авыруыннан) дөньяга килә. Икенче хатыны Һидая Мостафа кызы (1880), балалары Кәрәметдин (1908; авыл советы кенәгәсендә күрсәтелә), Мәрхәметдин (09.02.1909), Госаметдин (09.03.1912–1912), Мәгъдәния (13.09.1913), Миңленаҗия (22.10.1916), Мөхәссәнә (1922–1924) һәм Әһлетдин (02.10.1925) була. Әһлетдингә 1942 елның 4 августында чакыру кәгазе килә, Белоруссиянең Витебск өлкәсе Макарово авылы янындагы сугышларда 1944 елның 7 февралендә һәлак була (1944 елның гыйнварында хәбәрсез югала, дип әйтелгән чыганак та бар). Бер чыганакта Әһлетдиннең туган урыны хәтта Смоленск өлкәсе дип, икенчесендә Башкортстанда туган, Смоленск өлкәсеннән сугышка киткән дип әйтелә. Димәк, Әһлетдиннең язмышы күпмедер вакыт шул яклар белән дә бәйле булган (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Зиннурның улы Мәрхәметдин Зиннуров сугышта һәлак була, икенчесе (Кәрәметдин) сукыр иде, дип әйткән иде Хәмит абый Маликов. Шул Кәрәметдин булса кирәк, сугыш алды исемлегендә Кәрим (1908) дип теркәлгән, үзен метрикәдән тапмадык. Бу нәсел кешеләренең күпчелеге кебек, Зиннурның да исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән.

Ибраһимнең дүртенче улы Имаметдиннән икенче мәхәлләдә Мәрхәметдин (26.03.1904), Миңлебәһия (08.05.1906), Миңлегали (11.03.1909), Нәҗия (04.10.1911; анасы Бибибания Вәлиәхмәт кызы) туган.

Шулай итеп, Мөхетдин Бикташевның беренче улы Ибраһимнан шактый нәсел кала. Мөхетдиннең икенче улы Әдһәмнән (мондый исемле кеше Катай тарихында бер ул гына була) дә нәсел тармакланып китә.

Әдһәм Мөхетдин улы балалары: Заһретдин (1868), Афзалетдин (1874–25.09.1909), Хәйретдин (16.07.1875; анасы Бибисабира), Бибигалимә (15.10.1878), Хөҗҗәтелислам (15.12.1881), Бибимөкәррәмә (01.10.1884–1889) һәм башкалар. Әдһәм кызы Бибигалимә 1899 елда Яңа Куянның (Камышлытамакның) Гыйззетдин Габдуллин улы Әлмөхәммәткә (23 яшь) кияүгә чыга. Кызның ризалык шаһитлары Садрелшәрига Ибраһим улы белән Хәйретдин Әдһәм улы була. Әдһәм (50 яшь; өченче никах) 1895 елның 23 сентябрендә авылдашы Камалетдин Габделнасыйр улының кызы Җиһанбануны (40 яшь; дүртенче никах) хатынлыкка ала.

Заһретдин Әдһәм улы балалары: Миргабитҗан (14.10.1897; анасы Бибифакия Әбүнәгыйм кызы), Мәзхөррәфә (16.06.1900), Бибихәтимә (29.06.1903), Бибимосаллия (12.03.1906), Әнүзә (03.05.1909), Сабирҗан (18.07.1910), Газизҗан (03.07.1914), Галимҗан (05.03.1917), Мөҗәһидә (1921–1924). Туганнары арасында Заһретдин Әдһәмов иң хәллесе санала, 1917 елда аның 8,62 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче яллаган. Улы Сабирҗан Заһретдинов (1910) сугышта һәлак була (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Афзалетдин Әдһәм улы балалары: Әхмәдулла (20.03.1901; анасы Гыйльмиҗиһан Төхфәтулла кызы), Насыйх (1903–1905), Хәдичә (20.12.1905). Әхмәдулла Афзалетдинов (15 яшь) 1917 елда анасы (40) һәм сеңлесе белән яши, хуҗалыгында 1,05 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм кәҗәсе була.

Хәйретдин Әдһәм улы балалары: Минһаҗетдин (20.07.1909–1910), Шәйхетдин (03.02.1912; анасы Мәликә Якуп кызы), Мәрьям (30.03.1915; анасы Мәликә Идрис кызы), Гыйлаҗетдин (15.12.1917). Хәйретдин Әдһәмов 1917 елда хатыны (30 яшь), ике улы һәм кызы белән яши, 1,24 дисәтинә җире һәм 2 кәҗәсе була.

Хөҗҗәтелислам Әдһәмов Беренче бөтендөнья сугышында 32 Себер укчы полкында хезмәт итә, 1915 елның 4 февралендә яралана. Хөҗҗәт (Хөҗҗәтелисламны шулай кыскартып әйтәләр) Әдһәмовның Ватан сугышы башланганда гаиләсендә хатыны Сәхипбану (1884), уллары Зиннәт (мулла кушкан исеме Зиннәтелислам; 17.12.1912; хуҗалыгы аерым), Ислам (мулла кушкан исеме Гыймаделислам; 1923), кызлары Гания (1920), Мәрьям (1934; читкә чыгып китә) һәм Гөлҗәннәт (1937) була. Зиннәт Хөҗҗәт улы Әдһәмовның (1912) сугышка киткәндә хатыны Гания (1920), кызы Гафия (1941) кала, үзе сугышка керү белән диярлек һәлак була. Гыймаделислам да 1943 елда сугыш яланнарында ятып кала. Шулай итеп, аяусыз сугыш аркасында нәселнең Хөҗҗәт тармагында ир-ат калмый (сугыш корбаннары Зиннәт белән Гыймаделислам Хөҗҗәт ул-

лары Әдһәмовлар Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгәннәр). Хөҗҗәт кызы Гөлҗәннәт авылдашы Рифкать Сарьянов белән кавыша.

Китапның бу бүлеген Мөхетдин Бикташевның төпчек улы Мортаза белән тәмамлыйбыз. Мортаза Мөхетдин улы (19 яшь) 1880 елның 7 декабрендә авылдашы Бибимәрхәбә мулла Мөхәммәтнәби кызы (18 яшь) белән никахлаша, балалары Бибигайшә (17.02.1884), Мәрьям (16.09.1887–1911), Зөләйхабикә (27.07.1889), Гөлчирә (25.03.1891), Зөләйха (29.04.1894), Хәдичәбикә (12.12.1895), Рузәтелҗинан (26.01.1898) туа. Мортаза кызы Гайшә (20 яшь) 1905 елның 8 декабрендә Килкабыз авылы кешесе, Иске Катайның икенче мәхәллә имамы Харис Шәрәфетдин улы Яугилдин (16.11.1871) белән никахлаша. Харисның атасы Шәрәфетдиннең Яңа Катайдан Килкабызга күчеп утыруын, Арсланбәк нәселеннән булуын искәртеп үтик. Әлеге никахтан Әхмәтләбип (1908), Җәүһәрә (13.08.1909), Нәйрә (21.12.1911), Габделәхәт (29.11.1913) һәм башка балалар туа.

Мортазаның кече кызы Мәрьям (20 яшь) 1908 елда Минзәлә өязе Пучы олысы Усы авылының Фазлымөхәммәт Мәгъдәннур улы (25 яшь) белән гаилә кора. Мәрьям 1911 елның 8 февралендә вафат булгач, Мортаза ике көннән шул ук кешегә кызы Зөләйхабикәне (17 яшь) бирә. Мортаза Мөхетдинов (58 яшь) 1917 елда хатыны (55), оныгы (8) һәм кызы (18 яшь) белән яши, димәк, аның нәселен дәвам итүче ир баласы булмый. Хуҗалыгында аты, 2 сыеры, 7 сарыгы була, иген чәчми.

Мортаза Мөхетдинов – Иске Катайда икенче мәхәллә булдыру нияте белән башлап йөрүчеләрнең берсе, шул ниятне тормышка ашыруда бар булган акчасын тоткан киң күңелле, игелекле зат. «Үткәннәрен бел Катайның» китабында без аны зурлап яздык, безнең буын гына түгел, киләчәк буыннар да аның исемен телгә алып якты рухына дога кылсын иде.

# VI бүлек.
# Гобәй нәселе

Туксанынчы елларда бу китапка мәгълүмат туплаганда, сугыш һәм хезмәт ветераны Кыям абый Ситдыйковтан үткән чорлар турында сорашып, үз шәҗәрәсен ничә буынга чаклы белүе белән кызыксындым. «Безнең нәселне Гобәй нәселе дип әйтәләр иде, бабайларның берсе Ханай исемле булган, аның уллары – Мөхәммәтситдыйкъ белән Мөхәммәтнәби. Мөхәммәтситдыйкъ минем Кадермөхәммәт әтәемнең атасы була. Мөхәммәтнәби исә Фәез, Риф һәм Ралиф Нәбиевләрнең бабасыдыр», дип искә алган иде Кыям абый.

«Безнең ерак бабайны Ханай дигәннәр. Аның Мөхәммәтнәби исемле улыннан безнең Хаҗиәхмәт бабай, Хаҗиәхмәттән әтиебез Мирзаәхмәт була инде». Әлеге мәгълүматны Фәез белән Риф абый Нәбиевләр әйтте. Хаҗиәхмәт картның кибет тотканын, сәүдә итеп, иген игеп, күп терлек асрап, мул тормышта гомер итүен аталары сөйләгән булган.

Архив документларына мөрәҗәгать итик. Нәсел башында Ырсай карт тора. Аның 1671 елда ук туган улы Мөслим, хәтта 1762 елда да исән-сау була. Алга таба нәселне Мөслимнең – Нәдер (1709 елда туган), Нәдернең Зәйнелгабидин (1743), Сәгъди (Сәгъдетдин 1764), Габидулла (1768) исемле уллары дәвам итә. Зәйнелгабидин ике ул (Гобәйдулла һәм Хәбибулла) һәм дүрт кыз үстерә. Сәгъдетдин белән Габидулланың да балалары һәм оныклары була.

Әлеге нәселнең Гобәй нәселе дип аталуына алдарак телгә алынган Зәйнелгабидинның Гобәйдулла исемле улы сәбәпче булган икән. Архив мәгълүматына караганда, Гобәйдулла Зәйнелгабидинов 1792 елда дөньяга килгән, нәселен уллары Габделханнан (1809–05.02.1883) һәм Хәлилулла (1818–08.11.1895) дәвам итә. Исемен кыскартып-җайлаштырып, Габделханнанны авылдашлары Ханай, дип әйтә торган булганнар, рәсми документларда исә аның уллары Ханнанов йөри. Габделханнанның 1859 елда хатыннары Газизә Гайсар кызы (1809) белән Шәрифә Миңлегали кызы (1809) була, беренче хатыныннан – уллары Миңлесафа (Мөхәммәтсафа, 1834), Мөхәммәтситдыйкъ (1840), Мөхәммәтнәби (1845), икенче хатыныннан Габделмәннан (1845) һәм Нурлыгаян дөньяга килә.

Мөхәммәтсафа Габделханнан улы балалары: Миңлемәүгазия (1861), Мөхәммәтдин (08.04.1875; анасы Мәгъфүрә), Нуриәхмәт (1912 елда вафат), Нургали (1869). Мөхәммәтсафа кызы Миңлемәүгазия (19 яшь) 1880 елның 11 декабрендә Камышлытамакның Биктимер Биктаһир улы (22 яшь; атасы Биктаһир Бикбатыр улы) белән никахлаша.

Мөхәммәтдин Мөхәммәтсафа улы балалары: Бибизәйнәп (11.12.1902), Саяфетдин (22.04.1905), Зиннәтулла (03.03.1908; анасы Хәкимә Мөхәммәтшәриф кызы), Инсафетдин (04.12.1910), Бибинур (12.11.1916). Мөхәммәтдин Мөхәммәтсафин (42 яшь) 1917 елда хатыны (37), ике улы, өч кызы һәм туганының улы (15) белән яши, 4,82 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм кәҗәсе була. Мөхәммәтдин нигезендә Хәбип Газизов йорты тора, дип әйткән иде Хәмит абый.

Нуриәхмәт Мөхәммәтсафа улы балалары: Фәтхелгаян, Хәтирә (17.01.1895), Миңлефазлыәхмәт (04.08.1897; анасы Шәмсебанат Тыпыйның Шәйхетдин кызы), Бибикамал (10.06.1901), Галиәхмәт (09.09.1904), Бибиҗиһан (28.05.1907–1911), Бибизакирә (08.02.1912). Нуриәхмәт кызы Хәтирә (18 яшь) 1912 елның 15 гыйнварында Корычның Гыйльман Сәлман улы (27 яшь, икенче никах; атасы Сәлман Кәлимулла улы) белән никахлаша. Фәтхелгаян Нуриәхмәт улыннан Мөкәррәмә (15.04.1910; анасы Фатыйма Фәтхулла кызы) билгеле.

Нургали Мөхәммәтсафа улы балалары: Фәрхизиядә (09.03.1897), Шәмсезиядә (17.12.1898–1899; эч авыруыннан, анасы Фәрхебану Иске Катайның Зәйнулла кызы), Нуретдин (07.09.1904), Мәдхиҗиһан (06.03.1907), Әнвәретдин (02.01.1910–1911; анасы Шәмсеҗиһан Һибәтулла кызы). Нургали Сафин (48 яшь) 1917 елда хатыны (50 яшь), ике улы һәм кызы белән яши, 1,68 дисәтинә җире, аты була. Көтүче булып яллана.

Мөхәммәтситдыйкъ Габделханнан улы балалары: Бикмөхәммәт (22.02.1876), Миңлешәмсемөхәммәт (17.10.1878), Миңлекадермөхәммәт (25.09.1881–02.10.1882), Кадермөхәммәт (07.07.1884), Шәрфениса (06.02.1885), Миңленурмөхәммәт (19.01.1886–1893; ютәл зәхмәтеннән вафат), Нурулла (21.02.1893; анасы Газизә Яңа Катайның Мөхәммәтсадыйк кызы). Иллегә җиткәч, Мөхәммәтситдыйкъ Габделханнан улы (өченче никах) 1890 елның сентябрендә Яңа Катайның Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәткәрим улының кызы Бибигазизә (19 яшь) белән никахлаша. Мөхәммәтситдыйкъ Ханнановның улын (24 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (65 яшь) белән яши, 8,57 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм 2 кәҗәсе була.

Бикмөхәммәт Мөхәммәтситдыйкъ (Миңлеситдыйкъ) улыннан Миңлехәтимә (11.12.1917; анасы Мәгъсүмә Мөхәммәтзакир кызы) билгеле.

Миңлешәмсемөхәммәт Мөхәммәтситдыйкъ улы (метрикәдә Миңлеситдыйкъ; 25 яшь) 1911 елның 20 ноябрендә Яңа Катайның Фазлыәхмәт Гайнанша улының кызы Мәгъсуфә (Мәүсуфа; 17 яшь) белән никахлаша, балалары Динмөхәммәт (29.08.1913), Миңлемәүҗүдә (13.01.1916) туа. Шәмсемөхәммәт Ситдыйков 1917 елда хатыны (25 яшь), улы һәм кызы белән яши, 2,06 дисәтинә җире, 4 сарыгы һәм кәҗәсе була.

Кадермөхәммәт Мөхәммәтситдыйкъ улыннан Миңлемулламөхәммәт (06.08.1916; анасы Бибимәгъдәния Фәттахетдин кызы), Шаһимөхәммәт (1919), Кыяметдин (1923), Нәкыя (1928), Минзиан (1930) туган. Кадермөхәммәт Мөхәммәтситдыйков 1917 елда хатыны (20 яшь) һәм улы белән яши, 2,17 дисәтинә җире була. Утын кисеп, такта ярып кәсеп иткән. Мулламөхәммәт (1916), Ша-



**Кыям Ситдыйков (унда), Хавис Исламов, Тавис Заһиров, Тавис хатыны Фәйрүзә, Фиркать Хавис улы, Рәшит Кыям улы**

һимөхәммәт (1919–1986), Кыяметдин (1923) Ситдыйковлар – Ватан сугышы ветераннары. Шаһимөхәммәт «Японияне җиңгән өчен» медале, Кыяметдин «Сугышчан хезмәтләре өчен» (07.11.1943), «Батырлык өчен», «Сталинград оборонасы өчен» медальләре белән бүләкләнгән.

Кыяметдин Ситдыйков авылдашы Саяда Гыйлебаян кызы белән гаилә кора, балалары Мулламөхәммәт (1947–1967), Сәния (1950), Рәзинә (1953), Фәнил (1959), Наил (1957), Рәшит (1961), Ләлә (1966) туа. Тыныч тормышта да батырлык күрсәтергә була, Наил Кыям улы Ситдыйковның (1957) »СССР дәүләт чикләрен саклауда батырлык күрсәткән өчен» медале белән бүләкләнүе шул хакта сөйли.

Нурулла Мөхәммәтситдыйкъ улының Маһирә Гыйльметдин кызы белән никахыннан Хәмидулла (1920; Ватан сугышына китә), Шәрхемулла (25.02.1924), Гыйльмулла (29.05.1925–1938), Хәдичә (1930–1940), Галия (1934–1940) дөньяга килә. Нурулла Ситдыйков турында «Үткәннәрен бел Катайның» китабында әйтеп үттек.

Мөхәммәтнәби Габделханнан улы балалары: Хаҗиәхмәт (15.08.1874), Хаҗгали, Гыйльмениса (15.02.1877; анасы Хәсбиниса), Хәерниса (1881), Гайшә (15.11.1882), Бибигайшә (1884), Хәмдесафа (20.04.1885), Галиәхмәт (07.05.1889), Гыйльмисафа (12.06.1892; анасы Хәсбиниса, Күгәрчен авылыннан), Фәхеркамал (23.08.1907; анасы Латыйфакамал Мөхәммәтҗан кызы), Фәхерҗиһан (1908–1910), Гайникамал (12.11.1910; анасы Латыйфакамал Гайнулла кызы, Рәҗәпнеке), Майкамал (1913–1914, чәчәк авыруыннан вафат). Мөхәммәтнәби

кызы Хәерниса (18 яшь) 1900 елның 20 гыйнварында Корычның Гыйндулла Гыйбадулла улы (25 яшь) белән кавыша. Икенче кызы Бибигайшә (18 яшь) 1903 елның 3 мартында Сеңрәннең Мирзахәниф имам Мөхәммәтхәниф улы (26 яшь) белән кавыша. Өченче кызы Гыйльмисафа (18 яшь) 1910 елның 25 гыйнварында Килкабызның Фәхрислам Фәхретдин улы (23 яшь; атасы Фәхретдин Гыйсмәтулла улы) белән никахлаша, әмма өч елдан аерылып, 1913 елның 3 октябрендә Камышлының Мөхәммәтгәрәй Габделкаһир улы (45 яшь) белән гаилә кора (икенче никахлары). Гыйльмисафаның беренче никахында ризалык шаһитлары – абыйсы Хаҗиәхмәт Мөхәммәтнәби улы һәм нәселдәше Нургали Мөхәммәтсафа улы, икенчесендә абыйсы Хаҗиәхмәт Мөхәммәтнәби улы белән Мөхәммәтдин Миңлесафа улы була. 58 яшьлек Мөхәммәтнәби Габделханнан улы хатынсыз калгач, 1906 елның 19 декабрендә Бибисабира Габделгани кызы (50 яшь) белән никахка керә. Икесенең дә – өченче никахлары, ризалык шаһитлары Хәйдәргали Минһаҗетдин улы белән Фәхретдин Гыймадетдин улы була. Мөхәммәтнәби Ханнанов 1917 елда хатыны (55 яшь), улы һәм кызы белән яши, 9,28 дисәтинә җире, 3 аты, сыеры, 4 сарыгы һәм 2 кәҗәсе була. Мөхәммәтнәбинең төпчек кызы Гайникамал (1910) авылдашы Мөхәммәтситдыйкъ Исламов белән никахлаша.

Хаҗиәхмәт Мөхәммәтнәби улы (21 яшь) 1895 елның 23 ноябрендә авылдашы Мөхәммәтнасыйп Сафиулла улының кызы Шәмсезиядә (18 яшь; Табыш нәселеннән) белән никахлаша. Егетнең ризалык шаһитлары Гарифулла Кәлимулла улы (тамгасы Юлдаш нәселеннән икәнлеген күрсәтә) белән Мөхәммәтситдыйкъ Габделханнан улы була. Хаҗиәхмәт балалары: Хәдичә (23.12.1897), Фатыйма (12.11.1900), Хоббәтелислам (09.01.1902), Суфиәхмәт (16.09.1903), Мирзаәхмәт (04.10.1906–1993), Бибигайшә (13.06.1909–1909, кызамыктан вафат), Латыйфа (1912; метрикәдә теркәлмәгән), Миңлекамал (1915–1916, чәчәктән), Заһит (1918; Ватан сугышы ветераны) була. Хаҗиәхмәт Мөхәммәтнәбиев 1917 елда хатыны (44 яшь), ике улы, өч кызы һәм бер хезмәтчесе (41) белән яши, 18,93 дисәтинә җире, 4 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була.

Суфиәхмәт Нәбиев Яңа Катайның Мөхәммәтхәтим Күчемов кызы Мөшәррәфә (1908) белән гаилә кора, балалары Мәвазиф (1932) һәм Рузалин (1934) була. Мирзаәхмәт Нәбиев авылдашы Әхмәтзәки Мөхәммәтшәфикъ улының кызы Миңлесабира белән никахлаша, балалары Ләйлә (1930), Фәез (1936), Люция (1939), Гайшә (1941), Риф (1944), Хәдичә (18.08.1946) һәм Ралиф (1948) туа. Заһит Нәбиевне 1939 елда хәрби хезмәткә чакыралар, шуннан сугышка керә, инвалид булып кайта. Яңа Катайның Әхмәтнәгыйм Госманов кызы Халә (1924) белән балалары: Әнүзә (1945), Әлфинә (1950), Мөзәмил (1951), Мөнәвир (1953), Диләвир (1956), Рәвис (1958) һәм Венера (1961).

Габделханнанның төпчек улы Нурлыгаяннан бары бер бала, Муллагаян (04.11.1907; анасы Зәкия Бәдретдин кызы) була.

Гобәйдулланың икенче улы, әйтеп киткәнебезчә, Хәлилулла (Хәлиулла) иде. Хәлилулланың хатыннары Мөхибҗамал Габдерәшит кызы (1826) белән

Миңлежамал Фәтхулла кызы (1828) була. Хәлилулла Гобәйдулла улы балалары: Миңлехәлим (1847; исеме бер чыганакта ялгыш Габделхәлим дип язылган), Гыйльмиҗамал (1853), Габидулла (1858), Шаһидулла (Шәйдулла; 1858), Заһидулла (Зәйдулла; 1863), Шәйхулла (1867), Шәмсесорур (1882–1887), Шәйхелислам (15.12.1884–1888), Миңлехафизә (11.07.1887–1888), Шәмсеҗиһан (02.06.1891–1904; анасы Сәрвиҗамал Мөхәммәтәмин кызы).

Миңлехәлим Хәлилулла улы балалары: Бибифатиха (29.12.1880), Миңлехәтимә (05.11.1883), Сәлимгәрәй (1885), Бибихәтирә (26.11.1890–1893), Миңлегәрәй (05.08.1895; анасы Латыйфа Камышлының Мәдияр кызы), Миңлехәтирә (03.09.1898; анасы Латыйфа Камышлының Мөхәммәдьяр кызы), Хәтимә (1899–1902). Миңлехәлим кызы Фатиха (18 яшь) 1902 елның 7 ноябрендә Тыпыйның Газетдин Галләметдин улы (23 яшь; атасы Галләметдин Габдерәшит улы) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Нуриәхмәт Мөхәммәтсафа улы белән Габидулла Хәлилулла улы була. Сәлимгәрәй Миңлехәлим улы (25 яшь) 1910 елның ноябрендә авылдашы Галиулла Шәрифулла улының кызы Гыйльмениса (18 яшь) белән никахлаша. Миңлехәлим Хәлиуллинның олы улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (60 яшь), кече улы (22) һәм кызы (15) белән яши, 4,42 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була.

Миңлегәрәй Хәлимов (1895–1945) – Ватан сугышы ветераны, сугыш алды елларында гаиләсендә хатыны Кәримә (1897), балалары Бибирәхимә (25.08.1924; анасы Кәримә Шәрәфетдин кызы), Миңлегалим (15.01.1928–27.06.2014), Рәфига (1934), Заһидә (1939) була. Миңлегалим белән Мәрфуга Кәрам кызы (1924–09.08.1979; Иске Катайның Кәрам Кашапов кызы) балалары: Нәзифә (09.11.1955), Мөнәвир (11.07.1957–18.04.2019), Мөдәмир (10.07.1959–06.10.2009), Рәмзия (29.12.1960), Рәзинә (05.01.1963), Рәфизә (11.02.1967). Әлеге мәгълүматны Нәзифә Миңлегалим кызы язып җибәрде.

Габидулла Хәлилулла улы балалары: Шәйхенур (13.12.1883), Гыйльмиҗиһан (25.06.1887–1888), Ярулла (1892–1892), Шәмсехәят (02.06.1894–1895, кызамыктан; анасы Шәмсебанат Баһаутдин кызы), Әсәдулла (21.04.1909; анасы Фәрхиҗамал Хәйрулла кызы), Сәхипкамал (1910–1911), Гаделбану (1912–1914), Шәмсебану (23.09.1917). Шәйхенур Габидулла улыннан Заһидия (29.02.1916; анасы Бибигалия Әхмәтлатыйф кызы) билгеле.

Шәйдулла Хәлилулла улы балалары: Гыйльмиҗиһан (25.01.1887), Насыйбулла (23.02.1891; анасы Хәмденисә Баекның Вәлишә кызы), Бибимөшәррәфә (1892–1893), Гайниҗамал (11.02.1895–1895; анасы Сәрвиҗамал Килкабызның Шиһабетдин кызы). Насыйбулланы Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1916 елның 15 июлендә башы яралана. Шәйдулла Хәлиуллин 1917 елда хатыны (57 яшь) белән яши, 0,81 дисәтинә җире, аты һәм 2 кәҗәсе була.

Заһидулла Хәлилулла улы балалары: Шәрифулла (13.12.1892; анасы Гайнелхәят Габделхаликъ кызы), Хөснулла (11.09.1903), Шәмсебануа (21.10.1909–1911), Гаделбану (03.09.1912). Заһидулла Хәлиуллинның олы улын Беренче

бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (50 яшь), кече улы һәм кызы белән гомер итә, 3,44 дисәтинә җире, 2 аты һәм 4 кәҗәсе була.

Шәйхулла Хәлилулла улы балалары: Галимулла (28.01.1911–1916), Гатифә (13.11.1915; анасы Фатиха Мөхәммәтзариф кызы). Шәйхулла Хәлиуллин (50 яшь) 1917 елда хатыны (47) һәм кызы (4) белән яши, 2,19 дисәтинә җире, аты, 2 кәҗәсе була.



**1885 елгы никах язуында аста Рәхмәтулла Хәбибулла улы (сулда) белән Сафиулла Рәхмәтулла улы нәсел тамгасын (түгәрәк астында сызык) салганнар**

Югарыда сүз Зәйнелгабидиннның өлкән улы Гобәйдулладан киткән тармаклар турында барды. Зәйнелгабидиннның икенче улы Хәбибулла да нәсел ишәюгә өлеш кертә, Рәхмәтулла (1821–09.04.1899) һәм Кәлимулла (1830) исемле уллары була.

Рәхмәтулла Хәбибулла улы балалары: Мохтарулла (1848), Сафиулла (1854), Галиулла (1859), Миңлеҗиһан (1867), Шәйхулла (1870), Шәмсекамал (1873–1892), Әхмәтвәли (16.12.1880), Фәрхеруй (1882), Шәмсенур (06.10.1883), Миңлеәхмәтгәрәй (14.07.1886), Миңлевәдига (11.03.1889; анасы Фәрхиҗиһан Әделгәрәй кызы). Рәхмәтулла кызы Миңлеҗиһан (18 яшь) 1885 елның 5 декабрендә Балыклының Сәетгәрәй Сәлимгәрәй улы (22 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Хәлилулла Гобәйдулла улы белән Сафиулла Рәхмәтулла улы була. Рәхмәтулланың икенче кызы Фәрхеруй (19 яшь; икенче никах) 1902 елның 3 гыйнварында Яңа Катайның Әхтәмҗан Мөхәммәтҗан улы (26 яшь; икенче никах) белән кавыша. Бу никахы да озакка бармый, 1903 елның 25 октябрендә Фәрхеруй (20 яшь) Минзәлә өязе Әмәкәй авылының Миңлегали Габделгалләм улы (23 яшь) белән кавыша.

Мохтарулла Рәхмәтулла улы балалары: Төхфәтулла (01.08.1876; анасы Хәйрелбанат), Миңлекамал (1878–1892), Мәргубҗамал (04.10.1881), Мөхәммәтхафиз (04.11.1883), Шәмсия (20.10.1885–1887), Хәйрулла (1887–1888), Миңлегалия (29.07.1889), Гобәйдулла (08.10.1893; анасы Гайниҗамал Яңа Катайның Миңлегәрәй кызы), Тимергали (28.08.1900; анасы Мәхтүмә Иске Катайның Фәйруша кызы), Бибилатыйфа (29.02.1902), Хәтим (27.02.1904), Миңлемәгъсүмә (13.11.1905), Әхмәдулла (15.05.1907), Сәфәргали (14.02.1910), Гыйлемхан (05.01.1912–1912), Миңлесәфирә (04.05.1914). Мохтарулла Рәхмәтуллин 1917 елда хатыны (45 яшь), өч улы һәм ике кызы белән яши, 4,23 дисәтинә җире, 3 аты һәм башка маллары була.

Сафиулла Рәхмәтулла улы балалары: Миңлесәйфулла (25.11.1884), игезәкләр Хәсән белән Хөсәен (12.01.1887), Гыйндулла (02.03.1890), Хәйрулла (11.02.1893–1899; анасы Шәрифҗамал Куянның Галиулла кызы), Шәмсекамал (15.07.1895). Сафиулла Рәхмәтуллинның ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда оныгы (1 яшь) һәм килене (20) белән яши, 5,05 дисәтинә җире, 2 аты, 11 сарыгы, 2 кәҗәсе була. Гыйндулла Сафиулла улыннан Миңлерәдanә (23.01.1925; анасы Миңлеҗиһан Мөхәммәтгәрәй кызы) туа.

Шәйхулла Рәхмәтулла улы Яңа Катайның Маһикамәр Гыйльметдин кызы белән гаилә кора, балалары Шәрифә (22.04.1901), Галиулла (23.03.1904), Әгъләметдин (09.06.1909–1916), Саимә (09.01.1907–1912), Мөхәммәтхәниф (03.09.1911), Әгъләметдин (27.06.1913), Кифая (06.09.1917) дөньяга килә. Шәйхулла Рәхмәтуллин (47 яшь) 1917 елда хатыны (35 яшь), улы һәм ике кызы белән яши, 4,29 дисәтинә җире, аты, 3 кәҗәсе була. Йөкче булып ялланган.

Әхмәтвәли Рәхмәтулла улы 1907 елның 1 ноябрендә авылдашы Шәмсия Фәхрислам кызы (18 яшь; атасы Фәхрислам Габделихсан кызы) белән никахлаша, балалары Мөгаллимә (28.11.1909), Фәйрүзә (23.12.1911–1912), Рәхимә (09.03.1914), Миңлемәгъдәния (03.07.1916) туа. Әхмәтвәли Рәхмәтуллин (35 яшь) 1917 елда хатыны (25), кызы һәм энесе белән гомер итә, 5,05 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры, 4 сарыгы, 2 кәҗәсе була. Метрикәдә Миңлемәгъдәния исеме өстенә 1936 елның 15 апрелендә туу турында белешмә алуы язып куелган.

Кәлимулла Хәбибулла улының хатыны Бибилатыйфа Хатымтай кызы (1832), балалары Миңлехәкимә (1854), Бибихәтимә (1857), Вәлиулла (1859–1909, йөрәктән вафат), Нәбиулла (1865–1946), Вәлиәхмәт (1868–14.01.1915) була.



**Кәлимулла Хәбибулла улы нәсел тамгасын салган документ фрагменты. 1860 ел**

Вәлиулла Кәлимулла улы (25 яшь) 1883 елның 17 августында Килкабызның Маһисорур Габделханнан кызы (25 яшь, икенче никах; атасы Габделханнан Габделхаликъ улы) белән гаилә кора. Вәлиулла балалары: Галиулла (05.08.1887), Шәмсенур (01.09.1888; анасы Маһисорур), Бибисорур (1891), Мөсәвәрә (21.09.1894–1895; анасы Маһинур Әлмәт авылының Мәһди кызы), Мотыйгулла (1895–1897), Нигъмәтулла (28.01.1899), Габдулла (04.05.1901), Бибинур (29.10.1904; анасы Маһисорур), Гыйззенур (1907–1909; чәчәк зәхмәтеннән), Мотыйгулла (16.04.1910–1911). Вәлиулла кызы Шәмсенур (18 яшь) 1905 елның 16 декабрендә Килкабызның Гыйльметдин Фәхретдин улына (26 яшь) кияүгә чыга. Кызның ризалык шаһитлары Хөрмәтулла Хәбибулла улы белән Шәйхулла Рәхмәтулла улы була. Икенче кызы Бибисорур (18 яшь) 1909 елның ноябрендә Яңа Катайның Габдулла Габделгазиз улы белән никахлаша. Кызның

ризалык шаһитлары Әхмәтвәли белән Шәйхулла Рәхмәтулла уллары була. Бу никах барып чыкмый, 1912 елның 1 августында «мәхәббәтләре юклык сәбәпле» аерылышалар.

Вәлиәхмәт Кәлимулла улы балалары: Галиәхмәт (16.04.1891–1894), Җаниәхмәт (29.07.1898; анасы Кәримә Катайның Ибраһим кызы), Миңлесәрия (18.05.1903–1912), Суфиәхмәт (17.07.1906), Фәүзия (16.05.1910–1912).

Нәбиулла Кәлимулла улы (25 яшь) 1893 елның 19 ноябрендә Яңа Катайның Габделҗаббар Габделгаффар улының кызы Хушҗамал (19 яшь) белән никахлаша. Нәбиулла балалары: Нурулла (02.12.1894; анасы Хушҗамал), Ярулла (25.12.1897), Фатыйма (1899), Хәтирә (09.12.1900–1902), Шәрифулла (05.02.1903), Гарифулла (23.12.1906; анасы Мәгъшукҗиһан Габделҗаббар кызы), Сөнәгатулла (09.01.1910; анасы Мәгъшукҗиһан), Хәтимә, Бәһия (1915), Җәүһәрә (Җәүрә; 24.03.1924; анасы Гыйльмисафа Бәдретдин кызы), Хәдичә (1928), Хәзинә белән Ханә (1939; игезәкләр). Нәбиулла кызы Фатыйма 1917 елның 3 декабрендә авылдашы Әхияретдин Фәхретдин улына кияүгә чыга. Нәбиулла Кәлимуллинның (48 яшь) ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда ике хатыны (20 һәм 26 яшьләрдә), калган дүрт улы, туганының улы (16), ике кызы белән яши, 9,88 дисәтинә җире, 4 аты, 2 сыеры һәм башка маллары, ярма яргычы була. 1931 елда Нәбиулла картны олы яшьтә, ишле гаиләле дип тормаганнар, «кулаклык»та гаепләп, өеннән чыгарганнар. Сөйләп бетергесез зур авырлыклар кичерергә туры килә бу гаиләгә.

Хәмит абый Маликов Нәбиулла картны япон сугышында катнашкан, хатыннары Хупҗамал белән Гыйльмисафа дип сөйләде. Нәбиулланың балалары күп булганлыктан, һәрберсен сораштыру озакка китә иде, шулай да улы турында сорап, аннан нәселне Әсгать дәвам иткәнен кәгазьгә теркәп куйганмын. Нәбиулланың 1904 һәм 1905 елда бер баласы да тумаган, димәк, ул бу вакытта, Хәмит абый әйткәнчә, 1904–1905 елгы япон сугышында булган.

Нурулла Нәбиуллин 1917 елның 11 октябрендә авылдашы Галләметдин Гыймадетдин улының кызы Мөнәвәрә (18 яшь) белән никахлаша. Әлеге никахтан Мәгъсүм (1921), Миңлеҗәүһәрия (16.04.1925) һәм башка балалар туа. Мәгъсүм Нуруллин Ватан сугышында һәлак була (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Ярулла Нәбиуллин 1918–1922 елларда гражданнар сугышында катнаша, кайткач авылдашы Мөхәммәтхарис Нурмөхәммәт улының кызы Бибиәсма (1897) белән гаилә кора, балалары Мөдәррис (25.05.1925), Фәнәхия (1936), Расих (1940; Калтасыда яшәгән) туа. 1942 елның 15 гыйнварында Ватан сугышына китә, «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале (09.06.1945) белән бүләкләнеп исән-имин кайта, ә менә аның улы Мөдәррис Нәбиуллин Украинадагы сугышларда башы яраланып, 1943 елның 10 октябрендә госпитальдә мәрхүм була (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Югарыда без Нәдернең Зәйнелгабидиннән киткән тармагын карадык. Нәдернең икенче улы Сәгъди (Сәгъдетдин 1764–1800) дә зур нәсел калдыра.

Сәгъди (Сәгъдетдин) уллары: Фәрхетдин (Фәхретдин; 1802–1854), Гайнетдин (1804–1852). Фәрхетдин Сәгъдетдинов уллары: Гыймадетдин (1836), Камалетдин (1844–16.04.1907). Гыймадетдин Фәрхетдин (Фәхретдин) улы балалары: Фәррахетдин (1867–29.01.1910), Миңлекамал (29.05.1889), Шәмсекамал (02.07.1891–1898; баш авыруыннан вафат; анасы Бибикамал), Мифтахетдин (16.08.1894–1898; әбсе зәхмәтеннән), Фәтхетдин (29.05.1897), Шәмсеҗамал (28.09.1898–1899, ютәл авыруыннан; анасы Бибикамал Манчар авылының Шиһабетдин кызы).

Фәррахетдин Гыймадетдин улы (25 яшь) 1892 елның 24 июнендә авылдашы Сәхипкамал (18 яшь; атасы Фәррахетдин Фәхретдин улы) белән никахлаша, балалары Сәлахетдин (04.12.1894; анасы Сәхипкамал Фәрхетдин кызы), Раҗетдин (23.06.1904–1909, кызамыктан), Миңлекамал (25.12.1906–1910) туа.

Камалетдин Фәрхетдин улы балалары: Хәйретдин (02.01.1876; анасы Фәйрузкамәр), Имаметдин (1879), Миңлекамәр (10.01.1882), Миңлешәмсия (1883). Камалетдин кызы Миңлекамәр (21 яшь; икенче никах) 1902 елның 10 декабрендә Иштирәкнең Гайнулла Ибраһим улы (26 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Миңлеситдыйкъ белән Мөхәммәтнәби Габделханнан уллары була. Икенче кызы Миңлешәмсия (18 яшь) 1901 елның гыйнварында Яңа Катайның Мөхәммәткәрип Бәдретдин улы (26 яшь) белән никахлаша.

Имаметдин Камалетдин улы (30 яшь; икенче никах) 1909 елның гыйнварында Килкабызның Хәерниса Заһидулла кызы (27 яшь; өченче никах) белән никахлаша, балалары Баязит (03.07.1913), Гыйльмисафа (27.02.1917) туа. Имаметдин Камалетдиновның олы улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (45 яшь) һәм төпчек улы белән яши, 4,26 дисәтинә җире, аты була.

Нәдернең өченче улы Габидулладан Габделгани (1813) туган, тик аның нәселен дәвам итүче ир балалар юк.

Шулай итеп, Гобәй нәселе Иске Катайда чагыштырмача аз санлы нәсел булып тора. Нәсел кешеләре беренче мәхалләдә теркәлгән, димәк, алар Катайга Юлдаш нәселе һәм аның ерак нәселдәшләре белән бер чорда килеп утырган.

# VII бүлек. Бишенде нәселе

Бу нәселнең Катайга кайчан күчеп килүе хакында «Үткәннәрен бел Катайның» китабында әйтеп үттек, шуңа күрә кабатлап тормыйбыз. Октябрьский шәһәре янындагы Түбән Бишенде авылыннан булуларын истә тотып, аны шартлы рәвештә «Бишенде нәселе» дип атау дөрес булыр кебек.

Күченеп килүчеләр Катайда чирек гасырдан күбрәк яшәсәләр дә, авылның рәсми исемлекләрендә беренче тапкыр 1859 елда теркәлә. Шуңа күрә нәселне шул ел исемлегенә һәм метрикә мәгълүматына таянып карыйбыз. Кызыксынучылар Түбән Бишенденең борынгырак исемлекләрен һәм тарихын өйрәнеп, нәсел турында белемнәрен арттыра һәм тирәнәйтә алалар, бу китапта исә андый максат куелмады.

Иске Катайның 1859 елгы исемлегендә теркәлгән ике Түбән Бишенде гаиләсенең беренчесе итеп Вәлимөхәммәт Габделгазизов (1798) гаиләсе күрсәтелә. Вәлимөхәммәт уллары: Нурмөхәммәт (1835–25.03.1917; 1917 елгы метрикәдә нәсел фамилиясе Габделнасыров дип бирелә), Мөхәммәтхафиз (1841), Мөхәммәтшәфикъ (1845–1899), Мөхәммәтзариф (1848), Мөхәммәтсадыйк (1855), Мөхәммәтсафа (1859).

Нурмөхәммәт Вәлимөхәммәт улы балалары: Мөхәммәтхарис (1862), Сәрвиҗиһан (1864), Мөхәммәтгариф (1871–10.03.1881), Мөхәммәтлатыйф (26.02.1881–1888), Мулламөхәммәт (01.08.1874–1902), Шәмсемөхәммәт (02.04.1877–1899; анасы Хәбибҗамал). Нурмөхәммәт кызы Сәрвиҗиһан (25 яшь) 1887 елның 2 мартында Дөмәйнең Имаметдин Гыймадетдин улы (27 яшь; атасы Гыймадетдин Тәхаутдин улы) белән кавыша.

Мөхәммәтхарис Нурмөхәммәт улы балалары: Мөхәммәтхәтим (22.05.1892), Шәймөхәммәт (1896–28.08.1980), Бибиәсма (1897; авылдашы Ярулла Нәбиуллинга кияүгә чыга), Дөрәсма (28.09.1899; анасы Шәмсенур Тыпыйның Габдерәкыйп кызы), Шәмсемөхәммәт (15.01.1903), Мәрьям (19.08.1905), Муллаәхмәт (28.03.1908; анасы Шәмсенур Галләметдин кызы), Миңлехөснә (21.03.1911), Газим (14.06.1914; метрикәдә исеме Мөхәммәтгазый, анасы Шәмсенур Галләметдин кызы дип язылган). Мөхәммәтхарис Нурмөхәммәтовның (55 яшь) бер улын (21 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (50 яшь), дүрт улы һәм ике кызы белән яши, 10,93 дисәтинә җире, 4 аты, 4 сыеры һәм башка маллары була, даими эшче яллый.

Мөхәммәтхәтим Мөхәммәтхарис улы (26 яшь) 1917 елның 13 октябрендә авылдашы Бибихәдичә Дәүләтгәрәй кызы (18 яшь; атасы Дәүләтгәрәй Конгыр-



**Мөдир абый белән. 2018 ел**

бай улы) белән никахлаша, балалары Гамил (1920; Ватан сугышы ветераны), Мөхәммәтшамил (21.01.1925) дөньяга килә.

Шәймөхәммәт белән Мәрзия Мөхәммәтзакир кызы (Тыпыйныкы) Харисовлар балалары: Миңлеридәнә (15.10.1924), Мөдир (1933), Әнүдә (1939), Рәйханә (1942). Шәймөхәммәт Харисов – Беренче бөтендөнья һәм Бөек Ватан сугышы ветераны. Шәйми бабай белән аралашу күңелле, агач (столяр) һәм бакча эшен яратып эшли торган иде, китап-гәзит укырга яратты, университетта беренче курста укыганда миңа Тукайның үзе исән вакытында чыккан, гарәп имлясы белән язылган бер китабын укырга биреп торганы искә төшә. Мөдир Шәймөхәммәт улы Харисовның төп хезмәт биографиясе Бакалы КПСС райкомы белән бәйле булды. Монда ул 1964 елның 1 июлендә инструктор-пропагандист булып килеп, озак еллар оештыру-инструкторлар бүлеге мөдире (1968–1975), гомуми бүлек мөдире (1975–1985), аннары район мәгариф бүлегендә инспектор (1985–1998) булып эшләде.

Шәмсемөхәммәт Харисов (1903) 1942 елда сугышта хәбәрсез югала, хатыны Саимә Гайнетдин кызы, балалары Мәхүбә (1930), Сәһлә (1931), Мәкки (1934), Вәсилә (1936), Нәсимә (1938) кала. Таянычсыз калган, балаларын ач үлемнән коткарам дип, кечкенә «гаеп» аркасында төрмәгә эләккән Саимә Харисова турында беренче китаптагы Әлфия апа Хәйдәрова истәлекләрендә әйтелде. Газим Харис улы Харисов (1914) – Ватан сугышы ветераны, аның турында да беренче китапта әйтеп үттек.

Мөхәммәтхарисның энесе Мулламөхәммәт Нурмөхәммәт улының Хәмидә исемле кызы (03.05.1901; анасы Мәмдуха Үрмәт авылының Габдулла кызы) билгеле.

Вәлимөхәммәт Габделгазизовның икенче улы Мөхәммәтхафиз иде. Мөхәммәтхафиз Вәлимөхәммәт улы балалары: Мифтахетдин (1878–1903), Маһикамал (Майкамал; 1879), Миңлемөхәммәтгали (10.08.1884), Бибикәшифә (28.09.1888; анасы Гафифә), Әхмәтгәрәй (05.06.1894; анасы Гафифә Балак авылының Әгузәр кызы), Мөхәммәтфатих (21.09.1899). Мөхәммәтхафиз кызы Маһикамал (18 яшь) 1897 елның 30 декабрендә авылдашы Исхак Сәхипбаян улы (25 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Бибикәшифә (18 яшь) 1907 елның ноябрендә авылдашы Мөхәммәтшәех Мөхәммәтсадыйк улы (27 яшь; атасы Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтсафа улы) белән гаилә кора. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтназиф белән Мөхәммәтгариф Мөхәммәтзариф уллары була. Мөхәммәтгали Мөхәммәтхафиз улы (22 яшь) 1909 елның 19 декабрендә

авылдашы Дәүләтгир Дәүләтбай улының кызы Бибишәрифә (18 яшь) белән кавыша.

Вәлимөхәммәт Габделгазизовның өченче улы Мөхәммәтшәфикътан да нәсел дәвам итә. Мөхәммәтшәфикъ Вәлимөхәммәт улы балалары: Бибимәстүрә (1874), Мөхәммәтшәех (15.07.1883), Бибигарифә (29.09.1890). Мөхәммәтшәфикъ кызы Бибимәстүрә (18 яшь) 1892 елның 21 декабрендә Камайның Насретдин Фәхретдин улы (25 яшь; атасы Фәхретдин Исхак улы) белән никахлаша. Шул ук Бибимәстүрә (22 яшь; икенче никах) 1895 елның 15 гыйнварында авылдашы Солтангәрәй Мөхәммәтгәрәй улы (26 яшь; вәкиле Әһлиулла Шәяхмәт улы) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтзакир Мөхәммәтшәфикъ улы белән Мөхәммәтсафа Вәлимөхәммәт улы була. Бибимәстүрәнең бу никахы да уңышлы булмый, 1898 елның 14 сентябрендә Балыклы мишәре (документта шулай язылган.– *Т.К.*) Сәхипгәрәй Солтангәрәй улы (25 яшь; атасы Солтангәрәй Мортаза улы) белән никахлаша. Егетнең ризалык шаһитлары Шәнгәрәй Мортаза улы белән Сәлимҗан Салават улы була.

Вәлимөхәммәт Габделгазизовның дүртенче улы Мөхәммәтзарифка тукталыйк. Мөхәммәтзариф Вәлимөхәммәт улы балалары: Мөхәммәтназиф (10.08.1875; анасы Гайшә), Мөхәммәтгариф (25.03.1882–1883), Миңлефәрхеруй (08.05.1884–1888), Бибигалимә (06.08.1887; анасы Гайшә). Мөхәммәтзариф кызы Шәмсеруй (18 яшь) 1900 елның 20 гыйнварында Корычның Габдулла Вәлиша улы (26 яшь; атасы Вәлиша Сәетборһан улы) белән кавыша. Шунысы аеруча игътибарга лаек, никах язуында Вәлиша Сәетборһан улы салган тамга Яңа Катайның Азамат нәселе тамгасы белән тәңгәл килә.

Мөхәммәтзарифның кече кызы Бибигалимә (18 яшь) 1904 елның мартында авылдашы Габдерәкыйп Мөхәммәтлатыйф улы (25 яшь; атасы Мөхәммәтлатыйф Габделвафи улы) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары – Мөхәммәтсафа Вәлимөхәммәт улы белән Әхмәтвәли Җәләлетдин улы, егетнеке Мөхәммәтхафиз Вәлимөхәммәт улы белән Мөхәммәтшакир Могтәметдин улы була. 1917 елда Мөхәммәтзариф Вәлимөхәммәтов хатыны һәм улы (15 яшь) белән яши, 4,45 дисәтинә җир эшкәртә, аты, 2 сыеры, 2 бозавы була.

Мөхәммәтназиф Мөхәммәтзариф улы балалары: Мөхәммәткә-



**Корычның Вәлиша Сәетборһан улы салган тамга Яңа Катайның Азамат нәселе тамгасы белән тәңгәл килә**

шиф (16.01.1901; анасы Хәмдия Камайның Гыйззәтулла кызы), Миңлезадә (19.11.1902), Мөхәммәтнасыйп (28.10.1904), Мөхәммәтсалих (12.09.1906), Мөхәммәтгариф (10.07.1908), Мөхәммәтзаһир (12.08.1910), Мөхәммәтзаһит (06.09.1911), Бибимәмдүдә (27.08.1914; анасы Хәмдия), Әхмәтзариф (03.08 1915; анасы Шәмсенур Хөснетдин кызы), Мөхәммәтшәфикъ (1920–1924). Насыйп (1904) белән Гариф (1908) Зариповлар Ватан сугышына китәләр (исемнәре Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән), беренчесе 1943 елда хәбәрсез югала, икенчесенең язмышы билгесез. Заһит Назиф улы Зарипов (1911) – сугыш ветераны, кече лейтенант була, «Кызыл Йолдыз» ордены (07.10.1943) бүләкләнә (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Вәлимөхәммәт Габделгазизовның бишенче улы Мөхәммәтсадыйк балалары: Мөхәммәтсалих (1883–1883), Миңлегыйльмиҗиһан (15.04.1884), Шәмсеҗиһан (14.07.1888–1889; анасы Миңлеҗиһан), Бибинәфисә (07.11.1890), Бибисара (29.07.1892), Гыйльмезиядә (23.11.1899; анасы Миңлеҗиһан Корычның Хөснетдин кызы), Гыйльмениса (21.10.1904; анасы Гөлҗиһан Хөснетдин кызы). Мөхәммәтсадыйк Вәлимөхәммәтовның (62 яшь) улын (20) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (60) һәм кызы белән яши, 4,29 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була.

Вәлимөхәммәт Габделгазизовның алтынчы улы Мөхәммәтсафа балалары: Миңлемөхәммәтхәтим (22.02.1891), Бибизакирә (20.10.1892–1900, чәчәк авыруыннан вафат), Миңлефәрханә (08.08.1895–1900; анасы Хәмдия Сәкәшнең Габделбаян кызы), Мөхәммәтнәгыйм (03.12.1897), Тимерхан (12.03.1900–1978), Бибизакирә (21.09.1902; Рәиф Әхмәтхановның анасы), Әбүнәгыйм (05.10.1907; анасы Хәмдия Габделбаян кызы), Нурдидә (1910), Мөхәммәтфазыйл (03.02.1912). Мөхәммәтсафа Вәлимөхәммәтовның олы улын (20 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны, өч улы һәм ике кызы белән яши, 14,84 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була. Хезмәтче тота, умартачылык белән шөгыльләнә.

Мөхәммәтсафа Вәлимөхәммәтовның өч улы – Мөхәммәтнәгыйм, Тимерхан Сафиннар, Фазыйл Вәлиев – Ватан сугышы ветераннары. Әбүнәгыйм Вәлиев (1907) »Байкал» колхозында механик булып эшли, 1942 елның 14 июлендә сугышка китә һәм 1944 елда хәбәрсез югала, хатыны Гафия (1912) кала. Мөхәммәтнәгыйм Сафинның улы Тимергазиянны (1924) да сугышка алалар (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән), кайтканмы-юкмы, ачыклый алмадык (аның анасы Хәкимә, сеңелләре Әнисә, Ханә, Әнүзә була). Сугыш ветераннарының балаларына тукталып тормыйбыз, мәгълүмат җитеп бетми.

Вәлимөхәммәт Габделгазизовның энесе Габделвәлидән (1800) Хөснетдин (1832–1908), Шәрәфетдин (1833–1854), Борһанетдин (1847) туа. Болардан нәселне дистәгә якын гаилә дәвам итә.

Хөснетдин Габделвәли улы балалары: Гыйззәтулла (1854–16.02.1882), Төхфәтулла (1859), Хөснулла (1869), Гыйндулла (1872), Шәйхулла (20.10.1874; анасы Фәрхинур), Шәфигулла (25.08.1877), Фәрхисорур (05.09.1880), Зиннәтулла

(11.01.1883), Фәрхизадә (25.05.1885), Сәгъдәтулла (1891–1892). Хөснетдин кызы Фәрхисорур (18 яшь) 1900 елның 18 ноябрендә Туктаголның Мөхәммәтфатих Габделлатыйф улы (22 яшь; атасы Габделлатыйф Габделбасыйр улы) белән никахлаша. Икенче кызы Фәрхизадә (18 яшь) 1904 елның мартында Яңа Катайның Хөрмәтулла Хәлилулла улы (25 яшь) белән кавыша. Егетнең вәли вәкиле – бертуган агасы Шәрифулла Хәлилулла улы, ризалык шаһитлары Шәйгәрәй Тимербулат улы белән Сәлимгәрәй Шәйгәрәй улы була.

Гыйззәтулла Хөснетдин улының кызы Маһисафа (18 яшь) 1895 елның 29 гыйнварында Килкабызның Низаметдин Раҗетдин улы (24 яшь) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле – бабасы Хөснетдин Габделвәли улы, егетнеке Гыйлаҗетдин Раҗетдин улы була.

Төхфәтулла Хөснетдин улы балалары: Гыйззәтулла (25.01.1889–1890; анасы Мәфтуха), Нигъмәтулла (10.08.1899–1900), Лотфулла (10.06.1901; анасы Маһруй Куянның Габдрахман кызы), Әхмәдулла (14.04.1904–1912), Миңлефакия (12.07.1907–1909, кызамыктан вафат), Гыйнаятулла (23.10.1909; анасы Зәкия Габделдаян кызы), Миңлефатыйма (23.08.1911), Фәйзулла (24.09.1913–1914, кызамыктан). Төхфәтулла кызы Мәлүфәне (18 яшь) 1908 елның 25 апрелендә Яңа Катайның Газетдин Саяфетдин улына (26 яшь; агасы Шәрәфетдин вәкил була) кияүгә бирә. Кызның ризалык шаһитлары – Шәфигулла белән Хөснулла Хөснетдин уллары, егетнеке Сәлимгәрәй Шәйгәрәй улы белән Сәйфетдин Фәттахетдин улы була. Төхфәтулла Хөснетдинов 1917 елда хатыны (45 яшь), улы һәм өч кызы белән яши, 4,18 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм 4 сарыгы була, такта яру белән кәсеп итә.

Хөснулла Хөснетдин улы балалары: Зиннәтулла (08.12.1895; анасы Миңлесылу Туктаголның Габделлатыйф кызы), Сәгъдәтулла (05.08.1897), Фазулла (22.11.1899), Гыйниятулла (1903–1905), Миргабитҗан (18.08.1905), Миңлесаимә (27.10.1907), Нигъмәтулла (15.07.1909–1914, кызамыктан; анасы Миңлесылу Габделлатыйф кызы), Оркыя (29.08.1911), Миңлегалиәкрәм (17.03.1914; анасы Миңлесылу Шәйхетдин кызы). Хөснулла Хөснетдиновның (48 яшь) олы улын (21) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (40), 4 улы һәм кызы белән яши, 2,43 дисәтинә җире, аты һәм 3 кәҗәсе була.

Гыйндулла Хөснетдин улы балалары: Закирә (17.10.1900; анасы Бибизәкия Килкабызның Ногман кызы), Нәкыя (02.08.1902), Өммегөлсем (09.12.1906), Бибизәйнәп (15.06.1909–1909, кызамыктан), Нурулла (04.08.1910), Миңлехәниф (03.07.1913). Гыйндулла Хөснетдинов (45 яшь) 1917 елда хатыны (42), улы һәм өч кызы белән яши, 2,65 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры һәм 2 кәҗәсе була. Нурулла Гыйндуллин тракторда эшли, 1942 елның 27 августында сугышка китә һәм хәбәрсез югала (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән), хатыны Саимә (1912), уллары Әхнәф (1934), Фанис (1937) кала.

Шәйхулла Хөснетдин улы балалары: Фәзилә (06.02.1903), игезәкләр Сәфәргали белән Рәкыя (19.01.1905; анасы Фәрхениса Фазулла кызы), Миңлефаризә (11.08.1906; анасы Хәерниса Мофаздал кызы), Галимәрдан (13.08.1908), Ти-

мергали (07.01.1910–1910), Габидулла (10.10.1911). Шәйхулланың төпчек улы Мәрдан Шәйхулла улы Шәйхуллин (1921) сугышка 1942 елда Куйбышев военкоматыннан китә, 1943 елда хәбәрсез югала.

Шәфигулла Хөснетдин улы балалары: Маһисорур (02.09.1904; анасы Бибисорур), Шәрхемулла (23.02.1906; анасы Бибисорур Мөхәммәтхарис кызы), Зәкәрия (26.10.1907; анасы Фәрхисорур Мөхәммәтхарис кызы). Шәфигулла Хөснетдинов (40 яшь) 1917 елда хатыны (35 яшь), ике улы, кызы һәм анасы (70) белән яши, 4,66 дисәтинә җире, аты, сыеры, бозавы һәм 5 сарыгы була.

Габделвәлинең икенче улы Шәрәфетдиннән варис булып Кашшафетдин (1854) кала. Кашшафетдин Шәрәфетдин улы (22 яшь) 1878 елның 1 октябрендә Яңа Катайның Бибишәргыя Нәҗметдин кызы (19 яшь) белән никахлаша, балалары Гайнетдин (02.04.1883–1905), Хәдичә (1886–1889), Афзалетдин (15.06.1890), Бибивәдига (17.06.1892–1911; анасы Бибишәргыя) туа.

Кашшафетдин 1917 елгы исемлектә Габделвәлиев фамилиясе белән теркәлгән, аңа 64 яшь, хатыны (48 яшь), дүрт улы һәм кызы белән яши, 5,82 дисәтинә җире, 4 аты, 3 сыеры һәм башка маллары була. Хәмит абый Маликов Кашшафетдин уллары Кәрам, Кәшбел һәм Кәнзел Кашаповлар, олысы сугышта катнашты, дип әйткән иде. Тик аларның берсе дә Иске Катай метрикәсендә теркәлмәгән, 1917 елгы исемлеккә карап Кәнзел 1907 дә, Кәшбел 1911 елда туган булырга тиеш, дип исәпләп чыгарган идек, югыйсә. Кәрам Кашапов (1895) – Ватан сугышы ветераны, сугыш чоры исемлегендә хатыны Фатиха Мөхәммәтзакир кызы (1904), балалары Мәрфуга (09.09.1924), Мәгариф (1932), Фәнәдия (1935) һәм Фәнәһия (1941) теркәлгән. Метрикәгә Мәрфуга 1974 елның 1 ноябрендә туу турында белешмә алган дип язылган.

Габделвәлинең өченче улы Борһанетдин иде. Борһанетдин Габделвәли улы балалары: Миңлеҗиһан (1870), Хәйретдин (10.06.1875), Имаметдин (09.04.1877), Нуретдин (1878), Хәйдәретдин (08.07.1882), Шәмсеҗиһан (07.09.1884), Мөхәммәтдин (10.10.1886), Фәттахетдин (09.09.1888–1893; баш авыруыннан), Мөхәммәтдин (29.02.1891; анасы Сәрвиҗиһан Сафуан кызы), Шәмсебәдәр (02.09.1893). Борһанетдин кызы Миңлеҗиһан (18 яшь) 1888 елның декабрендә Баекның Габделлатыйф Хәбибулла улы (24 яшь) белән кавыша. Икенче кызы Шәмсеҗиһан (18 яшь) 1908 елның 3 гыйнварында Килкабызның Билал Мөхәммәтәмин улына (23 яшь) кияүгә чыга. Өченче кызы Шәмсебәдәр (18 яшь) 1914 елның 13 гыйнварында Иске Куянның Фәтхелбәян Баһманша улы (25 яшь) белән никахлаша. Борһанетдин Габделвәлиевнең (72 яшь) улын (25) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (57) белән яши, 9,16 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була, даими эшче яллый.

Хәйретдин Борһанетдин улы балалары: Мифтахетдин (1901–1909), Бибигарифә (16.04.1906), Хәнәфи (11.07.1910; анасы Гафифә Дәүләтбай кызы).

Имаметдин Борһанетдин улы балалары: Әсхәбетдин (13.05.1904; анасы Гыйльмехәят Гариф кызы), Шәмсехәят (11.01.1906), Шәмсениса (17.08.1907),

Миңлеәхкәметдин (07.01.1909–1909; анасы Гыйльмехәят Гарифулла кызы), Низаметдин (29.08.1910–1912).

Нуретдин Борһанетдин улы (23 яшь) 1905 елның 21 гыйнварында авылдашы Бибизәкия Гаязетдин кызы (18 яшь; атасы Гаязетдин Фәхретдин улы) белән никахлаша, балалары Җәмгыйтдин (09.04.1907–1914), Әхияретдин (14.07.1909), Рәфәгатдин (03.04.1911) дөньяга килә. Хатынын, ике улын калдырып, Нуретдин Борһанетдинов Беренче бөтендөнья сугышына китә, алга таба язмышы билгесез.

Хәйдәретдин Борһанетдин улы 1899 елның 11 декабрендә Яңа Катайның Дәүләтгәрәй Хәлилулла улы Мортазин кызы Бибигафифә (18 яшь) белән никахлаша. Хәйдәретдин балалары: Фәттахетдин (19.04.1901), Саяфетдин (21.09.1903; анасы Гафифә Дәүләтгәрәй кызы), Әгъләметдин (19.05.1910; анасы Һидая), Гыймадетдин (28.12.1916; анасы Гафифә Дәүләтгәрәй кызы), Мөхәммәтхади (1921; Ватан сугышы корбаны), Миңлезифа (21.10.1924; анасы Әдия Габдулла кызы), Әүхади (1928). Әүхадинең улы Дәниф – Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, туган районы икътисадына өлеш керткән авылдашларымнан берсе.

Мөхәммәтдин Борһанов 36 нчы Себер укчы полк составында Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, 1915 елның 8 июлендә һәлак була.

Түбән Бишендедән Катайга күчеп килгән икенче гаилә башлыгы – Габделнасыйр Мостафин. Габделнасыйр балалары: Мифтахетдин (1809–09.11.1878), Камалетдин (1813), Җамалетдин (1833), Гаязетдин (1842), Гайшә (1843).

Мифтахетдин Габделнасыйр улы балалары: Җәләлетдин (1838), Миңлегәрәй (1840–23.09.1916), Әхмәтгәрәй (1850), Хәкимә (1858). Мифтахетдин кызы Хәкимә (20 яшь) 1878 елның 15 гыйнварында Яңа Катайның Әбүнәгыйм мулла Хөснетдин улы (22 яшь) белән гаилә кора. Кызның ризалык шаһитлары туганнары Миңлегәрәй белән Әхмәтгәрәй Мифтахетдин уллары була.

Җәләлетдин Мифтахетдин улы Габделнасыйров балалары: Әхмәтвәли (1863), игезәкләр Гыйлаҗетдин (04.10.1874–1878) белән Фәхретдин (04.10.1874; аналары Шәмсия), Мифтахетдин (03.05.1877).

Әхмәтвәли Җәләлетдин улы балалары: Дөрреләсма (1891–1892), Зөлмәган (07.06.1893–1895), Кәнзелмәган (24.11.1895; анасы Гыйльмебану Килкабызның Әхмәтҗан кызы), Мөгаллимә (28.08.1898–1899), Хыялый (18.12.1899; анасы Хөррәмбану Камайның Габделсалих кызы), Хаҗгали (26.12.1901; анасы Фәрхебану Камайның Мөхәммәтсалих кызы), Әхмәтхәниф (02.11.1904), Саҗидә (27.06.1907), Әхнәф (21.05.1910–1911; анасы Хөррәмбану Мөхәммәтсалих кызы), Имамгыйзали (29.01.1912), Әүхади (28.01.1916; анасы Хөррәмбану). Әхмәтвәли Җәләлетдинов (54 яшь) 1917 елда хатыны (35 яшь), алты улы һәм кызы белән яши, 7,68 дисәтинә җире, 2 аты һәм 2 кәҗәсе була, ике улы утын кисү белән кәсеп итә. Хаҗгали (Хаҗекай) Вәлиев сугыш алды елларында хатыны Мәдхизиян (1903), кызлары Мөсәвәрә (1925), Рәйсә (1932), Әнисә (1934), Закирә (1938) белән яши. Кәнзелмәган Вәлиевнең улы Зөлмәган (1923) 1942

елның 17 июлендә сугышка китә һәм шул елны хәбәрсез югала (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән). Хәниф Вәлиев (1904) 1942 елның мартында сугышка китә һәм 1943 елда хәбәрсез югала, хатыны Зоя тол кала.

Фәхретдин Җәләлетдин улы (28 яшь; икенче никах) 1907 елның сентябрендә нәселдәше Бәдретдин Камалетдин улының кызы Гыйльмисафа (18 яшь) белән никахлаша. Егетнең вәли вәкиле – бертуган агасы Мифтахетдин Җәләлетдин улы, ризалык шаһитлары Хәйрулла Борһанетдин улы белән Сираҗетдин Камалетдин улы була. Бу никах 1912 елның 5 ноябрендә таркала. Фәхретдин Җәләлетдинов (42 яшь) 1917 елда хатыны белән яши, 1,55 дисәтинә җире була, итекләр тегә.

Мифтахетдин Җәләлетдин улы балалары: Хөршидҗиһан (14.10.1909; анасы Маһикамал), Фәвәрис (07.08.1912; анасы Маһинур Баһманша кызы), Рабига (16.01.1914; анасы Шәмсеҗиһан Баһаутдин кызы), Хираҗи (10.12.1925; анасы Гөлчирә). Мифтахетдин Җәләлетдинов 1917 елда хатыны (40 яшь), улы һәм өч кызы белән яши, 6,61 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була.

Миңлегәрәй Мифтахетдин улы Габделнасыйров балалары: Рәйфә (1875), Сәетгали (26.11.1877–1883), Мөшәррәфә (20.02.1880), Мөхәммәтмиргали (26.12.1881), Сәетгали (12.01.1884–1886), Бибисаҗидә (29.07.1888; анасы Мәфтуха), Хәтирә (29.04.1891–1895, анасы Мәфтуха Габделгани кызы; утка янып), Җәмигънур (23.11.1907–1916; анасы Гыйззенур Мөхәммәтзакир кызы), Кәшифә (12.01.1910), Гакифә (08.09.1912). Миңлегәрәй кызы Мәэлүфә (18 яшь) 1889 елда Яңа Катайның Ахунҗан мулла Әхмәтҗан улы белән никахлаша. Икенче кызы Рәйфә (18 яшь) 1893 елның 1 гыйнварында Тымытыкның мөәзин Әхмәтгариф мулла Әхмәтшакир улы (25 яшь; атасы Әхмәтшакир мулла Мифтахетдин улы) белән гаилә кора.

Әхмәтгәрәй Мифтахетдин улы Габделнасыйров балалары: Бибикәримә (1876–1893), Нәгыймә (27.03.1878; анасы Рабига), Сәрвәрия (15.07.1880), Әхмәтсафа (08.07.1884), Мирҗәләлетдин (29.08.1886–1888), Бибимәрьям (30.11.1888), Бибиәсма (27.10.1890), Әһлия (15.06.1892–1894; анасы Рабига Рәхмәтулла кызы), Әһлия (27.03.1897), Сәвия (15.07.1899; анасы Фатыйма Мәчти авылының Сөләйман кызы), Әхмәтгата (28.01.1901), Наҗия (05.11.1904), Сәхипзадә (29.06.1907–1912; анасы Мәфтуха Солтангәрәй кызы), Сәетзадә (25.02.1911), Сәхипзадә (22.03.1914). Әхмәтгәрәй кызы Бибикәримә (18 яшь) 1892 елның 30 гыйнварында Яңа Катайның Гыйлемхан Бәдретдин улы (23 яшь; атасы Бәдретдин Габделфәез улы) белән кавыша. Икенче кызы Сәрвәрия (18 яшь) 1899 елның 26 ноябрендә Яңа Катай имамы Мөхәммәтзакир Фәттахетдин улы (27 яшь) белән кавыша. Өченче кызы Бибимәрьям (18 яшь) 1906 елның 5 августында Иштирәкнең мөәзин Гарифулла Мөхәммәдьяр улы (30 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Әхмәтсафа Әхмәтгәрәй улы белән Әхмәтвәли Җәләлетдин улы була. Әхмәтгәрәй Мифтахетдинов (66 яшь) 1917 елда хатыны (44), ике улы һәм кызы белән яши, 15,56 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һәм 5 сарыгы була.

Әхмәтсафа Әхмәтгәрәй улы балалары: Минlenaҗия (04.04.1910; атасы Мөхәммәтсафа Әхмәтгәрәй улы, анасы Мөнирә Шаһингәрәй кызы), Гыйлемзадә (12.01.1912; анасы Мөнирә Шаһингәрәй кызы), Әхмәтвафа (15.03.1917), Әхмәтзәки (1922–1924), Миргали (21.03.1925). Әхмәтсафа Әхмәтгәрәевне Беренче бөтендөнья сугышына алалар, хатыны (30 яшь), өч улы кала, 1917 елда 13,56 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була. Вафа белән Миргалим Гәрәевлар сугыштан кайтмадылар, дип әйткән иде Хәмит абый. Гыйлемзадәне Галим, диде, ул сугыштан кайта, улы Әхияр була.

Сәхипзадә Гәрәев (1914–2001) 1920 елда ата-анасы үләт чиреннән вафат булгач абыйсы Сафа Гәрәев тәрбиясендә үскән, зур тормыш юлына басканда исемен Гәрәйгә үзгәрткән. Шуңа күрә рәсми чыганакларда Гәрәй Гәрәй улы Гәрәев дип языла. Башта Катайда, аннары Бакалы урта мәктәбендә укый. Башкорт педагогия институтында белем алган (1931–1933 елларда) иң беренче Катай авылы кешесе була. Ике ел Йөзәй (Юзәй) мәктәбендә укыта, 1936–1939 елларда хәрби хезмәттә була, туган ягына кайткач Магдалина исемле кызга өйләнә. Ике ел Камышлы мәктәбендә завуч, 1941–1942 елларда Катай җидееллык мәктәбендә директор булып эшли, шуннан фронтка китә. «Сугышчан хезмәтләре өчен», «Кенигсбергны алган өчен» медальләре белән бүләкләнә. Хатыны һәм улы Робертны кайтып алып, 1947 елга кадәр Берлинда хезмәт итә. 1947 елда Бакалыга кайталар, аны Яңа Балыклы җидееллык мәктәбенә директор итеп билгелиләр. 34 ел шул мәктәптә директор вазифасын башкара, 44 еллык укытучы стажы белән пенсиягә чыга. Боларны архив чыганагына һәм авылдашым Рәсимә Шәйдуллина мәгълүматына таянып язам. Гәрәй (Сәхипзадә) Гәрәев Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән.



**Гәрәй Гәрәев (сул якта) 1936–1939 елларда хәрби хезмәттә була**

Габделнасыйр Мостафинның икенче улы Камалетдин иде. Камалетдин Габделнасыйр улы балалары: Бәдретдин (1847–11.03.1912), Җиһанбану (1855), Мәхүбҗамал (1863), Садретдин, Сираҗетдин (1869). Камалетдин кызы Җиһанбану (40 яшь; дүртенче никах) 1895 елның 23 сентябрендә авылдашы Әдһәм Мөхетдин улы (50 яшь; өченче никах) белән никахлаша. Кече кызы Мәхүбҗамал (20 яшь) 1884 елның 25 гыйнварында Килкабызның Әхмәтнәби Әхмәтҗан улына (22 яшь; атасы Әхмәтҗан Әхтәм улы) кияүгә чыга.

Бәдретдин Камалетдин улы балалары: Хәмдесафа (25.07.1880–1888), Әхмәтнәгыйм (13.03.1884), Хәйриниса (07.04.1887), Гыйльмисафа (17.08.1890; анасы Гыйльмениса), Әбүнәгыйм (02.05.1894–1899; анасы Гыйльмениса Сәетбаттал кызы). Бәдретдин кызы Гыйльмисафа (17 яшь) 1907 елның сентябрендә

нәселдәше Фәхретдин Җәләлетдин улы (28 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Гайса Габделгалләм улы белән Галиулла Шәрәфулла (Шәрифулла) улы була. Бу никах 1912 елның 5 ноябрендә таркала. Әхмәтнәгыйм Бәдретдин улының кызлары Бибиразыя (1922–1924), Мосаллия (07.03.1925; анасы Шәмсенур Нургали кызы) була.

Садретдин Камалетдин улы балалары: Мөхәммәтдин (12.12.1890–1892), Гыймадетдин (22.01.1892), Фәрваҗетдин (16.10.1894; анасы Миңлебану Корычның Әхмәтҗан кызы), Җәмгыйтдин (1896–1898), Гыйльмебану (02.02.1899–1900), Хөснибану (13.02.1901; анасы Миңлебану Корычның Габделгазиз кызы), Гыйльмебану (12.11.1905; анасы Миңлебану Әхмәтҗан кызы), Сәйфетдин (1910–1911), Әхкәметдин (15.03.1912).

Сираҗетдин Камалетдин улы (23 яшь) 1892 елның 6 мартында Мөхәммәди Чурагол улының кызы Мәмдуха (25 яшь; икенче никах) белән никахлаша, балалары Әһлетдин (10.08.1894), Сәлахетдин (19.03.1901–21.11.1908), Әгъләметдин (10.11.1903–1905), Бәһия (02.09.1906), Әһлия (11.05.1910) туа.

Әлерәк әйтеп үткән бертуган Садретдин белән Сираҗетдин Камалетдиновлар гаиләләре бәхет эзләп читкә чыгып китәләр, алар турында башка хәбәр юк.

Габделнасыйр Мостафинның өченче улы Җамалетдингә күчәбез. Җамалетдин Габделнасыйр улы балалары: Фәрхиҗиһан (1864), Шәрәфетдин (1871). Җамалетдин кызы Фәрхиҗиһан (19 яшь) 1883 елның 13 декабрендә Яңа Катайның Габделмәннан Габделкаһир улы (23 яшь; атасы Габделкаһир Мөхәммәтгалим улы) белән кавыша. Бу вакытта Җамалетдин исән булмый, шуңа күрә кызның вәли вәкиле итеп Камалетдин Габделнасыйр улы теркәлә.

Шәрәфетдин Җамалетдин улы балалары: Хөсниҗиһан (02.09.1897; анасы Гөлзаһирә Дөмәйнең Сәлимгәрәй кызы), Миңлекәримә (05.11.1898), Фәтхетдин (08.10.1900), Галимҗан (17.02.1902), Заһретдин (28.06.1904), Миңлемөнирә (26.12.1908; анасы Гөлзөһрә), Миңлешәмсебанат (08.01.1910), Миңлеҗәмилә (07.04.1911; анасы Гөлзаһирә Сәлимгәрәй кызы), Мосаллия (1912–1914, кызамыктан вафат), Миңлефәгыйлә (06.07.1916; анасы Гөлзөһрә Сәлимгәрәй кызы). Шәрәфетдин Җамалетдинов (46 яшь) 1917 елда хатыны (40), дүрт улы һәм өч кызы белән яши, 4,22 дисәтинә җире, аты һәм башка маллары була. Зур гаиләне туйдыру өчен игенчелек биргән керем генә җитми, шуңа күрә ул кара эшче булып ялланган.

Габделнасыйр Мостафинның төпчек улы Гаязетдин (1842) яклап та нәсел дәвам итә. Гаязетдин Габделнасыйр улы балалары: Җәләлетдин (1868), Нурлыгаян (15.08.1878; анасы Шәмсенур), Зәкия (02.12.1882), Миңлегарифә (25.06.1883), Миңлехәнифә (25.06.1885–1887), Миңлефәтхелгаян (05.01.1888; атасы Гаязетдин Габделнасыйр улы, анасы Хәкимә), Миңлегабделбаян (02.04.1890–1892; атасы Гаязетдин Габделнасыйр улы Габделгазизов, анасы Миңлехәлимә Нурмөхәммәт кызы дип язылган), Фәтхетдин (1891–1895), Миңлефакия (29.07.1892–1893), Мифтахетдин (20.09.1894; анасы Хәкимә Яңа Катайның Нурмөхәммәт кызы), Кәшфелмәган (29.09.1897), Әкълимә (22.12.1901),

игезәкләр Бибифатиха белән Фатыйма (22.09.1904; анасы Хәкимә Нурмөхәммәт кызы). Гаязетдин Насыйров (74 яшь) 1917 елда улы (22) һәм кызы (15) белән яши, хуҗалыгында 2,80 дисәтинә җире, аты була, игенчелектән тыш, утын кисү, такта яру белән шөгыльләнә.

Җәләлетдин Гаязетдин улы балалары (беренче мәхәллә): Бибигарифә (17.08.1897–1900; анасы Бибикамилә Килкабызның Фәхретдин кызы), Саимә (28.09.1900), Фәрваҗетдин (13.04.1904), Кәнзелголум (02.07.1909), Хыялетдин (02.10.1913–1914, кызамыктан вафат), Зөлмәган (06.03.1916–1924; анасы Бибикамилә). Җәләлетдин Гаязетдинов (49 яшь) 1917 елда хатыны (40), өч улы һәм кызы белән яши, 1,05 дисәтинә җире, 2 аты һәм 3 кәҗәсе була. Җәләлетдин кызы Саимә авылдашы Сәлахетдин Сираев (1891 елгы; Юлдаш нәселеннән) белән гаилә кора. Фәрваҗетдин Гаязов – Ватан сугышы ветераны. Фәрваҗетдин балалары: Фоат (1934), Рәсимә (1937), Дөлфәт (1940-май, 2018; Җәләев фамилияле) һәм Фәвәрис (1947; Гаязов фамилияле). Бабасы Җәләлетдинне күз алдында тотып, Дөлфәт абый без «Җәләй нәселе» дип әйткән иде. Аның иҗат итәргә омтылыш ясап, шигырь язып караганы булды. Фәрваҗетдиннең энесе Кәнзелголум Гаязов (Җәләев) 1943 елның 22 декабрендә сугышта һәлак була, хатыны Гөлсем, ике кызы (берсе Рәгънә, 1940) һәм анасы Камилә (1875) кала. Рәгънә нәселдәше Фанис Фәхретдиновка кияүгә чыга.



**Ат янында сугыш ветераны Фәрваҗетдин Гаязов басып тора**

Нурлыгаян Гаязетдин улы 1906 елның декабрендә Яңа Катайның Шәрәфулла Гафиятулла улының кызы Газизҗамал (18 яшь) белән никахлаша, балалары Рәкыя (03.11.1909), Мирзаҗан (26.02.1911–1914), Миргабитҗан (23.03.1914) туа. Фәтхелгаян (Фаткыл; 1888) Гаязов гаиләсендә Ватан сугышы алдыннан хатыны Гыйльминиса (1892), балалары Тимергаян (1923; Ватан сугышы ветераны), Рухылбаян (1928), Мәгънәви (1932), Ләйлә (1926) була. Тимергаян белән Гайнур Әхмәтгали кызы (1923; Яңа Катайныкы) балалары: Фларид (1949), Насыйх (1952), Ягъфәр (1955; Саратов өлкәсе Балаково шәһәрендә яшәгәндә мәрхүм була), Мирсат (1957), Фәрәгать (1960). Бүгенге көндә болардан бер Насыйх кына исән.

Алга таба нәселне Габделнасыйр Мостафинның туганы Габделхаликъ яклап карыйк. Габделхаликъның беренче улы Гыймадетдин (1815) була. Гыймадетдин Габделхаликъ улы балалары: Сәгъдетдин (1834–1852), Миңлегариф (1843), Галләметдин (1851), Фәхретдин (1857), Фәрвизә (1858). Гыймадетдин кызы Фәрвизә (18 яшь) 1876 елның 1 ноябрендә авылдашы Арслангали Мөхәммәтгали улы (22 яшь) белән никахлаша.

Галләметдин Гыймадетдин улы балалары: Фәрваҗетдин (17.02.1878; анасы Шәмсеталига), Сираҗетдин (25.04.1882), Мөшәррәфә (1883), Хисаметдин (Госаметдин; 20.11.1884), Миңлемөкәррәмә (29.11.1887–1888), Миргаязетдин (06.05.1889), Мөкәррәмә (10.02.1892), Исламетдин (15.07.1894; анасы Шәмсеталига Токтагулның Риян кызы), Миңлемөнәвәрә (15.03.1897), Раҗетдин, Гыйльметдин (16.04.1907; анасы Хәмдиҗиһан Фәхретдин кызы), Мәргубә (17.11.1909). Галләметдин кызы Мөшәррәфә (18 яшь) 1902 елның 7 ноябрендә Корычның Сәрваҗетдин Фәррахетдин улы (25 яшь; атасы Фәррахетдин Баһаутдин улы) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Фәхретдин белән Раҗетдин Гыймадетдин уллары була. Галләметдиннең төпчек кызы Мөнәвәрә (18 яшь) 1917 елның 11 октябрендә авылдашы Нурулла Нәбиулла улы (22 яшь) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары – Хисаметдин Галләметдин улы белән Фәхретдин Гыймадетдин улы, кияү тарафыннан вәли вәкил Нәбиулла Кәлимулла улы була.

Галләметдин улы Хисаметдин (1884–1970) Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Хисаметдин Галләметдин улы балалары: Гөлбану (16.02.1914), Әнвәретдин (12.11.1916; анасы Фәрхебану Низаметдин кызы), Әнгам (1920), Гайнелҗиһан (08.11.1925; анасы Фәрхебану Низаметдин кызы), Әхәт (1933; анасы Мөкәррәмә Камайның Госман мулла кызы), Һашим (1936–2011), Мәгъсүмә (1940), Гамил (1943). Хатыны вафат булгач, Хисаметдин 1932 елда биш баласы янына хатын итеп, Камайдан мулла Госман кызы Мөкәррәмәне алып кайта, аннан да биш бала туа. Хисаметдиннең ике улы (Әнвәретдин белән Әнгам Галләмовлар) Ватан сугышында хәбәрсез югала.

Хисаметдин кызы Мәгъсүмә 1962–1967 елларда Казан дәүләт университетының юридик факультетында укый, илле еллап адвокат булып эшли. Мәгъсүмә апаның мулла кызыннан тууын истә тотып, Катай мәктәбендә укыганда

укытучылар аңа кырын караган, «башлангыч классларда минем белән беркем дә сөйләшмәде», дип искә ала ул, кайберләренең исемнәрен атап. Атасы Хисаметдин талдан бала бишекләре, каз оялары үреп саткан, ирле-хатынлы колхозга кермәгәннәр. Матыда унны тәмамлагач, Мәгъсүмә апаны эшкә чакырырга колхоз рәисе төшкән, «аннан чормага качып, икенче көнне Уфага чыгып киттем», ди. Анда төзелештә эшләп, форсат ачылгач, Катайдан иң беренче булып мәшһүр университетның В. И. Ульянов-Ленин укыган юридик факультетына укырга керә ул.

Бу китапны нәшер итәргә җыенганда, энем Дамир белән Мөкәррәмә апаны искә алдык. Мәгъсүмә апа анасы янына кайтып йөри, кайткан саен күп итеп күчтәнәчләр алып кайта иде. Әнием Рәкига Мөкәррәмә апа белән дусларча гел аралашканнан, аңа барып йөргәнлектән, ул күчтәнәчләр безгә дә эләгә, өрек-йөзем һәм кәнфит кебек тәмле ризыкны сөенә-сөенә авыз итә идек. Аш-суга оста булгандыр, мичтә эремчек пәрәмәчләре пешергәли, бик тәмле иде, дип искә ала энем Дамир, ул әниемә ияреп Мөкәррәмә апага баргалаган булган икән. Мөкәррәмә апа дини гаиләдә үскәч, намазлы иде, аның йогынтысы булгандыр, әнием дә догалар белә, безне дә дингә өнди иде. Мөкәррәмә апа 1985 елның мартында дөнья куйды, бу самими балачак истәлекләре аның якты рухына дога булып ирешсен.

Исламетдин Галләметдин улы да, абыйсы Хисаметдин кебек, Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Аның Мәрьям Миһран кызы белән никахыннан балалары Мөдәсир (10.11.1925), Тимерхәмит (1929), Гапхәмит (1932), Асия (1940) туа, икесе яшьли мәрхүм була, Тимерхәмит белән Асия читкә чыгып китә. Тимерхәмит Новокузнецк якларында булды да, аннары Уфага кайтып төпләнде, дип сөйләде Мәгъсүмә Хисаметдин кызы Галләмова.



**Документ фрагментында – Фәхретдин Гыймадетдин улының һәм аның нәселдәшләренең тамгалары (икесе «Т» хәрефенә охшаган)**

Фәхретдин Гыймадетдин улы балалары: Әхиярeтдин (22.03.1893; анасы Гыйльмисафа Туктаголның Мусакай кызы), Газетдин (1896–1900), Нурисафа (23.06.1898–1914, ютәлдән вафат), Әһлесафа (10.06.1901), Әнвәретдин


ایکنجی فصل ۱۹۱۷ نچی ییلده اولان نکاحلرنی یازار ایچون

**Патша чоры беткәч, тамганың да кирәге беткәнме? Әхияретдин Фәхретдин улы никахы теркәлгән метрикә бите. 1917 ел, 3 декабрь**

(27.02.1905), Әгъзаметдин (14.09.1907; анасы Гыйльмисафа), Сәрвәҗетдин (19.02.1924; анасы Сатия Якуп кызы). Фәхретдин Гыймадетдин улының берьюлы ике баласы (1 яшьлек Әнвәретдин, 9 яшьлек Әхкәметдин) кызамык белән авырып, 1906 елның 11 гыйнварында мәрхүм була. Беренче мәхәлләдә бу авырудан тагын дүрт баланың гомере киселә. Фәхретдин Гыймадетдиновның олы улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда ул хатыны һәм кече улы белән яши, 4,11 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була.

Әхияретдин Фәхретдин улы 1917 елның 3 декабрендә авылдашы Нәбиулла Кәлимулла улының кызы Фатыймага (18 яшь) өйләнә, балалары Әсхия (1924–1926), Миңлефәһимә (10.03.1925), Мөзәгарәфә, Акмал (1928), Фанис (1941–2019) дөньяга килә. Әхияретдин Фәхретдинов (1893–1974) – Ватан сугышы ветераны, «Сугышчан Кызыл Байрак» ордены (04.03.1945) белән бүләкләнгән. Акмал белән Нәҗибә Хөснулла кызы балалары: Зимфира (1951–2015), Альберт (1957), Роберт (1961). Роберт Фәхретдинов хатыны Клара, кызлары Ирина (1995) һәм Регина (2000) белән Октябрьский шәһәрендә яши, теш табибы булып эшли. Атна саен Катайдагы туган нигезенә кайтып йөри, ярдәмчел, шәфкатьле, киң күңелле булуы белән үзенә тарта, хөрмәт уята.

Фанис белән Рәгънә Кәнзелголум кызы балалары: Рузалия (1961), Ильвира (1969), Рөстәм (01.09.1973). Болардан бүгенге көндә бер Ильвира гына исән, гаилә корып Куянда яши.

Габделхаликъның икенче улы – Гыйлаҗетдин (1832). Гыйлаҗетдин Габделхаликъ улы балалары: Фәррахетдин (1853), Фәрхиҗамал (1858). Гыйлаҗетдин кызы Фәрхиҗамал (17 яшь) 1875 елның 1 гыйнварында Яңа Катайның Мифтахетдин Галләметдин улы Үмербаев белән никахлаша.

Фәррахетдин Гыйлаҗетдин улы (23 яшь; вәли вәкиле – Йосыф Габделгалләм улы) 1876 елның 1 гыйнварында авылдашы Мәгърифә Гаделша кызы белән никахлаша, балалары Мөхәммәтсабир (06.02.1876), Миңлетаифә (05.03.1878), Гакифә (05.02.1880), Таифә (1881), Бибизәкия (15.01.1885), Гакифә

(1886), Мөхәммәтнасыйп (12.10.1887–1903), Бибифакия (1889), Бибифатыйма (15.01.1891–1892), Мөхәммәтхафиз (12.04.1894), Зәкия (1895) туа. Фәррахетдин кызы Таифә (18 яшь) 1899 елның 26 ноябрендә Камайның Исламгәрәй Миңлегәрәй улына (25 яшь) кияүгә чыга. Икенче кызы Гакифә (18 яшь) 1905 елның 2 февралендә Корычның Әхтәмҗан Әхмәтҗан улы (26 яшь; атасы Әхмәтҗан Габделбаян улы) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтсабир Фәррахетдин улы белән Галләметдин Гыймадетдин улы була. Өченче кызы Бибифакия (18 яшь) 1907 елның 27 ноябрендә Туктаголның Фәтхелгаян Габдерәхим улы (26 яшь) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтсабир Фәррахетдин улы белән Фәхретдин Гыймадетдин улы була. Әлеге кияү 1908 елда Фәтхелбәян дип күрсәтелә, аның 20 сентябрьдә Иске Катайда кызы Фәүзия туа. Фәррахетдиннең төпчек кызы Зәкия (18 яшь) 1914 елның 15 гыйнварында Камайның Исламгәрәй Миңлегәрәй улы (35 яшь; икенче никах) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтсабир Фәррахетдин улы белән Мөхәммәтхафиз Могтәметдин улы була. Фәррахетдин Гыйлаҗетдиновның (65 яшь) ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (65), килене (42) һәм оныклары (5, 10) белән яши, 16,06 дисәтинә җире, 5 аты, 3 сыеры һәм башка маллары, җилгәргече була, хезмәтче яллый.

Монда бер искәрмә ясап үтик. 1914 елгы никах язуында Фәррахетдин Гыйлаҗетдин улы исеме артыннан – Юлдаш нәселе тамгасын, ә Камайның Исламгәрәй Миңлегәрәй улы тамгасы итеп «Т» хәрефенә охшаган Бишенде нәселе тамгасын салганнар. Ризалык шаһитларының берсе (Мөхәммәтхафиз Могтәметдин улы) Юлдаш нәселеннән булганга, никах язуына шул нәсел тамгасы килеп кергән, тик ул тамга мулла хатасы белән Фәррахетдин Гыйлаҗетдин улыныкы булып чыккан. «Т» хәрефенә охшаган Бишенде тамгасы әнә шул Фәррахетдин исеме артыннан соң урын алырга тиеш булган. Никахта хотбә укучы Мөхәммәтлатыйф мулла Мөхәммәтнәби улы дип күрсәтелгән, димәк, әлеге хата өчен ул гаепле булып чыга түгелме?



**Тамгаларны буташтырып салган никах язуы. 1914 ел**

Мөхәммәтсабир Фәррахетдин улы балалары: Мөхәммәтнасыйп (13.09.1904; анасы Хәмдия Төхфәтулла кызы), Мөхәммәтзакир (19.01.1908–1916; анасы Хәмдия Төхфәтулла кызы), Фәүзия (1910–1911), Мәүдигия (29.06.1912), Мөхәммәтзакир (21.05.1924–1984; анасы Сайра Хәбибулла кызы), Гөлсем



**1958–1960 елгы фоторәсемдә – тарихыбыз, нәселләребез**

(1927), Гөлмиян (1933). Сабир Фәрраховның (1875–1940) соңгы хатыны Майбану (1895) була. Гөлсемнең Әсхәдулла Габдуллин белән никахыннан Мәүлисә (02.09.1959) туа. Закир Сабир улы Фәррахов – Ватан сугышы ветераны, «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале белән бүләкләнгән.

Мөхәммәтхафиз Фәррахетдин улының 1925 елга чаклы балалары: Рәкыя (1921–1924), Хәтирә (1923–1924), Миңлерәкыя (15.06.1925; анасы Мәгъдәнбану Габдулла кызы). Ирсез калган Мәгъдәнбану Фәррахова (1901; Юлдаш нәселеннән) Ватан сугышы алдыннан балалары Нәкыя (1929), Мөхәммәткамал (1931–1984), Хәтирә (1935) белән яши. Нәкыя Рәиф Әхмәтхановка кияүгә чыга. Фәррахов Камал белән Рәзинә Шагали кызы (1936–2020; Килкабызныкы) балалары: Розалия (1959), Рәвис (14.10.1961), Зилия (1964), Шамил (1967), Ралия (1973). Хәтирә Бохарада яши, аннары Туймазыга кайтып төпләнә. Камал абый флотта хезмәт иткән, көчле булган, бер явызны акылга утырткан, дип сөйлиләр иде, пилорамда эшләде. Рәвис математиканы бик яхшы белеп, республикада өченче урынны алды, авиация институтын тәмамлап, армиядән офицер булып кайтты, шуннан соң күп тормый мәрхүм булды (Фиркать Исламов мәгълүматы).

Китабымның Иске Катай нәселләренә багышланган бүлекләрен уникаль фоторәсемне тасвирлап тәмамлыйм. Ул фоторәсемдә күпчелеге Иске Катай кешеләреннән торган төркемне күрәсез. Сулдан уңга (1 нче рәт, утырганнар): Галимә Мофаздалова, Сибагатулла Йосыпов, Мирзаәхмәт Хәйдәров, Мәгъдәнбану Фәррахова, Мәргубә Сафина, Әбүгали Шәнгәрәев, Шәйшәриф Харисов, Фәрваҗетдин Гаязов, Хәтим Харисов. 2 нче рәт (басканнар): Халә

Нәбиева, Фәния Дәүләтова, Мәгъмүрә Галиева, Дөһәдия Галиева, Өммегөлсем Җәләева, Камилә Солтанова, Нәфисә Галиева, Газим Харисов, Мәмдудә Зарипова, Саимә Харисова, Салих Шәрифуллин, Саимә Галиева, Әмирҗан Нәфиков, Хәбип Шәкүров. Бу фоторәсем нәселдәшем Риф Тимергали улы Галиевтә саклана, күчермәсен 14 майда энем Дамир Кәримов җибәрде. Риф абый белән очрашып кайбер нәрсәләрне сораштыр, борынгы фоторәсемнәре булса, күчермәсен алып җибәр, дигән идем аңа.

Белсәгез иде, бу фоторәсемне күргәч ничек шатлануымны! Бу таныш йөзләрнең күпчелеге – «Байкал» колхозының төп көчен тәшкил иткән кешеләр. Сугыш елларында төп авырлык әлеге һәм башка хатын-кызлар, үсмерләр җилкәсенә төшә. Фоторәсемдәге ир-ат катайлылар – барысы диярлек сугыш ветераннары (Әмирҗан абый гына яше җитми катнашмаган), сугыштан соң колхоз алга китсен өчен зур көч куйган кешеләр. Уртада костюм-галстуктан – Әбүгали Солтангали улы Шәнгәрәев, «Байкал» колхозы белән 1958 елның мартыннан җитәкчелек итә, 1960 елның 4 апрелендә авылдагы колхозларны «Бакалы» совхозына кушкач, Катай бүлекчәсе идарәчесе (управляющие) булып эшли, ә җәйгә кергәч район аны башка эшкә күчерә (бу хакта беренче китапта әйттем). Димәк, фоторәсем ул эшләгән 1958–1960 елларга карый.

Фоторәсем тарихыбызның бер зур сәхифәсен (этабын) чагылдырып кына калмый, Иске Катайның барлык нәселләре вәкилләрен бер урында (бер кадрда) күрсәтә кебек. Кемнәр кайсы нәселгә кергән – китапны игътибарлы укыган булсагыз, беләсез, шуңа исемнәрне яңадан атап, нәселләрен күрсәтеп тормыйм, бары Иске Катай килене Дөһәдия апаның Яңа Катайдагы Арсланбәк нәселенә керүен, фоторәсемне күрү шатлыгы сәбәпчесе аның улы, нәселдәшем Риф абый булуын билгеләп үтәм. Шунда китапның Иске Катай битен ябып, Яңа Катайга, аның иң зур нәселе саналган Арсланбәк нәселенә күчәбез.

# *Яңа Катай нәселләре*

## VIII бүлек.
## Арсланбәк нәселе

Арсланбәк нәселенә караган хуҗалыклар Яңа Катайда шул кадәр күп ки, 1910 елның көзендә өченче мәхәллә барлыкка килгәч, яңа гына муллалыкка керешкән Гариф Күчемовны һәм аның нәселенә караган берничә хуҗалыкны исәпләмәсәк, мәхәллә тулысынча диярлек бу нәселдән тора. 1911 елда яңа туган 15 ир һәм 14 кыз баланың 28 е шул нәселнеке, бары шул елда туган Җәмигылфнүн Күчемов кына (90 нчы еллар ахырында бу юллар авторы аның белән очрашкан иде) аерым булып тора.

«Үткәннәрен бел Катайның» китабының беренче бүлегендә бу нәселгә «нигез салучы» Арсланбәк Якупов телгә алынды. Ул үзенең бертуганы Солтанморат Якуп улы белән бергә 1753 елгы документта теркәлгән, икесе дә нәсел тамгасын салган. 1816 елгы ревизия документында исә 10 нчы сан астында Салих Якупов бирелә. Ул 1735–1812 елларда яшәгән, йортында варислары булып уллары Сәфәргали (1794) белән Фәтхетдин (1799) калган.



**1753 елгы документ фрагментында Арсланбәк Якуп улы тамгасы**



**Астан икенче юлда нәкъ уртада Кинҗәбай үзенең тамгасын салган. Документның өстән икенче юлы Катай авылының дип башлана**

Димәк, нәсел башында торучы Якупның Арсланбәк, Солтанморат һәм Салих исемле уллары булган, тагын булганмы-юкмы, ачыклап булмый. Арсланбәктән киткән тармаклар күп булу сәбәпле, Яңа Катай аксакаллары телендә «Арсланбәк нәселе» дип атала иде, ревизия исемлекләре дә бу нәсел кешеләреннән башлана. 1816 елгы исемлектә 46 хуҗалык күрсәтелсә, шуның 10 нан артыгы Якупка нисбәтле дип әйтергә була. Арсланбәкнең ерак нәселдәшләрен дә кушып исәпләсәң, Яңа Катайның яртысы диярлек бу нәсел кешеләреннән тора.

Билгеле, Арсланбәк Якуп улының нәселдәшләре бер Катай белән генә чикләнми. Шул ук 1753 елгы документта нәкъ шундый тамга салган Дөмәйнең Кинҗәбәй улы да телгә алына. Ул шул авылга нигез салган Дөмәйнең улы булырга тиеш, документ күчермәсендә Кинҗәбәй исеменнән соң «Дө» дип язылганын ачык укып була, калган өлеше өстәрәк «мәй» дип язылган. Кызыксынып, Яңа Дөмәй авылының 1816 елгы ревизия документын ачып караган идем, Кинҗәбай нәселен уллары Баттал (1816 елда 68 яшь) белән Сәетборһан (26 яшь) Кинҗәбаевлар дәвам итүен күрдем[1].

Арсланбәк Якуп улының ерак нәселдәшләре Сакат авылында да була. 1841 елгы документтагы Зөбәер Биккенәев тамгасы аның Арсланбәк нәселдәше булуын күрсәтә. Зөбәер һәм аның авылдашлары Сакатка 150 ел элек килеп утыруларын әйтәләр[2]. Арсланбәк варислары башкорт сословиесендә булса, болар типтәр сословиесендә теркәлгән. Тамгаларны өйрәнүне дәвам иткәндә, Арсланбәк нәселдәшләрен башка авыллардан да табып булыр иде кебек.



**1841 елгы документта Сакатның Зөбәер Биккенәев тамгасы. Бу тамга аның Арсланбәк нәселдәше булуын күрсәтә**

1816 елгы ревизия документы Арсланбәк Якупов нәселен уллары Солтанбәк (1760) белән Габидулла (1766) дәвам итүен күрсәтә. Алга таба сүз аларның балалары һәм оныклары турында барачак.

Солтанбәк биш ул – Фәйзулла (туган елы билгеле түгел), Хәбибулла (1782), Фәтхулла (1786), Төхфәтулла (1801), Сафиулла (1822) – тәрбияләп үстерә. 1834 елда Солтанбәк хатыннары Рәхимә (1771) һәм Шәмсикамәр (1785) була.

Фәйзулланың Фазулла (Фазлулла; 1802) исемле бердәнбер улы булып, аннан Саяфетдин (1833–14.08.1903), Хөснетдин (1836) һәм Гыймадетдин (1844) дөньяга килә.

Саяфетдин Фазлулла улы балалары: Фәттахетдин (1856), Кашшафетдин (1866), Шәрәфетдин (халык телендә исеме Шәрәй; 1870), Галләметдин (1872), Камалетдин (17.02.1878; анасы Мәхмүдә), Җәләлетдин (15.03.1880; анасы Мәхмүдә), Газетдин (1881), Низаметдин (1884).

---

[1] БҮДТА, И-138 ф., 2 тасв., 151 сакл. бер., 15 б.а.

[2] БҮДТА, И-172 ф., 18 сакл. бер.

Фәттахетдин Саяфетдин улы Солтанбәков (1856) балалары: Майҗамал (1884), Майкамәр (1888), Майкамал (25.02.1890; анасы Гөлҗамал Җәләлетдин кызы), Шәмсенур (09.03.1895–1902), Гыйльметдин (1899–1903), Гайнетдин (10.02.1900), Шәмсенур (1906–1915; тамагы шешеп вафат була), Шәмсебану (06.06.1907; анасы Маһинур Нурислам кызы), Шәмсетдин (14.11.1909–1915; тамак шешеп), Шәмсемөхәммәт (1911–1915, тамак шешеп вафат), Хуҗагали (15.10.1915–1916). Фәттахетдин кызы Майҗамал 1901 елның 6 февралендә Корычның Әхмәтзәки Бәхетгәрәй улы (23 яшь; атасы Бәхетгәрәй Сибгатулла улы) белән гаилә кора. Икенче кызы Майкамәр 1905 елның 10 гыйнварында Иске Катайның Мөхәммәтзаһир Мөхәммәтшакиров улы Мөхәммәтшәкүр (23 яшь) белән никахлаша. 1905 елның ноябрендә Фәттахетдин Саяфетдин улы (45 яшь) икенче хатынлыкка нәселдәше Нурислам Шәйхелислам улының кызы Миңлемаһинурны (17 яшь) ала. Маһинурдан Шәмсемөхәммәт (28.09.1912) билгеле.

Кашшафетдин Саяфетдин улы Фазлуллин 1888 елның декабрендә Иске Катайның Вилдан Гыйльман улының кызы Шәмсенәһар (18 яшь) белән гаилә кора, улы Заһретдин (20.07.1889–10.05.1925; анасы Шәмсенәһар Вилдан кызы) туа. Улы туып бераз вакыт үткәч Кашшафетдин мәрхүм булган, ахры, башкача телгә алынмый, ә Шәмсенәһар аның энесе Шәрәфетдин хатыны дип күрсәтелә.

Шәрәфетдин Саяфетдин улы Фазлуллин Иске Катайның Вилдан Гыйльман улының кызы Шәмсенәһар (Юлдаш нәселе) белән никахлаша, балалары Кәраметдин (халык телендә исеме Кәрам, 26.07.1894), Сәрвиҗиһан (21.02.1897), Шәмсеҗиһан (30.12.1898–1903), Гайнелҗиһан (02.03.1901), Майҗиһан (Майҗиян; 06.11.1903), Гөлҗиһан (Гөлҗиян; 23.08.1906), Фәхерҗиһан (23.03.1909), Сәлахетдин (28.03.1911–1915), Фәрхиҗиһан (21.08.1913) дөньяга килә. Шәрәфетдин Саяфетдиновның улын (Кәраметдин) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда ул хатыны (35 яшь), дүрт кызы һәм туганының улы (26) белән яши, 8,32 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була. Шәрәфетдин 1931 елның маенда кулаклыкта гаепләнә, хөкем ителә, 1989 елда исеме аклана. Шәрәфетдин кызы Майҗиян Камышлының Хәйдәр Биктимеровка кияүгә чыга, балалары туа. Майҗиян кызы Рәмия Яңа Катайның Җәүдәт Вәлиев белән никахлаша.

...Шәрәй (Шәрәфетдин) исемле кеше көчле саналган. Ачлык елны симәнәгә ашлык таратканда, авыл советы рәисе Кашапов Ихай Шәрәй Кәраменә иң беренчеләрдән биргән. «Ул ач торса тора, симәнәгә дигән ашлыкны ашамый, бөртегенә кадәр чәчә, ә син ашыйсың, син үл», дип әйткән ди, шунда икенче бер авылдашына.

Саяфетдиннең дүртенче улына күчик. Галләметдин Саяфетдин улы (22 яшь) 1894 елның 8 декабрендә Иске Катайның Хасбиран Вилдан улының кызы Гыйльмиҗамал (18 яшь; Юлдаш нәселе) белән никахлаша. Егетнең ризалык шаһитлары Шәрәфетдин белән Фәттахетдин Саяфетдин уллары була. Галлә-

метдин балалары: Афзалетдин (1896), Фәрхиҗамал (07.06.1899), Шәмсеҗамал (28.08.1902–1905), Саимә (1904–1907), Минһаҗетдин (халыкта телендә Минаж; 20.06.1905), Акмалетдин (1909–1915), Имаметдин (28.03.1911), Әхкәметдин (22.02.1914).

Мөәзин Афзалетдин Галләметдин улының Ватан сугышына чаклы туган балалары: Нурдидә (07.06.1925; анасы Галимә), Әминә (1928), Акмалетдин (1930), Вәзимә (1936). Афзалетдин Галләметдин улы Галләмов – Ватан сугышы ветераны, «Кызыл Йолдыз» ордены (18.07.1945) белән бүләкләнгән. Минһаҗетдин Галләмов та кулына корал тотып, фашистларга каршы сугыша (язмышы билгесез; исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән), сугышка чаклы хатыны Мәликә (1906), уллары Халәф (1930), Фәнис (1935), Әхәзис (1939) белән яши. Әхкәметдин Саяповның (1914) Ватан сугышына киткәндә әти-әнисе, хатыны Гания (1915), кызы Фина (1942) кала, 1943 елда хәбәрсез югала (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Саяфетдиннең бишенче улыннан да нәсел дәвам итә. Җәләлетдин Саяфетдин улы балалары: Мәдхиҗиһан (08.05.1907; анасы Фәрхиҗиһан Әхмәтгәрәй кызы), Әхияретдин (1909–1915), Мәгъдәнҗиһан (15.05.1913), Шәмсеҗиһан (15.01.1916). Нәселнең бу тармагыннан тагын Мисбахетдин (1931) белән Мөзәмил (1937) Саяповлар билгеле.

Низаметдин Саяфетдин улы (26 яшь; икенче никах) 1912 елның 7 февралендә авылдашы Мөхәммәтхафиз Габделсаттар улының кызы Бибиһидая (23 яшь; икенче никах) белән никахлаша, балалары Әнвәретдин (02.09.1913–1916), Сәрия (04.09.1916) туа. Низаметдин Саяповның совет чорында туган балалары Катай авыл советы кенәгәсендә теркәлгән, болар: Сәрия (1921), Әминә (1925), Хөршидә (1926), Илһаметдин (1939–1940). Низаметдин Балыклының Сания Кәлимулла кызын алган була, «мәхәббәтләре булмаганлыктан» 1911 елның 7 ноябрендә аерып җибәрә.

Солдат Газетдин Саяфетдин улы (26 яшь) 1908 елның 25 апрелендә Иске Катайның Төхфәтулла Хөснетдин улының кызы Мәэлүфә (18 яшь) белән никахлаша. Газетдин Саяпов балалары: Миңлесәвия (25.01.1911–1911; анасы Мәэлүфә), Тимергази (20.10.1912–1913; анасы Маһигарифә Мөхәммәтзакир кызы), Миңлемөгаллимә (18.05.1914; утырмадан өшеп кайткач, чирле булып кала), Әкрәметдин (1921–1941), Нуретдин (1923–1943), Әнвәретдин (12.06.1925–16.07.2019; анасы Маһигарифә Мөхәммәтзакир кызы), Әгъләметдин (1930). Әкрәметдин һәм Нуретдин Саяповлар – Ватан сугышы корбаннары (исемнәре Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).



**Мулла Гариф Күчемов Әнвәретдиннең дөньяга килүен теркәгән метрикә фрагменты. 1925 ел**



**Сугышчы Әнвәретдин Саяпов**

Ватан сугышы ветераны Әнвәретдин Саяпов 1951 елның маенда Иске Катайның Шәрифулла Шаригин кызы Сания (09.01.1930–10.07.2008) белән гаилә кора, балалары Мәвәзинә (1952), Мәрхәм (1954), Мәүфәт (1956), Наил (1959), Дамира (1962) туа. Әнвәретдин гомеренең соңгы елларында кызы Дамира тәрбиясендә Орловкада яши. Әгъләметдин Саяпов Иске Катайның Сабирҗан Солтанов кызы Дәнә (1937–2003) белән никахлаша, балалары Диләвир (1959), Ринат (1962), Радик (1965; өчесе дә Чаллы шәһәрендә яшиләр) дөньяга килә.

Югарыда нәселнең Саяфетдин тармагы каралды. Саяфетдиннең беренче энесе Хөснетдин (1836) иде. Хөснетдин Фазлулла улы Солтанбәков балалары: Мөхәммәтшәриф (1862), Бибимәүгыйзә (1870–1889), Бибигазизә (1875–1895), Мөхәммәтнасыйп (10.02.1877), Бибифакия (01.07.1880; анасы Мәүлиха), Габдулла (05.01.1895; анасы Гандәлип Габдерәхим кызы), Зәкия (21.02.1901; анасы Фатиха Гыйззәтулла кызы). Хөснетдиннең бер никахы 1893 елның 7 мартында Иске Дөмәйнең Бибисәйдә Сәхаутдин кызы (45 яшь; икенче никах) белән була. Аннан соң Хөснетдин Бәләбәй өязе Сарсаз авылының Габдерәхим Габделкадыйр улының кызы Гандәлип белән никахлаша, 1895 елның 22 мартында алар аерылышалар («араларында мәхәббәт вә өлфәт булмаган сәбәпле»). Хөснетдин кызы Бибифатиха (17 яшь) 1909 елның 23 гыйнварында Корычның Мөхәммәтсалих Мөхәммәтсадыйк улы (23 яшь; атасы Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтҗан улы) белән никахлаша. Бибифатиха (23 яшь) кияүдән кайтып, 1913 елның февралендә Иске Катайның Миңлемөхәммәт Хаҗиәхмәт улы (25 яшь; икенче никах) белән кавыша. Бибифатиханың (30 яшь) өченче никахы 1915 елның 3 ноябрендә Иске Катайның Мифтахетдин Камалетдин улы (43 яшь) белән теркәлә.

Мөхәммәтшәриф Хөснетдин улы Фазлуллин балалары: Бибигайшә (10.12.1894; анасы Бибилатыйфа Мофаздал Сыртлан улының кызы), Гөлчирә (27.06.1897; атасының фамилиясе Солтанбәков дип язылган), Гөлҗамал (17.10.1900–1904), Әхмәтхарис (29.10.1905). Мөхәммәтшәриф кызы Бибигайшә 1912 елның 20 декабрендә Килкабызның Шәехзаман Тимергази улы (25 яшь; атасы Тимергази Миңлегали улы) белән никахлаша. Икенче кызы Гөлчирә 1917 елның 1 гыйнварында Килкабызның Шәймөхәммәт Мул-

ламөхәммәт улы (25 яшь; атасы Мулламөхәммәт Габделхәбир улы) белән кавыша.

Мөхәммәтнасыйп Хөснетдин улы 1903 елның 29 октябрендә авылдашы Фәррахша Әхмәди улы Азаматов кызы Гайнижиһан (17 яшь) белән никахлаша. Мөхәммәтнасыйп балалары: Миңлежиһан (24.02.1905), Мәүгыйзә (07.03.1907), Мөхәммәтнасыйх (27.02.1909), Миңлемәргубә (20.01.1911; анасы Гыйльмижиһан Фәррахша кызы), Мөнәвәрә (25.07.1913–1917), Габдулла (05.07.1915), Мөхәммәтвазыйх (10.09.1916), Мөхәммәтнасыйх (27.02.1917), Мәрьям (28.05.1925; анасы Мәдинә Габделгалим кызы). 1931 елның 24 апрелендә колхозчы Насыйп Хөснетдиновны кулга алалар, хөкемдарлар аңа ике статьялык (58–9, 58–10) »гаеп» тагалар. 1989 елда «эше» яңадан каралып, гаепсез табыла. Насыйпны Урта Азиягә качып котылган, дип сөйләгән иде картлар.

Саяфетдиннең икенче энесе Гыймадетдин Фазлулла улы Солтанбәков балалары: Бибисорур (1873), Фәхретдин (06.02.1877; анасы Шәмсезиядә), Фәрхисорур (1878), Хәйдәретдин (1883), Әһлетдин (1884–1910). Гыймадетдин кызы Бибисорур 1893 елның 13 гыйнварында Иске Катайның Гомәр Йосыф улы (21 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Фәрхисорур 1898 елның 12 февралендә Туктаголның Хаммадулла Сәлимгәрәй улы (29 яшь; икенче никах) белән кавыша. Хәйдәретдин Гыймадетдин улы (22 яшь) 1905 елның 12 декабрендә нәселдәше Сәлимгәрәй Мөхәммәтвәли улы Солтанбәков кызы Бибисара (17 яшь) белән никахлаша. Әһлетдин Гыймадетдин улы (25 яшь) 1910 елның 2 гыйнварында нәселдәше Әхмәтгәрәй Мөхәммәтвәли улының кызы Шәмсежиһан (17 яшь) белән кавыша, шул үк көнне «эч рәнҗүеннән» мәрхүм була.

Солтанбәкнең икенче улы Хәбибулланың ир балалары Шәяхмәт (Шаһиәхмәт; 1809–1858), Шәйхулла (1815), Шәйхелислам (1831), Шәйморат (Шаһиморат; 1835) була. Шәяхмәт уллары: Яхъя (1841–18.02.1914), Гайса (1844–11.04.1912), Якуп (1848).

Яхъя Шәяхмәт улы балалары: Миңлежиһан (Әхмәтгәрәй Мөхәммәтгәрәй улы Мөхәммәтвәлиев (Күчемов) белән никахлаша), Габдрахман (10.08.1880; анасы Бибифәрхебану).

Гайса Шәяхмәт улының кызы Бибизакирә (1878–1913) билгеле. Бибизакирә 1904 елның сентябрендә Иске Катайның Мифтахетдин Камалетдин улы белән никахлаша.

Якуп Шәяхмәт улы балалары: Сәрвәретдин (11.11.1877; анасы Фәрхиҗамал), Гыйлаҗетдин. Якуп Шәяхмәтовның олы улын (40 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (55), ике улы, килене (40) һәм өч оныгы белән яши, 10 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була.

Сәрвәретдин Якуп улы 1901 елның 4 гыйнварында авылдашы Гарифулла Сәетбаттал улының кызы Бибимөшәррәфә (18 яшь) белән никахлаша, балалары Кашшафетдин (05.01.1902–1913), Кәшифә (02.03.1904), Хәйдәретдин (23.08.1906), Миңлешәрифә (29.06.1909), Фәрваҗетдин (12.08.1911), Фәрвизә (15.04.1914–1916), Сабира (15.07.1916), Миңлешәрифә (1917) туа.

Гыйлаҗетдин Якуп улы балалары: Хөсникамал (11.07.1912; анасы Шәмсекамал Сәйфетдин кызы), Гыйзаметдин (25.04.1914), Зәйнәгытдин (22.06.1916).

Шәйхулла Хәбибулла улы Солтанбәков балалары: Мәрфуга (1859), Җиһангир (1858), Гайниҗамал (1874–1894). Шәйхулла кызы Мәрфуганы (29 яшь) 1883 елда Сеңрәннең Әбүбәкер Шәмсетдин улына (25 яшь) кияүгә бирә. Никах язуында кызның ризалык шаһитлары булып нәселдәшләре Хөснетдин белән Гыймадетдин Фазлулла уллары теркәлгән.

Хәбибулла Солтанбәковның өченче улы Шәйхелислам иде. Шәйхелисламнан нәселне Нурислам (1858) белән Нургали (1863) дәвам итә.

Нурислам Шәйхелислам улы Солтанбәков балалары: Миңлемаһинур (1888), Бибинур (1891), Фәрхенур (1892–1895), Фәхрислам (29.10.1893; анасы Фәхрикамал), Гыймаделислам (08.10.1895–1895; анасы Фәхрикамал), игезәкләр Зиннәтелислам (04.02.1897) белән Миңлекамал (04.02.1897), Хөҗҗәтелислам (10.07.1900), Галислам (26.02.1903), Миңлесалих (13.11.1909–1910; анасы Фәхеркамал Шәмгол кызы), Әмирҗан (22.11.1925; анасы Хәерниса Исмәгыйль кызы). Нурислам кызы Миңлемаһинур 1905 елның ноябрендә нәселдәше Фәттахетдин Саяфетдин улына (45 яшь) икенче хатынлыкка бара. Икенче кызы Бибинур (17 яшь) 1908 елда Иске Дөмәйнең Мөхәммәтҗан Гарифулла улына (25 яшь; икенче никах) кияүгә чыга. Кызның ризалык шаһитлары Нургали Шәйхелислам улы белән Мөхәммәтнасыйп Хөснетдин улы була. Бибинур иреннән аерылып, 1916 елның 19 февралендә Яңа Корычның Миңлеәхмәт Сираҗетдин улы (29 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Нурисламның төпчек кызы Миңлекамал 1917 елда Күктауның Мөхәммәтҗәлил Мөхәммәтлатыйф улы (25 яшь) белән кавыша. Нурислам Шәйхелисламовның ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (50 яшь), өч улы һәм кызы белән яши, 24,06 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була.

Монда бер искәрмә ясап үтик. Нурислам кызларын Дөмәй, Корыч, Күктау авыллары кешеләренә биргән. Бу һәм башка күп кенә авылларда Яңа Катай кешеләренең ерак нәселдәшләре яшәве, авыллар кан-кардәшлек аркасында тыгыз элемтәдә булуы турында нәсел тамгаларына һәм башка мәгълүматка таянып гел әйтәбез, әлеге никахлар моны дәлилли төшә.

Нурислам улларының язмышлары ничек булган? Фәхрислам Нурисламов (1893) Ватан сугышына киткәндә гаиләсендә хатыны Мәрьям (1901), балалары Мосаллия (1923) белән Тимерҗан (1940) була, язмышы билгесез. Зиннәт Нурисламов (1897) Ватан сугышы алды елларында хатыны Хәкимә (1892), кызы Рәшидә (1924) белән яши. Хөҗҗәт Нурисламов (1900) – Ватан сугышы ветераны, сугышка чаклы гаиләсендә хатыны Майсафа (1900), балалары Әмирҗан (1927), Гөлҗәннәт (1929), Гөлфәридә (1936) була. Галислам Нурисламовның (1903) хатыны Зәйтүнә (1912), кызы Сәгыйдә (1932) билгеле, 1943 елның 3 июнендә хәбәрсез югала. Зиннәтнең язмышын ачыклыйсы бар, ә менә Фәхрислам, Хөҗҗәт, Галислам Нурисламовлар исемнәре Катайның мемориаль стеласына өстәп куелырга тиеш.

Нургали Шәйхелислам улы Солтанбәков балалары: Исламгали (02.12.1893–1895; анасы Миңлежиһан Хөснетдин кызы), Фәрхениса (22.10.1899; анасы Миңлениса Мөхәммәтвәли кызы), Миргали (15.06.1902), Миркасыйм (07.12.1904), Мирзаһит (14.10.1907), Гыйльмиҗиһан (03.08.1910), Гайнелҗиһан (25.03.1914–1917; анасы Миңлениса Вәли кызы). Нургалинең хатыны Балыклының «ясашный башкорт» Хөснетдин Мусакай улының кызы Миңлесафа була, 1895 елның 28 мартында «араларында мәхәббәт вә өлфәт булмаган сәбәпле» аерылышалар. Шул ук Нургали (30 яшь; өченче никах) 1898 елның 7 апрелендә Минзәлә өязе Ирәкте олысы Вәрәш авылының Мөхәммәтвәли Габделкадыйр улының кызы Миңлениса (18 яшь) белән кавыша. Нургали Шәйхелисламов 1917 елда хатыны (35 яшь), өч улы һәм дүрт кызы белән яши, 9,14 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була. Картлардан сораштырып, истәлекләр язып алганда, Нургали улларыннан Миркасыймны телгә алганнар иде, бу китапны нәшер итәргә әзерләгәндә Миркасыйм Нургалиевнең сугыш вакытында яраланып госпитальдә ятканын ачыкладым (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Хәбибулла Солтанбәковның төпчек улы Шәймораттан Фатыйма (1866) билгеле. Фатыйма (17 яшь) 1883 елның 7 декабрендә Үрмәтнең Сәйфулла Таҗетдин улы (25 яшь) белән никахлаша.

Солтанбәкнең өченче улы Фәтхуллага (1786) күчәбез. Хәрби хезмәткә җәлеп ителгәнлектән, дәрәҗәсе («юртовый есаул») була, нәселен бердәнбер улы Мөхәммәтвәли (1813–05.12.1890) дәвам итә. Мөхәммәтвәли Фәтхулла улы Солтанбәков балалары: Мөхәммәтшәриф (1834–07.10.1898), Сәлимгәрәй (1839), Асылгәрәй (1842), Дәүләтгәрәй (1849), Хафизгәрәй (1853), Әхмәтгәрәй (1856) һәм Фазыйлгәрәй. Мөхәммәтвәлинең соңгы никахы Туктаголның Гайникамал Сибгатулла кызы белән була, 1889 елның 29 гыйнварында «өлфәт вә мәхәббәт булмау сәбәпле» аерылышалар.

Мөхәммәтшәриф Мөхәммәтвәли улы балалары: Хаҗгали (1862–25.08.1925), Арслангали (1864), Хаҗимөхәммәт (1865), Мөхәммәткәрим (1866–09.09.1925), Сәрвәретдин (1875), Нургали (07.01.1880; анасы Якутелҗинан), Шәйшәриф (1885).

Хаҗгали Мөхәммәтшәриф улы Фәтхуллин (Вәлиев дип тә языла) балалары: Шәмсевафа (1895), Миңлесафа (24.03.1900; анасы Миңлевафа Тимербай кызы), Хәйдәргали (21.01.1903), Гыйльмисафа (04.01.1907). Хаҗгали кызы Шәмсевафа 1913 елда Корычның Сәрвәретдин Баһаутдин улы (25 яшь) белән никахлаша.

Арслангали Мөхәммәтшәриф улы Солтанбәков (25 яшь) 1890 елның 12 гыйнварында Иске Катайның Габделнасыйр Габделкаһир улының кызы Гыйльмебану (18 яшь) белән кавыша. Арслангали балалары: Шагали (17.12.1890), Сәетгали (21.04.1894; анасы Гыйльмебану), Гаделбану (1899–1901), Фатыйма (13.11.1901–1901; анасы Нәгыймә Гыйльметдин кызы), Тимергали (14.07.1904; анасы Хәлимә Гыйльметдин кызы), Дәүләтгали (02.12.1910),

Әхмәтвәли (01.05.1914–1916, кызамыктан вафат; анасы Нәгыймә Гыйльметдин кызы).

Хаҗимөхәммәт Мөхәммәтшәриф улы Солтанбәков балалары: Шәмсевафа (23.03.1894; анасы Миңлевафа Тимербай кызы), Шәмсебану (02.06.1897; атасы Мөхәммәтхаҗи дип язылган). Мөхәммәтхаҗи Шәриповның улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (56 яшь) һәм дүрт кызы белән яши, 2,30 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була.

Мөхәммәткәрим Мөхәммәтшәриф улы Мөхәммәтвәлиев балалары: Мөхәммәтзариф (13.06.1895; анасы Гөлбану Гафиятулла Хәсән улының кызы), Гыйльмебану (18.07.1898), Мөхәммәтгариф (21.03.1901–1925). Кәрим Шәриповның олы улы Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (45 яшь), ике улы һәм кызы белән яши, 6,12 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була.

Сәрвәретдин Мөхәммәтшәриф улы балалары: Фәрхинур (25.01.1906; анасы Фәхерниса Мөхәммәтвәли кызы), Фәрхисорур (14.10.1908–1914), Майсорур (14.12.1910), Шәмсенур (05.05.1914), Фәрхисорур (05.10.1916). Сәрвәретдин Шәрипов гаиләсе 1917 елда хатыны (35 яшь) һәм дүрт кызыннан тора, 4,64 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була. Сәрвәр Шәрипов (1875) Ватан сугышы алдыннан хатыны Фәхерниса (1880), кызы Фәрбизә (1929) белән яши.

Нургали Мөхәммәтшәриф улы балалары: Муллагали (22.09.1906; анасы Бибисәвия Гыйрфанетдин кызы), Мирзагали (1908–1917), Миргасим (09.12.1910), Бибикамилә (19.12.1912), Саҗидә (02.12.1914), Миргали (10.10.1916–1917). Нургали Шәриповны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (33 яшь), ике улы һәм кызы кала, 1917 елда 9,05 дисәтинә җире, 3 аты, сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче яллый. Нургали улы Муллагали (1906) совет чорында загстан туу турында белешмә ала, язмышы билгесез.

Шәйшәриф Мөхәммәтшәриф улы (25 яшь) 1910 елның 12 ноябрендә авылдашы Габделзаһир Габделихсан улының кызы Хөсниҗиһан (17 яшь) белән никахлаша, кызы Гөлҗиһан (18.01.1913) туа. Шәйшәриф Шәриповны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (25 яшь) һәм кызы кала, 4,73 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче яллый. Шәйшәриф (өченче никах) 1925 елның 2 февралендә Чүмәлә Катайның Шәмсеҗиһан Гали кызы (22 яшь; икенче никах) белән никахлаша, Шәрифгали (15.11.1925) туа.

Югарыда нәселне Мөхәммәтвәли Фәтхулла улы Солтанбәковның беренче улы Мөхәммәтшәриф яклап карадык. Алга таба Мөхәммәтвәлинең башка улларына тукталып үтәбез.

Сәлимгәрәй Мөхәммәтвәли улы балалары: Зиннәтулла (07.08.1874), Әбуталип (20.03.1878; анасы Бибимәхтүмә), Бибисара (1888). Мөхәммәтвәли кызы Бибисара 1905 елның декабрендә авылдашы Садретдин Гыймадетдин улы (22 яшь; атасы Гыймадетдин Фазлулла улы) белән никахлаша.

Асылгәрәй Мөхәммәтвәли улы Солтанбәков балалары: Сәетгәрәй (1871), Сәхипгәрәй (02.08.1876), Миңлеәхмәт (20.01.1880; анасы Шәрифә). Сәетгәрәйнең Шәмсия Миңлегали кызы белән никахыннан Мөхәммәтгәрәй (10.01.1897) туа. 1899 елның 15 гыйнварында Сәетгәрәй (28 яшь; икенче никах) Килкабызның Шәмсенур Миңлегали кызы (23 яшь; икенче никах) белән кавыша, балалары Дөррия (27.09.1900), Мәдинә (1901–1904), Бибинур (23.07.1907), Маһинур (05.11.1913) туа. Сәетгәрәй Асылгәрәевне һәм аның улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (45 яшь) һәм ике кызы кала, 1917 елда 1,25 дисәтинә җире, сарыгы була.

Хафизгәрәй Мөхәммәтвәли улы Фәтхуллин (Солтанбәков) балалары: Батыргәрәй (1881), Афзалетдин, Мөхәммәтдин (1889–1980), Имаметдин (1890–1913), Хәкимә (1894), Гыймадетдин (17.12.1895; анасы Гайнелхәят Мөхәммәтәмин Мөхәммәдьяров кызы), Җәмгыйтдин (03.03.1899), Әгъләметдин (25.12.1901). Хафизгәрәй кызы Хәкимә 1912 елда Килкабызның Мөхәммәтхан Әхмәтлатыйф улы (25 яшь; атасы Әхмәтлатыйф Тимергази улы) белән никахлаша. Хафизгәрәй Вәлиев 1917 елда хатыны (57 яшь) һәм өч улы белән яши, 8,25 дисәтинә җире була.

Батыргәрәй Хафизгәрәй улы балалары: Афзалетдин (23.08.1906), Гыйльметдин (09.01.1909; анасы Мәрфуга Галиакбәр кызы), Кашшафетдин (06.08.1911–1912), Фәрхебану (25.03.1913), Шәмсебану (13.08.1915). Афзалетдин Ватан сугышына Чүмәлә Катайдан китә, 1942 елда хәбәрсез югала.

Мөхәммәтдин Хафизов Ватан сугышы алдыннан хатыны Фәрхисорур (1896), кызлары Мәдхиҗамал (1921), Кифая (1927), уллары Әнгам (1927), Гыйниятулла (1930), Әнвәр (1935) белән яши. Шушы Әнгам Хафизовмы (туган елы күрсәтелмәгән; кавалерист), Сталинград өлкәсендә барган сугышта 1942 елның 22 ноябрендә һәлак була.

Әгъләметдин Хафизгәрәй улы (25 яшь) 1925 елның 15 гыйнварында Хәмдесафа Вәлиәхмәт кызы (20 яшь; атасы Вәлиәхмәт Шәяхмәт кызы) белән никахлаша. Әгъләм Хафизов 1942 елның көзендә сугышта һәлак була (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән), хатыны Хәмдесафа (1904), уллары Мәснәви (1929), Мәдих (1932), Фәбис (1934) һәм Мөхәррәм (1939) кала. Мәснәви белән Фәүханә балалары: Ясави, Фәнзилә, Равил, Мөнәвис, Фәүнә, Флера. Мәдих белән Әнисә Габделкотдус кызы балалары: Фәнзәлия, Мәгъфия, Әлфинә, Румия, Расих. Мөхәррәм белән Нәзифә балалары: Тимерҗан, Әлфия, Фәнзирә. Мәгълүматның бер өлешен классташым Фәнзәлия Мәдих кызы Хәбибуллина (Хафизова) язып җибәрде.

Әхмәтгәрәй Мөхәммәтвәли улы Фәтхуллин (Солтанбәков) балалары: Хөснниҗиһан (1892), Шәмсеҗиһан (1893), Мөхәммәтнәби (26.06.1895; анасы Сәрвиҗиһан Габделгалим Тимергали улының кызы), Хәлфиҗиһан (20.04.1899). Әхмәтгәрәй кызы Шәмсеҗиһанны (17 яшь) 1910 елның 2 гыйнварында нәселдәше Әһлетдин Гыймадетдин улына кияүгә (25 яшь; атасы Гыймадетдин Фазлулла улы) бирә. Кызның ризалык шаһитлары – Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтвәли улы

белән Нургали Мөхәммәтшәриф улы, кияүнеке Әхмәтситдыйкъ Габделмәннаф улы белән Вәлиәхмәт Мөхәммәтгали улы була (барысының да тамгалары Арсланбәк нәселенеке). Икенче кызы Хөснижиһанны (18 яшь) шул ук елның 6 декабрендә Килкабызның Гыйльман Рамазан улы (22 яшь; атасы Рамазан Габдрахман улы) белән кавыштыра.

Мөхәммәтвәли Фәтхулла улы Солтанбәковның дүртенче улы Дәүләтгәрәйдән дә нәсел дәвам итә. Дәүләтгәрәй Мөхәммәтвәли улы балалары: Дәүләтгали (28.08.1874; анасы Сара), Шәйсолтан (01.08.1877), Бибифакия (1889), Бибисафура, Фәрхебану (26.06.1894–1895; анасы Шәһәрбану). Дәүләтгәрәй кызы Бибифакия (17 яшь) 1906 елның ноябрендә авылдашы Фәтхелбәян Дәүләтгир улы (25 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Бибисафура 1910 елның 6 декабрендә Тыпыйның Гыйкрәмә Мөхәммәтгалим улы (22 яшь; атасы Мөхәммәтгалим Мөхәммәтгали улы) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары туганы Шәйсолтан Дәүләтгәрәй улы белән нәселдәше Нургали Мөхәммәтшәриф улы була.

Дәүләтгали Дәүләтгәрәй улы балалары: Галихәйдәр (29.06.1903), Габделгали (15.03.1906; анасы Габидә Баһаутдин кызы), Шагали (25.01.1909), Мирзагали (15.11.1911), Әминә (01.01.1915–1915).

Шәйсолтан Дәүләтгәрәй улы (24 яшь) 1901 елда Иске Катайның Ибраһим Мөхетдин улының кызы Мөнәвәрә (20 яшь) белән никахлаша. Шәйсолтан балалары: Мәгъфүрә (20.10.1904; анасы Бибимөнәвәрә Ибраһим кызы), Мәгъфүрә (1906–1910), Шагали (02.01.1907–1915), Шаһинур (28.02.1910), Шәйхенур (03.06.1913–1917), Зөләйха (09.09.1925; анасы Талибә). Шәйсолтан Дәүләтов Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, Ватан сугышы алдыннан хатыны Талибә (1894), балалары Һидая (1928) һәм Мәвләви (1932) белән яши.

Югарыда Солтанбәкнең өченче улы Фәтхулладан киткән тармаклар каралды. Солтанбәкнең калган уллары турында әйтеп үтик. Төхфәтулла Солтанбәков 1829 елның 21 мартында мөәзинлеккә указ ала, Яңа Катай барлыкка килгәч, вазифасын шунда башкара, нәселен дәвам итүче ир баласы булмый. Сафиулла Солтанбәковның 1845 елда улы Һидиятулла дөньяга килә. Һидиятулла Сафиулла улы Солтанбәков балалары: Миңлекамал (1875), Майкамал (06.04.1877–1898), Зиннәтулла (17.11.1880; анасы Гыйззекамал), Хөрмәтулла (07.10.1883), Габидулла. Һидиятулла кызы Миңлекамал 1893 елның 8 мартында Корычның Әхмәтвәли Миңлегали улы (22 яшь) белән кавыша. Икенче кызы Майкамал 1894 елның 14 гыйнварында Минзәлә өязе Әмәкәй олысы Әлмәт авылының Шәяхмәт Фазлыәхмәт (28 яшь) улы белән никахлаша.

Зиннәтулла Һидиятулла улы балалары: Майкамал (30.10.1905–05.01.1906; анасы Фәтхия Мәгъдәннур кызы), Мөхәммәтшәриф (12.12.1907–1907; анасы Бибизәкия), Нурулла (19.07.1910), Фәүзия (11.09.1913; анасы Зәкия Әюп кызы), Лотфулла (12.10.1915). Зиннәтулланың беренче хатыны Фәтхия (Мәгъдәннур Гыйльман улының кызы) 1906 елның 8 гыйнварында 20 яшьтә вафат була.

Габидулла Һидиятулла улы балалары: Фәүзия (22.03.1912; анасы Фәхерҗиһан Мөхәммәтнәби кызы), Сәвия (14.03.1914). Габидулланы Беренче бө-

тендөнья сугышына алалар, 1916 елның 24 декабрендә Румыниядә хәбәрсез югала.

Арсланбәкнең икенче улы Габидулла (русча чыганакларда Гобәйдулла дип хаталы язылган очраклар да бар) да шактый нәсел калдыра: Рәхмәтулла (туган елы билгесез), Тимербулат (1801–26.10.1878), Сәетбаттал (1805), Сәйфелмөлек (1808–1828), Тимергали (1810), Мөхәммәтгали (1814), Мөхәммәтша (1819). Боларның һәрберсенә аерым тукталып үтик.

Рәхмәтулладан Һибәтулла (1798) туа, Һибәтулладан нәселне Гыйззәтулла (1835–25.02.1911) дәвам итә.

Гыйззәтулла Һибәтулла улы балалары: Минхәтулла (1856–1898), Бибилатыйфа (1863), Әһлиулла (1867), Мосифулла (1868–02.05.1912), Бибитаифә (1873), Төхфәтула, Сәйфулла, Мохтарулла (1875), Фәтхулла, Хәбибулла (14.11.1890; анасы Гаделбану Җиһанша кызы). Гыйззәтулла кызы Бибилатыйфа (20 яшь) 1883 елда Иштирәкнең Ногман Мөхәммәтвәли улы (25 яшь) белән никахлаша. Никах язуында кызның энесе Әһлиулла Гыйззәтулла улы нәсел тамгасын салган. Шунда ук Фәтхулла Гыйззәтулла улы да ризалык шаһиты булып язылган. Гыйззәтулланың икенче кызы Бибитаифә (17 яшь) 1890 елның 23 ноябрендә Корычның Әдһәмгали мөәзин Мөхәммәтсадыйк улы (25 яшь) белән кавыша.

Минхәтулла Гыйззәтулла улы Һибәтуллин балалары: Маһиҗиһан (1882), Нурҗиһан (04.02.1883; анасы Бәдриҗиһан), Бибифакия (14.08.1889), Бибифатыйма (1894 елда вафат), Гыйльмиҗиһан (09.03.1895–1895; анасы Бибихәкимә Габделгани Габделкәрим улының кызы). Минхәтулла кызы Маһиҗиһан (17 яшь) 1899 елның 10 октябрендә Килкабызның Дәүләтгир Габделсаттар улы (20 яшь; атасы Габделсаттар Габделхаликъ улы) белән кавыша. Кызның вәли вәкиле карт әткәсе Гыйззәтулла Һибәтулла улы, ризалык шаһитлары Сәйфулла һәм Төхфәтулла Гыйззәтулла уллары була.

Әһлиулла Гыйззәтулла улы Һибәтуллин балалары: Гыйльмебану (1888), Гыйниятулла (16.05.1894–1895; анасы Гаделбану Җиһанша Булат улының кызы), Рәхмәтулла (30.06.1900). Әһлиулла кызы Гыйльмебану 1905 елның 6 гыйнварында авылдашы Мәхмүтҗан Мөхәммәтҗан улы (23 яшь) белән никахлаша. Гыйльмебану ирдән аерылып, 1906 елның 5 декабрендә Сеңрәннең хатын аерган Шәехзаман Шәймәрдан улы (34 яшь; өченче никах) белән кавыша. Әһлиулланың икенче никахы 1897 елның 14 августында Иске Катайның Габдерәшит Габделгалләм улының кызы Бибисәвия (20 яшь; икенче никах) белән була.

Мосифулла Гыйззәтулла улы Һибәтуллин балалары: Сафура (1891–1895), Бибихәтимә (01.11.1894; анасы Маһинур типтәр Әхмәтҗан Каракай улының кызы), Әхмәтгази (19.10.1897), Бәһия (1901–1901), Мөхәммәтмәкки (28.10.1909; анасы Майбану Әхмәтҗан кызы), Дөһөдия (22.04.1912).

Төхфәтулла Гыйззәтулла улы Һибәтуллин балалары: Мөхәммәтхәниф (25.01.1898; анасы Бибизәкия Әхмәтша Гаделша улының кызы), Мөхәммәткәшиф (17.08.1900), Мөхәммәтзариф (16.08.1904–1906).

Сәйфулла Гыйzzәтулла улы Һибәтуллин балалары: Бәһия (05.06.1901–1901), Бәһия (01.08.1902; анасы Маһинур Әхмәтҗан кызы).

Мохтарулла Гыйzzәтулла улы Һибәтуллин балалары: Галимә (16.12.1903–1905; анасы Бибифатыйма Фәтхелислам кызы), Нурулла (19.07.1906), Ярулла (10.12.1909), Сәгъдулла (25.08.1914–1914). Мохтарулла кызы Нурҗиһан (17 яшь) 1902 елның 11 ноябрендә Килкабызның Арслангали Миңлегали улына (21 яшь) кияүгә чыга. Мохтарулла Гыйzzәтуллинны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (35 яшь) һәм ике улы кала, 1917 елда 6,56 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була. Мохтар Гыйздәтов (1875) Ватан сугышы алдыннан хатыны Әдия (1883), балалары Габдулла (1924), Саҗидә (1926), Фаягөл (1928) белән яши. Аның улы Ярулла Мохтаров (1909; колхозда тракторчы, 1941 елның 12 сентябрендә хәрби хезмәткә чакырыла) гаиләсендә бу вакытта хатыны Мәдхизиян (1912), балалары Хәтмулла (1935), Фәнүдә (1937), Нәҗибә (1939), Хәдимулла (1941) була. Ярулла – Ватан сугышы корбаны, «Халык хәтере» («Память народа») сайтында «Гизатуллин Ярулла Мухтарович» дип теркәлгән.

Югарыда нәселне Габидулла Арсланбәковның беренче улы Рәхмәтулла яклап карадык. Габидулланың икенче улы Тимербулаттан нәселне Дәүләтша (1821), Җиһанша (1824–10.04.1899), Фәйруша (1826–02.10.1910; метрикәдә Фәйрузша), Гайнанша (1828), Шәймәрдан (Шаһимәрдан, 1836–02.03.1913), Шәнгәрәй (Шаһингәрәй, Шәйгәрәй; 1839–13.07.1915) дәвам итә.

Дәүләтша Тимербулат улы балалары: Миңлегәрәй (1844–05.04.1894), Дәүләтгәрәй (1847), Фәрхепҗамал (1858), Сәлимгәрәй (1859). Дәүләтша кызы Фәрхепҗамал (17 яшь) 1876 елның 9 мартында Балыклының Әхмәтгәрәй Арслангәрәй улы (19 яшь) белән никахлаша.

Миңлегәрәй Дәүләтша улы Булатов балалары: Әхмәтгәрәй, Батыргәрәй (1872), Миңлеәхмәт (20.10.1874; анасы Фәрхебану), Гыйльмебану (16.11.1877), Миңлежиһанбану (10.06.1880; анасы Шәмсебану), Хәмидәбану (12.06.1883), Газизәбану (1886–1907), Миңлеәхмәт (1889–1889; анасы Шәмсебану Габделгалим кызы). Миңлегәрәй кызы Газизәбану (17 яшь) 1902 елның 22 июнендә Иске Куянның Һибәтулла Төхфәтулла улы (22 яшь; атасы Төхфәтулла Хәбибулла улы) белән никахлаша. Ирдән аерылгач, Газизәбану 1906 елның мартында хатыны вафат булган авылдашы Хәсәнҗан Нуриәхмәт улы (25 яшь) белән кавыша.

Сүз уңаеннан әйтик, югарыда телгә алынган куянлы Һибәтулла Төхфәтулла улы – өлкән дустым Рәмил Әмир улы Ибәтуллинның бабасы. Аның шәҗәрә схемасы болай: Бикмәт – Мөхсин – Сәйфулла (1776) – Хәбибулла (1803–1886) – Төхфәтулла (1847–1904) – Ибәтулла (1876) – Миңсылу (1923–1995) – Рәмил (1949).

Әхмәтгәрәй Миңлегәрәй улы Дәүләтшин (22 яшь) 1894 елның 12 ноябрендә авылдашы Шәйхулла Шәймәрдан улы Нөрмәтов кызы Сафура (17 яшь) белән кавыша. Әхмәтгәрәй балалары: Солтангәрәй (11.04.1900; анасы Сафура Шәй-

хулла кызы), Майбану (18.04.1910), Сәетгәрәй (17.06.1913–1916, кызамыктан вафат; анасы Сафура), Әбелкәрам (03.09.1914; анасы Миңлежиһан Яхъя кызы), Дәүләтгәрәй (25.03.1916; анасы Сафура Шәйхетдин кызы).



**Өлкән дустым Рәмил Ибәтуллин белән. 2017 ел**

Җиһанша Тимербулат улының кызы Мәүлиха (1866) билгеле. Ул кыз 1883 елда Корычның Әһлетдин Хөснетдин улы белән никахлаша. Никах язуында Җиһанша Тимербулат улы белән Мөхәммәтша Габидулла улы нәсел тамгасын салганнар, шунда ук кияүнең атасы Хөснетдин Ярмөхәммәт улы тамгасын да күрәбез.

Тимербулатның өченче улы Фәйруша туганнары арасында зур дини белемле булуы белән аерылып торган. 1902 елгы метрикәдә мулла дип язылган, димәк, мәдрәсә бетергән, әмма муллалыкка указ алмаган. Мулла Фәйруша Тимербулат улы балалары: Хәсәнша, Нәбиулла (1862), Галиулла (1866), Мохтарулла (1872). Хәсәнша Фәйруша улы Булатовның кызы Бибигания (14.06.1889; анасы Бибисара Габдулла кызы) билгеле.

Нәбиулла Фәйруша улы Габидуллин балалары: Җәләлетдин (06.06.1895), Миңлеҗәмилә (06.01.1898; анасы Миңлебану Камалетдин Мөстәкыйм улының кызы), Габдулла (06.04.1901). Нәбиулла Фәйрушинның (55 яшь) уртанчы улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (55), ике улы, кызы һәм килене (20) белән яши, 6,55 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була.

Галиулла мулла Фәйруша улы Габидуллин 1895 елның 10 гыйнварында авылдашы Мәрданша Әхмәди улы Азаматов кызы Шәмсениса белән никахлаша, балалары Сафиулла (04.01.1897), Гыйльмениса (24.08.1902), Гыйззениса (28.08.1907) туа. Галиулла Фәйрушин Ватан сугышы алдыннан хатыны Шәмсениса (1869), оныклары Мөзәянә (1921), Мөнәвәрә (1929), Мөкәррәмә (1931) белән яши. Сафиулла Галиулла улының беренче хатыны мәрхүм була, аннан кызлары Мөзәянә белән Мөнәвәрә кала. Сафиулланың икенче никахы авылдашы Галимә белән була, балалары Фәнә (1937), Фәнил (1939), Ләйлә (1942) дөньяга килә. Сафиулла Галиуллин 1942 елда Смоленск өлкәсендә барган сугышларда һәлак була (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән). Фәнил Галиуллин Иске Катайның Мөхәммәтдин Хафизов кызы Гафия белән гаилә кора, балалары Фәнзирә (1967), Лүзил (1969), Лүзә (1973) туа. Галиулланың балалары һәм оныклары турында өстәмә мәгълүматны Лүзә Сөнәгәтуллина (Галиуллина) язып җибәрде.

Мохтарулла Фәйруша улы балалары: Сания (04.01.1902; анасы Шәмсия Вәлиша кызы), Мөхәммәт (04.03.1904), Муллаәхмәт (25.06.1906), Сә-

хия (10.10.1908), Нух (12.01.1911–1911), Локман (14.07.1912–1912), Гайнелгалим (28.08.1913), Гания (02.11.1916). Мохтарулла Фәйрушин 1917 елда хатыны (40 яшь), өч улы һәм өч кызы белән яши, 9,06 дисәтинә җире, 5 кәҗәсе була.

Тимербулатның дүртенче улы Гайнаншага күчик. Гайнанша Тимербулат улы балалары: Нуриәхмәт (Нурәхмәт; 1860), Шәяхмәт (1865), Фазлыәхмәт (1869).

Нуриәхмәт Гайнанша улы Булатов балалары: Хаҗиәхмәт (24.03.1889; анасы Хафизә), Фазлыәхмәт (1890), игезәкләр Хәсән белән Хөсәен (07.06.1897; анасы Миңлевафа Нәбиулла Хәбибулла улының кызы), Шакирҗан (08.12.1903; анасы Хәмдевафа Нәбиулла кызы), Галимҗан (30.05.1907), Камилә (10.06.1910–1911; анасы Хәмдевафа), Нигъмәтҗан (02.01.1916–1917; анасы Мәрфуга Мөхәммәтзакир кызы). Нурәхмәт Гайнаншинның ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (57 яшь), өч улы һәм кызы белән яши, 1,89 дисәтинә җире, аты була. Фазлыәхмәт Нуриәхмәт улы (26 яшь) 1917 елның 20 февралендә Куянның Мөхәммәтзакир Миңлехан улының кызы Мөшәррәфә (30 яшь; икенче никах) белән никахлаша.

Фазлыәхмәт Гайнанша улы (25 яшь) 1894 елның 28 мартында Кадернең Мөхәммәтшәфикъ Габдерәфикъ улы Рәхимов кызы Мәэлүфә (17 яшь) белән никахлаша. Фазлыәхмәт балалары: Мәгъсуфә (1894), Мәгъсүмә (07.07.1898–1901), Мәбрүрә (16.07.1901–1904; анасы Мәэлүфә Габделшәфикъ кызы), Муллаәхмәт (13.07.1904–1905; анасы Мәэлүфә Мөхәммәтшәфикъ кызы), Мәгъмүрә (22.12.1906), Мәгъфүрә (1907–1909), Әхләм (18.03.1909), Бибисәкинә (25.01.1912–1913; анасы Зәйнәп Мөхәммәтлатыйф кызы), Хуҗагали (16.02.1914), Мәбрүрә (06.10.1917). Фазлыәхмәт кызы Мәгъсуфә 1911 елда Иске Катайның Шәмсемөхәммәт Мөхәммәтситдыйкъ улы (25 яшь) белән никахлаша. Фазлыәхмәт Гайнаншин 1917 елда хатыны (48 яшь) һәм ике улы белән яши, 4,31 дисәтинә җире, 2 аты, 3 сарыгы була. Әхләм Фазлыевнең (1909) хатыны Зәкия (1902), кызы Тәзкирә (1938) билгеле. Бурят-Монголиядән сугышка китә, 1942 елның көзендә агуланудан мәрхүм була.

Тимербулатның бишенче улы Шәймәрданнан да нәсел дәвам итә. Шәймәрдан балалары: Шәрәфетдин (1873), Шәмсекамал (1878–1893), Бәдримөнирә (05.08.1880; анасы Фәрхиҗамал). Шәймәрдан кызы Бәдримөнирә (17 яшь) 1899 елның 2 декабрендә Иске Катайның Миңлеәхмәт Якуп улы (25 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Шәрәфетдин Шәймәрдан улы белән Вәлиәхмәт Мөхәммәтгали улы була.

Шәрәфетдин Шәймәрдан улы (25 яшь) 1898 елның 25 октябрендә Сеңрәннең Бибимәрхәбә Дәүләтгәрәй кызы (18 яшь) белән никахлаша. Шәрәфетдин балалары: Мәхдүмә (18.02.1901), Дөһәдия (13.06.1906–1909; анасы Мәрхәбә Дәүләтгәрәй кызы), Тәзкирә (03.01.1908), Бәдретдин (20.08.1911), Шәрхемулла (10.03.1915–1916).

Тимербулат Габидуллинның төпчек улы Шәнгәрәй (Шаһингәрәй) дә нәсел калдыра. Шәнгәрәй Тимербулат улы Габидуллин балалары: Сәлимгәрәй (28.11.1876; анасы Фәрхиҗамал), Зәйнәп (1877), Бибимәрьям (15.10.1880), Мә-

хиян (1884), Мәүҗүдә (04.10.1893; анасы Хафизә). Шәнгәрәй кызы Зәйнәп (17 яшь) 1895 елның 1 гыйнварында Иске Катайның Гайса Габделгаләм улы Хәкимов (30 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Сәлимгәрәй Шәнгәрәй улы белән Вәлиәхмәт Мөхәммәтгали улы була. Шәнгәрәйнең икенче кызы Мәүҗүдә 1912 елда авылдашы Миңлегали Миңлехәким улы (23 яшь) белән никахлаша. Мәхиян Шәнгәрәев (31 яшь) 1915 елның 21 февралендә 4 нче Себер полкы составында Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, яралана, госпитальдә ята.

Сәлимгәрәй Шәнгәрәй улы (25 яшь) 1897 елның 30 декабрендә Иске Катайның Шәрифулла Төхфәтулла улының кызы Фәхерҗиһан (18 яшь) белән гаилә кора. Сәлимгәрәй балалары: Әкълимә (17.11.1900; анасы Фәхерҗиһан), Һаҗәр (28.01.1904; анасы Бибинур Хөснетдин кызы), Мөҗәһит (22.09.1906–1910; анасы Бибинур Хөснетдин кызы), Мөгаллим (01.03.1912–1912; анасы Заһирә Фәттахетдин кызы), Мирсәгыйть (15.12.1913), Мирсалих (01.12.1916). Сәлимгәрәй Шәнгәрәев гаиләсе белән Чүмәлә Катайга (Утар авыл советы, «Пушкин» колхозы) күчеп утыра, бер улы (Әнгам, 1923) 1944 елның гыйнвар башында Ленинград өлкәсендә барган сугышларда һәлак була.

Габидулла Арсланбәковның өченче улы Сәетбаттал иде. Сәетбаттал уллары Сәйфетдияр (1833), Гарифулла (1848) һәм Хәмидулла (1856) була. Сәетбаттал Габидуллин Яңа Катайда җәмигъ мәчет салу белән бәйле 1853 елгы документта телгә алына (бу хакта, бәлки, беренче китапта тулырак сөйләп үтәргә кирәк булгандыр) [БҮДТА, И-2 ф., 1 тасв., 7550 сакл. бер.].

Сәйфетдияр Сәетбаттал улының бер кызы (Мәгъдәнҗиһан (1865–1894)) билгеле. Гарифулла Сәетбаттал улы балалары: Бибимөшәррәфә (25.01.1880), Тимергази (1888–1889). Гарифулла кызы Бибимөшәррәфә (18 яшь) 1901 елның 4 гыйнварында нәселдәше Сәрвәретдин Якуп улы (22 яшь) белән кавыша.

Габидулла Арсланбәковның дүртенче улы Тимергалигә тукталыйк. Әлеге тармак Габделгалим (1836), Якуп (1844), Йосыф (сабый вакытта вафат була), Даут (1855), Әхмәтшалар (1859) белән билгеле.

Габделгалим Тимергали улы Габидуллов балалары: Хәбибрахман (1875), Габдрахман (28.05.1878; анасы Шәмсеруй). Габделгалим кызы Гыйльмиҗиһан (18 яшь) 1895 елның 25 октябрендә авылдашы Хәбибрахман Габделвахит улы Габделвафиев (26 яшь) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле – атасы белән бертуган агасы Әхмәтша Тимергали улы, ризалык шаһитлары Хәбибрахман Габделгалим улы белән Әфләтун Габделлатыйф улы була.

Хәбибрахман Габделгалим улы балалары: Бәһия (02.01.1909), Габбәс (01.02.1911; анасы Маһитап Хәким кызы), Габделкотдус (12.10.1914–1915). Хәбибрахман Габделгалимовны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (35 яшь), улы һәм өч кызы кала, 1917 елда 1,90 дисәтинә җире, кәҗәсе була.

Габдрахман Габделгалим улы балалары: Мәдхия (23.06.1902), Лотфрахман (04.06.1911–1915; анасы Мәгъфүрә Мослахетдин кызы), Зөләйха (18.05.1914).

Габдрахман Габделгалимовны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (35 яшь), улы һәм өч кызы кала, 1917 елда 4,53 дисәтинә җире, аты, кәҗәсе була.

Якуп Тимергали улы нәселен Йосыф (1876) дәвам итә. Йосыф Якуп улы Тимергалиев балалары: Мөхәммәтгариф (04.03.1903), Гыйльмехәят (04.11.1905; анасы Латыйфахәят Гыйззәтулла кызы), Мөхәммәтнәҗип (02.04.1908), Шәмсехәят (1909–1915), Бибиәминә (1910–1911), Бибигалимә (03.12.1911), Мөхәммәтнасыйх (15.12.1914), Нәҗип (1923), Насыйх (1924). Нәҗип Йосыф улы Якупов (1923) – Ватан сугышы ветераны, туганы Насыйх 1943 елның гыйнварында сугышта һәлак була.

Әхмәтша Тимергали улы Габидуллов (Булатов дип язылган очраклар да бар) балалары: Әхмәтситдыйкъ (1880), Гайникамал (1886), Сабирҗан (04.08.1889; анасы Майшәрифә Габделвахит Габделвафи улының кызы), Миңлекамал (23.06.1893, анасы Гайниҗамал Габделихсан Габделкәрим улының кызы), Майсорур (24.11.1893; анасы Майшәрифә Габделвахит Габделвафи улының кызы), Нигъмәтҗан (1896–1903), Хәбирҗан (30.03.1897; анасы Гайниҗамал), Закирҗан (16.06.1899; анасы Гайнелхәят Габделихсан Габдерәхим улының кызы), Бибисорур (02.01.1903; анасы Майшәрифә), Нигъмәтҗан (28.08.1910; анасы Камилә Фәррахетдин кызы), игезәкләр Хәсән (1913–1914) белән Хөсәен (15.06.1913–1913; анасы Камилә), Шәкүрҗан (03.03.1916). Әхмәтша кызы Гайникамал 1903 елның 30 октябрендә Иске Катайның Габделгалим Ибнәмин улы (30 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Икенче кызы Миңлекамал 1911 елда Туктаголның Нурлыгаян Хөснулла улы (25 яшь; атасы Хөснулла Сәлимгәрәй улы) белән кавыша. Шәкүрҗан Әхмәтшин (1916) – Бөек Ватан сугышы ветераны (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Әхмәтша Тимергали улы 1895 елның 1 гыйнварында авылдашы Габделихсан Габдерәхим улының кызы Гайниҗамал белән аерылыша («араларында өлфәт вә мәхәббәт булмаган сәбәпле»). Әллә бер ай эчендә мәхәббәтләре яңарып, бер-берсенә хөрмәт (өлфәт) арткан, Әхмәтша Тимергали улы (өченче никах) 1895 елның 6 февралендә шул ук Гайниҗамал (30 яшь; икенче никах) белән яңадан кавыша. Әхмәтшаның соңгы никахы (47 яшь) 1905 елның 17 ноябрендә Иске Катайның Фәррахетдин Шәйхетдин улының кызы Бибикамилә (17 яшь; Табыш нәселе) белән була. Әлеге никахтан Нигъмәтҗан һәм башка балалары туа. Әхмәтша Тимергали улы гомеренең соңгы чорын Чүмәлә Катайда яши, анда туган бер улы (Габдулла, 1924–1925; анасы Камилә Фәррахетдин кызы) метрикәдә теркәлгән.

Әхмәтситдыйкъ Әхмәтша улы (22 яшь) 1902 елның ноябрендә авылдашы Габделхак Габделнәфикъ улының кызы Галиябану (17 яшь) белән никахлаша. Әхмәтситдыйкъ балалары: Габделкәбир (13.10.1904), Галимә, Әхмәтнәгыйм (17.11.1909), Иклимә (09.03.1912; анасы Галиябану), Әхмәтлатыйф (25.07.1914), Мөхтәрәм (1921), Нажия (1926). Иклимә нәселдәше Вәлиәхмәт

Вәлимөхәммәт улы белән никахлаша. Габделкәбир Әхмәтситдыйкъ улы Әхмәтшин (1904—1980) сугыштагы батырлыклары өчен «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләнә. Әхмәтнәгыйм, Әхмәтлатыйф һәм Мөхтәрәмне дә хәрби хезмәткә чакыралар, язмышлары билгесез.

Габидулла Арсланбәковның бишенче улы Мөхәммәтгалигә күчик. Мөхәммәтгали Габидулла улы балалары: Нурмөхәммәт (1842—01.08.1912) һәм Вәлиәхмәт (1854).

Нурмөхәммәт Мөхәммәтгали улы балалары: Газизҗан (1876), Шакирҗан (24.03.1877), Хәсәнҗан (1881), Бибимөнәвәрә (1892), Җиһангәрәй (08.08.1894; анасы Бибилатыйфа Мөхәммәтгәрәй Мөхәммәтвәли улы). Бибимөнәвәрә (17 яшь) 1909 елның 2 ноябрендә Корычның Миңлехан Ногман улына (25 яшь) кияүгә чыга, туганы Хәсәнҗан кызның ризалык шаһиты була. Нурмөхәммәт Мөхәммәтгалин (70 яшь) 1917 елда ялгыз яши, 9,29 дисәтинә җире, 2 сыеры була.

Газизҗан Нурмөхәммәт улы (28 яшь) 1904 елның октябрендә авылдашы Галләметдин Гыймадетдин улының кызы Гыйззениса (17 яшь) белән никахлаша, балалары Шакирҗан (03.08.1905), Фатыйма (25.09.1906—1910), Галимә (05.01.1909), Миңлерәкыя (14.05.1910—1914), Өммегөлсем (10.10.1911—1913), Закирҗан (05.09.1913), Гыйлемҗан (07.07.1915—1917), Бибиәсма (01.11.1916) туа. Газизҗан Нурмөхәммәтов (40 яшь) 1917 елда хатыны (35) һәм ике улы белән яши, 4,53 дисәтинә җире, аты була.

Вәлиәхмәт Мөхәммәтгали улы Габидуллин (Булатов дип тә языла) балалары: Шәйхәйдәр (19.07.1889), Миңлесәйдә (1890), Шәйхелимам (Шәйхимам; 31.01.1893; анасы Нурсафа Габделгалим Габделкәримов кызы), Таибә (11.04.1897—1897; анасы Бәдрисафа Габделгалим Габделкәримов кызы), Шәйхенур (29.10.1898; анасы Нурсафа), Мөхәммәтсафа (22.06.1902), Вәлимөхәммәт (06.02.1906; анасы Нурсафа Габделгалим кызы). Вәлиәхмәт кызы Миңлесәйдә 1906 елның декабрендә Корычның Раҗетдин Хөснетдин улы белән никахлаша. Вәлиәхмәтнең тагын кызы Хәмдесафа булган, бу хакта Фәһим Вәлимөхәммәт улы әйтте.

Шәйхәйдәр Вәлиәхмәт улы балалары: Рабига (10.11.1914; анасы Рәзифә Муллаян кызы), Дөргалия (16.10.1916—1917). Рабига совет чорында загстан туу турында белешмә ала.

Шәйхелимам Вәлиәхмәт улы (21 яшь) 1915 елның 12 мартында Иске Катайның Гомәр Йосыф улының кызы Бибибайнә (Бивия; 17 яшь) белән никахлаша, кызы Дөһөдия (25.09.1916) туа. Дөһөдиянең беренче ире (Әнвәретдин Афзалов) 1944 елда сугышта һәлак була, сугыштан соң Иске Катайның Тимергали Әхмәтгали улы Галиев белән никахлаша. Шәйхелимам Вәлиев — Ватан сугышы ветераны, сугышка киткәндә гаиләсендә хатыны Өммегөлсем (1899), уллары Шәйхеләгълә (1927), Мулланур (1929), кызлары Әнисә (1934), Флүнә (1937), Мөршидә (1939) була. Болардан тыш, сугыштан соң Шәйхенур (1943) белән Казхинур (07.11.1950) дөньяга килә.

Вәлимөхәммәт Вәлиәхмәт улы (1906) сугыш алды еллары кенәгәсендә Вәли Вәлиев дип теркәлгән, сугышка киткәндә хатыны Иклимә (1912), балалары Фәнә (1936) һәм Фәһим (01.01.1939) була. Бик күпләр кебек, югалтулар исемлекләренә дә кермичә, сугышта хәбәрсез югала (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән). Фәһим Вәлимөхәммәт улы Вәлиәхмәтов Иске Катайның Мөхәммәтдин Хафизов кызы Миңлефлүзә белән гаилә кора, балалары Фәйрүзә (1966), Рәмзилә (1970), Зимфира (1972) туа. Фәһим абый пенсиягә чыккач, дин нигезләрен өйрәнеп, мулла вазифасын башкарды.

Габидулла Арсланбәковның алтынчы улы Мөхәммәтшадан да нәсел дәвам итә. 1859 елгы документта аның уллары Мәрданша (1843) белән Гәрәйша (1859) теркәлгән.

Мәрданша Мөхәммәтша улы Габидуллинның ике хатыннан балалары: Әхмәдиша, Афзалетдин (03.01.1875; анасы Фәрхебану), Җиһанбану (10.07.1877), Гайнулла (22.04.1880; анасы Фәрхебану), Хәлфеҗиһан (20.12.1880; анасы Шәмсенәһар), Фәрхиҗиһан (1892), Җиһанбану (26.06.1894–1895; анасы Фәхеркамал Габделихсан Йөзәй улының кызы), Шәмсеҗиһан (1895), Мөбәрәкша (06.01.1898; анасы Фәхрикамал Габделихсан кызы), Гәрәйша (14.03.1900), Әхияретдин (1902), Әхиярулла (28.02.1903; анасы Фәхеркамал), Хәррамша (05.08.1905), Гайникамал (11.03.1907–1909), Дәүләтша (08.01.1909–1913). Мәрданша кызы Фәрхиҗиһан 1909 елның 2 ноябрендә Корычның Миңлехаҗи Миңлегәрәй улына (25 яшь) кияүгә чыга. Икенче кызы Шәмсеҗиһан 1913 елда Камайның Мөхәммәтрәхим Габделхаликъ улы (23 яшь) белән никахлаша.

Әхмәдиша Мәрданша улы Мөхәммәтшиннан Шәмсеруй (21.01.1900; анасы Маһруй Әхмәтша кызы) туган. 1901 елның 22 февралендә Әхмәдиша чахоткадан вафат була.

Афзалетдин Мәрданша улы балалары: Гыйльметдин (03.12.1905; анасы Газимә Габделлатыйф кызы), Талбетдин (02.01.1909), Әнвәретдин (10.03.1911), Бибигалимә (21.07.1914). Сугыш чоры кенәгәсендә Талбетдин Афзалов Талби дип теркәлгән, бу вакытта гаиләсе хатыны Талига (1911), улы Нәҗметдин (1938), анасы Газимәдән (1880) торган. Талбетдин Афзалетдин улы Мәрданшин – Ватан сугышы ветераны. Талбетдинның улы Әхнәф Афзалов дуңгыз асрау комплексында эшләгәндә, яшь коммунист буларак, комсомол оешмасы секретаре була, үзешчән сәнгатькә җитәкчелек итә, эштәге уңышлары өчен Мәскәүгә баруга һәм Кремльдә Ватан сугышы каһарманы генерал-полковник Чистяков һәм ВЛКСМ Үзәк комитеты секретаре Новожилова белән фотога төшүгә лаек була. Сержант Әнвәретдин Афзалетдин улы Мәрданшин (1911) 1944 елда сугышта хәбәрсез югала.

Арсланбәк улларыннан киткән нәсел тармакларын карауны төгәлләп, аның энесе Салихка күчәбез. Салих Якупов 1812 елда 77 яшьтә вафат була, нәселен Сәфәргали (1794–1850) белән Фәтхетдин (1797) дәвам итә. Сәфәргали уллары: Юныс (1827–12.03.1898), Йосыф (1829), Муса (1832). Юныс Сәфәргали улы

(30 яшь; икенче никах) 1886 елда Иске Катайның Миңлежиһан Сәеткол кызы (22 яшь) белән никахлаша.

Фәтхетдиннең улы Фәхретдин (1820) булып, Фәхретдин балалары: Миңлесадретдин (1899 елгы метрикәдә Садретдин; 1850–20.05.1899), Гыйлаҗетдин (1859–14.10.1906), Бибивәдига (1872). Фәхретдин кызы Бибивәдига (17 яшь) 1889 елның 24 ноябрендә авылдашы Мөхәммәтсабир Габделнәфикъ улы (25 яшь; атасы Габделнәфикъ Габделгаффар улы) белән никахлаша.

Садретдин Фәхретдин улы Фәтхетдинов балалары: Кашшафетдин (05.03.1890; анасы Гайниҗамал Шәймәрдан кызы), Мөхәммәтдин (1893–1912), Кашшафетдин (05.09.1895).

Гыйлаҗетдин Фәхретдин улы Фәтхетдинов балалары (беренче мәхәллә): Гыймадетдин (20.06.1889), Гөлчирә (25.02.1894–1895), Гөлчирә (28.08.1899; анасы Хөсникамал Мохтарулла кызы), Миңлемөнирә (30.03.1902), Әһлетдин (1905–1906).

Арсланбәкнең ерак нәселдәшләренә күчкәнче, бер шәҗәрә схемасы китерик. Нигъмәтулла – Ногман (1800) – Калкаман (1834–28.07.1876) – Солтангәрәй (1862) һәм Янбулат (1875) Калкамановлар. Нигъмәтулла, фараз кылып әйтсәк, Арсланбәк улы була. Чөнки 1816 елгы исемлектә ул Һибәтулла Рәхмәтуллин белән Солтанбәк Арсланбәков хуҗалыклары арасында бирелә.

Беренче мәхәлләдә Солтангәрәй Калкаман улы балалары: Шәмсевафа (13.04.1889), Сәетгәрәй (16.11.1893), Сәлимгәрәй (13.08.1898), Минлевафа (05.12.1900), Нурсафа (26.02.1903; анасы Миңлесафа Габделнәфикъ кызы), Нурҗиһан (03.11.1905), Миңлегәрәй (1910–1917), Нәзһая (20.08.1913–1914).

**Арсланбәкнең ерак нәселдәше – Гали** (метрикәләрдә Мөхәммәтгали).

Гали уллары: Сатлыган (1790), Мөхәммәткәрим (1802–30.03.1878), Мөхәммәтсадыйк (1805). Сатлыган уллары: Әхмәди (1821), Мөхәммәди (1824–26.03.1883). Мөхәммәди Сатлыган улыннан нәселне Мөхәммәтнәби (1855) белән Мөхәммәтхафиз (1867) дәвам итә.

Мөхәммәтнәби Мөхәммәди улы Сатлыганов балалары (беренче мәхәллә): Галиулла (1890), Фәрхиҗиһан (1892), Фәрхебану (04.10.1894), Шәмсебану (03.08.1899–1901; анасы Сәрвиҗиһан Гайнулла Галикәй улының кызы). Мөхәммәтнәби кызы Фәхриҗиһан (17 яшь) 1910 елның гыйнварында нәселдәше Гыйбадулла Һидиятулла исемле улы белән гаилә кора. Мөхәммәтнәби Мөхәммәдиевнең улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (60 яшь), ике кызы, килене (20) һәм ике оныгы белән яши, 11,62 дисәтинә җире, җилгәргече, 4 аты һәм башка маллары була, хезмәтче яллый. Галиулла Мөхәммәтнәби улы балалары (өченче мәхәллә): Хадимулла (13.04.1915; анасы Фатыйма Мөхәммәтхарис кызы), Хадимулла (1923–1925), Мулланур (03.11.1925).

Мөхәммәтхафиз Мөхәммәди улы Сатлыганов (1900 елда Садыйков дип тә язылган) балалары: Мөхәммәтсабир (09.11.1893; анасы Гөлзифа Фәтхулла кы-

зы), Шәмсеталига (29.03.1900), Мөхәммәтхарис (20.11.1902–1903), Мөхәммәтгариф (12.04.1905; анасы Шәмсебану), Мөхәммәтназиф (29.07.1907–1913), Шәмсенур (28.10.1909), Бибинур (10.03.1912). Мөхәммәтхафиз 1904 елның 1 гыйнварында икенче тапкыр өйләнә, хатыны авылдашы Миңлегәрәй Мөхәммәтша улының кызы Шәмсебану (22 яшь; икенче никах) була.

Сатлыганның беренче энесе Мөхәммәткәрим иде. Мөхәммәткәрим Гали улы ир балалары: Мөхәммәтсадыйк (1824), Хөснетдин (мулла; 1831–05.07.1912), Гыйрфан (1837), Кашшафетдин (Кәшфетдин; 1840–01.11.1912), Шәйхетдин (1843). Боларның һәрберсенә тукталып үтәбез.

Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәткәрим улы балалары: Ибраһим (1850–1855), Ибраһим (1856), Мөхәммәтзакир (1863), Бибигазизә (1871). Мөхәммәтсадыйк кызы Бибигазизә (19 яшь) 1890 елның сентябрендә Иске Катайның Мөхәммәтситдыйкъ Габделханнан улы (50 яшь; өченче никах) белән никахлаша.

Ибраһим Мөхәммәтсадыйк улы Кәримов балалары: Әхмәтзакир (05.09.1883), Бибисорур (05.08.1894; анасы Маһинур), Әхмәткәрам (08.03.1900; анасы Маһинур Габделнасыйр кызы). Ибраһим кызы Бибисорур 1913 елда Килкабызның Шәмсемөхәммәт Сәлимгәрәй улы (25 яшь; атасы Сәлимгәрәй Гайнан улы; икенче никах) белән кавыша. Ибраһим 1883 һәм 1890 елгы метрикәләрдә мулла дип күрсәтелә, димәк, дини гыйлемгә ия булган. Ибраһимның тагын бер улы Исмәгыйль Катай авыл советы кенәгәсендә Исмәгыйль Ибраһимов (1898) дип теркәлгән (аны 1897–1899 елгы метрикәләрдән тапмадык). Ул 1942 елның 25 октябрендә сугышка китә һәм хәбәрсез югала (исеме Катайның мемориаль стеласына язылмаган), хатыны Гыйльмикамал (1902), кызлары Мөфәвазә (1930) һәм Мөзәянә (18.10.1935) кала. Мөзәянә Иске Катайның Рәис Дәүләтов белән гаилә кора.

Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы Кәримов балалары: Миңлемөхәммәт (1892–1895), Фәрхеруй (30.11.1894), Бибисәрмәдия (1896), Мөхәммәтрәхим (30.05.1899; анасы Маһруй Мөхәммәтзариф Мөхәммәтвәли улының кызы), Мөхәммәтхәниф (09.10.1902), Мөхәммәтгариф (10.10.1905; анасы Маһинур Мөхәммәтзариф кызы), Әхмәткәрам (28.11.1908). Мөхәммәтзакир кызы Бибисәрмәдия 1914 елда Туктаголның Дәүләтша Хәсән улы (25 яшь) белән никахлаша. Закир Садыйков 1917 елда хатыны (48 яшь) һәм дүрт улы белән яши, 4,65 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була.

Мөхәммәтрәхим Мөхәммәтзакир улыннан Мөхәммәткамал (07.11.1925; анасы Мәрьям Әсләм кызы) билгеле. Әхмәткәрам Мөхәммәтзакир улы Закиров (1908) – Ватан сугышы ветераны.

Мулла Хөснетдин Мөхәммәткәрим улы Галиев балалары: Әбүнәгыйм (1855), Нурлыгаян (1858), Сәлахетдин (1861), Фәрхебану (1875–1898), Гыйльмиҗиһан (1876), Кәраметдин (01.04.1877; анасы Шәмсекамал), Гайнелҗиһан (1878). Хөснетдин кызы Фәрхебану Сеңрәннең Габделмәннан Габдрахман улы Мөхәммәтхәнәфиевкә кияүгә чыккан була, «араларында мәхәббәт вә өлфәт» булмаганлыктан, 1895 елның 7 декабрендә аерылышалар. Имам Габделҗәмил

Мөхәммәтҗан улы Кучемов әллә ялгыш, әллә Хөснетдиннең нәселен белеп бетермәгәнлектән, фамилиясен Күчемов дип язган. Хөснетдиннең икенче кызы Гыйльмиҗиһан (18 яшь) 1894 елның 21 декабрендә Килкабызның Мөхәммәтхарис Габделханнан улы Мөхәммәтгалиев (22 яшь) белән никахлаша. Өченче кызы Гайнелҗиһан 1897 елның 10 декабрендә Иске Катайның Габдрахман Фазлыәхмәт улы (25 яшь) белән кавыша.

Әбүнәгыйм Хөснетдин улы (22 яшь) 1878 елның 15 гыйнварында Иске Катайның Мифтахетдин Габделнасыйр улының кызы Бибихәкимә (20 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Миңлегәрәй белән Әхмәтгәрәй Мифтахетдин уллары була. Бу никахтан Әхмәтнәгыйм (06.11.1878) белән Әбуталип (30.09.1880) туа.

Нурлыгаян мулла Хөснетдин улы Кәримов балалары: Бибисәрвиҗиһан (19.06.1889; анасы Бибихәлимә Габделмәннаф кызы), Нәгыймә (1890–1898), Бибигалимә (23.10.1898), Кәшфелмәган (04.05.1901), Кәшфелгаян (03.02.1904), Габделбаян (02.03.1907), Нәгыймә (15.05.1910). Нурлыгаян кызы Бибигалимә 1917 елда Корычның Габделлатыйф Мөхәммәтзакир улы (28 яшь) белән никахлаша. Нурлыгаян Хөснетдиновның ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (35 яшь), өч улы һәм кызы белән яши, 10,84 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры, 4 сарыгы була.

Кәшфелмәган (документта Кәшбелмәган; 1901) Нурлыгаянов 1942 елның гыйнварында Ватан сугышына китәр алдыннан хатыны Кафия (1906), кызлары Гөлҗәннәт (1928) һәм Фәния (1933) белән яши. Кәшфелгаян (документта Кәшбелбаян, 1904 ел) Нурлыгаянов сугышка 1941 елның декабрендә китә, хатыны Гакифә (1906), балалары Мәлих (1936) һәм Тәкмилә (1939) кала. Кәшфелмәган 1944 елның гыйнварында хәбәрсез югала (Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән). Яңа Катайның тагын бер нәселендә дә Нурлыгаяновлар бар, аларның да берсе сугышта һәлак бара.

Сәлахетдин мулла Хөснетдин улы Кәримов авылдашы Габделлатыйф Габделвафи улының кызы Гыйльмикамал белән никахлаша, балалары Бибиҗиһан (23.06.1894–1895), Сәрвиҗиһан (1897–1905), Имаметдин (29.03.1899–1901), Әнвәр (30.07.1901), Мәдхиҗиһан (02.03.1905–1905), Имаметдин (25.03.1906), Фәхерҗиһан (28.11.1908–1909), Әхияретдин (02.04.1910), Афзалетдин (15.08.1911–1912), Әхкәметдин (19.02.1913) туа. Сәлахетдин Хөснетдиновның (56 яшь) олы улын (25) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны һәм өч улы белән яши, 10,86 дисәтинә җире, 3 аты, сыеры һәм башка маллары була.

Указлы мулла Гыйрфан Мөхәммәткәрим улы Галиевнең балалары Хаҗирә (12.09.1878) белән Шәйшәриф (07.12.1883; анасы Фәрхиҗиһан) билгеле.

Кашшафетдин Мөхәммәткәрим улы Галиев балалары: Сиражетдин (1868), Афзалетдин (09.08.1874), Ширияздан (18.02.1877), Ихыялетдин (халык телендә Ихай; 10.08.1880; анасы Бибинәфисә). Кашшафетдин кызы Бибикафия (17 яшь) 1889 елның 14 ноябрендә авылдашы Камалетдин Гыйлажетдин улы (атасы Гыйлажетдин Мөхәммәткәрим улы) белән никахлаша.

Сиражетдин Кашшафетдин улы Мөхәммәткәримов (27 яшь) 1895 елның 8 июлендә Корычның Габдерәфикъ Габдулла улының кызы Шәрифҗамал (24 яшь; икенче никах) белән кавыша. Кияүнең ризалык шаһитлары Ширияздан Кашшафетдин улы белән Мөхәммәтшәфикъ Габделмәннан улы була.

Ширияздан Кашшафетдин улы (икенче никах) 1914 елның 21 июнендә Иске Катайның Нәдергол Шәмгун улының кызы Миңлекамал (25 яшь, икенче никах) белән никахлаша. Егетнең вәли вәкиле – кардәше Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы, ризалык шаһитлары Шәйгәрәй Тимербулат улы белән Исламгәрәй Шәнгәрәй улы була. Бу никахтан Шәрифҗан (25.11.1915; анасы Миңлекамал) туа. Ширияздан Кашшафетдин улы белән Бибикамал Нәдергол кызы (25 яшь; исеме шулай язылган) 1915 елның 1 сентябрьдә аерылышалар да («араларында мәхәббәтләре киткәнлектән»), шул ук елның 3 сентябрендә яңадан никах кылып кушылалар, ә инде 1916 елның 9 февралендә «хатын ир хөрмәтенә ярамаганлыктан» бөтенләйгә аерылышалар. Хатынсыз озак тормый, 1916 елның 15 мартында Ширияздан Килкабызның Бибифатыйма Шәрифулла кызы (37 яшь; икенче никах) белән никахлаша.

Ихыялетдин Кашапов (1880; 2 группа инвалиды) Ватан сугышы алдыннан хатыны Рәхимә (1900), балалары Җәмигънур (1926), Флүн (1930) белән яши. Җәмигънур Ихыялетдин улы Кашапов (1926–1981) – Ватан сугышы ветераны. Флүн белән Фәһимә балалары: Рәшит (1956), Разит (1960), Фәнисә. Рәшит Кашапов бу юллар авторы белән бер чордарак Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетының тарих бүлегендә укыды, бер җәй бергә факультетның студент төзелеш отрядында булды.

Шәйхетдин Мөхәммәткәрим улы Галиев балалары: Садретдин (1872–1912), Гыйлаҗетдин (1874), Мәһдивафа (1877), Җәләлетдин (1879), Нуретдин (1888–1889), Әгъләметдин (05.11.1904–1905; анасы Нурҗиһан Йосыф кызы). Шәйхетдин кызы Мәһдивафа (18 яшь) 1895 елның 10 ноябрендә Иске Катайның Ахунҗан мөәзин Шәймөхәммәт Кәримов улы (26 яшь) белән никахлаша. Бу никах барып чыкмый, 1897 елның 15 ноябрендә ул авылдашы Шәяхмәт Гыйниятулла улы (30 яшь; икенче никах) белән кавыша. Шәйхетдин (50 яшь; икенче никах) хатынсыз калгач, 1903 елда авылдашы Йосыф Фәйзулла улының кызы Нурҗиһан (1863 елгы; икенче никах) белән никахлаша.

Шәйхетдиннең өч улы – Садретдин, Гыйлаҗетдин һәм Җәләлетдин – гаилә корып, нәселне дәвам итә. Аларның һәрберсенә тукталып үтәбез.

Садретдин Шәйхетдин улы Кәримов балалары: Сания (28.12.1894), Сәмигулла (20.04.1897; анасы Бибифатыйма Мөхәммәтсадыйк Әрдәшир улының кызы), Хәтимә (28.04.1900), Хәмидулла (29.05.1903), Фатиха (07.04.1906), Хәбибулла (13.03.1908), Әгъзаметдин (02.07.1910; анасы Бибифатыйма Мөхәммәтсадыйк кызы), Афзалетдин (27.07.1912–1914).

Гыйлаҗетдин Шәйхетдин улы Кәримов (25 яшь) 1899 елның 1 ноябрендә Югары Сәрдекнең Шәйхелислам Мөхәммәтшаһит кызы Бибинәфисә (17 яшь) белән никахлаша. Никах Яңа Катайның икенче мәхәллә мет-

рикәсендә теркәлә, кыз вәкиле (метрикәдә «кызны тәрбия кылып бирүче», димәк, тәрбияләп үстергән) Мөхәммәтзакир Мөхәммәтвәли улы Нөрмәтов була. Никах язуына егетнең атасы Шәйхетдин Кәрим улы Арсланбәк нәселенә хас тамга салган. Кызның ризалык шаһитлары Шәрәфулла Хәбибулла улы (Азамат нәселеннән) белән Җиһангир Әделгәрәй улы (Нөрмәт нәселеннән) була. Гыйлаҗетдин балалары: Шәрифә (09.08.1902; анасы Бибинәфисә), Миңлехәнифә (06.06.1905), Рәйфә (30.08.1910), Әгъләметдин (05.02.1913–1915), Миңлешәрифә (05.09.1915; анасы Фәрхенур Госман кызы). Гыйлаҗетдин (40 яшь) 1914 елның 28 июлендә авылдашы Фәрхинур (дүртенче никах; атасы Госман Гомәр улы Миңлеголов) белән никахлаша. Шул ук Гыйлаҗетдин 1916 елның 7 маенда Корычның Гыйльмиҗиһан Сәфәргали кызы (23 яшь; икенче никах) белән кавыша, шул елның 17 декабрендә аерылышалар (сәбәбе – « ир тәрбия кылмаган»). Әлеге никахта ирнең ризалык шаһитлары Шәйсолтан белән Нурмөхәммәт Ильяс уллары булып, тамга салганнар, ә Гыйлаҗетдин үзе кул куйган. Гыйлаҗетдиннең калган гомере Чүмәлә Катайда үтә, 1925 елда анда кызы Әбәдия (анасы Фәрхенур Госман кызы) дөньяга килә.



**Никах язуының аскы өлешендә өч нәсел кешеләре – Шәйхетдин Кәрим улы, Шәрәфулла Хәбибулла улы, Җиһангир Әделгәрәй улы тамгалары**

Җәләлетдин Шәйхетдин улы балалары: Мәгъфүрә (14.11.1904; анасы Гыйльмениса Фәрхетдин кызы), Гыймадетдин (02.01.1908), Мәгъсүмә (01.08.1911; анасы Хәерниса Фәрхетдин кызы), Зыятдин (25.07.1914–1914), Әхмәдетдин (20.09.1915–1916; анасы Гыйльмикамал Фәхретдин кызы).

Сатлыганның икенче энесе Мөхәммәтсадыйк (1805) иде. Мөхәммәтсадыйк Гали улы варислары Исмәгыйль (1833–24.03.1903) һәм Ильяс (1841) була.

Исмәгыйль Мөхәммәтсадыйк улы балалары: Исхак (1859), Якуп (1863), Госман (Госмангали; 1867), Гомәр (1872), Шәмсенур (01.12.1880; анасы Хәбибҗамал), Гали (1883).

Исхак Исмәгыйль улы Садыйковның Фәхриниса Әбелхәсән кызы белән никахыннан беренче мәхәлләдә Габбәс (22.09.1889) туа. Аннан соң Исхак

Мәрьям (атасы Кәлимулла Фәтхулла улы) белән никахка керә, алар гаиләсендә Әбүбәкер (24.07.1895), Мәрзия (05.01.1897), Хәкимә (23.07.1899), Хөрмәтулла (06.05.1902), Гайшә (20.12.1911) туа. Исхак Исмәгыйлевнең ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (48 яшь), төпчек улы һәм ике кызы белән яши, 2,30 дисәтинә җире, аты һәм башка маллары була. Катай авыл советы кенәгәсендә Габбәс Исхаковның (1889) хатыны Сорузиян (1907), балалары Нәсимҗан (Нәсимьян; 1928), Фәния (1933), Тимерҗан (Тимерьян; 1940) теркәлгән. Нәсимҗан белән Мәхүҗүрә Габдулла кызы балалары: Альберт (1955), Салават (1957), Алмаз (1960), Дамир (1962). Исхакның икенче улы Әбүбәкер (1895) Чүмәлә Катайда гаилә корып яши. Хөрмәтулла 1936 елда загстан туу турында белешмә ала, язмышы билгесез.

Якуп Исмәгыйль улы Садыйков балалары: Рәхимә (02.05.1894–1898), Нәгыймә (02.09.1898–21.02.1905), Миңлесайра (25.11.1900–19.03.1905; анасы Бибисара Шәрифетдин кызы), Мулламөхәммәт (29.06.1904–16.04.1905), Нурмөхәммәт (1905–1906). Якупның бер-бер артлы өч баласы (соңгы икесе эч сырхауыннан) 1905 елда мәрхүм була. Аның улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (54 яшь) белән яши, 5,70 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була.

Госмангали Исмәгыйль улы Садыйков балалары: Габдрахман (15.06.1900; анасы Фәрхиҗиһан Фәрхетдин улының кызы), Гыйлемҗан (08.10.1901), Гайнелҗинан (09.12.1904), Рузәтелҗинан (03.01.1911), Галимҗан (19.07.1914), Гарифҗан (22.06.1916). Госмангали Исмәгыйлев 1917 елда хатыны (45 яшь), өч улы һәм ике кызы белән яши, 0,92 дисәтинә җире, аты һәм 2 кәҗәсе була.

Гомәр Исмәгыйль улы Садыйков балалары: Җәмилә (29.09.1900; анасы Бибихәлимә Зәйнетдин кызы), Галимә (10.03.1902–1905), Имаметдин (18.06.1904), Әхияретдин (07.12.1905–1906), Гыймадетдин (18.12.1906), Бәһия (02.04.1908), Миңлерабига (12.03.1910), Разыя (17.12.1912–1913), Дөһөдия (28.08.1914). Гомәр Исмәгыйлев 1917 елда хатыны (40 яшь), улы һәм өч кызы белән яши, 10,55 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була.

Гали Исмәгыйль улы (22 яшь) 1907 елның 11 ноябрендә авылдашы Гыйндулла Галиулла улының кызы Гыйльмиҗиһан (17 яшь) белән никахлаша, балалары Мәдхиҗиһан (07.01.1909), Сәрвәрия (28.10.1910), Мирсәгыйть (15.06.1913–1913), Миңлеәбүнәгыйм (25.06.1914), Нәгыймә (1920), Җәмигъяур (02.04.1925), Мөстафидә (1930) дөньяга килә. Миңлеәбүнәгыйм совет чоры исемлекләрендә Әбүнәгыйм Исмәгыйлев дип теркәлгән, Ватан сугышында һәлак була (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Мөхәммәтсадыйк Галиевнең икенче улы Ильяс (1841) та шактый нәсел калдыра. Ильяс Мөхәммәтсадыйк улы (35 яшь; икенче никах) 1878 елның 20 апрелендә авылдашы Гайнулла Галикәй улының кызы Сәрвиҗиһан (17 яшь) белән кавыша. Ильяс балалары: Шәйсолтан (1865), Нургали (1875–1878), Бикмөхәммәт (1877–06.06.1915), Исламгали (03.04.1878–1878; анасы Фәрхиҗиһан), Нурмөхәммәт (1880), Фәрхиҗиһан (1882–1894).

Шәйсолтан Ильяс улы (22 яшь; вәли вәкиле Нурислам Шәйхелислам улы) 1887 елның 4 октябрендә Иске Катайның Шәйхетдин Габделвахит улы Сөяргголов кызы Бибихәнифә (18 яшь) белән никахлаша. Шәйсолтан балалары: Шагали (1888–1889), Бибигарифә (28.06.1893), Маһирә (1899–1906), Ярмөхәммәт (02.06.1902), Бибишәрифә (1907–1909), Маһирә (12.03.1909; анасы Хәнифә Шәйхетдин Габделвахит улының кызы), Рәхмәтулла (08.08.1911; анасы Гыйльмебану Хәйрулла кызы), Кадермөхәммәт (15.08.1915–1916; анасы Гыйльмебану Хәйрулла кызы). Шәйсолтан Ильясов 1917 елда хатыны (30 яшь), өч улы һәм кызы белән яши, 4,39 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була. Рәхмәтулла Шәйсолтан улы Ильясов 1942 елның 13 сентябрендә хәрби хезмәткә китә (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән), бу вакытта хатыны Сания (1913), балалары Гөлбану (1933), Нажия (1937), Нуриман (1943), энесе Әхмәтшәех (1924–1995) була.

Монда бер искәрмә биреп үтик. Шәйсолтан мәрхүм булгач, аның хатыны Гыйльмебану Хәйрулла кызы 1921 елгы ачлыкта бөтен гаиләсен югалткан, ялгыз авылдашы Әхмәтгәрәй Күчемов белән никахлаша. Әлеге никахтан Әхмәтшәех дөньяга килә, шуңа сугыш алдыннан Рәхмәтулла Шәйсолтан улы Ильясов гаиләсендә теркәлгән. Әхмәтшәех Әхмәтгәрәй улы Күчемов турында башка мәгълүмат Күчем нәселенә багышланган бүлектә бирелә.

Бикмөхәммәт Ильяс улы (25 яшь) 1902 елның 27 октябрендә авылдашы Мөхәммәтшәриф Галикәй улының кызы Гөлбану (17 яшь) белән никахлаша. Бикмөхәммәт балалары: Майбану (16.10.1906–1909; анасы Гөлбану Мөхәммәтшәриф кызы), Мулламөхәммәт (08.03.1910–1910), Җаннур (02.12.1911; анасы Гыйльмиҗиһан Сәфәргали кызы), Җәмгыйтдин (10.11.1913).

Нурмөхәммәт Ильяс улы Садыйков (үги атасы Мөхәммәтнәби Мөхәммәди улы) 1903 елның февралендә авылдашы Нигъмәтулла Гайнулла улының кызы Бибисара (17 яшь; үги атасы Хәбибулла Шәһидулла улы) белән никахлаша, балалары Әлмөхәммәт (07.02.1904), Шәмсебану (07.09.1906), Миңлегалия (23.10.1909; анасы Бибисара Хәбибулла кызы), Динмөхәммәт (20.04.1912–1913), Миргабитҗан (30.06.1914–1916; анасы Бибисара Нигъмәтулла кызы) туа. Нурмөхәммәт Ильясовны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (39 яшь), ике улы һәм ике кызы кала, 5,02 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры, 10 сарыгы була. Әлмөхәммәт Нурмөхәммәт улы Ильясов 1942 елның 10 маенда сугышта һәлак була (атасының исеме Катайның мемориаль стеласында дөрес күрсәтелмәгән, «И» хәрефе куелган).

**Арсланбәкнең ерак нәселдәше – Даут**.

Даутның уллары Аеткол (1771–1823) һәм Колый (1785–1822) 1816 елгы исемлектә Арсланбәкнең энесе Салих Якупов артыннан 11 нче хуҗалык (гаилә) булып теркәлгән, нәсел беренчесеннән дәвам итә.

Аеткол Даут улы ир балалары: Гайнулла (1799–1856), Зәйнулла (1805), Гайнан (1810; беренче хатынынннан туган), Габделсалих (1810), Габделхаликъ (1813), Рәхмәтулла (1815; икенче хатынынннан).

Гайнулла Аеткол улы ир балалары: Шаһидулла (1827–05.12.1903), Нигъмәтулла (1845), Кәлимулла (1848–02.05.1909).

Шаһидулла Гайнулла улы Аетов балалары: Хәбибулла (1859–02.07.1915), Нурҗиһан (1878). Шаһидулла кызы Нурҗиһан (17 яшь) 1895 елның 24 гыйнварында Базы Куянның Габдерәкыйп Габделгазиз улы (22 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Хәбибулла Шаһидулла улы белән Габделхак Габделхаликъ улы була.

Нигъмәтулла Гайнулла улы Аетов балалары: Майҗамал (1872), Шәехгали (21.07.1878; анасы Мәхүбҗамал), Бибикамилә (25.10.1883), Мөхәммәтгали (1884), Бибисара (1886), Мөхәммәтһади (06.12.1889; анасы Мәхүбҗамал Арслангәрәй кызы). Нигъмәтулла кызы Майҗамал (17 яшь) 1889 елның 15 декабрендә авылдашы Фәттахетдин Хөснетдин улы Азаматов (22 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Бибисара 1903 елның февралендә нәселдәше Нурмөхәммәт Ильяс улы белән кавыша.

Мөхәммәтгали Нигъмәтулла улы (25 яшь) 1909 елның 5 гыйнварында авылдашы Мөхәммәтшәфикъ Габделмәннан улының кызы Гайнелзифа (17 яшь) белән никахлаша. Кияү тарафыннан вәкил үги атасы Хәбибулла Шаһидулла (Шәйдулла) улы була. Мөхәммәтгали балалары (беренче мәхәллә): Мөхәммәткәрим (28.03.1910–1910), Мөхәммәтназиф (1911–1915), Шәехгали (12.04.1915; анасы Бибизифа Мөхәммәтшәфикь кызы), Наҗия (1921), Мөзәккия (25.08.1925; анасы Бибизифа), Зөфәр (04.09.1925; анасы Фәрхиҗиһан Мөхәммәтнәби кызы). Мөхәммәтгали Нигъмәтуллинны (30 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (30), улы (2 яшь; Шәехгали) һәм анасы (70) кала, 1917 елда 12,12 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче яллый. Җитеш тормышта яшәгәнгә, 1931 елда кулак дип табыла, мал-мөлкәте тартып алына, ике йортының берсен сельсовет бинасы итәләр (бу хакта Мөдәррис Фәрвазов кызы Рузидә әйтте). Мөхәммәтгали Нигъмәтуллин (1886) гаиләсендә Ватан сугышы елларында хатыны Фәхерзиян (1888), балалары Мөназдия (1926), Вәрис (1928), Тәрҗимә (1930), оныгы Рузидә (1942) теркәлгән.

Вәрис Нигъмәтуллин авылдашы Нурзидә Сөнәгатулла кызы белән гаилә кора, балалары Рәис (1952), Рәмил, Фәнил, Шамил туа. Мөнәздия Иске Катайның Рәиф Әхмәтханов белән никахлаша, 1949 елда мәрхүм була, кызы Зилә (1947–1996) кала. Зилә әби-бабасы (Кәшиф белән Закирә) тәрбиясендә үсә, кияүгә чыга, кызлары Гөлнара белән Гүзәл туа. Гөлнара яшьли вафат була, сеңлесе Гүзәл кияүгә чыга, улы туа, бүгенге көндә табибә булып эшли һәм укыта.

Кәлимулла Гайнулла улы Аетов балалары: Гыйльменур (1876–1901), Әһәдулла (22.10.1877; анасы Шәмсенур), Фәрхенур (1878), Әсәдулла (1883), Бибинур, Әхмәдулла (19.07.1893; анасы Хәдичә Мөхәммәтшәриф кызы), Гыйниятулла

(08.02.1900). Кәлимулла кызы Гыйльменур 1897 елда Килкабызның Кашшафетдин Фәрхетдин улы (25 яшь) белән кавыша. Икенче кызы Фәрхенур (17 яшь) 1895 елның 24 гыйнварында авылдашы Шәйхелгаттар Шәйморат улы Нөрмәтов (23 яшь) белән гаилә кора. Кызның ризалык шаһитлары Хәбибулла Шаһидулла улы белән Муллаян Үмербай улы була. Өченче кызы Бибинур 1907 елда авылдашы Солтангали Габделгани улы белән никахлаша.

Әсәдулла Кәлимулла улы (25 яшь) 1908 елның 28 ноябрендә авылдашы Сөләйман Мөхәммәтша улының кызы Шәмсеҗиһан белән никахлаша, балалары Бибинур (1909), Миңлегарифә (26.01.1910–1910), Сәгъдулла (03.12.1910–1916, кызамыктан вафат), Нурулла (22.05.1914), Насыйбулла (03.12.1915–1916) һәм Шәрхемулла (09.05.1917) туа. Хәрби комиссариат документында Шәрхемулла Кәлимуллин Шәрхым, туган елы 1918 дип теркәлгән. Нурулла белән Шәрхемулла Кәлимуллиннар (Әсәдуллиннар) – Ватан сугышы корбаннары. Бер документта Шәрхемулла – Шәрхәп Әсәдуллин, хатыны Мөсәвәрә (1918), кызы Сәһлә (1938) дип язылган.

Әсәдулла Кәлимуллинның икенче никахы авылдашы Хәлфезиян Заһир кызы белән була, балалары Мосаллия (1921), Гыйльмулла (1924), Әсгать (1929), Фәүзия (1933), Фәрдидә (1937) туа. Әсгать белән Сабира Габидулла кызы (Килкабызныкы) балалары: Фәндүзә (23.02.1956), Рәмзилә (10.10.1957), Рифкать (1959), Ринат (1963).

Әхмәдулла Кәлимулла улы белән Латыйфа Гаязетдин кызы никахыннан Хәүлә (03.09.1925) туа. Әхмәдулла (Әхмәй) Кәлимуллин Ватан сугышына киткәндә гаиләсендә хатыны Латыйфа (1894), кызлары Хәүлә (1925), Хәзинә (1927), Фәүханә (1930), Нәирә (1937) була.

Гыйниятулла Кәлимуллин (1900; Ватан сугышы ветераны) 1940 елда Бурят-Монголиягә чыгып китә, 1943 елның 27 гыйнварында гаиләсе авылга кайтып төшә, бу вакытта хатыны Гайникамал (1895), кызы Гөлҗәүһәр (1928), уллары Сәгъдәтулла (1930), Хәтмулла (1932) була. Хәтмулла балалары: Тәнзилә (1955), Нигъмәтулла (1956), Рафаэль (1957), Гөлфинә (1962), Гөлназ (1972).

Югарыда нәселне Гайнулла Аетов яклап карадык. Гайнулланың бер энесе Габделхаликъ Аетов (1813) булып, Габделхаликътан Габделхан (метрикәдә Габделхак) туа.

Гайнулланың икенче энесе Рәхмәтулла Аетовның ир балалары Мөхәммәтзариф (1838) һәм Һидиятулла (1842) була. Һидиятулла Рәхмәтулла улы балалары: Бибиҗиһан (Миңлеҗиһан; 01.04.1877), Хәлфеҗиһан (20.02.1880; анасы Бибиҗамал), Шәмсеҗиһан (02.12.1889), Гыйбадулла (1890), Шәмсеҗиһан (18.08.1894), Шәмгыя (1895), Гыйниятулла (28.03.1897–1897; анасы Бибиҗамал Динмөхәммәт кызы). Һидиятулла кызы Миңлеҗиһан (18 яшь) 1895 елның 24 ноябрендә Корычның Габидулла Хәйрулла улы Сибгатуллов (21 яшь) белән никахлаша. Уртанчы кызы Хәлфеҗиһан 1898 елның 15 декабрендә Тыпыйның Яхъя Габделхаликъ улы (25 яшь; атасы Габделхаликъ Габделҗәлил улы) белән

гаилә кора. Төпчек кызы Шәмгыя 1913 елның 15 маенда авылдашы Кашшафетдин Камалетдин улы (20 яшь) белән кавыша.

Гыйбадулланың Һидиятулла исемле улы 1910 елның гыйнварында нәселдәше Мөхәммәтнәби Мөхәммәди улының кызы Фәхриҗиһан (17 яшь) белән гаилә кора. Кияүнең ризалык шаһитлары – Хәбибулла Шаһидулла улы белән Мөхәммәтгали Нигъмәтулла улы, кызныкы Мөхәммәтхафиз Мөхәммәди улы белән Нурмөхәммәт Ильяс улы була. Бу никахтан Нәҗибә (05.02.1915) туа.

Арсланбәкнең ерак нәселдәшләренә шулай ук Сәйфетдин (1785–1822), Шәмсетдин (1791), Фәйзулла (1805–21.06.1889) Корбанаевлар (Корбангалиевләр) да керә.

Сәйфетдин Корбангали улы 1816 һәм 1834 елгы исемлекләрдә сигезенче булып теркәлгән, аның ир балалары Шиһабетдин (1812), Хисаметдин (1818–02.03.1889), Нәҗметдин (1830) була. Боларның берсеннән генә (Хисаметдин) нәсел дәвам итә.

Хисаметдин Сәйфетдин улының варисы Минһаҗетдин (1869) була. Минһаҗетдин Хисаметдин улы Корбангалиев (20 яшь) 1889 елның 23 февралендә авылдашы Шәйморат Хәбибулла улының кызы Бибигайшә (17 яшь) белән никахлаша. Минһаҗетдин балалары: Шәмсеталига (05.08.1893–1894; анасы Бибигайшә), Бибиҗиһан (07.03.1895), Гыйльмиҗиһан (16.12.1898), Гайнелҗиһан (25.02.1903), Җамалетдин (30.03.1906), Зыятдин (18.11.1909), Әгъләметдин (21.08.1913; анасы Гайнелҗиһан Шәйморат кызы).

Фәйзулла Корбангалиев улы балалары: Йосыф (1835–19.08.1903), Гарифулла (1847), Юныс (1850–07.03.1899), Бибикамал. Фәйзулла кызы Бибикамал (25 яшь; икенче никах) Килкабызның Динмөхәммәт Бикморза улы (45 яшь; икенче никах) белән кавыша.

Йосыф Фәйзулла улы Корбангалиев балалары: Нурҗиһан (1863), Мөхәммәтназиф (1870), Хөсниҗиһан (1876), Маһиҗиһан (20.07.1877; анасы Фәрхиҗиһан), Мөхәммәтзакир (1888). Йосыф кызы Нурҗиһан (17 яшь) 1890 елның 17 октябрендә Кара Көчек авылының Габделхәким Бәхтияр улы (38 яшь; икенче никах) белән кавыша. Шул ук Нурҗиһан тол калып, 1903 елда авылдашы Шәйхетдин Мөхәммәткәрим улы (50 яшь; икенче никах) белән никахлаша, аннан аерылып Иске Катайның Габделкадыйр Габделхаликъ улы (50 яшь; икенче никах) белән гаилә кора. Йосыфның икенче кызы Хөсниҗиһан (19 яшь) 1895 елның 27 ноябрендә авылдашы Муллаян Габделгани улы Габдрахманов (40 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Өченче кызы Маһиҗиһан 1897 елның 25 ноябрендә Чуракайның Мөхәммәтсалих Мөхәммәтҗәләл улы (23 яшь; атасы Мөхәммәтҗәләл Ардуан улы) белән кавыша.

Мөхәммәтназиф Йосыф улы балалары: Гайнелҗиһан (21.06.1901), Мөхәммәтнәҗип (07.12.1903; анасы Миңлеҗиһан Мөхәммәтгәрәй кызы), Майҗиһан (09.06.1906), Мөхәммәтшакир (1909–1915), Рәфия (13.08.1911), Гайнелҗиһан (08.05.1914). Мөхәммәтназиф Йосыпов 1917 елда хатыны (37 яшь), улы һәм биш кызы белән яши, 4,11 дисәтинә җире, аты, сыеры, 2 кәҗәсе була.

Мөхәммәтзакир Йосыф улы (25 яшь) 1914 елның 15 гыйнварында беренче мәхәлләдә авылдашы Габделхак Габделнәфикъ улының кызы Миңлениса (19 яшь) белән никахлаша, балалары Әхмәтзәки (29.10.1914) туа.

Гарифулла Фәйзулла улы Корбангалиев балалары: Гафифә (1872–1895), Бибимәфтуха (1878), Бибимәмдуха (10.08.1880; анасы Бибифатиха), Бибимәрфуга (01.08.1883), Габидулла (1892), Мәэлүфә (1896–1901). Гарифулла кызы Гафифә (17 яшь) 1889 елда нәселдәше Нуриәхмәт Гайнанша улы (25 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Икенче кызы Бибимәфтуха (17 яшь) 1895 елның 20 гыйнварында Иске Катайның Мөхәммәтдин Дәүләтбай улы Конгырбаев (22 яшь) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтдин Габделлатыйф улы белән Нуриәхмәт Гайнанша улы була. Өченче кызы Мәмдуха (17 яшь) 1899 елның 17 гыйнварында авылдашы Сәүбән Баһман улы Шәйхетдинов (25 яшь; дүртенче никах) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Миңлегали Габделфәез улы белән Мөхәммәтдин Габделлатыйф улы (икесенең дә тамгалары Арсланбәк нәселенеке) була. Мәмдуханың кияүдәге тормышы бер дә уңышлы булмый, өченче ireннән аерылгач, 1913 елның язында Иске Катайның Миңлехан Тәхаутдин улы (51 яшь; икенче никах) белән никахлаша (шул елның 15 маенда бу ире белән дә арасы бетә). Гарифулланың дүртенче кызы Бибимәрфуга (17 яшь) 1901 елның 10 сентябрендә Иске Катайның Шәрәфетдин Камалетдин улы (35 яшь; дүртенче никах) белән кавыша.



**Никах язуының аскы өлешендә Миңлегали Габделфәез улы белән Мөхәммәтдин Габделлатыйф улы тамга салганнар**

Габидулла Гарифулла улы (22 яшь) 1914 елның 20 мартында Иске Катайның Галимә Фәттахетдин кызы (18 яшь; атасы Фәттахетдин Баһаутдин улы Юлдаш нәселеннән) белән кавыша, өченче мәхәлләдә балалары Хәмидулла (12.06.1915–1917), Рәхмәтулла (1922), Гыйльмулла (01.08.1925), Камилә (1930) туа. Аталы-уллы Габидулла һәм Рәхмәтулла Гарифуллиннар – Ватан сугышы ветераннары.

Юныс Фәйзулла улы Корбангалиев 1875 елның 2 гыйнварында нәселдәше Сафиулла Солтанбәков кызы Гөлмәдинә белән никахлаша, балалары Зәйнулла (10.07.1877), Бибишәфига (05.09.1889), Мотыйгулла (03.08.1893–1895), Гыйниятулла (07.07.1897) дөньяга килә.

**Арсланбәкнең ерак нәселдәше – Гапсәлам** (Әпсәлам).

Габделсаттар Гапсәламов (1794) исемлекләрдә Күчем нәселе һәм аның ерак нәселдәше арасында 17 нче булып теркәлгән. Аның беренче хатыныннан уллары: Габделмәннан (1831–25.05.1916; Габделмәннаф дип тә язылган очрак бар), Габделнасыйр (1834–07.01.1889), Габделлатыйф (1837), икенче хатыныннан уллары: Мөхәммәтхафиз (1852), Мөхәммәтсафа (1854).

Габделмәннан Габделсаттар улы балалары: Мөхәммәтлатыйф (1850–05.01.1901), Мөхәммәтшәфикъ (1865), Мөхәммәтхарис (1867).

Мөхәммәтлатыйф Габделмәннан улы Габделсаттаров балалары: Хөснизиһан (1877), Мөхәммәтнасыйп (1884), Әхмәтнәгыйм (17.01.1889; анасы Гарифәтелкамал Төхфәтулла кызы), Әбүнәгыйм (1893–1895), Мөхәммәтназих (24.07.1895; анасы Фәхеркамал Төхфәтулла Габделмән улының кызы), Мөхәммәтзариф (29.12.1898). Мөхәммәтлатыйф кызы Хөснизиһан (18 яшь) 1895 елның 14 декабрендә Корычның Сәүбән Кәлимулла улы Хәлилуллов (22 яшь) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтшәфикъ белән Мөхәммәтхарис Габделмәннан уллары була.

Мөхәммәтнасыйп Мөхәммәтлатыйф улы балалары: Майшәрифә (29.07.1907; анасы Гайнелҗинан Газетдин кызы), Фәхерҗиһан (13.05.1910–1911; анасы Гайнелҗиһан Газетдин кызы), Мәгъдәнҗинан (16.07.1912), Мөхәммәтнәгыйм (17.07.1915). Мөхәммәтнасыйп Латыйпов (33 яшь) 1917 елда хатыны (28), улы һәм ике кызы белән яши, иманасы булмый, ат һәм кәҗә асрый, көтүче булып ялланган. Мөхәммәтзариф Латыйпов (19 яшь) 1917 елда ялгыз яши, ике абыйсын Беренче бөтендөнья сугышына алганнар, 5,90 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры була.

Мөхәммәтшәфикъ Габделмәннан улы Габделсаттаров белән Зәкия Гыйлаҗетдин Хәбибулла улының кызы гаиләсендә Гайнелзифа (1891), Мәрьям (1892–1901), Мөсәвәрә (1896–1901), Мөхәммәтнәҗип (24.06.1899–1901), Миңлемәрьям (14.06.1902) дөньяга килә. Мөхәммәтшәфикъ кызы Гайнелзифа (17 яшь) 1909 елның 5 гыйнварында нәселдәше Мөхәммәтгали Нигъмәтулла улы (25 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтхарис Габделмәннан улы белән Мөхәммәтнасыйп Мөхәммәтлатыйф улы була. Шәфикъ Мәннанов 1917 елда хатыны (57 яшь) һәм кызы белән яши, 6,23 дисәтинә җире, аты һәм башка маллары була.

Мөхәммәтхарис Габделмәннан улы Габделсаттаров балалары: Өммеҗиһан (04.12.1893; анасы Зарифа типтәр Габделбасыйр Габделкадыйр улының кызы), Мәдхиҗиһан (1896–1917), Кәнзелмәгариф (19.03.1898), Әбүталип (1899–1901), Әбүнәгыйм (19.07.1900), Гөлҗиһан (06.01.1903), Мөхәммәтләбип (12.08.1905), Мөхәммәтнәҗип (10.11.1907; анасы Зарифа), Мөсәвәрә (30.08.1910; 1966 елда загстан туу турында белешмә ала). Харис кызы Өммеҗиһан 1911 елның 10 февралендә Сеңрәннең Әбүталип Миңлеәхмәт улы (28 яшь; атасы Миңлеәхмәт Биктимер улы) белән кавыша. Икенче кызы Мәдхиҗиһан 1916 елда Туктаголның Төхфәтулла Камалетдин улы (50 яшь) белән никахлаша. Харис Мәннанов-

ның олы улын (Кәнзелмәгариф) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (45 яшь), ике улы һәм ике кызы белән яши, 6,51 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була.

Кәнзелмәгариф Харисов (1898) – Ватан сугышы ветераны, сугыш чорында гаиләсендә хатыны Фатыйма (1900), балалары Хәлифьян (1927), Вәзига (1934), Мәсгут (1936), Рәшидә (20.08.1942) була. Мәсгут Харисов Иске Катайның Фәнәвия Исламгали кызы Галиева белән гаилә кора, улы Фәнзил туа.

Мөхәммәтләбип Харисов (1905) – Ватан сугышы ветераны, сугышка киткәнче Бурят-Монголиядә яши, 1942 елның җәендә хатыны Рәхимә (1906), кызлары Зәнә (1928), Миннихалә (1931), уллары Хәбип (1930), Дим (17.08.1942) белән авылга кайта. Мөхәммәтләбип хатыны мәрхүм булгач, Латыйфа Хаҗиәхмәт кызы белән никахлаша, балалары Зөлфия (1945), Мәгъфурҗан (1949), Зөләлә (1954), Зәлифә (1957) туа.

Мөхәммәтнәҗип Харисов (1907–09.05.1988) Сеңрәннең Галимә Арслангали кызы (1907; мулла Әхмәтов нәселеннән) белән гаилә кора, балалары Хәмит (1936), Фәһим (1939, яшьли вафат), Хөснә (1946) һәм Галим (1950) туа. Нәҗип Харисов сугышка чаклы бригадир була, Ватан сугышында зур җәрәхәтләр ала (инвалид), сугыштан соң «Яңа тормыш» колхозы рәисе (1945, 1946 һәм 1949 елларда), бригадир, ферма мөдире булып эшли. Кешеләр белән эшләү, оештыру сәләтен улы Галим да күрсәтте, авыр елларда «Катай» ҖЧҖ оештырып, озак еллар уңышлы эшләде, дистәләрчә авылдашларыбызны эш белән тәэмин итте, зур ихтирам казанды.

Габделлатыйф Габделсаттар улы балалары: Мөхәммәтдин (1862), Җәмгыйтдин (1863), Габделкаюм (1868; 1911 елдан өченче мәхәллә мөәзине), Гыйниятулла (1875; мулла), Кашшафетдин (1876) һәм башкалар.

Мөхәммәтдин Габделлатыйф улы Габделсаттаров (25 яшь) 1887 елның гыйнварында Иске Катайның Габделнәфикъ Габделвәли улы Сөярголов кызы Бибифатыйма (18 яшь) белән кавыша, беренче мәхәлләдә балалары Кәшфелмәган (26.01.1889), Рәйфә (30.01.1893–1909), Гакифә (07.10.1898–1903), Мөнәвәрә (09.04.1901), Шәйхенур (17.10.1903), Шәехзаман (13.02.1906–1906), Мирсәгыйть (02.03.1908) туа.

Җәмгыйтдин Габделлатыйф улы балалары: Җәмигънур (30.11.1899; анасы Маһирә Габделлатыйф кызы), Камилә (01.02.1902–1905), Әхияретдин (1904–1906), Кәнзелголум (11.05.1906), Миңлесәкинә (26.11.1908), Салиха (28.01.1911), Кәнзеләсрар (1919; Ватан сугышы ветераны). Боларның нәселен кемнәр дәвам итә, дип сорагач, Кәнзелголумнан Тимерҗан, Кәнзеләсрардан Әсгать Латыйпов, дип әйткәннәр иде.

Мөәзин Габделкаюм Габделлатыйф улы Габделсаттаров балалары: Кәшфелмәган (06.06.1894–1894; анасы Гайникамал Шәйхулла Хәбибулла улының кызы), Мәрьям (1895), Шәйхенур (1898–1903), Нәгыймә (17.10.1901). Габделкаюм кызы Мәрьям 1913 елда Килкабызның Мөхәммәтзакир Мөхәммәтхафиз улы (25 яшь; атасы Мөхәммәтхафиз Габделнасыйр улы) белән кавыша. Габ-

делкаюмның икенче никахы 1914 елның 15 апрелендә авылдашы Фәррахша Әхмәди улының кызы Гыйльмиҗиһан (20 яшь) белән була, балалары Нәкыя (07.07.1915–1916), Рәкыя (01.08.1916–1917) туа. Габделкаюм Габделлатыйпов 1917 елда хатыны (45 яшь) һәм өч кызы белән яши, 20,87 дисәтинә җире, 5 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була. Габделкаюм кызы Нәгыймә (1901) авылдашы Хуҗагали Гомәров (Азамат нәселеннән) белән гаилә кора.

Мулла Гыйниятулла Габделлатыйф улы 1904 елның 20 февралендә авылдашы мулла Мөхәммәтзариф Мөхәммәтҗан улы Күчемов кызы Бибикәшифә (17 яшь) белән никахлаша, балалары Дөррия (15.10.1907), Әлтаф (14.09.1909), Наҗия (29.11.1911), Суфия (16.10.1913) туа. Әлеге 1904 елгы никах теркәлгән метрикәдә Гыйниятулланың яше 25 дип күрсәтелсә дә, беренче мәхәлләдә имам-хатип буларак үз кулы белән тутырган 1911 елгы документта 1875 ел дип бирелә. Муллалыкка укып йөрепме, өйләнүе шулай соңга калган, дип уйларга кирәк. Беренче китапта истәлекләргә таянып, Әлтаф Латыйповны, 1931 елда кулакларны эзәрлекләү башлангач, авылдан качып киткән дигән идек.

Кашшафетдин Габделлатыйф улы балалары: Мирзаҗан (02.12.1902; анасы Мәдхиҗамал Мөхәммәтгәрәй кызы), Мирсалих (01.11.1903), Әминә (12.02.1906–1906; анасы Мәдхиҗиһан Әхмәтгәрәй кызы), Миргалим (22.11.1907), Мирзаһит (16.06.1910; анасы Мәдхиҗамал Мөхәммәтгәрәй кызы), Мәхтүмә (23.12.1912–1913; анасы Мәдхиҗиһан Мөхәммәтгәрәй кызы), Салихҗан (10.07.1914), Саимә (1917; Катай авыл советы кенәгәсендә күрсәтелә, метрикәдә юк), Зәки (1917; Катай авыл советы кенәгәсендә күрсәтелә, метрикәдә юк; 1939 елда хәрби хезмәткә алалар), Шәрифҗан (1921), Фаягөл (01.10.1925; анасы Гыйльмиҗиһан Фәрухша кызы), Мәкки (1927; Ватан сугышы ветераны), Мөтәвәкил (1931), Мөзәкки (1933), Зәмзәмия (1936). Боларның бер өлеше Кашапов (мәсәлән, Мөтәвәкилдән – Әлтаф, Атлас, Зәлифә, Әлфит Кашаповлар, Мөзәккидән Фирдәвес, Рәүфәт, Фәрит Кашаповлар), икенчеләре Латыйпов фамилиясендә йөриләр, күп булганга һәрберсенә аерым тукталып тормыйбыз. Мирсалих Кашапов – Ватан сугышы ветераны, авыл советы кенәгәсендә сугышка чаклы хатыны Кәримә (1905), балалары Сөгъдә (1931), Рифкать (1933), Фәһим (1935), Риба (1939) теркәлгән. Миргалим Кашапов сугышка 1941 елның 14 июлендә китә, хатыны Мөнәвәрә Афзал кызы (1911), балалары Фәүханә (1932), Фоат (1939) кала. Миргалим (1907), Салихҗан (1915), Шәрифҗан (1921) Латыйповлар – Ватан сугышы корбаннары (исемнәре Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Мөхәммәтхафиз Габделсаттар улы Гапсәламов балалары: Бибихәмидә (1876), Бибизәкия (25.08.1877; анасы Бибигабидә), Мөхәммәтзариф (01.02.1880; анасы Габидә), Мөхәммәтсалих (1882), Бибифакия (1887), Бибиһидая (07.08.1889), Мөхәммәтназиф (24.10.1899; анасы Габидә Фәхретдин Фәтхетдин улының кызы). Мөхәммәтхафиз кызы Бибихәмидә (19 яшь) 1895 елның 26 ноябрендә Яңа Куянның (Камышлытамакның) Әхмәтнәби Төхфәтулла улы Габделмәнов (20 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары

Мөхәммәтсафа Габделсаттар улы белән Мөхәммәтшәфикъ Габделмәннан улы була. Икенче кызы Бибифакия 1904 елның гыйнварында Килкабызның Җиһангир Мөхәммәтхафиз улы (24 яшь; атасы Мөхәммәтхафиз Әрдәшир улы) белән кавыша. Өченче кызы Бибиһидая 1911 елда авылдашы Низаметдин Саяфетдин улы белән гаилә кора. Мөхәммәтхафиз Гапсаттаровның олы улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (60 яшь), төпчек улы (17) һәм килене белән яши, 6,18 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була. Мөхәммәтназиф белән Кәшифә (1905; Килкабызныкы) балалары: Нәфисә (1925), Җәүдәт (1931), Фәнәви (1937), Әүхәт (1940). Назиф Хафизов – Ватан сугышы ветераны (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән). Җәүдәт Кадернең Әзерия Имамразый кызы (1940) белән гаилә кора, балалары Фәвилә (1960), Илгиз (1964), Илдар (1967), Илфат (1976), Венера (1978) туа.

Мөхәммәтсалих Мөхәммәтхафиз улы балалары (өченче мәхәллә): Мөхәммәтгариф (25.02.1912–1912), Галләметдин (10.04.1916; анасы Гыйльмиҗиһан Гайнулла кызы).

Мөхәммәтсафа Габделсаттар улы Гапсәламов 1877 елның 1 гыйнварында авылдашы Ногман Таҗетдин улының кызы Кафия (17 яшь) белән никахлаша, балалары Мөхәммәтсабир (12.02.1878), Мөхәммәткәбир (05.10.1880; анасы Бибикафия), Сабира (01.07.1883), Бибисара (1888), Мөхәммәтхәбир (13.11.1889), Маһирә (28.03.1893–1907; анасы Кафия Ногман кызы), Мөхәммәтшакир (1894) дөньяга килә. Мөхәммәтсафа кызы Бибисара (17 яшь) 1906 елның февралендә Иске Дөмәйнең Хәсәнҗан Шәфигулла улы (25 яшь; атасы Шәфигулла Габделхәбир улы) белән никахлаша.

Мөхәммәтсабир Мөхәммәтсафа улы балалары: Дөһөдия (18.06.1904–1905; анасы Бибиәсма Муллагали кызы), Мөхәммәтнасыйх (22.01.1906), Бәһия (10.10.1908; 1963 елда загстан туу турында белешмә ала), Бибимаһирә (15.02.1911), Миркасыйм (20.10.1913). Мөхәммәтсабир Мөхәммәтсафин 1917 елда хатыны (37 яшь), ике улы һәм өч кызы белән яши, 7,43 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры, 6 сарыгы була. Сабир Сафин (1874) Ватан сугышы алды елларында хатыны Әсма (1877), улы Миркасыйм (1913), килене Шәмсия (1919), кызы Сания (1918), оныгы Мэлс (1940) белән яши. Миркасыйм сугышта хәбәрсез югала (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән). Мөхәммәтшакир Мөхәммәтсафа улы 1917 елда авылдашы Фатиха Әхмәтситдыйкъ кызы (25 яшь) белән никахлаша, язмышы билгесез.

Югарыда сүз Габделсаттар Гапсәламовның балалары һәм оныклары турында барды. Габделсаттарның энесе Габделфәез (1799) дә нәсел калдыра. Габделфәезнең беренче хатыныннан уллары: Миңлегол (1856 елда 28 яшьтә вафат), Габделгазиз (1841), икенче хатыныннан уллары: Габделҗаббар (1849–25.02.1916), Миңлегали.

Габделгазиз Габделфәез улы балалары: Миңлешәһәрбану (1858), Фатыйма (1873–1878), Хәкимә (19.06.1877; анасы Суфия), Хәтирә (1885), Габдулла (1887), Фатыйма (26.09.1889). Габделгазиз кызы Миңлешәһәрбану (18 яшь) 1876 елның

4 декабрендә Килкабызның Хисаметдин Җамалетдин улы (24 яшь) белән гаилә кора. Икенче кызы Хәтирә 1901 елның 2 гыйнварында авылдашы Нурлыгаян Нурмөхәммәт улы Нөрмәтов (24 яшь) белән никахлаша. Өченче кызы Фатыйма 1910 елның 4 октябрендә авылдашы Мөхәммәтсалих Әфләтун улы (25 яшь; икенче никах) белән кавыша.

Габдулла Габделгазиз улы 1909 елның ноябрендә Иске Катайның Вәлиулла Кәлимулла улының кызы Бибисорур (18 яшь) белән никахлаша. Егетнең вәли вәкиле – Габделҗаббар Габделфәез улы, ризалык шаһитлары Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк белән Сафиулла Рәхмәтулла уллары була. Габдулла балалары (өченче мәхәллә): Фәрхисорур (01.11.1911, анасы Бибисорур), Фәүзия (24.11.1913–1914; анасы Фәрвиҗамал Тәхаутдин кызы), Бибисәкинә (25.10.1915–1916). Габдулла Бибисорур белән 1912 елның 1 августында «мәхәббәтләре юклык сәбәпле» аерылыша. Шаһитлар Муллаҗан Габделгани улы белән Мөхәммәтхафиз Мөхәммәди улы «Н» хәрефе формасында тамга салалар.

Габделҗаббар Габделфәез улы Гапсәламов балалары: Садыйкҗан, Миңлеҗиһан (08.11.1893–1894), Әмирҗан (28.10.1895; анасы Бәдриҗамал Мөхәммәдьяр Әсфәндияр улының кызы).

Садыйкҗан Габделҗаббар улы балалары (өченче мәхәллә): Мөбәракша (05.11.1911–1915; анасы Хөсниҗиһан Әхмәтгәрәй кызы), Фәрхиҗиһан (24.11.1913–1915; анасы Фәрхиҗамал Әхмәтгәрәй кызы), Сабитҗан (10.02.1916; анасы Хөсниҗиһан).

Миңлегали Габделфәез улы балалары (өченче мәхәллә): Шәмсеруй (1888), Фәрхисорур (1889–1893), Хаҗгали (1894–1895), Дәүләтгали (01.02.1899; анасы Шәмсехәят Хәлилулла Галикәй улының кызы), Миңлесорур (30.10.1901), Сәетгали (16.10.1904; анасы Шәмсехәят Хәлилулла кызы), Хуҗагали (27.07.1907), Шәехгали (10.11.1911–1915), Исламгали (28.02.1913). Миңлегали кызы Шәмсеруй (20 яшь; икенче никах) 1909 елның 10 гыйнварында Туктаголның Сөнәгатулла Шаһидулла улы (23 яшь) белән никахлаша.

**Арсланбәкнең ерак нәселдәше – мулла Яугилде Үрмәтов** (1762).

Яугилденең уллары мөәзин Таҗетдин (1793; беренче хатыныннан улы) белән Сираҗетдин (1796; икенче хатыныннан улы) була. Таҗетдин уллары: Гыйлаҗетдин (1815–1817), Камалетдин (1818; беренче хатыныннан уллары), Ногман (1826), Бәдретдин (1840; икенче хатыныннан уллары), Раҗетдин (1843), Хөснетдин (1849), Хисаметдин (1857). Мөәзин Таҗетдин Яугилдин кайбер туганнары белән 1858 елда Килкабыз авылына күчеп утыра. Шунда һәм совет чорында Корычкаранда гомер иткән Яугилдиннәрнең мин төзегән бер шәҗәрәсе болай: Үрмәт–Яугилде (1762 туган; мулла) – Сираҗетдин (1796) – Шәрәфетдин (1833; мөәзин) – Кәшфелмәган (1867–30.12.1917) – Әхмәтхәбип (1895–1958) – Шамил (1931–1991) – Радик (1956) – Гүзәл (1985), Марат (1978), Алия (1998). Радик Шамил улы Яугилдин «Башмелиорация» генераль дирек-

торы булып эшләгән иде, илле бишкә дә житми йөрәк белән китеп барды. Мөәзин Таҗетдиннең дүрт улы була, шуларның берсе Раҗетдиннән Габделхак (1874) туа. Әнгам Габделхак улы Яугилдин – Ватан сугышы ветераны, Катай мәктәбендә берара директор, аннары укытучы булып эшләде. Әнгамнең апасы Гайшә (1918) – Бакалы район полициясенең элеккеге башлыгы Зөлфәт Шәмси улы Шәймәрдановның анасы. Түбәндә Яугилденең Катайдагы варислары турында мәгълүмат биреп үтәбез.

Камалетдин Таҗетдин улы балалары: Низаметдин (1844), Фәрхетдин (1855–15.06.1907), Фәхретдин (1859).

Низаметдин Камалетдин улы Таҗетдинов балалары: Гыйлаҗетдин (01.05.1877; анасы Мөгълифә), Мәүлиха (1884), Гыймадетдин (24.07.1894–1895; анасы Мөгълифә Әбүбәкер Миңлекәй улының кызы). Низаметдин кызы Мәүлиха (17 яшь) 1901 елның 4 сентябрендә авылдашы, хатыны вафат булган Нуриәхмәт Равил улы (45 яшь) белән никахлаша.

Гыйлаҗетдин Низаметдин улы балалары (өченче мәхәллә): Җәмгыйтдин (10.07.1902; анасы Зәкия Хөснетдин кызы), Бәһия (20.12.1904; анасы Бибизәкия Хөснетдин кызы), Гакифә (12.02.1907–1910), Факия (25.03.1909–1910), Миңледөһедия (05.01.1911–1915), Кашшафетдин (01.08.1913–1915), Әһлия (05.10.1915). Гыйлаҗетдин Низаметдиновны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (35 яшь), улы, ике кызы һәм анасы (60) кала, 1917 елда 3,68 дисәтинә җире, аты була.

Җәмгыйтдин Гыйлаҗетдин улы белән Мәдинә Мөхәммәтҗан кызы никахыннан Мөкәмил (22.02.1925) туа. Җәмгыйтдин Гыйләҗов – Ватан сугышы ветераны, «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале (25.07.1944) белән бүләкләнгән, сугышка чаклы гаиләсендә хатыны Гарифа (1906), балалары Гафифә (1930) белән Әүхади (1932) була.

Фәрхетдин Камалетдин улы Таҗетдинов балалары: Миңлебану (10.07.1880; анасы Бибишәмсия), Бәдретдин (1881), Шәрәфетдин (19.06.1889), Нурлыгаян (12.06.1895), Кашшафетдин (24.03.1898), Зыятдин (15.06.1901–1905; анасы Шәмсия Габделнәфикъ кызы), Миңлешәрифә (20.11.1906; анасы Хәнифә Габделҗәмил кызы). Фәрхетдин кызы Миңлебану (17 яшь) 1901 елның февралендә авылдашы Шәймәрдан Мәрданша улы (30 яшь; икенче никах) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Галләметдин Гыймадетдин улы белән Фәхертдин Фәрхетдин улы була.

Бәдретдин Фәрхетдин улы (22 яшь) 1902 елның 7 ноябрендә авылдашы Садретдин Гайнетдин улының кызы Гыйльмиҗиһан (17 яшь) белән никахлаша, балалары Гыйльметдин (06.10.1903–1905), Сорурҗиһан (12.10.1905), Фәхерҗиһан (02.05.1908), Шәкүрҗан (20.08.1910), Гөлҗиһан (22.03.1913), Өммегөлсем (10.12.1914) туа.

Ногман Таҗетдин улы балалары: Кафия (1859), Гайса (1860). Ногман кызы Кафия (17 яшь) 1877 елның 1 гыйнварында авылдашы Мөхәммәтсафа Габделсаттар улы (22 яшь) белән никахлаша.



**Гайсиннар гаиләсе. 1954 елның 22 июне**

Гайса Ногман улы Таҗетдинов балалары: Шәмсехәят (1888), Шәмсебәдәр (1896), Шәмсебану (02.08.1897; анасы Шәмсекамәр Шәяхмәт Шәйморат улының кызы), Әбүнәгыйм (09.08.1904), Шәмсеҗиһан (29.04.1907), Бибинур (15.01.1911). Гайса кызы Шәмсехәят 1906 елның 26 гыйнварында Туктаголның Галиулла Шаһидулла улы (25 яшь; атасы Шаһидулла Хәмидулла улы) белән кавыша. Икенче кызы Шәмсебәдәр 1917 елның 6 гыйнварында Туктаголның Мөхәммәтрәхим Сөләйман улы (23 яшь; атасы Сөләйман Сәмигулла улы) белән никахлаша. Гайса Ногмановның ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда ул кече улы Әбүнәгыйм белән яши, 12,62 дисәтинә җире, 2 аты һәм сыеры була. Әбүнәгыйм Гайсин (1904) Иске Катайның Бибигалимә Кадермөхәммәт кызы (1905–14.03.2003) белән никахлаша, 1945 елның 31 гыйнварында Ватан сугышында һәлак була, хатыны, балалары Фәнүзә (1932), Рәис (1935), Фәния (1938) кала. Фәнүзә Инсаф Җәләев белән гаилә кора. Фәния ире Мөгаллим белән Ташкентка чыгып китә. Рәис Гайсин авылдашы Ягъдә Мәрдан кызы белән гаилә кора, балалары Рөстәм (1965) һәм Миләүшә (1966) туа. Рөстәм хатыны Илсөяр белән Алабуга шәһәрендә яши, уллары Илдар белән Азат. Миләүшә тормыш иптәше Рәдис белән Чакмагышта гомер итә, уллары Вадим, Ленар һәм Динар. Яугилденең икенче

улы Сиражетдин иде. Сиражетдин уллары: Гыймадетдин (1821), Шәрәфетдин (1833). Гыймадетдиннән нәселне Галләметдин (1864–19.02.1909) белән Бәдретдин дәвам итә.

Галләметдин Гыймадетдин улы Сиражетдинов балалары: Гыйззениса (1887), Фәрхениса (20.08.1895; анасы Гыйльмениса Фәхрулла Гайнулла улының кызы), Гыйлаҗетдин (09.08.1898–1898), Фәрхениса (23.01.1906; анасы Гыйльмениса Фәхрулла кызы), Фәрхенур (1907–1910). Галләметдин кызы Гыйззениса 1904 елда авылдашы Газизҗан Нурмөхәммәт улы белән никахлаша, кызның ризалык шаһитлары Фәрхетдин Камалетдин улы белән Бәдретдин Фәрхетдин улы була.

Бәдретдин Гыймадетдин улы Сиражетдинов балалары (өченче мәхәллә): Госаметдин (05.01.1909), Фатыйма (05.07.1911; анасы Бибисара Сәлимгәрәй кызы), Бибикамал (1914–1915), Фәхретдин (01.12.1915; анасы Бибисара Сәлимгәрәй кызы), Бибисаҗидә (1923–1925). Бертуган Госаметдин (Хисаметдин; 1909), Фәхретдин (1915) һәм Хирай (1922; очучы) Бәдретдиновлар (Гыймазетдиновлар) – Ватан сугышы корбаннары (икесенең исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән), сугыш алды еллары кенәгәсендә аларның анасы Сара (1876) һәм сеңлесе Фатыйма теркәлә.

Хисаметдин Бәдретдинов гаиләсендә Ватан сугышы алдыннан хатыны Оркыя (1911), балалары Инсаф (1930), Сәхлә (1933), Вәсилә (1936), Рәсимә (1940) була. Инсаф Гыймадетдинов (1930) Мулланурның (Тыпыйның) Гамилә Сәлах кызы Сафина (10.02.1932 туган) белән гаилә кора, балалары Лариса (21.04.1960), Тәслия (02.01.1962), Илшат (25.01.1964), Гөлнара (01.06.1971) дөньяга килә.

**Арсланбәкнең ерак нәселдәше – Колмәмәт** (Колмөхәммәт; боларның нәсел тамгасы ике таяк, шул таякның сул ягындагы очыннан аска таба сызык).

Исемлекләрдә югарыда сүз барган Габделсаттар Гапсәламовлардан соң 18 һәм 19 саннар астында теркәлә.

Колмәмәт балалары: Динмөхәммәт (1766–1827), Мөхәммәткәрим (метрикәләрдә Габделкәрим; 1784–1851), Колый (гомере 1812 елда хәрби хезмәттә өзелә).

Динмөхәммәт Колмәмәт улы нәселен Ногманвәли (1818–1853) дәвам итә. Ногманвәли Динмөхәммәт улы балалары: Әхмәтвәли (1845), Шәмсевафа (1843–1903), Габделвәли (1849–1852).

Әхмәтвәли Ногманвәли улы балалары: Әхмәтгали (10.05.1889–1979; анасы Бибишәмсия Гыймадетдин кызы), Мөхәммәтнәби (23.02.1903), Нәгыймә (10.08.1900–1901), Закирә (18.07.1905–1906), Гакифә (23.07.1907), Шәйхенур (13.02.1911–1911; анасы Сабира Габделҗәмил кызы), Маһирә (22.12.1913), Кифая (25.01.1916). Әхмәтгали Әхмәтвәли улы Вәлиев бер энесе белән Беренче бөтендөнья сугышында, аннары үзе Ватан сугышында катнаша. 1917 елда аның 11,58 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була.

Мөхәмммәткәрим Колмәмәт улы балалары: Габдерәхим (1807), Габдерәфикъ (1810), Габделгани (1812), Габделлатыйф (1826).

Габдерәхим Мөхәмммәткәрим улы балалары: Габделихсан (1835–11.08.1903), Габделкәрим (1838), Габделгалим (1841–29.02.1917), Габделмалик (1859), Габдрахман (21.08.1874; анасы Сара), Шәмсебану (1873), Шәмсеҗамал (1875). Габдерәхим кызы Шәмсебану (17 яшь) 1890 елның октябрендә Килкабызның Гыйззәтулла Сибгатулла улы (25 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Шәмсеҗамал (24 яшь; икенче никах) 1899 елның 20 сентябрендә авылдашы Шәйхелгаттар Шәйморат улы (23 яшь; икенче никах) белән кавыша. Хатынның вәкиле – бертуган агасы Габдрахман Габдерәхим улы, ирнеке атасы Шәйморат Шәймәрдан улы була.

Габделихсан Габдерәхим улы Кәримов балалары: Габделгазим (1862), Габделзаһир (1865), Габделкадыйр, Гайниҗамал (1865), Мөхәммәтхарис, Мөхәммәтзакир (19.07.1874–1875), Мөхәммәтхафиз (29.08.1876; анасы Шәмсекамал). Габделихсан кызы Гайниҗамал (30 яшь; икенче никах) 1895 елның 6 февралендә ерак нәселдәше Әхмәтша Тимергали улы Габидуллин (40 яшь; өченче никах) белән кавыша.

Габделгазим Габделихсан улы (30 яшь; икенче никах) 1892 елның 5 октябрендә Иске Катайның Яхшыгол Миңлегол улының кызы Бибикамилә (1867–13.05.1905; икенче никах) белән никахлаша. Габделгазим балалары: Маһисафа (1888), Бибикамал (18.04.1894; анасы Бибикамилә Яхшыгол Миңлегол улының кызы), Хәмидә (1895), Габделгазиз (25.10.1898), Бибишәфига (1903–1906), Шәйхелгалим (21.03.1906; анасы Бәдерниса Гыйльметдин кызы), Гыйльмегалим (13.03.1909), Габдулла (22.07.1912–1915), Фәрхениса (09.05.1917). Хатыны вафат булгач, Габделгазим 1906 елның декабрендә Минзәлә өязе Ахун авылының Гыйльметдин Сәйфетдин улының кызы Бәдерниса белән никахлаша. Габделгазим кызы Маһисафа (17 яшь) 1905 елның 16 ноябрендә авылдашы Нургали Фәрукша улы (25 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Бибикамал (18 яшь) 1913 елның гыйнварында Дөмәйнең Минһаҗетдин Бәдретдин улы (24 яшь; атасы Бәдретдин Габделгалим улы) белән гаилә кора. Бибикамал кире кайтып, 1914 елның 25 маенда Тыпыйның Габделхәбир Габделлатыйф улына (38 яшь; икенче никах) кияүгә бара. Габделгазимның төпчек кызы Хәмидә 1915 елда Иске Катайның Нурмөхәммәт Хаҗиәхмәт улы (45 яшь) белән кавыша.

Габделзаһир Габделихсан улы (25 яшь) 1890 елның 26 ноябрендә авылдашы Сираҗетдин Хөсрәүбәшир улының кызы Миңлеҗиһан (17 яшь) белән никахлаша, балалары Миңлехөсниҗиһан (22.09.1893), Габделҗәлил (16.10.1897), Хәлфеҗиһан (19.01.1901), Хәсбиҗинан (22.10.1903), Фәрхиҗиһан (05.12.1905), Бибиҗиһан (20.10.1908), Фатыйма (11.05.1912) туа. Габделзаһир кызы Хөсниҗиһан (17 яшь) 1910 елның 12 ноябрендә авылдашы Шәйшәриф Мөхәммәтшәриф улы (25 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Габделкадыйр белән Мөхәммәтхафиз Габделихсан уллары була. Габделзаһирның икенче кызы Хәлфеҗиһан Әсәдулла Кәлимуллин белән гаилә кора. Ватан сугышы алдыннан

Фәрхиҗиһан Заһирова (1905) апасы Хәсбиҗинан (1903), анасы Миңлеҗиһан (Миннизиян; 1878) белән яши.

Габделзаһирның биш кызы булуын, кайберсенең язмышы турында Әсгать Кәлимуллин кызы Фәндүзә Зарипова (1956 елгы) белә торган булып чыкты. Кызларның кайсы авылда гаилә корып яшәвен, Габделзаһирны «кулак»лыкта гаепләп, мал-мөлкәтен тартып алуларын сөйләде. Кайбер мәгълүмат төгәлмеюкмы икәнен ачыклауны таләп иткәнлектән, ул сөйләгәннәрнең барысын да язмаска булдым.

Габделкадыйр Габделихсан улы Кәримов балалары: Габделхәбир (07.11.1893; анасы Шәмсекамал Зәйнулла Нигъмәтулла улының кызы), Гайникамал (06.09.1895), Гайнелҗинан (04.08.1897–1897), Габделкәбир (09.07.1898–1898), Габделханнан (26.10.1899–1905), Габделгазиз (30.08.1902), Майбану (12.10.1906; анасы Шәмсебану Зәйнулла кызы), Миңлебану (02.07.1908–1909), Миңлегариф (20.04.1910–1914; анасы Шәмсекамал Зәйнетдин кызы), Мосифулла (09.08.1913). Өч бала атасы Габделхәбир Кадыйров (1893) сугышта яралана, 1944 елда исән була, алга таба язмышы билгесез (ул сугышка Чүмәлә Катайдан киткән, ахры). Газиз Кадыйров (1902) 1941 елның ноябрендә хәрби хезмәткә китә (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән), өендә хатыны Хәтимә (1906), уллары Габделфаяз (06.08.1925), Хәмит (1934), Гавис (1939), кызы һәм анасы Шәмсевафа (1868) кала.

Мөхәммәтхарис Габделихсан улы Габдерәхимов белән Миңлевафа Шәйхетдин Хисаметдин улының кызы гаиләсендә Мөхәммәтзакир (15.03.1899) дөньяга килә.

Мөхәммәтхафиз Габделихсан улы (25 яшь) 1906 елның 6 мартында авылдашы Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтгали улының кызы Мәликә (17 яшь) белән гаилә кора. Мөхәммәтхафиз балалары: Сәрия (24.02.1913), Мөхәммәтзариф (03.09.1915; анасы Мәликә Мөхәммәтхафиз кызы), Нәкыя (12.10.1925; анасы Сәгурә Дәүләтгәрәй кызы). Мөхәммәтхафиз Габделихсанов 1917 елда хатыны (25 яшь), улы (2), кызы (4) һәм анасы (70) белән яши, 11,23 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры, сарыгы була. Хафиз Ихсанов (1874) Ватан сугышы алды елларында хатыны Сәгурә (1889), улы Зариф (1915), кызлары Фатыйма (1918), Тәгъзимә (1928), Фәһимә (1932) белән гомер итә. Ватан сугышы башлангач Зарифны хәрби хезмәткә чакыралар (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Габдерәхим Габделкәрим улы нәселен тагын бишенче улы Габдрахман дәвам итә. Габдрахман Габдерәхим улы 1902 елның 3 ноябрендә авылдашы Борһанетдин Гыйлаҗетдин улы Күчемов кызы Хәдичә (17 яшь) белән никахлаша. Кияүнең вәкиле – Габделкаюм Габделгани улы Кәримов, ризалык шаһитлары Солтан Калкаман улы белән Габделзаһир Габделихсан улы була. Габдрахман белән Хәдичә балалары: Хәбибрахман (07.07.1904–20.03.1910), Шәйхерахман (25.01.1906), Гыйззерахман (15.08.1907–1910), Шәйхәйдәр (13.11.1908), Хәбибрахман (21.07.1910–1913), Рәйфә (17.01.1912), Мәэлүфә (05.08.1913), Шәйхе-

рам (09.02.1915–1915), Шәйхенур (09.01.1917), Мәгъсуфә (1924), Мәгъсүмә (12.07.1925), Рәйсә (1932). Габдрахман Габдерәхимов 1917 елда хатыны (30 яшь), өч улы һәм ике кызы белән яши, 21,90 дисәтинә җире, җилгәргече, 5 аты, 3 сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче яллый. Габдерәхим кызы Рәйфә (1912) Иске Катайның Җәмигънур Хәсән улы (1911) белән никахлаша. Шәйхерахман (1906) белән Шәйхенур (1917) Габдрахмановлар 1942 елда Ватан сугышында хәбәрсез югалалар, Шәйхәйдәр исән-сау кайта (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Шәйхәйдәр Габдерәхимовның беренче хатыны Иске Катайның Мирзаян Кәримов кызы Наҗия (1914; Юлдаш нәселе) була. Бу никахтан Габделхәй (1937), Мәгъфирә (02.04.1947), Фәһимә (1948) һәм Фәния (10.07.1950) дөньяга килә. 1954 елда хатыны Наҗия мәрхүм булгач, Шәйхәйдәр кабат өйләнә, балалары Фәридә, Рәмилә, Фәнүзә һәм Фәйрүзә дөньяга килә. Мәгъфирә Шәйхәйдәр кызы Нәбиева Килкабызда яши, балалары Гүзәлия (1966) һәм Илдар (1969) туа, шигырьләр яза. Фәһимә Шәйхәйдәр кызы атасының сеңлесе Мәгъсуфә (1924) тәрбиясендә үсә. Фәһимәнең кызы Лилия Садыйкова бу юллар авторы белән элемтәгә кереп, Юлдаш нәселе буенча кайбер мәгълүмат әйтте, тарихыбыз белән кызыксынып яшәвен күрсәтте.

Югарыда сүз Габделкәрим Колмәмәт улының беренче варисы Габдерәхимнең балалары һәм оныклары турында барды. Габделкәрим Колмәмәтовның икенче улы Габдерәфикъ иде. Габдерәфикъ Габделкәрим улы балалары: Габделбасыйр (1841–15.06.1899), Габделмәннан.

Габделбасыйр Габдерәфикъ улы Кәримов балалары: Бибихәнифә (17.07.1877; анасы Сара), Габделсадыйр (30.07.1880), Бибихәкимә (1882), Габделмәҗит (22.07.1883), Габдулла (10.09.1893; анасы Сабира Арслан кызы). Габделбасыйр кызы Бибихәнифә 1895 елның 22 ноябрендә Корычның Ильяс Мөхәммәт улы Үмербаев (21 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары – Габделкаюм Габделгани улы һәм Габделмәннан Габдерәфикъ улы, кияүнеке Әюп белән Йосыф Мөхәммәт уллары була. Габделбасыйрның икенче кызы Бибихәкимә (17 яшь) 1901 елның августында Корычның хатын аерган Габделмалик Габделгалим улы (25 яшь) белән никахлаша. Бибихәкимә бу һәм тагын бер ир белән тормышы барып чыкмагач, 1903 елның 3 октябрендә Кадернең хатыны вафат булган Нигъмәтулла Рәхмәтулла улы белән (25 яшь; икенче никах) кавыша.

Нәселне Габделкәрим Колмәмәтовның өченче улы Габделгани дә дәвам итә. Габделгани Габделкәрим улы балалары: Габделкадыйр (1841), Габделзаһир (1846–1851), Габделкаюм (1850), Габделҗәмил (1855–28.12.1909), Муллагали (1859–08.07.1909), Бибигазизә (1864–1894), Бибихәкимә, Бибифакия (1873), Солтангали (1877–12.10.1916). Габделгани кызы Бибихәкимә нәселдәше Минхәтулла Гыйззәтулла улы Һибәтуллин белән кавыша. Икенче кызы Бибифакия (17 яшь) 1890 елның 11 октябрендә авылдашы Шәйгардан Шәймәрван улы (20 яшь) белән никахлаша.

Габделкаюм Габделгани улы Кәримов балалары: Хөснибану (21.06.1877), Габделҗәлил (06.02.1880; анасы Фәрхебану), Маһибану (1882–1905), Санияшәрьям (19.01.1889), Мөхәммәткәрим (21.03.1893–1893; анасы Фәрхебану Мөхәммәтҗәлал кызы), Сәхипбану (22.08.1894), Гөлбану (1896–1901), Майсорур (18.12.1898; анасы Фәрхебану), Мирзаһит (13.02.1899; анасы Хөррәмбану Мөхәммәтлатыйф Вәли улының кызы), Хөснибану (28.08.1901), Гөлбану (06.11.1904), Мирсәгыйть (15.10.1913–1914; анасы Бану Җиһангир кызы), Габделмөэмин (13.12.1915; анасы Хөррәмбану Мөхәммәтлатыйф кызы). Габделкаюмның икенче никахы 1898 елның 3 гыйнварында авылдашы Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтвәли улының кызы Хөррәмбану (23 яшь; икенче никах) белән була. Габделкаюм кызы Маһибану (17 яшь) 1899 елның 29 ноябрендә Яңа Күктауның Миңлеәхмәт Якуп улы (20 яшь) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Габделмәннан Габдерәфикъ улы белән Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтгали улы була. Уртанчы кызы Санияшәрьям 1905 елның декабрендә авылдашы Габдулла Төхфәтулла улы (22 яшь) белән никахлаша. Төпчек кызы Фәрхисорур (17 яшь) 1908 елның 5 гыйнварында Килкабызның Әюп Динмөхәммәт улы (20 яшь; атасы Динмөхәммәт Мөхәммәтвәли улы) белән гаилә кора. Кызның ризалык шаһитлары – Габдрахман Габдерәхим улы белән Габделҗәмил Габделгани улы, егетнеке Сәетбаттал Мөхәммәтвәли улы белән Якуп Динмөхәммәт улы була. Каюм Ганиев 1917 елда ике хатыны (40 һәм 60 яшьләрдә), өч улы һәм ике кызы белән яши, 47,18 дисәтинә җире, 5 аты, 6 сыеры һәм башка маллары, җилгәргече була, хезмәтче яллый.

Габделҗәмил Габделгани улы Габделкәримов 1888 елның декабрендә Иске Катайның Хәйрулла Төхфәтулла улының кызы Бибикафия белән никахлаша. Габделҗәмил балалары: Бибикифая (07.12.1889), Бибикәшифә (1890–1894), Бибигашия (15.08.1893; анасы Бибикафия), Әбүнәгыйм (06.03.1898), игезәкләр Майшәрифә (20.12.1901; анасы Фәрхиҗиһан Сәеткол кызы) белән Шәрифҗан (20.12.1901–1905), Шаһиҗан (10.10.1907), Хәсәнҗан (25.12.1909–1910).

Муллагали Габделгани улы Габделкәримов балалары: Хаҗгали (24.07.1895), Хәтимә (01.08.1897–1898; анасы Фәрханә Мөхәммәт Үмербай улының кызы), Камилә (02.01.1902; анасы Шәмсебану Хисаметдин кызы), Маһибану (06.08.1905).

Солтангали Габделгани улы Габделкәримов балалары (беренче мәхәллә): Тимергали (25.01.1911; анасы Бибинуар Кәлимулла кызы), Тимерхан (15.01.1914–1914), Әхмәтнәгыйм (21.01.1916–1917).

Габделкәрим Колмәмәтовның нәселен тагын төпчек улы Габделлатыйф дәвам итә. Габделлатыйф Габделкәрим улы балалары: Мөхәммәтлатыйф (1846), Мөхәммәтзариф, Мөхәммәтшакир (1868).

Мөхәммәтзариф Габделлатыйф улы Кәримов балалары: Мөхәммәтсадыйк (12.08.1877), Бибиталига (1888), Бибишәмсеталига (14.11.1889), Бәдерталига (17.06.1893–1893; анасы Шәрифҗамал Ибнеәмин кызы). Мөхәммәтзариф кызы

Бибиталига 1905 елда авылдашы Нигъмәтулла Хәлилулла улы (22 яшь) белән никахлаша.

Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтзариф улы 1900 елның 3 мартында Иске Катайның Шәйхеразый Габделихсан улының кызы Бибихәтирә (18 яшь) белән никахлаша, балалары Мөхәммәтсалих (12.02.1902), Кәшифә (10.05.1904), Хәтимә (11.02.1906), Бәдерталига (1910–1917), Мөхәммәтгали (28.11.1911–1914), Фәймә (02.04.1915) туа. Салих Садыйков Чүмәлә Катайда яши, сугышта «Батырлык өчен» (06.05.1945) медале белән бүләкләнә.

Мөхәммәтшакир Габделлатыйф улы Кәримов 1894 елның 1 гыйнварында Тогашның Мостафа Моратбакый улының кызы Бибимотаһарә (18 яшь) белән гаилә кора.

Колмәмәтнең төпчек улы Колыйдан да нәсел дәвам итә. Аның уллары Габделгаффар (1796–02.02.1876), Хөсрәүбәшир (1805), Хасфран (1811–1812) була.

Габделгаффар Колыевның беренче хатынынnan уллары: Габделнәфикъ (1826), Габделбәшир (1829–08.03.1904), Габделҗаббар (1834). Габделнәфикъ Габделгаффар улы ир балалары: Мөхәммәтшәриф (1846), Габделхак (1848), Габделшәфикъ (1852), Миңлехан (1853–1925), Әмирхан (1855), Шәфигулла, Мөхәммәтсабир (1864).

Габделхак Габделнәфикъ улы Габделгаффаров балалары: Габделханнан (24.04.1876), Галиябану (1885), Шәһәрбану (1886–1893), Миңлесылу (27.03.1894; анасы Фатыйма Сәйфетдин кызы). Габделхак кызы Галиябану 1902 елның ноябрендә авылдашы Әхмәтситдыйкъ Әхмәтша улы (22 яшь) белән никахлаша.

Габделшәфикъ Габделнәфикъ улы Габделгаффаров (30 яшь; икенче никах) 1882 елның 29 октябрендә Иске Катайның Миңлегаффар Сәеткол улының кызы Фәрхиҗиһан (18 яшь) белән кавыша, балалары Майкамәр (1880), Сәрвиҗиһан (1886), Зөлхиҗә (15.06.1893) туа. Габделшәфикъ кызы Майкамәр 1898 елның 17 мартында Килкабызның Миңлегәрәй Миңлекол (25 яшь) улы белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Миңлехан белән Әмирхан Габделнәфикъ уллары була. Икенче кызы Сәрвиҗиһан 1903 елның 12 гыйнварында Минзәлә өязе Күбәк авылының Хәйрелбәшир Габделҗәлил улы (27 яшь) белән никахлаша.

Миңлехан Габделнәфикъ улы Габделгаффаров балалары: Галихан (1887), Галия (1891–1905), Миңлениса (1894), Гыйлемхан (01.03.1895; анасы Ситдыйка Габделханнан Габделмәннан улының кызы), Габделкәбир (26.04.1898–1901; анасы Фатыйма Сәйфетдин кызы), Әминә (28.02.1902–1905; анасы Бибиситдыйка Габделханнан кызы). Миңлехан кызы Миңлениса (19 яшь) 1914 елның 15 гыйнварында авылдашы Мөхәммәтзакир Йосыф улы (25 яшь) белән никахлаша. Миңлехан Мөхәммәтнәфиковның (чыганакта шулай язылган; 65 яшь) ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, хатыны (55), килене һәм оныгы белән яши, 1917 елда 11,22 дисәтинә җире, 2 аты, 3 сыеры, 6 сарыгы була.

Галихан Миңлехан улы (27 яшь) 1914 елның 1 гыйнварында авылдашы Әхмәтша Тимергали улының кызы Маһисорур (халыкта Майсорур; 18 яшь) белән никахлаша, балалары Миргабитҗан (06.05.1917), Фәүзия (25.11.1925), Зәкәрия (1927) туа. Галихан Миңлеханов Ватан сугышы алдыннан хатыны Майсорур (1890), улы Зәкәрия (1927) белән яши. Галиханның улы Зәкәрия Миңлеханов – Ватан сугышы ветераны, Яңа Катай мәчетен салганда җиң сызганып эшләгән авылдашларымның берсе.

Әмирхан Габделнәфикъ улы балалары: Гөлҗиһан (18.01.1901–1904), Габдулла (02.02.1904; анасы Гөлҗамал Рәхмәтулла кызы), Хөсниҗамал (09.02.1907–1913), Мәһдия (29.06.1913), Габделһади (23.06.1915–1916, кызамыктан вафат).

Мөхәммәтсабир Габделнәфикъ улы Габделгаффаров (25 яшь) 1889 елның 24 ноябрендә авылдашы Фәхретдин Фәтхетдин улының кызы Бибивәдига (17 яшь) белән никахлаша, балалары Нәгыймә (07.02.1893–1893), Мөхәммәтназиф (29.08.1894), Габделхәбир (1897–1901; атасы Габделсабир дип язылган), Миңленәгыймә (02.01.1899), Миңлехәйдәр (13.01.1901), Хәйдәргали (21.01.1903), Мирзагали (26.01.1905), Хуҗагали (22.12.1906), Кифая (22.09.1909), Әбүнәгыйм (21.10.1911) туа. Сабир Нәфиков 1917 елда хатыны (48 яшь), биш улы һәм кызы белән яши, 29,67 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры, 3 сарыгы була. Сабир Ватан сугышы алды елларында мәрхүм була, бу вакытта йортында хатыны Закирә (1895), улы Әбүнәгыйм (1911), кызлары Сафура (1927), Салидә (1929), Зәмзәмия (1933) була. Аның улы Әбүнәгыйм сугыш яланында ятып кала (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

«Мин бабамның Сабир Нәфиков икәнен генә беләм. Аны раскулачить иткәннәрен әбием сөйләгән иде. Чак кына Себергә җибәрми калганнар: иртәгә китәсең, җыенып тор дип киткәннәр, нишләптер иртән килүче булмаган. Өйләрендә бернәрсә калдырмаганнар. Кайнатып юарга казанга салган бала киемнәре генә калды, дип сөйли торган иде әбием. Кем кашык китерә, кем чәшке китерде, ди иде. Шуңа ачуы зур булгандыр инде бабамның, үлгәнче колхозга кермәде, дип әйтә иде әбием. Тауда бакчасы да булган бабамның, җитмеш төп каен агачы утырткан булган, сугыш чорында кисеп бетергәннәр», дип язды китап авторына Сабирның оныгы Рәсүлә Абдуллина (Шәмсемөхәммәтова).

Шәфигулла Габделнәфикъ улы Колыевтан Мөхәммәтлатыйф (23.02.1890) билгеле. Шулай итеп, Габделгаффар Колыевның беренче улы Габделнәфикътан нәсел шактый тармаклана. Габделгаффарның икенче улы Габделбәшир дә варислар калдыра.

Габделбәшир Габделгаффар улы Колыев балалары: Габделгалләм (1854–05.08.1925), Миңлехәким (1959–06.07.1909), Шәмсебану (1867), Җиһанбану (1875), Гыйльмезадә (1885), Миңлегыйльмебану (1888–1889), Миңлесаимә (25.12.1889), Гөлбану (03.09.1895–1895), Әлмөхәммәт (01.01.1897–1901; анасы Гыйльмиҗиһан Хисаметдин кызы), Бибишәрифә (25.10.1900). Габделбәшир кызы Җиһанбану (18 яшь) 1893 елның 16 октябрендә авылдашы Галләметдин Мөхәммәтсадыйк улы Кучемов (25 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы



**Габделбәшир Габделгаффар улы тамга салган метрикә бите. 1900 ел**

Шәмсебану 1897 елның 10 июлендә Чуракайның Әхмәтхафиз Миңлешәриф улы (25 яшь) белән гаилә кора. Өченче кызы Миңлезадә 1899 елның 4 ноябрендә авылдашы Гыймадетдин Насретдин улы (атасы Насретдин Гайнетдин улы Арсланбәк нәселенә карый) белән кавыша. Дүртенче кызы Гыйльмезадә (17 яшь) 1902 елның 30 октябрендә авылдашы Шәйхеразый Шәймәрван улы (26 яшь) белән никахлаша. Бишенче кызы Миңлесаимә 1907 елның 11 гыйнварында Минзәлә өязе Әмәкәй олысы Сәет авылының Шірияздан Шәймәрдан улы (25 яшь) белән гаилә кора. Төпчек кызы Бибишәрифә 1917 елның 8 февралендә авылдашы Кәшфелголум Кашшафетдин улы (26 яшь) белән никахлаша, 21 февральдә аерылышалар («араларында өлфәт вә мәхәббәт юк сәбәпле»). Шул ук Бибишәрифә (19 яшь; икенче никах) 1917 елның 26 октябрендә авылдашы Мөхәммәткашшаф Габделлатыйф улы (24 яшь) белән кавыша.

Габделбәшир Габделгаффар улы (50 яшь; өченче никах) 1900 елның 25 февралендә Бөре өязе Манчар авылының Шиһабетдин Габдулла улының кызы Бибикамал (40 яшь; өченче никах) белән никахлаша. Никах Иске Катайның беренче мәхәлләсендә теркәлә, Габделбәшир метрикә битенә Арсланбәк нәселенә хас тамга сала (ике таяк та, уртага сызык).

Габделгалләм Габделбәшир улы балалары: Әхмәтлатыйф, Хәлимә (1876), Бибихәкимә (1878), Миңлехәким, Бибисәвия (1886), Бибимәдинә (02.02.1889; анасы Фатыйма Садретдин кызы), Бибимәрьям (1890), Миңлеҗиһан (10.12.1910), Мөхәммәтфатих (22.11.1912; анасы Шәмсеҗиһан Муллагали кызы), Мөхәммәтнасыйп (19.01.1914), Гайнелҗинан (22.10.1916). Габделгалләм кызы Хәлимә (17 яшь) 1893 елның 10 гыйнварында Иске Катайның Габделмөэмин Габделмалик улы (25 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Бибихәкимә 1897 елда Килкабызның Әхмәтзакир Әхмәтша улы Сәйфелмөлеков (25 яшь) белән кавыша. Өченче кызы Бибисәвия 1903 елда Иске Дөмәйнең Мәүләви Яхъя улы белән гаилә кора (әлеге Мәүләви совет чорында Катайда яшәүче Мәүләви Яхин буларак билгеле). Дүртенче кызы Бибимәрьям (17 яшь) 1906 елның 6 декабрендә авылдашы Ахунҗан Әхтәмҗан улы Күчемов (25 яшь) белән никахлаша. Төпчек кызы Гайнелҗинанның тууы турында метрикә мәгълүматын сорап,

кемнәредер 1966 һәм 2015 елларның июлендә архивка мөрәҗәгать иткәннәр, бу хакта аның исеме астына язылган.

Әхмәтлатыйф Габделгалләм улы балалары: Мәдинә (15.09.1901), Әхмәткәрам (04.11.1905; анасы Суфия), Таһирә (21.12.1908; атасы Габделлатыйф, анасы Ситдыйкасафа дип язылган), Рәхимә (24.12.1911; анасы Мөхәммәди кызы), Әхмәтфазыйл (12.07.1916; анасы Ситдыйкасафа Мөхәммәди кызы).

Мөхәммәтшәех Габделгалләм улы балалары: Мөхәммәтзаһит (09.01.1911), Миңлекәрим 25.10.1915; анасы Фәрхенуар Мөхәммәтгариф кызы). Шәех Галләмов 1929 елда «Яңа Тормыш» колхозына башлап керүчеләрнең берсе була.

Миңлехәким Габделбәшир улы Габделгаффаров (Колыев) балалары: Миңлегали (30.11.1889), Миңлеәхмәт (1892–1893), Миңлехуҗагали (10.02.1894; анасы Фәрхиҗиһан Мөхәммәтҗәләл кызы), Миңлемөхәммәт (02.06.1898–1901), Шәмсеҗиһан (20.09.1900; анасы Фәрхиҗиһан Мөхәммәтҗәлал кызы), Сәрвиҗиһан (07.01.1903), Хөсниҗамал (1904–1910), Фәхерҗиһан (19.04.1905), Миңлегайса (23.09.1907), Гөлҗиһан (15.03.1909).

Миңлегали Миңлехәким улы (23 яшь) 1912 елда авылдашы Шәйгәрәй Тимербулат улының кызы Мәүҗүдә (17 яшь) белән никахлаша, балалары Мөшәррәфә (23.07.1916; совет чорында загстан туу турында белешмә ала) туа.

Габделгаффар Колыевның өченче улы Габделҗаббар иде. Габделҗаббар Габделгаффар улы балалары: Габделвахит (1859–05.11.1915), Галихәйдәр (11.10.1877; анасы Бәдриҗамал), Фәрхиҗамал (20.12.1877; анасы Шәрифҗамал), Миңлегабдерәшит (10.06.1880; анасы Шәрифҗамал), Шәмсеҗамал (18.08.1900; анасы Бибикафия Нигъмәтулла кызы), Миңлеҗәгъфәр (20.02.1901–1904; анасы Бибикамал Җамалетдин кызы). Габделҗаббар кызы Хушҗамал (19 яшь) 1893 елның 19 ноябрендә Иске Катайның Нәбиулла Кәлимулла улы (25 яшь) белән никахлаша.

Габделвахит Габделҗаббар улы Габделгаффаров балалары: Мәмдуха (1894), Бибисәрия (15.10.1895; анасы Мәрхәбә Мөхәммәтхафиз Габделкаһир улының кызы), Габделсаттар (халыкта Гапсаттар; 1897), Асия (04.01.1898), Габделмәҗит (04.10.1900; анасы Бибимәрхәбә Мөхәммәтхафиз кызы). Габделвахит кызы Мәмдуха 1911 елда Иске Катайның Шәйхерам Шәймөхәммәт улы (27 яшь) белән никахлаша. Гапсаттар Вахитовны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында анасы (56 яшь), сеңлесе (19) һәм энесе (17) кала. 1917 елда хуҗалыгында 17,20 дисәтинә җире, 4 аты, 3 кәҗәсе була. Гапсаттарның улы Закуан Вахитов (1920–1980) – Ватан сугышы ветераны. Кече сержант, разведчик була, «Кызыл Йолдыз» ордены (10.11.1944), «Батырлык өчен» (26.08.1944), «Ленинград оборонасы өчен» (12.1942) медальләре белән бүләкләнә. Закуан Иске Катайның Габдулла Галиев кызы Нәкыя белән никахлаша, балалары Гөлнәзирә, Рәсимә туа.

Закуан абый сугышка чаклы – авыл советы секретаре, сугыштан кайткач «избач» була. Аның вазифасы «избач» дип аталганын Сайка апа Исмәгыйлева (Сәпәева) (1943 елгы) сөйләде. «Аннан укырга китаплар ала идек, эчтәлеген дә

сөйләттерә иде», дип искә алды ул. Егерменче еллардан бирле «изба-читальня», соңрак китапханә хезмәткәрен «избач» дип әйтү гадәте сакланган була, алтмышынчы елларда гына «избач»ны «китапханәче» сүзе алыштыра. Закуан абый Катайда соңгы «избач» була, бу вазифасын ул Катайга колхоз рәисе булып Әбүгали Шәнгәрәев килгәнче башкара. Рәиснең хатыны Венерага эш кирәк булгач, китапханәчелек аңа күчә. Ул да «декрет»ка киткәч, китапханәче вазифасын Әлфия апа Хәйдәрова башкара башлый.

Галихәйдәр Габделҗаббар улы балалары (өченче мәхәллә): игезәкләр Әмирҗан (30.08.1904) белән Сабирҗан (30.08.1904–1904; анасы Факия Мөхәммәтхафиз кызы), Шәйхәйдәр (25.06.1906), Шәехзаман (1908–1915), Гакифә (19.07.1910), Миңлекәшифә (10.07.1912–1912), Рәхимҗан (10.08.1913).

Габдерәшит Габделҗаббар улы белән Мөшәррәфә Мөхәммәтзакир кызы балалары: Габделхаликъ (1910–1910), Габделхәбир (11.04.1911), Габдерәкыйп (15.04.1913), Габделгазиз (10.04.1915–1915).

Габделгаффар Колыевның энесе Хөсрәүбәшир (1805) иде. Хөсрәүбәшир уллары Хөснетдин (1833–1850) белән Сиражетдин (1839) була.

Сиражетдин Хөсрәүбәшир улы балалары: Миңлеҗиһан, Гыймадетдин (08.06.1883). Сиражетдин кызы Миңлеҗиһан 1890 елның 26 ноябрендә авылдашы Габделзаһир Габделихсан улы (25 яшь; атасы Габделихсан Габдерәхим улы) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары булып Габделҗаббар Габделгаффар улы белән Габделхак Габделнәфикъ улы теркәлгән.

Шулай итеп, Арсланбәктән һәм аның ерак нәселдәшләреннән киткән буыннар бүгенге көндә бик күп хуҗалыклар тәшкил итә, бу нәсел кешеләре кайбер башка авылларда да күзәтелә.

# IX бүлек.
# Арсланбәкнең ерак нәселдәшләре

Бү бүлектә сүз барачак катайлылар Арсланбәкнең ерак нәселдәшләре булып торалар. Тик нигәдер нәселләрне азмы-күпме белгән аксакаллы авылдашларым аларның бер төркемен аерым нәсел итеп карый иде. Нәсел тамгалары буыннан-буынга күчү совет чорында тукталгач, аларны белүче дә, моңа әһәмият бирүче дә юк иде кебек. Әнә шул тамгаларны гел күз алдында тотып, анализлап, бу бүлектә сүз барачак авылдашларымның Арсланбәкнең ерак нәселдәшләре булуына инандым. Чөнки алар метрикә язуларында вәли вәкил һәм ризалык шаһиты буларак бераз аерылган үз тамгаларын да, Арсланбәк Якупов варисларына хас тамгаларны да кулланганнар. Баштарак бер-берсенең тамгасын ялгыш салмаганнармы дип уйлый идем, әмма бу өлкәдә белемебезме кулланып һәм тамгаларның төп элементы тәңгәл килүеннән чыгып (бу хакта алдарак тулырак әйтербез), юк, ялгышмаганнар дигән нәтиҗә ясадым. Тамгаларның күпмедер аермалыгын, нәсел традициясе-истәлеге булуын һәм мәсьәләнең фәнни яктан әһәмиятен истә тотып, Арсланбәкнең ерак нәселдәшләреннән торган Әхмәт (Этҗыймас) һәм кайбер башка (Дәүләт) төркемен аерым бүлектә карарга булдым. Тамгалар өлкәсендә безнең күзәтүләргә-анализларга башка галимнәр дә игътибар итәр, моңа багышлап фәнни хезмәтләр язганда кулланырлар, дигән уй да моңа этәрде. Бәлки, бу китаптагы нәсел тамгалары буенча күзәтүләрне туплап, үземә дә аерым фәнни хезмәт язарга туры килер.

Табылдыклар дип аталган төркемгә керә, дип әйттеләр картлар Этҗыймас варисларын аерым нәсел санап. «Эт җыймаган, ягъни эт тә ашамаган, ат улагы астында ятканда табып алынган ул бала», дип сөйләгәннәр иде. Этҗыймас дигән исемне шуны күз алдында тотып кушканнар, имеш. Табылдык дип аталганнар турында сүз чыкса, ни өчендер, нәселмени алар, дип әйтәләр (моның белән һич кенә дә килешеп булмый, әлбәттә).

Этҗыймас исеменең килеп чыгышына карата менә шундый риваять, дип әйтик. Әмма ничек инде кешегә шул мәгънәдән чыгып исемен Этҗыймас дип кушсыннар, ди. Моның белән килешәсем килмәде, архив мәгълүматы тупланган дәфтәремне алып, тагын бер тапкыр карап чыгасы иттем. 1816 елгы ревизия исемлегендә 43 нче сан астында Этҗыймас Ишбулдин теркәлгән бит тәки. Анда русчалатып «Адзимяс» дип язылган, димәк, татарчасы «Этҗыймас» була инде. Бу юллар күптән язылып, китапны төгәлләп килгәндә, башка авыллар исемлекләрен карап чыгарга булдым. Ахыр чиктә бу шактый таралган борынгы төрки-татар исем (борынгы бабаларыбыз йөрткән исемнәрне белмәү

оят түгелме соң әле?) булып чыкты, мәсәлән, Тыпый авылының 1859 елгы исемлегендә «типтәр» Ибраһим Этҗыймасов күрсәтелә. Түбән Бишенденең 1816 елгы исемлегендә 45 нче булып 24 яшьлек Этҗыймас Нарышев (документта «Адзимал Нарушев») теркәлгән[1]. Димәк, риваять бер нәрсә, исем икенче нәрсә. Этҗыймас исеменең килеп чыгышын аксакаллы авылдашларым фараз кылып кына әйткән булып чыга. Бу һәм башка ят тоелган борынгы төрки-татар исемнәренең чын мәгънәсен кайчан да булса белербезме?

Ни гаҗәп, Катай авылы метрикәләрендә Этҗыймас исеме бер тапкыр да телгә алынмый. Барлык метрикәләрдә Этҗыймас урынына гел Әхмәт дип языльп килә. Билгеле, Әхмәт матур яңгырашлы исем, муллалар шуннан чыгып Этҗыймасны Әхмәткә үзгәрткәннәр, күрәмсең. Матур яңгырашлы исемнәр эзләп, гарәп-фарсыдан алынганнарын күбрәк әйләнешкә кертеп, хәтта үзләренчә өстен күреп, тарихыбыздан борынгы төрки-татар исемнәрен кысрыклап чыгаручылар шул дин әһелләре түгелме? Шул ук Этҗыймасның атасы – Ишбулды, Ишбулдыныкы Дәүәти булган. Ишбулды да, Дәүәти дә – борынгы төрки-татар исемнәр, татар тарихына төс бирүче, безнең милли үзенчәлекләребезне чагылдыручы, кадерле, күңелгә якын исемнәр. Ишбулды дип, ярдәмче, юлдаш ир бала булды мәгънәсендә кушкан ерак бабаларыбыз. Дәүәти дип нинди мәгънәдә кушканнар (әтисе кебек дәү, исән-имин үссен дигән теләктән түгелме?), беләсе иде боларның барысын да. Моны белер өчен башка төрки халыкларның да тарихына күз салырга кирәк, күп фәнни әдәбият укырга, эзләнергә, махсус шөгыльләнергә, зиһенне максатчан эшкә җигәргә кирәк.

Ишбулды Дәүәти улы бер нәселдәше белән (аның турында да сүз бу бүлектә барачак) 1753 елгы документта үзенең нәсел тамгасын салган. Бу китапта аерым бүлектә сүз барган Азаматның да атасы шундый ук исемле булганын искә алсак, Дәүәти борынгы бабаларыбыз үз иткән-яраткан исемнәрнең берсе, дип әйтергә була.



**1753 елгы документ фрагментында Ишбулды Дәүәти улы тамгасы (өч таяк, аркылыга сызык)**

Этҗыймас Ишбулдинның (1779–1830) 1816 елда Үмербай (метрикәләрдә Гомербай дип тә языла; 1807), Тимергали (1811–1817), Корбангали (1817), Мөхәммәтгали (1824) исемле уллары була. Энесе Тимергалинең (1791) ир балалары булмый, 1859 елда исән-сау, 68 яшьтә була.

Метрикәләрдә Этҗыймас урынына Әхмәт язылган икән, без дә алга таба шулай язарга булдык, шуңа Этҗыймас исеменең башкача телгә алынмавын

[1] БҮДТА, И-138 ф., 2 тасв., 156 сакл. бер., 12 б.а.

аңлап кабул итәрсез. Әхмәтнең (Этҗыймасның) улларын белдек, кемнәр икән буыннан буынга оныклары, шуларның бүгенге варислары?

Үмербай Әхмәт улы балалары: Мөхәммәтҗан (1832), Мөхәммәтсадыйк (1834–20.01.1894; беренче хатыныннан), Муллаян (1856; икенче хатыныннан).

Мөхәммәтҗан Үмербай улы балалары: Шаһимөхәммәт (1859), Ахунҗан (1869), Әхтәмҗан (1874), Мәхмүтҗан (1880), Хәерниса. Мөхәммәтҗан кызы Хәерниса (икенче никах) 1906 елның гыйнварында Иске Дөмәйнең Госман Мөхәммәтшәриф улы (дүртенче никах) белән кавыша.

Ахунҗан Мөхәммәтҗан улы Үмербаев балалары: Мәдхиҗамал (1897), Хәсәнҗамал (16.06.1901; анасы Нәфисҗамал Мөхәммәтәмин кызы), Әмирҗан (17.06.1904), Гарифҗан (03.01.1908; беренче мәхәллә), Хөсниҗиһан (01.10.1911), Өммелкамал (06.08.1913). Ахунҗан кызы Мәдхиҗамал 1915 елның декабрендә Туктаголның Әгъләм Миргаләветдин улы (31 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Ахунҗан Мөхәммәтҗанов 1917 елда хатыны (35 яшь), ике улы һәм өч кызы белән яши, 7,85 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була. Гарифҗан (1908) »Үткәннәрен бел Катайның» китабында сугыштан исән кайтканнар исемлегендә Ахунов фамилиясе белән бирелде, туган елы куелмаган иде, менә бу китап өстендә эшләгәндә кайчан дөньяга килгәне төгәл ачыкланды.

Әхтәмҗан Мөхәммәтҗан улы Үмербаев 1894 елның 3 гыйнварында авылдашы Габделгалим Миңлегол улы Нөрмәтов кызы Бибирабига (17 яшь) белән кавыша, балалары Галимҗан (30.09.1900), Сабирҗан (28.01.1902–1905), Миңлесәрия (11.09.1906), Миңлевәдига (21.12.1908), Галимҗан (1910–1910) туа. Әхтәмҗан Мөхәммәтҗанов 1917 елда хатыны, улы һәм ике кызы белән яши, 8,32 дисәтинә җире, аты, сыеры була.

Мәхмүтҗан Мөхәммәтҗан улы (23 яшь) 1905 елның 6 гыйнварында ерак нәселдәше Әһлиулла Гыйззәтулла улы Һибәтуллин кызы Гыйльмебану (17 яшь) белән никахлаша. Егетнең бертуган агасы Әхтәмҗан Мөхәммәтҗан улы вәкил (нәсел тамгасы өч таяк) була. Бу никах 1906 елда таркала.

Мәхмүтҗан Мөхәммәтҗан улы балалары (беренче мәхәллә): Мансурҗан (12.02.1906; анасы Гыйльмебану Әһлиулла кызы), Миңлешәрифә (10.02.1907; анасы Гыйльмезадә Мөхәммәтлатыйф кызы), Сабирҗан (1910), Закирә (23.01.1915; анасы Гыйльмезадә Мөхәммәтлатыйф кызы). Мәхмүтҗан Мөхәммәтҗановны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (28 яшь), улы (7) һәм өч кызы кала, 9,05 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була. Ватан сугышы алдыннан Мәхмүтҗан Мөхәммәтҗанов (1880) гаиләсендә хатыны Фәхрниса (1880), уллары Габит (1920, сугышка алалар), Миргазиян (1924), Мәгънәви (1927), кызы Мәснүнә (1930) була.

Шул ук Ватан сугышы алды елларына караган исемлектә Сабирҗан Мәхмүтҗанов (1910), аның хатыны Бибиҗиһан (1913), кызлары Бибигалимә (1939), Вәзига (1941) теркәлгән. Сабирҗан Мәхмүтҗан улы Мөхәммәтҗанов (1910) 1941 елның 14 июлендә Ватан сугышына китә һәм 1942 елда хәбәрсез

югала (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән). Галимә Сабирҗан кызы Мәхмүтҗанова – хөрмәтле авылдашыбыз, танылган терлекче, ике тапкыр Ленин ордены кавалеры, РСФСР Югары Советының VII чакырылыш депутаты.

Үмербай Әхмәт улының кызы Хәсбиҗиһан (18 яшь) 1889 елның 25 октябрендә Иске Дөмәйнең Бәдретдин Габделгалим улы (30 яшь; икенче никах) белән кавыша. Әлеге никах язуында кызның вәли вәкиле бертуган агасы Мөхәммәтҗан Үмербай улы һәм ризалык шаһитлары Мөхәммәтсадыйк белән Муллаян Үмербай уллары бу нәселгә хас өч яисә дүрт таяклы тамганы салганнар.

Әхмәтнең өченче улы Корбангали иде. Корбангали Әхмәт улы балалары: Мөхәммәтшәриф (1845–28.08.1912), Мөхәммәтситдыйкъ (1868–12.03.1909), Фәрхизиядә (1876). Корбангали кызы Фәрхизиядә (18 яшь) 1894 елның 9 декабрендә Иске Катайның Нургали Габделнәфикъ улы (25 яшь; Юлдаш нәселеннән) белән никахлаша.

Мөхәммәтшәриф Корбангали улы Әхмәтов балалары: Арслангали (1870), Хаҗиәхмәт. Арслангали тол калгач, 1900 елның 24 сентябрендә Иске Катайның Гыйльметдин Тәхаутдин улының кызы Нәгыймә (18 яшь) белән никахлаша. Егетнең ризалык шаһитлары Сәлимгәрәй белән Әхмәтгәрәй Мөхәммәтвәли уллары (Арсланбәк нәселеннән) була. Арслангали балалары: Тимергали (1904–1912), Миңлерәйфә (12.03.1917; анасы Нәгыймә).

Мөхәммәтситдыйкъ Корбангали улы Әхмәтов балалары: Нәгыймә (15.10.1894), Мөхәммәтхәниф (04.12.1895–1914; анасы Бибизәкия Тәминдар Габделгани улының кызы), Мөхәммәтназиф (19.10.1897), Фәүзия (03.01.1900), Миңлесайра (13.03.1901), Мөхәммәтсалих (05.04.1903), Хәмдия (04.10.1905), Мөхәммәткәшиф (1908–1909).

Әхмәтнең төпчек улы Мөхәммәтгалидән дә нәсел дәвам итә. Мөхәммәтгали Әхмәт улы балалары: Мөхәммәтәмин (1846–12.07.1910), Хөсниҗиһан (1858), Мөхәммәтхафиз. Мөхәммәтгали кызы Хөсниҗиһан (17 яшь) 1875 елның 1 декабрендә Корычның Габделмәннан Габделкаһир улы (20 яшь; атасы Габделкаһир Габделхаликъ улы) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле – атасы Мөхәммәтгали Әхмәт улы, ризалык шаһитлары туганнары Мөхәммәтәмин белән Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтгали уллары (алар өч таяклы нәсел тамгасын салганнар) була.

Мөхәммәтәмин Мөхәммәтгали улы балалары: Мөхәммәтхафиз (1866), Камилә (1868–1898), Мөхәммәтнәби (1870), Фәхерҗиһан (26.07.1880; анасы Гыйльмиҗиһан), Шәмсезиядә (1888). Мөхәммәтәмин кызы Фәхерҗиһан (17 яшь) 1901 елның феврalendә Сеңрәннең Һибәтулла Галиулла улы (23 яшь) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтнәби Мөхәммәтәмин улы белән Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтгали улы була. Икенче кызы Шәмсезиядә 1905 елның 15 декабрендә Корычның Шәйхеразый Гыйндулла улы (22 яшь) белән никахлаша.

Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтәмин улы (50 яшь; өченче никах) 1916 елның 3 декабрендә авылдашы Җиһангир мулла Габделгани улының кызы Бибиәсма (30 яшь; дүртенче никах) белән никахлаша. Аның ризалык шаһитлары Ахунҗан Мөхәммәтҗан улы белән Галләметдин Саяфетдин улы була (аларның һәм Мөхәммәтхафизның тамгасы «Н» хәрефен хәтерләтә). Шул ук Мөхәммәтхафизның 1916 елның 26 гыйнварында кызы Сәкинә (анасы Фәрхиҗамал Гыйндулла кызы) туган, метрикәнең шул битенә Сәкинәнең 1936 елның 2 июнендә загстан туу турында белешмә алуы турында язылган.



**Өч урында «Н» хәрефен хәтерләткән бер нәсел кешеләре тамгалары**

Мөхәммәтнәби Мөхәммәтәмин улы Мөхәммәтгалиев балалары (беренче мәхәллә): Миңлеәхмәт (15.05.1898–1917; анасы Гыйльмикамал Мөхәммәтәмин кызы), Әбүнәгыйм (06.12.1900; анасы Сәрвиҗиһан Галиулла кызы), Мөхәммәтфазыйл (12.07.1903), Миңлесәрвәрия (30.10.1905), Әсхия (1910–1917), Галиәхмәт (1911–1917), Миңлекамил (03.08.1913), Рәкыя (26.11.1915). Мөхәммәтнәби Мөхәммәтәминовның олы улын (21 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (35 яшь), өч улы һәм ике кызы белән яши, 17,12 дисәтинә җире, 4 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була. Сугыш алдыннан Нәби Әминов (1870) гаиләсендә хатыны Хәлимә (1900), кызлары Гөллидәм (1921), Мостафидә (1925), Мөҗәһидә (1929), Гөлүдә (1939), улы Мәкки (1934) була.

Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтгали улы Әхмәтов балалары (беренче мәхәллә): Әхмәтзакир (1888–1889), Мәликә (1889), Мөхәммәтхарис (13.02.1893; анасы Мәгъсүмә), Мөхәммәтзакир (06.12.1895; анасы Мәгъсуфә Равил кызы), Мөхәммәтфатих (28.10.1898), Мөхәммәтнасыйп (14.03.1901; анасы Мәгъсуфә Равил кызы), Мөгаллимә (12.10.1907; анасы Фәрхиҗамал Гыйндулла кызы), Миңленәгыймә (30.08.1910), Мөхәммәтнасыйх (29.03.1913–1915). Мөхәммәтхафиз кызы Мәликә (17 яшь) 1906 елның 6 мартында Мөхәммәтхафиз Габделих-

сан улы (25 яшь) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтнәби Мөхәммәтәмин улы белән энесе Мөхәммәтхарис Мөхәммәтхафиз улы була. Хафиз Мөхәммәтовның (50 яшь) олы улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (30), ике улы һәм өч кызы белән яши, 1,55 дисәтинә җире, 2 аты, кәҗәсе була.

Мөхәммәтхарис Мөхәммәтхафиз улы (21 яшь) 1914 елның 14 мартында Иске Дөмәйнең Тәминдар Габделгани улының кызы Мөзәккия (40 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Кияүнең ризалык шаһитлары Мөхәммәтнәби Мөхәммәтәмин улы белән Хәбибулла Шаһидулла улы була. Катай тарихында ир-атның үзеннән ике тапкыр олы хатынга өйләнүен беренче тапкыр бу мисалда күрәбез.

Фатих Хафизов (1898) Ватан сугышы алдыннан хатыны Гыйльминиса (1902), кызлары Мөхәссәнә (1923), Мокатдәсә (1926), Нәгыймә (1931), Мөслимә (1942), уллары Кави (1928), Вагиз (1938) белән яши, 1944 елның 3 апрелендә сугышта һәлак була.

Зимфира Исламова мәгълүматы буенча, бабасы Мөхәммәтнасыйп Хафизов (1901–1988) Гөлчирә Ситдыйкъ кызы белән гаилә кора, балалары Гөлбостан (1927), Насыйх (1929–1984), Фәниз (1932), Ләйлә (1939), Сәлимә, Рәзинә дөньяга килә. Насыйх белән Рәхимә (Тыпыйның Шабаев Хәйдәр кызы, 1934–2013) балалары: Рузилә (1954), Равил (1956–1983), Зимфира (1958), Нәсимә (1960), Раушания (1964). Зимфира һәм Марат Исламовлар балалары: Айгөл (1980) белән Әлфия (1983). Зимфира Исламова – Чаллыда яшәп итеп иҗат итүче авылдашыбыз, китаплар авторы, язучылар берлеге әгъзасы.

Муллаян Үмербай улы (25 яшь) 1881 елның 25 декабрендә Иске Катайның Хупҗамал Мөхәммәткәрим кызы (22 яшь; Юлдаш нәселе) белән никахлаша. Муллаян балалары: Нурлыгаян (11.06.1883), Хөрриҗиная (1892), Кәшфелмәган (02.08.1893; атасы Әхмәтов фамилиясе белән язылган, анасы Маһинур Ибраһим кызы). Муллаян кызы Хөрриҗиная (17 яшь) 1909 елның 17 ноябрендә Туктаголның Әгъләм Миргаләүтдин улы белән никахлашканда, Ахунҗан белән Мәхмүтҗан Мөхәммәтҗан уллары кызның ризалык шаһитлары булып, өч таяктан торган тамгаларын салалар. Муллаян 1898 елның 15 апрелендә мәрхүм була, метрикәдә атасы Гомербай Әхмәт улы дип язылган.

Нурлыгаян Муллаян улы 1905 елның декабрендә авылдашы Габделкадыйр Йөзәй улының кызы Миңлебану (17 яшь) белән никахлаша. Егетнең вәли вәкиле – кардәше Ахунҗан Мөхәммәтҗан улы, ризалык шаһитлары Мөхәммәтситдыйкъ Корбангали улы белән Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтгали улы була. Нурлыгаян балалары: Фәтхелбәян (03.09.1907–1907), Фәгыйлә (07.01.1910), Фәтхелбәян (халык телендә Фаткыл; 15.08.1911; анасы Өммегөлсем Яхъя кызы), Нәҗия (11.03.1914). Нурлыгаян Муллаяновны (33 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (23), улы, ике кызы, энесе һәм килене кала. Хуҗалыгында 15,75 дисәтинә җире, 4 аты, сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче яллаган. Ватан сугышы башланганда Нурлыгаян Муллаянов хатыны

Мәсхиҗамал (1878), улы Фаткыл (1911), кызлары Рәхимә (1913) һәм Вәзимә (1921) белән яши. Фәтхелбәян (документта Фаткыл) Нурлыгаянов 1942 елның апрелендә сугышта хәбәрсез югала (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Кәшфелмәган Муллаян улы белән (22 яшь) 1916 елның 12 октябрендә авылдашы Галимә Әхмәтвәли Габделмәннаф улы Габдрахмановның кызы белән никахлаша.



**1753 елгы документ фрагментында Яхшый Сөеш улы тамгасы (өч таяк, аркылыга сызык)**

**Әхмәтнең (Этҗыймасның) нәселдәше – Дәүләт белән Яхшый Сөеш уллары.** Алдарак Ишбулды Дәүәти улы нәсел тамгасы бирелгән 1753 елгы документ турында сүз барган иде. Шул ук документта нәкъ шундый ук тамганы Дәүләт белән Яхшый Сөеш уллары да салганнар. Бер үк тамырдан булганнарына ишарәләгәндәй, Дәүләт Сөеш улы тармагына караган кешеләр 1816 һәм аннан соңгы еллар исемлекләрендә Әхмәт (Этҗыймас) варислары һәм оныклары белән бер үк урында, алар алдыннанрак бирелә. 1877 елның 17 мартына караган никах язуында Габделвахит Габделвафи улы салган нәсел тамгасы Этҗыймасларныкына хас (өч таяк, аркылыга сызык). Арсланбәк нәселенә хас тамга (ике таяк, аркылыга сызык) куючылар күбрәк күзәтелә (бер мисал: 1911 елның 11 октябрендә өченче мәхәлләдә Мөхәммәтшакир Мөхәммәтзариф улы Галикәев белән Әфләтун Габделлатыйф улы тамгасы). Бары бер очракта гына шул ук Яңа Катайның өченче мәхәлләсендә 1911 елның 26 февралендәге никах язуында Әхтәмгали белән Әхмәтвәли Габделмәннаф уллары салган тамга Күчем нәселенеке белән тәңгәл килә (бу тамганы алар түгел, мулла үзе салгандыр, мөгаен). Шулай итеп, Арсланбәк һәм аның ерак нәселдәшләре, Дәүәти (аның оныгы Әхмәт (Этҗыймас) дип әйттек) һәм Сөеш бер үк тамырдан чыкканнар, аларның тамгалары арасында принципиаль аерма юк, ике таякмы-өч таякмы, кем ничек теләгән, шулай салган, бу хата саналмаган.

Алдарак Дәүләт Сөеш улы 1753 елгы документта телгә алына дип әйттек. Дәүләтнең ир балалары Габдерәшит (Габдери; 1756–1831), Вәлиша (1771) һәм Габдрахман (1784) 1816 елгы документта теркәлгән.

Габдерәшит Дәүләт улы ир балалары: Хәким (1786), Габделвафи (1798–1831). Хәкимнең улы Габделнәфикъ (1813–1818) була. Габделвафи Габдерәшит улы ир балалары: Габделвахит (1822) һәм Габделлатыйф (1829–02.06.1898).

Габделвахит Габделвафи улы балалары: Шәйхәйдәр (1859), Маһишәрифә (1865), Габдрахман (1867), Хәбибрахман (1869), Маһитап (1877). Габделвахит кызы Маһишәрифә (18 яшь) 1883 елда авылдашы Нурислам Шәйхелислам



**1883 елгы документта Әфләтун Габделлатыйф улы тамгасы («Н» хәрефе кебек)**

улы белән гаилә кора. Кызның ризалык шаһиты булып Әфләтун Габделлатыйф улы нәсел тамгасын куя. Әлеге тамга алдагы бүлектә сүз барган Арсланбәк варисларыныкы белән тәңгәл килә. Габделвахитның икенче кызы Маһитап (18 яшь) 1895 елның 9 ноябрендә Килкабызның Мөхәммәтхафиз Әрдашир улы (40 яшь; өченче никах) белән никахлаша. Кыз вәкиле – бертуган агасы Габдрахман Габделвахит улы, кияүнеке авылдашы Гыйлаҗетдин Ражетдин улы була. Кызның ризалык шаһитлары – Мөхәммәтдин Габделлатыйф улы белән Мөхәммәтсафа Габделсаттар улы, кияүнеке Килкабыздан Җәләлетдин мөәзин Шәрәфетдин улы белән Хәйрулла Хәбибулла улы була.

Габдрахман Габделвахит улы Вафиев балалары: Кәшфелмәган (1891–1894), Габдерәхим (17.11.1897; анасы Фәрхисорур Габделгазиз кызы), Габделхәлим (14.08.1901), Фәтхия (05.08.1905; анасы Мәгъфүрә Мослахетдин кызы), Габделгалим (18.02.1906; анасы Фәрхисорур), игезәкләр Хәдичә (13.03.1908; анасы Хөснеруй) белән Гайшә (13.03.1908), Фатыйма (20.09.1912; анасы Хөснеруй Әхмәтша кызы). Габдрахман Вахитов 1917 елда хатыны (36 яшь), дүрт улы һәм кызы белән яши, 6,85 дисәтинә җире, 3 аты, сыеры һәм башка маллары, җилгәргече була.

Хәбибрахман Габделвахит улы Габделвафиев (26 яшь) 1895 елның 25 октябрендә ерак нәселдәше Габделгалим Тимергали улы Габидуллов кызы Гыйльмиҗиһан (18 яшь) белән никахлаша. Кияүнең вәкиле бертуган агасы Габдрахман Габделвахит улы була. Хәбибрахман балалары (өченче мәхәллә): Гайнелҗиһан (1897), Хәлилулла (12.02.1899), Хәбибулла (02.07.1900–1915), Миңлежиһан (05.08.1903), Габидулла (06.08.1905), Латыйфа (11.02.1908), Нигъмәтулла (30.08.1910; анасы Гыйльмиҗиһан Габделгалим кызы), Кәлимулла (02.08.1913), Габдулла (20.06.1916–1916). Хәбибрахман кызы Гайнелҗиһан 1915 елда нәселдәше Әхмәтлатыйф Әхмәтситдыйкъ улы (28 яшь) белән кавыша. Хәлилулла Хәбибрахман улы 1925 елның 5 февралендә авылдашы Зәйнәп Җәләлетдин кызы белән никахлаша.

Габделлатыйф Габделвафи улы балалары: Әфләтун (1855), Шәйсолтан (1859), Шәмсекамал (1859), Гыйльмикамал (1867), Гатаулла (1873–1908), Вәсфикамал (1875), Төхфәтулла. Габделлатыйф кызы Гыйльмикамал авылдашы Сәлахетдин мулла Хөснетдин улы белән никахлаша. Икенче кызы Шәмсекамал (18 яшь) 1877 елның 17 мартында Корычның Сәлимгәрәй Мөхәммәдьяр

улы (30 яшь; икенче никах) белән гаиләкора. Кызның ризалык шаһитлары булып Габделваһит Габделвафи улы белән Әфләтун Габделлатыйф улы нәсел тамгасын салганнар. Габделлатыйфның төпчек кызы Вәсфикамал (17 яшь) 1893 елның 14 гыйнварында авылдашы Габделкаюм Габделнасыйр улы Күчемов белән никахлаша. Бу



**1877 елгы документта Габделваһит Габделвафи улы белән Әфләтун Габделлатыйф улы тамгалары**

һәм тагын бер никахы таркалгач, Вәсфикамал (22 яшь; өченче никах) 1899 елда Рәҗәпнең Корбангали Габидулла улына (45 яшь; өченче никах) кияүгә чыга. Кызның вәли вәкиле – бертуган агасы Әфләтун Габделлатыйф улы, ризалык шаһитлары Әхмәтша Тимергали улы белән Төхфәтулла Габделлатыйф улы була.

Әфләтун Габделлатыйф улы Габделвафиев балалары: Мирсалих (01.09.1876; анасы Хөббениса), Бибифакия (29.09.1880; анасы Бибизәйнәп), Бибизакирә (08.01.1883), Габдулла (19.06.1889; анасы Зәйнәп Мохтарулла кызы), Зиннәтулла (1891), Гыйниятулла (1892), Бибибания (05.07.1895; анасы Бибизәйнәп Мохтарулла Хәлилулла кызы). Әфләтун кызы Бибизакирә 1904 елның 16 гыйнварында Килкабызның Габделгали Әхмәтгали улы (25 яшь) белән никахлаша. Әфләтунның ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (55 яшь) һәм килене (25 яшь) белән яши, 12,79 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була.

Габдулла Әфләтун улының кызы Гыйльмиҗамал (08.07.1915; анасы Шәмсеҗиһан Мөхәммәтхарис кызы) билгеле. Зиннәтулла Әфләтун улы балалары: Кәрамәтулла (15.11.1912; анасы Фәхрикамал Габдерәхим кызы), Сәгадәтулла (07.09.1915). Зиннәтулла Әфләтунов 1917 елда хатыны (25 яшь) һәм ике улы белән яши, 1,53 дисәтинә җире, аты һәм сыеры була.

Гыйниятулла Әфләтунов (1892) турында мәгълүмат Катай авыл советы кенәгәсендә бирелә. Ул Ватан сугышына киткән, хатыны Газидә (1894), кызлары Галия (1925), Зәйтүнә (1930), Нәкыя (1931), Рюзә (1937), уллары Мөдәррис (1927), Гыйбадулла (1933) калган.

Төхфәтулла Габделлатыйф улы Габделвафиев балалары (өченче мәхәллә): Шакирҗан (15.08.1894; анасы Кафия типтәр Габделхаҗи Габделгани улының кызы), Галимҗан (29.07.1897), Миңлерәкига (03.04.1901), Шәрхемулла (15.08.1904), Шәрифҗан (29.08.1910–1912; анасы Кафия Хаҗи кызы).

Гатаулла Габделлатыйф улы Вафиев балалары: Бибикәшифә (01.08.1893–1898; анасы Бибизакирә Фәрхетдин кызы), Габидулла (26.12.1901–1905), Сә-


О БРАКОСОЧЕТАВШИХСЯ ВЪ 1889 ГОДУ.

**Иң өстә Мөхәммәтшәриф Галикәй улы тамгасы, аста хаталы Баһманша тамгасы**

мигулла (10.09.1905). Сәмигулланың улы Рәис Гатауллиннан (1930) Илсөяр (1960) һәм аның туганнары дөньяга килгән.

Вәлиша Дәүләт улының варисы Галикәй (1798) була. 1834 елда Вәлиша хатыннары: Сәхибә (1771) һәм Гафия (1814). Галикәй балалары: Хәлилулла (1819), Галиулла (метрикәдә Гайнулла; 1822), Мөхәммәтшәриф (1830–04.03.1897), Мөхәммәтзариф (1835). Галикәйнең бер кызы (исеме ачык язылмаган) 1875 елның 1 мартында Минзәлә өязе Әгъбәс авылының Мөхәммәтгариф Фәтхулла улы (19 яшь; атасы Фәтхулла Габделваһап улы) белән никахлаша.

Хәлилулла Галикәй улы балалары: Вәлиулла (1853), Шәмсехәят, Гайнелхәят (1867), Шәрифулла, Хөрмәтулла (1875), Нигъмәтулла (1883). Хәлилулла кызы Шәмсехәят авылдашы Миңлегали Габделфәез улы белән никахлаша. Икенче кызы Гайнелхәят (22 яшь; икенче никах) 1889 елның гыйнвар башында мөәзин Габдерәхим мулла Әхмәтҗан улына (35 яшь; икенче никах) кияүгә чыга. Метрикә кенәгәсенең никах язуында Галикәйнең берьюлы өч улы (Хәлилулла, Мөхәммәтшәриф, Мөхәммәтзариф) күрсәтелә. Ризалык шаһитларыннан берсе булган Иске Катайның Баһманша Баһаутдин улы исеменнән соң Арсланбәк тамгасы бирелә, мондый сирәк була торган хатада мулла гаепле дип фараз кылыйк.

Вәлиулла Хәлилулла улы балалары: Нәбиулла (20.04.1876; анасы Шәмсениса), Хәмдениса (1884). Вәлиулла кызы Хәмдениса (17 яшь) 1901 елның 19 октябрендә Килкабызның Дәүләтша Мөхәммәтҗан улы (23 яшь) белән никахлаша.

Шәрифулла Хәлилулла улы балалары: Гайнелҗиһан (13.10.1897; анасы Фәрхиҗамал Арслангәрәй кызы), Зиннәт (14.09.1901), Бәдигылҗамал (03.11.1905–1906), Хәсбиҗамал (15.11.1909–1914), Хәмидулла (22.03.1913), Сибагатулла (15.08.1915). 1917 елда Шәрифулла Хәлиуллин хатыны (45 яшь) һәм өч улы белән яши, 11,39 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була.

Хөрмәтулла Хәлилулла улы (25 яшь; солдат) 1904 елның мартында авылдашы Хөснетдин Габделвәли улының кызы Фәрхизадә (18 яшь) белән кавыша, балалары Рәхмәтулла (06.02.1906), Шәмсемәрьям (05.11.1911), Рамазан (25.07.1914–1914) туа. Хөрмәтулла Хәлиуллинны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (34 яшь), ике улы һәм кызы кала, 1917 елда 5,87 дисәтинә җире, аты, 4 сарыгы, 2 кәҗәсе була.

Ватан сугышы алды еллары кенәгәсендә Әхмәй Хөрмәтов (1910), аның хатыны Зәйнәп (1905), балалары Өммегөлсем (1930), Фатыйма (1933), Рәис (1936) теркәлә. Әхмәдулла Хөрмәтов – Ватан сугышы корбаны. Бер чыганакта Әхмәдулла 1942 елның 23 ноябрендә һәлак була (хатыны Зәйнәп) дип әйтелә, шул документтан бер көн алдарак авылдашы-полкташы Әнгам Хафизовның (чыганакта «Фафизов Англам» (хатыны Сафа)) да гомере өзелүен беләбез. Икенче чыганакта Әхмәдулла 1943 елның 17 февралендә һәлак була, хатыны шулай ук Зәйнәп дип күрсәтелә. Әхмәдулла, ни сәбәпледер, Яңа Катай метрикәсендә теркәлмәгән, шуңа күрә аның бу Хөрмәтулланың (Яңа Катайда тагын бер Хөрмәтулла була) улы булуын чыганакларны анализлап яздык.

Нигъмәтулла Хәлилулла улы (22 яшь) 1905 елның 15 ноябрендә нәселдәше Мөхәммәтзариф Габделлатыйф улының кызы Бибиталига (17 яшь) белән никахлаша. Бер нәсел кешеләре булганга, никах язуындагы кыз вәкиле Мөхәммәтзариф Габделлатыйф улының, ике якның ризалык шаһитлары Габделмәннан Габдерәфикъ улы, Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтзариф улы, Шәрифулла белән Хөрмәтулла Хәлилулла улларының тамгалары тәңгәл килә («Н» хәрефе формасында). Нигъмәтулла балалары: Мәликә (22.09.1906), Гарифә (28.02.1910–1912), Әхмәдулла (15.01.1913), Дөррия (08.01.1916).

Гайнулла Галикәй улы балалары: Мөхәммәтдин (1859), Сәрвиҗиһан (1861). Гайнулла кызы Сәрвиҗиһан (17 яшь) 1878 елның 20 апрелендә авылдашы Ильяс Мөхәммәтсадыйкъ улы Галиев (35 яшь; икенче никах) белән кавыша.

Мөхәммәтшәриф Галикәй улы балалары: Камилә (1873), Әхзаретдин (12.04.1874–10.10.1912; анасы Гафия), Бибикафия (1875), Шәрәфетдин (26.03.1877), Шәмсезиядә (1878), Гөлбану (21.02.1880; анасы Гафия). Мөхәммәтшәриф ике тап-



**Нәселдәшләр никахы (тамгалары бертөрле)**

кыр кияүдә булган кызы Камиләне 1889 елның 22 октябрендә Әмәкәйнең Хәсән Исхак улы (27 яшь; өченче никах) белән кавыштыра. Икенче кызы Бибикафия (18 яшь) 1893 елның 13 октябрендә авылдашы Хафизмөхәммәт Шәмсемөхәммәт улы Күчемов (25 яшь) белән никахлаша. Өченче кызы Шәмсезияләне (17 яшь) 1895 елның 13 гыйнварында Минзәлә өязе Әгъбәс авылының Хаҗимөхәммәт Мөхәммәтсолтан улы Габделмәннановка (25 яшь) кияүгә бирә. Кияүнең ризалык шаһитлары – Яңа Катайның Габделнасыйр Мөхәммәтгалим улы (Күчем нәселе) белән Иске Катайның Мөхәммәдьяр Мөхәммәткәрим улы (Юлдаш нәселе), кызныкы Әхзаретдин Мөхәммәтшәриф улы белән Муллагали Габделгани улы була. Мөхәммәтшәрифнең төпчек кызы Гөлбану (17 яшь) 1902 елның 27 октябрендә авылдашы Бикмөхәммәт Ильяс улы (25 яшь) белән никахлаша.

Әхзаретдин Мөхәммәтшәриф улы балалары: Җәләлетдин (28.07.1907; анасы Майҗиһан Шәймөхәммәт кызы), Әгъләметдин (16.03.1910), Афзалетдин (01.10.1912–1913). Әхзаретдин Мөхәммәтшәриф улының 1911 елның ноябрендә өченче мәхәллә метрикәсендә салган нәсел тамгасы Арсланбәк нәселенә хас «Н» хәрефен хәтерләтә.

Мөхәммәтзариф Галикәй улы балалары: Мөхәммәтшакир (1861), Сәрвисафа (1873). Мөхәммәтзариф кызы Сәрвисафа (20 яшь) 1893 елның 2 сентябрендә Казан губернасы Мамадыш өязе Сатыш авылының Мөхәммәтзакир Бикмөхәммәт улы (35 яшь; икенче никах) белән кавыша. Шул ук Сәрвисафа (30 яшь; бишенче никах) 1903 елның маенда Иске Катайның Фәттахетдин Баһаутдин улы (35 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Ирдән-иргә йөргән Сәрвисафа ахыр чиктә Килкабызда 40 яшьлек Җәләлетдин Камалетдин улы белән гаилә кора. Никах өченче мәхәлләдә 1911 елның 10 октябрендә була, мулла әллә белә торып, әллә белмичә, икенче никахлары дип язган. Сәрвисафа бу ирдә бәхетен тапканмы-юкмы, алга таба ачыклап тормадык.

Мөхәммәтшакир Мөхәммәтзариф улы Галикәев 1895 елның 29 ноябрендә авылдашы Габделбасыйр Мөхәммәтгалим улы Күчемов кызы Саимә белән гаилә кора, балалары Кәримә (16.01.1898–1898), Сабиткәрам (30.10.1899), Закирҗан (27.04.1903), Фатыйма (11.05.1906), Латыйфа (16.11.1909), Миңлекәрам (1914; метрикәдә теркәлмәгән) туа. Шакир Зарипов (1861) Ватан сугышы алды елларында хатыны Бәдерниса (1865) белән гомер итә, ике улы сугышта һәлак була (исемнәре Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Сабиткәрам Шакиров фронтка 1942 елның 2 февралендә китә, Көнбатыш фронтта шул ук елның 28 ноябрендә башы җәрәхәтләнә һәм күп тә үтми мәрхүм була, хатыны Мәрфуга (1910), кызы Мәснүнә (1931) кала. Миңлекәрам Шакир улы Шакиров (1914) 1943 елның мартында хәбәрсез югала, хатыны Гайникамал (1914), кызы Фәһимә (1936) кала.

«Халык хәтере» («Память народа») сайтыннан Сабиткәрамны караганда, Яңа Катайдан тагын Хәбирҗан Шакир улы Шакиров (1923; 1942 елның октябрендә хәбәрсез югалган) белән Харис Шакир улы Шакиров (1894; 1943

елның 15 мартында һәлак булган) исемнәренә тап булдык (икесе дә Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Беренче мәхәлләдә Нәбиулла Вәлиулла улы Хәлилуллов (Галикәев) белән Кафия Габделгани Мөхәммәтгалим улының кызы гаиләсендә Хәмидулла (30.07.1897), Гыйндулла (10.05.1899), Галимә (05.03.1902–1903), игезәкләр Мохтарулла (1904–1905) белән Галимә (23.06.1904), Гыйниятулла (22.12.1906), Майшәрифә (23.10.1909) дөньяга килә.

Гыйндулла Нәбиулла улы балалары Хадимулла (1922–1925), Нәкыя (24.07.1925; анасы Хәссәмбану Габделкаюм кызы). Гыйндулла Нәбиуллин (1899) гаиләсендә Ватан сугышы алды елларында хатыны Хәссәмбану (1901), кызлары Фәүханә (1930), Фәйханә (1932), улы Фәнис (1939) була. Фәүханә авылдашы Мәснәви Әхмәтханов белән кавыша.

Дәүләтнең төпчек улы Габдрахман иде. Габдрахман Дәүләт улы балалары: Габделмәннан (1805–1828), Габделхәбир (1814–1818), Габделвахит, (1815–1818), Габделмәннаф (1824–05.11.1894; эч рәнҗүеннән), Габделвәли (1859 елгы исемлектә Габделгани; 1825), Яугәрәй (1827).

Габделмәннаф Габдрахман улы балалары: Әхмәтситдыйкъ (1854), Әхтәмгали (1861) һәм Әхмәтвәли (1867). Габделмәннаф кызы Бәдерталига (18 яшь) 1875 елның 1 мартында Иске Куянның Гыйздетдин мөәзин Хәлилрахман улы (23 яшь; атасы мөәзин Хәлилрахман Габдерәхим улы) белән никахлаша. Икенче кызы Миңлеҗиһан (20 яшь) 1890 елның 10 ноябрендә Иске Катайның Габделҗәлил Габделгалләм улы (22 яшь) белән кавыша.

Әхмәтситдыйк Габделмәннаф улы Габдрахманов балалары (өченче мәхәллә): Бибифакия (1886), Әхмәтлатыйф (1887), Бибифәрвизә (1888–1889), Бибифаизә (15.11.1890; анасы Бибимәрзия Хәсән кызы), Миңлефатиха (23.05.1894), Шәрифә (03.06.1897), Рабига (20.06.1900; анасы Бибимәрзия Хәсәнша кызы), Мәгъдәнҗинан (19.06.1903). Әхмәтситдыйкъ кызы Бибифакия 1903 елда Корычның Хәйретдин Әбүнәгыйм улы (23 яшь; атасы Әбүнәгыйм Әсәдулла улы) белән никахлаша. Икенче кызы Бибифаизә 1911 елның 26 февралендә Корычның Хаҗиәхмәт Шәймәрдан улы (23 яшь) белән гаилә кора. Төпчек кызы Миңлефатиха 1917 елда авылдашы Мөхәммәтшакир Мөхәммәтсафа улы (23 яшь) белән кавыша.

Әхмәтлатыйф Әхмәтситдыйкъ улы (28 яшь) 1915 елның 16 гыйнварында авылдашы Хәбибрахман Габделвахит улының кызы Гайнелҗиһан (18 яшь) белән никахлаша. Никах язуында Әхмәтситдыйкъ Габделмәннаф улы (кияүнең вәкиле) белән Габдрахман Габделгалим улы (ризалык шаһиты) салган тамгалар Арсланбәк нәселенекенә хас «Н» хәрефен хәтерләтә.

Әхтәмгали Габделмәннаф улы Габдрахманов балалары: Исламгали (1888), Сафура (1890), Бибинәгыймә (09.05.1893–1903; анасы Бибигайшә Зәйнелгабидин кызы), Сатига (28.11.1895), Фәрхизиядә (14.11.1900–1901). Әхтәмгали кызы Сафура 1907 елда Иске Катайның Хәсәнша Фәйрузша улы (25 яшь) белән никахлаша. Әхтәмгали Габделмәннаповның улын Беренче бөтендөнья

сугышына алалар, 1917 елда хатыны (56 яшь), ике кызы, килене (22) һәм оныгы белән яши, 8,79 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры, 4 сарыгы була.

Исламгали Әхтәмгали улы (25 яшь) 1913 елның 13 февралендә Иске Катайның Мөхәммәтзариф Габделнәфикъ улының кызы Бибивәдига (18 яшь; Юлдаш нәселеннән) белән никахлаша. Кыз тарафыннан вәли вәкил бертуган агасы Мөхәммәтхафиз Мөхәммәдиша улы була. Кызның ризалык шаһитлары – Әхмәтгали белән Мөхәммәтхарис Мөхәммәдиша уллары, егетнеке Әхмәтвәли Габделмәннаф улы белән Мөхетдин Габделлатыйф улы була. Исламгали балалары (өченче мәхәллә): Габдулла (15.04.1914–1914), Мөгаллим (25.04.1915–1932), Дөррия (1924), Тәрҗимә (1928–2008), Мөсәллим (07.09.1933–13.09.2004), Асия (1935), Нәсия (1940). Дөррия – авылдашы Шәмсегали Исламовка, Тәрҗимә авылдашы Фәһим Арслановка кияүгә чыга. Укытучылар Мөсәллим Мәннапов белән Зәйфә Хәлим кызы (25.08.1932–04.03.2002; Бәләбәй районы Чулпан авылыннан) балалары: Салават (1960), Айрат (1962), Илфак (1967). Асия Туктаголның Лотфулла Ахметхафизов белән кавыша, балалары Дамир (1961), Лилия (1965) Венер (1970). Нәсия А. Грищенко белән гаилә кора, Мәскәүдә яши, балалары Артур (1964), Эдуард (1970). Исламгали Мәннапов – Беренче бөтендөнья һәм Ватан сугышы ветераны.

Әхмәтвәли Габделмәннаф улы Габдрахманов балалары: Галимә (1894), Солтангали (16.12.1895; анасы Бибигайшә Ибраһим Габделхаликъ улының кызы), Хаҗгали (25.08.1898), Рәхимә (13.11.1900; анасы Бибигайшә Ибраһим кызы), Рәхилә (19.08.1903), Шагали (07.09.1906), Сәетгали (12.12.1909; анасы Бибигайшә Ибраһим кызы). Әхмәтвәли кызы Галимә 1916 елда авылдашы Кәшфелмәган Муллаян улы белән (22 яшь) никахлаша. Әхмәтвәли Габделмәннаповның олы улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (20), өч улы һәм ике кызы белән яши, 8,77 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры, 3 сарыгы була.

Солтангали Әхмәтвәли улы Вәлиев (1895) Беренче бөтендөнья сугышында катнаша (409 пехота полкы), 1917 елның февралендә авырып хәрби хезмәттән азат ителә. Ватан сугышына киткәндә хатыны Фәрхебану Әлмөхәммәт кызы (1904), балалары Фәүзия (1924), Рәгъфәния (1934), Җәүдәт (1935), Хәмдия (1939) була. Солтангали бу сугыш михнәтләрен үз башыннан кичерә, зур җәрәхәтләр алып (бер аягының тездән аскы өлешен, икенче аягының бармакларын югалта), гаиләсен шатландырып кайтып төшә. Аның бердәнбер улы Җәүдәт Камышлының Хәйдәр Биктимеров кызы Рәмия (1936–2010) белән гаилә кора, балалары Гөлсинә (1960), Рәшит (1962), Флүр (1965) туа. Җәүдәт абый 1978–1980 елларда кырчылык бригадасы бригадиры, 1969–1973 һәм 1980–1988 елларда ферма мөдире булып эшли. Катайга беренче К-700 тракторын ул алып кайта, чишмәдән торба сузып, авылны су белән тәэмин итүдә башлап йөри.

Шагали Вәлиев (1905) – Ватан сугышы ветераны, сугышка киткәндә гаиләсендә хатыны Шәрифә Хөррәмшә кызы (1907), балалары Разыя (1930), Нәҗибә (1939), Вәҗинур (1936), Фәвәрис (1941) була. Сугыштан соң Нәсибә (1947) белән Зөбәер (1950) туа.



**Ике сугыш каһарманы Солтангали Вәлиев**

Сәетгали Вәлиев (1909) – Ватан сугышы ветераны. Сәетгали белән Гөлбикә Гыйззәтулла кызы (1913) балалары: Шәмсегали (1947), Камил (1950), Вәсимә (1954), Әхнәф (1956), Фәвәзинә (1957).

Габдрахманның тагын бер варисы Габделгани (1824) була. Габделгани Габдрахман улы балалары: Муллагали (1848), Муллаян (1853), Әхтәмҗан (1856), Мәхтүмзадә (1874), Әхмәтҗан (23.06.1875–1913; анасы Шәмсеҗиһан), Ахунҗан (11.11.1877), Хөснижиһан (1879), Фәрхиҗиһан (13.02.1889; анасы Шәмсеҗиһан Габделсаттар кызы). Габделгани кызы Хөсниҗиһан (17 яшь) икенче мәхәлләдә 1899 елның 27 ноябрендә Иске Катайның Нургали Миңлегали улы Рамазанов (30 яшь; беренче никахы) белән никахлаша. Кыз тарафыннан вәли вәкил – бертуган агасы Әхмәтҗан Габделгани улы Габдрахманов, кияү тарафыннан вәкил «әткәсе» белән бертуган агасы Җомагол Рамазан улы була. Шул ук Хөсниҗиһан (22 яшь; икенче никах) 1901 елның 10 гыйнварында Килкабызның Габидулла Заһидулла улы (28 яшь; икенче никах) белән кавыша. Икенче кызы Мәхтүмзадә 1904 елның 25 сентябрендә Корычның Мөхәммәтшәриф Мөхәммәтвәли улына (50 яшь; икенче никах) кияүгә чыга. Төпчек кызы Фәрхиҗиһан 1906 елның мартында Камышлытамакның Хәсән Фәттахетдин улы (атасы Фәттахетдин Сираҗетдин улы) белән гаилә кора.

Муллаян Габделгани улы Габдрахмановның бер никахыннан Мәгърисафа (30.08.1893–1912; анасы Ситдыйкасафа Фәхретдин Шәмсетдин улының кызы) туа. Хатыны Ситдыйкасафа 1895 елның 20 октябрендә вафат булгач, Муллаян

(30 яшь; дүртенче никах) 1897 елның 3 мартында авылдашы Җиһанша Габделлатыйф улының кызы Хөснибану (21 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Әлеге никахтан Кәшифә (02.01.1898; атасы Муллаян Габделгани улы Кәримов дип язылган), Гакифә (11.08.1901) дөньяга килә.

Муллагали Габделгани улы Габдрахманов балалары: Нургали (11.03.1889; анасы Хәйриҗамал Шәрәфетдин кызы). Муллагали Габделганиев (65 яшь) 1917 елда хатыны (21), улы һәм кызы белән яши, 12,51 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була.

Әхмәтҗан Габделгани улы Габдрахманов балалары: Казыйхан (06.01.1900; анасы Шәмсебану Мөхәммәтгәрәй кызы), Гыйлемхан (05.04.1902), Хаҗгали (09.06.1906; анасы Җиһан Мөхәммәтзариф кызы).

Габделгани Габдрахмановның энеләре Яугәрәй (1827–1852) белән Мөхәммәтгәрәй (1840) иде. Мөхәммәтгәрәй Габдрахман улы балалары (өченче мәхәллә): Мөхәммәтгали (12.09.1874–12.07.1912; анасы Шәмсениса), Әхмәтзакир (01.07. 1877; анасы Шәмсениса), Хәмдиҗиһан (20.02.1880), Мөхәммәтхаҗи (10.02.1883), Фәрхениса (1885–1893).

Мөхәммәтгали Мөхәммәтгәрәй улы (23 яшь; икенче никах) 1901 елның 27 ноябрендә авылдашы Җиһангир Мөхәммәтвәли улының кызы Шәмсевафа (17 яшь) белән никахлаша, балалары Шәмсенур (01.07.1904), Шәмсенәһар (18.08.1908), Әгъзамгали (11.12.1910) туа.

Югарыда нәселне Дәүләт Сөеш улы яклап карадык. Дәүләтнең туганы Яхшый Сөеш улы нәселен Имангол (1771; исемлектә Этҗыймаслар алдыннан) дәвам итә. Имангол Яхшыев уллары: Бирдегол (1796), Йөзәй (1798), Мөхәммәтҗан (1802), Мөхәммәтәмин (1807). Боларның бары берсеннән генә нәсел дәвам итә.

Йөзәй Имянголовның ир балалары: Шаһислам (1889 елгы метрикәдә Шәйхелислам Солтанголов дип язылган; 1829), Габделихсан (1836), Габделкадыйр (1839–07.11.1915; 1859 елгы исемлеккә кермәгән), Габделхаликъ (1842).

Шәйхелислам Йөзәй улы нәселен Фәтхелислам (1859) дәвам итә. Фәтхелислам Шәйхелислам улы Йөзәевтән Хәерниса (08.08.1889) туган. Фәтхелислам Шәйхелисламов 1917 елда улы (22 яшь) белән яши, 4,33 дисәтинә җире һәм 2 аты була.

Габделкадыйр Йөзәй улы балалары: Солтангәрәй (1871), Гыйльмебану (10.02.1878; анасы Сәхипбану), Фәхретдин (1881), Миңлебану (19.07.1883; анасы Хөснибану), Миңлебану (1888). Габделкадыйр кызы Миңлебану 1905 елның декабрендә авылдашы Нурлыгаян Муллаян улы (25 яшь) белән никахлаша.

Солтангәрәй Габделкадыйр улы балалары: Мәдхиҗиһан (17.01.1910), Миңлегәрәй (14.07.1912–1912; анасы Фәрхиҗиһан Габделмәннан кызы), Әбүнәгыйм (22.02.1914), Хөсниҗинан (15.07.1916). Солтангәрәй Габделкадыйровның энесен (Фәхретдин) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (33 яшь), улы, ике кызы, килене (30 яшь; Хәкимә Солтан кызы) һәм анасы

(70) белән яши, 17,59 дисәтинә җире, җилгәргече, 3 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була. Әбүнәгыйм Солтанов (1914) – Ватан сугышы ветераны.

Габделхаликъ Йөзәй улы Солтанбәков балалары: Бибифатиха (20.08.1878; анасы Бибифатыйма), Фазлыәхмәт (19.02.1889; анасы Мәүгзия), Факия (27.11.1897; анасы Бибикамилә Хаҗиәхмәт кызы), Габделзаһит (08.02.1905; анасы Кафия Арслан кызы), Кифая (10.06.1913; анасы Кафия).

Габделхаликъның икенче никахы Минзәлә өязе Тогаш хан авылының Мостафа Моратбакый улының кызы Бибимотаһарә (18 яшь) белән 1893 елның 11 октябрендә теркәлә, шул елны ук алар аерылышалар. Бер елга якын хатынсыз торгач, Габделхаликъ 1894 елның 29 ноябрендә Иске Катайның Хаҗиәхмәт Мөхәммәтхәнәфи улының кызы Бибикамилә белән кавыша. 1899 елның 29 октябрендә Габделхаликъ хатынлыкка Шәйморат Шәймәрдан улы Нөрмәтов кызы Бибилатыйфаны (27 яшь; икенче никах) ала. Егетнең агасы Габделихсан Йөзәй улы вәкил булып, нәсел тамгасын сала. Кияү белән кызның ризалык шаһитлары Габдрахман Габдерәхим улы белән Шәйхелгаттар Шәймәрдан улы була.

**Әхмәтнең (Этҗыймасның) нәселдәше – Исламгол.**

Исламголның уллары Үмербай (Гомербай; 1778–1824) белән Тимербай (1784–1833) була. Үмербай Исламгол улы ир балалары: Шиһабетдин (1813–1859), Баһаутдин (1818), Галләметдин (1824). Шиһабетдиннән нәселне Шәйхетдин (1834–17.04.1913), Сәйфетдин (1838–10.05.1911), Сиражетдин (1852) дәвам итә.

Шәйхетдин Шиһабетдин улы Үмербаев балалары: Маһинур (1866), Нуркамал (1876), Шәмсенур (29.10.1877; анасы Шәмсекамал), Габдулла (01.02.1880; анасы Шәмсекамал), Сәйфулла (1882), Маһикамал (Майкамал; 21.11.1883), Нурлыгаян (30.10.1889), Гайникамал (1892), Бибикамал (09.04.1898; анасы Шәмсекамал Шәрәфетдин кызы). Шәйхетдин кызы Маһинур (17 яшь) 1883 елның 1 гыйнварында Туктаголның Мөхәммәтшәфикъ Мөхәммәтсадыйк улы (26 яшь) белән кавыша. Икенче кызы Нуркамал (18 яшь) 1895 елның 16 ноябрендә авылдашы Мөхәммәтталип Мөхәммәтшәфикъ улы (22 яшь; Күчем нәселеннән) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Габдулла Шәйхетдин улы белән Сәйфетдин Шиһабетдин улы була. Өченче кызы Майкамал (18 яшь) 1906 елның 6 гыйнварында Иске Катайның Шәйәгъзам Сәхратулла улы (22 яшь) белән кавыша. Шәйхетдиннең төпчек кызы Гайникамал (17 яшь) 1909 елның февралендә Туктаголның Мөхәммәтзакир Гатаулла улы (39 яшь; икенче никах) белән гаилә кора.

Сәйфулла Шәйхетдин улының Мәэлүфә Хаҗиәхмәт кызы белән никахыннан Мәхдүмә (19.04.1916) туа. Сәйфулла Шәйхетдинов (1883) Ватан сугышы алдыннан хатыны Шәмсикамәр (1875), улы Нурулла (1925) белән яши. Нурулла 1945 елда фронтта хәбәрсез югала (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Нурлыгаян Шәйхетдин улы Нәгыймә Хәбибулла кызы белән никахлаша, балалары Нажия (22.07.1925) туа. Нурлыгаян Шәйхетдинов (1889) Ватан сугышы алдыннан хатыны Нәгыймә (1898), балалары Кәшбелгаян (1922), Нажия (1928), Кәндел (1930), Сәгыйть (1933) һәм Вәрис (1940) белән яши.

Габдулла Шәйхетдин улы 1906 елның 10 февралендә авылдашы Фәррахша Әхмәди улының кызы Фәрхиҗиһан (17 яшь) белән никахлаша, балалары Бәһия (25.05.1907–1916), Сәвия (01.01.1909), Шәрхемулла (28.10.1910), Шәйхелмәрдан (03.01.1914–1914) туа. Ватан сугышы алдыннан Габдулла Шәйхетдинов (1880) хатыны Фәрхи (1880), балалары Шәрхемулла (Шәрхем; 1910), Хәтмулла (Хатми; 1922), Нәҗибә (1924), Бәһия (1929) белән яши. Шәрхемулла белән Хәтмулланы армиягә чакыралар, язмышлары билгесез.

Сәйфетдин Шиһабетдин улы балалары: Гыйльметдин (1867), Әһлетдин (1871), Хөббениса (20.12.1877), Сәйфулла (20.09.1880; анасы Фәхерниса).

Гыйльметдин Сәйфетдин улы (25 яшь) 1893 елның 7 гыйнварында Иске Катайның Низаметдин Габделгазиз улының кызы Хәтирә (18 яшь) белән никахлаша, балалары Мәдинә (11.06.1895), Гыйндулла (14.07.1897), Хәтимә (19.02.1901–1904), Саимә (16.07.1904), Бибисания (09.12.1906) туа. Гыйльметдин Сәйфетдинов 1917 елда хатыны (30 яшь), улы һәм өч кызы белән яши, 3,00 дисәтинә җире, 2 кәҗәсе була.

Әһлетдин Сәйфетдин улы Шиһабетдинов балалары: Шәмсеҗиһан (20.04.1897; анасы Мәдхиҗиһан Сәригаскәр кызы), Сәрвиҗиһан (28.03.1900–1905), Акмалетдин (06.05.1903–1905), Әгъләмҗиһан (02.02.1906), Гыйльмиҗиһан (1907–1909), Әгъләм (25.01.1909), Әхияретдин (14.12.1911), Җәмгыйтдин (30.05.1914), Хәйрулла (01.01.1917). Әһлетдин кызы Шәмсеҗиһан 1914 елда Корычның Шәйәгъзам Сәлахетдин улы (23 яшь; атасы Сәлахетдин Тәхаутдин улы) белән кавыша. Әһлетдин Сәйфетдинов 1917 елда хатыны (40 яшь), дүрт улы, кызы (20) һәм анасы (65) белән яши, 4,41 дисәтинә җире, аты, кәҗәсе була. Сиражетдин Шиһабетдин улы балалары: Ражетдин (20.08.1874), Кашшафетдин (30.01.1877; анасы Шәмсе [...]).

Үмербайның икенче улы Баһаутдин (1818–20.03.1902; мулла дип күрсәтелә, беренче мәчетнең метрикәсендә атасының исеме Гомербай дип язылган) иде. Баһаутдин Үмербай улы балалары: Баһман (1850), Борһанетдин, Афзалетдин, Майҗиһан, Бибимәргубә (1878–1895). Баһаутдин кызы Майҗиһан (бер чыганакта исеме Миңлеҗиһан) 1876 елның 25 ноябрендә авылдашы Гаязетдин Шәйхетдин улы Нөрмәтов белән никахлаша, ире мәрхүм булгач, 1905 елда Базы Куянның Нурислам Исламгол улына (40 яшь; икенче никах) тормышка чыга.

Баһманша мулла Баһаутдин улы Үмербаев балалары: Фәсихеласаф (1877), Гыйлемхан (1882), Шәмсеҗиһан (1887), Хәмдиҗиһан (25.12.1890; анасы Бибилатыйфа Җамалетдин кызы), Мәгъшукҗиһан (25.03.1892; анасы Маһинур Килкабызның Габделханнан кызы), Әхмәтхан (02.01.1893; анасы Латыйфа Мөхәммәтшәриф кызы), Бибимәргубә (1897), Әхмәтхан (05.07.1900; анасы

Латыйфа Җамалетдин кызы). Баһманша кызы Шәмсеҗиһан 1904 елда Иске Катайның Мифтахетдин Җәләлетдин улы (икенче никах) белән никахлаша. Икенче кызы Бибимәргубә (20 яшь) 1917 елның 22 ноябрендә Куянның Мөхәммәтшакир Мөхәммәтлатыйф улы (22 яшь) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Ахунҗан Мөхәммәтҗан улы белән Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтәмин улы була. Кияүнең вәкиле – Миңлебай Мөхәммәтлатыйф улы, ризалык шаһитлары Шәйхетдин белән Сәфәргали Мөхәммәтгали уллары була. Баһман Баһаутдиновның улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (65 яшь) һәм кызы белән яши, 1,80 дисәтинә җире, аты була.

Фәсихеласаф Баһманша улы балалары: Миңлеказыйхан (12.12.1907; анасы Бибибәдригабану Миңлеяр кызы), Әминә (02.11.1911). Фәсхенислам Баһманов (чыганакта шулай язылган) 1917 елда хатыны (30 яшь), улы һәм анасы (78) белән яши, 9,37 дисәтинә җире, аты һәм башка маллары була.

Гыйлемхан Баһман улы (30 яшь) 1912 елның 3 ноябрендә авылдашы Минһаҗетдин Хисаметдин улының кызы Бибиҗиһан (18 яшь) белән никахлаша. 1917 елда ялгыз яши, җире һәм мал-туары булмый.

Беренче мәхәлләдә Борһанетдин Баһаутдин улы Үмербаев гаиләсендә Лотфиҗиһан (17.02.1899) туа. Афзалетдин мулла Баһаутдин улыннан Әгъләметдин (03.05.1901; анасы Мәрфуга Мөхәммәтшәфикъ кызы) билгеле.

Үмербайның өченче улы Галләметдин (1824) иде. Галләметдин Үмербай улы балалары: Бәдретдин (1841–17.07.1911), Мифтахетдин (1848–26.04.1908), Шәрәфетдин (1856–05.06.1917).

Бәдретдин Галләметдин улы балалары: Афзалетдин (01.01.1883; анасы Фәрхиҗамал), Газетдин (25.09.1889). Афзалетдин Бәдретдинов 1917 елда энесе белән яши, 1,03 дисәтинә җире була.

Мифтахетдин Галләметдин улы Үмербаев 1875 елның 1 гыйнварында Иске Катайның Фәрхиҗамал Гыйлаҗетдин кызы (17 яшь) белән никахлаша, балалары Шәмсезиядә (1877), Фәрхизиядә (11.11.1878), Шәмсеҗиһан (15.12.1889–1894) туа. Мифтахетдин кызы Шәмсезиядәне (17 яшь) 1895 елның 20 февралендә Тыпыйның Мөхәммәтзакир Рәмкол улы Буранголовка кияүгә бирә. Кызның ризалык шаһитлары Бәдретдин белән Шәрәфетдин Галләметдин уллары була.

Шәрәфетдин Галләметдин улы Үмербаев балалары: Фәтхетдин (1892–1894), Кашшафетдин (27.07.1894–1895; анасы типтәр Мәхмүдә Габделгазиз Габделгалим улының кызы), Бибимәмдуха (16.05.1901; анасы Хәбибзифа Сәйфетдин кызы), Шәмсетдин (17.11.1904–1904; анасы Шәмсезифа Габдулла кызы), Әгъзаметдин (29.08.1906; анасы Хәбибзифа Сәйфетдин кызы), Әгъләметдин (05.01.1910–1916; анасы Миңлерәйфә Габдрахман кызы), Гыйльменур (15.06.1913–1914; анасы Хәсбизифа Сәйфетдин кызы), Мәүлиха (05.06.1917; анасы Хәбибзифа Сәйфулла кызы).

# X бүлек. Азамат нәселе

«Үткәннәрен бел Катайның» китабында 1753 елгы документка таянып Азамат Дәүәтиев хакында әйткән идем. Китап чыккач авылдашым Салават Хаҗиәкрәм улы Госманов бу фамилиягә игътибар иткәнен, Яңа Катай ягында Дәүәти яланы барлыгын әйтеп мине шатландырган иде. Авылдашымның китабымны игътибарлы укуы үзе бер куаныч булса, өч гасыр элек яшәгән Дәүәтинең исеме ялан атамасында бүгенгәчә саклануы аннан да зуррак шатлыксөенеч иде. Тарихыбыз документларда һәм китапларда гына түгел, әнә шулай атамаларда саклана, яңа төсмерләр ала икән.

Менә шул кеше нәселнең киң тармаклануына, халык телендә Азамат нәселе дип аталуга сәбәпче була. Әмма нәселне бары аңа гына бәйләп карау дөрес булмас, чөнки Азаматның үзеннән генә түгел, ә нәселдәше мулла Мерәс Габитовтан да (ул үзе һәм аның улы Мортаза Мерәсов шул ук 1753 елгы документта теркәлгән) киткән тармак бар. Документта Азамат Дәүәтиев белән Мортаза Мерәсов бер үк нәсел тамгасын салганнар, шуңа күрә аларны нәселдәшләр дип әйтәбез. 1816 елгы исемлектә башта Мортаза Мерәсов, аннан соң Азамат Дәүәтиев варислары теркәлүен дә искә алыйк. Барлыгы 12 гаиләдән (кушымтадагы исемлектә №№ 26—37 саннар астында бирелә) торган бу нәсел шул чорда ук ишле булуы белән аерылып тора.



**1753 елгы документ фрагментында Азамат Дәүәти улы тамгасы**

Азаматтан киткән тармаклар күп санлы һәм аеруча ишле булганлыктан, халык та нәселне аның исеме белән атаганлыктан, сүзебезне аннан башлыйбыз. Кылчым белән туганнан туган булган, дип сөйләгән иде картларның берсе аның турында, әмма нәсел тамгаларында бернинди охшашлык юк, димәк, бу сүз дөрес түгел.

Азамат картның биш улы була: Зөбәер (1756—1831), Бәхтияр (1761), Әүдияр (1774—1831), Габделкәрим (1777), Мәдияр. Мәдиярнең Азаматның улы булуы

турында метрикә мәгълүматыннан чыгып әйтәбез, анда оныкларының нәсел фамилиясе Азаматов дип язылган.

Зөбәер Азаматовның Гозәер (1783–1830) һәм Гобәйдулла (1796) исемле уллары була, икесе дә нәсел калдыра.

Гозәер Зөбәер улы ир балалары: Габидулла (1799), Рәхмәтулла (1815) һәм Шаһидулла (1827). Габидулла Гозәер улы ир балалары (икенче мәхәллә): Шәйхулла (1833–13.06.1899) һәм Төхфәтулла (1847–28.12.1908).

Шәйхулла Габидулла улы балалары: Хөснулла (1862), Кәлимулла (1863), Шәрәфулла (1869). Боларның өчесеннән дә нәсел дәвам итә.

Хөснулла Шәйхулла улы Габидуллин (Гозәеров) балалары: Хәерзаман (1892–1893), Бибимәрьям (07.01.1895; анасы Шәмсенур Камалетдин кызы), Шәйхенур (01.08.1897; анасы Гыйззекамал Камалетдин кызы). Хөснулла Шәйхуллинның олы улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны, ике улы һәм ике кызы белән гомер итә, 43,70 дисәтинә җире, җилгәргече, 6 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче яллый.

Кәлимулла Шәйхулла улы Гозәеров балалары: Насыйбулла (1891), Шәрхемулла (06.03.1893; анасы Бибигайшә Әхмәтша Сәйфелмөлеков кызы), Бибимөнирә (18.09.1895), Бибимәсрүрә (05.09.1898), Шәмгыя (14.02.1902), Нурулла (02.01.1905–1905), Бибисәвия (28.07.1906), Сания (01.01.1909). Кәлимулла Шәйхуллинның ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны, өч кызы белән яши, 30,51 дисәтинә җире, 6 аты, 2 сыеры, 10 сарыгы, 2 кәҗәсе була. Кәлимулла Шәйхуллин озын гомерле була, хәтта Ватан сугышы алды еллары кенәгәсендә дә теркәлгән.


**Бакчачы Насыйбулла Кәлимуллин**

Насыйбулла Кәлимуллин Ватан сугышы алдыннан хатыны Әбәдия (1893), улы Камил (1920; Ватан сугышы ветераны) белән яши, сугыштан кайткач 1953 елга чаклы колхозның бакчачылык тармагына җитәкчелек итә.

Шәрхемулла Кәлимуллин авылдашы Габделҗәмил Мөхәммәтҗан улы Күчемов кызы Ниһая (Нигая) (1890) белән гаилә кора, Ватан сугышы алдыннан балалары Рауза (1920), Рәмнә (1922), Хәмит (1925), Сания (1927) белән яши. Аталы-уллы Кәлимуллиннар – Ватан сугышы ветераннары. Шәрхемулла кызлары үз ярларын авылда табалар: Рауза – Шәйхезаман Шәяхмәтовка, Рәмнә – Әслахетдин Шәрәфетдиновка, Сания Мәрхәметдин Гыйлаҗевкә кияүгә чыга. Хәмит белән Вәсилә балалары: Флүзә, Әнис, Нурия, Тәкмилә, Лениза.



**Сугышчы Хәмит Кәлимуллин**

Шәрәфулла Шәйхулла улы Габидуллин (Гозәеров) балалары: Бәдриҗиһан (21.07.1897), Сәрвиҗиһан (09.08.1899), Миңлехәдичә (02.01.1901–1904), Лотфулла (30.06.1903–1904; анасы Шәмсезиядә Зәйнулла кызы), Гыйниятулла (17.03.1905), Әбелкәрам (01.11.1907), Лотфрахман (25.08.1909–1910), Хәерзаман (20.05.1911–1913), Мөсәвәрә (03.10.1913; анасы Фәрхизиядә Зәйнулла кызы). Шәрәфулла Шәйхуллин 1917 елда хатыны (35 яшь), улы һәм кызы белән яши, 19,99 дисәтинә җире, җилгәргече, 7 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче яллый.

Төхфәтулла Габидулла улы Гозәеров балалары (икенче мәхәллә): Бибиҗиһан (1876–1898), Миңлехан (27.03.1877), Миңлеҗиһан (1881), Габдулла (1882), Мәдхиҗиһан (07.03.1883; анасы Мәфтуха), Хәлфиҗиһан (1888), Әхмәдулла (06.08.1889), Мәмдуха (1893), Мәүлиха (01.02.1895), игезәкләр Хәсән белән Хөсәен (13.09.1898; анасы Мәфтуха мулла Бәдретдин кызы), Хәсән (04.01.1900; анасы Мәфтуха Бәдретдин Габделмәннан улының кызы). Төхфәтулла кызы Миңлеҗиһан (18 яшь) 1899 елның 27 ноябрендә Иске Катайның Афзалетдин Әдһәм улы Мөхетдинов (25 яшь) белән гаилә кора. Икенче кызы Хәлфиҗиһан (18 яшь) 1907 елның 30 ноябрендә авылдашы Мирзагали Габделгалим улы (22 яшь) белән никахлаша. Өченче кызы Мәмдуха (17 яшь) 1910 елның 2 апрелендә Килкабызның Мөхәммәтназиф Мөхәммәтлатыйф улы (25 яшь; атасы Мөхәммәтлатыйф Тимергази улы) белән кавыша. Төпчек кызы Мәүлиха (18 яшь) 1915 елның 6 февралендә Килкабызның Исламгали Нурмөхәммәт улы (23 яшь; атасы Нурмөхәммәт Хәбибулла улы) белән гаилә кора.

Габдулла Төхфәтулла улы (22 яшь) 1905 елның 16 декабрендә авылдашы Габделкаюм Габделгани улының кызы Саниямәрьям (17 яшь) белән никахлаша, икенче мәхәлләдә балалары Оркыя (02.03.1908), Әбәдия (13.07.1910–1910), Сәудия (метрикәдә Сәвия; 05.05.1912), Хәсән (27.12.1914) дөньяга килә. Ватан сугышы алдыннан Габдулла Төхвәтов (1879) хатыны Мәрьям (1878), кызлары Оркыя (1908), Сәудия (1912), Нурзиян (1915; метрикәдә теркәлмәгән), Рәгъбәрия (1925), уллары Хәсән (1915), Габделхәй (1928) белән яши. Хәсән Габдуллин – Ватан сугыш ветераны (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән), бер кулы гарип булып кайта, шуңа «чулак Хәсән» дип әйтәләр

Хәсәннәр тагын булганга. Хәсән кызлары: Фәнә (1940; беренче хатыныннан туган, Туктаголда яши), Әлфия, Әлфинә, Гөлфинә. «Хәсәнне, Оркыя әбине, Сәудия җингине бик яхшы хәтерлим. Оркыя әби берүзе иде, алар бер ихатада тордылар, йорты бик бәләкәй иде», дип язып җибәрде Уфада яшәүче авылдашым Рузилә Мөхәммәтнәгыйм кызы Госманова, нәселнең бу тармагына ачыклык кертә төшеп.

Гозәернең икенче улы Рәхмәтулла (1815) иде. Аннан нәселне Гыйззәтулла (1845–23.01.1906) һәм Ярулла (1847–1908) дәвам итә.

Гыйззәтулла Рәхмәтулла улы Гозәеров балалары: Шәмсеҗиһан (1866–1915), Әсәдулла (1870), Шәрифә (01.01.1877; анасы Мәмдуха), Зиннәтулла (1879), Бибишәрифә (1884), Фәрхизиядә (1886), Шәмсезиядә (20.11.1889), Сөнәгатулла (19.08.1893; анасы Бибифакия мулла Габделҗәмил Мөхәммәтҗан улы Күчемов кызы), Әһлия (1895–1898), Шәмсия (15.04.1899), Гыйниятулла (09.05.1901; анасы Бибифатиха имам Габделҗәмил Мөхәммәтҗан улының кызы), Нигъмәтулла (16.12.1903–1904; анасы Бибифатиха). Гыйззәтулла кызы Бибишәрифә (18 яшь) 1902 елның 5 ноябрендә Баекның Фәтхетдин Габдерәфикъ улы (48 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Икенче кызы Фәрхизиядә (20 яшь) 1906 елның мартында Туктаголның Әгъләм Әхмәтвәли улы (28 яшь; икенче никах) белән кавыша. Кызның вәли вәкиле – атасы белән бертуган агасы Ярулла Рәхмәтулла улы, ризалык шаһитлары Әсәдулла белән Зиннәтулла Гыйззәтулла уллары була.

Гыйззәтулла Рәхмәтулла улының икенче никахы 1890 елның 20 мартында авылдашы имам Габделҗәмил Мөхәммәтҗан улы Күчемов кызы Бибифатиха (18 яшь) белән була. Шуңа күрә 1890 елдан соңгы туган балалары барысы да бу хатыннан, ни сәбәпледер, бер очракта (1893 елда) аның исеме Бибифакия дип язылган.

Әсәдулла Гыйззәтулла улы Гозәеров 1894 елның 20 февралендә нәселдәше Шәяхмәт Дәүләтша улының кызы Зәйнәп (17 яшь) белән никахлаша, балалары Бибимәрьям (27.12.1894), Хөрмәтулла (05.09.1903), Шәрхегабдулла (21.02.1906), Гыйльменур (19.09.1911) туа. Әсәдулла кызы Бибимәрьям 1914 елда Корычның Җәгъфәр Садыйк улы (24 яшь) белән никахлаша.

Зиннәтулла Гыйззәтулла улы балалары: Шәмсезиядә (28.03.1909), Әһлия (22.03.1911; анасы Шәмсекамәр Муса кызы), Миңленәфисә (29.01.1914–1917; анасы Шәмсеталига Муса кызы). Зиннәтулла Гыйззәтуллин 1917 елда хатыны (34 яшь) һәм кызы белән яши, 10,73 дисәтинә җире, өчешәр аты, сыеры, 9 сарыгы була.

Сөнәгатулла Гыйззәтулла улы Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, аның Бибинур Габделдаян кызы белән никахыннан улы Нурулла (12.07.1925) туа. Сөнәгать Гыйздәтов (документта шулай язылган; 1893) Ватан сугышы алдыннан хатыны Бибинур (1888), уллары Гыйльмулла (1922), Нурулла (1925–2007; Ватан сугышы ветераны), кызлары Нурзидә (1929), Фәния (1930), Әнисә (1937) белән яши. Гыйльмулла Сөнәгатуллин сугышка чаклы Корыч урта

мәктәбенә (9 класс), энесе Нурулла Иске Маты тулы булмаган урта мәктәпкә (7 класс) барып укый. Гыйльмулла белән Нурулла Сөнәгатуллиннар – Ватан сугышы ветераннары. Аларның атасы Сөнәгатулла сугыш вакытында шулай ук хәрби хезмәткә чакырылган була, язмышы билгесез (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Гыйниятулла Гыйззәтулла улы (1901-ноябрь, 1941; исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән) гаиләсендә Ватан сугышына чаклы хатыны Рәхимә (1896), балалары Нигъмәтулла (1929), Рәдинә (1932) була, Гыйздәтов фамилиясе белән теркәлгәннәр.

Рәхмәтулланың икенче улы Ярулла да зур нәсел калдыра. Ярулла Рәхмәтулла улы Гозәеров балалары: Мөхәммәтхарис (1870), Мөхәммәтзариф (1872), Әхмәтҗан (1875–1877), Миңлемөхәммәтхафиз (18.01.1877), Бибигайшә (06.02.1880; анасы Фатыйма), Бибисафа (1881), Бәдерталига (1888), Бибикамилә (23.12.1889), Гарифә (1892), Мөхәммәтмәкки (27.01.1894; анасы Өммегөлсем Хөснетдин мулла Әүдияр улы Азаматов кызы), Мөхәммәтгази (1896–1898), Әхмәделгази (26.02.1899), Мөхәммәтнәгыйм (29.04.1900; анасы Өммегөлсем Хөснетдин кызы), Шәмсеталига (28.09.1901; анасы Майсорур Мөхәммәтшәриф кызы), Әбүнәгыйм (09.03.1903), Әхмәтнәгыйм (10.01.1906), Салихҗан (09.09.1908–1909, кызамыктан вафат; анасы Өммегөлсем Хөснетдин кызы) һәм башкалар. Ярулла кызы Бибисафа 1898 елның 4 декабрендә Килкабызның Ахунҗан Мөхәммәтҗан улы (25 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Бәдерталига 1905 елның гыйнварында Сеңрәннең Шәехсолтан Әхмәтгәрәй улы (21 яшь; атасы Әхмәтгәрәй Шәйхелгаттар улы) белән кавыша. Өченче кызы Гарифә 1909 елның 16 февралендә Сеңрәннең Әлмөхәммәт Әбүбәкер улы (25 яшь; атасы Әбүбәкер Шәмсетдин улы) белән гаилә кора.

Мөхәммәтхарис Ярулла улы Гозәеров (20 яшь) 1893 елның 12 гыйнварында нәселдәше Дәүләтгир Габделфәез улының кызы Бибифакия (18 яшь) белән никахлаша, балалары Мөнәвәрә (01.01.1894), Мөкәррәмә (08.11.1901) туа. Мөхәммәтхарис кызы Бибимөнәвәрәне (17 яшь) 1910 елның 10 гыйнварында Мөхәммәтгариф мөәзин Мөхәммәтзариф улы (24 яшь; атасы Мөхәммәтзариф Мөхәммәтҗан улы) белән кавыштыра. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтзариф белән Мөхәммәтхафиз Ярулла уллары була. Мөхәммәтхарис Яруллин Яңа Катайда иң бай кешеләрнең берсе санала, 1917 елда аның 55,05 дисәтинә җире, җилгәргече, 12 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була, ике хезмәтче яллый. Бу чорда хатыны (48 яшь), улы һәм кызы белән яши.

Мөхәммәтзариф Ярулла улы Азаматов балалары: Бибихәнифә (20.04.1901), Сабит (24.01.1903; анасы Бибимәфтуха Габделхәбир кызы), Мөхәммәтгариф (13.02.1905), Мөхәммәтхәниф (17.12.1906), Мөхәммәтмәлих (01.02.1909), Әхнәф (23.03.1911–1914), Әхнәф (22.09.1914). Мөхәммәтзариф Яруллин 1917 елда хатыны (40 яшь), өч улы һәм 2 кызы белән яши. Ул да абыйсы Мөхәммәтхарис кебек, бай тормышта яши: 38,50 дисәтинә җире, суктыргычы, җилгәргече, 7 аты, 3 сыеры һәм башка маллары була, сәүдә итә. Совет хакимияте урнашкач

бу байлыклар кими, колхоз барлыкка килгәч бөтенләй бетә, Зариф чарасызлыктан күбрәк калай эше остасы буларак көн күрә башлый. Ватан сугышы алды елларында хатыны Мәфтуха (1875) һәм оныгы Мәсгут (1930; атасы Мәлих) белән яши. Зарифның олы улы Сабит Яруллин (1903) – Ватан сугышы ветераны, кечесе Әхнәф Яруллин (1914) сугышта хәбәрсез югалган (исемнәре Катайның мемориаль стеласына язылмаган).

«Запастагы солдат» Мөхәммәтхафиз Ярулла улы балалары: Мөхәммәтхәниф (22.07.1905–1905), Әхнәф (02.09.1906–1909, кызамыктан вафат), Әлтаф (18.02.1910–1910; анасы Хафизә Мөхәммәтхәлим кызы), Әхмәтшәриф (20.09.1911), Мөхәммәтгариф (03.09.1914–1914; анасы Хафизә Габделхәким кызы), Әлтаф (1922). Мөхәммәтхафизның балалары совет чоры исемлекләрендә Хафизов һәм Яруллин фамилияләрендә теркәлгән.

Әхмәтшәриф Яруллинны (бер документта фамилиясе Хафизов; 1911) сугышка 1942 елның 7 февралендә озаталар, 1943 елның декабрендә хәбәрсез югала, хатыны Гарифә (1910), балалары Мөзәвир (1932), Фәнәви (1939), Явирә (1942) кала. Әхмәтшәрифнең һәм 1943 елның ноябрендә сугышта хәбәрсез югалган Әлтаф Яруллинның исемнәре Катайның мемориаль стеласына өстәп язылырга тиеш.

Әбүнәгыйм Яруллин (1903) 1925 елның 18 апрелендә нәселдәше Казыйхан Бәдретдин улы Азаматов кызы Мәдхиҗиһан (25 яшь; икенче никах) белән никахлаша. 1942 елның 6 гыйнварында сугышка алалар, 1943 елның 15 гыйнварында Ростов өлкәсендә һәлак була, хатыны Мәдхиҗиһан (1902), уллары Мәкки (1928), Мөҗәһит (1932), Әбүзәр (1934), Марс (1938), кызлары Маһизурә (1930), Тәрҗимә (1931), Гөлҗәннәт (1940), Рюзә (1942) кала. Мәккинең гомере Нефтекамск шәһәрендә үтә. Мөҗәһит Иске Катайның Яхья Хәбибуллин кызы Суфия белән гаилә кора, балалары Зилә, Зира, Илдар туа. Маһизурә Иске Катайның Ясир Шагали улы Шәвәлиев белән никахлаша.

Әхмәтнәгыйм Яруллин (Әхмәй; 1906) сугышка 1941 елның 14 июлендә китә, хатыны Сәхия (1908), кызлары Зөбәйдә (1932), Сәгадәт (1935), уллары Зөфәр (1937), Өлфәт (1940) янына дошманны җиңеп кайта. Сәгадәт Иске Катайның Шайман Казхинур улы Хәсәновка кияүгә чыга.

Зөбәер Азаматовның икенче улы Гобәйдулладан Нигъмәтулла (1822) белән Равил (1829–25.06.1878) туган. Нигъмәтулла балалары: Гатиятулла (1845–08.08.1909; Тобаев фамилиясе белән теркәлгән), Әхтәмҗан (1855), Муллаян (1859), Сөләйман, Шәмсеруй (1864). Нигъмәтулла кызы Шәмсеруй 1894 елның 24 октябрендә нәселдәше Әхмәтша Әхмәди улы Азаматов (40 яшь; икенче никах) белән кавыша.

Гатиятулла Нигъмәтулла улының беренче хатыны Бәдерниса Моратбакый кызы була, алар 1876 елның көзендә аерылышалар. Гатиятулла балалары (беренче мәхәлләдә): Шәрхемулла (1889), Маһирә (1895). Гатиятулла кызы Маһирә 1912 елның декабрендә Җөнле (Юнле; хәзерге вакытта бу авыл Илеш райо-

нына керә) авылының Казыймөхәммәт Шәймөхәммәт улы (22 яшь) белән никахлаша.

Шәрхемулла Гатиятулла улы (23 яшь) 1912 елның 23 мартында нәселдәше Җиһангир Габделгани улының кызы Бибиәсма (19 яшь; икенче никах) белән никахлаша, әмма берничә ай гына бергә булалар. Шәрхемулла балалары: Дөһәдия (20.04.1915; анасы Кәшифә Габделкаюм кызы), Хәтмулла (1923), Гафур (1925), Сәрмәдия (1931), Фәвәрис (1936). Авылдашлары арасында Шәрхемулла балта остасы буларак билгеле була.

Гафур Шәрхемуллин – Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителгән яугир, аның батырлыгы «Үткәннәрен бел Катайның» китабында тулы яктыртылды. Катайның 1940–1943 елгы хуҗалыклар кенәгәсендә Гафурның сугышка чаклы Иске Корыч мәктәбендә сигезенче класска чаклы укуы хакында әйтелә, димәк, белемгә омтылышы зур булган.

Бу китапны язганда Гафурның абыйсы Хәтмулла язмышы белән кызыксынып «Халык хәтере» сайтына кердем һәм өр-яңа мәгълүмат таптым. Энесеннән аермалы буларак, Хәтмулла документта Гатиятуллин фамилиясендә теркәлгән (исеме Катайның мемориаль стеласына язылмаган). Ул сугышка 1942 елның 7 мартында китә, 1943 елда ике тапкыр яралана, госпитальдән аэродромны хезмәтләндерү батальонына җибәрелә, монда командирлары 10 тапкыр рәхмәт белдерә һәм 1945 елның апрелендә «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале белән бүләкли. Сугыштан исән-имин кайткан, «Ватан сугышы» ордены (1 нче дәрәҗә) (06.04.1985) белән бүләкләнгән. Сугыштан соң Уфада яшәгән булса кирәк, 1985 елгы бүләкләү документында ялгыш шунда туган дип күрсәтелә.

Муллаян Нигъмәтулла улы Гозәеров балалары: Фәтхелбәян (1885–1889), Йосыф (13.04.1889; анасы Шәмсеҗамал Бикмөхәммәт кызы), Шәмсенур (30.03.1895), Хөсниҗинан (23.09.1899; атасының нәсел фамилиясе Тобаев, анасы Нурҗиһан Рәхмәтулла кызы), Фәтхелбәян (02.09.1903; анасы Нурҗиһан Рәхмәтулла кызы), Хәсбинур, Фәүзия (15.03.1907; анасы Фәхерҗиһан Фәхретдин кызы), Сәвия (08.03.1911; анасы Нурҗиһан Рәхмәтулла кызы). Муллаян кызы Шәмсенур 1913 елда Баекның Шәфигулла Хәйрулла улы (22 яшь; атасы Хәйрулла Ибнямин улы) белән никахлаша. Муллаян Нигъмәтуллинның олы улын (30 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (55), төпчек улы һәм биш кызы белән яши, 9,05 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була.

Фәтхелбәян Муллаян улы Нигъмәтуллин (1903–1994) – Ватан сугышы инвалиды (2 группа), сугышка киткәндә Катай авылы кенәгәсендә аның хатыны Нурикамал (1910), уллары Әгълә (1930), Габделхәй (1938), Фәнис (1941), кызы Җәннәт (1933) теркәлә. Сугыштан соң Рәисә (1949) белән Әнисә (1951) дөньяга килә.

«Әгълә абый гомер буе Катай авылында яшәде, балалары: Рафаэль (1954), Ильвира (1956), Зөләйха (1958), Рима (1960), Раил (1972). Габделхәй абый Маты совхозында баш энергетик булып эшләде, балалары Ильмира, Альбина (РОНО

да эшли). Әнисә сеңлем Алабуга пединститутын бетерде, Нефтекама шәһәрендә яши. Үзем Матыда 9–10 классларны укыдым, Йоматау авыл хуҗалыгы техникумын тамамлагач, «Сөн» колхозында (Шаран районы) – экономист, аннары бухгалтер ярдәмчесе, ә 1986 елдан пенсиягә чыкканчы, авыл хакимиятендә баш бухгалтер булып эшләдем. Ирем Миргасим Газимов белән өч бала үстердек, ике кызыбыз пединститут, улым Илдар Уфа нефть университетын бетерде», дип хәбәр итте Рәисә Фәтхелбаян кызы Газимова. Рәисә ападан әтисе турында да язуын сорадым, түбәндә аның язмасын китерәбез.

«Әтием башта фин сугышында катнаша, ә Бөек Ватан сугышына беренче көннәрендә үк киткән. Ул Брянск урманнарында булган сугышлар турында бик сагышланып сөйли иде: анда күп югалтулар булуын, якын дусларын югалтуын әйтә иде. Бик тә салкын кыш булып, кар өстендә еш кына төн үткәргәннәре, аяклары өшегәне турында сөйли иде. Украина фронтында сул кулы яралана (йөрәк турында), госпитальдә ятып чыга, ярасы зур гына шрам булып кала.

Сугыш беткәннән соң илне төзеклəндерүдә катнаша, 1948 елда гына авылга кайта. Әтием заманына күрә укымышлы кеше була: гәрәп, латин хәрефләре белән язганны укый, яза белә иде. Ул авылда балта остасы булды: бура бурау, түбә ябу гына түгел, тәрәзә кәчәкләре, рамнарын, көянтәләр, чана, чаңгы, бәләкәй арбалар да ясый иде. Авыл халкы әткәйнең көянтәләрен мактый иде: җиңел, ныклы, җайлы диләр иде. Әтием бик тә изге күңелле кеше иде: күршебез Тәгълимә апа Камаева безнең гаилә кешесе кебек, атна саен мунча кереп, тирләп-пешеп чәй эчеп чыгып китә иде. Тәгълимә апа сугыш вакытында тракторда эшләгән.

Тау итәгендә ике чишмә бар иде. Ул чишмәнең суы таш арасыннан, күз яше саркып чыккан кебек, тамчылап тама иде, шул тамчыларга юл ясап, калай кулашалар аша җыеп, чишмә итеп агыза иде әтием. Кыш көннәрендә, бураннарда көрәп, баскыч ясап куя иде. Чишмә суына аргы яктан да чыгалар иде. Суы йомшак, бик тә тәмле иде. Әтием ярдәм сорап килгән беркемне дә борып чыгарганы булмады. Пенсиягә чыккач та, урманчы (лесник) Тәкиулла абзый чакыргач, «кәҗүннәй»гә агач утыртырга, араларын тазартырга эшкә йөри иде, 70 яшендә дә салам эскертләргә барды.

Табигать безнең нәселебезгә камил акыл гына түгел, физик яктан да сәламәтлек биргән: әтием 90, әнием 93, Фәүзия түткәй 97 яшькә җиттеләр. Әгъләабыебызның 90 яшен бәйрәм иттек быел, үзе әле бик әйбәт йөреп тора. Бездә мәктәпне көмеш, алтын медаль белән, югары уку йортын кызыл дипломнар белән тәмамлаучылар күп. Улым мәктәпне – көмеш, оныгым алтын медаль белән тәмамлады. Оныгым Лилия Бәшәрова авиация институтын кызыл дипломга бетереп, хәзерге вакытта Мәскәүдә Югары Икътисад мәктәбендә (ВШЭ) укый. Аларның уңышларына куанып яшибез».

Нигъмәтулла Гобәйдуллин балалары һәм оныклары турында сүзне аның төпчек улы Сөләйман белән тәмамлыйбыз. Сөләйман Нигъмәтулла улы Гозәеров (1898 һәм 1900 елгы метрикәләрдә фамилиясе Тобаев) балалары: Гарифҗан

(27.10.1895), Сабирҗан (07.04.1898; анасы Хәмдия Мофаздал кызы), Закирҗан (18.09.1900).

Гобәйдулла Зөбәеровның икенче улы Равилдән нәселне Нурмөхәммәт (1854), Нуриәхмәт (1856), Нургали (1871) дәвам итә.

Нурмөхәммәт Равил улы балалары: Сабит (1891), Кафия (27.11.1895; анасы Бәдигылҗамал Габделбәшир Габделлатыйф улының кызы), Сафуан (01.01.1899; 1899 елгы метрикәдә нәсел фамилиясе Тобаев), Бәһия (27.09.1902; анасы Бәдигылҗамал Габделбәшир улы), Закуан (30.07.1907). Сабит Нурмөхәммәт улы (23 яшь) 1914 елда Килкабызның Габделхәбир Габделгалим улының кызы Мәгъфүрә (19 яшь) белән никахлаша, кызы Мәгъсүмә (25.01.1915) дөньяга килә. Балта остасы Сабит Нурмөхәммәтов гаиләсендә Ватан сугышы алды елларында хатыны Фәрхи (1898), уллары Нәҗих (1928), Хәмит (1931), Заһит (1939), кызлары Әдия (1927), Зәйтүнә (1935), Шәмгыя (1940) була, 1940 елда авылдан чыгып китәләр. Сафуан Нурмөхәммәтов 1942 елның 27 августында сугышта һәлак була, хатыны Галимә (1893), балалары Рюзә (1921), Җәүһәрия (1924), Мәккия (1928), Гавис (1936), Суфия (1940) кала.

Нуриәхмәт Равил улы Гозәеров балалары: Нурзифа (1887–1917), Сабит (11.08.1889; анасы Бәдигылҗамал Зәйнелбәшир кызы), Вәлиәхмәт (27.09.1894; анасы Нурҗиһан типтәр Габделлатыйф кызы), Нурикамал (03.08.1897; анасы Нурҗиһан Мөхәммәтлатыйф Өметбай улының кызы), Хаҗиәхмәт (13.03.1900; анасы Нурҗиһан Габделлатыйф кызы). Хатыны вафат булгач, Нуриәхмәт (45 яшь) 1901 елның 4 сентябрендә авылдашы Низаметдин Камалетдин улының кызы Мәүлиханы (17 яшь) алып кайта, балалары Рәйфә (13.08.1903), Нурислам (12.10.1906), Миңлегарифә (23.04.1909), Фатыйма (03.08.1912), Хәтимә (29.10.1915–1916, кызамыктан вафат) туа.

Нургали Равил улы балалары: Нурлыгаян (25.12.1895; анасы Рузәтелҗинан Нурмөхәммәт Нигъмәтулла улының кызы), Гайнелҗинан (11.08.1898), Хаҗиәхмәт (02.10.1901), Нурулла (21.03.1905), Дөррелҗинан (03.09.1908–1910), Нуретдин (12.09.1911), Гарифә (1912–1914), Галимулла (29.11.1915–1916, кызамыктан вафат). Хаҗиәхмәт Нургалиев (1901) 1943 елның апрелендә сугышта хәбәрсез югала (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Нурулла Нургалиев (1905) Ватан сугышы алдыннан хатыны Хәтимә (1910), балалары Насиха (1938) һәм Нәбис (1940) белән яши, 1941 елның 23 мартында гаиләсе белән авылдан чыгып китә, сугыштан исән-имин кайта. Нурулла Нургали улы Нургалиев (1905) – Ватан сугышы ветераны, «Кызыл Йолдыз» ордены (02.02.1945) белән бүләкләнгән. Аның энесе Нуретдин Нургалиев (1911) сугышка 1941 елның 2 августында китә, бу вакытта хатыны Фатыйма (1911), кызлары Вәсилә (1939), Фәнә (03.01.1942) була.

Бәхтияр Азаматовның нәселе калмый, бары бер генә улы (Габделхаликъ) булып, ул да яшьли дөнья куя. Азамат картның өченче улы Әүдияр – XIX гасыр башларында Катайның указлы мулласы. Аның Шәрәфетдин (1802–1823), Фәт-

хетдин (1810), Габделгани (1810), Хөснетдин (1826–23.02.1902), Шәрәфетдин (1829) һәм Гыйлаҗетдин (1830) исемле уллары була.

Әүдиярның улы Габделгани да мулла була. 1859 елгы мәгълүмат буенча, Габделганинең хатыннары Зөлхиҗә Гозәер кызы (1811) белән Гафифә Галибай кызы (1827) була, беренче хатыныннан Җиһангир (1847–03.10.1910), икенче хатыныннан Сәүбән (1848–1853), Солтангир (1859) һәм алты кызы дөньяга килә. Габделгани кызы Мәфлиха (30 яшь; икенче никах) 1888 елның 11 февралендә Балыклының Гайфулла Фәтхулла улы (50 яшь; икенче никах) белән кавыша. Әлеге никах Иске Катай мәчетендә теркәлә.

Җиһангир мулла Габделгани улы балалары: Әхмәтзәки (1871), Әхмәтгали (10.08.1880; анасы Фәрухҗамал), Бибикамилә (20.06.1883), Хәйдәргали (1888–1889), Бибихәкимә (22.12.1889), Бибиәсма (10.04.1894; анасы Җамалетдин кызы), Саимә (30.06.1901–1901). 1903 елның октябрендә Җиһангир җиденче тапкыр өйләнә, бу юлы хатыны Кадернең Шәмсезиядә Гыйльван улының кызы (35 яшь; алтынчы никах) була. Җиһангирның төпчек кызы Бибиәсма 1912 елда Чуракайның Шакирҗан Бәдретдин улыннан аерылып, нәселдәше Шәрхемулла Гатиятулла улы (23 яшь) белән никахлаша. Бу никах та уңышлы булмагач, 25 яшьлек Бибиәсманы 1913 елның язында Иштирәкнең Мөхәммәтмөэмин Габделкадыйр улы (56 яшь; икенче никах) белән кавыштыралар. Мөхәммәтмөэмин белән күпмедер торгач, аерылышалар һәм 1915 елның 11 февралендә тагын кушылалар. Ахыр чиктә Бибиәсма (30 яшь; дүртенче никах) Катайга кайтып, 1916 елның 3 декабрендә авылдашы Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтәмин улы (50 яшь; өченче никах) белән гаилә кора.

Әхмәтзәки Җиһангир улы (23 яшь) 1894 елның 18 декабрендә авылдашы Шәйморат Шәймәрдан улы Нөрмәтов кызы Бибилатыйфа (18 яшь) белән никахлаша, балалары Әхмәтнәгыйм (26.09.1895) һәм Хөсния (07.10.1897) туа.

Габделгани Әүдияровның энесе Хөснетдингә күчәбез. Хөснетдин Габделгани улы балалары: Фәттахетдин (1849), Хәсбиетдин (1853–30.08.1904), Фазлытдин (1855–02.04.1916), Фәттахетдин (1867), Өммегөлсем (1875), Бибихәлимә (1880). Хөснетдин кызы Өммегөлсем нәселдәше Ярулла Рәхмәтулла улында кияүдә була, 1908 елда ире мәрхүм булгач, туганнары аны Минзәлә өязенең Бүләк авылында яшәүче 75 яшьлек картка димлиләр, никахлары икенче мәхәлләдә 1910 елның 10 июнендә теркәлә. Әлеге картның (Шаһидулла Габделвахит улы) бу дүртенче, хатынның (аңа 35 яшь) өченче никахы була. Хөснетдиннең төпчек кызы Бибихәлимә 1897 елның 20 августында Иске Катайның Шәймөхәммәт Шәмбаз улы (38 яшь; өченче никах) белән никахлаша.

Хәсбиетдин Хөснетдин улы Азаматов балалары: Бибиҗиһан (1879), Кашшафетдин (1886–1914), Гыйлаҗетдин (1888), Хәлфеҗиһан (09.08.1889; анасы Бибикамал), Гөлҗиһан (1892), Хәмдеҗиһан (01.05.1895; анасы Гыйльмикамал Әбушахман кызы), Гыйльмиҗиһан (22.01.1898), Шәмсеҗиһан (14.08.1900; анасы Гыйльмикамал), Бибисәрия (31.03.1903–1904). Хәсбиетдин кызы Бибиҗиһан (22 яшь; өченче никах) 1901 елның 11 июнендә Килкабызның Әхмәтгали

Әхмәтҗан улы (27 яшь; икенче никах) белән кавыша. Икенче кызы Гөлҗиһан (17 яшь) 1909 елның 2 декабрендә Баекның Сәрвәретдин Низаметдин улына (25 яшь, икенче никах; атасы Низаметдин Ибниямин улы) кияүгә бара. Өченче кызы Хәмдиҗиһан 1912 елның 11 октябрендә Иске Катайның Хәйдәргали Габделкадыйр улы (25 яшь; Юлдаш нәселеннән) белән никахлаша.

Кашшафетдин Хәсбиетдин улы балалары: Шәмсениса (04.01.1907; анасы Шәмсекамәр Габделбасыйр кызы), Зыятдин (01.09.1909–1915; анасы Галимә Шәйхелислам кызы), Минһаҗетдин (19.05.1911), Әгъзаметдин (07.08.1913–1917).

Гыйлаҗетдин Хәсбиетдин улы (26 яшь; икенче никах) 1914 елның 26 июнендә Бөгелмә өязе Габдрахман авылының Җиһангир Тимербай улының кызы Бибигалимә (24 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Гыйлаҗетдиннең башка никахтан кызы Әминә (03.06.1917; анасы Галимә Шәйхелислам кызы) билгеле. Гыйлаҗетдин Хәсбиетдиновны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (30 яшь), улы (5), кызы һәм сеңлесе кала, 1917 елда хуҗалыгында 3,93 дисәтинә җире, 2 аты һәм башка маллары була, хезмәтче яллый.

Фазлытдин Хөснетдин улы Азаматов балалары: Бибисара (1887), Галимә (23.08.1889), Фәтхетдин (1890), Бикмөхәммәт (15.07.1893; анасы Зөләйха Шәйхетдин улы Күчемов кызы), Саимә (1896), Динмөхәммәт (12.09.1897), Бибигалимә (03.06.1900), Сәрвиҗиһан (23.02.1902), Фәрхиҗиһан (1904–1905), Сәхипзадә (01.02.1906–1906). Фазлытдин кызы Бибисара 1905 елның 19 декабрендә Килкабызның Мөхәммәтдин Нәбиулла улы (22 яшь; атасы Нәбиулла Ильяс улы) белән никахлаша. Икенче кызы Саимә 1914 елның 7 мартында Иске Катайның Мөхәммәтсадыйк Хаҗиәхмәт улы белән кавыша.

Фәтхетдин Фазлытдин улы (23 яшь) 1913 елның 14 февралендә Иске Катайның Мөхәммәтгариф мулла Мөхәммәтнәби улының кызы Зәкия (18 яшь) белән никахлаша. Динмөхәммәт Фазлытдин улының Фәррахия Хәйрулла кызы белән никахыннан Нәҗмелгалим (26.11.1925) туа.

Фәтхетдин Хөснетдин улы Азаматов (22 яшь) 1889 елның 15 декабрендә авылдашы Нигъмәтулла Гайнулла улының кызы Майҗамал (17 яшь) белән никахлаша. Фәтхетдин балалары (икенче мәхәллә): Афзалетдин (28.11.1893–1898), Минһаҗетдин (20.11.1895; анасы Майҗамал Нигъмәтулла Гайнулла улының кызы), Бибикамилә (1899–1909), Афзалетдин (06.07.1901–1902), Әгъләметдин (08.06.1903), Фәрхиҗиһан (26.04.1904; анасы Зөләйха Фәррахетдин кызы), Мөхәммәтдин (24.04.1905–1906; анасы Майҗамал), Хәтимә (22.09.1906–1909, кызамыктан вафат), Фатыйма (06.11.1907), Нәгыймә (29.04.1909), Наҗия (22.06.1911–1912), Әфлах (18.10.1912), Фәсхетдин (01.03.1914–1914). Фәтхетдин Хөснетдинов 1917 елда хатыны (50 яшь), өч улы һәм ике кызы белән яши, 17,53 дисәтинә җире, җилгәргече, 6 аты, 5 сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче яллый. Ватан сугышы алдыннан тракторчы Әфлах Фәтхеев (1912) хатыны Әһлия (1911), балалары Тәлгать (1933), Фәнис (1936), Мәгъзүмә (1939), Хәмнәҗәр (1941; хатыны Мәвәзинә) белән яши, сугышка китә (язмышы билгесез).

Габделгани Әүдияровның икенче энесе Шәрәфетдиннән дә нәсел ишәя. Шәрәфетдин Габделгани улы балалары: Садретдин (1854), Нуриәхмәт (1856), Нуретдин һәм Хаҗиәхмәт (1863).

Садретдин Шәрәфетдин улы Азаматов балалары: Шәмсенәһар (17.09.1883; анасы Фәрхиҗамал), Газетдин (1888–1889), Әбелмөкәрам (27.06.1893–1894; анасы Фәрхиҗамал Хәбибулла улы).

Нуретдин Шәрәфетдин улы Азаматов балалары: Исламгали (17.11.1893–1895), Солтангәрәй (24.12.1895; анасы Гыйльмиҗинан Габделсаттар кызы), Рузәтелҗинан (13.10.1898), Кафия (12.09.1900), Тимергали (22.06.1903–1905), Мәргубә (21.12.1905), Камалетдин (28.07.1908), Мәгъфурый (01.01.1912–1912).

Хаҗиәхмәт Шәрәфетдин улы Азаматов балалары: Вазыйха (1896), Суфиәхмәт (25.01.1899; анасы Хәерниса Хәйрулла Габдерәхим улының кызы), Рабига (28.02.1900), Габдулла (29.01.1903; анасы Шәмсениса Хәйрулла кызы), игезәкләр Хәтимә (17.04.1906) белән Фатыйма (17.04.1906–1906), Хәкимә (10.04.1910), Гакифә (29.09.1915; анасы Шәмсебанат Хәйрулла кызы). Хаҗиәхмәт кызы Вазыйха 1913 елда авылдашы Гыймаделислам Гаязетдин улы (20 яшь) белән никахлаша.

Нәселнең Габделкәрим Азаматов тармагын аның уллары Габделфәез (1798), Габделкадыйр (1800), Габделгалим (1803; мөәзин), Габделлатыйф (1815–17.09.1897) һәм Мөхәммәтша (1822) дәвам итә. Габделкәримнең уллары 1816 һәм 1834 елгы ревизияләрдә, ни сәбәпледер, Габделкәримов урынына Кариев дип бирелә.

Габделфәез Габделкәрим улы балалары: Дәүләтша (1821), Батырша (1837–1853), Бәдретдин (1843), Дәүләтгир (1847–24.10.1898).

Дәүләтша Габделфәез улы ир балалары: Шәяхмәт (1847), Әхмәтвәли (1850–23.02.1902).

Шәяхмәт Дәүләтша улы балалары: Госмангали (12.01.1876; анасы Хәмдесафа), Зәйнәп (1877), Шәймөхәммәт (1880), Бибизөһрә (1882), Гайшә (1884–1903), Шагали (1887–1889), Рәйфә (1888). Шәяхмәт кызы Зәйнәп (17 яшь) 1894 елның 20 февралендә нәселдәше Әсәдулла Гыйззәтулла улына (22 яшь) кияүгә чыга. Икенче кызы Бибизөһрә (17 яшь) 1899 елның 5 мартында авылдашы Мөхәммәтхәтим имам Габделҗәмил Мөхәммәтҗан улы Күчемов (26 яшь) белән никахлаша. Өченче кызы Рәйфә 1907 елда Корычның Шәрифҗан Гайнетдин улына (19 яшь) кияүгә бара, аннан кайтып 1914 елның язында Иштирәк авылының 50 яшьлек кешесе белән кавыша. Шәяхмәт Дәүләтшинның улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда ул хатыны (70 яшь), килене (37), биш оныгы һәм эшчесе (35) белән яши, 30 дисәтинә җире, 8 аты, 7 сыеры һәм башка маллары була, ике хезмәтче (берсе даими) тота. Бакалея товарлары белән сәүдә итә, сuктыргычы, җилгәргече була.

Госмангали Шәяхмәт улы Азаматов (23 яшь) 1901 елның 3 мартында авылдашы Габделнасыйр Мөхәммәтгалим улының кызы Фәрхисорур (17 яшь; Күчем нәселеннән) белән никахлаша. Егетнең ризалык шаһитлары Әхмәтвә-



**Гыйльман Госманов хатыны Халидә белән**

ли Дәүләтша улы белән Әхмәтнәби Әхмәтвәли улы була. Госмангали (Госман) балалары (икенче мәхәллә): Шагали (25.07.1903–1903; анасы Фәрхисорур), Шәйхенур (09.11.1904), Гакифә (30.01.1908; анасы Фәрхисорур), Кәшифә (04.01.1911; анасы Фәрхисорур), Миңлефатыйма (05.09.1914–1915; анасы Сәкинә Минһаҗетдин кызы), Рәкига (07.12.1915), Шәрифә (21.12.1917), Шәйхезаман (1919–2011), Зиннур (11.01.1927–12.02.2007), Гыйльман (1930–1988). Никахтан соң шактый гомер иткәч, 1913 елның 23 февралендә Госмангали хатыны Фәрхисорурны аерып җибәрә, тиз арада яшь хатын алып кайта. Госмангали Шәяхмәтов 1917 елда хатыны (25 яшь), улы һәм өч кызы белән яши, 15,81 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була. 1931 елда репрессияләнә. Бертуган Шәйхезаман белән Зиннур Шәяхмәтовлар – Ватан сугышы ветераннары.

Шәйхезаман белән Рауза Шәрхемулла кызы (1919–1993) балалары: Әнисә (1947), Мәккия (1949), Канәфи (1954–2014), Өлфәт (1956; техник фәннәр докторы), Вәрисә (1958), Зәнфәрия (1960). Гыйльман белән Халидә Гыйлемхан кызы (1930–1996) балалары: Равил (1956), Рәмил (1958), Фәнирә (1961–2009), Зәлирә (1964), Зилия (1973–2017). Зиннур Шәяхмәтов озак еллар Катай авылы мулласы булды, бик ачык, зур дини белемле иде. Бер дини китапның җитешсезлеген күреп, Казан мөфтиятенә хат язды, мин аны үз кулым белән илтеп тапшырдым, аннары икенче очрашканда җавап язганнарын сөйләгән иде. Мине хөрмәт итте, мин дә аны хөрмәт иттем, әледән-әле сагынып искә алам, авыл тарихының тизрәк басылып чыгуын теләгәнен искә төшерәм. Хатыны Мөзәккия Вазыйх кызы (05.06.1922–18.02.2007) белән Әнәс (17.10.1946; тарих укытучысы), Әлфия (17.06.1955; полиграфист, район газетасында наборно-строкоотливной машинада наборщица), Зөлфәт (01.06.1957; агроном һәм автомеханик) һәм Зәлияне (23.09.1959; сатучы һәм ипи пешерүче) тәрбияләп үстерделәр.

Шәймөхәммәт Шәяхмәт улы Азаматов балалары: Хәтимә (08.08.1906; анасы Гөлзаһирә Сәмигулла кызы), Шәйәгъзам (1909 елда яшьли вафат), Зәйтүнә (24.02.1912), Мәликә (11.11.1914), Билал (20.07.1925).

Дәүләтшаның икенче улы Әхмәтвәлидән дә нәсел дәвам итә. Әхмәтвәли Дәүләтша улы балалары: Әхмәтнәби (03.09.1877; анасы Гайшә), Саимә (02.01.1880; анасы Гайшә), Миңлеәхмәт, Хәтимә (1884), Хәкимә (1888), Гали (Мөхәмmәтгали, 30.08.1889; анасы Гайшә Фәхретдин кызы), Мөхәммәтхан (1896), Фатыйма (1897), Миңлехәниф (18.02.1900). Әхмәтвәли кызы Хәтимә 1902 елның 25 февралендә Камышлытамакның Габдулла Идрис улы (21 яшь;

атасы Идрис Габделкаһир улы) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле агасы – Шәяхмәт Дәүләтша улы, ризалык шаһитлары Әхмәтнәби белән Миңлеәхмәт Әхмәтвәли уллары була. Әхмәтвәлинең икенче кызы Хәкимә 1905 елның 10 февралендә авылдашы Шәехгали Шәйхелмансур улы (21 яшь) белән гаилә кора. Төпчек кызы Фатыйма (19 яшь) 1917 елның 28 февралендә Корычның Шакирҗан Хөсәен улы (23 яшь; атасы Хөсәен Габделлатыйф улы) белән никахлаша. Кыз вәкиле атасы белән бертуган агасы Шәяхмәт Дәүләтша улы була. Мөхәммәтхан Вәлиев (1897) Ватан сугышы алдыннан хатыны Миңлеҗамал, балалары Хәүлә (1926) һәм Нажих (1929) белән яши. Нажих Вәлиев авылдашы Сәрвәретдин Җәләев кызы Бәһия белән гаилә кора, балалары Расих, Рәис, Мәвазиф, Мөдәррис, Зөһрә туа.

Әхмәтнәби Әхмәтвәли улы балалары: Фәхерислам (20.12.1904; анасы Мәликә Мөхәммәтрәхим кызы), Шәйхелислам (03.01.1907; Ватан сугышы ветераны), Мөхәммәткамил (20.11.1909), Мөхәммәтислам (10.10.1911), Әхмәтнәгыйм (19.02.1914), Мирсәет (1916), Әмирҗан (1926). Әхмәтнәби Әхмәтвәлиев (41 яшь) 1917 елда хатыны (37) һәм алты улы белән яши, 8,30 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры һәм башка маллары була. Фәхерислам, Мөхәммәтислам, Мөхәммәткамил – Ватан сугышы корбаннары, Шәйхелислам, Әхмәтнәгыйм, Мирсәет (1916), Әмирҗан (1926)– Ватан сугышы ветераннары.

Шәйхелислам Нәбиев (1907) 1941 елның 14 июлендә хәрби хезмәткә чакырыла, бу вакытта хатыны Фәүзия (1912), балалары Рәфәт (1938), Рәсимә (1941), анасы Фәрхнур (1860) була. Камил Нәбиев (бер чыганакта Камил Нәби улы Вәлиев; 1909) 1941 елның 12 сентябрендә Ватан сугышына китә һәм һәлак була, хатыны Сәрвиҗиһан (1906), кызы Фәүханә (1935) кала. Әхмәтнәгыйм Әхмәтнәбиев (1914) сугышка чаклы тракторда эшли, хатыны Кәнифә, балалары Зөһрә, Фәнис, Глүзә, Зәлифә, Сәнирә. Мирсәй Нәбиевнең хатыны Разия, кызы Гөлнәзирә була. Әмирҗан Саҗидә белән гаилә кора, балалары (Сәлим, Халидә, Салихҗан, Мәүлидә) туа. Фәүханә Корычкаранның Сәрвәретдин Садриевкә кияүгә чыга, алар дүрт ул (Денис, Әгъләметдин, Венер, Земфир) һәм ике кыз (Венера, Фәнзилә) тәрбияләп үстерделәр. Сәрвәретдин кода 2018 елның 1 нче маенда Бәраәт кичәсен билгеләп үткән төндә дөнья куйды.


**Ватан сугышы корбаны Камил Нәбиев (уңда)**



**Сәрвәретдин белән Фәүханә Садриевлар**

Миңлеәхмәт Әхмәтвәли улы балалары: Суфиәхмәт (05.12.1911), Мәрьям (02.08.1914; анасы Сәгыйдәбану Гарифулла кызы), Әмирҗан (10.10.1925; анасы Сәгыйдәбану Гарифулла кызы).

Гали Әхмәтвәлиевне (25 яшь) һәм энесен (22) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында анасы (65) һәм икенче энесе (16) кала, 11,58 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була. Гали Вәлиевнең бер кызы Могтәбәрия (01.04.1925; анасы Бибиталига Шәйхеразый кызы) була, Ватан сугышы алдыннан хатыны Талига (1898), уллары Галинур (1927), Галиәкрәм (1930), кызлары Дарига (1939), Миңлезифа (1942) теркәлә. Хәниф Вәлиев (1900) сугышта һәлак була, хатыны Нурзидә (1906), балалары Мөзәянә (1926), Фәвәрис (1938), Мәвәзинә (1941) кала.

Габделфәезнең өченче улына күчик. Мулла Бәдретдин Габделфәез улы балалары: Гыйлемхан (1868), Әхмәтхан (1870), Казыйхан (07.06.1874), Сәрвиҗиһан (24.03.1877–20.08.1901), Афзалетдин (06.02.1880; анасы Шәмсеҗиһан), Газетдин (Гыйззетдин? 22.03.1883). Бәдретдин Фәезов 1917 елда хатыны (75 яшь), улы (37), ике оныгы һәм килене (35) белән яши, 14,0 дисәтинә җире, 4 аты, 3 сыеры һәм башка маллары була. Бәдретдин кызы Сәрвиҗиһан 1898 елның 3 декабрендә Сөякәйнең мөәзин Сибгатулла Төхфәтулла улы Рәхмәтуллов (37 яшь; дүртенче никах) белән никахлаша.

Имам Гыйлемхан Бәдретдин улы Азаматов 1892 елның 30 гыйнварында Иске Катайның Әхмәтгәрәй Мифтахетдин улының кызы Бибикәримә (18 яшь) белән кавыша. Шул ук Гыйлемхан (25 яшь; икенче никах) 1893 елның 16 февралендә авылдашы имам Габделҗәмил Мөхәммәтҗан улы Күчемов кызы Бибихәтимә (22 яшь) белән никахлаша, балалары Саимә (24.02.1894), Әкрәм (09.06.1895) туа. Гыйлемхан Бәдретдинов 1891 елдан Иске Куянда имам-хатип һәм мөгаллим вазифасын башкара. Ул 1868 елның апрелендә туган, Каран авылында мулла Нурлыгаян һәм Фәтхелбәян хәзрәтләр мәдрәсәсендә белем алган.

Әхмәтхан Бәдретдин улы Габделфәезов балалары: Шәрифҗан (1896), Сабирҗан (21.11.1898), Фәрхиҗиһан (19.07.1900; анасы Мәфтуха Габделмән Габделлатыйф улының кызы), Сәрвиҗиһан (03.01.1903–1905), Фәрхикамал (25.12.1904), Газизҗан (22.12.1906), Миңлекамал (08.12.1908–1909), Рәхимҗан (01.10.1910), Галимҗан (19.10.1912). Әхмәтхан Бәдретдиновның олы улын (20 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (43), ике

улы һәм ике кызы белән яши, 31,30 дисәтинә җире, җилгәргече, 4 аты, 3 сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче яллый. Шәрифҗан Әхмәтханов (1896) Ватан сугышында һәлак була, хатыны Бибикәримә Мослахетдин кызы (1906), кызлары Рәйсә (1929), Әнисә (1930), уллары Мәснәви (1932), Өлфәт (1938) кала. Мәснәви авылдашы Гыйндулла Нәбиуллин кызы Фәүханә белән гаилә кора, балалары Ринат (1958; химия фәннәре докторы), Рәмилә туа. Галимҗан Әхмәтханов – Ватан сугышы ветераны (Уфада милициядә эшләгән). Бу мәгълүматның бер өлешен Мәснәви абый Әхмәтхановтан сорашып белдем. Бабасы Әхмәтхан Бәдретдиновны «раскулачить» иткәннәрен дә өстәп әйтте.

Казыйхан Бәдретдин улы Азаматов балалары: Мәдхиҗиһан (24.01.1902; анасы Гыйльмисафа Нурмөхәммәт кызы), Соруржиһан (19.09.1904–1904), Мөхәммәтнәгыйм (15.11.1905), Бибинәкыя (09.06.1908), Гарифә (16.10.1910), Тәзкирә (07.08.1912–1913), Бибимәрьям (17.04.1914–1916). Совет чорында Казыйханның тагын кызлары Закирә (1924) белән Мәдинә (1931) туа, метрикәгә Гарифәнең 1962 елда загстан туу турында белешмә алуын язганнар. Мәдхиҗиһан 1925 елның 18 апрелендә нәселдәше Әбүнәгыйм Яруллин (1903) белән кавыша.

Афзалетдин Бәдретдин улы (25 яшь) 1902 елның 29 декабрендә Иске Катайның Бәдретдин Яхшыгол улының кызы Бибизәкия (18 яшь) белән никахлаша. Афзалетдин балалары: Мөшәррәфә (14.06.1906–1906; анасы Камышлыдан Мөкәррәмә Риян кызы), Мөнәвәрә (13.03.1908), Мөнирә (22.12.1910–1912), Мостафа (06.03.1914–1914), Хәдичә (24.07.1915). Афзалетдин исемлекләрдә Азаматов фамилиясе белән теркәлә, авыл советы кенәгәсендә сугыш алдыннан хатыны Бибисафа (1890), кызлары Мәдхия (1920), Мәгъсүмә (1922; тракторчы), Илһария (1924), Әминә (1931), Сәүдә, Җәүһәрия (1939), улы Габделхәй (1934) теркәлгән.

Дәүләтгир Габделфәез улы Азаматовның ир балалары: Муллаян (1867), Фәтхелбәян (1881), Нурлыгаян (1887–1961), Солтангәрәй (23.06.1894; анасы Майсорур Мөхәммәтшәриф кызы), Туангир (22.02.1899; анасы Шәмсебану Мөхәммәтҗан кыз). Дәүләтгирнең өч хатыннан кызлары: Бибифакия (1874), Мәрхәбә (18.08.1875), Мәргубә (10.09.1876; анасы Хәтирә), Миңлемөкәррәмә (17.12.1889; анасы Майсорур Мөхәммәтшәриф кызы), Бибимөшәррәфә (17.12.1889; анасы Шәмсебану Мөхәммәтҗан кызы), Мәрзия (1892), Миңлемәрьям (27.03.1894–1895; анасы Шәмсебану «типтәр» Мөхәммәтҗан Габделдаян улының кызы), Бибибәһия (1896), Мәликә (20.01.1897; анасы Майсорур Мөхәммәтшәриф кызы). Дәүләтгирнең бер елны (1889) һәм көнне (17 декабрь) ике хатыныннан берьюлы ике кызы тууы игътибарга лаек.

Дәүләтгир кызы Бибифакия (18 яшь) 1893 елның 12 гыйнварында нәселдәше Мөхәммәтхарис Ярулла улына (20 яшь) кияүгә бара. Икенче кызы Мәрзия 1909 елның 4 мартында Кадернең Гыйниятулла Фәйрузша улы (25 яшь; атасы Фәйруша Габидулла улы) белән никахлаша. Өченче кызы Бибибәһия (20 яшь) 1916 елның 19 ноябрендә авылдашы Хаҗиәхмәт Миңлегәрәй улы (25 яшь) белән кавыша. Дүртенче кызы Мәликә (18 яшь) 1917 елның 25 февра-

лендә Сеңрәннең Суфиәхмәт Миңлеәхмәт улы (40 яшь; икенче никах) белән гаилә кора. Кызның вәли вәкиле – агасы Фәтхелбәян Дәүләтгир улы, ризалык шаһитлары Солтангәрәй Дәүләтгир улы белән Мөхәммәтнәгыйм Ярулла улы була.

Муллаян Дәүләтгир улы Азаматов балалары: Әсма (15.09.1894; анасы Фәхерҗиһан Габделхаликъ Габделтаһир улының кызы), Мирзаҗан (26.11.1897–1915; анасы Фәхеркамал Габделхаликъ кызы), Дөрреләсма (01.10.1900), Гөлҗәүһәрә (08.08.1903; анасы Фәхерҗиһан Габделхаликъ кызы), Әмирҗәләл (02.04.1906–1915), Әһлия (25.01.1909), Мосаллия (06.08.1912), Муллагаян (1913–1917). Муллаян кызы Әсма 1912 елның 9 ноябрендә Килкабызның Хәсәнҗан Әхмәтша улы (28 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Муллаян Дәүләтгир улының (48 яшь) икенче никахы 1915 елның 19 мартында авылдашы Хәбибрахман мулла Әхмәтҗан улы Күчемов кызы Мөкәррәмә (30 яшь) белән була.

Фәтхелбәян Дәүләтгир улы (25 яшь) 1906 елның ноябрендә авылдашы Дәүләтгәрәй Мөхәммәтвәли улының кызы Бибифакия (17 яшь) белән никахлаша, балалары Әмиргаян (05.08.1908), Зәкия (19.12.1910), Миршәриф (19.07.1913), Закирә (29.06.1916; икенче мәхәллә) туа.

Нурлыгаян Дәүләтгир улы Азаматов Туктаголның Гөлмаһиҗиһан (Гөлмаһиҗиян) Шакир кызы (1894) белән никахлаша, балалары Сәкинә (27.08.1912), Тәгълимә (24.06.1915; яшьли вафат була), Рухылбаян (1918), Наҗия (1921), Мәгънәви (09.12.1925–1944), Әүхади (01.07.1929–12.06.2000), Фәния (1932) туа. Нурлыгаян Дәүләтгирев (чыганакта шулай язылган; 30 яшь) 1917 елда хатыны (25 яшь) һәм ике кызы белән яши, 1,03 дисәтинә җире, 3 сарыгы, 2 кәҗәсе була. Нурлыгаян Дәүләтов колхозда тимерче булып эшли. Нурлыгаян кызы Сәкинә Иске Катайның Муллагаян Ихсанов (1909) белән никахлаша. Икенче кызы Наҗия Корычкаранның Хәмзә белән кавыша. Өченче кызы Фәния Иске Катайның Габделбасыйр Мөхәммәтхафизов улы Габделзаһир (1925) белән гаилә кора.


**Нурлыгаян Дәүләтов**

Рухылбаян Иске Катайның Исламгали Әхмәтгали улының кызы Мәрьям (1921) белән никахлаша, балалары Әфтәх (1941), Зилә (1949), Зәйлә (1951), Бәния (1954), Риф (1957). Рухылбаян Нурлыгаян улы Дәүләтов – сугыш ветераны, сугышта сержант була, «Сугышчан хезмәтләре өчен» (20.11.1943), «Праганы азат иткән өчен» медальләре белән бүләкләнә. Кече лейтенант Мәгънәви Нурлыгаян улы Дәүләтов (1924–30.07.1944) сугышта һәлак була.

Әүхади Дәүләтов Иске Катайның Мөхәммәтдин Хафизов кызы Тәрҗимә белән никахлаша, балалары Нәвәзир (1952–2013), Фәнүзә (1954), Мәгънәви

(1957) һәм Нәүфилә (1967) туа. Ата-бабалары турында берникадәр мәгълүматны Нәүфилә Газетдинова (Дәүләтова) язып җибәрде.

Солтангәрәй Дәүләтгир улы белән Мәрьям Фәрхетдин кызы никахыннан Мөхәссәнә (28.05.1917) туа. 1943 елгы мәгълүматка караганда, Солтан Дәүләтовны (1894) Ватан сугышына алганнар, йортында хатыны Саҗидә (1891), анасы Майсорур (1860), кызлары Заһидә (1919), Мөхәссәнә (1922), Мәгъсүмә (1927), Илһамия (1932), уллары Мөбәрәкҗан (1930), Мәгъсүм (1940) калган. Солтан сугыштан исән-имин кайта, Мөхәссәнә – Газим Харисовка, Мәгъсүмә Зәкиҗан Латыйповка кияүгә чыга.

Югарыда без Габделфәез Габделкәрим улы Азаматов балаларына һәм оныкларына тукталып үттек. Габделкәримнең икенче улы Габделкадыйр (1800) иде. Габделкадыйр Габделкәрим улы ир балалары: Миндияр (1824), Галләметдин (1831), Минһаҗетдин (1835). Галләметдин уллары: Мослахетдин (1859), Имаметдин (1872), Сәлахетдин. Минһаҗетдиннең бер генә улы (Гыйлаҗетдин, 21.09.1874) билгеле.

Мослахетдин Галләметдин улы Азаматов балалары: Гыйльметдин (1889–1889; анасы Хәмдия), Әхкәметдин (12.04.1894; анасы Хәмдия Габделмәннаф Гаделша улының кызы), Гыйзаметдин (1900–1904), Бибизакирә (1903–1905), Нәгыймә (01.03.1906; анасы Хәерниса Садыйк кызы), Сания (12.12.1909; анасы Хәмдия Габделмәннаф кызы), Бибизакирә (1910–1910), Камилә (02.05.1913–1916; анасы Хәмдия). 21 яшьлек Әхкәметдин Мослахетдиновны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 212 нче Романов пехоты полкы составында сугыша, 1915 елның 30 ноябрендә һәлак була.

Имаметдин Галләметдин улы Азаматов (23 яшь) 1895 елның 15 ноябрендә Иске Катайның Әдһәм Мөхетдин улының кызы Хәкимә (18 яшь) белән никахлаша. Кияүнең вәли вәкиле – Могыйнетдин Галләметдин улы, ризалык шаһитлары Мослахетдин Галләметдин улы белән Бәдретдин Габделфәез улы була. Имаметдин балалары: Җәмгыйтдин (21.01.1898; анасы Хәкимә Әдһәм кызы), Йөзлебикә (29.05.1903; анасы Хәкимә), Бибиәсма (10.12.1905), Дөһөдия (14.04.1908–1916), Сәвия (05.01.1913–1917). Җәмгыйтдин Имаметдин улы Азаматовның Фатыйма Мөхәммәтхарис кызы белән никахыннан Мирһадетдин (01.11.1925) туа. Йөзлебикә Имаметдин кызы Азаматова (20 яшь) 1925 елның 12 февралендә Иске Катайның Әнгаметдин Исмәгыйль улы (26 яшь) белән никахлаша. Имаметдиннең энесе Сәлахетдин Галләметдин улы Азаматовның кызы Бибизакирә (30.06.1903; анасы Хәмдия Габделмәннан кызы) билгеле.

Габделкәрим Азаматовның дүртенче улы Габделлатыйфка тукталып үтик. Аның нәселен Җиһанша (1843–18.12.1908), Әхмәтша (1845), Мөхәммәдиша (1854) дәвам итә.

Җиһанша Габделлатыйф улы балалары: Хәсәнша, Хөснибану (1876), Сәгъдебану (1878), Шәмсеруй (1880–1904; анасы Гыйльмебану Габделхәким кызы), Хәсәннур (1882), Хөснеруй (1883). Җиһанша кызы Сәгъдебануны (17 яшь) 1895 елның 20 гыйнварында Балыклы авылы ясаклы татары Габдулла Хөснет-

дин улы Мусакаевкә (23 яшь) кияүгә бирә. Икенче кызы Хөснибану (21 яшь; икенче никах) 1897 елның 3 мартында авылдашы Муллаян Габделгани улы (30 яшь; дүртенче никах) белән никахлаша. Өченче кызы Шәмсеруй (19 яшь) 1899 елның 16 декабрендә Туктаголның Заһретдин Шәрәфетдин улы Нигъмәтуллов белән кавыша. Дүртенче кызы Хәсәннур (19 яшь) 1901 елның 4 маенда Байсарның Фәтхелислам Җәмгыйтдин улы Җоманголовка (34 яшь; өченче никах) икенче хатынлыкка бара.

Хәсәнша Җиһанша улы балалары: Шәмсеруй (01.09.1907), Мәрданша (19.07.1910; анасы Һидая), Рәкыя (20.01.1915–1916; анасы Һидая мишәр Шәрифулла кызы). Мәрданша Җиһаншин сугышка чаклы колхозда агротехник, кызлары Зәйтүнә (1938), Фәүдәнә (1939, яшьли вафат), Дөлфәнә (1941) була, сугыштан кайтмый (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Әхмәтша Габделлатыйф улы Азаматов балалары: Нургали, Нурлыгаян (1878–1903), Фәрхебану (1875), Майсорур (1880), Маһинур (1883), Әхмәтгали (14.10.1889; анасы Шәмсебану Габделгалим кызы). Әхмәтша кызы Фәрхебану (18 яшь) 1893 елның 14 октябрендә Иске Катайның Габдулла Габделгалләм улы (25 яшь) белән гаилә кора. Икенче кызы Майсорур 1898 елның 17 декабрендә Кадернең Миңлеәхмәт Гәрәйша улы (25 яшь) белән никахлаша. Өченче кызы Маһинур (18 яшь) 1901 елның 5 октябрендә шул ук авылның Сәлимгәрәй Мөхәммәтсадыйк улы Мөхәммәтгалиевкә (37 яшь; өченче никах) икенче хатынлыкка бара. Нургали Әхмәтша улыннан Хаҗгали (10.02.1898–1904; анасы Шәмсеҗамал Баһаутдин улының кызы) билгеле.

Әхмәтгали Әхмәтша улы балалары: Бибизәкия (25.03.1916–1916, ютәлдән вафат; анасы Гайникамал Нәҗметдин Мөхәммәтгали улының кызы), Гайнур (10.08.1917). Әхмәтгали Әхмәтшин 1940 елның декабрендә гаиләсе белән Бурят-Монголиягә чыгып китә, әмма 1941 елның февралендә кире әйләнеп кайта. Бу вакытта аның хатыны Гайникамал (1872), кызлары Гайнур (1923) белән Флүрә (1931) була. Гайнур Иске Катайның сугыш ветераны Тимергаян Гаязов белән гаилә кора.

Габделкәрим Азаматовның төпчек улы Мөхәммәтша иде. Мөхәммәтша уллары: Миңлегәрәй (1846–25.04.1911), Даут (1849), Сарман (1857), Сөләйман, Солтан, Сәүбән (соңгы икесе 1883 елгы метрикәдә нәсел тамгасын салганнар).

Миңлегәрәй Мөхәммәтша улы балалары: Миңлеәхмәт (1868), Фәрхинур (22.07.1877; анасы Бибифәрхебану), Әбуталип, Шәмсебану (1882), Шәмсенур (18.08.1889; анасы Фәрхиҗамал Камалетдин кызы), Солтангәрәй (04.09.1895; анасы Фәрхизиядә Габделгаффар Гыйбадулла улының кызы). Миңлегәрәй кызы Фәрхинур (17 яшь) 1895 елның 9 февралендә Килкабызның Миңлехәким Әхмәтҗан улы (27 яшь; егетнең вәли вәкиле – агасы Әхмәтнәби Әхмәтҗан улы) белән кавыша, өченче никахы 1905 елның 28 июнендә Сеңрәннең Гыйсмәтулла Хаммадулла улы (35 яшь; өченче никах) белән була. Шәмсебану (17 яшь) 1899 елның 18 февралендә авылдашы Әхмәтҗан Габделгани улы Габдрахманов (25 яшь) белән кавыша, бу никах барып чыкмый, 1904 елның

1 гыйнварында авылдашы Мөхәммәтхафиз Мөхәммәди (35 яшь; икенче никах) улына кияүгә чыга.

Миңлеәхмәт Миңлегәрәй улыннан Хуҗаәхмәт (09.01.1901; анасы Вәсфикамал Мөхәммәтлатыйф кызы) билгеле. Миңлеәхмәтнең (37 яшь) икенче никахы 1905 елның 15 ноябрендә авылдашы Сәригаскәр Миңлехан улының кызы Мәфтуха (17 яшь) белән була, балалары Миңлемөхәммәт (26.11.1909–1910) туа. Мәфтуха 1910 елда дөнья куя.

Даут Мөхәммәтша улы балалары: Сөләйман, Мәгъдәннур (21.11.1883), Бибимөкәррәмә (1888). Даут кызы Бибимөкәррәмә (18 яшь) 1906 елның 14 февралендә Үрмәтнең Акмалетдин Җәләлетдин улы (24 яшь; атасы Җәләлетдин Хисаметдин улы) белән никахлаша. Икенче кызы Мәгъдәннур (24 яшь; өченче никах) 1909 елның 2 декабрендә Учтымның Кәраметдин Гарифулла улы (25 яшь; икенче никах) белән кавыша. Кызның вәли вәкиле – атасы белән бертуган агасы Миңлегәрәй Мөхәммәтша улы, егетнеке атасы Гарифулла Кәлимулла улы була.

Сөләйман Мөхәммәтша улы Азаматов балалары: Фәрхиҗиһан (1887), Миңлешәмсеҗиһан (24.07.1889; анасы Миңлеҗамал Габдерәфикъ кызы), Мөхәммәтшакир, Шакирҗан. Сөләйман кызы Фәрхиҗиһан (18 яшь) 1905 елда Килкабызның Исмәгыйль Мөхәммәтбәшир улы (22 яшь) белән кавыша. Икенче кызы Шәмсеҗиһан 1908 елда авылдашы Әсәдулла Кәлимулла улы (25 яшь; Арсланбәк нәселеннән) белән никахлаша.

Азамат карт нәселдәшләренә 1816 елгы исемлектә күрсәтелгән Ишморат (1766–1833), Ишкуәт (1779) һәм Миңлебай (1785) Солтанморатовлар да керә. Солтанморат яшь булганлыктан, 1753 елгы документта теркәлмәгән, шуңа аның кемнән туганын фараз кылып кына әйтергә була. 1816 елгы исемлектә Азаматовлардан соң теркәлүен һәм нәсел тамгалары бер булуын күз алдында тотып, Солтанморат – Азаматның туганы (энесе), Дәүәти улы, дигән фикергә килдем (бу юлларны авылдашым Салават Госмановның «Солтанморатның атасы кем булган?» дигән соравына җавап итеп язам). Солтанморат улларының һәрберсенә аерым тукталып үтик.



**Китап авторы Салават Хаҗиәкрәм улы Госманов белән. 2018 ел**

Ишморатның олы улы Мөхәммәтәмин 1818 елда 26 яшьтә вафат була, нәселне аның улы Мөхәммәткәрим (1820–01.11.1895) дәвам итә. Ишморатның икенче улы Кәлимулла (1797–20.11.1875) булып, Кәлимулладан Шәрәфетдин хаҗи (1824–16.08.1911) билгеле. Катайдан хаҗга баручы шул бер Шәрәфетдин генә була, башка беркемнең дә хаҗи дип язылганы юк.

Мөхәммәткәрим Мөхәммәтәмин улы балалары: Мөхәммәтшәриф (1844), Хуҗагали (1880), Һидая (1887). Мөхәммәткәрим кызы Һидая (17 яшь) 1904 елның октябрендә Иске Катайның Шәехзаман Вәлиәхмәт улы (икенче никах) белән никахлаша, кызның туганы Хуҗагали Мөхәммәткәрим улы ризалык шаһиты була.

Хуҗагали Мөхәммәткәрим улы балалары: Гакифә (05.04.1906; анасы Кәшифә Низаметдин кызы), Кашшафгали (08.11.1907), Шәйхелгали (28.10.1909–1913), Мөхәммәтгали (12.01.1912), Шагали (07.02.1914), Сәетгали (19.12.1916), Мәдинә (1917), Зөлфия (25.11.1925). Хуҗагали Мөхәммәткәримовны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (30 яшь), ике улы һәм өч кызы кала, 1917 елда 13,59 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче тота. Хуҗагали Кәримов Ватан сугышына чаклы колхозда умартачылык тармагын җитәкли, улы Шагали комбайнда эшли. Бертуган Кашшафгали белән Шагали Кәримовлар Ватан сугышында һәлак булалар.

Ишкуәтнең олы улы Ибнеямин (1830 елда 32 яшьтә вафат) белән икенчесе Миңлеярдан (1800) нәсел калмый. Ишкуәтнең (метрикәдә Ишморат) өченче улы Миңлегол (1811–16.05.1889) була, Миңлеголдан нәселне Әбүбәкер (1844), Гомәр (1847–1925) һәм Шәйхелислам (1857) дәвам итә.

Әбүбәкер Миңлегол улы балалары: Гарәфетдин (24.04.1876; анасы Миңлеҗиһан), Сәрвәрҗиһан (1877–1877), Гыйздетдин (1879–1904), Зәкия (1888), Исламетдин (25.08.1889; анасы Миңлеҗиһан Баһаутдин кызы). Әбүбәкер кызы Зәкия 1905 елда авылдашы Шәйхелислам Шәймәрван улы Нөрмәтов (26 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Исламетдин Әбүбәкер улы балалары: Миңлефәүзия (10.02.1915–1915; анасы Мәгъшукҗиһан Баһманша кызы), Зыятдин (25.03.1916–1916, бума зәхмәтеннән вафат).

Гомәр Миңлегол улы Ишкуәтовның башка балалары: Госман (1870), Госмангали (1874), Исламгали (1881), Бибиталига (21.11.1883), Бибисафура (1886), Бибиталига (1888), Әхтәмгали (03.01.1889; анасы Мәзхүрә), Әхмәтвәли (1892), Бибигакифә (05.05.1894; анасы Мәзхүрә Хәлилулла Хәбибулла улы Мортазин кызы), Әхмәтгали (1896), Миңлегали (25.02.1899; нәсел фамилиясе Ишкуәтов), Габделгали (11.07.1901), Хуҗагали (05.03.1904), Миңлегарифә (22.08.1906). Гомәр кызы Бибисафура 1903 елның гыйнварында Корычның Ярмөхәммәт Динмөхәммәт улы белән никахлаша. Икенче кызы Бибиталига (17 яшь) 1906 елның 16 июнендә Балыклының Вәлиулла Галиулла улы (22 яшь; атасы Галиулла Фәтхулла улы) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары туганнары Госман белән Госмангали Гомәр уллары була. Гомәр Миңлеголовның өч улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (56 яшь), калган өч улы һәм кызы (9) белән яши, 12,49 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була.

Госман Гомәр улы Миңлеголов (Ишкуәтов) балалары: Фәрхинур (1894), Фәрхисорур (17.11.1897; анасы Сәрмәдия Вәлиәхмәт кызы), Әхмәтнәгыйм (20.07.1900), Әбүнәгыйм (16.06.1903), Шәмсесорур (18.09.1906; анасы Сәрмә-

дия Вәлиәхмәт кызы), Мөхәммәтзәки (18.01.1913; анасы Сәрмәдия), Әбәдия (09.12.1916). Госман кызы Фәрхинур 1911 елда Иске Дөмәйнең Гыйлаҗетдин Бәдретдин улы (19 яшь) белән никахлаша. Фәрхинур ирдән аерылып, 1912 елның гыйнварында Сеңрәннең Габделкаюм Бикмөхәммәт улы (30 яшь; икенче никах) белән кавыша. Шул елны ук ирдән кайтып, 4 декабрьдә 24 яшьлек Туктагол егетенә кияүгә чыга. 1914 елның 28 июлендә авылдашы Гыйлаҗетдин Шәйхетдин улы (40 яшь) белән Фәрхинурның дүртенче никахы теркәлә. Госман Гомәров 1917 елда хатыны (45 яшь), өч улы һәм дүрт кызы белән яши, 4,76 дисәтинә җире, икешәр аты, сыеры һәм башка маллары була.

Әхмәтнәгыйм Госманов – сугыш корбаны, хатыны Габидә (1902), кызы Халә (1924) кала. 1943 елның 7 маена караган хәрби документта болардан тыш улы Зәки (22 яшь) хакында да язылган. Халә Иске Катайның Заһит Нәбиевкә кияүгә чыга.

Әбүнәгыйм нәселдәше Муллаян Нигъмәтулла улының кызы Фәүзия (1907) белән никахлаша, балалары Фәния (1929), Мөхәммәтнәгыйм (1932–30.12.2001), Малих (1938), Мәкки (1941), Зәки (1943) туа. Әбүнәгыйм 1945 елның 23 февралендә һәлак була.



Ватан сугышы корбаны
Әбүнәгыйм Госманов

Мөхәммәтнәгыйм Госманов авылдашы Хәйдәр Мифтахов кызы Вәзимә (19.02.1931–18.02.2001) белән гаилә кора, балалары Рәмилә (11.07.1956), Хәмит (20.10.1957; Уфа авиация институтын тәмамлый), Рузилә (16.12.1960), Илшат (29.08.1965) туа. «Абый – Чаллыда (пенсиядә; энергетик булып эшләде), апам – Корычта (бухгалтер булды), мин – Уфада (УМПО да эшләдем), Илшат авылда яши», дип язып җибәрде Рузилә Госманова. Аңа чаклы өлешчә мәгълүматны Рәисә апа Газимова язган иде.

Мөхәммәтзәки Госманов – Ватан сугышы ветераны (бер аягын өздереп кайта). Мөхәммәтзәки нәселдәше Габдулла Төхвәтов кызы Сәүдия белән гаилә кора, балалары Әҗерия (Яркәйдә яшәгән), Вәкил, Габделхәй, Фәрит, Согъдә туа.

Госмангали Гомәр улы балалары: Хаҗгали (28.03.1905; анасы Мәрхәбә Габделнасыйр кызы), Нәгыймә (08.06.1909–1914), Әхмәтзакир (15.07.1913; анасы Мәрхәбә Габделнасыйр кызы), Хәйдәргали (26.06.1916; анасы Мәрхәбә). Госмангали Гомәровны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (35 яшь) һәм өч улы кала, 1917 елда 1,54 дисәтинә җире, кәҗәсе, сыеры була. Хаҗгали Госманов (1905) 1941 елның 14 июлендә Ватан сугышына китә, хатыны Талига (1905), балалары Хаҗиәкрәм (1930–2014), Наилә (1933), Әбелкәрам (1942) кала. Хаҗиәкрәм Госманов белән Әфудә Мәрдан кызы балалары: Салават (1954), Әлфинә (1956), Флүзә (1958).

Исламгали Гомәр улы (26 яшь) 1907 елның ноябрендә Иске Катайның Габделбаян Габделгалләм улының кызы Бибихәмидә (18 яшь; Юлдаш нәселеннән) белән никахлаша. Егетнең ризалык шаһитлары Сәхипгәрәй белән Әхмәтгәрәй Ибнехаҗип уллары була. Бу никахтан Исламгали балалары (беренче мәхәллә): Мөхәммәтгали (12.10.1908), Хәнифә (03.04.1911), Мөхәммәтнәби (24.11.1913–1914), Кашшафгали (10.11.1915), Әсхия (1921), Шәмсегали (1926–2008), Газимә (1932). Исламгали Гомәровны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда йортында хатыны (30 яшь), ике улы һәм кызы кала, 1917 елда 2,14 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була. Кашап Исламов шофер ярдәмчесе булып эшли, 1940 елда хәрби хезмәткә чакырыла, 1941 елның ноябрендә сугышта хәбәрсез югала. Шәмсегали Исламов сугыштан кайткач, авылдашы Исламгали Мәннапов кызы Дөррия белән гаилә кора, балалары Фәнирә (1951), Тәнзилә (1953), Сәмига (1955), Әнфәл (1956), Рафаэль (1957) туа.

Әхмәтвәли Гомәр улы балалары: Шәйхелгали (29.11.1914; анасы Кафия Һибәтулла кызы), Мөхәммәтвәли (09.02.1917), Ниһая (03.10.1925). Әхмәтвәли Гомәровны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны һәм улы кала, 1917 елда 1,29 дисәтинә җире, сыеры була. Авыл советы кенәгәсендә Әхмәтвәли гаиләсендә 1943 елда хатыны Фәрхиҗамал (1898), уллары Мөхәммәтвәли (1917; сугышка китә), Хәмзә (1933), Әбелгавис (Әбелгас; 1936), Хәнәфи (1940) һәм бер кызы теркәлгән.

Әхмәтгали Гомәров (1896) колхозда төзелештә (балта остасы) эшли, 1942 елның 19 гыйнварында сугышка китә, хатыны Гайшә (1897), балалары Тимергали (1928), Тәкмилә (1937), Рәзинә (1938) кала.

Хуҗагали Гомәров (1904–1972) – Ватан сугышы ветераны, сугышка киткәндә хатыны Нәгыймә (1901), ике улы (берсе Зөфәр, 1940) була. Алар да сугыш алдыннан Бурят-Монголиягә чыгып киткәннәр, ахры, 1940–1942 елларда читтә яшиләр. Хуҗагалидән авылда кемнәр калган дип сорагач, Зөфәр, Зөфәрдән Фирдәвес Гомәров, дип әйттеләр.

Шулай итеп, Миңлеголның Әбүбәкер һәм Гомәр исемле улларыннан нәсел бүгенге чорга чаклы дәвам итә. Аның өченче улы Шәйхелислам 1903 һәм 1905 елгы метрикәләрдә телгә алына, тик балалары турында бернинди мәгълүмат бирелми.

Ишкуәтнең кече улы Ибнехаҗип (1815) нәселен уллары Якуп (1847–25.07.1906), Исхак (1859), Әхмәтгәрәй (1862), Сәхипгәрәй (1868) дәвам итә. Ибнехаҗип кызы Гарифә (20 яшь) 1877 елның 10 гыйнварында Минзәлә өязе Чуракай авылының Шәймәрдан Җамалетдин улы (22 яшь; атасы Җамалетдин мулла Вәлиша улы) белән гаилә кора.

Якуп Ибнехаҗип улы Ишкуәтов балалары: Фәхерниса (1880), Миңлесылу (1887), Галихан (19.07.1889–1898; фамилиясе Ишморатов), Гыйлемхан (27.06.1893; анасы Зәйниса; фамилиясе Азаматов), Миңлехан (16.11.1897). Якуп кызы Фәхерниса 1898 елның 16 октябрендә Әмәкәйнең Фазлыәхмәт Шәяхмәт улы (40 яшь; икенче никах) белән кавыша. Әлеге иреннән аерылып, Фәхерни-

са 1899 елның 25 августында Килкабызның Яхъя Әүдияр улы (23 яшь; өченче никах) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары нәселдәшләре Гомәр Миңлегол улы белән Галләметдин Җамалетдин улы була. Якупның икенче кызы Миңлесылу 1904 елның 15 октябрендә Яңа Күктауның Габделфазыйл Каһарман улы (22 яшь) белән гаилә кора.

Гыйлемхан Якуп улының Зәкия Шәрәфетдин кызы белән никахыннан Кыйделҗан (07.10.1925) туа. Гыйлемхан Якупов (1892) – Ватан сугышы ветераны, сугышка киткәндә гаиләсендә хатыны Хөсниҗамал (1910), балалары Мәгъдәния (1921, хәрби хезмәттә), Гыйльмизиян, Сәхия (1930), Гыйльфан (1942) була.

Балта остасы Миңлехан Якупов 1942 елның 23 февралендә сугышка китә, кавалерия дивизиясе составында шул ук елның 28 ноябрендә һәлак була. Хатыны Зәкия (1891), уллары Фәйзелхан (1931), Тимерхан (1933), кызы Сәдәвия (1940) кала. «Үткәннәрен бел Катайның» китабындагы хатаны төзәтәбез: 78 нче биттәге өстәге фоторәсемдә Фәез Нәбиевтән соң өченче кеше булып (иң кырыйда) Тимерхан Якупов басып тора (бу хакта 2018 елда аның улы Равил (1960) әйтте).

Әхмәтгәрәй Ибнехаҗип улы Ишкуәтов балалары: Хәдичә (02.08.1895), Дәүләтгәрәй (1897), Нәгыймә (14.07.1898), Мөхәммәтгәрәй (22.03.1901–1904; анасы Мәүдүдә Мифтахетдин кызы), Кифая (19.07.1904). Әхмәтгәрәй Хаҗиповның улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (45 яшь) белән яши, 9,30 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була. Әхмәтгәрәй кызы Хәдичә 1914 елның 20 февралендә Яңа Күктауның Тимергази Гарифулла улы (23 яшь) белән кавыша. Дәүләтгәрәй Әхмәтгәрәй улы сугыштан кайткач, 1917 елның 5 ноябрендә авылдашы Камалетдин Тәхаутдин улының кызы Бибихәмидә (19 яшь) белән никахлаша. Кияүнең ризалык шаһитлары нәселдәшләре Әхмәтвәли Гомәр улы белән Нургали Равил улы була.

Сәхипгәрәй Ибнехаҗип улы Ишкуәтов балалары: Хәтимә (1896), Бибикамилә (03.12.1897; анасы Шәмсекамал Әхмәтҗан кызы), Хәкимә (28.06.1900–1916), Сәетгәрәй (03.05.1902–1904), Сәлимгәрәй (10.09.1904), Солтангәрәй (12.02.1907), Нәгыймә (06.03.1913; анасы Шәмсекамал), Камилә (23.10.1915–1916), Сания (11.07.1917). Сәхипгәрәй кызы Хәтимә Тыпыйның Әбүбәкер Равил улы (24 яшь; атасы Равил Габделнасыйр улы) белән никахлаша. Сәхипгәрәй Хаҗипов 1917 елда хатыны (35 яшь), өч улы һәм ике кызы белән яши, 5,14 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры һәм башка маллары була.

Ишкуәттән киткән тармакны карауны тәмамлап, аның энесе Миңлебай Солтанморат улына күчәбез. Миңлебай уллары Әхмәди (1811) һәм Шаһимәрдан (1834) булып, Әхмәдидән нәселне Әхмәтша (1841–08.08.1903), Мәрданша (1844–28.03.1912), Фәрукша (метрикәдә Фәррахша; 1852) дәвам итә.

Әхмәтша Әхмәди улы Азаматовның ике хатыннан балалары: Гайнанша (1867), Мәйсорур (1878), Мөхәммәдиша (1882), Гәрәйша (13.02.1883; анасы Фаизә), Гыйззенур (1884), Фәрхенур (1887), Муллаәхмәт (15.10.1895; анасы Шәм-

серуй Нигъмәтулла Гобәйдулла улының кызы), Маһинур (19.07.1901–1904). Әхмәтшаның хатыны Шәмсеруй нәселдәше Нигъмәтулла Гобәйдулла улы Азаматов кызы була, аларның никахлары 1894 елның 24 октябрендә теркәлә. Әхмәтша кызы Мәйсорур 1895 елның 10 гыйнварында Килкабызның Әбелхәер Әхмәтҗан улы Риянов (23 яшь) белән кавыша. Икенче кызы Гыйззенур 1901 елның 6 гыйнварында Корычның Насыйбулла Хәйрулла улы (23 яшь; атасы Хәйрулла Сибгатулла улы) белән никахлаша. Өченче кызы Фәрхенур 1904 елның гыйнварында Баекның Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтсабит улы (23 яшь) белән гаилә кора.

Гайнанша Әхмәтша улы Ишморатов балалары: Бибигазимә (08.10.1889), Миңлеһидая (1892–1893), Фатыйма (1893), Миңлекәримә (22.11.1894; анасы Камилә Гарифулла кызы), Мөхәммәтша (04.05.1898), Миңлерәхимә (04.10.1901), Рәйфә (26.07.1905). Гайнанша 1910 елның 9 гыйнварында кызы Фатыйманы (17 яшь) Иштирәкнең Әхмәтзариф Заһидулла улына (25 яшь) кияүгә бирә. Кызның ризалык шаһитлары Фәррахша Әхмәди улы белән Саяфетдин Җамалетдин улы була. Миңлекәримә 1915 елның 12 мартында Туктаголның Исламгали Гыймаделислам улы (22 яшь) белән никахлаша. Гайнанша Әхмәтшинның ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда ике хатыны (35 һәм 40 яшьләрдә), төпчек улы һәм 2 кызы белән яши, 18,17 дисәтинә җире, җилгәргече, 3 аты һәм башка маллары була.

Мөхәммәдиша Әхмәтша улының кызы Галия (01.03.1914; анасы Гайниҗамал Нәҗметдин кызы) була. Мөхәммәдишаны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (27 яшь) һәм кызы кала, 1917 елда 4,50 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм сарыгы була.

Мәрданша Әхмәди улы Азаматов балалары: Шәймәрдан (1870), Шәмсениса (1875), Хәмдениса (13.09.1878–1903). Мәрданша кызы Шәмсениса (19 яшь) 1895 елның 10 гыйнварында авылдашы Галиулла Фәйрузша улы Габидуллин (27 яшь; Арсланбәк нәселеннән) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Шәймәрдан Мәрданша улы белән Фәррахша Әхмәди улы була.

Шәймәрдан Мәрданша улы белән Бибисафа (атасы Әхмәтнәби Мөхәммәтшәриф улы) балалары: Галимәрдан (01.01.1895), Шәйхелмәрдан (13.11.1897–1898). Бу хатыны вафат булгач, Шәймәрдан 1901 елның февралендә авылдашы Фәрхетдин Камалетдин улының кызы Миңлебану (17 яшь) белән кавыша, беренче мәхәлләдә балалары Гыйльмебану (20.02.1904), Гыйльмиҗиһан (03.11.1906), Шәехмәрдан (22.04.1909), Фәрхиҗиһан (01.01.1912), Миңлеҗиһан (01.07.1914), Сорурҗиһан (08.03.1917) туа. Шәймәрдан Мәрданшинның олы улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (30 яшь), төпчек улы, биш кызы һәм анасы (70) белән яши, 9,30 дисәтинә җире, аты була.

Фәррахша (халыкта Фәрукша) Әхмәди улы Азаматов балалары: Гөлҗиһан (1877), Гайниҗиһан (15.12.1878), Гайниҗиһан (1886), Фәрхиҗиһан (1888), Хәсәнша (13.08.1889; анасы Фәхерҗиһан Габделхәбир кызы), Бибиҗиһан (05.08.1889; анасы Шәмсеҗиһан Хәлилулла кызы), Миңлеҗиһан (06.10.1893;

анасы Шәмсеҗиһан Хәлилулла Галикәй улының кызы), Гыйльмиҗиһан (1894), Гыйлемхан (03.11.1898), Гыйлемҗан (20.08.1902), Гарифҗан (04.01.1905), Рәхимҗан (03.09.1908), Шәрифҗан (22.09.1910), Шакирҗан (26.12.1914–1915; анасы Шәмсеҗиһан). Фәррахша кызы Гөлҗиһан 1897 елда Минзәлә өязе Әлмәт авылының Миргалим Җиһангир улы Нигмәтуллов (24 яшь; атасы Җиһангир мулла Вәлимөхәммәт улы) белән никахлаша. Икенче кызы Гайниҗиһан 1903 елның 29 октябрендә авылдашы Мөхәммәтнасыйп Хөснетдин улы (25 яшь) белән гаилә кора. Өченче кызы Фәрхиҗиһан (17 яшь) 1906 елның 10 февралендә авылдашы Габдулла Шәйхетдин улы белән кавыша. Төпчек кызы Гыйльмиҗиһан (20 яшь) 1914 елның 15 апрелендә авылдашы мөәзин Габделкаюм Габделлатыйф улына кияүгә чыга. Фәррахша (чыганакта Фәрукша) Әхмәдиев 1917 елда хатыны (46 яшь), дүрт улы һәм ике кызы белән яши, 16,47 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була.

Монда бер искәрмә ясап үтик. Фәррахша белән Фәрухша «шат, сөенеч» дигән бер мәгънәне аңлаткан исемнәр. Шуннан чыгыптыр инде, халык метрикәдәгечә Фәррахша диясе урынга, Фәрукша дип тә әйтә. Билгеле, бу буталчылык тудыра, кемдер Фәррахшаны Фәрукша дип кенә белсә, аның балалары Фәрукшин фамилиясендә генә теркәлергә тиеш, дип уйларга мөмкин. Бу очракта исә Фәррахша балалары Фәррахов фамилиясендә дөрес теркәлгәннәр, түбәндә аларның берничәсенә тукталып үтәбез.

Гарифҗан Фәррахов (1905) – Ватан сугышы ветераны, сугышка чаклы хатыны Сәкинә (1909), кызлары Әнүдә (1939), Әлфәридә һәм улы белән яши. Рәхимҗан Фәррахов (1908) Ватан сугышында һәлак була, гаиләсендә хатыны Хәтимә (1910), кызы Фәнүдә (1938), уллары Фәнис (1940) һәм Фәнәви (16.01.1942) кала. Шәрифҗан Фәррахов (1910) – Ватан сугышы ветераны, сугыш алдыннан гаиләсендә хатыны Идая (1911), балалары Әминә (1933) һәм Хәбибҗан (1938) була.

Азаматның төпчек улы Мәдияр иде. Мәдиярнең улы Габделҗәлил (1780) була, Габделҗәлилдән нәселне Җамалетдин (1812), Гыймадетдин (1821–20.04.1875) һәм Тәхаутдин (1825–24.01.1899) дәвам итә.

Җамалетдин Габделҗәлил улы балалары: Фәттахетдин (1845), Мифтахетдин (1858), Шәмсиҗамал (1860), Галләметдин (1862), Саяфетдин. Җамалетдин кызы Шәмсиҗамал (17 яшь) 1878 елның 19 гыйнварында авылдашы Бәхетгәрәй Мөхәммәтгәрәй улы (28 яшь) белән никахлаша.

Фәттахетдин Җамалетдин улы Азаматов балалары: Гайникамал, Мөхәммәтзакир (03.02.1873), Сәрвиҗиһан (1875–1902), Бәдриҗиһан (1887), Мөхәммәтдин (17.01.1889; анасы Хәбибҗамал Зәйнелбәшир кызы), Миңлемөхәммәт (1890–1898), Бибисаҗидә (02.02.1895), Миргасыйм (10.01.1898; анасы Хәбибҗамал Габделбәшир кызы), Әхияретдин (17.02.1902; анасы Хәбибҗамал Габделбәшир кызы). Фәттахетдин кызы Гайникамал 1877 елның 10 февралендә Сеңрәннең Камалетдин Шәйхетдин улы (50 яшь; икенче никах) белән кавыша. Икенче кызы Бәдриҗиһан (18 яшь) 1906 елның гыйнварында Тыпыйның

Шәйсолтан Әюп улы (23 яшь; атасы Әюп Хисаметдин улы) белән кавыша. Метрикәдә Әхияретдиннең 1939 елда загстан туу турында таныклык алуы теркәлгән, язмышы билгесез.

Фәттахетдин улы Мөхәммәтдин Факиягә (1894) өйләнә, аннан Әнвәретдин (1926–2019), Әгъзаметдин (1931), Фәрит (1940), Тәрҗимә (1928), Мәгъзүрә (1933) туа. Әнвәретдин Фәттахов Гөлрух (1928; Кызыл Бүләкнеке) белән гаилә кора, балалары Әбүзәр (1952), Габделбәр (1957), Илдар (1961), Диләрә (1963), Гөлирә (1965) туа. Илдар белән Диләрә (ире Госманов Камил Әхәт улы) Катайда яши, калганнары читтә. Мәгъзүрә (1933) Иске Катайның Җәмигънур Шәйнур улы Нургалиев белән кавыша, балалары туа.

Әнвәретдин Фәттахов Катайда яшәүче соңгы сугыш ветераннарының берсе булды. 2018 елның августында ул авырый, сораштырырлык хәлдә түгел иде. Хатыны Гөлрух апа әйтүенчә, ул илне нефть белән тәэмин иткән Бакуны саклауда катнашкан, җиде ел ярым шунда каравылда торган, соңыннан гына сугышта катнашканнар исемлегенә керә.

Имам Мөхәммәтзакир Фәттахетдин улы Азаматов (27 яшь) 1899 елның 26 ноябрендә Иске Катайның Әхмәтгәрәй Мифтахетдинов кызы Сәрвәрия (18 яшь) белән никахлаша, балалары Фәүзия (17.11.1900), Хәсәнгата (24.01.1902), Әмирҗан (30.07.1904), Әсхия (22.04.1907), Мирсәет (26.02.1909; икенче мәхәллә), Мәлих (1910–1912), Суфия (03.07.1913), Мирзаһит (1919; сугышта «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләнә) туа. Хәсәнгата 1933 елда загстан туу турында белешмә ала, язмышы билгесез. Өстәп шуны әйтик, Мөхәммәтзакир Тыпыйда Әхмәтвәли Миңлегали улы мәдрәсәсендә укый, 1899 елның 10 апрелендә Яңа Катайның икенче мәхәлләсенә имамлыкка указ ала, «Үткәннәрен бел Катайның» китабында Азаматов фамилиясе белән бирелә. 1922 елның 18 мартыннан имам вазифасын Чүмәлә Катайда башкара.

Галләметдин Җамалетдин улы Азаматов балалары: Шәмсеҗиһан (03.02.1889), Мифтахетдин (05.12.1890; анасы Хәсәнҗиһан Габдрахман кызы), Кашшафетдин (28.07.1894; анасы Шәмсеҗиһан Габдрахман кызы), Сәрвәретдин (12.02.1897; анасы Шәмсеҗиһан Габдрахман Габделҗәлил улының кызы), Шәмсекамал (10.02.1901), Афзалетдин (14.10.1904), Фәхретдин (22.11.1907). Галләметдин Җамалетдиновның өч улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны, ике улы һәм кызы белән яши, 9,29 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һәм башка маллары, җилгәргече була.

Саяфетдин Җамалетдин улы Азаматов балалары: Җәмгыйтдин (04.11.1894; анасы Бибизөһрә типтәр Нәҗметдин кызы), Зыятдин (15.02.1902; анасы Нурҗиһан Мөхәммәтвәли кызы), Хаятдин (1903–1905), Гыймазетдин (1905–1912), Хәйретдин (14.05. 1910–1914).

Габделҗәлилнең төпчек улы Тәхаутдин (1825–24.01.1899) иде. Тәхаутдин уллары: Җәләлетдин (1853–12.07.1914), Камалетдин (1856), Шәрәфетдин (1870), Бәдретдин. Тәхаутдин 1897 елның 17 июнендә Казан губернасы Казанбаш авы-

лының Мәхүпҗамал Габдулла кызы (76 яшь; дүртенче никах) белән никахлаша, бу аның өченче һәм соңгы никахы була.

Җәләлетдин Тәхаутдин улы Азаматов балалары: Газетдин (бер чыганакта Гаязетдин; 1882), Зәйнәп (1884–1894), Мәрьям (1890), Бибихаҗирә (1892–1894), Әхияретдин (1896–1898), Зәйнәп (16.03.1900; анасы Фәтхия Габдерәкыйп кызы), Рәкыя (26.04.1904–1917), Кәраметдин (30.07.1907), Рәшидә (1910–1911). Җәләлетдин кызы Мәрьям 1907 елда Корычның Галиулла Сафиулла улы (25 яшь) белән никахлаша.

Газетдин Җәләлетдин улы балалары: Әхкәметдин (17.11.1909–1916), Әкрәметдин (23.11.1911; анасы Мәгърифә Мөхәммәтгали кызы), Әнвәретдин (28.11.1913), Камил (18.03.1916–1916), Әгъләметдин (15.07.1917). Газетдин Җәләлетдиновны (35 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (25 яшь) һәм ике улы кала, 3,38 дисәтинә җире, аты, 5 сарыгы була.

Камалетдин Тәхаутдин улы Габделҗәлилов (Азаматов) балалары: Бибиҗиһан (1886), Бибикамилә (1887), Сәлахетдин (15.11.1889), Миңлекашшафетдин (25.02.1893), Галимә (06.09.1895), Бибихәмидә (26.07.1899; анасы Бибигайшә Шиһабетдин Хәйрелбәшир улының кызы), Кәримә (26.10.1901), Җәмгыйтдин (1904), Җамалетдин (30.03.1906), Имаметдин (25.05.1909–1910), Тәгълимә (11.02.1911). Камалетдин кызы Бибиҗиһан 1903 елның 5 гыйнварында Корычның Сираҗетдин Фәттахетдин улы (23 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Бибикамилә 1906 елның гыйнварында Кадернең Хәсәнша Мөхәммәтша улы (24 яшь; атасы Мөхәммәтша Габделбасыйр улы) белән гаилә кора. Төпчек кызы Бибихәмидә (19 яшь) 1917 елның 5 ноябрендә авылдашы Дәүләтгәрәй Әхмәтгәрәй улы (20 яшь) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары булып Шәрәфетдин Тәхаутдин улы белән Сәлахетдин Камалетдин улы теркәлә. Камалетдин Тәхаутдиновның 1917 елда 7,92 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры, сарыгы була.

Камалетдиннең Җәмгыйтдин исемле улы метрикәдә теркәлмәгән. Аның бу улы турында Катай авыл советы исемлегеннән беләбез. Җәмгыйтдин Камаев – колхозда бригадир, сугышка киткәндә хатыны Сәвия (1910), балалары Фаяз (1931), Ханә (1937), Габделхәмит (1938), Фәнис (1940), анасы Гайшә (1868), сеңлесе Тәгълимә (1911) була. Аның энесе Җамалетдин Камаев – завхоз, сугышка киткәндә хатыны Салиха (1912), балалары Өлфәт (1938), Хөснә (1939) була. Җәмгыйтдин һәм Җамалетдин Камаевлар – Ватан сугышы ветераннары.

Кашшафетдин Камалетдин улы 1913 елның 15 маенда авылдашы Һидиятулла Рәхмәтулла улының кызы Шәмгыя (18 яшь) белән никахлаша. Кашшафетдин һәм аның туганы Сәлахетдинне Беренче бөтендөнья сугышына алалар, язмышлары билгесез.

Шәрәфетдин Тәхаутдин улы Азаматов балалары (беренче мәхәллә): Бәдигылҗамал (07.12.1894; анасы Бибисәфирә Фәтхетдин Хәбибулла улының кызы), Гашия (05.05.1898–1901), Зәкия (18.07.1901), Фәүзия (12.02.1908–1909), Мосаллия (23.01.1910), Галимә (03.02.1913; анасы Сәфирә), Әгъзаметдин

(15.08.1916). Шәрәфетдин кызы Бәдигылҗамал 1914 елда Тыпыйның Шәймәрдән Шиһабетдин улы (23 яшь; атасы Шиһабетдин Фәхретдин улы) белән кавыша. Тагын бер кызы (Галимә) авылдашы Сафиулла Галиуллин (Арсланбәк нәселеннән) белән гаилә кора.

Бәдретдин Тәхаутдин улы Азаматов балалары: Гыйлаҗетдин (01.01.1893), Минһаҗетдин (12.02.1895; анасы Бибиҗиһан Нурмөхәммәт Нигъмәтулла улының кызы), Сәрвәрҗиһан (05.06.1897), Гыйльмиҗиһан (04.08.1900; анасы Бибиҗиһан Нурмөхәммәт кызы), Афзалетдин (06.05.1903; анасы Бибиҗиһан Мөхәммәди кызы), Фәрхиҗиһан (07.08.1905), Акмалетдин (20.03.1909–1910; анасы Бибиҗиһан Нурмөхәммәт кызы). Авылдашым Мөнәвир Мифтахов әйтүенчә, Гыйлаҗетдиннең кызы Саимә (1916) булып, ул Мөдәррис Мифтаховка кияүгә чыга. Афзалетдин Бәдретдинов (1903) сугыш алдыннан колхозда бригадир булып эшли, гаиләсендә хатыны Рәүдә (1907), кызлары Мөҗәһидә (1928), Фаягөл (1930), Тәнкидә (1938), уллары Фәһим (1932), Фәнис (1934), Фәрит (1940) була, сугыштан исән-имин кайта.

Алга таба сүз Азаматның 19 гасырда башлыча Мортазин фамилияле икенче мәхәлләдәге ерак нәселдәшләре турында барачак. Боларның ерак бабасы мулла Мерәс Габит улы һәм аның варисы Мортаза 1753 елгы документта телгә алына. Бу документта Мортаза Мерәс улы Азамат нәселенә хас тамга салган. Нәселнең әлеге тармагына караган кешеләр метрикәләрдә Мортазин фамилиясе белән бирелә, ул аларның нәсел фамилиясе. Ә бит бу вакытка Мортаза гүр иясе булганга ике гасыр чамасы вакыт үткән була.



**1753 елгы документ фрагментында Мортаза Мерәс улы тамгасы**

Мерәс Габитов – Катай муллаларының иң борынгысы, аңа чаклы кемнәр дин әһеле булган, моны ачыклап булмый. Мерәснең улы Мортаза булып, аннан нәселне Ает дәвам итә (ул 1816 елгы документта теркәлгән). Шәҗәрә схемасы түбәндәгечә:

Габит–Мерәс–Мортаза–Ает (1771) – Хәбибулла (1796) – Хәлилулла (1822–28.02.1898). Хәлилулла Хәбибулла улы балалары: Дәүләтгәрәй (1847), Әхмәтгәрәй (1849–16.09.1898), Солтангәрәй (1859), Солтангали, Мәзхүрә.

Дәүләтгәрәй Хәлилулла улы Мортазин балалары (икенче мәхәллә): Сәетгәрәй (1872–1904), Солтангәрәй (10.07.1874; анасы Гафия), Бибигафифә (1881), Дәүләтбай (20.06.1883; анасы Бибимәргыя), Хәсән (1905), Өммегөлсем (20.07.1909–1909; анасы Сәгыйрә Шәймәрдан кызы). Дәүләтгәрәй кызы Бибигафифә (18 яшь) 1899 елның 11 декабрендә Иске Катайның Хәйдәретдин Борһанетдин улы Габделвәлиев (25 яшь) белән никахлаша. Кызның

ризалык шаһитлары туганнары Сәетгәрәй белән Солтангәрәй Дәүләтгәрәй уллары була.

Дәүләтгәрәйнең 1905 елда туган улы Хәсән Катай метрикәләрендә теркәлмәгән. 1905 елда мондый исемле бер генә кеше туа, аның атасы Мөхәммәдиша Фәрукша улы Күчемов була. Метрикәләрдә яңа туган балаларның исеме теркәлмәү очраклары ара-тирә күзәтелә, монда мулла гаеплеме яисә башка сәбәпме, төгәл әйтеп булмый.

Атасы дөнья куйгач, 14 яшьлек Хәсән анасы белән Урта Азия якларына чыгып китә, поездда барганда анасы Сәгүрә (Сәгыйрә) вафат була. Үзбәкстанда 1936 елга чаклы яшәп, анда сату-алу эшләрендә зур тәҗрибә туплап авылга кайткач, кооперация буенча эшкә урнаша, сугышка чаклы Иске Катай кибете мөдире була. Сугыштан кайткач та, Мостафа, Маты авылларында сәүдә системасында эшли. Хәсән карт бик мөһим эш башкарган: Аетка чаклы бабаларының исемнәрен дөрес язып калдырган. Кызы Рузинә апа әйтүенә караганда, ул атасы Хәсәннең нәселдәше Шаһи (Шаһимөхәммәт Солтангәрәй улы) белән бергәләп бабаларын барлап утырганнарын, бу хакта сөйләшүләрен күргән-ишеткән. Хәсән абый язганнар кыска, нибары бер бит, шулай булуга карамастан, күп мәгълүмат бирә, кайбер уй-фикергә этәрә.

Хәсән Дәүләтгәрәев 1936 елда Наҗия Сәрвәретдин кызы (Күчем нәселеннән) белән гаилә кора, балалары Шамил (1937—1984; Яңа Маты совхозында баш инженер була), Румия (1939; Түбән Камада яши), Румидә (1942; Санкт-Петербургта яши), Рузинә (1946), Рәзилә (1949; Украинада яши), Рәмил (1952), Айрат (1959) дөньяга килә. Рузинә, Рәмил һәм Айрат Катайда яшиләр.

Сәетгәрәй Дәүләтгәрәй улы Мортазин 1894 елның 7 февралендә авылдашы Җәләлетдин Мөхәммәтсәлим улының кызы Хәерниса (17 яшь) белән никахлаша, балалары Бибинәгыймә (30.01.1898—1901; анасы Хәерниса Җәләлетдин Мөхәммәтсәлим улының кызы), Сәлимгәрәй (22.08.1900—1905), Мөхәммәтгәрәй (03.06.1903—1907) туа.

Солтангәрәй Дәүләтгәрәй улы Мортазин 1898 елның ноябрендә авылдашы Шәехшәвәли Миңлехан улы Нөрмәтов кызы Бибисара (17 яшь) белән никахлаша. Солтангәрәй балалары: Миңлехәким (17.07.1900; анасы Бибисара Шәехшәвәли кызы), Миңлегаффар (16.07.1901—1901), Бибикамилә (24.09.1903—1909), Әхмәтгәрәй (02.10.1905—1914), Шаһимөхәммәт (02.09.1908; анасы Бибисара), Мөхәммәтгәрәй (19.12.1910—1914), Сәвия (10.01.1914), Җәүһәрия (24.03.1925; анасы Саҗидә Фәттахетдин Азаматов кызы). Шаһимөхәммәт Солтан улы Дәүләтов (1908) — Ватан сугышы ветераны, сугышта пулеметчы була, «Батырлык өчен» (20.05.1945), «Сугышчан хезмәтләре өчен» медальләре белән бүләкләнә. Сугыш чоры документында Шәймөхәммәт Солтанов фамилиясе белән дә күрсәтелә.

Әхмәтгәрәй Хәлилулла улы (23 яшь) 1875 елның 15 февралендә авылдашы Шаһингәрәй Хәсән улының кызы Гайниҗамал (18 яшь) белән никахлаша. Әхмәтгәрәй балалары: Әхмәткәбир (1883), Мәрзия (1884), Миңлегалимә

(19.03.1890), Мөхәммәтшакир (1892–1910), Тәгъзимә (26.12.1894; анасы Фатиха Шәмсетдин Җамалетдин улының кызы). Әхмәтгәрәй кызы Мәрзия 1907 елда Иске Куянның Сафиулла Әсәдулла улына кияүгә чыга.

Әхмәткәбир Әхмәтгәрәй улы балалары: Миргабитҗан (25.11.1913–1914; анасы Зәкия Әсфәндияр кызы), Миңлемиргазиян (15.09.1915). Әхмәткәбирне Беренче бөтендөнья сугышына алалар, алга таба язмышы билгесез.

Солтангали Хәлилулла улы Мортазин балалары: Якутелҗинан (06.10.1894–1895), Мөхәммәтгали (27.06.1897; анасы Хәлимә Гайнулла кызы), Шәмсегали (09.11.1901; анасы Рәхилә Гайнулла кызы), Шәрифелҗинан (27.10.1905; анасы Рәхимә Гайнулла кызы), Фәхерҗинан (11.03.1909). Солтангали бер кызын 1909 елның 4 декабрендә Сеңрәннең Миңлегали Нигъмәтулла улына (25 яшь; икенче никах) кияүгә бирә. Кызның ризалык шаһитлары нәселдәшләре Әхмәткәбир Әхмәтгәрәй улы белән Солтангәрәй Дәүләтгәрәй улы була. Солтангали Хәлиловның олы улын (20 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (45 яшь), төпчек улы һәм ике кызы белән яши, 12,24 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры була.

Хәлилулланың энеләре Хәмидулла Хәбибуллин (1829) белән Шәрифулла Хәбибуллин (1842–27.03.1914) була. Хәмидулла Хәбибуллинның кызы Бибимәрфуга (1856) һәм улы Вәлиулла (1857) билгеле. Хәмидулла кызы Бибимәрфуганы (18 яшь) 1875 елның 3 гыйнварында Килкабызның Мөхәммәтнәфикъ Аллабирде улына (30 яшь; икенче никах) кияүгә бирә.

Шәрифулла (Шәрәфулла) Хәбибулла улы Мортазин балалары: Бибифатиха (1877), Гарифулла (02.12.1880), Габидулла, Шәргыя (1886), Бибифәргыйя (01.02.1890), Газизулла (01.09.1893; анасы Бибигайшә Шәймөхәммәт кызы), Нургизә (14.06.1899), Бәһия (25.07.1907; анасы Фәрхебану Арслан кызы). Шәрифулла кызы Бибифатиха (17 яшь) 1894 елның 29 ноябрендә авылдашы Шәрәфетдин Гыйлаҗетдин улы Күчемов (24 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Шәргыя 1903 елның 14 мартында Тыпыйның Мифтахетдин Мосифулла улы (30 яшь; икенче никах) белән кавыша. Төпчек кызы Нургизә 1916 елда авылдашы Миңлеәхмәт Миңлегәрәй улы (36 яшь; дүртенче никах) белән гаилә кора.

Гарифулла Шәрифулла улы балалары: Мөкәррәмә (23.12.1906–1909, кызамыктан; анасы Мөнәвәрә Кашшафетдин кызы), Шәрхемулла (26.04.1909–1914; анасы Мөнәвәрә), Тәгъзимә (18.02.1911; анасы Мөсәвәрә Кашшафетдин кызы), Мосифулла (18.08.1913–1916; анасы Мөнәвәрә Кашшафетдин кызы), Вәҗия (19.11.1925; анасы Бибиҗамал Әфләтун кызы).

Югарыда Мортазаның Аеш исемле улыннан киткән тармакны карадык. Мортазаның төпчек улы Гайнуллага (1790) күчәбез. Гайнулла Мортаза улы балалары: Галиулла (1815), Фәхрулла (1821) һәм Төхфәтулла (1837–28.06.1911).

Галиулла Гайнулла улы балалары: Шәмсевафа (1830–1900), Гыйззәтулла (1846), Гатиятулла (1853), Мәгъдәнҗиһан (1858), Гыйндулла (1859). Галиулла кызы Мәгъдәнҗиһан (17 яшь) 1875 елның көзендә Туктаголның Габдрахман Габделхаликъ улы (25 яшь) белән никахлаша.

Гыйззәтулла Галиулла улыннан бары Зиннәтулла (21.06.1883; анасы Бибикамал) билгеле. Гыйндулла Галиулла улы Мортазин балалары: Гыйльмиҗиһан (1890), Хәлфеҗиһан (1893–1893), Әхмәдулла (02.03.1895; анасы Фәрхиҗиһан Рәмкол Бурангол улының кызы), Миңлеҗиһан (27.01.1898), Сәрвиҗиһан (11.06.1900–04.06.1916, суга бата; анасы Фәрхиҗиһан Рәмкол кызы), Бибиҗиһан (22.07.1902), Соруржиһан (22.03.1905), Сылуҗиһан (07.07.1907), Сорурия (1909–1916). Гыйндулла кызы Гыйльмиҗиһан 1907 елның 11 ноябрендә авылдашы Гали Исмәгыйль улы (22 яшь) белән никахлаша.

Фәхрулла Гайнулла улы Мортазин уллары: Гатаулла (1849–1852), Заһидулла (Зәйдулла; 1853), Хәйрулла (1855), Хәбибулла (1871).

Заһидулла Фәхрулла улы Мортазин балалары: Рәхимҗан (1886), Бибихәнифә (11.06.1893), Бибигарифә (1896), Бибикафия (10.03.1897; анасы Бибифәриха Габделхаликъ кызы). Заһидулла кызы Бибигарифә (17 яшь) 1910 елның 2 декабрендә Туктаголның Яхъя Якуп улы (25 яшь; атасы Якуп Исмәгыйль улы) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Хәйрулла белән Хәбибулла Фәхрулла уллары була. Зәйдулла Фәхруллинның улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (60 яшь), кызы, килене (25 яшь) һәм оныгы (6 яшь) белән яши, 3,32 дисәтинә җире, аты, кәҗәсе була. Рәхимҗан Заһидулла улы балалары: Сабирҗан (06.05.1911; анасы Фәхерниса Шәфикъ кызы), Сабитҗан (16.12.1913–1914), Сәкинә (1916–1916).

Хәйрулла Фәхрулла улы Мортазин (өченче никах) 1894 елның 18 ноябрендә Иске Катайның Миңлегали Рамазан улының кызы Фәриха (18 яшь) белән никахлаша, балалары Бибиҗиһан (1888), Мәгъдәнҗиһан (1893), Газизулла (1897–1905), Габидулла (26.03.1900), Миңлефатыйма (04.08.1901–1906), Тимергази (16.04.1910), Миңлефакия (30.09.1914) туа. Хәйрулла кызы Бибиҗиһан (18 яшь) 1906 елның гыйнварында Камайның Минһаҗетдин Шәйхетдин улы (20 яшь; атасы Шәйхетдин Нигъмәтулла улы) белән кавыша. Икенче кызы Мәгъдәнҗиһан (17 яшь) 1910 елның 1 гыйнварында Тыпыйның Исламгәрәй Дәүләтгәрәй улы (25 яшь; атасы Дәүләтгәрәй Сәхаутдин улы) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары нәселдәшләре Хәбибулла Фәхрулла улы белән Мохтарулла Гафиятулла улы була.

Хәбибулла Фәхрулла улы Мортазин балалары: Габдулла (14.12.1894; анасы Миңлеҗамал типтәр Нәдергол Шәмгол улының кызы), Миңлеҗиһан (25.07.1900–1905), Вәлиулла (12.05.1903), Шәфигулла (08.02.1907–1907), Гыйльмиҗиһан (1909–1915), Гыйлемҗан (11.07.1910; анасы Миңлеҗамал Нәдергол кызы), Шәрхемулла (15.02.1913–1913), Сәгъдулла (11.11.1914–1915), Гыйльменур (15.02.1916–1916, кызамыктан вафат), Фәрхенур (04.06.1917). Хәбибулла Фәхруллинның бер улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (40 яшь), дүрт улы һәм кызы белән яши, 5,50 дисәтинә җире, аты, сыеры, 2 кәҗәсе була. Хәбибулла гаиләсе белән Чүмәлә Катайга күченә, анда аның улы Габдулладан оныклары (Бибинур (1925) һәм башкалар) дөньяга килә.

Гайнулла Мортазинның төпчек улы Төхфәтулла иде. Төхфәтулла Гайнулла улы балалары: Хөрмәтулла (10.12.1877), Хәсән белән Хөсәен (22.02.1890; аналары Фатыйма Рәхмәтулла кызы). 1895 елның 27 гыйнварында Төхфәтулла Гайнулла улы икенче тапкыр өйләнә, хатыны Иске Катайдан 18 яшьлек Миңлеәминә (атасы Габделвафи Габделвәли улы; Юлдаш нәселеннән) була, тик «араларында мәхәббәт вә өлфәт булмаган сәбәпле» шул ук елның 21 сентябрендә аерылашалар.

Мортазаның ике улы (Ает белән Гайнулла) турында халык санын алу документлары төгәл әйтсә, өченче улы Гали булуын метрикәләр раслый. Ает белән Гайнулланыкы кебек, Галинең варислары да метрикәләрдә Мортазин фамилиясе белән бирелә. Гали Аеттан берничә яшькә зуррак булган дип фараз кылабыз, чөнки, төп йорттан беренче булып бүленеп чыга һәм үз хуҗалыгын булдыра. Галинең уллары Габбәс (1779), Хәсән (метрикәдә Хәсәнгали; 1788–1830) һәм Хөсәен (1793) Галиевләр беренче тапкыр 1816 елгы документта теркәлә. Габбәснең ике улы яшьли мәрхүм була, варислары калмый. Аның энесе Хәсән үзеннән соң өч ир бала калдыра, Хөсәеннең дә варисы була.

Иң башта Хәсәннән дәвам иткән тармакны карыйк. Хәсән Гали улы балалары: Гыйсмәтулла (ревизия документында Хисмәтулла, 1820), Гафиятулла (1823–23.04.1897) һәм Шаһингәрәй (Шәнгәрәй; 1829).

Гыйсмәтулла Хәсән улы балалары: Хөснулла (1851), Сибагатулла (1854), Сәмигулла (10.08.1874; анасы Миңлебану), Шәмсебану, Сафиулла. Шәмсебану 1875 елда авылдашы Мөхәммәтзакир Мөхәммәтвәли улы белән никахлаша.

Хөснулла Гыйсмәтулла улы Мортазин балалары: Шәмсебәдәр (1880), игезәкләр Кәлимулла (21.06.1883–1897) белән Миңлебану (21.06.1883), Мәликәбану (1884), Габдрахман (1887), Шәмсекамәр (18.03.1894; анасы Хәдичә), Хәбибрахман (26.06.1897). Хөснулланың соңгы никахы Корычның Миңлеҗиһан Кәлимулла кызы белән була, 1913 елның 5 июлендә «араларында өлфәт вә мәхәббәт юклык сәбәпле» аерылышалар.

Хөснулланың барлык кызлары гаилә корып уңышлы гына яшәп китә алмыйлар. Шәмсебәдәр 1897 елда Кадернең Мөхәммәтвәли Мөхәммәтҗан улы (37 яшь) белән никахлаша. Өч тапкыр ирдән аерылгач, Шәмсебәдәр 1902 елның 14 июнендә Корычның Ильяс Мөхәммәт улы (27 яшь, икенче никах; атасы Мөхәммәт Үмербай улы) белән кавыша. Хөснулланың икенче кызы Мәликәбану 1903 елда Раҗетдин Хөснетдин улы (35 яшь) белән никахлаша, аннан аерылгач, 1905 елда Иске Балыклының Сәхипгәрәй Мортаза улы (25 яшь; икенче никах) белән гаилә кора. Хөснулла 17 яшьлек өченче кызын 1909 елның 4 мартында Килкабызның Әхияретдин Фәтхетдин улына (25 яшь) кияүгә бирә. Кыз кияүдә озак тормый, шул елның 22 октябрендә Камайның Нургали Габдрахман улы (35 яшь; икенче никахлары) белән кавыша. Шул ук Хөснулла беренче никахы уңышсыз булган кызын (Мәликә; 20 яшь) 1910 елның 19 июнендә Иске Балыклының Сәхипгәрәй Солтангәрәй улына (35 яшь; өченче никах) кияүгә озата.

Ирдән-иргә йөрүнең төп сәбәбе итеп шул ук метрикәләрдә мәхәббәт һәм өлфәт (хөрмәт) булмау дип күрсәтелә. Кыз бала үзенең күзе төшкән егеткә түгел, әти-әни кирәк тапкан кешегә барган, егет тә әти-әни хуп күргән кызга өйләнгән. Шуңа күрә метрикәләрдә ел саен берничә никах таркалу очрагы теркәлә, аларны махсус өйрәнеп тормадык, күз салып кына үттек.

Китабымның бу һәм башка бүлекләрендә әледән-әле никах таркалу очракларын күрсәтүнең сәбәбе шунда: патша чорын күз алдында тотып кайбер матбагаларда кияүгә барган икән, гомер буе барган җирендә яшәгән дип язалар иде. Алай булмаган икән, хатын-кыз бер генә түгел, хәтта берничә тапкыр ирен ташлап, туган нигезгә борчу-хәсрәт төяп кайткан.

Гаилә ныклы булсын өчен бер-береңә хөрмәт белән, аңлашып, юл куеп яши белү кирәк. Хәзер моның өчен барлык шартлар бар, әти-әни фатихасын алып, яшьләр үзләре, күңелләренә хуш килгән ярны сайлап гаилә коралар. Бәхетле гаиләләр күп, киләчәгебез ныклы һәм ышанычлы булсын!

Хөснуллага кайтыйк. Кызлары кебек, улы да ныклы гаилә кора алмый, ахры. Габдрахман Хөснулла улы 1912 елның 3 гыйнварында Иске Катайның Миңлекамал Нәдергол кызы (20 яшь) белән никахлаша, балалары теркәлмәгән. Башка никахтан бер кызы (Мәгъфүрә, 14.06.1917; анасы Мөкәррәмә) мәгълүм.

Гыйсмәтулла Хәсән улының нәселен тагын Сәмигулла дәвам итә. Сәмигулла берничә хатын белән гаилә корып карый. Беренче никахы таркалгач, 1899 елның 30 апрелендә Тыпыйның Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтдин улының кызы Гыйззеҗамал (22 яшь; өченче никах) белән кавыша. Сәмигулланың башка никахлардан балалары: Гыйниятулла (13.06.1902–1904; анасы Хәерниса), Миңлемәрьям (25.07.1915; анасы Бибиҗамал мишәр Фәтхулла кызы). 1905 елның 1 июнендә Сәмигулланың чираттагы никахы була, хатынлыкка Туктаголның Бибисара Динмөхәммәт Габделҗаббар улының кызын (18 яшь; икенче никах) ала.

Шулай итеп, Хәсән Гали улы Мортазинның беренче улы Гыйсмәтулла яклап гыйбрәтле гаилә-нәсел тарихларын күзәттек. Хәсәннең икенче улы Гафиятулла (1823–23.04.1897) балалары: Гарифулла (1847–08.06.1907), Шәрәфулла (1854), Мохтарулла (1857), Хөснулла, Сафиулла (1867), Сөнәгатулла, Җиһанбану (1862). Гафиятулла кызы Җиһанбану 1897 елда Иске Катайның Арслангали Мөхәммәтгали улы (40 яшь; өченче никах) белән никахлаша.

Гарифулла Гафиятулла улы Мортазин балалары: Сәгыйдәбану (1877), Вәлиулла (10.08.1880; анасы Гаделбану), Хөрмәтулла (1883–1898), Габидулла (06.09.1889; анасы Гаделбану Гали кызы). Гарифулла кызы Сәгыйдәбану (17 яшь) 1894 елның 10 декабрендә Иске Катайның Габделвахит Габделвафи улы Габделвәлиев (25 яшь) белән никахлаша. Габидулла Гарифулла улы (25 яшь) 1917 елның 28 гыйнварында авылдашы Сәлимгәрәй Дәүләтгәрәй улының кызы Мөнәвәрәгә (18 яшь) өйләнә. Кияүнең вәкиле атасы белән бертуган агасы Мохтарулла Гафиятулла улы була.

Шәрәфулла Гафиятулла улы Мортазин (Хәсәнов) балалары: Газизҗамал (1888), Насрулла (27.01.1893), Гөлҗамал (02.05.1895–1898; анасы Хәсбиҗамал

Камалетдин кызы), Миңлеҗамал (26.09.1897), Әһлиулла (13.07.1902–1902; анасы Хәбибиҗамал Камалетдин кызы). Шәрәфулла кызы Газизҗамал (18 яшь) 1906 елның декабрендә Иске Катайның Нурлыгаян Гаязетдин улы (25 яшь) белән никахлаша. Шәрәфулла Гафиятуллинның улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (60 яшь) һәм кызы белән яши, 3,20 дисәтинә җире, кәҗәсе була.

Мохтарулла Гафиятулла улы Мортазин (Хәсәнов) балалары: Шәмсеталига (04.06.1894–1895), Нигъмәтулла (01.06.1898), Һидиятулла (05.10.1900–1901), Хөрмәтулла (11.07.1902), Шәмсенәһар (20.03.1905), Гыйльмулла (10.04.1907), Сәгъдулла (27.12.1910; анасы Шәмсекамал Хөснетдин кызы), Сәүдә (11.07.1912–1914), Кәнзелмәган (19.10.1914–1916). Мохтарулланың беренче никахы Корычның Миңлеҗиһан Кәлимулла кызы белән була, 1889 елның 1 гыйнварында «өлфәт вә мәхәббәт юклык сәбәпле» аерылышалар. Мохтарулла Гафиятуллин 1917 елда хатыны (50 яшь), өч улы һәм кызы белән яши, 9,38 дисәтинә җире, аты, сыеры, кәҗәсе була. Хөрмәтулла Мохтаруллин (1902) 1942 елда сугышта хәбәрсез югала (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Сафиулла Гафиятулла улы Мортазин балалары: Хәлимә (1897–1898), Гыйниятулла (28.03.1900; анасы Камилә Ахунҗан Мөхәммәтша улының кызы), Бибифакия (29.12.1901–1902), Һидиятулла (30.03.1904; анасы Камилә Әхмәтҗан кызы), Зәкия (29.10.1906; анасы Камилә Ахунҗан кызы), Зиннәтулла (22.07.1910–1911), Шәйхулла (30.07.1912), Миңлесәвия (24.09.1915). Сафиулла Гафиятуллин (50 яшь) 1917 елда хатыны (35 яшь), өч улы һәм ике кызы белән яши, 4,69 дисәтинә җире, аты, сыеры, сарыгы, кәҗәсе була.

Гафиятулланың калган ике улыннан метрикәләрдә нибары ике бала теркәлгән. Хөснулланың – улы Кәлимулла (1881–1897), Сөнәгатулланың кызы Факия (29.12.1901) була.

Хәсән Гали улы Мортазинның төпчек улы Шаһингәрәй иде. Шаһингәрәй Хәсән улының кызы Гайниҗамал (18 яшь) 1875 елның 15 февралендә авылдашы Әхмәтгәрәй Хәлилулла улы (23 яшь; атасы Хәлилулла Хәбибулла улы) белән никахлаша. Шул ук Гайниҗамалның икенче никахы 1878 елның 20 ноябрендә авылдашы Тимергази Хатымтай улы (45 яшь; икенче никах) белән була.

Хөсәен Гали улы Мортазиннан (1793) киткән тармакны карыйк. Аның нәселен дәвам иткән Хөснетдин Хөсәен улы (1831–13.04.1905) балалары: Раҗетдин (1868), Галәветдин (1872), Афзалетдин (21.07.1877; анасы Бибигайшә), Гыймадетдин (25.08.1880), Бибигаширә (1886). Хөснетдин кызы Бибигаширә 1903 елның 3 гыйнварында Килкабызның Газетдин Шәйхетдин улы (21 яшь) белән кавыша.

Раҗетдин Хөснетдин улы 1903 елның 2 октябрендә нәселдәше Мәликәбану Хөснулла Гыйсмәтулла улының кызы белән кавыша. Раҗетдиннең икенче никахы 1907 елның 1 мартында авылдашы Габдерәкыйп Мөхәммәди улының кызы Хөснизиядә (27 яшь; икенче никах) белән була, аларның балалары Әхияретдин (16.11.1910), Хәйдәретдин (1912–1917), Шәмсекамал (03.10.1913)

туа. Ражетдин Хөснетдинов 1917 елда хатыны, улы һәм өч кызы белән яши, 2,80 дисәтинә җире, 2 кәҗәсе, сыеры була.

Галәветдин Хөснетдин улы 1897 елның 25 октябрендә Иске Катайның Арслангали Мөхәммәтгали улының кызы Бибикафия (18 яшь) белән никахлаша. Егетнең вәли вәкиле – атасы Хөснетдин Хөсәен улы, ризалык шаһитлары Җәләлетдин Мөхәммәтсәлим улы белән Әхтәмҗан Мөхәммәди улы була. Бу никахтан бары Кифая (1902–1903) билгеле.

«Азаматлар – саран, әмма ныклы, таза нәсел, алар арасында фәкыйрьләр юк иде», дип әйткән иде Хәсән абый Шакиров. Шунда бер риваять тә сөйләде: «“Башкорт”лар Иске Катайдан аръякка күчерелгәндә, иң соңыннан Азаматлар киткән, ди. Бик тә ташлап китәсе килми икән Азаматның типтәр ягын, ат арбасына бәйләп, сөйрәп чыгарганнар моны типтәрләр. Бик тискәре, бик саран булган, ди ул, типтәрләрне күрә алмаган. Урманы да шәп булган бит Иске Катайның. Типтәрләр юкәдән көрәк саплары, усак-имәннән мичкәләр ясап сата торган булганнар. «Безнең агачтан туенасыз», дип әйткән ди Азамат. Шуннан киткән талаш...».

Менә шундый риваять белән тәмамлыйм китабымның бу бүлеген. Билгеле, Яңа Катай барлыкка килгән чорда сүз Азаматның үзе түгел, уллары турында гына барырга мөмкин. Риваятьнең башка ягына кагылмыйм, Азамат нәселен дәвам итүчеләр үзләре фикер йөртсеннәр...

Өлешчә җир мәсьәләсе кискен чорны яктырткан бу риваять – безнең тарих. Бу тарихта Азамат нәселен дәвам итүчеләр шактый эз калдырдылар һәм калдырачаклар да, иншалла. Болар кебек таза, ныклы нәселләр яшәгәндә авылыбызның киләчәге дә өметле.

# XI бүлек.
# Күчем нәселе

Туксанынчы елларда катайлылардан нәсел тарихы белән ныклап кызыксынган кеше, мөгаен, Хәсән Шакир улы Шакиров (1924 елгы) булгандыр. Ул үзенең ерак бабаларын Ык буендагы Тамьян авылында (хәзерге Мөслим районы территориясе) туып-үскән Күчем Теләкәевтән килә дип саный иде. Күчем батыр 1695—1696 елларда Петр патшаның Азов походында катнашкан. 1704—1711 елгы «башкорт» восстаниесендә әйдәп йөрүчеләрнең берсе булган. 1709 елда патша ягына чыгып, баш күтәрүчеләр һәм хөкүмәт вәкилләре арасында арадашчы ролен үтәгән. Күчемнең улы Акай шул гасырның утызынчы елларында хакимияткә каршы фетнә күтәргән, «Акай явы» исеме белән тарихка кереп калган.

Болар төбәк тарихын өйрәнүчеләр өчен яңалык түгел, кызыксынучылар күпмедер мәгълүматны «Башкортостан» энциклопедиясеннән яисә интернеттан таба ала. Хәсән абый үзе дә, төрле китаплардан һәм гәзитләрдән укып, нәсел башын ничек эзләвен әйтте. Аңарчы атасының агасы Шәйхелислам карттан ерак бабасы Күчемнең ничек хөкүмәт гаскәрләре тарафыннан Ыкка кысрыклануы турында сөйләгәнен генә ишеткән булган икән. Күчемнең бер малае Мөнип исемле булган, ди.

Хәсән абый сөйләгәннәрне сокланып тыңладым, аны бүләсем, бәхәскә керәсем килмәде (урын өстендә каты авырып яткан чагы иде), шулай да нәсел башын Күчем Теләкәевкә бәйләү дөрес түгел дип әйттем.

Күчем нәселе берничек тә Күчем Теләкәевкә барып тоташа алмый, архив документлары моны кире кага. Хәсән абыйның, «Күчемнәр башкача юк», дигән фикердән чыгып, нәсел башын Күчем Теләкәевкә тоташтырып куюы игътибарга лаек та соң, тик... унсигезенче гасырда мондый исемле кешеләр якын-тирә авыллардан Килкабызда да, хәтта марилардан торган Тукбирдедә дә булган (дәрәҗәләре булмагач, билгеле, исемнәре фамилия булып гасырдан гасырга күчмәгән). 1816 елгы ревизия исемлекләрен ачып карасак, Иске Дөмәйдә Карабай Күчемов (48 яшь), Түбән Бишендедә Күчем Шәрипов һәм аның улы Монасыйп Күчемов теркәлгәнен күрәбез[1]. Шуңа күрә Күчемне заманында киң таралган, аннары кулланыштан чыккан (сәбәбен тагын бер тапкыр әйтәм: дин йогынтысы көчәю аркасында гарәп-фарсы исемнәре өстенлек ала, ә милли исемнәр кысрыклана) борынгы төрки-татар исем дип карарга кирәк.

[1] БҮДТА, И-138 ф., 2 тасв., 151 сакл. бер., 8 б.а.; 156 сакл.бер, 9 б.а.

Югарыда язган юлларга ун ел вакыт узгач, 2009 елның җәендә Уфа архивында Катайның бер төркем кешеләре күрсәтелгән 1753 елгы уникаль документка тап булдым. Ул документ турында «Үткәннәрен бел Катайның» китабының беренче бүлегендә сөйләп үттем, шунда ук күчермәсен дә бирдем. Анда Күчемнең бер туганы Даут Сөләйманов телгә алына. Бу факт нәселне тулырак күзалларга, башка документларны да эшкә җигәргә ярдәм итте.

«Үткәннәрен бел Катайның» китабында Күчем нәселенә кагылышлы берничә документның күчермәсен (копиясен) китердем, аларны санап үтәм. Сөләйман (халык телендә Сөләй) Дусаев 1727 елгы документта теркәлгән. Фамилиясе Дусаев (Досаев) булгач, Сөләйманның атасы Дусай була. Сөләйманның уллары: Әбелгази, Даут һәм Күчем. Беренчесе – 1737, икенчесе – 1753, өченчесе 1770 елларга караган документта телгә алына, өчесе дә Сөләев фамилиясендә йөриләр. Соңгы документтан Күчем Сөләевнең 1770 елларда Кыргыз олысы старшиналарының берсе булуын беләбез.

1753 елгы документта Даут Сөләйманов белән бергә телгә алынган Бәтке авылы кешесе Муса Дусаев Сөләйманның туганы булуы, ихтимал, моңа төгәл җавапны ул авылның нәсел тамгаларын өйрәнү бирер иде.

Югарыда еллары санап үтелгән архив документларын беркем дә инкярь итә алмый. Китапның 7 нче битендә Әбелгази Сөләевне «Күчемов фамилияләрнең ерак бабасы» дип язган идек, төгәллек өчен «ерак бабасы Күчемнең туганы», дип өстик. Әбелгази Сөләев шуның белән әһәмиятле, ул 1727 елда «татарин» дип язылган, гадәттә 1917 елга чаклы документлар милләтне түгел, сословиене (башкорт, типтәр, ясаклы татар һәм башкалар) күрсәтә. Документның фәнни яктан да гаять әһәмиятен истә тотып бу китапта кабат бастырабыз.



**«1737 года марта в день Уфимского уезду Казанской дороги деревни Катаевой татарин Аблазеи Сулеевъ […]» дип язылган**

Болар ачыкланганда Хәсән абый күптән мәрхүм булган иде. Ул үзенең ерак бабаларын кыпчаклардан килеп чыккан дип тә әйтә иде. Минем белән сөйләшкәннән соң, Күчем Теләкәев версиясен юкка чыгарган, шәҗәрә башына Кыпчакны куйган булып чыкты. Бу хакта 2018 елда, Мөхтәсип Хәбибрахманов төзегән шәҗәрәне күргәч белдем. Хәсән абый мәгълүматлары нигезендә төзелгән ул шәҗәрәнең Габделҗәлилгә чаклы түбән буыннары дөрес булмаса да, Габделҗәлилдән тармакланып киткән өске буыннары шик уятмый дияр-

лек. Шуңа күрә Хәсән абый зур нәселнең бер тармагын ачыклау, киләчәк буыннарга калдыру максатыннан зур эш башкарган, үзе туплаган мәгълүматны ышанычлы кулларга биреп калдырган, изге гамәл кылган дип әйтәбез.

...Бу китапны төзәткәләп утырганда, Күчемовлардан берәү нәселен Күчем ханга бәйләп куйган шәҗәрә җибәрде. Архивка кереп нәсел тарихын өйрәнәсе урынга, кайберәүләр ерак бабаларын әллә кемнәр итеп күрсәтмәкче була, бөеклеккә ансат юллар эзли, ялган юлга баса. Кемнәрнеңдер нәсел башы пәйгамбәрләргә, ниндидер ханнарга тоташуын ишеткәнгә яисә укыганга, моңа гаҗәпләнмим. Әйдә, хыяллансыннар, тик ялганны башкаларга тагалар икән, Ходай каршында җавап бирәсен онытмасыннар.



**Күчем Сөләев Кыргыз олысы старшиналары аталган документта (1771 ел). БҮДТА, И-1 ф., 1 тасв., 428 сакл.бер.**

Күчем Сөләев нәселен дәвам итүчеләр 1816 елгы ревизия документында Кылчым (1739—1812) һәм Алиш (мулла кушкан исеме Әлмөхәммәт; 1752—1812) Күчемовлар дип теркәлгәннәр. Бары шул чордан, унтугызынчы гасыр башыннан гына, «Күчемов» нәсел фамилиясенә әйләнә.

Сүз уңаеннан әйтик, Туктаголдагы бертуган мөәзин Габделмән (1754), Габдеваһап (1758—1812), Габделвахит (1769), Галим (1771), Габделсалих (1773; «походный сотник и квартирмейстр») Күчемовлар шулай ук Күчем Сөләев нәселен дәвам итүчеләр, дип фараз кылабыз. Чөнки ул авыл кешеләренең кайберләре Катай метрикәләрендәге никах язуларында Күчем нәселенә хас тамга салалар (алдарак мисал китереп үтәрбез). Әгәр дә Туктагол метрикәләрен һәм нәселләрен махсус өйрәнеп, шул тамгаларның югарыда санап үткән Габделмән һәм башка Күчемовлар нәселенә караганын исбат итсәк, болар да Күчем Сөләев уллары дип фараз кылып түгел, төгәл һәм фәнни нигездә әйтә алыр идек.

Рәсми документлардан тыш, «Күчемов»ның нәсел фамилиясе булып китүе метрикәләрдә чагыла. Метрикәләрдә Кылчымга өстенлек биреп, нәсел фамилиясен «Кылчымов» дип язган очраклар да бар. Туксанынчы елларда Яңа Катай аксакаллары Кылчымны Күчемнең улы булганын белмиләр, аерым нәсел кебегрәк карыйлар, «алар Кылчымнар, без Кучумовлар», дип әйтәләр иде. Моңа зур әһәмият бирмәү сәбәпле, бабалары Кылчымга тоташканын бәйнә-бәйнә аңлатып тормадым, китабымнан укып белерләр, дип уйладым. Метрикәләр буенча, Яңа Катайдагы башка нәселләрнең дә нәсел фамилиясен беләбез, нәсел фамилиясе күрсәтелү шәҗәрә төзегәндә эшне җиңелләштерә.

Исемнәр кабатланса, метрикәдәге нәсел фамилиясенә карап, кемнең кайсы нәселгә караганын бернинди хатасыз ачыклау мөмкинчелеге туа.

Кылчым исеменең мәгънәсенә китабымның Юлдаш нәселе бүлегендә тукталып үткән идем, кабатлап тормыйм. Күчем исә фәнни әдәбиятта болай аңлатыла: «1. Күчүче, күченеп йөрүче. Күчү вакытында туган ир балага бирелгән. 2. Күч сүзе борынгы төрки телдә ил, гаилә, йорт, нәсел-ыру, халык, төркем мәгънәләрен дә белдергән»[1].

Ревизия документларына һәм метрикәләргә таянып, Кылчымның алты улын ачыкладым. Болар: Габделҗәлил (1770–1855; 1859 елгы ревизиядә «отставной походный старшина» дип язылган), Габделсалих (1773–1826), Габделмәннан (1781), Габделнасыйр (1782–1833), Мөхәммәткәрим (1786), Мөхәммәтәмин (1790–1813). 1834 елгы ревизия документында Габделҗәлил, Габделсалих, Габделмәннан, Габделнасыйрлар Кылчымов фамилиясендә теркәлгән.

Нәселнең Габделҗәлил тармагы искиткеч зур. Аның беренче хатынынннан Мөхәммәтсәлим (1795; урядник), Мөхәммәтсадыйк (1798), Мөхәммәди (1809–30.03.1895; 1895 елгы метрикәдә атасы Габделҗәлил Кылчым улы Күчемов дип язылган), Мөхәммәтҗан (1811), икенче хатыныннан Әхмәтҗан (1814–04.05.1889; 1889 елгы метрикәдә фамилиясе Кылчымов) һәм Әхтәмҗан (1816) исемле уллары туа. Текстта Габделҗәлил үз кулы белән язган 1828 елгы документ фрагментын күрәсез. Гарәп имлясы белән татарча «юртовой старшина Габделҗәлил Кылчым улы Күчемоф [...]» дип язган ул.


тельства. Апреля 8го дня 1828. Года. Сіе
прошеніе набело переписывалъ Войска орен
бургскаго 3го кантона бакалинской станицы
Служащій Урядникъ Андрей Альметевъ.
А проситель Старшина Абзелилъ Кучумовъ
татарскимъ письмомъ руку приложилъ.

**Габделҗәлил Кылчым улы Күчемов үз кулы белән язган документ фрагменты. 1828 ел**

Бу документның күчермәсен махсус бирдем. Чөнки кайберәүләр Башкортстан татарларын совет мәктәбендә татарча укыганга башкортча сөйләшмиләр дип ялганлап гаеплиләр. Татар булмасалар, татарча түгел, башкортча укытырлар иде, совет мәктәбе «тут ни причем», дип рус сүзләрен кыстырып әйтәм андыйларга. Совет чоры беткәнен көтеп кенә торганнар, диярсең, әнә хәзер көчләп диярлек башкорт теле, ялган тарих тага башладылар. Без 1917 елга чак-

[1] Гомәр Саттаров. Татар исемнәре сүзлеге.– Казан, 1981.

лы туган бабаларыбызның саф татарча сөйләшүен күреп үстек, алар арасында совет мәктәбен түгел, мәдрәсә бетергәннәре шактый иде. Инде бу документка күз салсак, анда «татарским письмом руку приложил», дип язылган (шул кайберәүләрнең моңа да аңлатмасы бар, тукталып тормыйм). Документта Бакалы «станица» дип язылган, чөнки анда казаклар яшәгән, алар турында һәм төбәгебезнең башка аз билгеле һәм кызыклы фактларга бай тарихын «Очерки по истории Бакалинского района» китабында яздым (ул кульязма китапны район китапханәсендә укый аласыз, шактый тулыландырылган варианты 2022 елда дөнья күрәчәк, иншалла)

Иң башта Габделҗәлилнең беренче улы Мөхәммәтсәлимнән китүче тармакны карыйк. Мөхәммәтсәлим Габделҗәлил улы ир балалары: Мөхәммәтвәли (1826), Мөхәммәтситдыйкъ (1831–22.10.1897), Мөхәммәтнәби (1832), Әфләтун (1834–15.10.1915), Шәмсемөхәммәт (1843), Җәләлетдин (1852–01.01.1917). Боларның һәрберсе нәсел калдыра, шуңа күрә аерым-аерым тукталып үтәбез.

Мөхәммәтвәли Мөхәммәтсәлим улы балалары: Гаязетдин (метрикәдә Гаязетдин; 1850), Сираҗетдин (халык телендә Сирай; 1858), Мәхиян, Җиһангир (1865–1895), Әхмәтвәли (12.11.1877; анасы Мәрфуга).

Гаязетдин Мөхәммәтвәли улы Күчемов балалары: Гыймадетдин (1915 елда вафат), Фатыйма (13.06.1883), Заһретдин (1886), Хәкимә (1892), Гыймаделислам (1893), Миңлелатыйфа (28.03.1894; анасы Миңлевафа типтәр Габделхаликъ кызы), Габдулла (22.10.1897). Гаязетдин кызы Хәкимә 1910 елның 13 ноябрендә Килкабызның Хәбипҗәббар Әүдияр улы (21 яшь; атасы Әүдияр Мөхәммәтгали улы) белән никахлаша. Габдулла Гаязов (Гаязетдинов; 1897) – Ватан сугышы ветераны, сугыш алдыннан хатыны Сәгыйдә (1906), кызы Мәхүҗүрә (1930) белән яши. Мәхүҗүрә авылдашы Нәсимьян Исхаковка (1928) кияүгә чыга.

Гыймадетдин Гаязетдин улы балалары: Сәхия (07.01.1911; анасы Бибихәтирә Мөхәммәтшакир кызы), Җәмгыйтдин (26.06.1912). Гыймадетдиннең тәүге хатыны Корычның Әһлетдин Хәбибулла улының кызы Мәәлүфә була, 1906 елның 26 июлендә «араларында мәхәббәт вә өлфәт юклык сәбәпле» аерылышалар. Шаһитлар Госман Гомәр улы белән Җиһангир мулла Габделгани улы була.

Заһретдин Гаязетдин улы 1916 елның 4 гыйнварында Учтымның Кашшафетдин Шәйхетдин улының кызы Хәтирә (25 яшь) белән никахлаша, балалары Мәрхәметдин (26.10.1916) туа.

Гыймаделислам Гаязетдин улы (20 яшь) 1913 елның 30 гыйнварында авылдашы Хаҗиәхмәт Шәрәфетдин улының кызы Вазыйха (17 яшь) белән никахлаша, балалары Газизә (29.03.1914–1914), Вәдига (03.04.1915) дөньяга килә.

Сираҗетдин Мөхәммәтвәли улы Күчемов балалары: Минһаҗетдин (1884), Сәрвәретдин (21.07.1889; анасы Шәмсеҗиһан Гайнулла кызы). Минһаҗетдин Сираҗетдин улыннан Гашия (09.04.1910; анасы Гарифә Җәләлетдин кызы) һәм Миркасыйм (09.08.1916) туган. Минһаҗетдин Сираев (33 яшь) 1917 елда хатыны (28), улы һәм кызы белән яши, 9,25 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче яллый. Метрикәдә Миркасыйм Минһаҗетдин

улы Сираевның 1935 елның 30 июнендә загстан туу турында белешмә алганы язылган, 1942 елның октябрендә Ватан сугышында хәбәрсез югала (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Әхмәтвәли Мөхәммәтвәли улы 1905 елның 12 декабрендә нәселдәше Борһанетдин Гыйлаҗетдин улы Күчемов кызы Миңлеҗиһан (18 яшь) белән никахлаша. Әхмәтвәли балалары: Саимә (27.09.1906), Бибикәшифә (10.11.1907), Хәтимә (07.06.1909; анасы Гөлҗиһан Борһанетдин кызы), Әхмәтнәби (27.11.1910–1915; анасы Гөлҗиһан), Әхмәтзәки (01.01.1913), Сәвия (02.11.1914). Әхмәтвәли Мөхәммәтвәлиев гаиләсендә Ватан сугышы алдыннан хатыны Гөлҗиһан (1882), улы Әхмәш (1922; хәрби хезмәткә чакырылган), кызлары Кәшифә (1926), Мәдинә (1933) була, гаилә башлыгы Әхмәтвәли шул чордарак дөнья куя. Әхмәтшәриф Әхмәтвәли улы Мөхәммәтвәлиев сугышка 1943 елның 3 мартында китә һәм шул елны хәбәрсез югала (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Югарыда Мөхәммәтвәли Мөхәммәтсәлим улыннан китүче тармакны карадык. Мөхәммәтсәлимнең икенче улы Мөхәммәтситдыйкъ балаларына һәм оныкларына тукталып үтик.

Мөхәммәтситдыйкъ Мөхәммәтсәлим улы Күчемов балалары: игезәкләр Әхмәтвәли белән Әхмәтгали (1859), Мөхәммәтзакир (1861), Мөхәммәтшакир (1865), Бибигайшә (10.12.1877), Нуретдин (04.08.1880), игезәкләр Фазлыәхмәт (02.01.1883) белән Вәлиәхмәт (02.01.1883), Миңлебану (07.12.1890), Галимә (1891), Галиәхмәт (30.08.1893; анасы Бибиҗамал Йосыф кызы), Бибимәрьям (1895). Мөхәммәтситдыйкъ кызы Бибигайшә (18 яшь) 1902 елның 6 ноябрендә Килкабызның Мөхәммәтхәлим Мөхәммәтәмин улы (23 яшь) белән кавыша. Икенче кызы Галимә (17 яшь) 1908 елның 21 декабрендә Туктаголның Хәбибрахман Габделхаликъ улы (24 яшь) белән никахлаша. Төпчек кызы Бибимәрьям 1913 елда Кадернең Әбушахман Фәйрузша улы (25 яшь; атасы Фәйрузша Габидулла улы) белән гаилә кора.

Әхмәтгали Мөхәммәтситдыйкъ улы Күчемов балалары: Гыйззениса (06.11.1894; анасы Фәрхениса Мөхәммәди Мөхәммәтша улының кызы), Шәмсениса (29.03.1900–1912), Әхмәтлатыйф (01.10.1903–1904), Хаҗгали (24.05.1906), Зәкәрия (05.03.1910–1910).

Мөхәммәтзакир Мөхәммәтситдыйкъ улы Күчемов балалары: Шакирҗан (02.10.1894; анасы Мәрхәбә Габделшәфикъ Вәлимөхәммәт улының кызы), Бибимөхазумә (26.09.1897–1897), Зәкия (22.10.1898–1905), Бибимәликә (28.06.1901), Фатиха (27.07.1904), Сабирҗан (02.11.1909), Бибифатыйма (14.02.1914–1914; анасы Мәрхәбә). Шакирҗан Мөхәммәтзакир улы Беренче бөтендөнья сугышында 152 нче Владикавказ полкы составында сугыша, 1915 елның 17 маенда яралана һәм дәвалангач туган авылына кайта. Шакирҗан Закиров балалары: Хәбирҗан (1923–1942), Салихҗан (22.03.1925–1925; анасы Өммегөлсем Миңлехан кызы), Хәдичә (07.10.1926–08.09.2003), Зәйтүнә (14.12.1931–08.01.2004), Әшрәфҗан (28.05.1932–16.05.2012). Хәбирҗан Ватан

сугышында хәбәрсез югала. Хәдичә белән Зәйтүнә Мәскәү якларында торф чыгаруда эшлиләр, Бакалыда гомер итәләр, балалары булмый. Әшрәфҗан Иске Катайның Рамазан Хәбибуллин кызы Разыя (03.10.1941 туган) белән гаилә кора, балалары туа. Лира Әшрәфҗан кызы картыйсы Өммегөлсемнең Корычта туып-үсүен, шул нәселдән булган Рәшит Әмирхан улы Миңлеханов белән гаилә шәҗәрәсен төзүен әйтте. Әшрәфҗан абый агач эше остасы иде, мин туып-үскән өйнең верандасын ясады, шунда беренче тапкыр якыннан күрсәм, соңгысы Катай сабантуенда очрашү-сөйләшү булган.

Мөхәммәтшакир Мөхәммәтситдыйкъ улы Күчемов балалары: Мөхәммәтгариф (20.03.1894; анасы Бибикафия Баһаутдин Җамалетдин улының кызы), Галия (1896–1901), Мөхәммәтнәгыйм (03.12.1898; анасы Бибикафия), Мөхәммәтхәниф (18.08.1900–1911; анасы Фәхерниса Галләметдин кызы), Мөхәммәтназиф (26.06.1904–1904), Гыйззениса (28.07.1905), Гыйззенур (29.04.1911; анасы Фәхерниса Галләметдин кызы). Мөхәммәтгариф Мөхәммәтшакир улы Күчемовның Хәлимә Шәрәфетдин кызы белән никахыннан Мөхәммәткамил (18.12.1925) туа.

Вәлиәхмәт Мөхәммәтситдыйкъ улы Күчемов (22 яшь) 1909 елның 13 декабрендә Иске Катайның Баһманша Баһаутдин улының кызы Кифая (19 яшь) белән никахлаша, балалары Хаҗиәхмәт (04.11.1910–1910), Хаҗиәкрәм (30.11.1911), Галиәхмәт (15.05.1914), Акмалетдин (23.08.1916) туа. Вәлиәхмәт Ситдыйков гаиләсендә Ватан сугышы алдыннан хатыны Майсорур (1887), уллары Мәрхәм (1921), Мирсәет (1925; ФЗО да укыган), кызы Фәһимә (1928) була. Мәрхәм белән Мирсәет сугышта һәлак булалар, аларның абыйсы Хаҗиәкрәмне дә сугышка алалар. Артиллерист, дошманны зур югалтуларга дучар иткән Галиәхмәт Вәлиәхмәт улы Ситдыйков «Батырлык өчен» (15.04.1943) медале белән бүләкләнгән. Акмалетдиннән дә нәсел дәвам итә, күрәсең, 2009 елның көзендә аның тууы турында загстан белешмә алганнар (Катайның мемориаль стеласында Ситдыйковларның берсе теркәлмәгән).



**1908 елгы документта өстә Мөхәммәтхарис Мөхәммәтнәби улы тамгасы, аста Туктаголның Галиәсгар Шәяхмәт улыныкы. Тамгаларның төп элементы (+) тәңгәл килә**

Мөхәммәтситдыйкъ Мөхәммәтсәлим улы тармагын карауны төгәлләп, Мөхәммәтсәлимнең өченче улы Мөхәммәтнәбигә күчәбез. Мөхәммәтнәби Мөхәммәтсәлим улы балалары: Мөхәммәтхарис, Мөхәммәтсабир (1871), Мөхәммәтнасыйп (16.12.1876), Талига (1882), Бәдерталига (1889). Мөхәммәтнәби

кызы Талига (19 яшь) 1902 елның 20 декабрендә Иске Куянның Җиһангир Хөсәен улы (23 яшь) белән кавыша. 1908 елның 23 декабрендә туганнары Мөхәммәтнәби кызы Бәдерталиганы (19 яшь) Туктаголның Галикәрам Галиәсгар улына (22 яшь; атасы Галиәсгар Шәяхмәт улы) кияүгә бирәләр. Кызның вәли вәкиле – бертуган агасы Мөхәммәтхарис Мөхәммәтнәби улы, ризалык шаһитлары туганнары Мөхәммәтсабир белән Мөхәммәтнасыйп Мөхәммәтнәби уллары була. Кияүнең ризалык шаһитлары нәселдәшләре Сәригаскәр белән Мөхәммәтзариф Шәяхмәт уллары була. Сәригаскәр кулы белән салынган тамганың төп элементы Күчем нәселенеке белән тәңгәл килә. Алдарак Туктаголда да Күчемов фамилиялеләр булган дигән идек, шуларның нәселен дәвам итмиләрме икән болар?

Мөхәммәтхарис Мөхәммәтнәби улы Күчемовның беренче никахы Кадернең Габделшәфикъ Габдерәфикъ улының кызы Бибилатыйфа белән була, 1893 елның 3 февралендә «араларында мәхәббәт вә өлфәт булмау сәбәпле» аерылышалар. Мөхәммәтхарис балалары: Мөхәммәтназиф (15.02.1898–1898; анасы Фәхернур Насретдин кызы), Галимҗан (09.06.1899), Газизҗан (30.01.1902; анасы Фәхербану Насретдин кызы), Мирсәгыйть (23.08.1905–1906; анасы Фәрхенур Насретдин кызы), Әмирҗан (06.07.1907; анасы Фәхеркамал Насретдин кызы), Бибинур (17.02.1911–1915; анасы Фәхернур), Гыйлемхан (15.11.1915–1916; анасы Фәхринур), Фәрхиҗиһан (12.02.1917), Казыйхан (1919–1942). Әлеге метрикә мәгълүматында Мөхәммәтхариснең хатыны төрлечә язылган, мулла исемен төгәл белмәгән, күрәсең. Мондый төгәлсезлекләр башка очракларда да күзәтелә, игътибарлы укучы китап авторы хатасы дип уйламасын тагын.

Мөхәммәтхариснең улы Газизҗан Харисов 1942 елда сугышта һәлак була, хатыны Хәлфиҗиһан Гыйндулла кызы (1910), балалары Мәгъфурҗан (1929), Миргабитҗан (01.05.1933), Миңлехөсни (1938) кала. Миргабитҗан авылдашы Гайшәбикә Мусахан кызы (03.01.1935) белән гаилә кора.

Әмирҗан Харисов та сугыштан кайтмый, авылда хатыны Гайникамал (1915), балалары Әҗерия (1930) белән Мөбәрәкҗан (1939; аныкы Илгиз), анасы Фәрхинур (1878) кала. Казыйхан Харис улы Нәбиев та сугыш корбаны була. Шулай итеп, Мөхәммәтхариснең өч улы Ватан сугышы яланнарында ятып кала.

Мөхәммәтсабир Мөхәммәтнәби улы Күчемов (23 яшь) 1894 елның 12 апрелендә нәселдәше Насретдин Нәҗметдин улы Күчемов кызы Гыйльмикамал (17 яшь) белән никахлаша, балалары Мөхәммәтсабит (22.11.1895), Мөхәммәтзаһир (09.11.1898), Мөхәммәткаһир (23.02.1901), Мөхәммәтзаһит (05.07.1904–1906), Габит (16.11.1907), Мөхәммәтназиф (20.10.1910), Гыйльмиҗамал (24.02.1914), Мөхәммәтнәгыйм (25.10.1916) туа. Заһир Сабиров (1898) – Ватан сугышы ветераны, гаиләсендә сугыш алдыннан хатыны Закирә (1903), уллары Хәмит (1924), Гамил (1927), кызлары Мәкнүнә (1935), Мәккия (1939), Тәзкирә (1941) була. Хәмит Заһир улы Заһиров сугышка алынганда колхозда хисапчы (учётчик) булып эшли, сигез класс белемле, хәрби әзерлек үткәч сержант була, 23 нче гвардияче һава десанты дивизиясе составында сугышка керә (язмышы

билгесез). Габит Сабир улы Нәбиев 1942 елда сугышта хәбәрсез югала (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән), хатыны Хәтирә (1904), балалары Мирзаһит (1930), Мөзәккия (1938), Мөнәвәр (1940) кала. Аның туганы Мөхәммәтнәгыйм (1916) 1935 елда загстан туу турында белешмә ала, алга таба язмышы билгесез.

Мөхәммәтнасыйп Мөхәммәтнәби улы Күчемов балалары: Мөсәвәрә (13.04.1909), Нигъмәтулла (28.11.1910–1912; анасы Мөшәррәфә Габдемәннан кызы), игезәкләр Хәсән (1912–1912) белән Хөсәен (29.01.1912–1912), Тимерҗан (20.05.1913), Шакирҗан (08.11.1914), Шәрифә (03.09.1917), Шәрифҗан (18.02.1925). Ватан сугышы алдыннан Катай авылы исемлегендә Насыйп Нәбиев (1876), хатыны Мөшәррәфә (1885), уллары Тимерҗан (1913), Шакирҗан (1914), Гыйлемҗан (1919), Шәрифҗан (1926), Фаяз (1933), кызлары Мөсәвәрә (1910), Шәрифә (1922) теркәлгән. Шакирҗан, Гыйлемҗан, Шәрифҗан Нәбиевләр кулларына корал тотып, ил азатлыгы өчен Ватан сугышында көрәшкәннәр.

Бүгенге көндә Нәбиев, Сабиров, Харисов фамилияләре белән билгеле Мөхәммәтнәби Мөхәммәтсәлим улы тармагын карадык, Мөхәммәтсәлимнең дүртенче улы Әфләтунга күчәбез. Әфләтун Мөхәммәтсәлим улы балалары: Мөхәммәтсалих (1866), Зөләйха (1867–1897), Бибизәйнәп (1874–1909). Әфләтун кызы Бибизәйнәп (19 яшь) 1893 елның 13 октябрендә нәселдәше Фәхретдин Нуретдин улы Күчемов (25 яшь) белән никахлаша.

Мөхәммәтсалих Әфләтун улы Күчемов белән Хәмдениса (атасы Мөхәммәтҗан Мөхәммәтсалих улы) балалары: Мирсәгыйть (01.04.1898), Миргали (29.04.1900), Хуҗагали (17.10.1901), Госмангали (01.01.1904–1905), Сабирҗан (07.11.1905), Шәехзаман (20.01.1908–1917), Сәрвиҗиһан (29.06.1910–1910). Бу хатыны вафат булгач, Мөхәммәтсалих 1910 елның 4 октябрендә авылдашы Фатыйма Габделгазиз кызына (17 яшь) өйләнә, аннан балалары Фәрвизә (03.11.1911), Саҗидә (31.05.1914–1914), Мөхәммәтназиф (16.01.1916–1917), Мөстәфидә (12.12.1925) туа. Мөхәммәтсалих Әфләтунов 1917 елда хатыны (30 яшь), дүрт улы һәм кызы белән яши, 2,55 дисәтинә җире, аты һәм сыеры була. Хуҗагали Салихов 1941 елның 22 сентябрендә сугышка китә, хатыны Мәдинә (1903), балалары Фәния (1930), Тимерхан (1934), анасы Фатыйма (1878) кала.

Әфләтун Мөхәммәтсәлим улы тармагын карауны шунда төгәлләп, Мөхәммәтсәлимнең бишенче улы Шәмсемөхәммәткә тукталып үтик. Шәмсемөхәммәт Мөхәммәтсәлим улы балалары: Хафизмөхәммәт (1868–29.10.1909), Фәезмөхәммәт, Хәнифә (01.12.1877), Нурмөхәммәт (1886).

Хафизмөхәммәт Шәмсемөхәммәт улы Күчемов (25 яшь) 1893 елның 13 октябрендә авылдашы Мөхәммәтшәриф Галикәй улының кызы Бибикафия (18 яшь) белән никахлаша, 1894 елның 20 апрелендә «араларында мәхәббәт вә өлфәт булмаган сәбәпле» аерылышалар. Хафизмөхәммәт балалары: Мирзаәхмәт (04.01.1894–16.08.1895; анасы Бибикафия), Динмөхәммәт (04.10.1895; анасы Бибизарифа Баһаутдин Хөсәен улының кызы), Таифә (12.01.1897), Рәй-

фә (20.04.1899), Әбәдия (02.10.1903), Мирзаәхмәт (22.08.1905–1907), Сафия (01.01.1908), Галиәхмәт (10.05.1910–1912). Хафизмөхәммәт кызы Рәйфә 1916 елда Иске Балыклы ясаклы татары Сәетгәрәй Әхмәтгәрәй улы (25 яшь; атасы Әхмәтгәрәй Мөхәммәтгәрәй улы) белән никахлаша. Фәезмөхәммәт Шәмсемөхәммәт улы Күчемовтан Мулламөхәммәт (12.07.1901; анасы Зарифа Баһаутдин кызы) билгеле.

Нурмөхәммәт Шәмсемөхәммәт улы Күчемов (25 яшь; икенче никах) 1911 елның 5 декабрендә Тыпыйның Баһаутдин Хөсәен улының кызы Зарифа (35 яшь; икенче никах) белән гаилә кора, уллары Әлмөхәммәт (халык телендә Әлмий; 11.09.1912) туа. 1913 елның 21 февралендә «араларында өлфәт вә мәхәббәт юклык сәбәпле» хатыны Зарифаны аерып җибәрә. Әлмөхәммәт Нурмөхәммәтов гаиләсендә сугыш алдыннан анасы Зарифа (1868), хатыны Фәрдәнә (1920; 1940 елда аерылышалар), уллары Мирзаәхмәт (1936) һәм Ярмөхәммәт (1939–1940) була.

Шулай итеп, Шәмсемөхәммәт Мөхәммәтсәлим улы тармагы бүгенге көндә Нурмөхәммәтов фамилиясе белән билгеле. Мөхәммәтсәлимнең бишенче улы Җәләлетдингә (халык телендә Җәләй) күчәбез.

Җәләлетдин Мөхәммәтсәлим улы Күчемов балалары: Хәерниса (1876), Минһаҗетдин (1879), Сәрвәретдин (1882), Шәрәфетдин, Нуретдин (16.06.1893), Әгъзаметдин (22.10.1895; анасы Бибикамал Корбангали Чурагол улының кызы), Хәсән (25.11.1897), Хөсәен (25.11.1897), Хәнәфи (25.11.1897), Рәкыя (25.11.1897), Бибиәсма (12.12.1898; анасы Бибикамал). Бу Катайда беренче тапкыр берьюлы дүрт бала табу очрагы, тик аларның өчесе икенче көнне, берсе декабрь башында ходай тәкъдире белән (метрикәдә шулай языла) җан тәслим кыла.

Җәләлетдин Мөхәммәтсәлим улының кызы Хәерниса (17 яшь) 1894 елның 7 февралендә авылдашы Сәетгәрәй Дәүләтгәрәй улы Мортазин (22 яшь) белән никахлаша. Ире вафат булгач, Хәерниса 1905 елның октябрендә Килкабызның Имаметдин Мифтахетдин улы (25 яшь; дүртенче никах) белән никахлаша.

Югарыда Җәләлетдиннең хатыны Бибикамал Корбангали Чурагол кызы дип күрсәтелә. Монда мулла хаталы язган, Бибикамал түгел, ә Бибиҗамал. Җәләлетдиннең Бибиҗамал белән никахы 1888 елның 7 апрелендә Иске Катайда теркәлә. Җәләлетдин сукыр эчәге (аппендицит) шартлап, 1917 елның 1 гыйнварында 64 яшьтә мәрхүм була.

Минһаҗетдин Җәләлетдин улы Күчемов балалары: Фәсхетдин (12.11.1900–1905; анасы Сафия Габдулла кызы), Бибизәкия (13.07.1902), Хәлимә (04.08.1904–1905), Бәлхия (26.09.1906), Химая (04.08.1908), Әминә (17.07.1910), Мөхәммәтдин (19.07.1912), Җәмгыйтдин (16.11.1914), Җәмигънур (26.10.1916), Нуретдин (20.02.1925–1925; анасы Бибинур Мөхәммәтсолтан кызы). Минһаҗетдин (халык телендә Минаҗ) Җәләев сугыш алдыннан хатыны Әбәдия (1891), уллары Җәмгыйтдин (1914), Җәмигънур (1916), килене Зәйтүнә (1921), оныгы Рузә (1942) белән яши. Кече лейтенант Җәмигънур Минһаҗ улы Җә-

ләев 1943 елның 14 гыйнварында сугышта һәлак була (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Сәрвәретдин Җәләлетдин улы Күчемов балалары: Сәхия (25.10.1908; 1961 елда загстан туу турында белешмә ала), Мәдхия (01.08.1911; анасы Хәтирә Имаметдин кызы), Нәҗия (13.03.1914). Сәрвәретдин Җәләев (1882) гаиләсендә Ватан сугышы алдыннан хатыны Хәтирә (1885), уллары Әкрәм (1922), Инсаф (1927), кызлары Бәһия (1925), Фәһимә (1930) була. Нәҗия авылдашы Хәсән Дәүләтгәрәев белән никахлаша. Ватан сугышы ветераны Әкрәм Җәләевтән нәселне уллары Мирхади белән Фәрит һәм кызлары Флүрә белән Флүзә дәвам итә. Инсаф авылдашы Фәнүзә Әбүнәгыйм кызы белән гаилә кора, балалары Рәшит (07.04.1962), игез кызлар Зәлифә белән Фәвисә (14.07.1964) туа. «Халык хәтере» сайтында Инсаф Җәләев бер төркем авылдашлары белән (барысы 12 кеше) сугыш чорында хәрби хезмәткә чакырылган дип күрсәтелә (исеме нигәдер Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Шәрәфетдин Җәләлетдин улы Күчемовтан Әнвәретдин (16.11.1916; анасы Хәтирә Имаметдин Мифтахетдин улының кызы) билгеле.

Югарыда сүз Габделҗәлил Күчемовның беренче улы Мөхәммәтсәлимнән киткән тармаклар турында сүз барды. Габделҗәлилнең икенче улы Мөхәммәтсадыйктан нәселне Мөхәммәтзариф (1822), Мөхәммәтзакир (1836–13.04.1899, указлы мулла), Мөхәммәтсадыр (1843), Мөхәммәтдин, Галләметдин (1869–1943) дәвам итә.

Монда бер искәрмә ясап үтик. Мөхәммәтсадыйкка һәм аның хатыны Бибигафифәгә 1859 елда 61 яшь була. Димәк, Мөхәммәтсадыйк күпмедер вакыттан тагын бер тапкыр никахлаша һәм аңа 71 яшь булганда төпчек улы туа. Шактый олыгайган ирнең яшь хатыны бала табуы ул заманда да, хәзер дә бөтенләй үк сирәк хәл түгел.

Мулла Мөхәммәтзакир мулла Мөхәммәтсадыйк улы балалары: Мөхәммәтзариф (1857), Мөхәммәтгаяз (1859), Мөхәммәтхафиз, Мирказый (тулы исеме Мирказыйгаяз), Гайникамал, Миргалим (1874–1875), Мирсәгыйть (04.06.1876; анасы Гыйзземөкәррәмә), Мөнәвәрә (1887). Мөхәммәтзакир кызы Гайникамал 1889 елның 18 февралендә Наратлы Елганың Нуретдин Минһаҗетдин улы (21 яшь; атасы Минһаҗетдин Сираҗетдин улы) белән кавыша. Әлеге никах Иске Катай мәчетендә теркәлә, кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтхафиз белән Мирказый Мөхәммәтзакир уллары була. Икенче кызы Мөнәвәрә (17 яшь) 1904 елның 27 февралендә Минзәлә өязе Табын авылының Сәгъдетдин имам Мөхәммәтзариф улы (26 яшь; атасы имам Мөхәммәтзариф Әлмөхәммәт улы) белән никахлаша. Әлеге никах шулай ук Иске Катайның беренче мәхәлләсендә теркәлә, чөнки Мөхәммәтзакир имам-хатип вазифасын шунда башкара.

Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтзакир улы белән Сәхипҗамал Хәлиулла улы никахыннан Килкабызда Суфия (22.07.1908–1989) туа. Мөхәммәтхафизның башка балалары да була, бу кызының Габидулла Баймөхәммәтов белән ни-

кахыннан Вильс (1939–1968) туа. Бу хакта Вильсның улы Игорь Күчемов хәбәр итте. Аның мәгълүматына таянып, Мөхәммәтхафиз Килкабызда мәчет каршындагы мәктәптә балалар укыткан, дип фараз кыла алабыз, моны тәгаен ачыклар өчен ул авылның метрикә кенәгәләрен һәм башка архив чыганакларын өйрәнергә кирәк. Суфияның кыз туганы Оркыя була, ул Корычта фельдшер-акушер булып эшли.



**Сәхипҗамал Күчемова кызлары Суфия һәм Оркыя белән. 1919 ел**

Мөхәммәтхафизның башка балалары турында мәгълүмат сорап, авылдашым Әлфия Зиннуровага яздым, шундый җавап алдым: «Оркыя Күчемова гел Корычта эшләгән һәм яшәгән, бер улы булган, улы читтә яшәгән. Катайда аның Хәтимә һәм Зәйнәп исемле апалары булган. Хәтимә апаның улы Әбүзәр Зәйнәп апа Низаевлар күршесендә тора иде (Сабантуйга төшеп китә торган жирдә, хәзер өе юк инде, фамилиясен белмим). Бу өч кызның читтә яшәүче туганы Суфия Зәйнәп апага кайтып йөри иде».

Мирказый Мөхәммәтзакир улы Күчемов балалары: Галикарый (1896), Рәкыя (30.01.1900–1904; анасы Нурхәят Габделҗаббар кызы), Фатыйма (28.12.1902–1909; анасы Мөнәвәрә), Миңлехәтимә (19.10.1906), Габделһади (1907–1909), Саимә (07.01.1909–1916; анасы Мөнәвәрә Шәйхелислам кызы), Мирһади (26.12.1910–1914), Нәфисә (10.07.1913), Тәзкирә (03.09.1915). 1925 елгы метрикәдә Галикарый Мирказый улы Күчемовның Зәйнәп Әхмәтлатыйф улының кызы белән никахыннан балалары Мәхүҗүрә (01.07.1925) теркәлгән.

Галикарыйның Яңа Катай авыл советы барлыкка килгәч, секретарь вазифасын башкаруы, «Яңа тормыш» колхозының беренче рәисе булуы, ачы язмышы турында «Үткәннәрен бел Катайның» китабында әйтелде, кызыксынучылар ул китапны тагын бер тапкыр ачып карый алалар.

Мөхәммәтсадыйкның чираттагы улы Мөхәммәтдингә күчик. Аның исәнимин үскән ир балалары булмый, кызы Мөгаллимә (17 яшь) 1906 елның мартында Корычның Фәхрислам Гыймаделислам улы (35 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле атасы белән бертуган агасы Галләметдин Мөхәммәтсадыйк улы була. Шул ук Мөгаллимә (20 яшь; икенче никах) 1909 елның 3 июнендә Сеңрәннең Борһанетдин Шәрәфетдин улы (30 яшь; өченче никах) белән кавыша. Мөхәммәтдиннең икенче кызы Мөшәррәфә

(17 яшь) 1909 елның 22 гыйнварында Туктаголның Имаметдин Афзалетдин улына (24 яшь) кияүгә чыга. Кызның вәли вәкиле – агасы Галләметдин Мөхәммәтсадыйк улы, ризалык шаһитлары нәселдәшләре Мөхәммәтталип Мөхәммәтшәфикъ улы белән Мөхәммәтшәриф Мөхәммәтвәли улы була. Туктагол вәкилләренең нәсел тамгасы Күчемнеке белән тәңгәл килә (бу беренче очрак түгел), димәк, алар бер нәсел кешеләре булып чыга.

Мөхәммәтсадыйкъның төпчек улы Галләметдиннән нәсел хәзерге чорга тикле дәвам итә. Галләметдин Мөхәммәтсадыйк улы (25 яшь) 1893 елның 16 октябрендә авылдашы Габделбәшир Габделгаффар улының кызы Җиһанбану (18 яшь) белән никахлаша, балалары Гыйззениса (02.07.1897–1897), Җәмгыйтдин (28.12.1898–1988), Имаметдин (03.07.1902), Зыязетдин (1906; метрикәдә теркәлмәгән), Галия (05.11.1910), Әхияретдин (03.01.1914) туа. Галләметдин Садыйков 1917 елда хатыны (43 яшь), дүрт улы һәм кызы белән яши, 12,18 дисәтинә җире, 6 аты, сыеры һәм башка маллары була.

Галләметдин улы Җәмгыйтдин хатыны Саимә апа белән җиде бала (Әсгать, Әгъләә, Рәшит, Геннадий, Сәһлә, Вәсилә, Нәсибә) тәрбияләп үстерде, Катайның хөрмәтле кешесе, мулласы булып, 90 яшендә дөнья куйды. Сиксәннең уртасында да велосипедта йөрде, Гата абыйлар урамыннан җәяү менгәндә аның, мине күрү белән, велосипедыннан төшеп, хәл-әхвәл сорашып торганы әле дә күз алдына килеп баса. Безнең беренче күрешү әтием мәрхүм булган 1980 елның көзендә иде, димәк, ул мине хәтерендә калдырган, олы башын кече итеп, махсус туктап, сөйләшәсе иткән.

Җәмгыйтдин абыйның уллары-кызлары турында күп сөйләргә булыр иде. Алар арасында аерылып торганы – Әгъләә Күчемов, ул спорт ветераннарының Россия һәм дөнья күләмендәге ярышларында даими катнашып, спортча йөрү («спортивная ходьба») буенча дистәләрчә тапкыр чемпион булды. Ветеранның тормыш юлы һәм спорттагы уңышлары турында күпсанлы язмалар, аңа багышланган китап сөйли. Аның читтә яшәүче туганы Рәшит Күчемов – техник фәннәр докторы, энесе Гыйнадил (Геннадий) Күчемов Уфада Бакалы районы якташлар җәмгыятен оештыручыларның берсе булды.

Катай авыл советы кенәгәсендә Ватан сугышы алдыннан Имаметдин Галләмов (1902) гаиләсендә хатыны Рәхилә (1904), балалары Фәнә (1929), Мәгъфия (1934), Зөлфәт (1937) теркәлгән. Зыязетдин Галләмов (1906) гаиләсендә хатыны Хәтимә (1905), кызлары Мәхмүдә (1931), Флүрә (25.07.1935), уллары Әбүзәр (1936), Мирсәгыйть (1938) була. Икесе дә хәрби хезмәткә чакырыла, Имаметдин 1945 елда хәбәрсез югала, Зыязетдиннең язмышы билгесез (исемнәре Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән). Истәлекләргә караганда, Зыязетдиннең хатыны Хәтимә Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтзакир улы Күчемов кызы була. Зыязетдин кызы Флүрә Салих Әхтәмҗановка кияүгә чыга.

Габделҗәлилнең өченче улы Мөхәммәди иде. Мулла Мөхәммәди Габделҗәлил улы балалары: Ахунҗан (1842–1850; беренче хатыныннан туган), Мәхиян (1847), Габдерәхим (1849), Әхтәмҗан (1853; икенче хатыныннан), Габдерә-

кыйп, Сәрвиҗиһан (1860), Майсорур (01.03.1877; анасы Таифә), Мөхәммәтзариф (20.06.1878), Габдулла (1887), Гыйная (1891–1906). 1883 елның 15 июнендә Мөхәммәди хатыны Таифә Мозаффар кызы белән аерылыша. Мөхәммәди кызы Сәрвиҗиһан (17 яшь) 1878 елның 10 февралендә Үрмәтнең Мөхәммәткашшафетдин Гайнулла улы (24 яшь; икенче никах) белән кавыша.

Мәхиян Мөхәммәди улы Күчемов балалары: Фәрхениса (26.09.1877), Габделбаян (1880), Фәрхениса (1881), Майкамал (1889–1893), Габделмәннан (30.03.1894; анасы типтәр Хупҗамал Мөхәммәди Мөхәммәтша улының кызы). Мәхиян кызы Фәрхениса 1897 елның 6 декабрендә Минзәлә өязе Азалак авылының Солтангали Җәләлетдин улы Сәйфетдинов (24 яшь) белән никахлаша. Мәхиян Мөхәммәдиевнең ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (64 яшь), ике килене һәм оныгы (1) белән яши, 7,29 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була.

Габделбаян Мәхиян улы (22 яшь) 1901 елның 1 апрелендә нәселдәше Гыйльметдин Бәдретдин улының кызы Бибирәйфә (18 яшь) белән никахлаша, әмма тиздән аерылышалар. Габделбаян балалары: Хәсбиния (20.08.1904–1910; анасы Хәмдия Гайникамал кызы), Шәмсия (19.02.1907–1912), Фәтхелбәян (05.09.1913), Кәшбелгаян (13.09.1910: анасы Хәмдия Гайникамал кызы), Әһлия (08.11.1916), Ганбәрия (11.12.1925; анасы Хәмдия Гатаулла кызы). Ватан сугышы алдыннан Баян Мәхиянов (1880) гаиләсендә хатыны Хәмдия (1881), балалары Кәшбелгаян (1910; хәрби хезмәткә алалар), Кафия (1911), Әһлия (1914), Ганбәрия (1925), оныклары Халә (1932), Шаһиян (1935), Әүхәт (1937; Кәшбелгаян балалары) теркәлгән. Бер шәҗәрәдә Габделбаян ялгыш Габделбаттал дип күрсәтелгән, анда Кәшбелгаянның тагын ике улы (Фәрит белән Гыйлембаян) теркәлгән.

Әхтәмҗан Мөхәммәди улы Күчемов балалары: Ахунҗан (10.11.1878), Ахунҗан (1881), Шәйхелислам, Шакирҗан, Нурислам (1889–1889), Шәмсебанат (05.12.1895; анасы Шәмсебану Мөхәммәтгали кызы), Миңлебанат (1897). Әхтәмҗан кызы Миңлебанат 1915 елда Кадернең Мөхәммәтсалих Мөхәммәтшакир улы (35 яшь; икенче никах) белән никахлаша.

Ахунҗан Әхтәмҗан улы Күчемов (25 яшь) 1906 елның 9 декабрендә авылдашы Габделгалләм Габделбәшир улының кызы Бибимәрьям (17 яшь) белән никахлаша, балалары Бибикифая (01.09.1911), Галимҗан (20.06.1914) туа. Ахунҗан Әхтәмҗановны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны, улы һәм ике кызы (9 һәм 7 яшьләрдә) кала, 4,03 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була. Галимҗан Ахунҗанов 1942 елда Ватан сугышында хәбәрсез югала, хатыны Сәгыйдә (1914), улы Сабирҗан (1939) кала.

Шәйхелислам Әхтәмҗан улы Күчемов балалары: Мосаллия (10.12.1910; анасы Сәвия Мөхәммәтҗан кызы), Гыйлемхан (25.08.1913), Саҗидә (21.12.1915–1916), Казыйхан (1917–1917). Шәйхелислам Күчемов (1879) Ватан сугышы алды елларында хатыны Сәвия (1885), балалары Мосаллия (1910), Гыйлемхан (1913), Фәхрислам (1917), Гыйлемҗан (1923; хәрби документта 1925 ел дип язылган),


За нашу Советскую Родину!

Сержант

Кучумов Фахрислам Шайхер.

Уважаемый товарищ!

Приказом №37[illegible] от 23 августа 1945 года Верховного Главнокомандующего Генералиссимуса Советского Союза товарища Сталина за отличные боевые действия в боях с японцами на Дальнем Востоке Вам объявлена БЛАГОДАРНОСТЬ.

Поздравляю Вас с заслуженной похвалой нашего Великого вождя и желаю новых успехов в Вашей боевой работе.

Командир части 32424

[illegible]

Начальник штаба 32424

майор

**Сержант Фәхрислам Күчемов Сталинның Рәхмәт хаты белән бүләкләнгән**

килене Гаделбану (1910), оныгы Нәкыя (1939) белән яши. Гыйлемхан Күчемов хәрби хезмәткә чакырыла, язмышы билгесез. Фәхрислам Шәйхелислам улы Күчемов – Ватан сугышы ветераны, хатыны Бәһия апа Нуретдинова Катай мәктәбендә башлангыч классларны укытты, бүгенге көндә нәселен улы Гыйлемҗан (1947), оныклары дәвам итә. Кече сержант Гыйлемҗан Күчемов 1944 елның 10 мартында сугышта алган яралардан Украинада мәрхүм була.

Шакирҗан Әхтәмҗан улы балалары: Хәтирә (09.09.1914; анасы Миңлекамилә мулла Мөхәммәтшәриф кызы), Мәгъфүрә (10.10.1917). Миңлекамилә Ватан сугышы алдыннан Камилә Шакирова (1880) дип теркәлгән, балалары Хәсәнҗан (1924), Сәхипзадә (1927), Гайшә (1930), Салихҗан (1936) белән яши. Хәсәнҗан белән Миңсылу балалары: Зәйтүнә (1952), Гафурҗан (1955), Сәлим (1959), Барый (1961), Самат (1963). Сәхипзадә уллары: Рәис, Рәшит, Рәфикъ. Салихҗан уллары: Ирек, Динар. Хәсәнҗан белән Сәхипзадә Шакировлар – Ватан сугыш ветераннары, Хәсән абыйдан китап авторы кайбер истәлекләр язып алды, нәсел тарихын сораштырды.

Габдерәкыйп Мөхәммәди улы балалары: Габдерәшит (1875), Габделмәҗит (04.09.1877), Хөснизиядә (1881), Фәтхелбәян (20.07.1883–1893; анасы Бәдигылҗамал). Габдерәкыйп кызы Хөснизиядә 1903 елда Корычның Габделбәян Габделгалләм улы белән никахлаша, кызның ризалык шаһиты нәселдәше Мөхәммәтвәли Мөхәммәтшәфикъ улы була. Берничә елдан кияүдән кайтып, Хөснизиядә (27 яшь; икенче никах) 1907 елның 1 мартында авылдашы Ражетдин Хөснетдин улы белән кавыша, балалар таба.

Габдерәшит Габдерәкыйп улы 1900 елның 12 февралендә Иске Катайның Тимергали Корбангали улының кызы Бибигайшә (19 яшь) белән никахлаша. Егетнең ризалык шаһитлары Җәләлетдин Мөхәммәтсәлим улы белән Мөхәммәтвәли Мөхәммәтшәфикъ улы була. Габдерәшит балалары: Миңлемөхәммәт (04.10.1909–1914), Миңлегали (30.05.1914–1914).

Мөхәммәтзариф Мөхәммәди улы Күчемов 1902 елның 16 гыйнварында Яңа Катайның беренче мәхәлләсендә Әмәкәйнең Бәдретдин Шәрәфетдин улының кызы Шәмсекамәр (17 яшь) белән никахлаша, балалары Мөхәммәтхафиз (24.02.1904–1904), Шәмсеҗиһан (22.07.1905), Фәрхиҗиһан (10.12.1909) туа. Бу хатыны мәрхүм булгач, Мөхәммәтзариф Хәтирә (1885–1974) белән никахлаша. Мөхәммәтзариф 1936 елда мәрхүм була, Ватан сугышы алдыннан Хәтирә балалары Харис (1915), Кәнзел (1921), Гамил (1929), Назиф (1931–2009) белән яши. Харис белән Кәнзел – Ватан сугышы корбаннары, танкист Харис 1945

елның маенда Польшада һәлак була, кавалерист Кәнзел хәбәрсез югала. Хәтирә сугыш чорында тимерче булып эшли.

Монда бер искәрмә ясап үтик. Яңа Катайның 1917 елга чаклы метрикәләрендә Мөхәммәтзарифның улы Харис бөтенләй теркәлмәгән (андый очраклар булгалый). Әгәр ул теркәлгән булса, шәҗәрәне бүгенге көнгә чаклы тоташтыру күпкә җиңел булыр иде. Наил Гамил улы (1955) белән – 2017 елда, Әлфинә Назиф кызы (1967) белән 2020 елда хат алышу, Мөхәммәтзарифның башка балаларын, атасының исеме Мөхәммәди булуын ачыкларга ярдәм итте. Әлфинә ханым Мөхәммәтзарифның бер кызы Фәрхиҗиһан (халык телендә Фәрхизиян) булуын әйтә алды, ә ул метрикәдә теркәлгән булып чыкты. Бу мәгълүматка таянып, Мөхәммәтзариф нәселен бүгенге көндә кемнәр дәвам иткәнен ачыкладык, шәҗәрә төзегәндә кечкенә тоелган мәгълүмат та әһәмиятле булуына тагын бер кат инандык.

Гамил Күчемов белән Уйкыя Тимерхан кызы (1930–2007; Мулланурныкы) балалары: Рәшидә (1951), Наил (1955), Рафаэль (1957), Камил (1960), Вәсимә (1963), Илшат (1965). Назиф Күчемов белән Вәсбия Фәхрислам кызы (1933–2005; Авыргазы районыннан) балалары: Рәсимә (1956), Нәвәзир (1960), Насих (1961), Шамил (1963), Ришат (1965), Әлфинә (1967).

«Запастагы солдат» Габдулла Мөхәммәди улы (24 яшь; вәкиле – агасы Мөхәммәтзариф Мөхәммәди улы) 1911 елның 6 гыйнварында Иске Катайның Госман Йосыф улының кызы Фәрхебҗамал (17 яшь) белән никахлаша, балалары Шәмсекамал (09.02.1912), Шәрхемулла (29.10.1914–1915) дөньяга килә.

Мөхәммәди 1895 елның 30 мартында мәрхүм була. Метрикәдә аның атасы Габделҗәлил Кылчым улы Күчемов дип язылган.

Габделҗәлилнең дүртенче улы Мөхәммәтҗан иде. Мөхәммәтҗан балалары: Габделҗәмил (1836–19.06.1913; 50 ел Яңа Катайда башта имам, аннары имам-хатыйп вазифаларын башкара), Мөхәммәтхафиз (1840), Мөхәммәтлатыйф (1841; Яңа Катайның икенче мәхәллә мөәзине) һәм Мөхәммәтзариф (1848–28.05.1910; Яңа Катайның беренче мәхәлләсендә мөәзин вә мөдәррис), Бибикамилә (1851). Мөхәммәтҗан кызы Бибикамилә (25 яшь; икенче никах) 1876 елның 10 декабрендә Казан губернасы Казанбаш авылының Хәлилулла Таһир улы (28 яшь; икенче никах) белән никахлаша.

Имам Габделҗәмил Мөхәммәтҗан улы балалары: Мөхәммәтфатих, Мөхәммәткәшиф (1872; 1911 елдан Яңа Катайның беренче мәхәллә мөәзине), Бибихәтимә, Мөхәммәтхәтим (1873), Мөхәммәткашшаф (25.03.1874; анасы Гайшә), Бибимәхтүмә (05.05.1877; анасы Гайшә), Мөхәммәтнасыйх (21.03.1880; анасы Бибикамилә), Мөхәммәтнасыйх (10.02.1883; 1914 елның 2 апреленнән Яңа Катайның икенче мәхәллә имам-хатыйбы), Кифая (20.04.1889; анасы Бибикамилә), Ниһая (Нигая; 1890), Мөхәммәтвазыйх (1892), Мөхәммәтгакиф (02.10.1894–1895; анасы Бибикамилә Сафиулла Равил улының кызы), Гыйная (12.11.1895–1898), Хөснелгыйная (02.06.1898; анасы Бибикамилә), Нажия (10.10.1909; анасы Мәгъдән). Габделҗәмил кызы Бибифатиха (18 яшь) 1890

елның 20 мартында авылдашы Гыйззәтулла Рәхмәтулла улы (икенче никах) белән никахлаша. Икенче кызы Бибихәтимә (22 яшь) 1893 елның 16 февралендә авылдашы имам Гыйлемхан Бәдретдин улы Азаматов (25 яшь; икенче никах) белән кавыша. Өченче кызы Кифая (18 яшь) 1910 елның 21 гыйнварында Яңабирде авылы имамы Солтангәрәй Сөләйман улы (27 яшь; атасы Сөләйман Шәмсетдин улы) белән гаилә кора. Дүртенче кызы Ниһая (Нигая) авылдашы Шәрхемулла Кәлимулла улына кияүгә чыга.

Мөхәммәтфатих имам Габделҗәмил улы Күчемов балалары: Мөхәммәтзаһит (01.01.1893), Һидая (20.08.1894; анасы Гыйльмишәрифҗамал типтәр Габделваһап кызы), Мөкәррәмә (11.03.1897), Мөхәссәнә (01.01.1900), Мөхәммәтгабит (13.07.1901–1903), Мөхәммәтсабит (30.09.1903), Сәкинә (18.05.1907), Саҗидә (1910–1910), Мөхәммәтнәкыйп (19.01.1914–1915), Саҗидә (20.01.1920). Сабит Фатихов – Ватан сугышы ветераны, сугышка чаклы Иске Корыч сельпосына караган кибет мөдире булып эшли, авыл советы кенәгәсендә 1940–1943 елларда хатыны Мәйсәрә (1906), балалары Лүбәбә (? 1927), Фоат (1929), Җәүһәт (1935), Шәүкәт (1939), Мизхәт (1940), анасы Гарифә (1873) теркәлгән.

Мөхәммәтхәтим имам Габделҗәмил Мөхәммәтҗан улы Күчемов (26 яшь) 1899 елның 5 мартында авылдашы Шәяхмәт Дәүләтша улының кызы Бибизөһрә (17 яшь) белән никахлаша, балалары Мөнәвәрә (16.02.1900; Улан-Удэ шәһәрендә гомер иткән), Әхмәтнәгыйм (06.12.1901; Сәмәрканд шәһәрендә яшәгән), Мөсәвәрә (10.04.1904; Сеңрәндә яшәгән), Мөшәррәфә (12.01.1908), Әхмәтзәки (21.10.1910–1914, эч авыруыннан вафат), Әхмәтшәриф (29.07.1912–10.06.1993), Миргаязетдин (18.05.1914; гомере Сибайда үтә), Тәрҗимә (13.12.1915), Мөнәвәрә (Улан-Удэда яшәгән) туа. Әйтергә кирәк, Мөхәммәтхәтимнең беренче хатыны Гөлчирә Мөхәммәтгәрәй кызы була, әлеге никахтан Гөлшәрифә (25.12.1898) туа. Мөхәммәтхәтим кызы Мөшәррәфә Иске Катайның Суфиәхмәт Нәбиев белән кавыша. Икенче кызы Тәрҗимә Иске Катайның Сәлахетдин Фәррахов белән гаилә кора.



**Әхмәтшәриф Күчемов (сулда) хезмәттәшләре белән**

Әхмәтшәриф Күчемов – өч сугыш (фин, Ватан, япон) ветераны, 1934 елда хәрби хезмәткә чакырылып, аннан кайтып, тагын китеп 1946 елда гына туган авылына кайта. Сугышка чаклы Иске Катайның Шәехзаман Вәлиәхмәт

улының кызы Тәзкирә белән гаилә кора, уллары Фәнил (1939) һәм Разит (1941) туа. Тәзкирә ире сугышларда йөреп кайтканын көтми, Катайның Хәбибулла (кушаматы «Хәбеш») исемле кешесе белән яши башлый. Әхмәтшәриф сугыштан кайткач Чакмагыш районы Бүләк авылында туып үскән Зәйнәп Назиф кызы белән никахлаша, аннан Денис (1947) туа. Хатыны мәрхүм булгач, Әхмәтшәриф Корычкаранның Мәгъсүмә Әхмәтҗан кызы


УЧЕТНАЯ КАРТОЧКА
К ВОЕННОМУ БИЛЕТУ
серии ... № ...
№№ ВУС 014
1912
1. Год рождения
(фамилия, имя и отчество)

| | | |
|---|---|---|
| 2. Запас 1 категории | 3. Группа учета | 4. Состав Солдаты |
| 5. № ВУС | 6. Наименование военно-учетной специальности | 7. Должностная квалификация |
| 8. Воинское звание Рядовой | 12. Национальность | |
| 9. Гражданская специальность | 13. Родной язык | |
| 10. Партийность | 14. Знание иностранных языков | не владеет |
| 11. Состоит ли в ВЛКСМ | 15. Социальное положение | |

Әхмәтшәриф Күчемовның хәрби документы

Күчемова белән гаилә кора, балалары Венер (10.01.1952), Рәдис (18.031956), Рәмзил (16.01.1958), Рәмил (04.07.1961), Розалия (13.10.1963) туа. Насыйбулла карттан бакчачылык эшен кабул итеп, 1953–1966 елларда бригадир була. Миргаязетдин Мөхәммәтхәтим улы Күчемов сугышта өлкән лейтенант (взвод командиры) була, «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале (30.04.1943) белән бүләкләнә, исән-имин кайта (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән). Мөхәммәтхәтим балалары турында өстәмә мәгълүматны Денис Күчемов белән Розалия Әхмәтшина (Күчемова) язып җибәрделәр.

Мөәзин Мөхәммәткәшиф имам Габделҗәмил Мөхәммәтҗан улы Күчемов балалары: Әфтах (02.07.1904; анасы Мәгъдәнҗинан Сәмигулла кызы), Нажия (1909–1914), Әхнәф (15.06.1912–1914), Мөзәккия (30.01.1914–1914). «Үткәннәрен бел Катайның» китабында аның турында сөйләгәндә төгәлсезлек киткән, Мөхәммәткашшаф дип язылган, бу хатаны төзәтәбез.

Мулла Мөхәммәтнасыйх имам Габделҗәмил улы балалары: Әминә (20.06.1914; Хәлимә Әбүбәкер кызы), Мөхәммәтләбип (25.01.1916–1992), Габделхәмит (11.08.1917–1917), Зөфәр (1924; Ватан сугышы ветераны (әсирлектә булып, 1944 елның 9 апрелендә азат ителә)), Мәрьям (14.11.1925), Фәрит (1928). Мөхәммәтләбип фин сугышында катнаша, аның бердәнбер баласы Илдус Күчемов (22.01.1943) Төрекмәнстанда, соңгы чорда Казанда яши, гандбол һәм баскетбол буенча тренер булып эшли.

Мөхәммәтвазыйх Габделҗәмил улы Күчемов (1892–1970) – Ватан сугышы ветераны (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән), хатыны Мөнәззәһә Сәлимгәрәй кызы (Сеңрәннән; 1899–1980), кызы Мөзәккия (1922–2007) була. Мөзәккия апа – шәфкать туташы, ә аның ире Зиннур Шәяхмәтов гомеренең соңгы чорында Катай авылы мулласы булды.

Монда бер искәрмә ясап үтик. Мөхәммәтвазыйх турында «Халык хәтере» («Память народа») сайтында 1944 елның 26 мартында Калинин өлкәсенең Пушкин районы Гнилуха авылы янындагы сугышта һәлак булды, дип язылган. Документның беренче битеннән күренгәнчә, 26 нчы Кызыл Байраклы Сталин дивизиясендә март-апрель айларында 220 кеше һәлак булган. Димәк,

дивизия канкойгыч сугышлар алып барган, югалтулар күп булган, шулар исәбенә ялгыш Мөхәммәтвазыйх та кергән. 26 мартта ул яраланып дәвалану өчен тылга озатылган булган, шул сәбәпле хезмәттәшләренең күз уңыннан чыккан, күрәсең.

Югарыда сүз Мөхәммәтҗанның беренче улы Габделҗәмилдән киткән тармаклар турында барды, икенче улы Мөхәммәтлатыйфка күчик. Мөәзин Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтҗан улы Күчемов балалары: Мөхәммәтшакир (1866), Мөхәммәтрәиф (25.08.1880–1910; анасы Сафа), Рәйфә (18.10.1883), Мөхәммәтхәлиф (1885), Мөхәммәтназиф (20.03.1887), Мөхәммәтзариф (1891–1917), Мөхәммәтситдыйкъ (22.08.1893; анасы Нурсафа Сәетборхан кызы), Рәйфә (09.03.1895–1895), Ләбип (07.04.1895; анасы Бибисафа), Мөхәммәтталип, Мөхәммәтнәҗип (22.01.1897), Сәрвиҗиһан (05.01.1898; анасы Нурҗиһан мөәзин Нурмөхәммәт Габделханнан улының кызы), Гыйльмисафа (07.06.1899; анасы Бибисафа Хасбулат кызы), Һидая (21.04.1900; анасы Майҗиһан мөәзин Нурислам кызы), Мәрьям (26.04.1902; анасы Нурсафа), Мөхәммәтмөбарәк (17.07.1904–1905; анасы Маһруй Габделгани кызы). Мөхәммәтлатыйфның бер хатыны Иске Куянның Әмирхан Арслан улының кызы Бибихатимә була, 1889 елның 23 октябрендә «өлфәт вә мәхәббәт булмау сәбәбеннән» аерылышалар. Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтҗановның үзе белән бергә яшәгән дүрт улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (70 яшь), кызы һәм килене белән яши, 11,91 дисәтинә җире, җилгәргече, 4 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче яллый.

Мөхәммәтшакир мөәзин Мөхәммәтлатыйф улы (37 яшь; икенче никах) 1903 елның 19 сентябрендә нәселдәше Гыйльметдин Бәдретдин улы Күчемов кызы Рәйфә (20 яшь; икенче никах) белән кавыша. Мөхәммәтшакир балалары: Галикарый (18.09.1904), Мәхбүбә (03.10.1911), Гәнбәрия (22.04.1917; анасы Хәнифә Әхмәдулла кызы). Мөхәммәтшакир Латыйпов 1917 елда хатыны (45 яшь) белән яши, 4,07 дисәтинә җире, 2 аты була. Ватан сугышы алдыннан Шакир Латыйповның хуҗалыгы – Иске Катайда, хатыны Хәнифә (1890), балалары Гәнбәрия (1917), Закир (1922), Кәрам (1927) була.

Мөхәммәтрәиф мөәзин Мөхәммәтлатыйф улы балалары: Габдерәуф (02.07.1904–11.05.1905; анасы Маһинур Шәйхелмансур кызы), Мәрзия (11.12.1906), Мөхәммәтрәхим (07.08.1909). Маһинур 1905 елның апрелендә 21 яшьтә мәрхүм була, шул ук елның декабрендә Мөхәммәтрәиф хатын итеп авылдашы Шәйхелмансур Миңлехан улының икенче кызын (Майсорур; 18 яшь) алып кайта.

Мөхәммәтхәлиф мөәзин Мөхәммәтлатыйф улы (26 яшь) Минзәлә өязе Суыксу авылының Шаһидулла Фәйзулла улының кызы Миңлеҗиһан (19 яшь) белән никахлаша. Яңа Катайның икенче мәхәлләсендә 1911 елның 9 ноябрендә теркәлгән бу никахта ике якның ризалык шаһитлары булып Бөгелмә өязе Габдрахман авылыннан Габделгаффар Габделсаттаров һәм шул өязнең Сәпәй авылыннан Мөхәммәтхарис Даут улы языла. Мөхәммәтхәлиф балалары: Мир-

гасыйм (1913 елда мәрхүм), Миргалим (20.11.1912), Хәнәфи (21.09.1914–1914), Риазелҗинан (21.11.1917). Шунысы кызык, метрикәдә нәкъ оныгы Миргалим артыннан Яңа Катайда яшәүче Суыксу кешесе Шаһидулла Фәйзулла улының үз баласы Шәйислам (04.12.1912) теркәлгән.

Мөәзин Мөхәммәтназиф Мөхәммәтлатыйф улы Күчемов улы (1887) балалары: Гыйльмисафа (1921, инвалид), Һәмам (25.03.1925; анасы Ханә Әхмәтзакир Күчемов кызы), Микдам (1928), Гыйдам (1931), Кыйвам (1938). Мөхәммәтталип мөәзин Мөхәммәтлатыйф улыннан Әфлах (20.03.1915; анасы Бибинур Мөхәммәтша кызы) билгеле.

Мөхәммәтҗанның өченче улы Мөхәммәтзариф иде. Мөәзин вә мөдәррис Мөхәммәтзариф Мөхәммәтҗан улы Күчемов уллары: Мөхәммәтгариф (1885; 1910 елның 6 ноябреннән Яңа Катайның 3 нче мәхәлләсендә имам-хатыйп), Кәнзелмәгариф (1888; халык телендә Кәнзел), Нәҗменгариф (1894), Шәмсемәгариф (17.03.1898; анасы Бибикафия Габделҗаббар кызы).

Мөхәммәтгариф мөәзин Мөхәммәтзариф улы (24 яшь) 1910 елның 10 гыйнварында авылдашы Мөхәммәтхарис Ярулла улының кызы Бибимөнәвәрә (17 яшь) белән никахлаша, балалары Җәмигелфнүн (28.11.1911), Дөррәтелгалия (25.08.1913), Мөхәммәтгавис (20.11.1915), Дөрнаҗия (1917), Мөкәррәмә (1922), Мисбах (1924), Әсгать (1926), Әсләм (1928), Хәзинә (1931), Мөстәкыйм (1935) һәм Бәшир (1937) туа.

1917 елгы документтан Мөхәммәтгариф мулланың 9,30 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һәм башка маллары булуы, хезмәтче тотканы билгеле. Бу вакытта аның энесе Кәнзелмәгариф Мөхәммәтзарифов (28 яшь) Беренче бөтендөнья сугышыннан кайтмаган, йортында хатыны (19), яңа туган улы, ике анасы (50, 60), энесе Нәҗменгариф (23 яшь) һәм сеңлесе (18 яшь) калган, хуҗалыгында 16,99 дисәтинә җире, хезмәтчесе, җилгәргече, 4 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була.

Мөхәммәтгариф балалары турында сүз чыкса, иң беренче сугыш ветераны Гавис абыйны телгә алабыз. Ул гомере буена сәгать төзәтте, мич чыгарды, аның улы Нәфис очкыч ясап, Катай өстеннән очып, күпләрне осталыгы белән шаккатырды. Мисбах абый пенсиягә чыкканчы хисапчы булып эшләде, авылның хөрмәтле кешесе, һәвәскәр бакчачы-умартачы иде. Әсләм абый монтер-электрик, дини белемле булды. Укытучы Хәзинә апа, урманчы Мөстәкыйм абый – болар һәм Мөхәммәтгарифнең башка балалары, оныклары турында күп язарга булыр иде.

Мөхәммәтзарифның икенче улына күчик. Кәнзелмәгариф белән Кифая Ибраһим кызы (1895 елгы) ир балалары: Әбүзәр (04.02.1917–05.02.1943; сугышта һәлак була), Габделбәр (1921-сентябрь, 1941; сугышта хәбәрсез югалган), Искәндәр (1922; сугышка китә, язмышын ачыклап булмады) һәм Әсләм (1937).

Мөхәммәтзарифның өченче улы Нәҗменгарифтән (ул Камышлыдан Баулыга күченеп, анда сәгать төзәтү остасы булып эшләгән) Наҗия, Наҗиядән (1924–2000) Гали һәм Әнисә Ганиевләр дөньяга килгән. Гали Газизович Гани-

ев – озак еллар «Баулынефть» идарәсе начальнигы, Татарстан халык депутаты булды, соңгы елларда Әлмәттә үзенең нефть бизнесы белән мәшгуль иде.

Мөәзин вә мөдәррис Мөхәммәтзариф Мөхәммәтҗан улы Күчемовның кызлары да шактый була. Беренче мәхәллә кенәгәсендә Кәшифә (13.09.1883), Бибикәшифә (1887), Рәйфә (1889–1898), Бәһия (17.07.1895; анасы Бибикафия Габделҗаббар Мозаффар улының кызы), Фәүзия (1896–1897), Бәһия (1898), Дөһөдия (08.06.1899), Фәрәгыя (08.04.1902; анасы Сәүдә), Зөлфия (08.07.1906–1909; анасы Сәүдә мулла Таип кызы), Рәшидә (03.08.1909; анасы Сәүдә) теркәлгән. Мөхәммәтзариф кызы Бибикәшифә 1904 елның 20 февралендә авылдашы мулла Гыйниятулла Габделлатыйф улы (25 яшь; атасы Габделлатыйф Габделсаттар улы) белән никахлаша. Икенче кызы Бәһия 1916 елның 7 июнендә Бәләбәй өязе Метер Әюп авылының Ярмөхәммәт хәзрәт Җамалетдин улы (33 яшь; өченче никах) белән кавыша.

Мөәзин вә мөдәррис Мөхәммәтзариф Мөхәммәтҗан улы Күчемов турында беренче китабымда берникадәр мәгълүмат биргән идем. Яңа Катайдагы мәдрәсәнең аның исеме белән бәйле булуын, аның кулы астында белем алучыларның берничәсе авылыбызда дини вазифаларны башкаруын искәртеп үтик. Мөхәммәтзариф мәдрәсәсен тәмамлаучылар башка авыллардан да булгандыр дип уйлыйбыз, тирә-як авылларның метрикә кенәгәләрен карап чыкканда, бу хакта мәгълүмат табып булыр иде кебек.

Югарыда Габделҗәлил Кылчым улы Күчемовның дүртенче улы Мөхәммәтҗаннан киткән тармакларны карадык. Габделҗәлилнең бишенче улы Әхмәтҗанны 90 нчы елларда истәлекләре белән уртаклашкан нәселдәшләре ишан хәзрәт, дип әйттеләр. Әхмәтҗан Габделҗәлил улы балалары: Габдрахман (1844), Габдулла (1849), Хәбибрахман (1855), Әхмәдулла (1857; мулла), Ахунҗан (1861–14.02.1911; 1890 елның 21 апреленнән Яңа Катайның беренче мәхәлләсендә имам-хатыйп) һәм башкалар.

Имам Габдрахман мулла Әхмәтҗан улы балалары: Гомәр (10.08.1874–1876; анасы Маһиҗамал), Әгъләм (13.02.1878), Бибиәминә (10.06.1880), Әкрәм (03.01.1883; анасы Маһиҗамал).

Хәбибрахман мулла Әхмәтҗан улы Күчемовның ике хатыннан балалары: Мөкәррәмә (1885), Габдулла (20.01.1889–03.06.1914; анасы Шәмсеруй Фәйзулла кызы), Бибифакия (11.06.1889; анасы Сатирә), Лотфрахман (19.11.1890; анасы Бибисатирә Мөхәммәтшәриф кызы), Фәйзерахман (1891–1893), Бибимөшәррәфә (1892), Гыйздерахман (15.05.1894; Кемерово өлкәсенең Белово шәһәре мулласы), Мәшһүдә (1899; анасы Сатирә Мөхәммәтшәриф Батырша улының кызы), Таибә (25.01.1901; анасы Сатирә), Шаһәгъзам (халык телендә Шәйәгъзам; 27.02.1903–1958), Хәбибнаҗәр (18.10.1904; анасы Шәмсебану Габделхәким кызы), Нәфисә (1906–1913), Кафия (10.03.1907), Миңленасиха (23.10.1908; анасы Шәмсебану), Мөдәррис (08.02.1909), Мәликә (25.07.1912), Мөҗәһит (12.06.1915; анасы Шәмсебану Габделхәким кызы; беренче мәхәллә), Мөхтәсип (08.01.1916; анасы Сатирә), Мөҗәһит (19.10.1916; анасы Шәмсебану).

Хәбибрахман кызы Бибимөшәррәфә (17 яшь) 1909 елның 17 ноябрендә Тырбый авылының Хаҗгали Сәетгәрәй улы (25 яшь) белән никахлаша. Кызның вәкилләре булып Лотфрахман Хәбибрахман улы белән Гыймадетдин Гаязетдин улы теркәлә. Кияүнең вәкиле Тырбый мөәзине мулла Габдерәхим мулла Әхмәтҗан улы була. Икенче кызы Мөкәррәмә (30 яшь) 1915 елның 19 мартында авылдашы Муллаян Дәүләтгир улы (48 яшь; икенче никах) белән гаилә кора.

Хәбибрахман улларыннан (Лотфрахман, Гыйздерахман, Шәйәгъзам, Мөдәррис) нәсел шактый тармакланып дәвам итә. Мәгълүмат аз булу сәбәпле, боларның барысына аерым-аерым тукталып тормыйбыз, аларның балалары Мөхтәсип Хәбибрахманов төзегән шәҗәрәдә күрсәтелә.

Шәйәгъзам Хәбибрахманов белән Мәбрүрә Имамгаздәли кызы (1921–2010; Яңа Корычтан) балалары: Вәрис (1949; Чаллы милициясендә өлкән офицер булып хезмәт итте), Мөдәррис (1952), Мөхтәсип (1953), Нурсидә (1957). Мөхтәсип – үз нәселе тарихы белән ныклап кызыксынучыларның берсе, Күчем нәселенең Габделҗәлил тармагы турында Хәсән абый Шакиров мәгълүматын халыкка җиткерүче, шәҗәрә төзүче.

Мулла Әхмәдулла мулла Әхмәтҗан улы балалары: Мөхәммәтгариф (05.01.1889; анасы Бибигайшә Габделгаффар кызы), Сәрия (1895–1915).


**Нәселдәшләр Галимҗан Ахунҗан улы белән Гыйздерахман Хәбибрахман улы (уңда)**

Имам Ахунҗан мулла Әхмәтҗан улы Күчемов (24 яшь) 1889 елның 23 гыйнварында Иске Катайның Миңлегәрәй Мифтахетдин улының кызы Бибимәэлүфә (18 яшь) белән никахлаша, балалары Шәкүрҗан (05.02.1890; 1913 елдан Яңа Катайның беренче мәхәлләсендә имам), Мәсрүрә (1893–1909), Сабирҗан (20.01.1894), Әмирҗан (02.01.1897–1898), Галимҗан (25.04.1899–10.02.1982), Салихҗан (06.01.1902), Әсхия (26.05.1904), Рәкыя (02.01.1909), Миргазиян (06.06.1911) дөньяга килә.

Имам Шәкүрҗан Ахунҗан улыннан Фаизә (03.12.1914–1916; анасы Шәмсеҗиһан Исрафил кызы) билгеле, бер шәҗәрәдә тагын улы Фәез теркәлгән.

Галимҗан Ахунҗан улы белән Мәдхинур (15.08.1903–05.07.1986; Тыпыйныкы) балалары: Нуар (15.09.1926–20.09.2015), Әнәс (1932), Нәсибә (14.02.1935–25.02.2003), Вәис (21.12.1938), Сәнирә (21.08.1942), Рәис (22.04.1946). Вәис Галимҗан улы Ахунов совет чорында Бакалы район башкарма комитеты рәисе булды, аннан соң да җитәкче вазифалар башкарды. Нәсибә апаның кызы Илсия Печенцева (Ахунҗанова; 1962) үз нәсел тарихы белән кызыксынып яши, авторга күп мәгълүмат әйтте.

Сабирҗан мулла Ахунҗан улы (23 яшь) 1916 елның 23 маенда Иске Катайның Гыймадетдин Гыйлаҗетдин улының кызы Гыйльмисафа (18 яшь) белән

никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтсолтан Мөхәммәтгәрәй улы белән Мөхәммәтшакир Могтәметдин улы, егетнеке Сәлимгәрәй Шәйгәрәй улы белән Мөхәммәтсадыйк Сафиулла улы була. Сабирҗан Ахунҗан улы Күчемов Чүмәлә Катайга күченеп, анда 1922 елның 21 февраленнән мөәзин вазифасын башкара, хатыны Гыйльмисафа Гыймадетдин кызы була. Сабирҗан Тыпыйда Әгъләм Күчемов мәдрәсәсен тәмамлаган.

Миргазиян Ахунов (Ахунҗанов) (1911) колхозда тракторда эшли, 1943 елның 22 февралендә Ватан сугышында һәлак була (документта Күчемов фамилиясендә). Авыл советы кенәгәсендә хатыны Әһлия (1917), балалары Фәйрүзә (1935) һәм Зиннур (1940) теркәлгән.

Югарыда Кылчым картның өлкән улы Габделҗәлилдән киткән тармак тасвирланды. Бу тармакның бүген кайбер буыннары Мөхтәсип Хәбибрахманов төзегән шәҗәрәдә тулырак яктыртыла, шуңа күрә тулы күзәтү ясап тормадым. Ул шәҗәрәдә Габделҗәлилнең атасы ялгыш Мәннәп дип күрсәтелгән, аннан соңгы аскы буыннар да дөрес түгел, ул хаталар төзәтелер дип уйлыйбыз.

Кылчымның икенче улы Габделсалих 1826 елда 53 яшьтә вафат була. Габделсалихтан нәсел калмый, аның 21 яшьлек улы Габделгалләм 1825 елда дөнья куя.

Кылчым картның өченче улы указлы мөхтәсип һәм мөдәррис Габделмәннан иде. Габделмәннан Кылчым улы Күчемов балалары: Мифтахетдин (1810), Нәҗметдин (чыганакта Назиметдин; 1811), Шәйхетдин (1815; 1834 елгы документта исеме Шәмсетдин), Бәдретдин (1819–26.03.1902; 1902 елгы метрикәдә фамилиясе Кылчымов), Сәйфетдин (1902 елда Саяфетдин дип язылган; 1832–10.07.1902).

Габделмәннанның олы улы Мифтахетдиннән нәселне Сәхипгәрәй (1841–10.02.1894) дәвам итә. Сәхипгәрәй Мифтахетдин улы балалары: Бибифаизә (1858), Гыйльмебану (1873), Солтангәрәй (06.09.1877), Сәлимгәрәй (10.08.1880; анасы Гөлбану), Сәетгәрәй (10.06.1883), Сәлимгәрәй (1888–1889), Гыйльменур (11.02.1890; анасы Гөлбану Галләметдин кызы). Сәхипгәрәй кызы Гыйльмебану (17 яшь) 1890 елның 15 октябрендә Корычның Шәйхелислам Гыймаделислам улы (25 яшь; икенче никах) белән кавыша. Икенче кызы Бибифаизә (35 яшь; өченче никах) 1893 елның 19 февралендә Карабашның Шәмсетдин Габдулла улы (40 яшь; икенче никах) белән никахлаша.

1890 елның 15 октябрендә булган никахта кызның вәли вәкиле – атасы Сәхипгәрәй Мифтахетдин улы, егетнең вәли вәкиле – атасы Гыймаделислам Шәяхмәт улы, ризалык шаһитлары Садретдин Нәҗметдин улы белән Фәррахетдин Шәйхетдин улы нәсел тамгаларын салганнар.



**1890 елгы метрикә фрагментында нәсел тамгалары**

Корыч вәкиленең өч таяктан торган тамгасы Яңа Катайның бер зур нәселендә дә күзәтелә, димәк, Корычта да бу нәсел кешеләре яши. Нәсел тамгасы әнә шулай ике авыл кешеләренең кан-кардәшлеген чагылдыра.

Габделмәннанның икенче улы Нәҗметдиннән балалары Нуретдин (1839), Насретдин (1844), Садретдин (1851), Мәстүрә (1858), Бибишәргыя (1859) дөньяга килә. Нәҗметдин кызы Мәстүрә (17 яшь) 1875 елның 1 февралендә Минзәлә өязе Чуракай авылының Габдерәфикъ Габделсалих улы (23 яшь; атасы Габделсалих Габделлатыйф улы) белән кавыша. Икенче кызы Бибишәргыя (19 яшь) 1878 елның 1 октябрендә Кашшафетдин Шәрәфетдин улы (22 яшь) белән никахлаша.

Нуретдин нәселен улы Фәхретдин (1868) дәвам итә. Фәхретдин Нуретдин улы Күчемов (25 яшь) 1893 елның 13 октябрендә нәселдәше Әфләтун Мөхәммәтсәлим улы Күчемов кызы Бибизәйнәп (19 яшь) белән никахлаша. Фәхретдин балалары: Газетдин (22.10.1894; анасы Бибизәйнәп), Сәвия (1897–1911), Бибисаимә (01.03.1900), Гыйлаҗетдин (04.02.1903), Мөнирә (14.10.1906), Фаизә (17.08.1909–1909), Мирсәгыйть (14.09.1910; анасы Гашурә), Мөҗәһит (09.12.1911), Гыйрфанетдин (13.12.1913–1914; анасы Гаширә), Мәгъфурҗан (10.06.1915–1916; анасы Гаширә Габделхәким кызы), Әбелмөкәрим (20.09.1917).

Насретдин Нәҗметдин улы Күчемов балалары: Гакифә, Нурлыгаян (1876), Садретдин, Бибифатыйма (1881), Бибифакия (1886), Әгъзаметдин (22.01.1889; анасы Гайниҗамал Габделвәли кызы). Насретдин кызы Гакифә нәселдәше Мөхәммәтбәсим Бәдретдин мулла улы Күчемов белән никахлаша. Икенче кызы Бибифатыйма (17 яшь) 1899 елның 12 декабрендә Корычның Мөхәммәтнасыйп Мөхәммәтзакир улы Фәризунов (25 яшь) белән гаилә кора. Кызның вәли вәкиле – бертуган агасы Нурлыгаян Насретдин улы, ризалык шаһитлары Фәррахетдин Шәйхетдин улы (нәсел тамгасын салган) белән Фәхретдин Бәдретдин улы була. Бибифатыйманың бу никахы уңышлы булмый, 1904 елның 28 октябрендә Иске Катайның Сайран нәселеннән Кашшафетдин Шәрәфетдин улы (25 яшь; икенче никах) белән кавыша. Насретдиннең өченче кызы Бибифакия 1903 елда Туктаголның Муллагали Һидиятулла улы белән гаилә кора.

Нурлыгаян Насретдин улы Күчемов балалары: Фәтхелбәян (25.09.1901–1905), Зөләйха (09.04.1905; анасы Зөлхия Габдерәфикъ кызы), Камилә (12.12.1907–1912), Фәтхелбәян (15.09.1910; анасы Зөлхия Габдерәфикъ кызы), Хәния (19.06.1915). Нурлыгаян 1909 елның 3 гыйнварында икенче хатын итеп Хөсникамал Мохтарулла кызын (35 яшь; икенче никах) ала. Нурлыгаян Насретдинов (42 яшь) 1917 елда хатыны (35 яшь), улы һәм ике кызы белән яши, 4,66 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була. Нурлыгаян гаиләсендә Ватан сугышы алды елларында хатыны Зөлхия (1877), улы Гыйльмебаян (1924) була. Фәтхелбәян (1910) белән Гыйльмебаян Күчемовлар – Ватан сугышы корбаннары (исемнәре Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Гыйльмебаян Күчемов 1943 елның 3 мартында Курск өлкәсенең Лубышево авылы янындагы сугышта һәлак була, «Халык хәтере» сайтында «Кузумов Бо-

ян» дип теркәлгән (шундагы документны ачып, атасының фамилиясе Күчемов икәнен белдем). Лубышево янындагы сугышта 354 нче дивизиядә бер көнне генә йөзләрчә кеше һәлак була, болар арасында Башкортстан ир-егетләре исемнәре дә күзгә чалына, шуннан Җинү никадәр зур корбаннар бәрабәренә килгәнен беләсең.

Әгъзаметдин Насретдин улы Күчемовның кызы Зөлфия (24.10.1925; анасы Гөлчирә Гыйлаҗетдин кызы) билгеле.

Садретдин Нәҗметдин улы Күчемов балалары: Шәмсенәһар (1876), Имаметдин (02.12.1880), Бәдеркамал (1882), Хәйретдин (1884–1906), Зиннуретдин (1886). Садретдин кызы Шәмсенәһар (17 яшь) 1893 елның 10 гыйнварында Корычның Габдерәхим Габделхәким улы (25 яшь; атасы Габделхәким Җамалетдин улы) белән кавыша. Икенче кызы Бәдеркамал (17 яшь) 1899 елның 12 декабрендә шул ук авылның Шәрәфетдин Хөснетдин улы (25 яшь) белән гаилә кора.

Зиннуретдин Садретдин улы (20 яшь) 1906 елның 6 ноябрендә авылдашы Бәхетгәрәй Миңлегәрәй улының кызы Шәмсехәят (19 яшь) белән никахлаша. Зиннуретдин балалары (икенче мәхәллә): Гайникамал (04.08.1908), Әхияретдин (1909–1911), Мөхәммәтдин (16.07.1912), Фәхеркамал (03.07.1914; анасы Шәмсехәят Бәхетгәрәй кызы). Мөхәммәтдин Зиннуретдин улы Садретдинов – Ватан сугышы ветераны. Сугышка чаклы бригадир була, хатыны Мөсәвәрә (1913), анасы Шәмсехәят (1870), улы Фәнил (1940) белән яши, Хәмәй Зиннуров (1912) дип теркәгәннәр. Яңа Катайда Мөхәммәтдинне кайбер очракта Хәмәй дип әйтә торган булганнар, Иске Катайда да бер Хәмәй була.

Габделмәннан Кылчым улы Күчемовның өченче варисы Шәйхетдиннән нәселне Фәррахетдин (1841–10.05.1917), Сәлахетдин (1850–15.05.1917), Фәрхетдин (1852) һәм Мослахетдин (1867–1941) дәвам итә.

Фәррахетдин Шәйхетдин улы Күчемов балалары: Бибимәгъфүрә, Гыймадетдин (17.02.1874; анасы Фаизә), Шәрәфетдин (01.12.1880), Нурәхмәт, Кәраметдин (06.12.1883; анасы Миңлеҗамал), Зөләйха (Азамат нәселеннән Фазлытдин Хөснетдин улына кияүгә чыга), Хәтимә (1885), Бибимәрьям (1886), Гөлҗамал (1889), Бәдигылҗамал (1890), Фәрхиҗамал (19.07.1893–1897; анасы Миңлеҗамал Гыйбадулла кызы), Бибизәйнәп (13.08.1895–1895), Бибикамилә (10.04.1898). Фәррахетдин кызы Бибимәгъфүрә (икенче никах) 1877 елның августында Корычның Мөхәммәтзакир Фәризун улы (25 яшь; икенче никах) белән гаилә кора. Икенче кызы Хәтимә 1902 елның 7 декабрендә Туктаголның Мөхәммәтхарис Мөхәммәтзариф улы (22 яшь; атасы Мөхәммәтзариф Габделхәким улы) белән кавыша. Өченче кызы Бибимәрьям 1903 елда Корычның Нәбиулла Гайнулла улына (25 яшь) кияүгә чыга. Дүртенче кызы Гөлҗамал 1910 елның 10 февралендә Иске Балыклы ясаклы татары Сөләйман Мөхәммәтгәрәй улы (25 яшь; атасы Мөхәммәтгәрәй Хәсән улы) белән никахлаша. Бишенче кызы Бәдигылҗамал 1907 елның 17 ноябрендә Килкабызның Исмәгыйль Мөхәммәтлатыйф улы (22 яшь) белән кавыша. Фәррахетдин Шәйхетдиновның үзе белән бергә яшәгән төпчек улын (26 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына

алалар, 1917 елда хатыны (40) белән яши, 9,80 дисәтинә җире, җилгәргече, 4 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче яллый.

Гыймадетдин Фәррахетдин улы Күчемов балалары: Һидая (21.08.1900; анасы Факия Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтсафа улының кызы), Шәйхерам (23.09.1901), Җамалетдин (04.03.1905; анасы Фарихә Мөхәммәтсадыйк кызы), Гарифә (22.09.1909–1910; анасы Фарихә Габделхәбир кызы), Фәүзия (16.10.1912), Зыятдин (21.07.1915). Гыймадетдин Фәррахетдинов (44 яшь) 1917 елда хатыны (35 яшь), ике улы һәм кызы белән яши, 4,37 дисәтинә җире, аты, сыеры, 3 сарыгы була.

Шәрәфетдин Фәррахетдин улы Күчемов балалары: Бибихәлимә (04.08.1901; анасы Миңлеҗиһан Ногман кызы), Әхияретдин (23.05.1911–1911; анасы Миңлеҗиһан Мөхәммәди кызы), Әфудә (14.06.1912), Әслахетдин (05.10.1914–2004; анасы Ногман кызы). Шәрәфетдинне Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (33 яшь), ике улы һәм өч кызы кала, 1917 елда 0,75 дисәтинә җире, 2 аты һәм башка маллары була. Әслахетдин Шәрәфетдинов – Ватан сугышы ветераны, «Ленинград оборонасы өчен», «Сугышчан хезмәтләре өчен» (10.05.1944 һәм 28.03.1945) медальләре белән бүләкләнгән, почтальон булып эшләде (аңа чаклы Вазыйх Күчемов эшләгән).

Запастагы солдат Фәтхетдин Фәррахетдин улы гаиләсендә Мәгъсүмә (22.10.1907; анасы Мәрьям Әбүбәкер кызы) дөньяга килә.

Сәлахетдин Шәйхетдин улы Күчемов балалары: Кашшафетдин (1879), Хәйдәретдин (1882), Фәрхиҗамал (1883), Фәрхиҗиһан (1887), Афзалетдин (06.02.1893), Нурҗамал (10.04.1895), Шәмсеҗамал (22.04.1897–1902; анасы Шәрифҗамал Габдерәфикъ Сәетборһан улының кызы), Әкрәметдин (13.11.1899), Әхияретдин (09.11.1890–1894; анасы Шәрифҗамал Габдерәфикъ кызы), Әгъзаметдин (20.01.1903), Бәдретдин (17.10.1905). Сәлахетдиннең 1877 елның язында аерылган хатыныннан (Шәмсеҗиһан Нәдерша кызы) балалар булганмы, билгесез. Сәлахетдин кызы Фәрхиҗамал (18 яшь) 1901 елның 4 февралендә Иске Катайның Әлмөхәммәт Мөхәммәтша улы (25 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Фәрхиҗиһан (22 яшь; икенче никах) 1909 елның 16 февралендә Тыпыйның Тимергали Мөхәммәтвәли улына (45 яшь; бишенче никах) кияүгә бара. Кызның ризалык шаһитлары Мослахетдин Шәйхетдин улы белән Кашшафетдин Сәлахетдин улы була.

Кашшафетдин Сәлахетдин улы Күчемов балалары: Фәрхисорур (11.12.1905–1906; анасы Шәмсерур Миңлегали кызы), Зыятдин (1908–1909), Миңлехәят (29.08.1909; анасы Хөснелхәят), Афзалетдин (18.06.1911–1911; анасы Хөснелхәят), Имаметдин (25.06.1913–1914; анасы Хөсниҗамал), Миңлебания (28.01.1915; анасы Хөснелхәят). Кашшафетдин Сәлахетдиновны (38 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (25) һәм ике кызы кала, иманасы һәм мал-туары булмый.

Хәйдәретдин Сәлахетдин улы Күчемовның Мөшәррәфә Әхмәдулла кызы белән никахыннан Рәйсә (12.12.1925) туа. Хәйдәр Сәлахов Ватан сугышы ал-

ды елларында хатыны, балалары Мәрхәм (1924; икенче документта – 1920), Сәфирә (1927), Илһам (1931), Гыйльфанетдин (1936), Җәүһәретдин (1940), Зимфира (1943) белән яши. Мәрхәм Хәйдәр улы Сәлахов 1942 елның декабрендә сугышта хәбәрсез югала (Катайның мемориаль стеласына теркәлмәгән).

Мослахетдин Шәйхетдин улы Күчемов балалары: Шәрифә (1893–1913), Миңлешәмсетдин (07.05.1894; анасы Хәерниса Мөхәммәтсадыйк Габделшәфикъ улының кызы), Гайнетдин (16.11.1897), Заһретдин (05.09.1900; анасы Хәерниса Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтшәфикъ улының кызы), Гыйрфанетдин (28.10.1905–1905), Бибикәримә (09.12.1906), Тәгъзимә (09.07.1910; анасы Хәерниса). Мослахетдин Шәйхетдиновның ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (47 яшь), төпчек улы һәм өч кызы белән яши, 8,83 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры, 10 сарыгы һәм башка маллары була. Бибикәримә авылдашы Шәрифҗан Әхмәтхановка кияүгә чыга. Шәмсетдин Мослахетдин улы Күчемовның Фәрхепҗамал Госман кызы белән никахыннан Сәгадетдин (1924–1925) туа.

Габделмәннан Кылчым улы Күчемовның дүртенче варисы Бәдретдин иде. Бәдретдин Габделмәннан улы балалары: Фәрдетдин (1846–26.03.1905), Мәсрүрә (1851), Гыйльметдин (1854; анасы Газизсафа Тимергали кызы), Мәфтуха (1855), Кашшафетдин (1858), Хафизетдин (1871–25.12.1901), Мөхәммәтбәсим (1872), Мөхәммәтгалим (16.07.1876), Мөхәммәтфатих (01.02.1880; анасы Бәдриҗиһан), Мөхәммәтфазыйл (02.01.1883).

Фәрдетдин мулла Бәдретдин улы балалары: Бибилатыйфа (1879), Бибифакия (1892–1906; анасы Фәрхиҗамал), Солтанетдин (1893–1901). Фәрдетдин кызы Бибилатыйфа (19 яшь) 1898 елның 2 апрелендә Тыпыйның Хәбибулла Галиулла улы (25 яшь) белән никахлаша.

Гыйльметдин мулла Бәдретдин улы Күчемов балалары: Бибирәйфә (1883), Мәәлүфә (1887), Җәмгыйтдин (14.11.1893; анасы Камәр Йөзекәй кызы), Имаметдин (~1897), Маһирә (12.11.1899), Мөнирә (08.02.1902). Гыйльметдин кызы Бибирәйфә (18 яшь) 1901 елның 1 апрелендә нәселдәше Габделбаян Мәхиян улы (22 яшь) белән никахлаша. Бу иреннән аерылгач, Рәйфә 1903 елның 19 сентябрендә икенче нәселдәше Мөхәммәтшакир мөәзин Мөхәммәтлатыйф улы (37 яшь; икенче никах) белән кавыша. Гыйльметдиннең икенче кызы Мәәлүфә 1907 елның 3 гыйнварында Чуракайның Нургали Габдерәфикъ улы (25 яшь; атасы Габдерәфикъ Габделсалих улы) белән гаилә кора.



**Сугыш корбаны Имаметдин Күчемов**

Имаметдин Гыйльметдин улы Күчемов авылдашы Шәйхелмансур Миңлехан улының кызы Сәрвиҗиһан (25.12.1901 туган) белән никахлаша, балалары Мәрьям (1923), Рәхимә (1926), Зәкәрия (1927), Идая

(14.07.1930), Ниһая (1937) туа. Сәрвиҗиһан 1941 елның 22 апрелендә мәрхүм була. Имаметдин 1942 елның 19 гыйнварында сугышка китә һәм шул елның мартында хәбәрсез югала (исемен Катайның мемориаль стеласына өстәп язарга кирәк), аның кызы Идая 1951 елның 27 октябрендә нәселдәше Мәгъдәннур Әгъзаметдин улы Фәрвазов белән гаилә кора.

Кашшафетдин мулла Бәдретдин улы Күчемов балалары: Кәшфелголум (1891), Кәнзелголум (1892–1895), Шиһабетдин (25.01.1895; анасы Бибиҗамал Габделвәли Мөхәммәтша улының кызы). Кәшфелголум 1917 елның 8 февралендә авылдашы Габделбәшир Габделгаффар улының кызы Бибишәрифә (18 яшь) белән никахлаша.

Мөхәммәтгалим мулла Бәдретдин улы Күчемов балалары: Мөхәммәткәрим (27.12.1901–1902; анасы Шәмсебәдәр Хөснулла кызы), Мөхәммәтфазыйл (03.05.1905–1913; анасы Шәрифҗамал Миңлегәрәй кызы), Хәнәфия (18.11.1910–1916), Бибизәкия (26.04.1914–1914; анасы Фаизә Хәбибрахман кызы), Фәүзия (10.07.1915–1916, кызамыктан вафат). Мөхәммәтгалим 1910 елда Габделгалим дип тә язылган.

Мөхәммәтбәсим мулла Бәдретдин улы Күчемов балалары: Мөхәммәтнәгыйм (17.12.1914–1915; анасы Хасимбану Арслангали кызы), Могтәбәр (20.07.1925; анасы Гакифә Насретдин Күчемов кызы). Бәсим (Вәсим) Бәдретдинов сугыш алдыннан хатыны Гакифә, уллары Могтәбәр (1925), Могтәкип (1929, 1 группа инвалид) белән яши. Могтәбәр Бәдретдинов – Ватан сугышы ветераны, балалары: Фәнәдия (1949), Фәнәһия (1951), Равил (1956), Рафис (1958), Рузил (1961), Рәмзил (1963).

Кылчым картның дүртенче улы Габделнасыйр иде. Габделнасыйр озак еллар мөәзин вазифасын башкара, 1833 елда 51 яшьтә вафат була, алты улы кала: Әхмәт (1805–12.08.1878), Әхтәм (1807), Мөхәммәтша (1809–1829), Мөхәммәтшәфикъ (1811; 7 нче һәм 8 нче ревизияләрдә – Мөхәммәтшәриф), Сафуан (1815), Гарифулла (1830). Сафуан үзенең улы Әхмәтхарис белән 1858 елда Рәҗәп авылына мөәзин булып күчә, Гарифулла да шул елны Корычка барып төпләнә.

Әхмәт Габделнасыйр улы Кылчымов (Күчемов) балалары: Мөхәммәтшәриф (1827), Мөхәммәтлатыйф (1830 яшь; мөәзин), Мөхәммәтша (1837), Дәүләтша (1842), Гайса (1846).

Мөәзин Мөхәммәтлатыйф Әхмәт улы балалары: Бибикамилә (23.04.1880; анасы Рузәтелҗинан), Мөхәммәтвагыйз (25.05.1899; анасы Рузәтелҗинан Габделхаликъ кызы), Шәмсезыя (03.01.1901; анасы Мәликә Шәяхмәт кызы).

Дәүләтшадан Әхмәтхарис (05.09.1877; анасы Гайшә) туа. Әхмәтхарис (Мөхәммәтхарис) Дәүләтша улы (26 яшь) 1910 елның 16 октябрендә авылдашы Хәмидулла Габдулла улының кызы Фатыйма (27 яшь; өченче никах) белән никахлаша. Әлеге никах Иске Катайның икенче мәхәлләсендә теркәлгән. Мөхәммәтхарис Дәүләтша улы балалары: Дөһедия (02.08.1911–1913), Әхмәткәрам (12.05.1914–15.12.1916, чәчәктән вафат), Мөхәммәтфатих (08.02.1917). Мөхәммәтхарис 1917 елның 19 июнендә мәрхүм була.

Әхтәм Габделнасыйр Кылчымов улыннан Җамалетдин (1832) дөньяга килә. Җамалетдин Әхтәм улы балалары: Фәрваҗетдин (1869–15.03.1910, баш авыруыннан), Афзалетдин (01.10.1874; анасы Гыйльмисафа), Нуриәхмәт (15.07.1877).

Фәрваҗетдин Җамалетдин улы Күчемов балалары: Имаметдин (26.01.1890), Бибикамилә (1892–1894), Афзалетдин (1893), Әгъзаметдин (1895–1972), Гарәфетдин (05.10.1897; анасы Мәргубә Габделмән Габделлатыйф улының кызы), Хәкимә (03.01.1900), Хәтирә (15.12.1901–1902), Рәхимә (01.03.1904), Әхияретдин (26.05.1906–1906), Хәмдия (11.07.1907), Сабирҗан (07.12.1909–1909).

Имаметдин Фәрваҗетдин улы Күчемов балалары: Мәдинә (29.10.1914–1916; анасы Хәкимә Хөснулла кызы), Хәләфетдин (04.06.1917–1954), Әфлах (1922), Җәмилә (1926), Камилә (1929), Гарәфетдин (1933). Хәләфетдин белән Әфлах Фәрвазовлар – Ватан сугышы ветераннары. Хәләфетдин Имаметдин улы Фәрвазов (Имамов) сугышта старшина (разведчик) була, «Кызыл Йолдыз» (11.02.1943; ике тапкыр), «Кызыл байрак» (05.01.1945), «Ватан сугышы» (2 нче дәрәҗә) (20.08.1944) орденнары, «Батырлык өчен» медале (17.09.1943) белән бүләкләнә. Хәләфетдиннең сугыштагы батырлыклары «Үткәннәрен бел Катайның» китабында тулы тасвирланды.



**Сержант Гыйльфан Фәрвазов**

Афзалетдин Фәрваҗетдин улы Күчемов сугыш алды елларында хатыны Миңлеҗиһан (1893), уллары Мөдәррис (1922–1983), Гыйльфан (1925) белән яши. Гыйльфан Афзал улы Фәрвазов сержант, артиллерист була, «Сугышчан хезмәтләре өчен» (11.10.1946) медале белән бүләкләнә. Мөдәррис Афзал улы Фәрвазов Сталинград сугышында катнаша.

Мөдәррис Фәрвазов Яңа Катайның Мөхәммәтгали Нигъмәтуллин кызы Наҗия белән гаилә кора, балалары Рузидә (1942), Фәвәрис (1944–2004), Фәнис (1946), Фәйрүзә (1949–1996), Фәнәзия (1951–2010), Рафис (1954–2014), Фәридә (1957), Гүзәлия (1963) туа. Рузидә Катай урта мәктәбендә математика укыта, 1973–1976 елларда Бакалы партия райкомында инструктор булып эшли, 1976 елның августында тормыш иптәше белән Ташкентка китә, 1998 елда кайтып, хәзерге вакытта Уфада яши. Фәнис Кушнаренкода РОВД начальнигы булып эшләп пенсиягә чыга, хәзерге вакытта Ветераннар советына җитәкчелек итә. Фәридә Катай урта мәктәбендә математика укыта, оештыручы булып эшли, хәзерге вакытта Дүртөйледә яши. Мөдәррис абыйның башка балалары да укыйлар, тормышта үз урыннарын табалар, барысы да гаилә коралар, балалар үстерәләр.

Гыйльфан Фәрвазов Иске Катайның Сабирҗан Солтанов кызы Гашия (1929–04.03.2016; Юлдаш нәселеннән) белән никахлаша, балалары Халидә (1951), Камил (1952), Зәлифә (1954), Фәзинә (1957), Шамил (1959), Рузалин

(1963) дөньяга килә. Халидә белән Зәлифә – Себердә Урай шәһәрендә, калганнары Бакалыда яши.



Әгъзаметдин Фәрвазов

Әгъзаметдин Фәрваҗетдин улы Күчемов авылдашы Идая Ахунҗан кызы (1903) белән гаилә кора, Ватан сугышы алдыннан балалары Мәгъдәннур (12.07.1925–11.02.2008; метрикәдә анасы Кифая Ахунҗан Күчемов кызы дип язылган), Мирзанур (1929) була. Рәсми документта (паспорт) Мәгъдәннурның туган елы 1924 елның 13 марты, Катай авыл советы кенәгәсендә 1925 ел дип күрсәтелгән. «Бик оста тәгәрмәч сугучы иде», дип искә ала картәтисен Мөслимә Мәгъдәннур кызы.

Мәгъдәннур Әгъзаметдин улы Фәрвазов – сугыш ветераны һәм инвалиды (2 группа), 1951 елда нәселдәше Имаметдин Гыйльметдинов кызы Идая белән гаилә кора, балалары Мөслимә (29.07.1952), Гөлсимә (18.01.1955), Нәфис (08.03.1957–08.05.1978), Илдус (02.03.1959–11.09.2018) туа. Идая Имаметдин кызы (14.07.1930) – сугыш вакытында колхозда эшли, тыл хезмәткәре буларак, Җиңүнең 30, 40 һәм 50 еллыгы медальләре белән бүләкләнә.

Мәгъдәннур абый – сугыш чорында әсирлеккә төшеп, исән калган дистәгә якын авылдашларымның берсе. Бер бинада тоткынлыкта ятканда, кызыл каләм белән стенага түбәндәге сүзләрне язган: «Я, Фарвазов Магданур Агзамович, родился в 1925 году, 28 февраля, город Уфа, район Вукалы, деревня Ново-Китай. В 43 году попал в плен в Германию. Мучают, обливают холодной водой на морозе. Лучше умереть в бою, чем попадать в плен». Бу язу авыррак укылган, күрәсең, әнә шулай хаталы килеш Сергей Борзенконың «Жизнь на войне» китабына кергән. Украинаның Летичев поселкы



**Мәгъдәннур һәм Идая Фәрвазовлар Украина пионерлары белән очрашу вакытында**



ІДУТЬ ЛИСТИ З БАШКИРІЇ

**Мәгъдәннурны зурлап язган Украина гәзите язмасы**

пионерлары сугыш каһарманының язмышы белән кызыксынып, Катайга хат язалар, исән-сау икәнлеген белгәч, очрашуга чакыралар. Тарихи очрашу 1983 елда була, бу хакта зурлап Украина гәзитләре язып чыга.

Мирзанур Әгъзаметдин улы Фәрвазов авылдашы Солтангали Вәлиев кызы Рәгъфәния белән никахлаша, балалары Равил (1954), Рим (1957), Урал (1960), Әнисә (1963; Урсайда яши) туа (бүгенге көндә боларның икесе генә исән (Рим белән Әнисә)).

Габделнасыйр Кылчымовның дүртенче улы Мөхәммәтшәфикътан да нәсел шактый тармакланып китә. Мөхәммәтшәфикъ Габделнасыйр улы балалары: Мөхәммәтсадыйк (1838–30.06.1903), Мөхәммәтхафиз (1840), Мөхәммәтвәли (1842), Мөхәммәдьяр (1844), Мөхәммәтталип (1873). Мөхәммәтшәфикъ 1894 елның 1 апрелендә мәрхүм була, мулла исемен – Габделшәфикъ, атасын Габделнасыйр Кылчым улы Күчемов дип язган.

Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтшәфикъ улыннан Гыйззениса (07.09.1877) билгеле, башка балалары күрсәтелми. Гыйззениса (17 яшь) 1894 елның 30 ноябрендә Иске Катайның Мөхәммәтдин Камалетдин улы Сайранов (25 яшь) белән кавыша, чыганакта исеме, ни сәбәпледер, Фәхерниса дип язылган.

Мөхәммәтвәли Мөхәммәтшәфикъ улы балалары: Җиһангир, Мөхәммәтгариф, Мөхәммәтшәриф, Миңлебану (03.09.1883), Мөхәммәтнәби (27.03.1889), Шәмсебану (1893). Мөхәммәтвәли кызы Шәмсебануны (17 яшь) 1909 елның 1 ноябрендә Корычның Гыйльман Сөләйман улына (23 яшь; атасы Сөләйман Кәлимулла улы) кияүгә бирә. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтгариф Мөхәммәтвәли улы белән Мөхәммәтталип Мөхәммәтшәфикъ улы була. Шул ук Шәмсебану 1912 елда Баекның Хәлилулла Хәмидулла улы (49 яшь; өченче никах) белән никахлаша. Икенче тапкыр ирдән аерылып, Шәмсебану 1913 елның 24 октябрендә Баекның Шәйхерам Хәсән улы (23 яшь) белән кавыша. Мөхәммәтвәли күкрәге авыртып, 1915 елның 23 мартында мәрхүм була.

Җиһангир Мөхәммәтвәли улы Күчемов балалары: Шәмсевафа (1886–1916), Гыйззелвафа (1888–1895), Әгъләм (19.12.1894; анасы Хәмдевафа типтәр Нәбиулла Хәбибулла улының кызы). Җиһангир кызы Шәмсевафа (17 яшь) 1901 елның 27 ноябрендә авылдашы Мөхәммәтгали Мөхәммәтгәрәй улы (23 яшь; икенче никах) белән никахлаша.

Мөхәммәтшәриф Мөхәммәтвәли улы Күчемов балалары (икенче мәхәллә): Миңлебану (20.07.1898; анасы Фәхерҗиһан Шәймөхәммәт Сәйфетдин улының кызы), Миңлемөхәммәт (05.02.1901–1904), Мөхәммәтнәби (18.03.1904; анасы Фәхерҗиһан Шәймөхәммәт кызы), Фәрхебану (23.04.1906–1907), Мөхәммәтнәгыйм (07.10.1909–1909), Фәрхебану (15.09.1911).

Мөхәммәтгариф Мөхәммәтвәли улы Күчемов балалары: Мөхәммәтгабит (18.11.1909), Рәкыя (05.08.1912–1913; анасы Шәмсекамал Зиннәтулла кызы), Миңленәкыя (26.01.1915), Сания (20.02.1925). Габит Вәлиев 1944 елда сугышта хәбәрсез югала, хатыны Мәгъдәния (1916), балалары Вәсилә (1937), Рабит (1940) кала.

Мөхәммәтталип Мөхәммәтшәфикъ улы Күчемов (22 яшь) 1895 елның 16 ноябрендә авылдашы Шәйхетдин Шиһабетдин улы Үмербаев кызы Нурикамал (18 яшь) белән никахлаша, балалары Нурҗиһан (1896), Мөхәммәтназиф (03.01.1900), Мөхәммәтлатыйф (21.01.1903), Мөхәммәтнәгыйм (04.10.1905–1906), Гыйльмениса (19.10.1907), Әхмәтнәгыйм (29.01.1911), Мөхәммәтхәтим (31.03.1914) дөньяга килә. Мөхәммәтталип кызы Нурҗиһан 1916 елның 20 ноябрендә Иске Катайның Шәкүрҗан мөәзин Шәймөхәммәт Кәримов улы (26 яшь) белән никахлаша. Талип Шәфиков 1917 елда хатыны (37 яшь), дүрт улы һәм ике кызы белән яши, 11,85 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була. Латыйп Шәфиков 1942 елда сугышта хәбәрсез югала, хатыны Нәгыймә, балалары Мөҗәһидә (1937) һәм Хәтиф (27.11.1939) кала. Сугыш корбаны Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән, сайтларда исеме Латыйп урынына ялгыш «Лабиб» дип язылган, документтагы туган урынына (Яңа Катай), елына (1903) һәм анасы исеменә (Нәгыймә) карап, Латыйп икәнен беләсең.

Хәтиф Латыйп улы Шәфиков әйтүенчә, анасы Нәгыймә 1901 елда туган, атасы Камалетдин була. Камалетдинның башка балалары турында мәгълүмат китапның бу бүлегендә бирелә. Хәтиф абый Иске Катайның Ватан сугышы ветераны Заһит Нәбиев кызы Әнүзә белән гаилә кора, балалары Фәйрүзә (1964), Фәзир (1967), Фәнзил (1973) дөньяга килә. 1966 елда Авыргазы районы профтехучилищесында бакчачылар курсын тәмамлап, озак еллар совхозның бакчачылык тармагын уңышлы җитәкләде.



**Китап авторы Хәтиф абый Шәфиков белән. 2018 ел**

Кылчым картның бишенче улы Мөхәммәткәримнән дә нәсел шактый тармакланып китә. Мөхәммәткәрим Кылчым улы Күчемов балалары: Хөснетдин (1831–18.02.1909; 1909 елгы метрикәдә атасы Мөхәммәткәрим Кылчым улы Күчемов дип күрсәтелгән) һәм Гыйлаҗетдин (1834).

Хөснетдиннән нәселне Газетдин (1859) һәм Кәраметдин (1876) дәвам итә. Хөснетдин кызы Фәрхебану (18 яшь) 1893 елның 10 маенда Сеңрәннең Габделмәннан Габдрахман улы (21 яшь) белән никахлаша.

Газетдин Хөснетдин улы Күчемов 1883 елның 1 июнендә авылдашы Шәймәрван Шәймәрдан улының кызы Фәрхиҗиһанга (17 яшь) өйләнә, балалары Зәйнелгабидин (12.11.1889), Минһаҗетдин (1892–21.11.1917), Гыйрфанетдин (20.06.1894–1902; анасы Фәрхиҗиһан Шәймәрван Шәймәрдан улының кызы), Хәлфиҗиһан (21.05.1899), Насретдин (14.03.1902; Ватан сугышы ветераны), Шәмсеҗиһан (29.07.1904–1905) туа. Газетдин Хөснетдиновның

ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда өч улы белән яши, 3,43 дисәтинә җире, аты була.

Монда бер искәрмә ясап үтик. Яңа Катай мулласы 1883 елгы никах язуында Хөснетдиннең улын Газетдин дип, башка очракларда Гыйздетдин дип яза. Дөресе – Газетдин, 1859 елгы ревизия документында да шулай язылган.

Насретдин Газетдиновның дүрт улы була: Хәмзә (1928 елгы, Саран (Караганда) шәһәрендә яши), Фәнүз (1932–29.12.2013), Хәләфетдин (12.1934–31.12.1979), Әхияретдин (1939–1971). Хәләфетдин Газетдинов уллары: Әлфис (27.10.1967) һәм Фәнәвис (03.06.1970). Әлфис Газетдинов – хәрби хезмәтен Әфганстанда үткән катайлыларның берсе, «Сугышчан хезмәтләре өчен», «СССР дәүләт чикләрен саклауда батырлык күрсәткәне өчен» медальләре, «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләнгән. Бу хакта укытучы Р. Г. Хәсәнованың «Авыл синең белән горурлана» исемле район гәзитендә басылган язмасында әйтелә. Хәрби хезмәттә тагын берничә авылдашыбыз дәүләт бүләкләре алган дип әйттеләр, димәк, алар да безнең горурлык, шул язмада аларның да исемнәрен атап үтәргә кирәк булган.

Кәраметдин Хөснетдин улы Күчемов балалары: Фәрхебану (23.08.1906; анасы Шәмсебану Габделгани кызы), Өммеханә (1909–1913), Өммегөлсем (04.01.1913–1913), Мәрхәметдин (22.06.1914–1916). Кәраметдин Хөснетдиновны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда йортында хатыны һәм кызы кала, 1,52 дисәтинә җире була.

Мөхәммәткәрим Кылчым улы Күчемовның нәселен икенче улы Гыйлаҗетдин дә дәвам итә. Гыйлаҗетдин Мөхәммәткәрим улы балалары: Низаметдин (1859), Борһанетдин (1861), Камалетдин, Мифтахетдин, Шәрәфетдин (1870), Гыймадетдин (22.05.1876; анасы Бибигазизә), Бибизәйнәп. Бибизәйнәп авылдашы Шәйхелмансур Миңлехан улы белән кавыша.

Низаметдин Гыйлаҗетдин улы Күчемов балалары (икенче мәхәллә): Фәрхисорур (1891), Шәмсенур (19.05.1894; анасы Фәрхенур Мөхәммәтназиф кызы), Бәдринур (1896–1901), Бибисорур (31.03.1899; анасы Фәрхенур Мөхәммәтназиф Габделгаффар улының кызы), Акмалетдин (20.04.1900–1914), Әнвәретдин (22.07.1904; анасы Фәрхиҗиһан Мөхәммәтназиф кызы), Фәүзия (30.03.1909). Низаметдин кызы Фәрхисорурны (17 яшь) 1908 елның 15 декабрендә Туктаголның Нуриәхмәт Әхмәди улына (25 яшь) кияүгә бирә. Низаметдиннең икенче кызы Шәмсенур 1916 елның 3 июнендә Корычның Сәфәргали Нуриәхмәт улы (36 яшь; икенче никах) белән никахлаша.

Әнвәретдиннең анасы авыл советы кенәгәсендә Фәрхинур (1851) дип күрсәтелә, туганнары Зәкия (1870), Майсорур (1895) хакында әйтелә. Әнвәр Низаев (1904) – Ватан сугышы ветераны, фронтка киткәндә авыл советы кенәгәсендә хатыны Идая (1905), балалары Тәлгать (1927), Әлхат (1937), Илһария (1940) теркәлә.

Борһанетдин Гыйлаҗетдин улы Күчемов балалары: Миңлеҗиһан (1887), Латыйфа (1889), Кәшифә (1892–1905), Афзалетдин (17.05.1893–1895), Бибикә-

шифә (09.06.1895), Кашшафетдин (27.05.1897; анасы Мәдхиҗиһан Галиулла кызы), Фәттахетдин (02.12.1899–1902), Хәтимә (27.02.1902–1905), Гыйрфанетдин (28.06.1904–1905; анасы Мәхупҗиһан Галиулла кызы). Борһанетдин кызы Миңлеҗиһан 1905 елда нәселдәше Әхмәтвәли Мөхәммәтвәли улы (25 яшь) белән кавыша. Икенче кызы Латыйфа (28 яшь) 1917 елның сентябрендә Иске Балыклының Әхмәдулла Һибәтулла улы (30 яшь) белән гаилә кора (икенче никахлары). Аңа чаклы хатын аның туганы Хәмидулла Һибәтулла улында кияүдә була, әлеге никах икенче мәхәлләдә 1910 елның 24 декабрендә теркәлә. 1917 елгы никахта кызның ризалык шаһитлары Камалетдин белән Низаметдин Гыйлаҗетдин уллары була. Борһанетдин Гыйлаҗетдинов 1917 елда хатыны (45 яшь) белән генә яши, 4,31 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була.

Камалетдин Гыйлаҗетдин улы Күчемов 1889 елның 14 ноябрендә авылдашы Кашшафетдин Мөхәммәткәрим улының кызы Бибикафия (17 яшь) белән никахлаша, балалары Бибинәгыймә (1891–1895), Мәэлүфә (07.07.1894–1912), Бибифакия (1898), Бибикамилә (04.12.1899), Бибинәгыймә (04.12.1901), Җәмгыйтдин (15.11.1904), Таибә (26.05.1908–1909) туа. Камалетдин кызы Бибифакия 1916 елның 25 ноябрендә Корычның Хафиз Сәфәргали улы (26 яшь) белән кавыша. Катай авыл советы кенәгәсендә Камалетдин 1940 елда мәрхүм булды дип әйтелә, аның соңгы хатыны Фатиха (1880) монда калмый, шул ук 1940 елда каядыр китә. Камалетдин улы Җәмгыйтдин (1904; фамилиясе Гыйләҗов) 1941 елның 12 сентябрендә сугышка китә һәм шул ук елны хәбәрсез югала (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән), хатыны Саҗидә (1910), кызлары Камилә (1930), Мөфәвазә (1934), Вәзига (1936), Тәрҗимә (1939), Тәкмилә (1941) кала.

Мифтахетдин Гыйлаҗетдин улы Күчемов балалары (икенче мәхәллә): Җәмгыйтдин (22.05.1894–1895; анасы Хәмдениса Шәмсемөхәммәт Мөхәммәтсәлим улының кызы), Бибибәһия (1898), Хәйдәретдин (17.05.1899), Әһлия (22.03.1902–1904), Фәттахетдин (20.10.1905–1905), Хаялетдин (халык телендә Хаях; 22.01.1907), Әмирҗан (12.04.1910; анасы Хәмдениса Шәмсемөхәммәт кызы), Шәрифҗан (08.04.1911–03.11.1916, чәчәктән вафат), Миңлерәкыя (19.05.1914–1914), Миңлеәминә (18.04.1916–03.10.1916, чәчәктән), Шәйхетдин (Шәех; сугыштан кайтмаган), Насиха һәм башкалар. Мифтахетдин кызы Бибибәһия 1916 елның гыйнварында Иске Катайның Мөхәммәтгалим Габделзаһир улы (25 яшь) белән никахлаша.

Хәйдәретдин Корычның Мөкәррәмә Әхмәтзәки кызы белән гаилә кора, балалары Мөдәррис (24.03.1925), Мөҗәһит (1926; Үзбәкстанда гомер иткән), Вәзимә (19.02.1931–18.02.2001), Суфия (1934; Чүмәлә Катайда яшәгән), Ягъдә (1938; Атамановка леспромхозында һәлак була) туа. Хәйдәретдин сугышта каты яралана, шул яралардан 1944 елның 19 июлендә Калинин өлкәсендә мәрхүм була. Аның уллары Мөдәррис Мифтахов белән Мөҗәһит Хәйдәровлар сугыштан исән-имин кайта. Хәйдәр кызы Вәзимә авылдашы Мөхәммәтнәгыйм Госмановка кияүгә чыга. Мөдәррис Мифтахов авылдашы Саимә Гый-

лаҗетдин улының кызы (1918) белән гаилә кора, балалары Мөнәвир (1950), Фәнәдия (1952; Корычта яши), Зөбәер (1954), Фәнәвия (1956) туа. Мөнәвир абый һөнәре буенча агроном, бүгенге көндә авылдашы-тормыш иптәше Фәнә Хәтим кызы белән Иглин районы Охлебенино авылында гомер итә, өстәмә мәгълүматны ул әйтте.

Хаях (1907; бер рәсми документта туган елы 1913 дип ялгыш күрсәтелә), Фаяз (1913), Мәрхәметдин (1926–1980; «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән) Гыйләҗевлар – Ватан сугышы ветераннары (берсе Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Мифтахов-Гыйлаҗевләр турында күп язарга булыр иде, андый максат куймадым. «Классташлар» аша Җәмигънур Гыйлаҗев белән аралашканнан, ул җибәргән мәгълүматны бирмичә булдыра алмыйм. Аның әтисе Мәрхәметдин Мифтахетдин улы Гыйлаҗев авылдашы Сания Шәрхемулла кызы (1927–1987) белән никахлаша, балалары Җәмигънур (1948), Әбүзәр (1950; Катайда яши), Гөлсинә (1958) туа. Җәмигънур Ташкентта яши, атасының сугыштан соң совхозга чаклы 17 ел колхоз рәисе урынбасары булып эшләвен, аталарыбызның дуслар булуын искә алды.

Шәрәфетдин Гыйлаҗетдин улы Күчемов (24 яшь) 1894 елның 29 ноябрендә авылдашы Шәрифулла Хәбибулла улы Мортазин кызы Бибифатиха (17 яшь) белән кавыша, балалары Рабига (16.08.1901), Вәдига (19.12.1908), Мөкәррәмә (16.02.1912), Әкълимә (26.01.1915; анасы Бибифатиха Шәрифулла Хәбибулла улының кызы) туа. Шәрәфетдин хатынын һәм дүрт кызын калдырып, Беренче бөтендөнья сугышына китә, алга таба язмышы билгесез.

Гыймадетдин Гыйлаҗетдин улы Күчемовның ике хатыннан балалары: Җамалетдин (02.02.1903–1905; анасы Бания Гыйззәтулла кызы), Әхкәметдин (05.07.1905), Әһлия (1909–07.11.1916, чәчәктән вафат), Мөсәвәрия (10.01.1908), Нуретдин (14.07.1912; анасы Миңлезадә Габделбәшир кызы), Зыятдин (19.12.1912; анасы Бания), Мөнәвәрә (15.08.1914; анасы Сәхипҗамал Бәдретдин кызы), Зәкәрия (17.12.1915–06.11.1916, чәчәктән; анасы Бания Гыйззәтулла кызы), Нажия (16.12.1917; анасы Бания).

Кылчым Күчемовның алтынчы улы Мөхәммәтәмин 1813 елда 23 яшьтә армиядә вафат була, улы Мөхәммәтша (1812) кала. Мөхәммәтша уллары: Фәрукша (1833), Җиһанша (1842–12.03.1917) һәм Мәрданша (1844).

Фәрукша Мөхәммәтша улы балалары: Мөхәммәдиша (1866), Нургали (1880), Бибимәгърифәт, Гарифә (1887), Муллагали. Фәрукша кызы Бибимәгърифәт 1905 елның гыйнварында Иске Катайның Хәйретдин Әдһәм улы белән никахлаша. Икенче кызы Гарифә 1905 елның декабрендә Корычның Фәттахетдин Кашшафетдин улы (25 яшь) белән кавыша.

Мөхәммәдиша Фәрукша улы (22 яшь) 1888 елның 31 октябрендә Иске Катайның Шәрәфетдин Сайран улының кызы Шәмсенур (18 яшь) белән гаилә кора, балалары Галимә (1891), Әхмәдиша (07.06.1894; анасы Шәмсенур), Миңлехәкимә (1899–1905), Хәтирә (29.04.1902), Хәсәнша (01.05.1905) туа.

Мөхәммәдиша кызы Галимә (18 яшь) 1909 елның гыйнварында Иске Катайның Исламгали Гатиятулла улы (22 яшь) белән никахлаша.

Нургали Фәрукша улы (25 яшь) 1905 елның 16 ноябрендә авылдашы Габделгазим Габделихсан улының кызы Маһисафа (Майсафа; 17 яшь) белән гаилә кора, балалары Нурисафа (12.10.1906), Нурикамал (19.02.1910–1916), Майкамал (20.07.1911), Нурмөхәммәт (03.08.1913–1914), Мирһади (01.11.1915) туа. Нургали Фәрукшинны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (30 яшь), улы һәм 2 кызы кала, җире һәм мал-туары булмый. Аның энесе Муллагали Фәрукша улы Күчемовтан Сабирҗан (22.11.1915; анасы Мәүлиха Сәригаскәр кызы) билгеле.

Җиһанша Мөхәммәтша улы Күчемов балалары: Гәрәйша (1879), Сәрвиҗиһан (10.08.1880; анасы Шәмсеҗиһан), Сәрвиҗиһан (1884–1898), Бәдерҗиһан (12.06.1893), Мәсрүрә (26.03.1897; анасы Фәхриҗиһан Мөхәммәтша кызы). Җиһанша Мөхәммәтша улы 1910 елның 24 гыйнварында кызы Бәдерҗиһанны (17 яшь) Килкабызның Нурлыгаян Миңлеяр улына (25 яшь; атасы Миңлеяр Сәетборһан улы) кияүгә бирә. Икенче кызы Мәсрүрә дә 1917 елның 16 декабрендә Килкабызның Асылгәрәй Мөхәммәтгәрәй улы (25 яшь) белән никахлаша.

Гәрәйша Җиһанша улы Күчемов 1905 елда авылдашы Асылгәрәй Әделгәрәй улының кызы Бибигайшә (17 яшь) белән никахлаша, балалары Хәсәнша (24.12.1906), Хәсәнша (19.02.1910), Бибизәкия (29.01.1912), Факия (12.02.1915), Зәйтүнә (20.04.1917) туа.

Мөхәммәтшаның төпчек улы Мәрданшадан Дәүләтша (08.01.1909; анасы Фәхрикамал Габделәхсан улы) билгеле.

Күчемнең өлкән улы Кылчымнан киткән тармак мөмкин кадәр тулы тасвирланды кебек. Күчемнең икенче улы Алишка (Әлмөхәммәт; 1752–1812) күчәбез, ул да шактый нәсел калдыра. Алиш уллары: Мөхәммәтрәхим (1792–1852), Мөхәммәтвәли (1797–1853) һәм Мөхәммәтгалим (1800–16.05.1875, атасы Әлмөхәммәт дип язылган). Болар, ни сәбәпледер, 1834 елгы ревизия документында Әминев фамилиясендә теркәлгәннәр.

Мөхәммәтвәли Алишев (Әлмөхәммәтов) уллары: Мөхәммәтгәрәй (1831), Шәйхелислам (1824), Мөхәммәтлатыйф (1842–15.08.1878).

Мөхәммәтгәрәй Мөхәммәтвәли улы балалары: Бәхетгәрәй (1844), Әхмәтгәрәй (1857), Бибишәмсия (1863). Мөхәммәтгәрәй кызы Бибишәмсия (27 яшь; дүртенче никах) 1890 елның 6 ноябрендә Иске Катайның Миңлегаффар Сәеткол улы (икенче никах) белән никахлаша.

Бәхетгәрәй Мөхәммәтгәрәй улы Мөхәммәтвәлиев (Күчемов) 1878 елның 19 гыйнварында авылдашы Җамалетдин Габделҗәлил улының кызы Шәмсекамал (17 яшь) белән кавыша. Бәхетгәрәй балалары: Мортаза (25.07.1894; анасы Гыйльмебану типтәр Габдрахман Габделхаликъ улының кызы), Мәүсуфә (03.06.1898), Сабирҗан (30.05.1901). Бәхетгәрәй Мөхәммәтгәрәевнең олы улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (55 яшь),

төпчек улы Сабирҗан һәм кызы белән яши, 5,32 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сарыгы, 3 кәҗәсе була.

Әхмәтгәрәй Мөхәммәтгәрәй улы Мөхәммәтвәлиев (Күчемов) балалары: Әхмәткәрам (28.10.1893), Шәмсеҗиһан (19.10.1895–1895), Әхмәтшәех (03.09.1899; анасы Миңлеҗиһан Яхъя Шәяхмәт улының кызы), Габдулла (01.01.1902), Әхмәтнәгыйм (07.01.1904), Әбүталип (02.04.1906), Гөлҗиһан (12.12.1908), Мансурҗан (12.02.1911–1911), Фәрхиҗиһан (15.06.1912), Гыйльмиҗиһан (11.12.1917), Әхмәтшәех (1924–1995; анасы Гыйльмебану Хәйрулла кызы).

1921 елгы ачлыкта бөтен гаиләсен югалткач, Әхмәтгәрәй Күчемов мәрхүм авылдашы Шәйсолтан Ильясовның хатыны Гыйльмебану Хәйрулла кызы белән никахлаша, уллары Әхмәтшәех дөньяга килә. Әхмәтшәех Волхов фронтында сугышларда катнаша, яралана, госпитальдә ятып чыккач, 1944 елда хәрби хезмәттән азат ителә. Катайга кайткач Әхмәтшәех Корычның Сәвия Нуретдин кызы (1918–1991) белән гаилә кора, балалары Габделхәмит (1952), Фәндимә (1953), Флүрә (1956) туа. Әхмәтшәехнең сугыштан соңгы гомере Чиләбе өлкәсенең Еманжелинск шәһәрендә уза, бирегә 1947 елда эшкә яллanып («вербовка» белән) килгән була. Бу мәгълүматны аның кызы Фәндимә хәбәр итте.

Югарыда сүз барган Мөхәммәтвәли Алишевның туганы Мөхәммәтгалим Алишев (Әлмөхәммәтов) була. Мөхәммәтгалим Әлмөхәммәт улы варислары: Габделбасыйр (1834), Габделкаһир (1835–12.12.1895; ни сәбәпледер, 10 ревизия исемлегендә Габделкадыйр дип теркәлгән), Габделнасыйр (1842–16.03.1910), Габделгани (1844–11.08.1917), Габделханнан (1849–1857).

Габделбасыйр Мөхәммәтгалим улы Күчемов балалары: Габделханнан (1859), Габделдаян, Габделбаян (1867), Габдрахман (23.03.1883). Габделбасыйр кызы Саимә (18 яшь) 1895 елның 29 ноябрендә авылдашы Мөхәммәтшакир Мөхәммәтзариф улы Галикәев (25 яшь) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле – агасы Габделдаян Габделбасыйр улы, ризалык шаһитлары Габделбаян Габделбасыйр улы белән Ситдыйкъ Габделнасыйр улы була.

Габделдаян Габделбасыйр улы Күчемов балалары: Габделханнан (17.05.1893; анасы Бибисафа), Габделҗәмил (28.03.1901–1905), Габделфәез (09.02.1906–1910; анасы Фәрхиҗамал Мифтахетдин кызы), Бибисара (16.11.1909), Фәтхелбәян (22.04.1911; анасы Фәрхиҗамал Мифтахетдин кызы), Бибисара (19.03.1914), Сәфирә (02.03.1917).

Габделбаян Габделбасыйр улы Күчемов балалары: Габдрахман (04.04.1895; анасы Хәмдениса Шәйхетдин Фәтхулла улының кызы), Габдерәхим (12.01.1897), Әһлия (18.03.1900), Габделгалим (04.01.1903), Бәһия (03.12.1906), Кәримә (18.07.1910), Нәгыймә (11.08.1915–1916). Габделбаян Басыйровның олы улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (40 яшь), улы һәм ике кызы белән яши, 3,66 дисәтинә җире, аты була.

Мөхәммәтгалим Алишевның икенче улы Габделкаһир иде. Габделкаһир Мөхәммәтгалим (Габделгалим дип тә язылa) улы балалары: Габделмәннан

(1860–05.10.1906), Габделфәттах (Фәттахетдин дип тә языла; 1865), Мөхәммәтгариф (16.07.1877; анасы Гайшә), Габдерәхим.

Габделмәннан Габделкаһир улы Күчемов (23 яшь) 1883 елның 13 декабрендә Иске Катайның Җамалетдин Габделнасыйр улының кызы Фәрхиҗиһан белән никахлаша, балалары Шәмсеҗиһан (1885–1895), Габдерәкыйп (10.04.1889), Габдерәкыйп (25.05.1894–1895), Миңлеҗиһан (1898), Мөхәммәтрәхим (27.01.1901), Шәмсеҗиһан (25.02.1903), Габдерәфикъ (20.06.1905–1906; эч рәнҗүеннән вафат) туа. Габделмәннан кызы Миңлеҗиһан 1917 елның 21 гыйнварында Килкабызның Нургали Гарифулла улы (42 яшь) белән никахлаша.

Габделфәттах Габделкаһир улы Күчемов балалары (беренче мәхәллә): Нурлыгаян (17.06.1899; анасы Бибизөһрә Габделбаян Сәлим улының кызы), Әхмәтзакир (22.07.1902), Кифая (08.11.1905–1913), Хәсән (27.07.1913; анасы Фәрхениса Гафиятулла кызы), Арслангали (22.08.1915–1916), Габделфаяз (12.03.1917). Габделфәттах Каһиров (52 яшь) 1917 елда хатыны (40) һәм улы белән яши, 1,56 дисәтинә җире була.

Мөхәммәтгалим Алишевның өченче улыннан да нәсел дәвам итә. Габделнасыйр Мөхәммәтгалим улы балалары: Габделханнан (1864), Әхмәтлатыйф (1865), Мөхәммәтситдыйкъ (1867), Габделкаюм (1872), Исламгали (11.06.1874–1915), игезәкләр Хәсән белән Хөсәен (01.01.1880; анасы Шәмсеруй), Фәрхисорур (1884), Фәрхинур (1886). Габделнасыйр кызы Фәрхисорур (17 яшь) 1901 елның 3 мартында авылдашы Госман Шәяхмәт улы Азаматов (23 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Фәрхинур 1903 елның 10 декабрендә Иске Катайның Габделхәбир Йосыф улы (23 яшь) белән кавыша.

Габделханнан Габделнасыйр улы Күчемов (Галимов) балалары: Миңлесалих (11.01.1894), Галислам (02.06.1897; анасы Бибиҗиһан Габдерәфикъ Габделхаликъ улының кызы), Әминә (23.01.1900), Миңленәфисә (25.09.1902), Галимәрдан (26.09.1906; Ватан сугышы ветераны), Кәнзелголум (23.09.1909), Кәнзелмәгариф (10.10.1914). Габделханнан Габденнасыйровның олы улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (45 яшь), дүрт улы һәм ике кызы белән яши, 5,25 дисәтинә җире, 3 аты, сыеры, 3 сарыгы була. Галислам Ханнановның хатыны Фәрхенур Сәрвәретдин кызы (1903) була, сугышка чаклы балалары Мөстәфидә (1923), Сөгъдә (25.11.1925), Вәсимә (1933), Флүрә (1939) туа. Галимәрдан Ханнанов авылдашы Гайнелхәят Сәетгәрәй кызы белән гаилә кора, балалары Дәнә (1930), Әфудә (1933; авылдашы Хаҗиәкрәм Госмановка кияүгә чыга), Ягъдә (Җәгъдә; 1938–2019; авылдашы Рәис Гайсин белән гаилә кора), Рухылбаян (1941). Галимәрданның икенче хатыны Хәлимә (Әфтах инәсе), балалары Венер, Фән була.

Габделлатыйф Габделнасыйр улы Күчемов (24 яшь) 1889 елның 19 февралендә авылдашы Баһманша Шәйхетдин улының кызы Бибимәрхәбә (17 яшь) белән никахлаша, кызлары Бибинур (01.12.1890) туа. Габделлатыйф (фамилиясе Галимов, 27 яшь; өченче никах) 1897 елның 5 ноябрендә авылдашы Садретдин Нөрмәтов кызы Шәмсеҗиһан (20 яшь; икенче никах) белән гаилә ко-

ра. Габделлатыйф балалары: Зиннәтулла (12.07.1894; анасы Мәрзия типтәр Габдерәшит Габделгалләм улының кызы), Мәдхиҗиһан (11.05.1898–1898), Гыйниятулла (02.11.1898; анасы Шәмсеҗиһан Садретдин кызы), Мөхәммәтназиф (15.10.1902; 1935 елда загстан туу турында белешмә ала), Сәрвиҗиһан (05.11.1904; анасы Шәмсеҗиһан Садретдин кызы), Нурҗиһан (1907–1910), Гөлҗиһан (26.05.1909–1910), Хөрмәтулла (25.07.1911–1913), Нигъмәтулла (29.03.1914), Сөнәгатулла (22.12.1915). Латыйф Насыйровның олы улын (22 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (30 яшь), дүрт улы һәм кызы белән яши, 11,17 дисәтинә җире, 5 аты, сыеры һәм башка маллары була. Габделлатыйф Күчемов Чүмәлә Катайга күчеп утыра, монда аның улы Мөхәммәтназиф 1925 елда Чүмәлә Катайның Гатиятулла Шәрифулла улының (ул үзе Иске Катайда туып-үскән) кызы Нурзидә (18 яшь) белән никахлаша. Шунысы кызык, метрикә язуында Габделнасыйр Арсланбәк нәселе тамгасын куйган. Сөнәгатулла Латыйпов (1915) сугышка Чүмәлә Катайдан китә, кече лейтенант, 1943 елда һәлак була.

Сүз уңаеннан әйтик, Чүмәлә Катайда Күчемовлардан тагын берәү (Кәрим) була, аның улы отделение командиры Әнвәр Күчемов (1924) 1944 елның 14 гыйнварында һәлак була.

Мөхәммәтситдыйкъ Габделнасыйр улы Күчемов балалары: Әхмәтгали (10.02.1889), Миңлекамал (10.01.1894; анасы Шәмсеҗамал типтәр Гыйззәтулла кызы), Шәйхелгали (27.04.1900), Хаҗгали (04.07.1903), Солтангали (15.02.1906), Шәмсекамал (01.08.1910), Галимә (29.07.1913). Миңлекамал 1912 елның 5 декабрендә Сеңрәннең Шәйхулла Бикмөхәммәт улы (25 яшь; атасы Бикмөхәммәт Биктаһир улы) белән никахлаша. Мөхәммәтситдыйкъ Насыйровның ике олы улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (30 яшь), дүрт улы һәм ике кызы белән яши, 4,05 дисәтинә җире, 2 аты һәм 2 сыеры була, хезмәтче яллый.

Әхмәтгали һәм Мәрьям Ситдыйковлар балалары: Корбангали (1922), Муллагали (1927), Мирзагали (1932–1941), Саҗидә (1938). Корбангали Ситдыйков Ватан сугышында каты яралана, 1942 елда госпитальдә мәрхүм була. Әлеге мәгълүматны оныгы Ләлә Сәлманова хәрби комиссариатка мөрәҗәгать итеп алган, бу хакта документны безгә җибәрде. Бик күпләрнеке кебек, Корбангалинең дә исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән. Саҗидә Сәлманова алдынгы сыер савучыларның берсе була, балалары: Халисә (1960), Ләлә (1962), Вәсил (1970–1995). Корбангалинең энесе Муллагали Ситдыйков 1944 елның 15 ноябрендә хәрби хезмәткә чакырыла, японнарга каршы сугышта катнашып, «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале белән бүләкләнә (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән). Әхмәтгалинең энесе Солтангали Ситдыйков балалары: Мәгъдәннур, Әгъләһәм башкалар.

Габделкаюм Габделнасыйр улы Күчемов (Галимов) 1893 елның 14 гыйнварында авылдашы Вәсфикамал Габделлатыйф Габделвафи улының кы-



**Габделкаюмның никах язуында нәсел тамгалары. 1893 ел**

зы (17 яшь) белән никахлаша. Габделкаюм балалары: Хәсәнкамал (23.11.1893; анасы Вәсфикамал), Габделназиф (20.12.1894–1895; анасы Зөһрә Мөсәллим Мөхәммәди улының кызы), игезәкләр Фатыйма (08.10.1897) белән Зәйнәп (08.10.1897–1898), Габделнәфикъ (19.06.1900–1905), Габдерәфикъ (07.09.1903–1905), Рамазан (26.03.1906), Камилә (04.11.1909), Тәгъзимә (05.07.1913–1914; анасы Зөһрә), Тәгъзимә (1914–1916, кызамыктан вафат). Габделкаюм кызы Хәсәнкамал 1911 елда Корычның Нурислам Габделихсан улы (22 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Фатыйма 1915 елда Балыклының Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтшәриф улы (25 яшь; атасы Мөхәммәтшәриф Мөхәммәдьяр улы) белән кавыша.

Исламгали Габделнасыйр улы Галимов балалары: Галимә (09.10.1900; анасы Мәдинә Мөхәммәтшәриф кызы), Галихәйдәр (24.06.1903–1905), Хуҗагали (13.08.1905), Хәйдәретдин (12.09.1909), Исламетдин (02.10.1911), Зыятдин (06.12.1914).

Мөхәммәтгалим Алишевның дүртенче улы Габделганигә күчәбез. Габделгани Мөхәммәтгалим улы Күчемов балалары: Бибикафия (1872–1917), Бибимәстүрә (1875), Мөхәммәтгали (1876), Бибимөнирә (02.12.1880), Шагали (15.10.1883). Габделгани кызы Бибикафия (17 яшь) 1889 елның 31 ноябрендә Кенәз авылының Җәләлетдин Гыймадетдин улы (икенче никах) белән никахлаша. Икенче кызы Бибимәстүрә (20 яшь) 1895 елның 15 декабрендә шул ук Бәләбәй өязе Балыклы авылы «ясаклы башкорт»ы Миңлехәким Арслангәрәй улы Тәмимдаров (21 яшь) белән гаилә кора. Кызның ризалык шаһитлары Мөхәммәтгали Габделгани улы белән Ситдыйкъ Габделнасыйр улы, кияүнеке Дәүләтгәрәй белән Әхмәтгали Арслангәрәй уллары була.

Мөхәммәтгали Габделгани улы балалары: Шәмсеҗиһан (07.11.1901; анасы Хөснижиһан Мөхәммәтзариф кызы), Хөснеҗинан (22.04.1904), Маһибану (23.02.1906), Маһикамал (02.07.1911; анасы Миңлесафа Мөхәммәткәрим кызы), Шәрифгали (20.10.1913; анасы Хөсниҗиһан), Әгъзамгали (26.12.1914–1917). Мөхәммәтгали Габделганиевне (41 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (35), улы һәм дүрт кызы кала, 2,37 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була.



**Катайдагы балалар йорты (детдом) хезмәткәрләре. 1950 еллар**

Шагали Габделгани улы балалары (беренче мәхәллә): Кашшафгали (10.02.1911; анасы Шәмсеҗиһан Корбангали кызы), Шәйәгъзам (10.07.1917). Шагали Чүмәлә Катайда яши, бер никахта ризалык шаһиты буларак теркәлә.

Күчем нәселе турында сүземне бер теләк белән тәмамлыйсым килә. «Без татарлар», дип горур әйтсеннәр, тел-милләт өчен көрәшнең алгы сафында булсыннар иде. Һәр нәсел эчендә ана теленнән ваз кичеп, милләтем башка дип, ят тел-милләтне үз итүче имансыз бәндәләр булырга мөмкин. Мондыйлар Күчем нәселендә дә юк түгел, китабымның бу бүлегендә аларның исемнәрен атап, нәсел тарихын таплыйсым килмәде.

# XII бүлек.
# Күчемнең ерак нәселдәше – Нөрмәт

Туксанынчы елларда Нөрмәтне аерым нәсел итеп карыйлар иде. Моның сәбәбе – бик борынгы чорлардан кулланылып килгән, рухи мираска әйләнгән үзенчәлекле нәсел тамгалары онытылган, бу хакта сөйләүче дә юк, кемнең кайсы нәселгә караганын тамга буенча түгел, кемнәндер ишетеп яисә тоемлап кына беләләр иде.

Нөрмәтне аерым нәсел санап, бер аксакалыбыз болай сөйләде: «Авылда Нөрмәтләрдән беркем дә калмады. Кайчандыр, Дәүләтгәрәй, Сәетгәрәй, Асылгәрәй, Батыргәрәйләр бу нәсел кешеләре булган, Дәүләтгәрәйнең Дәүләтбай исемле улы бай саналган. Дәүләтбайның улы – Хаҗи, Хаҗиныкы – Миркасыйм». Тагын да сораштыра һәм документларга таянып ачыклый торгач, Нөрмәттән киткән буыннар катайлылар арасында бүген дә бар һәм шактый булып чыкты.

Архив документларын анализлап, Нөрмәт картның биш улын ачыкладык. Болар: Ягъфәр, Җомагол, Гарәптан, Габдулла (1748–1811), Габделкәрим (1751–1826). 1816 елгы ревизия документында 12–16 саннар астында теркәлгәннәр, һәрберсенә аерым тукталып үтәбез.

Ягъфәрдән нәселне Әсфәндияр (1776–1831) дәвам итә. Әсфәндияр уллары: Мөхәммәдьяр (1814), Мөхәммәтҗан (1821), Әхмәтҗан (1821), Мөхәммәди (1829), Мөхәммәтша (1832). Мөхәммәдьяр Әсфәндияровның беренче хатыныннан улы Мөхәммәтәмин (1836) туа. Мөхәммәтша Әсфәндияр улыннан Мөхәммәдиша (28.03.1877; анасы Салиха) билгеле.

Мөхәммәтәмин Мөхәммәдьяр улы Гайнелхәят Гайнулла кызы белән никахлаша, балалары Мөхәммәтхафиз (1870), Гайнелҗинан (1878), Әхмәтлатыйф (07.02.1880) туа. Мөхәммәтәмин кызы Гайнелҗинан (18 яшь) 1897 елның 3 гыйнварында Рәҗәпнең Нургали Корбангали улы (20 яшь) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле – бертуган агасы Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтәмин улы, ике як ризалык шаһитлары Муллаян Үмербай улы белән Мөхәммәтнәби Мөхәммәтәмин улы була. Әлеге никах Яңа Катайның беренче мәхәллә метрикәсендә теркәлә.

Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтәмин улы Әсфәндияровның хатыны Тыпыйның Фәрхетдин Таҗетдин улының кызы Фәрхиҗамал була, 1895 елның 3 октябрендә алар аерылышалар («араларында мәхәббәт вә өлфәт булмаган сәбәпле»). Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтәмин улы Мөхәммәдьяровның беренче мәхәллә метрикәсендә кызы Миңлебәдәр (01.01.1898; анасы Майкамәр

Бәдретдин Мөхәммәтлатыйф улының кызы) теркәлгән. Мөхәммәтхафиз кызы Миңлебәдәр 1916 елның 24 гыйнварында Балыклының Кадермөхәммәт Хәсән улы (33 яшь) белән никахлаша. Кыз тарафыннан вәкил – Әхмәтлатыйф Мөхәммәтәмин улы, ризалык шаһитлары Мөхәммәтнәби Мөхәммәтәмин улы белән Ахунҗан Мөхәммәтҗан улы була. Хафиз Әминев (47 яшь) 1917 елда хатыны (22 яшь) һәм улы белән яши, 3,92 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче яллый.

Монда бер искәрмә ясап үтик. Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтәмин улы Яңа Катайда тагын бер нәселдә күзәтелә, ул берничә яшькә генә зуррак. Бер үк чорда һәм бер үк мәхәлләдә яшәгән бу кешеләр бабаларының исемнәре белән генә аерылалар. Әмма бабаларының исемнәре күрсәтелмәгән очракта, болар кайсы нәселгә карый дип тукталып каласың, бары тик хатыннары буенча кайсы нәселгә караганын китереп чыгарасың. Авыл зур булганлыктан, исемнәр шулай кабатлану ара-тирә очраштыргалый. Бу китапта никахларга тукталып үтү һәм яңа туган балаларның аналарын күрсәтү, нәселне ачыклауда буталчыклык булмаска да ярдәм итте.

Әхмәтлатыйф Мөхәммәтәмин улы балалары (беренче мәхәллә): игезәкләр Шакирҗан (03.11.1904) белән Әхмәтнәби (03.11.1904–1905); анасы Фатыйма Гаязетдин кызы), Кифая (27.11.1906), Әхмәтнәгыйм (25.07.1909), Һидая (28.09.1911), Ниһая (22.03.1915). Әхмәтлатыйфны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (35 яшь), улы, өч кызы һәм эшчесе (19 яшь) кала, хуҗалыгында 17,58 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче яллаган. Әхмәтлатыйфның улы Нәгыйм Әхмәтов (1909) Ватан сугышы алды елларында хатыны Гыйльмиҗамал (1917), кызы Мәсхүдә (1939), анасы Фатыйма (1889) белән яши, сугыштан «Батырлык өчен» медале (30.05.1945) белән кайта.

Нөрмәтнең икенче улы Җомагол (Җомай) балалары: Корбангали (1786–1856), Миңлегол (1794–1856), Зәйнетдин (1800–1831). Миңлегол хатыннары Сәхипҗамал (1791) белән Шәмсиҗамал (1812) була. Беренче хатыныннан – улы Габделсалих (1829–1856), икенче хатыныннан уллары Габделгалим (1838–28.09.1898) белән Габделихсан (1851) дөньяга килә.

Габделгалим Миңлегол улы Нөрмәтов балалары: Шәйхеразый (1865–1905), Әхмәтгали, Һидая (1871), Муллагали (1872–04.10.1907), Рабига (20.12.1877–1909; анасы Гайникамал), Мирзагали (10.08.1880), Рәхимә (15.10.1889–1904; анасы Гайникамал Габделмоталлап кызы). Габделгалим кызы Һидая (17 яшь) 1889 елның 2 гыйнварында Туктаголның Мөхәммәтәмин Габделхәким улы (35 яшь; икенче никах) белән кавыша. Кызның ризалык шаһитлары Шәйхеразый белән Әхмәтгали Габделгалим уллары була. Икенче кызы Рабига (17 яшь) 1894 елның 3 гыйнварында авылдашы Әхтәмҗан Мөхәммәтҗан улы (19 яшь) белән кавыша.

Шәйхеразый Габделгалим улы Нөрмәтов (24 яшь) 1889 елның 20 февралендә Мамадыш өязе Сатыш авылының Бибимаһирә Мөхәммәтгази кызы (20 яшь)

белән никахлаша. Шәйхеразыйның икенче никахтан кызы Рәйфә (20.10.1893; анасы Хәерниса Мөхәммәтҗан Үмербай улы Әхмәтов кызы) билгеле. 1893 елның 16 февралендә Шәйхеразыйның өченче никахы теркәлә, хатын итеп нәселдәше Шәйхелислам Габделбәшир улы Нөрмәтов кызы Зөләйханы (24 яшь; өченче никах) ала.

Муллагали Габделгалим улы Нөрмәтов балалары: Рәхимә (28.05.1904; анасы Хупҗамал Габделгазиз кызы), Миңлегали (14.07.1906–1906).

Мирзагали Габделгалим улы (22 яшь) 1907 елның 30 ноябрендә авылдашы Төхфәтулла Габидулла улының кызы Хәлфиҗиһан (18 яшь) белән никахлаша, балалары Саҗидә (19.08.1910–1910), Шәрифҗан (18.04.1912), Мәүгыйзә (03.03.1914–1914), Шәехгали (02.07.1915), Шәйхенур (05.02.1916–1917) дөньяга килә.

Габделихсан Миңлегол улы балалары Хөҗҗәтелислам (16.06.1878) белән Мәрьямбану (20.11.1883; анасы Гайшә) була.

Җомаголның төпчек улы Зәйнетдин иде. Зәйнетдин уллары: Гайнетдин (1822), Насретдин (1832–10.02.1903). Гайнетдин Зәйнетдин улы ир балалары: Садретдин (1852), Фәррахетдин (1858).

Садретдин Гайнетдин улы Нөрмәтов 1877 елның 1 декабрендә нәселдәше Нурмөхәммәт Шәяхмәт улының кызы Миңлеҗиһан (25 яшь; икесенең дә икенче никахлары) белән никахлаша, балалары Шәмсеҗиһан (01.12.1878), Гыйльмиҗиһан (1885), Бәдретдин (1886), Хәйдәргали (11.05.1889–1895), Солтангали (24.09.1893–1894), Миргали (1896–1905), Фәрхиҗиһан (1899–1905) туа. Садретдин кызы Шәмсеҗиһан 1897 елның 11 апрелендә Камышлытамакның Батыргәрәй Шәрәфетдин улы (35 яшь; икенче никах) белән никахлаша, әмма шул елны ук кияүдән кайтып, 5 ноябрьдә авылдашы Габделлатыйф Габделнасыйр улы Кучемов (27 яшь; өченче никах) белән кавыша. Икенче кызы Гыйльмиҗиһан (17 яшь) 1902 елның 7 ноябрендә авылдашы Бәдретдин Фәрхетдин улы (22 яшь; атасы Фәрхетдин Камалетдин улы) белән гаилә кора.

Бәдретдин Садретдин улы 1905 елның 7 декабрендә авылдашы Хөснетдин Хисаметдин улының кызы Гыйззелхәят (17 яшь) белән никахлаша. Кияүнең ризалык шаһитлары Гыйлаҗетдин Насретдин улы белән Галләметдин Гыймадетдин улы була. Бәдретдин балалары: Хөҗҗәтелислам (13.08.1907), Хәйретдин (15.10.1909–1914), Гыйздетдин (31.07.1912–1913), Газинур (20.11.1914).

Зәйнетдин Җомагол улының икенче варисы Насретдин дә нәсел калдыра. Насретдин Зәйнетдин улы балалары: Минһаҗетдин (1859), Гыйлаҗетдин (1867), Гыймадетдин (1872).

Гыйлаҗетдин Насретдин улы Нөрмәтов балалары (икенче мәхәллә): Фәрхизиядә (05.10.1894; анасы Фәрхеруй Габделнасыйр Мөхәммәтгалим улының кызы), Бибинур (30.08.1897), Шәмсенур (22.05.1900), Маһинур (19.02.1902–1905), Фәрхениса (23.08.1904), Сәрвиҗиһан (21.09.1906), Сәрвәретдин (03.11.1908; анасы Фәрхисорур Габделнасыйр кызы), Гыйлемҗан (02.03.1911–1911). Сәрвиҗиһан авылдашы Камил Нәбиев белән никахлаша, кызы Фәүханә туа.



**Сәрвиҗиһан (уңда) оныклары**

Сәрвәретдин Ватан сугышы алды еллары кенәгәсендә «Гилаев Сарбай» (1908) дип теркәлгән, фронтка киткәндә өендә хатыны Саҗидә (1911), уллары Зәкәрия (1933), Мөтәвәсим (1936), Мәгъсүм (1938) кала.

Гыймадетдин Насретдин улы 1899 елның 4 ноябрендә авылдашы Габделбәшир Габделгаффар улының кызы Миңлезадә белән никахлаша, балалары Шәһәрзадә (18.06.1901), Шәмсезиядә (20.06.1904–1905), Рәкыя (18.10.1906–1910) туа.

Нөрмәтнең өченче улы Гарәптан иде. Гарәптан улы Гыйсмәтулла 1781–1852 елларда яшәгән, 1816–1859 елгы документларда Гарәптанов фамилиясе белән бирелә. Гыйсмәтулла 1876 елгы метрикәдә мулла дип язылган, димәк, мәдрәсә тәмамлаган, аның нәселен Шәйхетдин (1813–02.01.1878) дәвам итә.

Шәйхетдин мулла Гыйсмәтулла улы балалары: Баһманша (метрикәләрдә Баһман; 1834), Заһретдин (1839), Гаязетдин (Гаязетдин, 1841; метрикә буенча 1852–1899 елларда яшәгән).



**Баекның Мөхәммәтша Мөхәммәтрәхим улы тамгасы («Н» хәрефе формасында) һәм Яңа Катайның Сәүбән Баһман улы тамгасы («+» (плюс) формасында)**

Баһманша Шәйхетдин улы балалары: Локманхәким (1858), Фәрданә (1863), Бибимәрхәбә (1872), Сәүбән (1874), Фәсихелихсан (01.12.1877), Миңлемөшәррәфә (икенче чыганакта Бибимөшәррәфә; 25.07.1880; анасы Бибисәгыйдә). Баһманша кызы Фәрданә (20 яшь) 1883 елның 21 гыйнварында Баекның Әхмәтгәрәй Мөхәммәтша улы (35 яшь; икенче никах) белән кавыша. Ирнең атасы Мөхәммәтша Мөхәммәтрәхим улы нәсел тамгасын сала, тамга нәкъ Арсланбәк нәселенеке, ягъни «Н» хәрефен хәтерләтә. Әлеге документка Сәүбән Баһман улы да нәсел тамгасын сала. Баһманшаның икенче кызы Бибимәрхәбә 1889 елның 19 февралендә авылдашы Әхмәтлатыйф Габделнасыйр улы (чыганакта исеме Габделлатыйф; 24 яшь) белән никахлаша. Өченче кызы Бибимөшәррәфә ирдән аерылгач, 1907 елның гыйнварында Корычның

Сәетгәрәй Сәлимгәрәй улы (икенче никах) белән гаилә кора. Кызның ризалык шаһитлары – Саяфетдин Җамалетдин улы белән Гыймаделислам Гаязетдин улы, кияүнеке Әгъләм белән Әнгам мулла Әхмәтситдыйкъ уллары була, никах беренче мәхәллә метрикәсендә теркәлгән.

Сәүбән Баһман улы Шәйхетдинов 1894 елның 24 гыйнварында Кадернең Мөхәммәтгариф Габдерәфикъ улының кызы Гыйззениса (17 яшь) белән кавыша, «араларында мәхәббәт вә өлфәт» булмаганлыктан, 1895 елның 10 февралендә аерылышалар. Шул ук Сәүбән (25 яшь; дүртенче никах) 1899 елның 17 гыйнварында авылдашы Гарифулла Фәйзулла улы Корбангалиевнең өченче кызы Мәмдуха (17 яшь) белән никахлаша, башкаларыннан кебек, монысыннан да балалары булмый.

Фәсихелихсан Баһманша улы балалары: Миңлерабига (24.07.1909), Әминә (1911–1914), Зөбәйдә (09.03.1914–1914), Мөхәммәтшамил (12.08.1915; анасы Зәбига Миңлеяр кызы). Фәсхелислам (чыганакта шулай язылган) Баһманов 1917 елда хатыны (30 яшь), улы һәм анасы (78) белән яши, 9,37 дисәтинә җире, аты һәм башка маллары була. Фәсихелихсан Чүмәлә Катайга күчә, монда Бүләктән алып кайткан хатынын аерып, 21 яшьлек Балыклы хатыны белән 1925 елның 15 августында бишенче никахын теркәтә.

Гаязетдин Шәйхетдин улы Нөрмәтов 1876 елның 25 ноябрендә авылдашы Маһиҗиһан (Майҗиһан) Баһаутдин Үмербаев кызы белән никахлаша, балалары Кашшафетдин (25.07.1878), Гыймадетдин (1879), Заһретдин (28.09.1880), Сәрвиҗиһан, Гыйльмиҗиһан (1883–1895), Бәдерталига (13.06.1893), Фәтхелислам (1895–1898), Мәдхиҗиһан (08.11.1898–1903) дөньяга килә. Гаязетдин улы Гыймадетдин (28 яшь; өченче никах) 1907 елның 20 ноябрендә Иске Катайның Хәтимә Әхтәмҗан кызы (22 яшь, атасы Әхтәмҗан Мөхәммәтҗан улы; икенче никах) белән гаилә кора. Ир тарафыннан вәкил Сәригаскәр Миңлехан улы була.

Гыйсмәтулланың олы улы Габделгалләм (1809) – указлы мулла, гаиләсе белән Куян авылына күчә, аның бу вакытта улы Габделхәлим (1837) була.

Нөрмәтнең икенче улы Габдулланың (1748–1811 елларда яшәгән) ир балалары булмый, шуңа бу яклап нәселне дәвам итүче юк.

Нөрмәтнең өченче улы Габделкәрим (1751–1826) иде. Габделкәримнең беренче хатыныннан ир балалары – Тимергали (1785), Мөхәммәтгали (1789), Мөхәммәдьяр (1790–1830), икенче хатыныннан Габделбәшәр (1798), Шаһиәхмәт (1800–1829) һәм Шаһимәрдан (Шәймәрдан; 1805) була.

Габделкәрим Нөрмәтовның икенче улы Мөхәммәтгалинең ир балалары: Гыймадетдин (1818), Җәләлетдин (1824). Болардан нәселне дәвам итүче юк кебек, чөнки 1834 елдан соң күрсәтелмиләр.

Габделкәрим Нөрмәтовның өченче улы Мөхәммәдьярдан нәселне Мөхәммәтгәрәй (1816), Миңлегәрәй (1834 елгы документта Шәнгәрәй; 1819), Әделгәрәй (1822), Арслангәрәй (1824) һәм Мөхәммәтвәли (1827–18.10.1904) дәвам итә.

Мөхәммәдьярның өч улыннан (Миңлегәрәй, Әделгәрәй, Асылгәрәй) нәсел шактый тармаклана. Миңлегәрәй Мөхәммәдьяр улы балалары: Хәсбиҗамал (1843), Дәүләтгәрәй (1844), Бәхетгәрәй (1847), Батыргәрәй (яшьли вафат), Солтангәрәй (1853). Миңлегәрәй кызы Хәсбиҗамал (35 яшь; икенче никах) 1878 елның 22 февралендә Кадернең Төхфәтулла Гыйсмәтулла улы (39 яшь; икенче никах) белән кавыша.

Миңлегәрәйнең беренче улы Дәүләтгәрәй (1844) иде. Дәүләтгәрәй Миңлегәрәй улының беренче хатыны Бибикамал Фәйзулла кызы була, 1876 елның гыйнварында аерылышалар. Дәүләтгәрәй балалары: Әхмәтгәрәй (1872), Бибиҗәмилә (1876), Сәлимгәрәй (1877), Шәмсекамал (02.12.1880), Миңлекамал (1881), Дәүләтбай (1883), Гайникамал (1891), Хаҗиәхмәт (19.04.1894; анасы Мәргыя типтәр Әһлиулла кызы), Муллаәхмәт (15.01.1897), Миңлекамал (27.04.1901–1901). Дәүләтгәрәй кызы Бибиҗәмилә (19 яшь) 1895 елның 23 ноябрендә Афзалетдин Гыймадетдин улы Сайранов (22 яшь) белән никахлаша. Икенче кызы Шәмсекамал 1897 елның 21 ноябрендә Кадернең Мөхәммәтсалих Миңлешакир улы (20 яшь) белән кавыша. Өченче кызы Бибикамилә (17 яшь) 1902 елның 10 ноябрендә Ырсайның Сәлахетдин Шәйхелислам улы (19 яшь) белән никахлаша. Дүртенче кызы Гайникамал (18 яшь) 1909 елның 23 гыйнварында Чуракайның Акмалетдин Гаязетдин улы (25 яшь; атасы Гаязетдин Фәхретдин улы) белән гаилә кора. Шул ук Гайникамал (20 яшь; икенче никах) иреннән аерылып, 1911 елның 11 февралендә Ырсайның Шәмсемөхәммәт Кәшфетдин улы (20 яшь) белән кавыша.



**Уң якта аста Сәлимгәрәй Дәүләтгәрәй нәсел тамгасын салган. 1895 ел**

Әхмәтгәрәй Дәүләтгәрәй улы Нөрмәтов балалары: Миңлекамал (25.06.1899; анасы Фәрхинур Габдулла Төхфәтулла улының кызы), Фәхерҗиһан (15.08.1900), Мөхәммәтгәрәй (22.09.1903–1903), Габдулла (01.01.1905–1925), Нуркамал (01.07.1907), Майкамал (10.03.1910; анасы Фәрхинур Шәйхелислам кызы). Әхмәтгәрәй Дәүләтгәрәев (45 яшь) 1917 елда хатыны (49), улы һәм өч

кызы белән яши, 3,87 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм башка маллары була. Әхмәтгәрәй Дәүләтов Ватан сугышы алды елларында хатыны Фәрхинур (1879) һәм кызы Дөһәдия (1921) белән яши.

Дәүләтбай Дәүләтгәрәй улы (26 яшь) 1908 елның 21 ноябрендә Иске Катайның Минһаҗетдин Таҗетдин улының кызы Латыйфа (18 яшь) белән никахлаша. Егетнең ризалык шаһитлары Бәхетгәрәй Миңлегәрәй улы белән Сәлимгәрәй Шаһингәрәй улы була. Дәүләтбай балалары: Миргалим (17.11.1909–1909; анасы Миңлелатыйфа Минһаҗетдин кызы), Наҗия (23.04.1912–1913), Миркасыйм (02.11.1913; анасы Хөсниҗамал Муллаян кызы). Миркасыйм (Миркай) Дәүләтов Ватан сугышына чаклы тракторда эшли, хатыны Рәкига (1916) һәм улы Мирсәгыйть (08.03.1942) белән яши, 1941 елда сугышта хәбәрсез югала.

Сәлимгәрәй Дәүләтгәрәй улы Нөрмәтов балалары: Бибимөнәвәрә (29.09.1900; анасы Бибимөсәвәрә Муллагали Галиулла улының кызы), Галиәхмәт (21.04.1903–1903), Мәсрүрә (30.03.1904), Мәгъсүмә (1905–1912), Мәүсумә (21.05.1907), Исламгәрәй (06.03.1910), Галимҗан (08.05.1913), Миңлефәүзия (16.04.1916; анасы Бания Мөхәммәтҗан Гыйсмәтулла улының кызы), Нәҗибә (17.12.1925), Гавис (1929), Гания (1933). Сәлимгәрәй кызы Бибимөнәвәрә 1917 елда авылдашы Габидулла Гарифулла улы (25 яшь) белән никахлаша. Сәлимгәрәй Дәүләтгәрәев (40 яшь) 1917 елда хатыны (25 яшь), ике улы һәм ике кызы белән яши, 8,59 дисәтинә җире, аты, сыеры, 3 сарыгы була. Ватан сугышы чорына караган авыл исемлегендә ул Сәлим Дәүләтов дип теркәлгән.

Миңлегәрәй Мөхәммәдьяр улының икенче варисы Бәхетгәрәйдән дә нәсел дәвам итә. Бәхетгәрәй Миңлегәрәй улы балалары: Миңлеәхмәт, Фазлыәхмәт (24.03.1877; анасы Фәрухҗамал), Нуриәхмәт (10.08.1880), Шәмсехәят (1887). Бәхетгәрәй кызы Шәмсехәят (19 яшь) 1906 елның 6 ноябрендә авылдашы Зиннуретдин Садретдин улы (20 яшь; Күчем нәселеннән) белән никахлаша. Кызның вәли вәкиле – бертуган агасы Миңлеәхмәт Бәхетгәрәй, ризалык шаһитлары абыйлары Фазлыәхмәт белән Нуриәхмәт Бәхетгәрәй уллары була.

Миңлеәхмәт Бәхетгәрәй улы Нөрмәтов балалары: Шәмсеталига (13.04.1897; анасы Сәрвиҗиһан Фәттахетдин Җамалетдин улының кызы), Мирзаәхмәт (06.10.1903–1905; анасы Миңлевафа Фәррахетдин кызы), Миңлесафа (10.04.1906), Шәһәрвафа (21.02.1909), Шәмсеталига (24.01.1912–1914), Бәдерталига (16.08.1914), Таибә (15.10.1917).

Фазлыәхмәт Бәхетгәрәй улы балалары: Хуҗаәхмәт (14.01.1904–1904; анасы Фатыйма Шәрифулла кызы), Хәтирә (16.03.1905), Мирзаәхмәт (12.02.1913–1913), Миңлесылу (23.06.1914–1914), Дөһәдия (16.11.1915).

Нуриәхмәт Бәхетгәрәй улы (25 яшь) 1907 елның февралендә Иске Катайның Исмәгыйль Миңлегали улының кызы Маһинур (18 яшь) белән никахлаша. Шул елның көзендә алар аерылышалар, 1911 елның 20 мартында Нуриәхмәт авылдашы Хөснулла Гыйсмәтулла улының кызы Шәмсекамәр (18 яшь) белән

гаилә кора, балалары Суфиәхмәт (13.09.1912–1916), Шәмсебанат (1916–1916, кызамыктан вафат) туа. Шул ук Нуриәхмәт 1915 елның 15 гыйнварында авылдашы Хөснулла Гыйсмәтулла улының кызы Шәмсекамәр (21 яшь; икенче никах) белән никахлаша, балалары Шәмсебанат (15.03.1916), Сәҗидә (10.10.1917) дөньяга килә.

Сүз уңаеннан әйтик, Бәхетгәрәй белән Батыргәрәй исемнәре Катайда тагын бер-ике нәселдә күзәтелә. Бәхетле һәм батыр булсын дигән теләктән чыгып, борынгы төрки-татар традицияләрне яд кылып кушылган бу исемнәр!

Габделкәрим Нөрмәтовның өченче улы Мөхәммәдьярдан нәсел дәвамчысы Әделгәрәй (1822) иде. Әделгәрәй Мөхәммәдьяр улы балалары: Әхмәтгәрәй (яшьли вафат), Асылгәрәй (1855), Җиһангир (1860), Гарифә (1875–1890).

Асылгәрәй Әделгәрәй улы Нөрмәтов балалары: Бибимәрзия (20.06.1883; анасы Миңлесафия), Бибигайшә (1888), Гыйниятулла (08.11.1894–1895; анасы Бания типтәр Шәмсулла Кәлимулла улының кызы), Бибивәдига (11.03.1895; анасы Сафия Миңлегали кызы), Зиннәтулла (18.05.1897), Хөрмәтулла (25.11.1899), Бибибәһия (25.02.1901; анасы Бибибания Кәлимулла кызы), Бибигалия (06.05.1904–1904; анасы Бибисафия Миңлегали кызы), Хәйдәргали (1905–1909), Нәгыймә (03.02.1909–1914), Гыйбадулла (02.01.1912; анасы Бания), Әхмәдулла (27.04.1915; анасы Нигъмәтулла кызы). Асылгәрәй кызы Бибигайшә 1905 елда авылдашы Гәрәйша Җиһанша улы (25 яшь) белән никахлаша. Асылгәрәйнең тагын Гыйндулла исемле улы булып, аның Мәүлидә Шәрәфетдин кызы белән никахыннан Вәзимә (01.04.1925) дөньяга килә.

Әделгәрәйнең төпчек улы Җиһангирдан (халык телендә Янгир) да варислар кала. Җиһангир Әделгәрәй улы балалары: Бибигарифә (30.11.1893; анасы Мәргубә типтәр Мөхәммәди кызы), Мөнирә (04.12.1902), Шәрхемулла (14.05.1905), игезәкләр Насыйбулла белән Мәһирә (15.02.1909; анасы Мәргубә Мөхәммәди кызы). Җиһангир Әделгәрәевнең (57 яшь) олы улын (20) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (50 яшь), ике улы һәм ике кызы белән яши, 4,56 дисәтинә җире, аты, сыеры, 5 сарыгы була. Җиһангир кызы Гарифә 1909 елның 5 декабрендә Ырсайның Шәйсолтан Мөхәммәтсолтан улы (24 яшь; атасы Мөхәммәтсолтан Габделгалләм улы вәкил була) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһитлары нәселдәшләре Асылгәрәй Әделгәрәй улы белән Фәхразый Ислам улы була. Насыйбулла Әделгәрәев – 1942 елның декабрендә хәбәрсез югалган Ватан сугышы корбаны (исеме Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Насыйбулла Янгиров 1941 елның 13 июлендә Ватан сугышына китә, язмышы билгесез (Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән), өендә хатыны Әсма (1912), кызы Асия (1932), улы Тимерхан (1939) кала. Тимерхан Янгиров туган авылында гаилә корып гомер итә.

Габделкәрим Нөрмәтовның өченче улы Мөхәммәдьярдан нәселне тагын Арслангәрәй (1824) дәвам итә. Арслангәрәйнең ир балалары: Батыргәрәй

(1855), Әхмәтгәрәй (1856), Сәетгәрәй (1862). Алар ерак бабалары исеменнән метрикәләрдә Нөрмәтов фамилиясендә теркәлгәннәр.

Батыргәрәй Арслангәрәй улы балалары: Мөхәмммәтгәрәй (06.02.1880; анасы Шәмсехәят), Солтангәрәй (1886), Габдрахман (1889–1889), Маһибану (1897–1905; анасы Гаделбану Шаһидулла кызы), Сәфирә (06.05.1912–1913; анасы Шәмсеҗиһан Якуп кызы). Батыргәрәй хатынсыз калгач, 1902 елның 10 гыйнварында Килкабызның Гаделбану Шаһидулла кызы (30 яшь) белән кавыша, икесенең дә өченче никахлары була.

Солтангәрәй Батыргәрәй улы (23 яшь) 1909 елның 7 гыйнварында авылдашы Нуриәхмәт Равил улының кызы Нурсафа (17 яшь) белән гаилә кора. Кияүнең ризалык шаһитлары – Сәетгәрәй Арслангәрәй улы белән Мөхәммәткашшаф мулла Габделҗәмил хәзрәт улы, кызныкы туганнары Нурмөхәммәт белән Нургали Равил уллары була. Әлеге никахтан Солтангәрәй балалары: Әхмәтгали (16.09.1906), Мөхәммәтгәрәй (20.05.1910–1910), Мәдинә (26.11.1914–1916). Солтангәрәй Батыргәрәевне (30 яшь) Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда йортында хатыны (25 яшь) һәм улы кала, 1917 елда гаиләсе нибары 0,80 дисәтинә җир эшкәртә, мал-туар асрамый.

Сәетгәрәй Арслангәрәй улы Нөрмәтов балалары: Шагали (29.05.1889; анасы Кафия Хөснетдин кызы), Саимә (25.02.1894; анасы Гыйльмикамал Шәймәрдән Булатов кызы), Хәкимә (11.09.1897), Хуҗагали (25.02.1901), Мөхәммәтгали (19.03.1904), Фәрхебану (01.05.1905–1906; анасы Шәмсебану Миңлегали кызы), Гайнелхәят (01.10.1907; анасы Гыйльмикамал Шәймәрдан кызы). Сәетгәрәйнең икенче никахы авылдашы Шәймәрдән Булатов кызы Гыйльмикамал (17 яшь) белән 1890 елның 19 мартында була. Сәетгәрәй кызы Саимә (17 яшь) 1910 елның 23 декабрендә Кадернең Әхмәтгәрәй Әхмәтвәли улы (22 яшь; атасы Әхмәтвәли Галиулла улы) белән никахлаша. Шул ук Саимә 1913 елда Иштирәкнең Минһаҗетдин Сиражетдин улы (45 яшь; икесенең дә икенче никахлары) белән кавыша. Сәетгәрәй Арслангәрәев (55 яшь) 1917 елда хатыны (45 яшь), ике улы һәм өч кызы белән яши, 10,26 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры һәм башка маллары була.

Сәетгәрәй кызы Хәкимә (1897–1938) Иштерәкнең Гыймазетдин Миназовка (1894–1986) кияүгә чыга, балалары Нәзирә (1925–2008; ире – Миргаяз Камалетдинов (1924–1983), Гарәфетдин (1927; хатыны – Нажия (1923–1998)) туа. Нәзирә балалары: Нәзилә (1959), Гөлбостан (1964), Альфир (1966). Гарәфетдин балалары: Фәрит (1952–2017), Ләис (1957), Фәйләс (1960), Флүсә (1962). Сәетгәрәйнең икенче кызы Гайнелхәят авылдашы Галимәрдан Ханнанов белән гаилә кора.

Хуҗагали Сәетгәрәй улы Арсланов (1901) сугышта хәбәрсез югала, балалары Әфтах (1936; укытучы), Венера (1938) һәм Фәния (1940) кала. Әфтах абый хатыны Зоя (Галим Хафизов кызы; фельдшер) белән өч бала – Азат (1961), Клара (1963), Зилә (1971) – тәрбияләп үстерә. Азат Бакалыда яши, хатыны Нәфисә (1961), балалары Илнур (1987) һәм Айнур (1989). Клараның Вадим исемле улы

бар. Зилә Казанда яши, тормыш иптәше танылган җырчы Айдар Габдинов, балалары Айсылу, Ильяс, Мансур.

Мөхәммәтгали Арсланов (1904) колхозда тракторда эшли, 1940 елның 10 декабрендә гаиләсе белән Бурят-Монголиягә бәхет эзләп чыгып китә, сугыш башлангач хатыны Мәсүрүрә (1908), уллары Фәһим (1928), Фәнис (1933), Индус (1938), кызы Наиләне (1942) авылда калдырып, фронтка китә, исән кайта. Сугыштан кайткач кызы Вәзиха туа.

Фәһим Арсланов та әтисе кебек тракторчы һөнәрен үзләштерә, авылдашы Тәрҗимә Исламгали кызы белән гаилә кора, тик гомере кыска була. Өч бала — Рәсимә, Зимфира, Фәнил — әтисез үсә, әмма әниләренең һәм үзләренең тырышлыгы белән тормышта юл салалар. Рәсимә белән Зимфира җитмешенче елларда татар теле һәм әдәбияте буенча Казан югары уку йортларында читтән торып укыйлар, гаилә коралар. Әтисе кебек, Фәнил дә кыска гомерле була, 28 яшьтә фаҗигагә тарый.



**Тәрҗимә Исламгали кызы Арсланова балалары белән**

Рәсимә Фәһим кызы Шәйдуллина әти-әнисе язмышын болай искә ала: «Әнием Арсланова Тәрҗимә Исламгали кызы (1928–2008) Яңа Катайда ишле гаиләдә дүртенче бала булып дөньяга килә. 1936 елда беренче класска укырга керә, «5»ле билгеләренә генә укый. Сугыш башлануга әтиләре Мәннапов Исламгалине тыл хезмәтенә алалар. Дүрт классны тәмамлаган кыз «Яңа тормыш» колхозында төрле эшкә йөри башлый, ә 1947 елдан фермада савучы булып эшли. 1951 елда Арсланов Фәһимгә кияүгә чыгып, матур гына яши башлауга, әтиебез салкын тидерә һәм шифаханәдә дөрес дәва алмыйча, 1956 елда мәрхүм була. Әниебез өч бала белән кала, кечесенә нибары ике генә ай була. Дөнья көтү парлы кешегә дә авыр вакытта, ул ирләр белән беррәттән ат жигеп печән, салам өю эшенә йөри. Балаларга күрше-күлән, туганнары ярдәм кулын сузалар. Ул чакта Катай халкының ярдәмчеллегенә исең китәрлек! Кибеттә ипинең дә җан башына бүлеп бирелүен исәпкә алсаң, ирсез хатынның тормышын, нинди авырлыклар белән балалар тәрбияләвен күз алдына китерү кыен булмас. 1961 елдан совхозда төрле эштә йөри. Ул вакытларда сәбәпсез эш калдыру юк иде. Трактор чаналарында

утын, печән-салам ташуда ирләр белән хатын-кызлар беррәттән эшләделәр. Язгы чорда симәнә агулауда алар йөрде. Яхшы эшләгәне өчен әнием берничә тапкыр рәттән авыл советына депутат булып сайланды. 1971 елдан дуңгызчылык фермасында эшләде, тырыш хезмәте өчен 1973 елда «Социалистик ярыш җиңүчесе» билгесе белән бүләкләнде, зур итеп агачтан өй салды, 1992 елда лаеклы ялга чыкты. Менә шулай гади генә авыл кызы намуслы хезмәт итә, зур авырлыкларны җиңеп сокланырлык тормыш юлы үтә. Авылыбыз шундый шәхесләр белән горурлана ала!».

Шулай итеп, Габделкәрим Нөрмәтовның өченче улы Мөхәммәдьярдан нәсел шактый ишәя. Мөхәммәдьярның төпчек улы Мөхәммәтвәлидән Мөхәммәтзакир (1852–10.08.1916) күрсәтелсә дә, аның 1875 елның 5 гыйнварында авылдашы Гыйсмәтулла Хәсән улының кызы Шәмсебану (18 яшь) белән никахыннан балалары булмый ахры.

Габделкәрим Нөрмәтовның дүртенче улы Габделбәшәрнең ир балалары: Миңлехан (1824), Шәйхелислам (1832), Шәймөхәммәт (1843–01.05.1909).

Миңлеханның 1859 елда хатыннары Сәхипбану белән Шәмсиҗамал, уллары Сәлигаскәр (метрикәдә Сәригаскәр; 1847), Шәйхаттар (1849–1851), Шәйхелмансур (1851–18.09.1915), Шәехшәвәли (1853), Фәхрелислам (1853) һәм ике кызы теркәлгән. Болардан тыш, төпчек бала булып Казыйхан (1884) дөньяга килә.

Сәригаскәр Миңлехан улы балалары: Миңлемәдхиҗиһан (20.06.1877), Бибимәмдуха (1884), Бибимәфтуха (06.02.1889–1910; анасы Хәмдесафа Габделнәфикъ кызы), Мәүлиха (1891), Фәхерҗиһан (1896), Габделфаяз (12.12.1901–1902; анасы Шәрифә Миңлегәрәй кызы), Хәтимә (12.02.1904; анасы Фатиха Гыйззәтулла кызы), Галиәкбәр (28.04.1907–1907). Сәригаскәр кызы Бибимәмдуха (17 яшь) 1901 елның 2 августында Тыпыйның Саяфетдин Фәйзулла улына (25 яшь) кияүгә чыга. Икенче кызы Мәфтуха (17 яшь) 1905 елның 15 ноябрендә авылдашы Миңлеәхмәт Миңлегәрәй улы (37 яшь; икенче никах) белән никахлаша. Сәригаскәр 1908 елның декабрендә бер-бер артлы ике кызын кияүгә бирә: Мәүлиханы (17 яшь) – Килкабызның Сәйфетдин Шәмсетдин улына (25 яшь), Мәмдуханы (22 яшь; икенче никах) Тыпыйның Гыйлемхан Мөхәммәтситдыйкъ улына (30 яшь; икенче никах). Беренче кызы тол калып, 1911 елның 20 февралендә авылдашы Муллагали Фәрукша улы (30 яшь) белән кавыша. Икенче кызы Мәмдуха Тыпыйдан кайтып, 1909 елның 15 маенда Килкабызның Мөхәммәтхарис Мөхәммәтзариф улы (35 яшь; өченче никах) белән кавыша. Сәригаскәрнең төпчек кызы Фәхерҗиһан (17 яшь) 1913 елның 6 гыйнварында Иске Катайның Фәхрелислам Гыйрфанетдин улы (26 яшь) белән кавыша. Сәригаскәр Миңлеханов (70 яшь) 1917 елда хатыны (60) һәм кызы (14) белән яши, 10,02 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм башка маллары була.

Шәйхелмансур Миңлехан улы балалары: Шәйхелгали (16.02.1878), Фәрхинур (02.12.1880; анасы Шәмсенәһар), Фәрхинур (1882), Шәехгали (25.03.1883), Маһинур (1884–21.04.1905; анасы Шәмсекамәр Йөзекәй кызы), Маһисорур (07.03.1889), Бибинур (30.05.1893–1894; анасы Бибизәйнәп Гыйлаҗетдин

Мөхәммәткәрим улы Күчемов кызы), Бибисорур (02.10.1895), Әхмәтгали (14.02.1898), Маһисорур (Майсорур; 1899), Бибинәгыймә (02.06.1900–1901), Сәрвиҗиһан (25.12.1901), Фәрхиҗиһан (10.06.1904), Хаҗгали (14.10.1906), Шәмсеҗиһан (27.12.1908–1909), Шәйхенур (10.01.1911), Шәехзаман (03.10.1913). Шәйхелмансур кызы Фәрхинур (17 яшь) 1899 елның 1 декабрендә Камышлытамакның Габдулла Габделмән улы Габделлатыйпов (20 яшь) белән гаилә кора. Икенче кызы Маһинур Мөхәммәтрәиф мөәзин Мөхәммәтлатыйф улы Күчемов белән никахлаша. Маһинур 1905 елның апрелендә вафат булгач, Шәйхелмансурның өченче кызы Майсорур (18 яшь) шул ук елның декабрендә мөәзин Мөхәммәтрәиф белән никахлаша. Шәйхелмансур Миңлехановның (65 яшь) ике улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда 11,88 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сарыгы, кәҗәсе була.

Әхмәтгали Мансуров (1898) Ватан сугышы алдыннан колхоз рәисе урынбасары вазифасын башкара, сугышка киткәндә хатыны Хөсниҗамал (1892), кызы Гайшә (1928), улы Тимергали (1932) була. Әхмәтгали – сугыш корбаны, хәрби хезмәткә 1942 елда чакырыла һәм шул елны хәбәрсез югала (Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Хаҗгали Мансуров (1908) 1942 елның октябрендә Ватан сугышында хәбәрсез югала (Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән), хатыны Рәхимә (1905), балалары Мәгънәви (1929), Рәшидә (1927), Ридәнә (1937), Мәвәзинә (1940) кала.

Шәйхенур Мансуров (1911) – «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале белән бүләкләнгән Ватан сугышы ветераны, сугышка чаклы хатыны Закирә (1917), уллары Галинур (1939), Җәмигънур (1941) белән яши. Риф Шәйхенур улы Мансуров 1977 елда Яңа Катай буенча сайлау комиссиясе рәисе була. Шәйхенурның энесе Шәехзаман Мансуров хәрби хезмәткә 1940 елда чакырыла, 1942 елның мартында хәбәрсез югала (Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән), хатыны Гадәвия тол кала.

Шәехгали Шәйхелмансур улы (21 яшь) 1905 елның 10 февралендә авылдашы Әхмәтвәли Дәүләтша улының кызы Хәкимә (17 яшь) белән никахлаша, балалары Саимә (05.01.1906), Муллагали (01.12.1907), Миңлегали (20.02.1909–1910), Бәһия (11.03.1911), Бибинур (29.01.1914–1916), Әһлия (26.03.1917), Мөхәммәтгали (1919) туа. Мөхәммәтгали Мансуров – Ватан сугышы ветераны.

Миңлеханның дүртенче улы Шәехшәвәлигә күчик. Шәехшәвәли Миңлехан улы Нөрмәтов балалары: Бибисара (02.12.1880), Шәмсеҗиһан (19.08.1889), Исламгали (1890), Шәмсегали (26.07.1894; анасы Фатыйма Хөснетдин мулла Әүдияр улы Азаматов кызы), Хәсәнгали (19.05.1897), Бибисорур (04.07.1905–1912). Шәехшәвәли кызы Бибисара 1898 елның ноябрендә авылдашы Солтангәрәй Дәүләтгәрәй улы Мортазин белән гаилә кора.

Исламгали Шәехшәвәли улы (25 яшь) 1916 елның 24 апрелендә Тыпыйның Бибизарифа Баһаутдин кызы (40 яшь; өченче никах) белән никахлаша. Сугыш алдыннан Исламгали Шәвәлиев гаиләсендә хатыны Нәгыймә (1890),

улы Шәйхали (1922), кызлары Назира (1928), Рәзинә (1935) була. Аталы-уллы Исламгали белән Шәйхали Ватан сугышына китәләр, язмышлары билгесез (исемнәре Катайның мемориаль стеласында теркәлмәгән).

Фәхрелислам Миңлехан улы балалары: игезәкләр Хәерзаман белән Бибимәсүрә (24.10.1889; анасы Мөхәммәтлатыйф кызы), Шәехзадә (02.06.1894; анасы Хөснибану Җиһанша Габделлатыйф улы Азаматов улының кызы), Шәехәгъзам (06.03.1895; анасы Хәйрәтмән Әхмәтшәфикъ Габделхаликъ улының кызы), Бибимөнәвәрә (05.01.1897), Шәехсолтан (30.07.1899). Фәхрелислам 1894 елның 29 мартында хатыны Хөснибану (атасы Җиһанша Габделлатыйф улы Азаматов) белән аерылыша («мәхәббәт вә өлфәт булмаган сәбәпле») һәм яңа гаилә кора. Фәхрелислам Миңлеханов 1917 елда хатыны (45 яшь), улы һәм кызы белән яши, 5,28 дисәтинә җире, аты, сыеры була.

Миңлеханның төпчек улы Казыйхан иде. Казыйхан Миңлехан улы балалары: Әхмәтхан (22.09.1911; анасы Бибикамилә Мөхәммәтәмин кызы), Әминә (04.08.1914–1915). Казыйхан Беренче бөтендөнья сугышында 37 нче Екатеринбур пехота полкы составында катнаша, 1915 елның 25 июлендә яралана. Казыйхан сугыш алдыннан хатыны Камилә (1880), улы Әхмәтхан, килене һәм оныклары белән яши. Аның улы Әхмәтхан Казыйханов Ватан сугышы алды елларында колхозда бригадир булып эшли, 1943 елда сугышта хәбәрсез югала, хатыны Рабига (1914), балалары Мөнәвир (1939), Фәнил (1942) кала.

Монда бер искәрмә ясап үтик. Ватан сугышы алдыннан Шәмсия Әхмәтова (1890) гаиләсендә Хатмизиян (1912, сыер савучы), Табирә (1914, авырту) һәм Зөлфән (1936) теркәлә. Зөлфәннең атасы – Әхмәтхан Казыйханов, анасы Хатмизиян (Килкабызныкы) була. Шулай итеп, югарыда телгә алынган Мөнәвир белән Зөлфән аталары ягыннан бертуган булып чыга («ата бер, ана башка» дип әйтәләр бу очракта). Зөлфән Иске Катайның Мөхәммәтхәтим Харисов кызы Ханә белән гаилә кора, бүгенге көндә Октябрьский шәһәрендә яшиләр.

Габделбәшәр Габделкәрим улы Нөрмәтовның икенче улы Шәйхелислам да нәсел калдыра. 1859 елда аңа 27 яшь, хатыннары Шәмсеҗиһан Моратша кызы (26 яшь) һәм Миңлекамал Җамалетдин кызы (26 яшь) була. Шәйхелислам Габделбәшәр улы балалары: Тәминдар (1857), Зөләйха (1868), Зөлхиҗә (1873), Фәхразый (25.03.1877; анасы Бибикамал), Миңлегали (10.08.1880; анасы Бибикамал), Казыйхан (1906). Шәйхелислам кызы Зөлхиҗә (17 яшь) 1890 елның 19 ноябрендә Сеңрәннең Мөхәммәтхуҗаҗан Мөхәммәтҗан улы (23 яшь) белән никахлаша.

Тәминдар Шәйхелислам улы Нөрмәтов балалары: Гайникамал (1893–1894), Казыйхан (10.03.1895), Гыйлемхан (20.05.1897; анасы Хәсәнкамал Әхмәтҗан кызы), Хәдимә (19.03.1902), Әмирхан (20.02.1906). Әмирхан Тәминдаров (1906) сугышта хәбәрсез югала, хатыны Мөхипҗамал (1905), кызлары Җәүһәрия (15.02.1932) һәм Мөхәссәнә (1938) кала. Җәүһәрия Иске Катайның Хыялетдин Сираев белән гаилә кора.

Фәхразый Шәйхелислам улы балалары: Хәлимә (09.05.1904; анасы Бибикамилә Бикмөхәммәт кызы), Казыйхан (30.10.1906; Ватан сугышы ветераны), Әмирҗан (27.04.1909–1909), Нәгыймә (19.04.1910–1913), Газимә (15.08.1913–1914), Галимҗан (29.01.1915), Фатыйма (1922–1925). Фәхразый Шәйхелисламовны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (42 яшь), ике улы, кызы һәм анасы (70) кала. 1917 елда 7,56 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һәм башка маллары була, хезмәтче яллаган.

Казыйхан Фәхразый улы балалары: Мәгънәви (1928–1994), Аманулла, Рәшидә, Фатыйма (1936), Вәгыйз (1942–2009), Вәрис (1942) Исламовлар. Мәгънәвинең хатыны Мөслимә Шәкүр кызы (1930–2010), балалары Марат (1958), Фоат (1960). Бу мәгълүматны Маратның хатыны Зимфира Насыйх кызы Исламова язып җибәрде.



**1895 елгы никах язуы тамгалары Нурлыгаян Нөрмәтовның Иске Катайдагы ерак нәселдәше белән гаилә коруын раслый**

Габделкәрим Нөрмәтовның бишенче улы Шаһиәхмәттән (1800–1829) нәселне Нурмөхәммәт (1829) дәвам итә. Нурмөхәммәт балалары: Нургали (Нурлыгали; 1871), Нурлыгаян (29.04.1875; анасы Маһиҗамал).

Нургали Нурмөхәммәт улы Нөрмәтов (24 яшь; вәли вәкиле – Нурлыгаян Нурмөхәммәт улы) 1895 елның декабрендә Иске Катайның Миңлегали Рамазан улының кызы Шәмсекамәр (18 яшь) белән никахлаша. Нургали балалары: Миргали (01.03.1901–1902), Мөшәррәфә (27.10.1903; хатыны Мохлифә Ширгазетдин кызы), Хаҗгали (27.04.1907), Хуҗагали (07.01.1911), Бибимөкәррәмә

(11.08.1914). Нургали Нурмөхәммәтов 1917 елда хатыны (40 яшь), ике улы һәм ике кызы белән яши, 2,53 дисәтинә җире, 2 аты була.

Нурлыгаян Нурмөхәммәт улы Нөрмәтов 1901 елның 2 гыйнварында авылдашы Габделгазиз Габделфәез улының кызы Хәтирә (17 яшь) белән никахлаша. Нурлыгаян балалары: Хәтимә (09.01.1902; анасы Хәтирә), Кифая (10.01.1904; анасы Латыйфа Мөхәммәтша кызы), Кәшифә (20.09.1907), Бәдигъша (17.11.1910), Фәхрелгаян (16.06.1914–1915). Нурлыгаян (27 яшь; икенче никах) 1904 елның 20 апрелендә Корычның Мөхәммәтша Мөхәммәтҗан улының кызы Латыйфага (20 яшь; өченче никах) өйләнә. Нурлыгаян Нурмөхәммәтовны Беренче бөтендөнья сугышына алалар, йортында хатыны (30 яшь), улы һәм өч кызы кала, 1917 елда 3,53 дисәтинә җире, кәҗәсе була.

Габделкәрим Нөрмәтовның төпчек улы Шәймәрдан (Шаһимәрдан; 1805) иде. 1859 елда ул хатыннары Сәрвиҗамал Тимербай кызы (50 яшь) һәм Шәмсеҗиһан Монасыйп кызы (55), күпсанлы балалары белән гомер итә. Шәймәрданның беренче хатынынннан уллары – Шәйморат (Шаһиморат; 1834–23.01.1909), Шәяхмәт (Шаһиәхмәт; 1836), Шәйхулла (1840–20.09.1906), Сәетбаттал (1843–19.05.1876), икенче хатынынннан Шәймәрван (Шаһимәрван; 1834), Шәнгәрәй (Шаһингәрәй; 1836–22.01.1904), Шәйхетдин (1839–23.12.1906) була. Шәнгәрәй Шәймәрдан улы балалары: Солтангәрәй (21.11.1883; анасы Шәмсекамал), Бибиҗамал (1888–1889). Солтангәрәй Шәнгәрәй улыннан Әкълимә (1901–1901) билгеле.

Шәймәрданның беренче улы Шәйморат иде. Шәйморат Шәймәрдан улы балалары: Шәйхелгаттар (1871), Бибилатыйфа (1872), Шәймөхәммәт (10.08.1880; анасы Бибифатыйма), игезәкләр Шагали (15.09.1883) белән Фәхерҗамали (15.09.1883). Шәйморат кызы Бибилатыйфа (18 яшь) 1894 елның 18 декабрендә авылдашы Әхмәтзәки Җиһангир улы Азаматов (23 яшь) белән никахлаша. Шул ук Бибилатыйфа (27 яшь; икенче никах) 1899 елның 29 октябрендә авылдашы Габделхаликъ Йөзәй улы Солтанбәков (45 яшь; өченче никах) белән кавыша. Бибилатыйфа бу ирендә озак тормый, 1901 елның 1 гыйнварында Иштирәкнең Миңлехан Шәйморат улына (35 яшь; икенче никах) тормышка чыга.

Шәйхелгаттар Шәйморат улы Нөрмәтов (23 яшь) 1895 елның 24 гыйнварында авылдашы Кәлимулла Гайнулла улы Аетов кызы Фәрхенур (17 яшь) белән кавыша. Кияүнең вәкиле – атасы Шәйморат Шәймәрдан улы, ризалык шаһитлары нәселдәшләре Сәетгәрәй Арслангәрәй улы белән Җиһангир Әделгәрәй улы була. Шәйхелгаттар Шәйморат улы балалары: Шәйхенур (1899; Ватан сугышы ветераны), Шәмсенәһар (05.08.1902; анасы Шәмсеҗамал Габдерәхим кызы), Габделгаффар (14.11.1905), Сәхипҗамал (05.01.1909–1909, ютәлдән вафат), Гайниҗамал (20.11.1910–1912; анасы Шәмсеҗиһан Габдерәхим кызы), Шәехбостам (22.09.1913; анасы Шәмсеҗамал Габдерәхим кызы). Болар Чүмәлә Катайда Шәйхаттаров дип теркәлгәннәр.

Шәймәрданның икенче улы Шәяхмәтнең язмышы билгесез, өченче улы Шәйхуллага күчәбез. Шәйхулла Шәймәрдан улы Нөрмәтов балалары: Шәйхелгаттар, Мөхәммәтшәех (Шәех; 1875), Миңлесафура (20.12.1877), Хәйрелхәят (1879), Хәдичә (20.08.1880; анасы Шәмсениса), Миңлемәгъфүрә (17.09.1883), Сөләйман (1886), Шәехзаман (09.11.1890; анасы Фәхрениса Фәхрулла кызы). Шәйхулла кызы Миңлесафура 1894 елның 12 ноябрендә авылдашы Әхмәтгәрәй Миңлегәрәй улы Булатов (22 яшь) белән кавыша. Икенче кызы Хәйрелхәят (19 яшь) 1899 елның 25 июнендә Тыпыйның Зәйнелгабидин Мофаздал улы Кабаев (25 яшь) белән никахлаша. Кызның ризалык шаһиты туганы Шәйхелгаттар Шәйхулла улы була.



**Кыз тарафыннан вәкил Шәйхулла Шәймәрдан улы тамга салган. Тамга Юлдаш нәселенеке белән тәңгәл килә**

Шәйхелгаттар Шәйхулла улы Нөрмәтов балалары: Хәмдениса (1897), Шәйхенур (19.12.1899), Саимә (07.11.1903; анасы Шәрифә Мөхәммәтсадыйк кызы), Хаҗинур (30.01.1907–1909), Гайниҗамал (20.11.1910; анасы Шәмсеҗиһан Габдерәхим кызы). Шәйхелгаттар кызы Хәмдениса 1915 елда Тыпыйның Миңлегали Габделгазиз улы (49 яшь; өченче никах) белән никахлаша, 1916 елда аннан кайтып, Килкабызның Фәтхелислам Нуриәхмәт улы (40 яшь; икенче никах) белән кавыша. Шәйхелгаттар гаиләсе белән Чүмәлә Катайга күчеп утыра, анда аның улы Шәйхенурның балалары (Хаҗинур, 1925 һәм башкалар) дөньяга килә.

Мөхәммәтшәех Шәйхулла улы Нөрмәтов балалары: Мәрзия (1898–1901), Миңлехәтимә (06.06.1899; анасы Фатыйма Фәхретдин кызы), Әбәдия (06.02.1904–1905; анасы Хәмдия Мофаздал кызы), Бибихәлимә (22.08.1906–1909), Нәгыймә (29.10.1909).

Сөләйман Шәйхулла улы (25 яшь) 1911 елның гыйнварында нәселдәше Шәйхелмансур Миңлехан улының кызы Майсорур (23 яшь; икенче никах) белән никахлаша, балалары Мәргубә (20.11.1911–1912), Мәдинә (08.08.1913) туа.

Югарыда сүз Шәйхулла уллары турында барды. Шәйхулла 1906 елның 30 сентябрендә дөнья куя. Метрикә кенәгәсендә икенче мәхәллә имамы

Габделҗәмил Мөхәммәтҗан улы Күчемов кулы белән Шәйхулланың атасы Шәймәрдан Габделкәрим улы дип язылган. Бу мәгълүмат аеруча әһәмиятле, чөнки русча чыганакларда Шәймәрданның атасы Карый, ә фамилиясе Кариев дип бозып күрсәтелә.

Габделкәрим Нөрмәтовның төпчек улы Шәймәрданнан бишенче булып Шәймәрван (1834) туганын белгән идек. Шәймәрван Шәймәрдан улы балалары: Шәйсолтан (1865), Фәрхиҗиһан (1866), Шәйгардан (1870), Шәйхеразый (1876), Шәйхелислам (1879), Шәймөхәммәт (25.07.1894; анасы Салиха Шәймәрдан кызы), Гыйльмиҗиһан (12.04.1897). Шәймәрван кызы Фәрхиҗиһан (17 яшь) 1883 елда авылдашы Газетдин Хөснетдин улы белән никахлаша, кызның ризалык шаһитлары Шәйсолтан Шәймәрван улы белән Шәехмансур Миңлехан улы була.

Шәйсолтан Шәймәрван улы Нөрмәтов балалары: Шагали (1888), Сәрия (16.07.1893–1913), Галия (1898–1914), Бибинәгыймә (25.02.1900), Хуҗагали (09.06.1903–1905), Хаҗгали (02.03.1906; анасы Мәхәүлия Габделханнан кызы), Мосаллия (27.11.1909). Шәйсолтан кызы Сәрия (17 яшь) 1910 елның 4 мартында Сеңрәннең Хәйрулла Гарифулла улына (24 яшь) кияүгә чыга. Икенче кызы Нәгыймә (18 яшь) 1917 елның 5 февралендә Тыпыйның Акмалетдин Гыйльметдин улы (35 яшь; өченче никах) белән кавыша. Соңгысында кызның ризалык шаһитлары Сәлимгәрәй Дәүләтгәрәй улы белән Шагали Шәйсолтан улы була. Шәйсолтанның олы улын Беренче бөтендөнья сугышына алалар, 1917 елда хатыны (55 яшь), кече улы һәм ике кызы белән яши, 4,07 дисәтинә җире, аты, сарыгы, кәҗәсе була.

Шәйсолтан улы Шагали (25 яшь) 1913 елның 25 февралендә Казан губернасы Мамадыш өязе Сатыш авылының Мөхәммәтзакир Бикмөхәммәт улының кызы Нәгыймә (17 яшь) белән никахлаша. Ватан сугышы алдыннан Шагали Солтанов гаиләсендә хатыны Шәмсезиян (1890), уллары Исламгали (1932), Кави (1934), Фәнәви (1938) һәм ике кызы була.

Шәйгардан Шәймәрван улы (20 яшь) 1890 елның 11 октябрендә авылдашы Габделгани Габделкәрим улының кызы Бибифакия (17 яшь) белән никахлаша, балалары Шәйхәйдәр (23.07.1893), Галиәхмәт (03.08.1900), Хаҗиәхмәт (08.09.1903–1904), Бибифәүзия (13.04.1905), Сәвия (1906–1909, кызамыктан вафат), Әбәдия (04.03.1908–1909; кызамыктан), Хуҗаәхмәт (13.10.1912), Миңленәкыя (25.12.1915) туа. Галиәхмәт Гарданов 1943 елда Ватан сугышында һәлак була, хатыны Сәрбикамал (1904), кызлары Саҗидә (1927), Мәгъдәния (1930), Мәгъсүмә (1932), Вәзиха (1937), Вәзимә (1939), Вәсилә (1941) кала.

Галиәхмәт Гардановның энесе Хуҗаәхмәт «Халык хәтере» сайтында «Гарданов Хузахмет Марванович» дип теркәлгән. Болай язуда төгәлсезлек шунда, Мәрван – Хуҗаәхмәтнең атасы түгел, ә бабасы. Ефрейтор-разведчик Хуҗаәхмәт Гарданов сугышта батырлык күрсәтә, «Кызыл Йолдыз» ордены (19.02.1945) һәм ике тапкыр «Батырлык өчен» (29.11.1942 һәм 20.08.1944) медале белән бүләкләнә. Орден белән бүләкләү документында аның 1945 елның

гыйнвар аендагы сугышларда 11 дошман солдатын дөмектерүе, 5 солдатны һәм 1 офицерны әсирлеккә алуы турында әйтелә. Беренче китапта кайсыдыр чыганакка таянып Хаҗиәхмәт дип язган идем, метрикәдә мулла кушкан исеме Хуҗаәхмәт булып чыкты.

Шәйхеразый Шәймәрван улы (26 яшь) 1902 елның 30 октябрендә авылдашы Габделбәшир Габделгаффар улының кызы Гыйльмезадә (17 яшь) белән никахлаша, балалары Гыйльмебану (19.11.1904–1905), Имамразый (1910–1912), Гаширә (05.08.1913) дөньяга килә.

Шәйхелислам Шәймәрван улы Нөрмәтов (26 яшь; икенче никах) 1905 елның 7 октябрендә авылдашы Әбүбәкер Миңлегол улының кызы Зәкия (17 яшь) белән никахлаша, кызның агасы Шәйхелислам Миңлегол улы вәли вәкил була. Бу никахтан Шәйхелислам балалары: Бибисания (09.12.1906), Гөлчирә (25.06.1907), Бибифакия (25.02.1909–1914), Нурислам (28.09.1912–1915), Тимергали (16.10.1915; анасы Бибизәкия Әбүбәкер кызы). Шәйхел Мәрванов (1878) Ватан сугышы алдыннан хатыны Зәкия (1883), улы Тимергали (1915) белән яши. Тимергалине 1942 елның гыйнварында хәрби хезмәткә чакыралар, күпмедер вакыттан кайта (сәбәбе күрсәтелмәгән).

Бу бүлектә алдарак сүз барган никах язуындагы тамгага игътибар итик. Ул Иске Катайның Юлдаш нәселенеке белән тәңгәл килә, димәк, кайчандыр нөрмәтнекеләр белән юлдашныкылар бер тамырдан чыгып, тармакланып киткәннәр. Катайны икегә бүлгәндә Нөрмәтнең Кәриме һич кенә дә Матының икенче ягына күченәсе килмәгән, арбасы белән күтәреп чыгарганнар, имеш. Төп сәбәп нәселдәшләреннән аерыласы килмәүдә түгелме икән?

Монысы риваять булды. Икенчесе – эчтәлеге аз билгеле документ. Ул чыганакта Юлдаш карт варисларының XVIII гасыр ахырында башкорт сословиесенә күчергә теләп гариза («прошение») язулары хакында әйтелә («Үткәннәрен бел Катайның» китабыннан кара). Нөрмәтнекеләр бу сословиедә булганда, аларның да «башкорт» булырга хакы бар дип язмадылармы икән алар?

Бу сорауларга без берничек тә җавап таба алмыйбыз. Әнә шундый җавапсыз сораулар булуга карамастан, кечкенә ачышлар белән авылыбыз һәм нәселләребез тарихы үзенә җәлеп итә, яңадан-яңа эзләнүләргә этәрә.

*Кушымта*

***Таблица 1***

***III ревизия (1762 ел) документы. Катай авылының ясаклы татар сословиесендәге ир-атлары***

| № | Исеме, фамилиясе | Яше |
|---|---|---|
| 1. | Табыш Абдуллин | 52 |
| | Аның балалары: | |
| | Мөэмин Табышев | 21 |
| | Ягъфәр Табышев | 18 |
| | Баязит Табышев | 10 |
| | Бяиз (?) Табышев | 4 |
| 2. | Мөслим Рысаев | 91 |
| | Аның улы Нәдер Мөслимов | 53 |
| | Нәдернең улы Зәйнелгабидин Нәдеров | 19 |
| 3. | Хөсәен Айтуков | 67 |
| | Аның улы Бикбулат Хөсәенов | 18 |
| 4. | Ает Бикчурин | 84 |
| | Аның балалары: | |
| | Мостафа Аетов | 6 |
| | Мөстәкыйм Аетов | 4 |
| 5. | Ямангол Мәсгутов | 17 |
| 6. | Ибраһим Госманов | 38 |
| | Аның балалары: | |
| | Морат Ибраһимов | 18 |
| | Морадым Ибраһимов | 3 |
| | Мәхмүт Ибраһимов | 1 |
| 7. | Ает Биккенин | 37 |
| | Абдул Аетов | 3 |
| | Аның бертуганы Рәмәй Сәетов | 10 |
| | Исламай Сәетов | 6 |
| 8. | Җанибәк Йувашкин | 75 |
| | Аның балалары: | |
| | Галибәк Җанибәков | 36 |
| | Гыйбадулла Җанибәков | 4 |
| | Галибәкнең улы Зәйсан Галибәков | 8 |
| 9. | Атнагол Монаитмасов | 10 |
| 10. | Акбай Янбулатов | 35 |
| 11. | Мөтек Алдаров | 76 |
| | Аның улы Ишкуәт Мөтеков | 21 |
| 12. | Зәет Йортбагышов | 52 |
| | Аның балалары: | |
| | Гомәр Зәетов | 24 |
| | Гомәр (?) Зәетов | 21 |
| | Гайсар Зәетов | 14 |

*Таблица 1 (дәвамы)*

| № | Исеме, фамилиясе | Яше |
|---|---|---|
| 13. | Тимер Йортбагышев | 41 |
| 14. | Арслан Юлдашев | 56 |
| | Аның улы Кылчан Арсланов | 20 |
| | Сөяргол Юлдашев | 41 |
| | Аның улы Сөендек Сөярголов | 3 |
| | Сәлим Юлдашев | 52 |
| | Аның балалары: | |
| | Баис (Баязит. – *Т.К.*) Сәлимов | 14 |
| | Әсәй Сәлимов | 1 |
| 15. | Көсәкәй Шыгаев | 69 |
| | Аның улы Үтәмеш Көсәкәев | 24 |
| | Әлеге исемлекнең ахырында түбәндәгечә язылган: «Деревни Катаевой без утайки объявил я выборной Ибрагим Усманов, подписку дал и тамгу приложил, в том я староста Табыш Абдуллин подписку дал и тамгу приложил»<br>Чыганак: Россия борынгы актлар дәүләт архивы, 350 фонд, 2 тасв., 3801 сакл. бер., 446, 447 битләр. | |


